# КАЗАН УТЛАРЫ

7.1990



## ЖУРНАЛ АЛДЫРУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Журналның брак саны килгән очракта аны газета-журналлар нәшриятының техник контроль бүлегенә җибәрүегезне үтенәбез. Адресы: *420066, Казань, ул. Декабристов, 2, Типография ГЖИ, ОТК.*

Редакция журнал җибәрү белән шөгыльләнми.

Әгәр журналның теге яки бу саны килми калса, «Союзпечать»нең җирле бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу мәсьәлә редакция вәкаләтенә керми.

Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР
БЕРЛЕГЕ
ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

1990

7

(813)

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

А. ГЫЙЛӘЖЕВ. Балта кем кулында? *Роман.* . . . . 3
Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Йөрәгемне эзлим. *Поэма.* . . 100
М. ХӨСӘЕН. *Сонетлар.* . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Сарман балладасы. *Повесть.* . .108
Д. ХӘЙРУЛЛИН. Күлле шәһәр. *Шигырьләр.* . . . . . . 122
Р. МИҢНУЛЛИН. Балалар өчен шигырьләр. . . . . 125

ХИКӘЯЛӘР ЯРЫШЫ

И. НИЗАМОВ. Колаксыз Зариф. *Хикәя.* . . . . . . . . . 127
Ә. ГАФФАР. Утын. *Хикәя.* . . . . . . . . . . . . . . . . 134

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. ЗӨЛКАРНӘЙ. «Арын көн дә коллыгыңнан!» . . . 139
Тукайлар рухы *(язучы һәм режиссер Р. Батулла белән әңгәмә).* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Х. ТӨХФӘТУЛЛИН. Камил Мотыйгый. . . . . . . . . 152
Р. МОСТАФИН. Г. Ибраһимовның соңгы көннәре. . . 166
М. ӘХМӘТҖАНОВ. Мәгърифәтче Шәмсетдин Күлтәси хакында яңа мәгълүматлар. . . . . . . . . . . . . 172

СӘНГАТЬ

Ф. ӘХМӘТОВА. Мәңгелеккә юл. . . . . . . . . . . . . 175

ТАТАР ХАЛКЫ: ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРДӘ, ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘ

М. ТАҺИР. Татарлар Кореяда . . . . . . . . . . . . . 178

Хатлардан юллар. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180

Әйдә, халыкка хезмәткә... *(академик М. Мәхмутов белән әңгәмә).* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183

Котлыйбыз. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Каләмдәшләребез — СССР Язучылар берлегенең яңа әгъзалары. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре. 187
Китаплар дөньясында. . . . . . . . . . . . . . . . . 189
Мәдәният тормышы көндәлеге. . . . . . . . . . . . 192

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

*Баш мөхәррир*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛУС ЛАТЫЙФИ
*(җаваплы сәркәтип)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИНЦУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш мөхәррир урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек мөхәррире)*
МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек мөхәррире)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары —
53-07-09,
җаваплы сәркәтип — 53-07-09.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият,
очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: начало романа А.ГИЛЯЗОВА «В чьих руках топор?»; повесть Р. ТУХВАТУЛЛИНА «Сарманская баллада».
Поэма Ф. ГИЗАТУЛЛИНОЙ, стихи М. ХУСАИНА, Д. ХАЙРУЛЛИНА, Р. МИННУЛЛИНА.
«На конкурс»: рассказы И. НИЗАМОВА и А. ГАФФАРА.
«Литературная критика»: статья Ф. ЗУЛКАРНАЕВА «Избавься от рабства». Беседа критика М. Валиева с писателем и режиссером БАТУЛЛОЙ об актуальных проблемах современной литературы и жизни.
«К истории культуры»: Отрывок документальной книги Х. ТУХВАТУЛЛИНА об отце — известном деятеле татарской культуры К. Мутыги. Статьи Р. МУСТАФИНА «Последние дни жизни Г. Ибрагимова»; М. АХМЕТЗЯНОВА «Новые сведения о просветителе Ш. Култаси».
«Искусство»: Ф. АХМЕТОВА «Путь к вечности».
«Татарский народ: в различных регионах страны и мира»: М. ТАГИР «Татары в Корее».
Письма читателей.
«Служить своему народу» — интервью с председателем общества «Ватан» академиком М. Махмутовым.
В номере отмечается 70-летие Дж. Тарджиманова.
Новые члены Союза писателей СССР.
Навыки чтения на основе арабской графики.
В мире книг.
На наших обложках — историко-архитектурный памятник «Мечеть Марджани». Портрет известного писателя, лауреата Государственной премии Татарии имени Г. Тукая М. Магдеева.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Р. Вафина, Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина.

Производствога бирелде 10.05.1990 ел. Басарга кул куелды 27.06.1990 ел. ПФ 05284. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы $70\times108\ ^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 83044. Заказ Д-244. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© Казан утлары», 1990 ел.

## Аяз Гыйләҗев

# БАЛТА КЕМ КУЛЫНДА?

РОМАН

1

Әүвәл әсәренде ул, аннан сискәнеп китте: моңарчы аны камаган дөнья төрле төсләрдән, исләрдән, күп санлы әйберләрдән, хәрәкәтләрдән тора иде, шулар кинәт юк булды; колак берни ишетмәс хәлгә килеп, күз алдын тоташ кара пәрдә каплады. Әйтерсең лә, язмыш аны тереклек яралмаган, җан ияләре булмаган төссез, иссез һәм шомлы тынлык хакимлек кылган бер галәм утравына илтеп ыргытты. Ул үзенең дөньяда барлыгын сынап, сул учы белән маңгаен кысып карады, маңгайның кайнарлыгын да, мул сибелгән бөрчек-бөрчек тир тамчыларын да сизмәде, димәк, аның сизү, сиземләү тойгысы да юкка чыккан. Ул, чеметеп карарга теләп, колагына үрелергә омтылды, кул кымшанмады, уч төбе киң маңгай тиресенә суырылып ябышкан иде.

Башкала китапханәсенең егерме кешелек иң аулак уку залында, тирә-ягына һич игътибар итмичә китабына йотылып утырса да, дөньяның яшәвен, янәшәсендәге гадәти тормыш агышын ул бик күп билгеләрдән чамалый иде, әлбәттә...

Хәзер әнә шул билгеләр, тирән упкынга убылгандай, һәммәсе берьюлы гаип булды, ул төссез, иссез, хәрәкәтсез шомлы чоңгылда бер башы торып калды. Үтә сәер, куркыныч халәт иде бу!

Мие бер тынга тәмам түнеп, зиһенен куе-соргылт шәүләләр чолгаса да, китапханә ябылырга җиткән мәлне шәйләде, мөгаен, уку залында соңгыларның берсе булып ул калгандыр. Китапханә хадимәсе, өенә кайтырга талпынып, бер аның иелгән киң җилкәсенә, бер дивардагы шакмаклы кара рам читләгән сәгатьнең өнсез-тавышсыз шуышкан чукмар телләренә карап-карап куядыр. Кузгалырга, кайтырга бик вакыт. Ләкин ул, җылы сумала сыланган ат сыртына менгән адәм угылы сыман, талпынса да ычкына алмый, ычкынырлык талпына да алмый иде.

---

*Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ (1928) — әдип, драматург, егермедән артык проза, пьеса китаплары авторы, РСФСРның М. Горький, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, РСФСРның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Иләс-миләс башының арт чүмечендә, кинәт кенә тәссез, тавышсыз яшен чартлады; ул, чарасыз калып, сулгарак янтайды, бераздан исенә килде һәм моңа охшашлы хәлне кайчандыр татыганы хәтеренә төште. Кайчан иде соң, кайда булды ул хәл?

Университетның кичке факультетында укып йөргәндә курсташына, Яльчик күле ягасына кунакка барган иде. Кичен, әреле куе кара балык ухасы ашап, сүнәр-сүнмәс янган учак тирәсендә озак кына гәп сугып утырдылар. Курсташының әтисе, урманчы, Ватан сугышында сул аягын тездән өздереп кайткан Каюм абзый чәүчәләк һәм быткыч кеше икән, сүзен әйтә дә сикереп тора, кашыгы белән черкиләр куа-куа дөнья хәлләрен сораштырып, студент егетләрнең хәлен алды. Җавап та көтеп тормый, бахыр, ялгыз яшәп теле кычытканмы, сорый да сорый. «Укып бетергәч эшкә кая җибәрәләр инде? Әйтмәсәгез дә беләм — сугыш кораллары ясарга тотынасыз. Казан каласы коралдан бүтәнне белми! Кая карама, яшертен заводлар. Ни нәмәгә кирәк ул корал? Рәчәйгә җир җитмиме? Булганның кадерен белергә бик вакыт. Нефть юкмы бездә? Күмер? Ясагыз корал, яса. Котыртыгыз тегеләрне. Үз башыгызга булмасмы! Менә аякка протез юк, каен түмәре бәйләп йөрим. Хатында тамак кастасы, пүчтәк кенә дару табар хәл юк. Ашарга такы-токы, он кайтармыйлар, ярма югалды. Өс-баш мәсхәрә, адәм көлкесе. Яшьләр чит илдән ташыганны кия, картларга — шымытыр. Ә ел саен ике тапкыр парад! Әй, чыгалар май бәйрәмендә тынычлык яклап, шатыр-потыр ракеталар тагып! Танклар җирнең үзәген сытып гүелди. Меңләгән эфисәр шак-шок бара, түшләр киерелгән! Тынычлык өчен көрәшәбез, янәсе. Май бәйрәмендә, язын, адәмнәрнең җаннары яңарганда берсе бер шәһәрне юк итәрлек ракеталар сөйрәгәч, безгә кем ышансын? Өркетәбез дип, тегеләрне котыртабыз лабаса!.. Алар азына дип без шашабыз! Атом заманында илләрне өркетеп ипкә китереп буламы? Дөнья ямен безнең ил башлыклары да нык боза... Ә бер-бер сүз әйтеп кара!»

Учак янында тыелып торган акылы, гәүдәсе җылы юрган астына кереп яткач, ашыгыч-ашыгыч уйларны арлы-бирле йөртә башлады. Чырае сытык булса да, төтене туры йөри каен аякның! «Яз җиткәч каен түмәреннән су тама!»— дип арттырса да, бүтән җәһәттә картның уйлары күңелне кузгатырлык иде. Ул да ялгыз калган мәлләрдә шундый икеле-микеле уйлар тозагында тырпылдап ятмыймыни? Миллион сумнарга төшкән парадлар ни өчен кирәк? Кемгә? Алган белеме шул тирәдә булганга, ул хәзерге заман сугыш коралларының көч-егәрен картка караганда биш тапкыр ачыграк белә!..

Күнегелгән кагыйдәләр буенча, ул картка ак-кара димәде, кайтарып җавап бирмәде, юрган астында йодырыгын йомарлап, кемнәр беләндер бәхәсләшеп, талашып ятты...

Чарлакта уянып калкынса, иптәше торып төшеп киткән, сул яктагы вак өлгеле тәрәзә ачык, очлы уклары белән биек-биек чыршы-нарат ларны аралап, зәңгәр күккә офыктан кояш күтәрелә иде. Ул, терсәкләренә таянып, сокланып, киртләч офыкка карап торды. Кояш бер нарат кәүсәсен үтте, икенчесенең артына кереп, әзгә генә югалып торды, өченче агачны тиз-тиз уза башлады. Ул, күзләрен шарландырып, якягына каранды: нәрсә бу? Нинди хәл? Кояш шул тиклем тиз бара аламыни? Нигә кабалана ул шулай? Әллә күкнең иң мәшһүр җисеме үзенең мәңгелек сызыгыннан, ходай тәгаенләгән орбитасыннан ычкынганмы? Җиргә афәт киләме? Гарасат?! Бетү! Дөнья бетәме?!

Ул туып, аңы үсеп исәйгәннән бирле карчык-корчыклар: «Алда адәм уллары вагаячак... Мич төбен ындыр табагы итеп ашлык сугачаклар. Ике меңенче елда дөнья бетәчәк»,— дип курку катыш ышаныч белән сөйлиләр иде бит, шул көн килеп җитеп, дәһшәтле һәлакәт сәгате суктымы әллә?

Күргән төшләре исенә төште, ул төне буе атом бомбалары, гайрәт-

ле танклар, хәрабәләр, тау-тау өелгән мәетләр, мәҗрухләрне күреп саташып ятты ләбаса. Кемдер, йомшак кара кәләпүш кигән көмеш дага сакаллы берәү, бармагын төртә-төртә аңа гел бер сүз сөйләде: «Укып кем буласың инде син? Адәм җанын кыючы җәллад буласыңмы?»— дип сорады...

Йокысыннан уянып, төшеннән арынып бетмәгән иде, чарлакның текә баскычыннан очып диярлек төште һәм яман акырган тавышка чабып кергән иптәшенең кочагына килеп ауды. Баш түбәсенә нидер китереп суккан иде шул чакта, һушы китте, сизелерлек урталай ярылган ныкча ияге дер-дер калтырап, ирен читләреннән ак күбек сызылып чыкты.

Аны түмәр аяк Каюм абзый дәвалады, иртән бер чәркә аракыга бер тустаган юкә балы туглап эчерде. Әбәдтә дә шуны кабатлады, кичке аш та шул булды, кичен бер тустаган хуш исле балга өч чәркә аракы кушылды. Ходайның әмере булдымы, өч көн дигәндә ул аягына басты һәм, берни булмагандай, Казанга кайтып китте.

Уку залында утлар кимеде, почмакларга караңгылык кереп оеды, башы лык итеп өстәл тактасына орынгач, ул айнып китте, чуендай авыр башын калкытты. Хадимә, сүрән генә елмаеп, аның иңбашына кагылды: «Ябабыз, актыкы булып сез калдыгыз».

Ул, уңайсызланып, җәһәт калкынырга теләде, кыймылдауга сул як кабыргасы астына үткер бер нәрсә килеп төртелде; ул, тешен кысып, хәлсезләнгән, камыр куллары белән китап-дәфтәрләрен өстәл тартмасына шудырды — китапханәнең бу яшерен залыннан кош канаты хәтле кәгазь алып чыгарга да рөхсәт ителми иде.

Тукталышта шактый көтәргә туры килде, гыйнвар җиле, аны аяктан егарга теләгәндәй, әле бер, әле икенче яктан килеп сарылды, бозланган җирдәге тәмәке төпчекләре, кәнфит кәгазьләре белән аны да зыр-зыр әйләндерде шикелле. Суык әрсезләнеп аяк бармакларын тешләде, җилкә чокырына үрмәләде, ниһаять, җелеккә төште. Таксига дип барлы-юклы акчаларын кармаштырганда, урамның аргы башында иренеп кенә кыймылдаучы троллейбус күренде, ул, туктала башлаган шоферга кул изәп, китәргә кушты.

Вакыт соң, төн суык, җилле, кеше әз, буш урыннар байтак. Ул, кеше юк якны сайлап, артка ук барып утырды. Утыруга, чалкан авып китте: ми капкачын дер селкетеп яшен чартлады, бая, китапханәдәге сыман күкрәгенә үткер уклар яуды. «Җылыдан чыгып җил күзендә озак тордым!»— диде ул, үз-үзен юатырга тырышып. Гәүдәсен көчхәлгә турайтты, «исерек дип уйламасыннар тагын!» Утыра торгач җылынгандай булды, йокымсырады, черем итеп алды. Торак йортының биек, авыр ишегенә килеп җиткәнче, күшеккән бармакларын чак кыймылдатып, сул чигәсен уа-уа атлады.

Лифтның уникедән соң ял иткәнен белсә дә, соры, салкын төймәгә баскалап, могҗиза көтте, аллаһы тәгалә бардыр ләбаса, аның тәмам алҗып кайтып килүен күргәндер ич, бер яхшылык кылса ни була? Ул, гасабиланып югарыга, кабиналар аска-өскә йөри торган, тимер рәшәткәләр каймалаган коега карап торды, хәрәкәт булмагач, култыксага ябыша-ябыша, чи тары көлтәсе кебек авыр гәүдәсен өскә, җиденче катка сөйрәде. Озак менде, аркасы җылынса да, куллар боз иде.

Тулай торак коридорындагы бушлык аны шикләндерде: ни булган бүген кешеләргә? Кая олаккан алар?

Ачкычын оясында калдырып эчкә керде, диванга тотына-тотына мыштырдап чишенде, киемнәрен кул астындагы урындыкка алак-шалак өя барды. Бүлмә уртасында бераз чайкалып торгач, иртән җыелмыйча калган урынга барып капланды, ыңгырашты...

Нәҗип Йосыф улы Нургалиевне бик хәтәр завод лабораториясендә эшләгән җиреннән Мәскәүгә, алты айлык курсларга җибәрделәр. Но-

мерлы, сак астында гына яшәгән заводның ул эшләгән лабораториясе гади кеше күзе җитмәслек эшләр белән шөгыльләнә иде.

Яңа елны каршыларга ул гаиләсе янына Казанга кайтты. Сагынышып күрештеләр, дөнья гаме кимеп торды, хатыны, уллары белән кавышу шифалы булды. Казаннан ул күтәренке күңел, дәрт белән аерылды. Завод директорының урынбасары Храмов: «Чихрадзены пенсиягә озатабыз, монда үзара мәслихәтләштек, кайтуыңа үзеңне мөдир итәбез!»— дип, Нәҗипне искәрмәс яктан сөендерде.

Яңа елның беренче көнендә җәмәгате, уллары белән сурәткә төшкән иде, кичәге почтада алар да килеп җитте. Томыраеп торган ике улын күргәч, Нәҗипнең йөрәге ихтыярсыз сыкрады, ул монда, канлы вәхши булуы өстенә, мактанырга да яраткан Сталин заманында зупзур тәрәзәле, биек итеп, муллык белән салынган бинаның болындай бүлмәсендә бер башы яши, ә алар анда, Яңа бистәнең тимер юлга чыга торган иң фәкыйрь урамында, дымлы, тынчу йортта интегеп яталар. Әле анда да йорт хуҗалары — Җәмилә карчык белән Тимерхан карт — нык ялындырып, назланып, шактый акча өстенә кыш корсагына биш кубометр утын түләрбез, шым яшәрбез, каршы әйтмәбез, дип, кат-кат ант эчкәч кенә сыендырдылар. Җиде-сигез метрдан артмаган, кыеш идәнле бүлмә уртасында киң итәкле марҗа булып акшарлы мич утыра, мичнең теге ягында, янәшә бүлмәдә, хуҗаларның кияүгә китмәгән, берүк вакытта кияүсез дә яшәмәгән кызлары Таңсылу көн күрә.

Таңсылу, җәфа, күз көеге булса да, югалып торгалый, мондагы тормышның төп көйсезлеге — көне-төне тынмаган, җәһәннәм арбасыдай дөбердәүдән туймаган, терәлеп диярлек үткән тимер юл иде. Көндезләрен бүтән тавышлар ул дөбердәүне басып торгалыйлар, әмма төннәрен, бигрәк тә җан зарыккан иртәләрдә, тәнне йокы изрәтергә тиешле мәлләрдә, тимер юл дөньяга бердәнбер хуҗа булып кала. Маневр паровозлары вагоннарны төн ката арлы-бирле сөйри, вагоннар, үгез сорап чебенләгән сыерлар сыман, берсе өстенә берсе менәләр, тормозлар исереп чыелдый, буферлар маңгайга-маңгай килеп очкын һәм тәмуг авазлары тараталар. Нәҗипнең сикереп торып тимер юлны шартлатасы, әзгә генә тавышларны тыеп торасы килгән чаклары күп булды. Авыр йөк төягән составлар алар йорты турында очрашса, өйдә чын кыямәт башлана, өстәл читендәрәк калган савыт-сабалар сикереп идәнгә төшә, дивардагы сәгать туктый, өй бүрәнәләре җегеннән ычкынырдай булып калтырый, зилзилә куба, җир тетри. Тавышка балалар елап уяна. «Һаман йокыга китә алмыйм!»— дип Наиләсе сукрана. «Нигә дөмекмисез, ачарбаклар!»— дип, теге яктан Таңсылу шакылдата. Кыскасы, тимер юл — дошман, тимер юл, — каһәрләнгән язмыш, тимер юл — гаиләдәгә талашларның сәбәпчесе иде.

Храмов өметләндереп, Наиләсе тынычландырып, балалары сөенешеп озатты аны Мәскәүгә — болай ук булыр дип кем уйлаган?!

Нәҗип йөзтүбән яткан килеш авыр йокымсырады, керфекләре кушылып ябышты, тәне әз-мәз җылынса да, тиздән түбән ягы салкын килеш калды.

Кайчан торып утын сүндергәндер, искәрмәде, дерт итеп уянганда бүлмә дә, зур тәрәзәгә аерылмаска сарылган дөнья да дегеттәй кара иде. Аңына уй йөгерүгә, бүлмәсенә тагын бер нәрсә — шом кереп тулганын сизенеп, сагаеп тыңлап ята башлады. Тирә-якта нидер үзгәргән, тәрәзә пәрдәсенә ябышып кара шәүләләр атына, ишектә дә, почмакларда да иләмсез күләгәләр кыймылдый иде? Бераз интегеп, җаны алмаштилмәш иңгән уйлар кысасында тырпылдап яткач, ул кискен үзгәрешнең үзендә, сул як күкрәк читлегендә икәнен абайлады. Күкрәккә, әйтерсең лә, үзле балчыктан әвәләгән салкын калкан япканнар иде. «Уф, алла, дип бер суласаң, тар сулышны киңәйтә»,— дигән авыл җыры исе-

нә төшкәч, ул кукрәген ачарга, «балчык»тан азат итәргә тырышып калкынды, кат-кат көрсенде. Торып утырыйм дигәндә, ыңгырашып, төпсез коега очты. Аяк, кул бармакларына кан барып җитмәде, кан сорап тамырлары чемер-чемер сулкылдады. Бераздан тагын исенә килде, янәшәсендәге өстәлдән кармаланып лампа төймәсен эзләде, җайсыз утырып калган термос идәнгә төште, пыяла чылтырады. «Зиһенем ачык, колагым ишетә!»— дип кабатлады аның көйгән иреннәре. Сүз белән ул үзен дәртләндерергә, тәненә көч бирергә теләде.

Азаплана торгач, идәнгә, җылымса чәйгә басты, килбәтсез эзләр калдырып ишек катына килде. Ишекне бикләмәгән икән, бу аны, сак игътибарлы кешене, гаҗәпләндерде. Ул баягыдан да шыксыз, үле төсләр сеңгән казна йортының ярым караңгы коридорына чыкты. Караңгылык аны тагын да ныграк куркытты. Сулда, өч бүлмә аша, аларның уртак кухнялары, үзбәк-таҗиклардан төнге ябалаклар кайвакыт анда пылау пешерәләр, аулакта үз телләрендә сөйләшеп, күңел шәмнәрен кабызалар. Алар янына барыргамы? Кем ишегенә кагылырга?

Көздән бирле, дүрт ай дәвамында бергә укысалар да, аның артык аралашкан кешесе юк, моңарчы йомыш төшеп берәүгә дә кергәне булмады. Аралашырга өнәмәгәнен сизенгән курсташлары да аның бусагасын үтеп йөрмәделәр. Нәҗипнең ничек яшәвен, кем булуын, эчке һәм тышкы дөньясын беркем белми иде. Төн уртасы авышкач, мамык аякларын көчкә сөйрәп барып керсә, аны бүген м ә з ә к итмәсләрме? Борып чыгармасларны?

Ул, сулышын тигезләргә тырышып, беравык басып торды да идәнгә чап-чоп басып үз бүлмәсенә борылды. Чайкалып китте, косасы килде, укшытты, кайтырга ярамый, хәле барында кемгәдер белдерергә кирәк иде. Тик кемгә?

Каршы як бүлмәдә үзе кебек үк курсант, инженер, уфалы татар Мөнир Якупов яши иде, ул шуның ишегенә килеп орынды. Авыз эче коп-коры, колак эче үтереп кычыта, бугазыннан әчегән эремчек суы тәме килә иде.

«Үләм!»— диде кинәт кенә Нәҗип. «Беттем!» Бу уе шулкадәр ачык һәм төгәл иде, дәү гәүдәсе куырылып, бер йомарлам булып кына калды. «Үләм, бетәм»,— дип кабатлады ул соңгы көчен җыеп.

Утыз өч яшенә җитеп, аның бер чакта да үлем хакында уйлап караганы юк иде. Якыннарының, кардәш-ыруларының әҗәлен бер тапкыр да күрмәгән, берәүнең дә соңгы сулышына шаһит булмаган Нәҗип үлемне үзеннән читтә, күз җитмәс еракта йөри торган рәшә итебрәк саный иде. Шөкер, әти-әнисе исән. Зәй ягында, авылда яшәп яталар. Олы абыйсы Сабит та шул төбәктә, туган якта гомер сөрә, колхоз рәисе. Энекәшләре дә исән, читтә, сеңлесе дә еракка кияүгә китте. Күрешмәсәләр дә, исәнлек хәбәрләре килеп ирешә. «Нургалиевләр токымы озын гомерле!»— дип мактанырга ярата иде Нәҗип. Бүтән җәһәттән алдынгылыкка чыкмаса да, үлемдә беренче нәүбәт аныкы икән. Мактан менә! «Әҗәлем, актык сулышым шушы икән, Мәскәүгә әҗәлем тартып китергән икән!»

Үкенечсез үлем юк, мәгәр егеткә үләргә һич ярамый иде әле! Әҗәлетдин якадан алганда бүтәннәр теленә ни киләдер, бүген ул бер сүзне тәкрарлады: «Ярамый! Иртә ич!»

Ни рәхәт күрде Нәҗип дөнья йөзендә? Һәм ни рәхәт күрсәтте?

Балачак кыенлыклары җиңел онытыла, алары үтте-китте. Балигъ булгач, көндез эшләп, кичен укып, мең бәлане җиңеп белем алды. Бүтәннәр кебек эшендә тиз төпләнә алмады, дипломлы белгечне заводында урыннан-урынга куып йөрттеләр. Берәүләргә табигате җай килмәде, «авыр холыклы», диделәр. Икенчеләр тырыш-үҗәтлеген өнәмәделәр: «Һавалы ул, тәккәбер!»— дип аннан ераграк йөрергә тырыштылар. Ниһаять, урнашып, моңарчы аякка кара елан булып уралган кара нужадан котылам, хатын, балаларыма муллык һәм бәхет китерәм дигән-

дә... Биеккә менгерә торган баскычның түбәнге аратасына аяк баскан-да... Аh, нинди вакытсыз һәм үкенечле була бу әҗәл! Газраил бүтән җайлырак ризык тапмады микәнни?

Бүтән балалар җай чыгуга ата-анага әз-мәз игелек кылганда ул күктән манный боткасы яуганны көтеп йөрде. Ни рәхәт күрсәтте ул хатынына? Өйләнеп туй үткәрмәде, балалар тугач, кунак җыйнап күңел ачмады, туган көннәрендә беркемне түренә өндәмәде... Алай гынамы, никахлашкач, бүләк-санак күтәреп килгән белеш-танышларын өерләп куып чыгарды. Үкереп елаган Наиләсен юатып: «Җылама! Җиде бәйрәмгә бер туй булыр. Бер булыр — бәрәгәйле булыр! Тирә-як дер калтырап торыр. Күктән йолдызлар өзелеп төшәр! Түз! Түз!» — диде.

«Түз! Вакыты җиткәч! Соңыннан! Баегач! Иркенгә чыккач!» Хатынын, үзен ничә еллар шушы сүзләр белән юатты, ымсындырды...

Ата-анасына күчтәнәч салмады, хат язмады, туганнары белән арасын кырт өзде. «Килер бер көн, дөньясы шаккатар!» — дип кабатлады.

Көткән көне шушы булып чыктымы?!

Эзең сакланырлык бер якты сукмак калдырмыйча, юньле бер игелек кылмыйча, ялгышларында үкенеп тәүбәгә килмичә, тот та дөньядан китеп бар инде! «Көнем килә, бәхет сәгате суга!» — дип, яшерен өметләр тышка чыга башлаганда, ике үксез сабыйны хатын кулында калдырып, кара гүргә кереп ят инде! Фатирсыз, акчасыз ул ничек яшәр? Малайларны аякка ничек бастырыр! Нинди тере, шук, чая аның уллары! Нинди якты күз белән карый иде ул Искәндәре белән Рөстәменә?! Кинәт бөтенесе челпәрәмә килә, чәнчелеп барып төшә, сүнә, түнә, ава... Иренең җансыз гәүдәсен Наиләсе Казанга ничек алып кайтыр? Каян акча юнәтер? Завод китапханәсендә иренең акча күрәрен көтеп яткан хатында нинди акча булсын! Институтын Нәҗип ташлатты бит. «Эшләтмәм! Мин тапканы җитәр!» — дип кырт куйды! Уллары, аның үзе кебек җәфа чигеп, такы-токыда укырлар, таяныр этиләре булмас, аларны «ятим-ялпы» дип кагарлар, читкә тибәрерләр. Шундый каргалган язмыш әзерли идеме ул сабыйларына? Моңарчы күргәннәренә түзгән Наиләсе таң туган саен аның кабере ягына карап нәләт укыр!..

«Үләм!» — дип әйтә алды аның умырылып аска иңә барган күңеле. «Беттем!» — дип кабатлады көрмәкләнгән теле. Ни үкенеч, аның соңгы сүзен тыңлар кеше юк, хәер, ни әйтсен ул бу ят кешеләргә? Ул, үзен күпчелектән өстен санап, борын чөеп, һаваланып йөрмәдемени? Менә хәзер ал әҗерен, берәрсенә кереп кара!

Уфалы Мөнирнең йокысы үтә сак иде, ул: «Баядан бирле ишектә кем тырмана икән, салмыш ярата торган Шаламбиридзе тагын кәгеп кайтканмы әллә?» — дип, ишекне ачып җибәрсә, ишеккә терәлеп торган Нәҗип Нургалиев, мәлҗерәп, аның бүлмә идәненә ишелеп төште. «Ни булды?» — диде Мөнир җирәнеп, аны исереккә чыгарып. «Беттем!» — диде Нәҗип. «Йөрәкме?» «Үләм», — диде Нәҗип өзек-өзек ыңгырашып. Аннары, күм-күк иреннәрен тешләп, тынып калды. Күз алмалары ике якка тәгәрәде, чыраеннан кан качты. Эш уеннан узган иде.

Мөнир, йөз дә дүрт килолы гәүдәсен таралып китмәсен өчен туптуры тотып йөри торган бәндә, Нәҗип аша очып чыкты да җиденче катның ял бүлмәсенә эленгән телефонга чапты.

2

Хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич — җан дуслар. Берзаман Мәскәүгә барышлый икесе бер купега туры килделәр дә юл буе авызга авыз сөйләштеләр. Икесе дә ашарга-эчәргә яраталар, ризык-мазарны умырып алганнар, юл кыскарды, сүзләр сайланып чыкты, серләре килеште, башкалага барып кергәндә мәңге аерыл-

маска сүз куешып, вәгъдәләр беркетеп, кочаклашып саубуллаштылар...
Белгән халык «аһ!» итте.
Ничек? Дуслашканнармыни? Бер-берсен ничек табышканнар? Ни якынайткан аларны?..
Инде ул очрашуга байтак вакыт үткән, күпме сулар аккан, ә хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич арасыннан җил дә үтми, гайбәт колагасе дә йөрми. Шәһәр һаман гаҗәпләнә, дуслыкның серенә төшенә алмый, чөнки Иван Иванович белән Басыйр Бариевич бер дә, бер дә бер-берсенә иш килгән кешеләр түгел инде югыйсә! Эш якынайта дисәң, бер-береннән ерак тармакларда хезмәт күрсәтә алар: Иван Иванович Идел буе төбәгендә абруйлы, хөрмәткә ия зат — шәһәр башкармасын җитәкли. Ә Басыйр Бариевичның оясы бераз таррак, ул Юдинодагы тимер юл идарәсен җилкәсенә күтәргән. Иван Иванович баһадир, җилкәсендә өч-дүрт сабыйны «эпипә»гә биетергә була, тавышы таш кантар ишелгәндәй калын, авыр, яңаклары чыгынкы, киң кашы ике себерке булып ярылып ята, учларында лилипутлар чабагач белән ашлык сугарлык. Ә Басыйр Бариевич нәрсә? Камыт аяк, буе кер бәләге,орчык кияк, ясмык тешләр, коелып беткән керфекләр арасыннан без күзләр җемелдәп тора. Иван Иванович ерак Украинадан килеп төпләнгән, чын хохол. Басыйр Бариевич тумышы ягыннан үз ягыбыз кешесе, әнкәсе әле дә исән, Юдинодан ерак түгел, ялгыз башы урыс-улак арасында яшәп ята. Басыйр Бариевич Мәскәүдә тимер юлчылар транспорты институтын кызыл дипломга тәмамлагач, аны Россия шәһәрләренең берсенә җибәрделәр, ул шунда чиркәнчек алды, чыныкты, марҗага өйләнде, телен һәм туганнарын оныткач, аны Татарстанга кайтардылар. Ни гаҗәп, башта элеваторларга баш булып йөрде, горкомда эшләп алды, аннан Юдинога, тимер юлга күчерделәр. Элегрәк Басыйр Бариевич елак һәм әләкче иде, хәзер тавышы күрәйде, сүзләре бөердән генә чыга, күз карашы белән дус-дошманны үтәли тишә ала... Ул сабый чакта Идел суы авылдан шактый ерак булып, пароход тавышлары бик сирәк, анда да ул яктан көчле җил искәндә генә килеп ирешсә, хәзер су бәрәңге бакчасына килеп терәлде, җилле кичләрдә чупылдаган тавыш тәрәзәдән керә. Иван Ивановичның ата-анасы исән, үзе Басыйр Бариевичка сөйләгәнчә, хәзерендә чик янындагы шәһәрчектә бик шәплә п яшәп яталар. Ватан сугышына яше кермәсә дә, Иван Иванович илленче елларда бандеровчыларга каршы сугышкан булып исәпләнә, төнге атыш вакытында, печән чүмәләсендә посып утырганда, наян пуля аның иңбашын сыдырып үткән, шуннан бирле ул «ветеран» санала, юбилейларда орден-медаль яңгыры яуганда бер чакта да мәхрүм калмый...
Икесе ике җирдә, ике кәсептә, әле ярый икесе дә депутат, икесе дә өлкәнең пленумы әгъзалары, сессияләрдә, пленумнарда, утырышларда, юбилейларда, тантаналарда еш очрашалар, читкә караган булып бер-берсенә күз кысышалар, дуслыкларның дәвамын ныгытып куялар. Мондый абруйлы җитәкче затларга үзара мөнәсәбәтләрен якты дөньяга чыгарырга ярамый, ходай сакласын! Дөрес, аларның бәйрәмдә йөрешкәнен, ризык бүлешкәнен байтак кеше белә, әмма бу дуслыкның эчке серләре икесе арасыннан бер чакта да читкә чыкмый! Бер чакта да! Телләреннән ялгыш сүз ычкынмас — ихластыр, дуслык әнә шул чакта гына дәвамлы, ышанычлы һәм какшамас була. Дуслыкның тәүге шарты — ике арадагы серне чишмәү. Күп еллар дәрәҗәле урында утырган затлар моны бик яхшы беләләр! Чөнки дәрәҗәле затларда, аларның газиз хатыннарында гына була серләрнең төрледән төрлеләре!
«Дуслык — бәйрәм!»— ди Иван Иванович.
«Дуслык — язмыш бүләге!»— ди аны җүпләп Басыйр Бариевич.
Ахирәтләр бу гадел хакыйкатьне күптән сеңдергәннәр, гап-гади сәфәрдән башланган якынлык еллар үткән саен ныгыган, тирәнәйгән.

Бәйрәм тантаналары бергә үтә (дәрәҗәле затларда бәйрәмнәрнең сансыз-исәпсез икәнен кем белми!), очрашулар күптәннән ныклы тәртипкә салынган, кунакка чиратлашып йөрешәләр, ике як та үпкәләрлек түгел, бүген Иван Ивановичларда җыелсалар, иртәгә табынның мулы Басыйр Бариевичларда әзерләнә. Дуслыкның кадерен аерата нык белә башлаган җан дуслар соңгы елларда очрашуларны, бәйрәм табынnarын Басыйр Бариевичның туган төягенә, Идел буендагы авылга күчерделәр. Анда инде аулак дисәң дә аулак! Һәм хикмәт шунда ки, дусларның нәни, әмма гаять әһәмиятле серен ачып китик, Иван Иванович авыл мунчасын һәм мичтә мәмрәп пешкән каз бәлешен ярата! Ә бу дөньяда иң сихәтле мунчаны, тәме атналар буе тел төбеннән китми торган хуш исле, юка камырлы, үзе авызга керергә атлыгып торган каз бәлешен Басыйр Бариевичның газиз әнкәсе Әнисә абыстайларда гына күреп-татып була. Күптәннән тол калып, ялгызлыктан тәмам гаҗиз булган Әнисә абыстай мондый дәрәҗәгә ирешкән улыннан да, аның кунакларыннан да курка, курыкса да кунакларын, аларга ияреп килгән мәшәкать-борчуларны күркәм сабырлык белән күтәреп ала. Һәр тарафтан бөек дәрәҗәләргә ирешкән улына, аннан бигрәк килене Ида Михайловнага ярарга тырыша, аш-суын бөртекләп әзерли, мунчасын җиренә җиткереп яга.

О-о, хәзерге ак заманда кара мунчада чабынып чыгу — белгәннәр өчен берни белән чагыштырмаслык олы бәйрәм! Хөрмәтле Иван Иванович белән кунакчыл Басыйр Бариевич хәтле (кара мунчаның тәмен белгәннән соң Иван Ивановичлар кунак кабул итүне бермә-бер сирәгәйттеләр, нишлисең, аларда мунча да, һәйбәт тозланган, ярка-ярка башлы кәбестә арасына кунакка дип әзерләп куелган симез каз күтиге дә юк!) мунчаның бөтен хасиятен, тулы ләззәтен һәм тәртибен аңлаган кеше дөнья йөзендә тагын бармы икән? Юктыр, валлаһи, юктыр. Булмас та! Шуны да әйтик, мунча алар өчен юыну, чабыну урыны гына түгел, икесе ике җирдә хезмәт кылалар, теләгән минутларда гел-гел очрашып булмый, ә мунча аларның сер алыша торган, планнарны барлап, күңелләрне беркетеп куя торган яшертен эш бүлмәсе дә. Ашыгыч һәм яшертен йомышлар калыкса, алар шартлы сүзләр белән телефоннан хәбәрләшәләр дә (телефон шуннан бүтәнгә ярамый!) очрашалар, Идел ярындагы мунчада иң җаваплы кадрлар мәсьәләсе карала, шәһәрнең үсеше билгеләнә, тимер юллар тирәсендә бер-бер чатак чыкса, Иван Иванович Басыйр Бариевичны һәрчак йолып ала. Басыйр Бариевич яклаган кемнеңдер түшенә орден куна, кемнәрнеңдер буйсынмас башы балта астына куела...

Кыш дәвамында атна саен мунча яктыралар алар. Әнисә абыстайның биле кузгалган очракларда, бу үтә җаваплы, аерата яшертен эш тимер юлчыларның профсоюзын күп еллардан бирле җитәкләгән Исламнур дигән иптәшкә йөкләнә. Иван Иванович баштарак: «Исламнур?.. Уңайсыз ич, үзе дә дәрәҗәле иптәш?» — дип, шиген белдергән иде, Басыйр Бариевич үз кандидатурасын күз алдына китереп көлеп җибәрде.

Булса да булыр икән ярдәмчел, итагатьле, кешеләргә игътибарлы, кече күңелле татар баласы! Исламнурның бары тик яхшылык кына тулган киң күкрәгенә ике ел саен орден юкка гына элмиләр шул! Һич иренмәс, үз эше ник шунда кырык җирдә кырылып ятмый, бер сызгыруда килеп җитәр, ярты сүздән аңлар, комсызлыгы юк, кылган хезмәте өчен берни сорамас, берни көтмәс, иң мөһиме — күңеле киң, тирән, диңгездәй серләр сыя аның күңеленә! Сыя да бата. Мунча ягуның әчке тәртибен, нечкәлекләрен, миллекләрнең шифасын, хасиятләрен бөтен ваклыкларына тикләм белә. Казан арты төбәкләрен җәяүләп йөреп чыккан, Мари урманнарын туйганчы ботаган, өлкәннәрдән төпченгән, сорашкан, белгәнен яшерми, ялкауланмый, иренми; эшкә тотынса, сәгатьтән күзен алмый, яга, сохаридәй шылтырап торган каен яркаларын

ташлар кызып сикергәләргә тотынганчы мич авызына өстәп тора. Суның салкынын, кайнарын бер взвод кычынган солдатка җитәрлек итеп ташый. Идәнне, сәкене, утыргычларны, ләүкә такталарын кыл мунчала белән ышкып кат-кат юа, берсе каен, берсе имән, берсе карлыган чыбыгыннан бәйләнгән мул яфраклы миллекләрне пешереп куя. Ә мунча алдына куелган ике суыткычта җаның ни тели, шул бар.

Суыткычлар да гади түгел, берсе финнардан, икенчесе Алжирдан килгән. Шешәләр тартма-тартма кереп ипләнәләр. Эчемлекнең агы, гадәттә, җиде-сигез төрле, океан артыннан килгән «Смирнофф» дисеңме, «Алтын алка», «Посольская»лар — бар да бар. Кызылны санап торган юк, мәктәптә математикадан гел бишлегә укысаң да, исәбенә чыга алмассың, эчмичә үк башыңа китәр! Чехлардан, юмарт финнардан, шведлардан килгән кырык төрле сыра банкалары, поляклар җибәргән чуар-чуар кәгазьле, матур бүксәле сыра шешәләре, яңгырлы җылы елларда-гы гөмбәләр сыман, күз кызыктырып бер-берсенә сыенышканнар. Кызыл мәйданга май парадына чыккан әфисәрләр диярсең!

Мунча көнен бәйрәм түгел дип кем әйтә ала? Юк, гади бәйрәм генә түгел, тиңсез олы, дуслык тантанасы! Шешәләргә ямь биреп, карауга авыздан су китерә торган, кара, кызыл уылдык банкаларын, тәрәч бавырын, крабларны да әйтсәң, хөрмәтле Иван Иванович белән Басыйр Бариевичның нинди бәхетле затлар икәне, шәт, аңлашыладыр? Бу оҗмахка Исламнурдан да түбән дәрәҗәле берәүне кертеп җибәреп кара син... Бәла-казасын, гайбәт сүзләрен җыеп бетерә алмассың!

Һәрчак дуслар үз машиналарында, үзләре белгән юллардан шыпырт кына килеп төшәләр. Дуслар кочаклашып күрешәләр, бәйрәм белән котлашалар. Хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич бер дә кабаланмыйча, үз кадерләрен белеп чишенәләр, учлары белән корсакларын уып көлешәләр. Басыйр Бариевичның корсагы бер учка сыеп бетсә, Иван Ивановичның җилпучтай учлары бүксәнең җидедән бер өлешен генә сыйдыралар. Дуслар бер-бер артлы иркен, киң ләүкәгә үрмәлиләр. Хезмәткә тәяр Исламнур кызган ташка швед сырасы сибә, куе салат исе пар сулышны киңәйтә, аппетитны ача. Парга күмелгән кунаклар ләүкәдә ахылдашып яталар. Иван Иванович Азия хәтле урын биләсә, Басыйр Бариевичка Аппенин ярымутравы булып бөгәрләнергә туры килә. Дустың хакына ниләр генә кылмыйсың?! Бераздан пар сыегая, Исламнур кушканны көтеп тормый, көмеш подноска утыртып кунакларның һәр икесенә мөлдерәтеп аракы, тустаганы белән чех сырасы алып кереп сона. Үзен дә мәхрүм итми, мунча ягып, су җылытып изрәгән тәненә көч, дәрт кайтсын өчен «Смирнофф»ны йотып куя, сыра банкасын ача.

Берзаман, сәгате суккач, ләүкә-җәннәттә пәри туе башлана: Иван Иванович белән Басыйр Бариевич алмаш-тилмәш чабынырга тотыналар. У-у, монда инде чыдап кына тор! Идәннән түшәмгәчә татлы пар бетерелеп ургыла, басымга чыдый алмыйча ишек ачылып китә, ташлар, туйга җыелганмыни, шарт-шорт бии, каен, имән яфраклары мина ярчыклары сыман сызгырып оча, карлыган яфраклары чыбыктан кубып, чап-чап тәнгә ябышып калалар.

Чирек сәгать чамасы тоташ чабынганнан соң, хөрмәтле Иван Иванович белән Басыйр Бариевич, оҗмахтан куылган шайтаннар кеби, селкетеп чабып чыгалар да куян тиреседәй ак кар көртләренә «гөрс!» итеп кереп чумалар. Иван Иванович чумган тур уңган килен чүмәләседәй калкып торса, Басыйр Бариевичны эзләсәң дә, тиз таба алмассың: чума да югала! Бераздан дуслар калкыналар, бер-берсенең җилкәсен карлы йодрыклары белән төяләр. Иван Иванович дөмбәскәсе белән субай суккан тавышлар чыгара, Басыйр Бариевич сак — бала сөйгән сыман чәп-чәп итә.

Ике-өч минут карда кинәнгәч, кунаклар, нәселле юргалардай пошкырып мунчага керәләр дә, Исламнур парландырып куйган ләүкәгә су-

зылышып яталар. Профсоюзның мөхтәрәм вәкиле җитез, чүмеч арты чүмеч шау кайнар суны ташка сибеп җибәрә, пар бии, пар идәнгә ургыла, пар күзләрне сукырайта. «Җитәрме?» — дип сорый идәнгә сеңгән уңган татар баласы. «Җитәр, җитәр!» — диләр ләүкәдәге гәүдәләр.

Иң тантаналы, кителгән минут җитәр алдыннан Исламнур мунча алдына атылып чыга, бисмилласын әйтеп, ярты тустаган акны җиффәрә, озынча таш кабакка охшаган, пеләшләнә башлаган башына калын бүрек чәпи, кулларына йон бияләй кия һәм үзенә йөкләнгән иң дәрәҗәле эшкә керешә. Беренче нәүбәттә хөрмәтле Иван Ивановичны яратып әйләндерә-әйләндерә, миллекләрен алыштыра-алыштыра озаклап чаба. Ул чаба башлауга ләүкәдән очып төшеп идәнгә сеңгән хөрмәтле Басыйр Бариевич, ах-ух килеп, көч биреп, дәртләндереп ята. Исламнур әүвәл миллеген затлы кешенең җилкәсенә тияр-тимәс кенә йөгертеп уза, тән тиресен пар белән йомшата, әзерли. Аннан тотына каезларга, киерелеп-киерелеп тукмый, миллек чыбыкларын тач май тәнгә батырып ышкый, имәнне каен алыштыра, каенны карлыган. Исламнур армый, талмый, мондый кадерле җилкә чокырын чапканда көчсез күренергә ярамый! Ниһаять, хөрмәтле Иван Ивановичның кура җиләгедәй кызарган центнерлы гәүдәсе карлыгач булып ләүкәдән очып төшә, ул Исламнур сузган бер чапчак карлы-бозлы суны башыннан коя. Басыйр Бариевич хихылдап, калак сөякләрен уйнатып, аннан бушаган урынга менеп ята, куе парда кәшәкә юанлыгы, төк каплаган ботлары күренмәс хәлгә килә. Исламнур аны баягы нәүбәт белән чаба, имән миллеге белән кабыргасын төя. Тимер юлчының кабыргалары майланмаган вагон тәгәрмәчләредәй шыгырдыйлар, умырткасы сынардай булып сыгылып-сыгылып ала. Басыйр Бариевичның бу җәзаны туктатасы, Исламнурны ләүкәдән куып төшерәсе килә, ярамый! Дусты Иван Ивановичтан калышаларммы соң!? Түзә Басыйр Бариевичның җилкәсе, чыдый, ул үзе сөенгән булып чикылдый, Иван Ивановичка ярарга тырышып ухылдый, мыркылдый. Ләүкәдән төшкәч, авыр чапчактагы суны Исламнур күтәреп коеп җибәрә. Тимер юлчыларның дәһшәтле җитәкчесенең чапчак күтәрерлек хәле беткән, ул соңгы көчен җыеп, бар көченә «әлә-лә!» дип кычкырып, баскан урынында тыпырданып бии. Тагын чабыналар, тагын атылып тышка чыгалар, кызган гәүдәләр комсыз чуртандай атылып көрткә барып чумганда, куян мамыгы кебек йомшак кар «чож-ж!» итеп эри.

Урын аулак, иптәшләр үзебезнеке, дуслар ышанычлы, сый мул, үз кесәңнән түгел, мунча илаһи шәп — тормышның кадерен белеп, илгә, ил хуҗаларына рәхмәт укып яшә дә яшә генә! Мондый иркен, мондый бәхетле, муллык ташып торган ил бармыни дөнья йөзендә?!

Ниһаять, кунаклар, калын-калын япон халатларын иңнәренә салып, кара-каршы утырышалар. Тантана дәвам итә, тантананың рәвеше генә үзгәрә. Бәллүр чәркәләрдә «Камю» коньягы язгы таңнардагы күк төсенә кереп балкый, бала күз яше кебек ап-ак «Алтын алка» аракысында сихри нурлар тирбәлә, сыра банкалары сыпылып кына ачылалар да алардан татлы арпа, салатлаган икмәк исе бөркелеп чыга. Бераздан Әнисә абыстай мунча алды ишеген сак кына шакый. Димәк, иң зур сыйга — әле генә мичтән чыккан каз бәлешенә чират җиткән. Әнисә абыстай, ак ашъяулыкка биләнгән бәлешне Исламнурга тоттыра, «Балам, берүк төшереп җибәрә күрмә!» — дип инәлергә дә иренми. Төшерәме соң Исламнур бәлешне! Бәйрәмнең татлы таҗыннан хөрмәтле авызларны мәхрүм итәме?

...Елның көтеп алынган ундүртенче гыйнварын алар шулай икәүдән икәү генә, гомергә онытылмаслык итеп үткәрделәр.

Хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич Әнисә абыстайда кунак булуны «коммунизм мәктәбе» дип атыйлар һәм үзләренең бөтен кешедән дә алдарак коммунизмга чыгулары белән гаять горурланалар иде. Яз-көз, кырлар ачык чакта, җир өстенә кара төн иңгән-

дә, Иван Иванович белән Басыйр Бариевич Әнисә абыйстайның каз симертә торган биләмәләренә дә чыгып керәләр. Тимер юлның Идел ягында буйдан-буйга урман кишәрлеге сузылган. Моннан кырык еллар элек утыртылган имәннәр, каен-юкәләр белән ярыша-ярыша үсеп, күтәрелеп киткәннәр, ныгыганнар. Маңгай утларын ялтыратып әледәнәле үтеп киткән поездлардан бу як, Әнисә абыстайның җәй-көз каз көтә торган иркен биләмәләре бөтенләй күренми. Иван Иванович килгән саен: «Басыйр Бариевич, күр, кара бу имән агачларына! Без дә бу җирнең имәннәре!»— дип әйтергә ярата. «Имәннәрдәй озын гомерле булырга язсын безгә!»— дип, Басыйр Бариевич аны куәтләп куя. Урман белән авыл арасындагы кыр кайчандыр совхозныкы иде. Көнбагыш чәчеп карадылар, яшелчә үстереп маташтылар да, рәт чыкмагач, сый күрсәтмәгән кысыр кырны калдау калдырдылар. Сөрелмәгән, чәчелмәгән җир хуҗасыз байтак япы-япы да куе үлән, әрем-билчән белән капланды. Руслар каз асрарга яратмый, алар аның әмәлен дә, тәмен дә белмиләр. Әнисә абыстайга мач килде, әлгәре бер оя асрый иде, соңгы өч елда ике ана калдыра, уңа да...

Бүген, бәйрәмнән кәефләнеп, икесе ике машинада тирбәлеп кайтырга чыккач, ак кар астында яткан караңгы кыр уртасында машинасын туктатып, Иван Иванович Басыйр Бариевичка борылып эндәште:

— Бу кырларны читләрдән сакла, әниең алпавыт, җир били, шулай булып калсын да!

Машиналар Казан юлына төштеләр...

Дөньяның вак ыгы-зыгыларыннан азат ике дус: җир шарында Нәҗип Йосыф улы Нургалиев яшәп ятадыр, ул менә нәкъ шушы кичтә, йөрәге кагып егылгандыр, дип уйлап та карамыйлар иде. Кыскасы, алар аны белмиләр дә иде.

Язмыш — аяусыз нәрсә. Ул бер-берсен бөтенләй белмәгән, белә дә алмаган җаннарның язмышын да чәлмәштереп ялгый, адәм уллары янәшә юллардан баралар, баралар да, берзаман аларның язмышлары кисешеп куя. Хәер, үндүртенче гыйнвар кичен бу затларның юл башы дип билгелик тә Нәҗип Йосыф улы Нургалиев янына кайтыйк.

## 3

Башта «инсульт» диделәр. Ныклабрак карагач, «инфаркт» булмагае дип шикләнделәр. Больницада як-яктан, эчтән-тыштан тикшергәч: «Инсульт юк, инфаркт булмаган, мәгәр организмы нык таушалган, тегесенең дә, бусының да булу ихтималы бик мөмкин»,— дип, Нәҗипне йөрәкләре удар алганнар палатасына салдылар. Мөнир Якупов Казанга, Наиләгә хәбәр итте. Наилә ике улын — Искәндәр белән Рөстәмне Казан арты бабаларына кайтарды да алтынчы көн дигәндә ире янына килеп җитте.

Реанимация палатасыннан күчерсәләр дә, Нәҗип янына бик авырлык белән генә керттеләр Наиләне, «Дулкынландырмаска, күп сөйләшмәскә, озак юанмаска, әйбер-кара бирмәскә!»— дип кат-кат кисәттеләр.

Һәрберсенең караваты пәрдә белән аерылып куелса да, ярым караңгы палатага килеп кергәч, Наилә анда дүрт кеше ятуын да, Нәҗибенең нәкъ ишек каршысына урнашуын да чамалап алды. Дүрт кеше авыр тынлыкта дүртесе тиң караватларына сеңгәннәр иде. Нәҗип Наиләнең кергәнен аермады, ул чалкан ятып, ярым йомык күзләре белән билгесез бер ноктага туктап онытылган иде... Наилә Нәҗипне танымады. Шушы әгъйифь, көчсез гәүдәме аның арысландай ыргылып торган ире? Бик күп егетләр арасыннан атылып килеп чыгып, Наиләне бер сүзе, ымы, ишарәләре белән үзенә караткан бөркет шушымы?.. «Мин бүген яшәмим әле, мин алга карыйм, сине дә үзем белән матур киләчәккә, беркем татымаган ләззәт дөньясына дәшәм!»— дип кыз күңелен шаштырган

җан шушымы? Аны кочкан, аның һәр буынын иркәләгән, һәр тере күзәнәген эзләп тапкан, мәхәббәт көймәсенә яткырып, кызлык чорыннан хатынлыкка алып чыга белгән куллар хәзер, атылган кош канатлары кебек, җансыз гәүдә янәшәсенә сузылганнар. Шул куллармы бу?! Моңарчы җил-давылларга бирешмәгән корыч калкан кебек нык күкрәктән бүген чак ишетелерлек сулыш чыга. Бетүеме бу Нәҗипнең?! Биргән вәгъдәләрең үтәлмәгән, кат-кат ныгытылган антлар тормышка ашмаган, өмет агачы тамырларын тирәнгә җибәреп, ботаклары белән күкләргә үрләмәгән...

«Ни булды сиңа, җаным?!»

Ул иренең күкрәгенә килеп капланды, җылы хисләре, сүнмәс дәрте, татлы тыны белән аңа көч өргәргә, дәрт бирергә исәпләдеме, озак кына аерыла алмыйча торды. Аны палатага озата кергән кизү врач арттан, аның күлмәк итәгеннән тартты, ым белән артсыз урындыкка утырырга кушты, иреннәрен чак кыймылдатып: «Саграк!»— дип пышылдады.

Алар пәрдә эчендә калдылар. Менә Нәҗип елмайгандай итте, ияге селкенде, күзләре белән хатынына иелергә кушты. Наилә аның кан качкан шыксыз иреннәренә колагын куйды. Нәҗип өзеп-өзеп бер җыр әйтте: «Ай-һай, дөнья, туйдым синнән... син дә туйгансың миннән! Шушы яшьләремә җитеп, ни рәхәт күрдем синнән?!» Наилә кайнарланып, ачы күз яшьләренә буылып, тончыгып тагын шул сүзләрен кабатлады: «Ни булды сиңа, җаным? Ничек төштең бу хәлгә? Бу көннәргә ник килеп җиттең?!»

Сөйләшергә ярамый иде, Нәҗипнең чынлап торып сөйләшер хәле дә калмаган иде, сөйләр сүзе дә юк кебек иде аның, көчсезлектән мескен булып калган учы Наиләнең тирләгән, кайнар учы белән очрашкач, ул тирән итеп бер көрсенде, телен чыгарып өске иренен ялады...

Әти-әнисе аны авылдан бер дә җибәрергә теләмәде, бригадир ярдәмчесе булып йөри башлаган Сабит абыйсын өлгегә алдылар да «китәм!» дигән авызын томаладылар. «Күр абыеңны, йомылып эшләп йөри. Басымчак, сүз тыңлаучан. Боерган булса, бригадир булып та китәр. Печәнгә, курмыга тиенербез. Син дә калхузда калсаң, нужадан котылырбыз. Каралты-кура йончыган, аларны рәтләрбез. Абыең башлыкүзле булса, мунча салырбыз. Бездән икегез дә артмассыз. Без — авыл кабартмалары, кара сөяк, укып мулла, чукып карга буласың юк, ике аягыңның берсен атлама!»— дип үсмер егетнең күзен ачырмадылар. Ялындылар, ялвардылар, тәмле тел белән тыңлата алмагач, рәнҗеделәр, юлына хәер-фатыйха бирмәделәр. Авылның һәр атламына килеп кысыла торган алап авыз Талия карчык: «Йөрсен, йөрсен! Выжлап, ачка койрык чәнчеп кайтыр, күрегез дә торыгыз. Ата-ана фатыйхасыннан йөз чөергән бәндәнең уңганы юк әле!»— дип, учын әйләндереп каргап озатты егетне.

Нәҗип авылдан «кире беткән», «алты-биш», «карама бүкәне», дигән кушаматлар ияртеп чыгып китте. Черәшкәне өчен Сабит абыйсыннан аңа нык ук эләкте...

Китте егет, бәхетсезлегеннәндерме, институтка үтә алмады. Авылга кайтып күренмәде, гарьләнде. Озын-озак уйламады, тотты да нәни генә механика заводының тимерчелегенә чүкеч сугучы булып керде. Эш бер сменалы, акча ару гына төшә, егетнең көче ташып торган чак. Озакламый тулай торактан урын бирделәр, ел эшләде Нәҗип, ике ел, алдагы ике елын армиядә үткәрде, кайткач университетка укырга керде, кичкегә. «Эшче, солдат!»— дип аны күтәреп алдылар. Беренче курсны тәмамлады, авылга кайтмады, икене бетерде, кайтмады, өс-башны бөтәйтәм дип пристаньдә эртилгә керде. «Күрсәтермен мин сезгә алтыбишне!»— дип, авылы ягына шактый ныгыган йодрыгын күрсәтте.

Шунда тулай торакта яшәп яткан Казан арты кызы Наиләгә өйләнде.

Көзгә яңадан тимерлеккә кайтты, укуын дәвам итте. Кыш уртасында аның белән әртилдә эшләгән егетләрне кулга алдылар. Иптәшләре Нәҗипкә сиздермичә генә шактый кара эшләр кыйраткан нар икән, шул калкып чыкты. Нәҗипкә кагылмадылар, гаебе юк иде. Мәгәр милициягә чакыртып, прокурорга йөртеп, кат-кат судка чакырып теңкәсенә тиделәр. «Заводтан ял алып эшләп йөрдем, аны-моны белмим, күргәнем юк!»— дип чатнап торды егет. Заводта һәркем исәпле, шигәйделәр, бәйләнергә сәбәпләр чыгып торды. Тимер чүкүче эштән китеп тора икән, алмашың юк, чүкечең тик тора, цехлардан килгән заказлар үтәлми, бер бирделәр егеткә шелтәне, икене, гарьчел Нәҗип түзмәде. «Әһә!— диде,— төкерәм мин сезгә!»

Авыр эштән ялыккан да иде, көне буе тимер тапаганнан соң университетның физика факультетында уку җиңелдән түгел. Көн азагына ми кайный, җилкәгә һәм күкрәккә кургаш калканнар асылына.

Эш — акча ул. Эшең юк икән, кесә тиз такырая. Нәҗипнең маясы тиз эреде, нәкъ шул көннәрдә Наиләсе бүләккә малай алып кайтты. «Тилеме әллә сез?»— дип бот чапты күргән-белгәннәр. Нәҗип укый, курс эшләрен тапшыра, ә акча юк. Наилә декретта, ары-бире талпынды да ир-ат яши торган бүлмәләрне җыештыручы булып ялланды. Ир сүзен-сүз итеп, институтын ташлаган иде. Завод китапханәсендә дә эшләп йөрде, мәгәр кетепханәченең акчасы... Тефү!

«Түзик!— диде аңа ире, тешен кысып.— Түзик! Укып кына бетерим, дөньясын учымда биетермен!»

Аларны тораклан куа башладылар, ялынмады Нәҗип, инәлмәде, хатынын, имчәк баласы Искәндәрне җитәкләп чыгып китте дә урам себерүче булып ялланды. «Бөек кешеләрнең язмышы урам себерүдән, табак-савыт юудан башланган!»— диде ул көлә-көлә.

Наилә, моңарчы ирен алла итеп санаган сүзсез-өнсез хатын, бу юлы көлмәде...

Урам себерүче Нәҗип Нургалиевкә сүтәргә билгеләнгән өч катлы йортның беренче катыннан, ишеге ачылган саен суык болыты бөркелеп керә торган почмактан, бүлмә бирделәр. Бүлмә гади түгел — таракан, кыргаяк һәм сычканнар оясы иде.

«Кайт заводка!»— дип инәлде Наилә. «Юк! Илдә чыпчык үлми».— дип карышты ире. «Чыпчык булып калдык-постык чүпләп йөрергә риза була торган затмы соң син?!»

Наилә кемгә, нинди кияүгә тап булуын шәйли башлаган иде.

«Күрәчәгең булса, күркә талап үтерер!» Беркөн, кичкырын, үзе вакытлыча хуҗа булып алган урамны себереп маташканда Нәҗипкә исеме белән атап кемдер эндәште. «Нәҗип авылдаш!» Күтәрелеп караса — Вәдүт! Яшьтәше. Нәҗип сер бирмәде, шакмаклы дәү картузын батырып киде дә, читкә борылып танавын сеңгерде. «Кемгә дәшәсез? Я вас не знаю!»— дип, себеркесен култык астына кыстырып, утын сарайлары арасына кереп югалды. Моннан ары урамда күренеп йөрергә ярамый иде. Нәҗип эш эзләргә тотынды.

Кулай эш табу җиңел түгел, беренче карашка гына ул бөтен почмакларга игъланнар эленгән: «Килегез! Күрегез! Урнашыгыз!» Бара башлыйсың, йә ул эш өч сменалы, йә анда махсус белем, әзерлек сорала, сабы килсә, җәбе килми, җәбе килсә, сабы ярамый! Айга якын җайлы эш эзләде Нәҗип, тапмады, акча бетте, фатирдан куа башладылар.

Коймә комга терәлде.

Наиләнең туганнан туышкан абзасы бар иде шәһәрдә, Фәтхулла абыйсы, промбазада ниндидер мөдир булып эшли. Урыны тып-тын, базасы дәү түгел, нәни генә предприятиенеке, бер көнне, ютәл белән интеккән Искәндәрне чырылдатып, парлашып Фәтхуллаларга барып керделәр. Өч көн ашаганнары юк иде. «Ичмасам, сыйланып кайтырбыз!»— диде Наилә.

Әлегә аның ирен әрләп сыңар сүз дә ычкындырганы юк иде.

Асты кирпеч, өсте нарат бүрәнәдән, үз йортлары белән тереклек итеп яталар тегеләр. Тимер капка, капка төбендә үк ике эт, берсе медалист, доберман пинчер, икенчесе — овчарка. Өрмиләр, яшькелт күзләре ут булып яна, хуҗа ымласа, өзгәләп ташлаячаклар.

Борыннары сизгән икән, табын өстенә туры килделәр Нәҗип белән Наилә. Миңсылу апалары аларны икенче катка, залга, кунаклар янына өндәде. Наилә, читенсенеп, апасы янында калды. Нәҗип, кыенсынып кына өскә менде. Урам себергәндә тотылганнан бирле егетнең кикриге шиңебрәк йөри иде.

Хуҗалар симертеп тана суйганнар икән, сугым ашына кунак дәшкәннәр, табын тирәсендә Фәтхулланың үзе төсле үк елгыр, үзе кебек үк тук, затлы киенгән өч ир утырышканнар иде. Тавышларының көр, чырайларының канәгать булуыннан Нәҗип кунакларның инде шактыйдан утырганнарын абайлады. Фәтхулла абыйсы аны гадәттәгедән зурлап, баш орып каршылады, утырдашларына: «Университет шәкерте! Галим! Көне килгәч мәртәбәле зат булыр, танып калыгыз, онытмагыз!»— дип таныштырды. Тегеләр: «Бәрәкалла, дөньяда йомыш төшмәгән кеше буламы? Онытмабыз!»— дип, куен кесәләреннән алтын каләмле ручкалар, бәрхет тышлы дәфтәрләр чыгарып, егетнең исем-фамилиясен теркәп куйдылар. Адресы, телефоны, әш урыны юк иде егетнең, ул тиргә батып утырганда Фәтхулла абыйсы бусын тиз көйләде: «Шушы арада һәммәсе булырга тиеш, ачыклагач өстәмә хәбәр итәрмен»,— диде.

Сөберке коллыгыннан әлерәк котылган Нәҗипнең абзыйсын кочаклап елыйсы килде, күптәннән җылы сүз ишетмәгән җан эреп китте. Фәтхулла алтын путалы чәркәләргә юмарт итеп аракы койды. Кунаклар сүз берләшкәндәй: «Яшь иптәшнең алдагы мул, кайгысыз тормышы өчен!»— дип уртлап куйдылар. Шешә бушады, яңасы килде, табактагы калҗалар, мартта яуган кар таулары кебек, тиз-тиз эреде. Фәтхулланың дуслары тамакка таза икән, Нәҗип тә сынатмады, симез-симез калҗаларны тозга мана-мана бөкте генә!

Күптән аракыдан авыз иткәне юк иде аның, тиз исерде, беренче чәркәдән үк башына китте, ул бик бирелеп кунакларның әңгәмәсен тыңлап караса да, ни сөйләшкәннәрен аңламады. Алар татарча сөйләшәләр дә кебек, татарча да түгел, табындашлар ярты сүздән, ым-ишарәдән бер-берсен аңлыйлар, йә көлеп җибәрәләр, йә чырайларын бозып кемнәргәдер яныйлар да шикелле иде. Димәк, болар һәммәсе дә күптән төйнәлгән, борынгы дуслар. Тора-бара бу мәҗлес кызыксыз һәм мәгънәсез тоела башлады, карын туйды. Нәҗип: «Әш табыгыз миңа, хөрмәтлеләр, кулай әш!»— дип чүт кычкырып салмады. Исереклеген сиздермәскә тырышып, утырган урындыгына ике кулы белән чытырдатып ябышты.

Кунаклар озак юанмады, тиз-тиз эреп таралдылар, тимер капка артында машиналар тавышы ишетелеп калды, Фәтхулла абзыйсының кунакларны озата чыкмавы гына исендә калды Нәҗипнең.

Ялгыз калдылар. «Йә, сөйлә, нинди нужа китерде сине безнең катка?»— дип сорады Фәтхулла абзыйсы, егетнең әлегрәк үзеннән читтәрәк йөрергә ярatканына кинаялап. Нәҗип чишелеп китүен сизми дә калды. Фәтхулла текә маңгаен җыерып тыңлады, җавабы катгый һәм кыска булды: «Тапкан каушарлык хәл! Муены булса, камыты табылыр! Бер елдан пенсиягә чыгам, алтмышым тула. Бүгеннән ярдәмче итеп алам да үз урыныма калдырам». Нәҗипнең үе болганган иде, абзасын аңлап бетермәде: «Минме? Физик башым белән? Промбазада мөдирме?» Ул ялварып, адашкан көчек кебек күзен мөлдерәтеп, мәрхәмәтле абзасына карады. Фәтхулла үпкәләмәде, көлеп куйды. «Кунакларны күрдеңме? Кемнәр дип калдың инде син аларны? Торгашлар дип белдеңме?» «Белмим»,— диде ныграк

каушап Нәҗип. «Берсе очкычлар ясаучы берләшмәнең директор урынбасары.— Фәтхулланың саллы алтын балдак белән авырайган симез бармагы һава сөзде.— Икенчесе финанс институтының хуҗалык эшләре буенча проректоры. Өченчесе исә, өченчесе... Анысын кычкырып әйтергә ярамый: «Черек күл» буеннан!»

Нәҗип кинәт айнып китте.

«Университет дипломы белән син мондый каттә кешеләр арасына керерсеңме, юкмы, әйтә алмыйм, теләсәң, кулымда көч барында, замана безнеке чагында, мин сине шулар арасына ныклап урнаштырам». Нәҗипнең тагын елыйсы килеп китте. «Әллә кай төшеңне яраттым!» — диде Фәтхулла аларны озатканда. Балалары юк иде Фәтхулла белән Миңсылуның.

«Ә мин Миңсылу ападан әҗәткә өч йөз сум алдым»,— диде Наилә, трамвайга кереп утыргач. Искәндәр сүзсез генә прәннек кимерде. Нәҗип дәшмәде, күңеленнән генә кемнәргә, күпме акча бурычы барлыгын санап барды. Санады, очына чыга алмады. Трамвайдан төшкәч телгә килде: «Килер бер көн! — диде ул, билгесез киләчәккә йодрык күрсәтеп,— безнең урамда да бәйрәм булыр!»

Тук карыннан ваемсызланган Наилә иренә шикләнеп һәм ышанмыйчарак карады, дәшмәде.

Бәргәләнә торгач, анда-монда сугылып тәмам сөмсере коелган Нәҗип мебель кибетенә грузчик булып эшкә керде. Теге чакта пристаньда әртилдә бергә эшләгән шадра Вафаны очраткан иде. Нәҗипнең хәл-әхвәлләре белән танышкач, Вафа кычкырып җибәрде: «Кил үзебезгә, урнаштырам. Ну, парин, судта егетлек күрсәттең. Мәңге онытмам!» «Мин берни белми идем ич!» — диде, гаҗәпсенеп Нәҗип. Шадра бармак янады: «Белмәгән ди! Тунадык без анда баржаларны. Ә син сатмадың. Синең белән утка-суга кереп була!»

Нәҗип үзенең авыллыгыннан, беркатлы сарык булуыннан гаҗиз калып телен тешләде.

Бер кыш шунда үтте. Күнеккәч, эш җайлы диярлек, әле Казанда йортлар тәбәнәк, тимер чүкеп ныгыган беләкләргә нәрсә ул шкафкөзгеләрне дүртенче, бишенче катка меңгерү? Кулдан-кулга очыртып кына йөртәләр. Хуҗалар белән Вафа чыш-пыш сөйләшә, акчаны да ул ала, фокусчымыни, тырышып-тырышып күзәткәләсә дә, Нәҗипнең күзе иярми дә кала. Шадра эшне оста йөртә, җеге җеккә сеңеп утыра!

Нәҗипнең риясызлыгын, авыллыгы чыгып бетмәвен аңлагач, Вафа салган баштан ачылып китте: «Биш мең сәмәнең булса, ике бүлмәле квартирны мин сиңа момент табам!» — диде. «Биш мең? Син миннән: «Күпме бурычың бар?» — дип сора». Вафа егылып көлде, ышанмады, бармагын янады: «Ну син! Беләм! Кыланып күрсәтәсең инде!»

Бер җәһәттән нык булды Нәҗип, укуын ташламады, имтиханнарын вакытында бирде, контроль эшләрен соңлатмады, укыды.

Мебель кибетеннән китәргә кирәклеген аңа кадрлар бүлеге түгел, шадра Вафа җиткерде: «Сине эшкә мин чакырдым,— диде ул,— мин сиңа китәргә дә кушам». «Нигә?» — диде бик аптырап Нәҗип. Вак-төяк бурычлардан котыла башлаган көн иде. «Иптәшләр синнән шикләнә». «Ник шикләнәләр?» — диде Нәҗип, кинәт боегып. Вафа башын чайкады: «Аракы эчмисең, акчаның ни икәнен белмисең». «Эчәргә вакыт юк, эштән соң кая барып йөргәнне беләсез ич!» — диде Нәҗип рәнҗеп һәм кызарып. «Бездә укыган кеше кирәкми, диләр. Укыган кеше — шикле ул, һич уйламаганда таралып китүе бар. Бер елың калдымы?» «Ел ярым»,— диде авырыксынып Нәҗип. «Туты,— диде Вафа,— диплом алгач, сине кая аткаралар? Мужыт милициягә! Мужыт прокурор янына?» Нәҗип көлеп җибәрде: «Юкка шүрлисез, физик мин. Заводка урнашам». Шадраны аударып бүлма-

ды, ул кисте дә куйды: «Китәсең дигәч китәсең!»

Гыйнвар азагында Наилә тагын бер йомры башлы малай алып кайтты, исемен Рөстәм дип куштылар. Таныш-белешләр аларга шикләнеп карады: акылдан шашканмы әллә бу Нургалиевләр? Кеше өстендә торалар. Нәҗипнең төпле эш урыны юк, фатирлары кайчан була? Бала артыннан бала ташыйлар!

Артта да сүз йөртteләр, күз алларында да «җүләрләр!» дип атадылар.

Наилә беренче тапкыр, елый-елый, маңгаен как өстәлгә бәрә-бәрә зарланды: «Туйдым бу тормыштан! Тәмам гарык!» Нәҗип очына-очына, хатынының иңбашларын сөя-сыйпый аны юатты: «Диплом керсен кулга. Диплом — без көткән оҗмах ишегенә ачкыч! Платон Платонович мине ярата, кафедрада эшкә калдыра. Күр дә тор, профессор булачакмын. Университет ректоры җәмәгате булуыңны күт тә тор!»

Наилә тынычлангандай кыланды, әмма иренә бөртек тә ышанмады. Олы малайны, ташбаш Искәндәрне Казан артына, бабаларына илтеп куйдылар. Тамаксау булды бала, тавык ите ярата, алма-груша-лар сорый... Әйдә, бабаларында бераз тамак үткәрсен әле!

Платон Платонович Захарчук Нәҗипнең кафедра мөдире иде. Озын буйлы, чөй сакаллы какча кеше, эре бөртекле кашлары күз читенә таба ишелеп төшкән. Карт булса да, тешләре ап-ак, моны белгән Захарчук, сөйләшкәндә вакыт-вакыт авызын ерып куярга ярата иде. «Кафедрада каласың, Нәҗип Йосыпович»,— диде ул кыш уртасында. «Платон Платонович Нургалиевне калдыра икән»,—дигән хәбәр шунда ук таралып өлгерде. Бергә укыган студентлар икегә бүленде: берәүләр эчкерсез котладылар, икенчеләрнең көнчелектән борыннары салынды, алар ачыктан-ачык дошманга әйләнделәр. Дөнья таный башлаган Нәҗип моны бу юлы бик дөрес аңлады.

Захарчук икәүдән-икәү генә сөйләшкәндә: «Лабораториядә, кафедрада калдырам. Тема аласың. Җиң сызганып диссертациягә тотынасың»,— дип ычкындырды. Бу яңалыкны Нәҗип берәүгә дә, хәтта Наиләсенә дә әйтмәде!.. Атаклы профессорның шәкерте булып йөргәндә дошманнарның шактый булачагын акылы исәйгән Нәҗип хәзер белә иде инде.

Диплом якларга атна калды дигәндә Платон Платонович Нәҗипне дачасына чакырды. «Вакытың булырмы?»— дип сорады. Остазы чакырганда вакыт тапмыймы соң Нәҗип?! «Язын анда вак-төяк эш табыла»,— диде ак тешләрен җемелдәтеп профессор.

Поездан төшкәч тә ул бакчаны бик тиз эзләп тапты. Платон Платонович: «Мин кичтән үк барып кунам, сиңа эш әзерли торам»,— дигән иде. Платон Платоновичның бакча йорты бүтәннәрнекеннән нык аерыла, шактый юан бүрәнәләрдән биек итеп салынган, такта верандасы да иркен, куе яшелгә буялган. Йортның ике кыегына эленгән ике оядан алмаш-тилмәш сыерчыклар очып чыгып, хуҗаларның табигать җанлы икәнен дөньяга чәчәләр. Йортның ишеге, хуҗаларның күңеле киңлеген раслап, киерелеп ачылган, морҗасыннан каен тузы янган тәмле ис таратып юаш кына төтен чыга. Нигәдер шигәебрәк атлаган Нәҗипнең күңеле бердән тынычланды. Бөтен җирдә — ком сибелгән сукмакларда, яшел яфрак белән бизәлгән җимеш агачларында, тәбәнәк, рәшәткәле коймаларда яз исе, яңарыш, уяныш исе.

Ул ачык ишектән сәлам биреп кергәндә верандада ике кеше бар иде. Берсе профессорның үзе, икенчесе йөз чалымнары белән аңа охшаш, буй-сыны белән дә аңа тартым, озын куе чәчле, өске ирене тирәсенә юка төк йөгергән, олы күзле кызмы, хатынмы тагын берәү бар иде. Хуҗа да, ят хатын-кыз да аны гадәттән тыш җылы каршыладылар. «Чәче ат кылы сыман катыдыр моның?»— дип,

үз-үзенә гаҗәпләнеп уйлады Нәҗип. Кафедраның котын алып торган Захарчук бүген тәкъвә, юаш һәм диндар мәчет картына охшап калган иде. Баш түбәсенә чәпәп куйган мөселманча кара түбәтәй аңа килешеп тора һәм, кырыслыгын җуеп, мөлаемлек, сөйкемлелек өстәгән иде. Аны-моны сорашкалап, ары-бире бер-ике сүз алышкач, чишендереп, кулын юындырып, аны җылы йөгергән эчке якка, залга чакырдылар.

Залда табын әзерләнгән икән. Табынның дача өчен мул һәм искиткеч зәвыгын Нәҗип бер карауда шәйләп алды. Аңа, моңарчы тамагын да юньләп туйдыра алмаган ир-атка, табын да, олы күзләре белән аны туктаусыз капшаган озын ханым да ошамады. «Чишендерәме әллә бу мине?»— дип уйлады ул кинәт. Һәм бу ямьсез уй, шул ямьсез уй тудырган авыр тойгы күңеленнән һич китмәде. «Ат кылыдыр моның чәче!»— дип уйлады ул, тагын да ныграк борчылып. Уйларыннан качар өчен сүз сөрешен эшкә борды. Платон Платонович, тешләре белән мактанып алгач, озак кына сөйләп ташлады: «Эшләргә өлгerербез! Көн озын! Менә Галинаның нигъмәтләреннән авыз итик, кызым бу минем. Нәҗип Йосыпович, бердәнберем, әнисе вафатына уникe ел, шул гомер эчендә ул мине тәрбия итте. Ходай тәгалә ул бирмәде! Кем улдан, кем кыздан уңа дигәндәй, гомерем белән мин кызыма бурычлы! Бакчага чакырдым чакыруын, ә монда төп хуҗа Галина. Без ни, картлар, бүген бар, иртәгә юк. Галина минем бердәнбер варисым. Хәзер мин монда кунак кына. Ризыгын татып карыйк, Нәҗип Йосыпович, аннан эшне сезгә Галина табачак!»

Этисенең шактый озынга сузылган сүзен Галина басынкы гына тыңлап торды, катышмады. Нәҗип, профессорның һәр сүзеннән эчке мәгънә эзләштереп, аның әле күтәрелеп киткән, әле күз яшьләренә манчылып моңсуланган тавышыннан, үзенең җайсыз бер хәлгә тап булуын чамалый башлады. Тел төбе чамадан тыш татлы һәм куркыныч дәрәҗәдә йомшак иде Платон Платоновичның. Мондый тел ярарга тырышканда яки ялчыларда гына була.

Галина, вак-вак атлап, фарфор савыт алып керде, пилмән исе таралды. Тәбәнәк, киң чәркәләргә коньяк коеп, бер-икене йотып куйдылар. Ашарга өзмәс кыстасалар да, эчәргә Нәҗипне өндәүче булмады. Аштан соң, болай, сүз дөреслеге өчен генә бакчага чыктылар. Бер тәрәзәнең наличнигы какшаган икән, шуны каккан булдылар. Нигез тирәләренә ике чиләк ком сипкәч, эш бетеп тә куйды. Захарчук үзе бер читтәрәк булышты, Галина юка иреннәрен бөреп, чытлыкланып, гел Нәҗип янында уралды, чүкеч алып килде, кадак сайлашты.

Гел юк-бар белән маташып гаҗиз булган Нәҗип, төшке чәйдән соң китәргә җыенды, «Хатын, балалар көтә»,— диде.

«Хатын, бала-чагалар»,— дигәч, Платон Платонович белән Галина бер-берсенә сәер генә карашып алдылар. Нәҗипнең баядан бирле күңелен кырып торган шиге көчәйде. Нигә әле ата кеше аны кызы белән ялгыз калдырырга тырыша? Сүз арасында гына Галина үзенең кияүдә булганын, ирдән уңмаганлыгын, аның көнетөне эчеп тәмам юлдан язганын сөйләп үткән иде инде. Галина белән киявенең ике арадагы низаглары шәһәргә саркып чыккан иде. Нәҗипнең дә бу хакта нидер ишеткәне булган икән, сөйләшә торгач ул шул гайбәтләрне хәтерләде. Ялгышмаса, «Платон Платоновичның кызы гаять холыксыз, тупас һәм усал нәмәрсә»,— дип сөйләгәннәр иде. «Шул кешене миңа сыламакчы буламы әллә бу карт бүре?»— дип уйлады Нәҗип һәм остазын «бүре» дип атаганын абайламый да калды.

Галинаның шома битенә саубуллашканда вак-вак җыерчыклар кунган иде, ул Нәҗипкә ике бармагын гына бирде дә, кырт борылып,

йортка кереп китте. Платон Платонович аны бакчалар капкасына хәтле озата барды. Ябык капкага барып җиткәч кенә: «Сез, Нәҗип Йосыпович, өйләнгән кеше икәнсез».— диде. «Ике балам бар!» «Шактый йомык икәнсез, белмәгән идем». «Нигә йомык?» «Бер дә үз тормышыгызны сөйләгәнегез булмады». Нәҗип көлемсерәде. Ниен сөйлисең? Акчасыз, фатирсыз, әшсез җәфа чиккәннәрен чәчеп йөрсенме? Серен ачсынмы? Белми калсыннар әле!

Платон Платонович артыгын төпченмәде, сөякчел бармаклары белән Нәҗипнең кулын кыскандай итте дә, кармак сабы кебек озын, нәзек сынын туп-туры тотып, үрә катып кайтып китте.

Диплом якланды, комиссия әгъзалары Нургалиевне тоташ мактадылар. «Кичкедә укып мондый уңышларга талант кына ирешә ала!»— диделәр. «Хезмәт, һичшиксез, кандидатлык диссертациясенә нигез була ала»,— диде күрше институттан килгән вәкил Захаров.

Остазына тулы өмет баглаган Нәҗип Йосыф улы Нургалиев ирекле диплом алып чыккан иде.

Мөнәсәбәтләр көтелмәгән якка борылды. Платон Платоновичны сагалап, кафедра ишеге тирәсен байтак саклады ул, ниһаять, очраштылар. «Мин яңа кафедра ачуны күздә тоткан идем, министрлыктан җавап алдык, ул эш барып чыкмаслыгын хәбәр иттеләр. Кызганыч»,— диде профессор, Нәҗипкә кырын күзен дә төшермичә. Нәҗип, кылган яхшылыклары өчен остазына рәхмәт әйтеп, Юрий Петрович Захаров янына ашыкты. Доцент Захаров урыныннан торып, хөрмәтләп каршы алды. Кул бирде. «А как же! Хәтерлим! Дипломыгыз сокланырлык иде. Сезгә шул юнәлештә эшләргә кирәк, эшләргә!» Нәҗип читенсенеп кенә рәхмәт әйтте һәм бүгенгә үзенең эшсез калуын белдерде. Захаровның алтын кысалы күзлеге төшеп китә язды. «Ә Платон Платонович?»— дип сорады ул төкселәнеп. «Аның белән борчагыбыз пешмәде»,— диде һаман хәйләгә остармаган Нургалиев. Юрий Петровичның алтын кысалы күзлеге калтыранган бармаклары арасына күчте, ул иягеп алга чөеп, шытырдатып кашып алды.

«Яшермим, сез талантлы егет. Киләчәктә сездән шәп белгеч чыгуы бик ихтимал,— диде Юрий Петрович, тамагын урынлы-урынсыз кыргалап,— тик шунысы бар: шәһәребезнең абруйлы, иң күркәм галиме белән борчак пешерә алмаган яшь иптәш минем белән пешерер дип уйлыйсызмы?» «Эшләп карыйк, Юрий Петрович! — диде гади генә итеп Нәҗип.— Мин белештем: сезнең кияүдән кайткан кызыгыз юк икән!»— дип шаяртырга теләде. Захаров боргаланыпсыргаланып тормады: «Платон Платонович белән арамны бозасым килми!»— дип ярып салды.

Кылган мәрхәмәте, туры әйтүе өчен аңа да рәхмәт әләкте. Захаров янына Нәҗип әвене янып кергән иде, балтасын суга төшереп чыгып китте. Фәнни тикшерү институтларын йөреп чыкты, төрле оешмаларга кагылды, профиле туры килердәй берләшмәләргә керде, кай ишеккә кагылмасын, Платон Платонович исеме калкып, Нәҗип Нургалиев бар җирдән дә тәртәсен кире борды. Беркем аның укымышы, әзерлеге, белеме белән кызыксынмады, һәр очраган кеше остазы белән арасы бозылуының сәбәбен белергә теләде. Захарчук кадәр Захарчук кызы өчен шулай әчелешле булып йөрмәс инде, остаз белән шәкерт арасын, бәлки, бүтән сәбәпләр бозгандыр? Ул дөресен әйтмәде, дөресен сөйләмәгәч, бар җирдә дә аннан шикләнделәр, сагаеп сөйләштеләр һәм, әлбәттә, үтенечен кире кактылар. Арадан бер иптәш, егетнең шактый михнәт чигеп йөргәнен белгәннән соң, өстәл артыннан ук чыкты, Нәҗипне аркасыннан сөеп диванга утыртты һәм кап-кара бөдрә сакалын тарый-тарый мәсьәләне ачыклап бирде: «Киңәшем шул: Платон Платоновичтан хәер-фатыйха, ягъни рекомендация алып килмәсәгез, институтларның, фәнни оеш-

маларның ишеге сезгә ябык. Нишлисең, тормыш аяусыз. Захарчукның кулы җитмәгән почмак шәһәребездә юк. Йә бүтән якка юл тотыгыз, йә завод-фабрикалар тирәсеннән эзләп карагыз!»

Рәхмәтен аңа да җәлләмәде Нәҗип.

«Әллә киңәшкә өлкә комитетына кереп карарга мы?»— дип Ирек мәйданында каңгырап йөргәндә, аның турысына өр-яңа, елкылдап торган кара «Волга» килеп туктады, аннан теге чакта Фәтхулла абзалары табынында танышкан иптәшләрнең берсе чыкты. Ирексездән аларның күзләре очрашты. «Безне ходай очраштырды!»— диде кыюланып Нәҗип һәм, тәвәккәлләп, үз хәлен кыска-кыска сөйләп бирде. Иптәш ашыга иде, ул күзен обком ишегеннән алмады, кесәсеннән визитка чыгарып Нәҗипкә тоттырды һәм: «Иртәгә сәгать унберенчедә шалтырат»,— диде. Кәгазь иясе, чыннан да, Горбунов берләшмәсенең директор урынбасары Храмов Иван Кириллович икән. Татарча үтә шома сөйләүче бу керәшен Нәҗипне дәртләндерде, ул икенче көнне, кушылган вакытта урынбасарга шалтыратты.

Завод идарәсе урнашкан йортның өченче катына тыны-өне бетеп менде, Храмовның кабинетын көч-хәл белән эзләп тапты. Күзебашы тонган иде егетнең. Фәтхулланың исеме үз эшен эшләде, урынбасар аны кемнәргәдер тәкъдим итте, телефоннан кат-кат шалтыратты. «Документларыңны җый!»— диде ул ахырдан. «Алары үзем белән»,— диде егет, каударланып. «Ашыкма,— дип бүлдерде аны җитди кеше,— син безнең эшнең асылын онытма. Укыган җиреңнең спецбүлегеннән белешмә китер. Ни кирәген алар белә. Туганнарың хакында белешмә кирәк. Авыл советыннан, колхоздан. Исәннәре кайда да, үлгәннәре кайсы зиратларга күмелгән. Шәт, чит илләрдә якыннарың юктыр? Яшермә!» «Юк, юк!»— дип кабатлады Нәҗип, сөенеп. Була калса, моннан да борып чыгарачаклар икән. Хәзер исә актыккы өмет монда, язмыш җәя бавы булып тартылган, «йә пан, йә пропал!»— оҗмах капкасын шушы кеше ачса ача, юк икән, дөньяда ник пыскып яшәргә?!

Тәки урнашты Нәҗип, кирәкле кәгазьләрен тапты, авылдан да җибәрделәр, борыны белән җир сөрдә егет, мәгәр һәммәсен җиренә җиткерде. Бөтен кешедән алда килде, иң соңгы кеше булып бүлмәдән чыкты. Күрсеннәр генә аны, белсеннәр! Кушканны җиренә җиткерде, кушмаганны үзе белеп үтәде. Беркемгә каршы сүз әйтмәде, килешмәсә дә түзде, чыдады. Шимбә өмәләренә рәттән чыкты, заводтан совхозга җибәрделәр, өч атна яңгырга-карга батып авылда ятты. Күрсеннәр генә! Стена газетасы чыгарды, бүлек мөдирләре, цех башлыкларының гына түгел, секретарь кызларның, идән себерүчеләрнең кәефенә ярарга тырышты. Директорның көнлек режимын өйрәнеп, коридорда аны очратырга, бөгелеп сәлам бирергә гадәтләнде. Күрсен генә! Бөтен начальствоның туган көннәрен белеп алды, хатын-кызларга чәчәк ташыды, ирләрне телефон аша котлады. Болар белән генә алдыра алмагач, нәүмизләнеп, башын ташка орыр дәрәҗәгә җитеп, ярсып та йөргәләде.

Ниһаять, көн төште! Ул дипломында яңа энергия чыганаклары эзләү мәсьәләсен күтәргән иде, заводка шул юнәлештәге заказлар бирелде. Нәҗип Йосыф улы Нургалиев кичә тәлинкә тоткан хезмәттәшләренә җилкә чокырын күрсәтә башлады, күрешкәндә ике бармагын гына бирде. Коллоквиумнарга аны җибәрделәр, фәнни дискуссияләрдә авыз ачып ул беренче сүзне әйтте, ул эшләгән лабораториягә илнең төрле заводларыннан заказлар ява башлады. Мәскәүдән алты айлык курсларга чакыру килеп, «кемне җибәрергә?»— дигәндә, җитәкчеләр Нургалиевне атадылар. Бу инде ышану, хөрмәт казану иде. Нәҗип яшерен өметләр, усаллана башлаган канатлы хыяллар белән башкалага китте. Ул аннан бөтенләй бүтән, олы кеше булып кайтачак! Татыган газаплары, кимсетүләр, җәбер-

җәфалар өчен ул кемнәрдәндер үч алачак әле! Сак булыгыз!

Гаиләдә фәкыйрьлекне, кимлекне хатын-кыз аерата авыр кичерә. Гомере буе туя ашамаган, юньле өс-баш күрмәгән Наилә, инде иренә ышаныч югалды дигәндә, җиргә басып түгел, ак болытларга утырып кына йөри башлады. Зур мөмкинлекләр яулап кайтачак ирен нинди күлмәк киеп каршылауга кадәр уйлап куйды Наилә. Һич тарсынмыйча, Миңсылу апасыннан өстәмә дүрт йөз сум әҗәткә алды, кунакка кемнәрне чакырырга кирәклеген барлады. Ире башкаладан мөдир булып кайтачак. Бер мөдир булып алган кеше, номенклатурага кергәч, һичкайчан төшеп калачак түгел! Күтәреләчәк аның Нәҗибе!..

Хыяллар һич уйда юкта тар-мар килде, өмет киселде, акчалар өс-баш карарга түгел, күңелсез юл чыгымнарына тотылды. Ир белән хатын арасын ныгытып килгән татлы уйлар ялган, буш куык булып чыкты. Әнә, дөньяны учында кысып тотып, язмышларын күккә чөяргә әзерләнгән бәндә хәзер биләүле бала хәлендә, күзе белән ялварып, иреннәре белән актык сүзләрен әйтергә тырышып, күз көеге булып ята. Утыз өч яшендә гарип, инвалид, адәм көлкесе, аяклы каза, җәфа, бәла һәм моннан ары бары тик хәсрәт-газаплар гына китерәчәк бичара.

Нәҗипнең сул күзеннән дәү бер тамчы тәгәрәп чыкты да Наиләнең кул аркасына тамды. Ирен генә түгел, Наилә үз-үзен дә танымады, күзеннән чыт итеп яше чыкмады, ирен кызганмады ул, күңеленең кайсы төпкелендәдер Нәҗипкә ачуы ташыды. Ирен чеметәсе, үтмәс пычак белән турыйсы, «Ялганчы! Хыянәтче! Сүзеңдә тормаган буш куык!» — дип кычкырасы килде аның. Дөрес, бу мәгънәсез ярсулы ташкын аны әзгә генә тетрәндереп тотты, әмма бу булды, күңелгә керде. Хатын-кыз күңеленә тирән керген тойгылар бер чакта да онытылмыйлар.

Ул, акылына килеп, як-ягына каранды, ширмалар артында һәркемнең әҗәл белән у з е н ч ә тартышып ятуын абайлап, икенче тапкыр иренең күкрәгенә капланды. Бөек хыяллар йөртүче Нәҗип Нургалиевнең атна эчендә саргайган яңаклары буйлап ике бөртек тонык яшь тамчысы тәгәрәде. Наилә дә еларга тырышып карады, елый алмады.

## 4

Өч атнага якын шифаханәдә яткырып, эчен ак, сары, яшькелт дару төймәләре белән дыңгычлап тутырып, беләкләрен, ябыккач бөршәеп калган артын төрле зурлыктагы уколлар белән тишкәләп бетергәч, Нәҗипне чыгарып җибәрделәр.

«Йөрәк шаярганны яратмый. Инфаркт юк-югын, ләкин йөрәгегез нык ук зәгыйфьләнгән. Стресслар заманы, шуның нәтиҗәсе. Кыскасы, кардионевроз, миокардит, кыскасы, күкрәк бакасы стенокардиягә бер адым калган булган. Режимне кискен үзгәртәсез! Фән белән шөгыльләрне кичектерәсез, күпкә түгел — бер елга, аннан күз күрер. Казан врачлары рөхсәт итсә, җиңелрәк эшкә урнашып торасыз, хәлегез бар икән, озаграк ял итәрсез. Бераз аруланугa, Кавказга, Кисловодскига нарзан ванналарына, тау һавасына барасыз. Даими һәйбәт тукланырга, болын һавасы суларга, чишмә суы эчәргә, борчылмаска, кайгырмаска, кабаланмаска, ярсымаска, үз вакытында шау-шусыз урында йокларга, вакытында торырга, режимны бозмаска! Сезгә, авыру иптәш, хәерле юл телибез!»

Инфаркт яшәрде. Нәҗип яткан палатадагы өч ирнең өчесе дә утыз белән кырык арасындагы яшьләр иде. Бераз хәл алуга, аларны

бер сорау гына борчыды: хатыннарны кайчанрак куенга алырга мөмкин булачак!?

Бу четерекле сорау аның күңеленә килмәде, аны бүтән яклар — эш урын, дәрәҗә, квартира мәсьәләләре ныграк талкый иде. Хатын качмас анысы, кичерер дә.

Нәҗип Йосыф улы Нургалиев, белемен яңа тәгълиматлар, өр-яңа юнәлешләр, чит илләрдә барган эзләнүләр белән ныгытып, Казанның атаклы заводларының берсенә лаборатория мөдире булып кайтырга киткән җиреннән, әнә шулай кәгазь — кәҗә билеты тотып, Татарстанның томанга, сөремгә, төтенгә, көлгә, тузанга һәм шау-шуга чумган гүзәл башкаласына кайтып төште. Урыны плацкарт, аның да ян кырыйдагысы, аның да бәдрәф янәшәсендәгесе иде. Төне буе керфек какмады. Ни уйларга да белмәде егет, кайсы якка гына уен юнәлтсә дә, уй йә упкынга очып төште, йә булмаса кара язмыш юлга чыгарып куйган таш кыяга килеп орынды. Әкияттәге кебек, каршысында әле кара урман, әле шашкын елга, әле ут ташкыны булды. Үтәр әмәл дә, яхшы күңелле сихерче биргән коткаргыч эманәтләр дә юк. Кеше аңының иң кыен мәле, уйламыйча да ята алмыйсың, уйларыңның җебе юк, нигезе, юнәлеше тотрыксыз, алар сине язгы ташкындагы йомычка кебек чайкалдырып йөртәләр, яр якын да кебек, ләкин чыгар юл юк, якынлашам дигәндә генә ул тагын да ераклаша...

Поезд Бишбалтаның кырыгынчы завод корым-сөременнән түбәнгә чүккән гарип йортлары арасына барып кергәч, ул суга егерме тамчы валокардин тамызып эчте. Наиләсенә күшеккән тавык булып күренәсе килмәде.

Наилә Нәҗипне караватта яткан хәлдә күреп кайткан иде, вагон ишегеннән ыбыр-чыбыр тутырган иләмсез төенчек тотып чыккан килбәтсез ирен күргәч, чак егылып китмәде. Пәлтәсе иңнәрен сытып аска салынган, чалбар балаклары гармунланган, күз читләренә саргылт эрен касмакланып каткан... «Әйберләр вагонда, күрерсең. Уфалы иптәш озатты. Син кереп ал инде, миңа авыр күтәрергә ярамый».

Наилә Искәндәрне җитәкләп, Рөстәмен күтәргән иде, берсен читкә кагып, икенчесен әтисенә тоттырды да бушап калган вагонга җил-җил кереп китте. Мәскәүдә очрашканнан бирле аны бер газап биләде: «Ничек яшәрбез без? Ничек гомер итәрбез?» Вагон аша Нәҗипнең китап-дәфтәрләрен өстерәп алып чыкканда, ул икенче улларын, Рөстәмне алып кайтуларына үкенде. «Ичмасам, берәү генә булса икән!»

Җил мехкомбинат ягыннан иде. Казан күген кара җилпәзә, февраль болытлары каплаган, көн чамасыз җылыткан, урамнар ярым караңгы, саграк шоферлар машина күзләренә ут төрткәннәр. Алар җиденче трамвайдан төшүгә, борынга сасы тире исе, комбинат кыш буе таратып урамнарга, агач ботакларына, баганаларга, йортларга сеңдергән авыр ис килеп бөркелде. Күктән эре-эре корым кисәкләренә уралып җепшек кар бөртекләре төшкәли иде. Әйбер-караларны Наилә ике тапкыр килеп алды, Рөстәмне күтәреп, Искәндәрне җитәкләп ире аны урам читендә көтеп торды. Көч-хәл белән, җепшегән карлы уйсуларда тая-тая, өйгә кайтып җиттеләр. Наилә манма су булды, пәлтә якасын чишеп җибәрде. Хуҗаларның җиргә тия язган тәрәзәләренә кырын күз сала-сала, үз ишекләренә, аргы башка үттеләр.

Мәскәүдән, мәһабәт пулатлар, Кремль йолдызлары янынннан ялгызы кайткач, Наилә, өенә керергә хурланып, гарьләнеп еламсырап басып торган иде. Бүген, ике баласын җитәкләп, чирле ире егылмасын дип борчылып кайткач, аны-моны уйлап тормады, фәкыйрьлек, мескенлек аларның гаиләсенә төс кебек тоелды.

Искәндәр, кучтәнәч күтеп, этисенең бөктәрләренә ымсынып карады. Әле ярый, уфалы татар, китәр алдыннан, «улларыңа», дип, бер тартма «зефир» тыккан иде, рәхмәт аңа, шуны тартып чыгаргач, малайлар, песи балалары кебек мыраулап, кучтәнәчкә ябырылдылар. Наилә, бәрәңге пешереп, аны бала юрганы белән төреп куйган икән, кара-каршы утырып, озакка сузарга тырышып шуны ашадылар, чәй эчеп алдылар.

Көн үтте, ашыгып кич килде. Нәҗип чак кына тынычлангандай булды, аңа карап Наиләнең дә эчке бураннары бераз басыла төште, ул: «Ходай биреп, тиз генә сәламәтләнеп, ныгып китсә... тормыш элеккеге эзенә кайтмасмы әле?!— дип, яңачарак уй беркетергә тырышты. Йокларга ятканнар гына иде, биләмнән Таңсылу кайтып керде, дөп-дөп басып ишекле-түрле йөрде: нидер аударды, шакылдатты, өстәл-урындыкларны, спектакль әзерләгән режиссер сыман, шкафларны урыннан-урынга күчерде, күрше бүлмәдәге энкәсенә Африкага ишетелерлек итеп кычкырды, җырлады. Ярты төнгә шае аның үчегү концертын тыңлап үткәрсәләр, төн авышкач, тимер юлда маневр паровозлары эшкә тотынды. Тәбәнәк кенә зәңгәрсу нәрсәләр киндер станының кылычыннан чыккан буй җепләр кебек тезелгән суык рельслардан ак, зәңгәр светофорларның туймас ихтыярына буйсынып, вагоннарны арлы-бирле тараттылар. Ми шарларын түндерергә теләп сызгырттылар, багана башына мәңгелеккә менгән радиорупордан дежур хатын-кыз кемнәрнедер өзмәс каулады, карлыккан исерек тавышлы кемнәрдер аңа хәбәр җиткерергә тырышып, нидер акырдылар, яман сүзләр белән таңны сискәндереп сүгенеп җибәрделәр. Рельслар дөбердәде, тәрәзә, бүрәнә аша суык сыкы белән ят авазлар кереп тулды, тар караватта тырпылдап яткан ике җан, җилгәргеч иләгендә ялгыз калган ике борчак кебек, һаман бер-берсеннән ераклашалар иде. Наилә һаман: «Ничек яшәрбез без? Ничек көн күрербез?»— дип тын гына уфтанса, Нәҗип, тел астына валидол салган саен: «Алай гына бирешмәм! Эйзенхауэр унике инфаркт кичергән! Бишәр инфаркт алганнар да яши! Йөрәкне ныгытырбыз, күңелгә йомшарырга ирек бирмәбез! Чак кына ял итәргә, эзгә генә түзәргә! Һәм изүне чишеп эшкә ябышырга!»— дип яңача иманын тәкрарлап ята иде.

Наиләнең иртәнге хәбәрләре җанны җылытмады. «Үлмәгән Захарчук, үләме соң? Декан ясаганнар үзен. Менә шул»,— диде ул чәйнеккә су салганда. Керогаз өстеннән гөлдердәп тавыш биргән чәйнеккә кушылып, Наилә икенче бер «сөенче» белән уртаклашты: «Ә Фәтхулла абыйны яңа эшкә, югарыга референт итеп күчерергә теләгәннәр». «Ә ул?» «Улмы? Бармаган!» «Җүләр!— диде кинәт Нәҗип.— Бу заманда кулыңда нәни генә власть юк икән, син тулы хокуклы кеше түгелсең!» «Алай димә... Власть ике төрле була ул, берсе аның күзгә күренә, икенчесе күренми. Бездә хәзер яшертен экономика, яшертен власть бар дип сөйлиләр ич!» Нәҗип: «Кемнән ишеттең?»— дип төпченмәде, ул сорашырга җыенган арада хатыны өченче яңалыкны әйтеп, аның авызын йомды: «Ә теге, кем соң әле, шадра инде... Мебель кибетендә бергә эшләгән идегез...» «Вафамы?»— дип сорады Нәҗип. «Шул инде, шул! Кибет директоры иткәннәр үзен!»

Дүрт класс белеме белән, русчаны түгел, татарчаны да такытокы гына белгән Вафа директор?! Бусы, чыннан да, искитәрлек иде...

Наиләнең кич алып кайткан яңалыгы аяз көнне күк күкрәгәндәй булды. Ул өйгә кызарып, ашыгып, мышнап диярлек кайтып керде: «Чихрадзе пенсиягә киткән!»— дип әйтеп салды. Нәҗип өйдә көне буе ялгыз калып, әле йөреп кереп, әле ятып шактый тынычланган иде, дерт итеп кабынып китте. «Гайбәт! Алтмыш аңа көз көне тула»,

«Күзне күтмәгән инде, сәбәбе булган». Наилә башта сәбәбен әйтмәде, балаларны берсен бакчадан, икенчесен яследән алып кайтырга кирәк иде, озак кына тарткалаштылар, соңга кала яздылар. «Беләсеңме — бел,— диде Наилә ярым кызып,— Чихрадзеның хатыны вафат икән...» «Әйе,— дип җөпләде аны Нәҗип,— былтыр күмдек». «Алар йортында, күршедә ун яшьлек бер кыз яши икән, элек тә, Чихрадзеның хатыны исән чакта, аларга гел кергәләп йөргән. Хәзер дә Чихрадзе аны еш кына дәшеп ала икән. Кәнфит белән сыйлый, тәмле сулар эчертә, юк-барны сораша торган булган». «Шуннан? Моның ни гаебе бар?» «Бар шул!— диде турсаеп Наилә,— көннәрдән бер көнне карт пәри, гөрҗи, кызның гыйффәтен тотып карый башлаган, бер тоткан, ике тоткан, кыз гәүдәле икән, җитеп килә!.. Оялып башта беркемгә бер сүз ычкындырмаган, ахыр, Чихрадзе моны кыса башлагач, йөгереп чыккан да әнкәсенә сөйләп биргән. Кыз зыян-зарар күрмәгән икән! Ашык-пошык кына пенсиягә озатканнар карт иблисне!»

Хәбәр бик хәтәр иде, Нәҗипнең зиһене томаланып, башы иңкеп китте. Күзгә кадәр ул элеккеге хәлемә кайтырмын дип нык ышана иде. Ныгыр өчен ял итәргә, күңелне яңа халәткә өйрәтергә кирәк иде. «Сиңа эшкә чыгарга туры килер»,— диде Наилә туп-туры. «Шулай булыр, ахрысы. Минем айлык больничныем бар барын...» «Заводның хәрби фәнни лабораториясен мөдирсез ай буе тотмаслар»,— диде Наилә ышаныч белән. «Бер-ике көн түзик, миңа күнегергә кирәк, Наилә». «Ике көн түзәрбез... Урын түзәрме? Шуны да уйла!»

«Әй Чихрадзе шыр тиле икән! Беткәнмени аңа хатын-кыз? Алай талагы ташыса, әнә безнең Таңсылу белән таныштырырга иде үзен!»— дип ычкындырды Нәҗип ишектән чыгып барганда.

Икенче көнне ул больницага барып каралырга, киңәшергә, эшкә чыгарга рөхсәт алырга тиеш иде. Наиләсенә «барам, барам» дип калган иде, бармады. Иртәдән үк көннең рәте булмады, башы авыртып торды, бертуктаусыз җепшек кар яуды, буран купты, тәрәзәләрне томалап юеш кар ябышты. Урын өстендә шактый аунагач, ул калкынып торды, киенде, кая барасын да уйламаган килеш, капка төбенә чыкты, аяк йөзен күмгән ябышкак карны ерып, Яңа бистәнең Бродвее — Мәҗит Гафури урамына чыкты. Аның сагышын арттырып тегеләй дә, болай да трамвайлар үтте, пычрак чәчеп машиналар каядыр ашыкты. Кинәт хәрәкәт азайды, машиналар тизлекләрен киметеп туктап калдылар. Нәҗип шәһәр ягыннан килгән, билен киң кара пута белән буган мәет машинасы катафалканы абайлап алды...

Мәет машинасы! Җеназа! Машинада җансыз гәүдә, үлек ята...

Кемдер төп итеп аның күкрәгенә китереп сукты, күз алды караңгыланды, ул бер мәлгә Мәскәүдәге кебек, яшәү белән әҗәл арасында кысылып калды. Аяк бармаклары чемер-чемер итте, бугазына кайнар кургаш тулды, сулышы авырайды. Аның бөтен күзәнәкләрен, аңын, зиһенен курку биләде. Ул җеназага катнашкан машиналарга күзен күтәреп карарга куркып шактый басып торды бугай, җепшек карга чумган аякларына дым бәрде, суык үтте. Аның яныннан узып торган кешеләр: «Көпә-көндез салган, ахрысы, бу исерек!»— дип борылып-борылып та карадылар.

Нәҗип Йосыф улы Нургалиев тагын бер тапкыр тормыш белән саубуллашып алды, коты ботына төште. Гүя, әнә шул дәһшәтле, кара билле аяусыз машинада а н ы ң гәүдәсен салып Яңа бистә зиратына илтәләр иде. Өенә кадәр исән-аман кайтып җитә алса ярый ла!..

Шулкадәр күңелсез, шулкадәр авыр иде аңа! Офыклар кап-кара, юллар чуалган, бара-бара да әллә кая, янга каерылып кереп китә, егылмас өчен койма такталарына, капка баганаларына ябыша. Аны күреп сәерсенгән этләр дә өрмәс булдылар, койрыкларын болгап

«Кая барып бәрелер икән бу бәндә?»— дип аны озата киттеләр...

«Беттем!»— диде аның күл төсенә кергән иреннәре, «үләм» дигән уй күңеленә сеңде, һаман ныгый, берегә барды. Ул, уеның юнәлешен үзгәртергә маташып, Наиләсе, балалары турында хәтерләргә азапланды, алар искә төшкән саен, Нәҗипнең өметсезлеге тирәнәя бара иде.

Кайтып житте, урам капкасын ачык калдырды, кыеш баскыч төбенә житкәч, тотка тимеренә ябышып торды. Кергәч, пальтосын иңеннән шудырды да, көч-хәл белән пычрак, юеш ботинкаларын ычкындырып, караватка менеп ятты. Аның кайтканын ишетеп теге яктан Таңсылу килеп чыкты һәм йөзтүбән капланып яткан Нәҗипнең арык җилкәсенә майлы, симез йодрыгы белән берне кундырды. «Тор! Күтәрәм сыер булдыңмы әллә? Ятасың да ятасың!» Нәҗип аһылдап йөрәк турын учы белән каплап торып утырды, Таңсылуга нәрсә: авыз мыймылдык, күз-каш тирәләре каймаланып бизәлгән, колак алкалары болыт арасында уйнаган яшендәй елык-ялык килә, авызлыклап куйгач, текәләнгән күкрәкләре тирбәләләр. «Йә, ни диден әле син кичә хатыныңа? Кемгә сыларга ниятлисең син мине? Әрмәнгәме, грузингамы? Сатар алдыннан товарның сыйфатын үзең бел! Ошамасам, теләгән кешеңә аткарырсың!» «Таңсылу дим, чакыр ашыгыч ярдәм машинасын!» «Нәрсә? Ни иркәләнеп ятасың? Мин синең җебегән хатының түгел, хәзер уятырмын...» «Үләм!» Таңсылуның халат төймәләре каптырылмаган икән, ул шәрә тәне белән сөзешергә килә башлады. «Затсызланма, Таңсылу!» «Җебемә, хәйван!» «Чакыр врачларны... үләм... йөгер!»

Таңсылу, гөбе-гөбе ботларын ачып ташлап, татлы хихылдап караватка ук менеп ятты, Нәҗипне стенага кысрыклады. «Ашыгыч ярдәм кирәк, имеш. Менә мин синең ашыгыч ярдәмең! Чирләгән икән берәүләр, һай алла! Хатыныңны алда! Марҗалар белән себерелгәнгә укуыңнан куганнар сине. Тап-таза ир, ходаем, утыз өч яшьтә! Мәскәүдә! Тик ятканга йөз илле тәңкә акча! Кругом кызлар! Негр марҗалары белән себерелгәнсеңдер әле? Бер танышым сөйләде, аларның уч төпләренә кадәр зәп-зәңгәр ди... Сөйлә инде! Йә!»

Нәҗип, йомык күз, ыңгырашты. «Таңсылу, күрмисеңмени? Үләм!» «Күрмим, күрмим! Яле күрсәт!» Таңсылуның бармаклары өзелеп калган кәлтә койрыгы булып кыймылдады, әллә кайларга кереп китте.

Ә Нәҗип, чалкан яткан да, аңын югалтып, җәйрап онытылган. Таңсылу шашынып-акырып чап-чоп үз ягына чыгып чапты, хушбуй исе таратып халат итәкләре җилфердәде.

## 5

Наиләне профкомга дәшеп алдылар. «Үткән елгы кәгазьләрне күздән үткәрәсе бар, әз-мәз миңа булышырсың, озак тотмам»,— диде Изил Латыйпов. Латыйпов үз исеме белән горурлана, җай чыккан саен: «Исемем — Изил, эти кушкан, минем кем буласымны, җәмгыятьтә күркәм урын аласымны алдан ук белгән. «Ис-пол-нитель заветов Ильича». Мондый исем белән югалмас заман киләсен шәйләгән!»

Озын, нәзек муенлы, бәләкәй башлы, төксез иякле бу кеше ике хатын аерып, хәзер буйдаклар өеренең башы булып йөри иде. Очраган бер сөйкемле хатынга күз кыса, һәркайсысына аның сыналган, шома төче сүзе бар, буфетта чират булса, ул күңеле төшкән ханымнар артына басарга тырыша, ышкына, ялгыш дигән булып аның шәрә беләгенә кагылып китә, түшенә орына, һич тайчынмый, үзеннән шактый өлкән хатыннарның колак итен тешли-тешли оятсыз

мәзәкләр сөйли. Наилә бу кешенең күзенә чалынмаска, аннан читтәрәк йөрергә тырыша иде. Моңарчы теләге кабул булса да, бүгенге чакырудан баш тарта алмады. Изил Латыйповны күрергә, аннан бик кирәкле бер-ике белешмә чокып алырга кирәк иде. Нәҗипнең чирләп егылганын, Казанга кайтып төшкәнен заводта беләләрмеюкмы? Бу бер. Икенчесе, Чихрадзе урынына мөдир булып кем киләчәк? Җитәкчеләр арасында нинди сүзләр йөри?

Изил Латыйповның дөньяда белмәгәне юк иде.

«Балаларны Нәҗип барып алыр, аңа юаныргa бер шөгыль булыр»,— дип тә уйлады Наилә.

Изил кабинетына кергәч тә, бүлмә хуҗасы Наиләне атылып килеп каршылады, өстен салдырышты. «Һаман чәчәк атасың, Наиләкәй! Матурлык алиһәсенең үги кызымы әллә син?» Яшь хатыннарның һәммәсенә «син» дип эндәшкән Изилгә Наилә үпкәләмәде. Тагын бер-ике төче мактау сүзе ычкындыргач, Изил, гадәтенчә, мәзәк сөйләп ташлады. «Төрмәдә, бер камерада бишәү утыралар икән. Берсе караклык өчен эләккән, биш ел биргәннәр, икенчесе талауга катнашкан — сигезне ямаганнар, берсенең дә сандыгы буш түгел, ә бишенче кеше почмакта авызына су кабып утыра икән. Тегеңә унбиш ел чәпәгәннәр, ди! Кысалар тегене, әйт тә әйт, нигә шулкадәр клиндер ашаталар сиңа? Аптырагач, йөдәгәч, теге бәндә: «Өч шыртлака өчен бирделәр срок!»— ди икән. «Өч шыртлака өчен унбишне өяләрме, дурак!»— дип бәйләнәләр икән камерадашлары. Шуннан сөйләп биргән теге. «Барам күл ярыннан, карасам, җирдә бер кирпеч ята. Бер ягына «динамит» дип язу ябыштырганнар, икенче ягында да шундый язу. Койрыгына ут төрттем дә күлгә тондырдым теге кирпечне... Карыйм, өч шыртлака һәм дүрт водолаз калкып чыкты»,— ди икән теге...»

Изил көлеп туктагач кына Наилә елмайгандай итте. Ә Изилнең борыныннан куык атылып чыкты. Суык тидергән икән профсоюз лидеры. Оятсыз Изилнең бүген кыюлыгы җитмәде, вакытсыз борынына кунган куык дәртен сүрелдердеме, Наиләне ярты төнгә калдырмады, майлы күзе белән капшанса да, кулын күкрәгенә сузмады. Алай да, кәгазьләрне сортка аерып, папкаларга теркәп шактый утырдылар. Көн соңарды. «Изил,— диде Наилә, мөмкин кадәр тәмле телле булырга тырышып,— Чихрадзе урынына кемне мөдир итәләр?» «Ә миңа кем булса да барыбер»,— диде бераз чытлыкланып Латыйпов. «Барыбер үк түгелдер лә! — диде күз карашын аңа текәп Наилә,— заводта кадрлар сайлаганда соңгы сүзне син әйтәсең диләр ләбаса!» Бу юлы аткан ук туры тиде, Латыйпов урыныннан сикереп торды, тар күкрәген алгарак чыгарып, күз алмаларын тәгәрәтеп Наиләгә таба атлады. «Анысы хак... Тырышырга туры килә. Һәр чакта да минем белән киңәшәләр. Әлегә Чихрадзе урыны буш». Бу хәбәрдән Наилә дә сикереп алды, моны үзенчә аңлаган Изил, келәйле бармаклары белән аның түшенә үрелде. Нинди әрсез, аңгыра һәм бушкуык ирләр бар бу дөньяда! Әгәр Изил бу минутта Наиләнең күңелен нинди уйлар өермәсе биләгәнен, йөрәгенең ничә градуслы утларда дөрләп янганын белсә... Кулы сузылуга Наиләнең хәсрәт утыннан очкын алып, кара күмер булып янар иде. Шушы секундтан Наилә бөтен эшен сукырларча башкарды, һич нәрсә уйлап, баш ватып тормады. Изил: «Тек», дисә, папканы текте. «Җый!»— дип боерса, кәгазьләрне берәмтекләп җыйды, үзе дә сизмәстән, эченә-тышына кара кайгы уралган җанлы курчакка әйләнде...

Яңа Бистәгә баручы алтынчы трамвай бүген тәмам чукынды, юк та юк! Тылсым белән тартып китерер иде Наилә, тылсымы юк! Ярсуы белән янына сөйрәр иде, шәһәр трамвайлары Наиләнең ярсуын аңлый торган түгел шул. Яннан гына дәү-дәү кара «Волга»ларга

киерелеп утырып шома-шома кешеләр үтә. Ишек пыялалары аша аларның чиртсәң кан чәчрәп чыгарлык тук чырайлары, кыйбатлы бүрекләре һәм текә күтәрелгән хәтәр танаулары гына күренеп кала. Тизрәк өйгә кайтып керергә, «урын буш!»— дип Нәҗипне дәртләндерергә һәм, иртәгедән дә калмыйча, заводка җибәрергә иде. Аның Нәҗибеннән дә лаеклырак кандидатура юк, алты айлык курсларның дүрт аен тәмамлады, аның ире елдам кеше, аласы белемне алгандыр!

Тукталышта кара болыт булып торган халыкны суык җил куып таратты, ниһаять, аргы яктан җәяү килгән бер мәрхәмәтле җан: «Юкка көтәсез, анда авария, трамвай белән машина бәрелешкән!»— дигәч, Наилә дә җәяү кайтырга җыенды. Бүтән чара калмаган иде.

Шәһәрдән Яңа Бистәгә шактый ара, караңгы, ике арада фонарьлар юк, әрле-бирле йөргән машина утлары гына шыксыз бушлыкны, җилләр уйнаган мәйданны, кар өемнәрен, боз кантарларын яктыртып уза. Сул якта әллә кайчаннан, юл төзүчеләрдән калган күгәргән калай вагон тора иде, курка-курка Наилә шуңа якынлашты. Тып итеп вагон артыннан каршысына килеп чыккан шәүләне күргәч, Наилә коелып иңде, батон белән сөт шешәсе салган чүпрәк букчасы кулыннан төшеп китте. Букчаны иелеп алганчы шәүлә кешегә әйләнде, уң кулы белән хатынның җиңен эләктереп алды. Ярсыган хатын кулында теләсә нәрсә — корал! Наилә ике аягын аерып басты да, букчасын, стадионнарда чүкеч ыргытырга җыенгандагы кебек, һавада болгый башлады, бер-ике адым чигенде. «Якын килмә!» Шәүлә һаман якынлашкач, букчаны бар көченә тегенең баш түбәсенә кундырды. Шешә ватылды, шәүләнең бүреге агарды, ул лып итеп артына утырды. Наилә җилдәй чабып аны үтеп китте, урамына кайтканчы йөгерде.

Капкадан керүгә, Тимерхан картның төнгә чылбырдан ычкындырыла торган шалбыр коерыклы алама эте «Звонок» абалап өрергә тотынды. Ни булган аңа? Ул абына-сөртенә өйгә керде, бусаганы атлап узгач, тын тартырга куркып тыңланып торды. Нәҗибе дә, балалар да өйдә юк иде. Кайтып җитмәгәннәрме әллә? Кайда булыр болар? Керогаз өстендә моңаеп утырган ятим чәйнекне капшап карады, суык. Мич тә ягылмаган. Мичне бер көнне Таңсылу, икенче көнне алар яга торган иде. Бүген — алар чираты. «Таңсылу апа!» Теге якта карават яман шыгырдады, күнеккән колак Таңсылуның бер яктан икенче якка авышуын чамалады. «Таңсылу апа!» Суык тавыш, җанны өшетеп: «Ни бар тагын?»— дип сорады. «Нәҗип кайда, белмисеңме?» «Нәҗип?»— дип кайтарды күрше хатын, соравына нәфрәт, җирәнү кушып. «Балаларны алып кайтмадымыни?» «Күрәсең ич, юк». «Ни булды соң?» Яши башлаганнан беренче мәртәбә ул Таңсылу ягына чыкты. Бүлмәнең бөтен стеналары, тәрәзә арасы, гөл чүлмәкләре, урындык артлары атаклы артистларның рәсемнәре белән тулган иде. Хәтта көзгегә дә чибәр-чибәр, бөдрә чәчле, фырт киенгән артистларның рәсемнәре ябыштырылган. Утырма көзге итәгендәге киштәгә мең-миллион төрле вак-вак шешәләр тезелгән иде. Киң һәм биек караватта, каз мамыгы тавында, ботын-чатын аерып Таңсылу ята, кулында көмеш саплы нәни эскәк белән түгәрәк көзге. Чәчен тузгытып ташлаган да үз яңакларының калкулыкларын, уйсулыкларын, тауч
ыкларын күзәтә. Бармак очы белән зәңгәр тәрткеле борын очына басып нидер үлчи, нидер саный. Наилә ни ашыкса да, бер карауда бүлмә эчендәге тәртипне, чисталыкны, пөхтәлекне абайлап өлгерде. «Нәҗип кайда?— дип кычкырды ул җан ачуы белән. «Скорый белән алып киттеләр җебегәнеңне!»— диде түшләрен уйнатып Таңсылу. Наиләнең кот очарлык кыяфәте аны куркытты. «Йөрәге начарланды да мин скорый чакырдым». «Ә балалар?» «Балаларыңның кайтканы юк!»

Наиләгә ике яктан ике ут беркелде: ике бала, икесе ике җирдә! Сәгать ничә хәзер? Ун тулып килә икән! Кая чабарга? Ничек икегә ярылырга? Җитмәсә, Таңсылу, теше сызлагандай чыраен сытып: «Мич ягылмаган, өй катып үләрлек»,— дип ярага тоз сипте. «Таңсылу апа!— дип кычкырды Наилә,— син хәзер балалар артыннан чабасың!» «Чапты диярләр...» «Чабасың!— дип кабатлады Наилә һәм караватк янына килеп, Таңсылуның ботын каерып ыргытты.— Тор!» Таңсылу дәшмәде, борын тишекләреннән, ирен арасыннан ешеш пар-тын беркелде. «Мин Нәҗипне юлларга ашыгам, балаларны син алып кайтасың. Берәр нәрсә ашый торырлар. Мичкә кайткач ягармын». «Ярый инде, үзем ягармын. Балаларың кайсы бакчада соң синең?» Наиләнең күз чокырларында ут уйнады: «Кыланма! Беләсең! Берсе мәчет янында, икенчесе мәктәп янында!»— дип кычкырды ул аяусызланып. Таңсылу нидер мыгырдап караваттаудан төшә калды. Наилә йортның өлкәннәр яши торган ягына атылып керде. «Җәмилә әби! Ун сум биреп торыгыз!»— дип кычкырды. Тимерханның күгәргән бугазы калтыранды, аннан: «Әбиең туталарына китте, хаста булып егылган»,— дигән өн чыкты. «Тимерхан абзый, ун сум! Түләрмен! Бише белән кайтарырмын!» Хатынынан башка, аның әмереннән тыш диварга кунган черкине дә үтермәгән Тимерхан карт бүген Европа күләмендә батырлык эшләде. Карчыгының үлемтекләр, нафталинлы энҗе калфаклар, көмеш тәңкәләр саклана торган сандыгын ачып, калтыранган куллары белән таушалып беткән өч өчлекне һәм бер тимер берлекне алып бирде. Наилә Гафури урамына чапты. Салкын тагын да аяусызланган, кар тоташ шыгырдый башлаган иде. Наилә аны сизмәде, беренче туктаган машинага утырып, үзләре беркетелгән шифаханәгә чапты, анда кизү врачтан ашыгыч ярдәм машиналарының чирлеләрне Арча кырындагы 15 нче больницага ташуларын белде. Озакламый машина, кар чәчеп, шул тарафка очты.

## 6

Һәрбер хатын-кызның сере була, ә сер бер чакта да тик ятырга яратмый, аның тизрәк юл саласы, дөньяга чыгасы килә. Шуның өчен һәр хатын-кыз үзенә сердәш, сер алмашырлык якын бер кешене сайлап ала. Наиләнең дә бар иде андый сердәше, якын кешесе, Гөлнара исемле. Гөлнара институт тәмамлаган, телләр белә, техник информация бүлегендә эшли, ире дә югары урында, Министрлар советында хезмәт итә. Казанның иң мәртәбәле, иң затлы районында— Ульяновлар урамында, биш бүлмәле квартира билиләр, гаражлары ишегалдында, гаражда — «Волга»; кай яктан килеп карасаң да, тормыш дәрәҗәләрендә — тигезсезлек, әмма хатыннар бер-берсен тиз табыштылар, җиңел якынлаштылар. Наиләгә Гөлнараның шундый күркәм, атаклы кешенең хатыны булуы ошаса, Гөлнара Наиләнең басымчаклыгын, кыланмавын, кынҗырланмавын, сүз йөртмәвен, гайбәт ташымавын, гаиләдәге сафлыгын яратты. Наиләгә бөтәнчәрәк, үзе бер чакта да ирешә алмаслык югары катлау тормышыннан информация зарур булса, Гөлнарага, серен читкә чәчәргә ярамаган, киң һәм күп яклы тормышта яшәүче хатынга, сер сыярлык, бушанырлык, иң кирәк җирендә генә ямансулап бер елап та алырлык кеше кирәк иде, хатын-кыз. Күңелләр һәрчак бер-берсен эзли, зарыгышып кына булса да таба. Наиләдән: «Ничек, нихәлләрдә яшәп ятасыз?»— дип сорасалар, әле аның шикләнмичә һәм һич икеләнмичә: «Әйбәт! Без бик бәхетле!»— дип, чатнатып җавап бирә торган чагы иде. Ә Гөлнара — Наиләдән өч яшькә генә олы хатын, тормышның сирәк кешегә эләгә торган коридор-лабиринтларын үткән, югары

даирәләрдә ниләр кайнаганын, нинди бәрелешләр, астыртын көрәш барганын ире аша көн саен ныграк белә барган, тәҗрибәле, көнче, үпкәләүчән һәм гайбәтләрне итәгенә җыя торган ут күзле хатын иде. Нәзберек, һавалы, үзен дөньяда бер чибәр дип санаучы бу хатынның тормышына Наилә (әле ул ир хатыны булуның рәхәт тә икәнлеге хакында башына да китерә алмый иде!) кызыгып түгел, бары тик кызыксынып кына карый иде.

Атна уртасында Гөлнара бер көн ял ала, ул көнне республика китапханәләрендә чит ил журналлары белән танышa, дип исәпләнә. Әмма Наилә белә: Гөлнара ул көнне китапханәләргә эз дә басмый, алар биш хатын — шәһәрнең иң атаклы кешеләренең бичәләре — җыйналышып, иртәдән мунчага, саунага баралар. Шәһәрнең мәшһүр массажчысы, Кавказдан махсус чакыртылган әрмән Григорьян көн буе алар белән мәшгуль була. Мунча бүтәннәр өчен ябык, ишекләр эчтән тома бикләнгән, аулак, биш хатын, атна буе аякларына ияргән яңалыкларны кыска-кыска гына, көлешләрен пыскытып тыеп бер-берсенә бушаталар да, Григорьян хикмәтле могҗизаларын тормышка ашыра башлый. Озак һәм оста массаждан соң ул хатыннарның тәнен балга манчып чыга, бал бөтен күзәнәкләргә, эссе саунадан соң йомшарган бөтен әгъзаларга үтеп керергә тиеш. Балга манчылган ханымнар кәефләнеп, таралып, җылытылган мәрмәр сәкеләрдә шактый вакыт йокымсырап яталар. Балны аларга дәүдәү алюмин флягаларда юкә урманнары күбрәк, нефть-газ исләре ераграк районнардан китерәләр.

Бал сүрүне көчле агым белән юдыртып төшергәннән соң, хатыннар бер-бер артлы, сауна белән янәшә үк парлы мунчага керәләр, Григорьян аларны иренмичә, рәхәтләндереп чаба. Аннан ахирәт ханымнар, гөжләп торган дәү корсаклы самавыр янына утырып, бик озаклап, биш кат тирләре чыкканчы чәй эчәләр. Чәй табынына һәркемнең өеннән алып килгән кучтәнәчләре, затлыдан затлырак ризыклар чыга. Дөрес, эчемлек монда Григорьянга гына, аңа да эзләп кенә, көч китмәслек итеп кенә куела. Хатыннар тулы режим, диета һәм тәртип саклыйлар, ризыкны тычкан тешләредәй вак тешләре белән вак-вак кабып, тел очларында әвәләп, җиренә җиткереп чәйнәп ашыйлар. Ашаганчы да, ашагач та шунда аларның зифа сыннарын астыртын гына сагалап торган үлчәү табасына барып басалар. Һәр ханым дәфтәр ачып авырлыгын, кан басымын язып, саннардан айлык, ярты еллык, еллык нәтиҗә чыгарып бара. Чәйдән соң йоклап алалар, йокыдан соң бассейн, бассейннан туры саунага керәләр, саунадан соң ял, ял иткәч төрле физик күнегүләр ясыйлар, табигый рәвештә тир чыгаралар, кичкә кадәр алмаштилмәш тазаралар, сафланалар, көч җыялар. Кайтыр алдыннан Григорьян аларның йомшак, алсу тәннәрен хуш исле майлар белән уа, аяк, кул бармакларына өстәмә массаж ясый, тырнакларны алсуга буйый... Чырык-чырык килеп торган мунча кич соң гына бушый, шат авазлар тына, егерме бишлекләр иплэп кенә Григорьянның биш хатыннан калган хуш исләр аңкыган йөнтәс бармаклары арасына кереп югалалар...

Юк, теге мунча юлдашлары Гөлнара ханымның сердәшләре түгел, алары — көндәшләре, бары тик мунчада очрашырга гына яраган «тастымал телләр», ирләренең бер дәрәҗәдә булулары гына аларны тыгыз берләштергән, аларга сер ачсаң — беттең диган сүз! Ходай сакласын!

Аның мунчадан соң, икенче көнне сөйләшерлек хәле булмый әле. Өченче көнне ул шашынып Наиләне эзли башлый, кайвакытта эш арасында телефоннан шалтыратып чакырып ала, китапханә аулаграк булса, чабып анда килеп җитә, тын почмакларга алып керә дә мунчада булган вакыйгаларны, көндәш-иптәшләренең кыланмышла-

рын, анда ишеткән гайбәтләрен, хатын-кызларның тәннәренә, ирләр күзе төшә торган нокталарына агулы бәя бирә-бирә рәхәтләнеп, кинәнеп, буасы ерылып беткәнче сөйли дә сөйли. Наиләне үз итәрлек тә шул, сорау биреп бүлдерми, көнләшми, аңа бу сүзләр ерактагы шәрыкъ әкияте кебек кенә, тыңлый. Гөлнара сөйләгән дөнья аңа чын түгелдер шикелле. Нәни генә заводның шундый аулак, яшерен мунчасы булуын да, аның җылы ак мәрмәр сәкеләрен дә, күе зәңгәр кафель белән әчләнгән, асты җен-пәри сурәтләре белән бизәлгән бассейнын да күз алдына китерә алмый.

Наиләнең беркатлы булуы, бик нәни, энә очы хәтле шатлыкны да зур бәхет итеп кабул итә алуы, бозылмаганлыгы Гөлнарага аерата ошый иде. Гомумән, бозык хатыннар саф хатын-кызлар белән дус булырга омтылалар, алар әнә шундый риясыз хатыннарның беркатлы бәхетләрен күрүдән тәм табалар.

Үз хәбәрләре дулкынында чайкалып, Гөлнара ханым Наиләнең күзләренә карарга вакыт җиткерә алмый иде. Кызганыч! Ул бу күзләрдә нинди дәһшәтле шәүләләр уйнаганын, танышлык көчәйгән саен шәүләләрнең җанлырак була баруын абайлаган булыр иде, шәт...

Гөлнара белән арадашлыкның тәэсирен Наилә тора-бара ачыграк сизә башлады, аның да шул биш алиһә белән саунада буласы, моңарчы ят ирләр кулы кагылмаган тәненә массаж ясатасы, балга манчылып онытылып-онытылып ятасы килде. Һич югында бер генә тапкыр булса да!.. Үзе саунага керә алмаса, сыңар күз белән генә шул бәхетләре ташыган ханымнарны карап торасы икән! Нәҗибе Мәскәүгә укырга китеп, телгә «мөдир» дигән сүзләр кереп ныгыгач, ул Гөлнарага ныграк тартылды, үзен элеккедәй тигез тота алмады, ике сүзенең берендә аны мактады, олылады, вак-төяк йомышларын үтәде, китапханәгә алынган китаплар исемлеген башлап аңа кертте. Кыскасы, ярарга тырышты. Гөлнара да моны сизмәде түгел, сизде, берзаман Наиләне югалтасын чамалады һәм моңа кадәр аңа җиткереп торган хәбәрләрнең өлешен бермә-бер киметте. Саунага йөрүче бишлекнең берсе шушы араларда китәргә җыена, ирен Мәскәүгә, бик югары урынга күчерделәр, биш кулдан акча алып күнеккән Григорьян кереме кимүгә ризалашмас, азсыначак, Гөлнараларга бишенче итеп кемнедер алырга туры киләчәк, мөдир хатыны була калса, Наиләне бер сыр югары күтәргәндә ярый, сердәшен корбан итеп булса да, Гөлнара аны арага кертер... Ә сердәш... Ирең совминда эшләгәндә, үзең затлы, бай хатын булганда рухи коллыкка тәяр хатыннар әзме әллә шәһре Казанда?!

«Бишлек»кә Наиләне әзерләргә, аны сер хуҗасы итәргә һәм серен алырга кирәк иде. Нәҗип Мәскәүгә киткәч, Гөлнара Наиләнең кылын тартып карады: «Эш пешереп буламы бу чи кабартма белән, юкмы?» «Бер ир сине күргәндә күзләре белән ашый!»— диде ул, сүз арасында. Гаҗәп, беркатлы Наиләнең моңа һич исе китмәде. «Һәй!»— диде дә кулын гына селкеде. Икенче кат дәшеп бакты Гөлнара: «Әллә сиңа гашыйк булган инде?» Моңарчы юньле өс-баш күрмәгән, тамагына туя ашамаган, шулай да оятсыз тәкъдимнәрне, әрсез күз карашларын шактый очраткалаган Наилә «гашыйк» сүзен ишеткәч, түзә алмады, бите алланып, ике ими арасы тирләп: «Кем ул алай... тиле?!»— дип сорады. Гөлнара информация бүлегеннән бик чибәр, Нәҗиптән дә озынрак буйлы, киң җилкәле, элек, студент елларында, баскетбол уйнаган, куппы мыеклы Миша Суворовны атады. Наилә көлеп җибәрде, чебен кунгандай, кулын гына селкеде. Ул Гөлнарага ышанмады, юри, сынар өчен генә Суворовның исемен атады, дип уйлады. Завод хатын-кызларының яртысы Суворовка яшерен гашыйк икәнне ул бик яхшы белә иде. Ә икенче яртысы шушы еллар эчендә Суворов кулыннан үткән иде инде. Гөлнара: «Син яртылашларның кайсысына керәсең?»— дип сорагач, Наилә чын кү-

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ ◆ БАЛТА КЕМ КУЛЫНДА? ◆

ңеленнән болай дип җавап бирде: «Мин татар хатыны, ирем һәйбәт, улларым сәламәт, үзем тормышымнан канәгать!» «Канәгать?— дип ярым мыскыллап көлде Гөлнара,— син, бала! Канәгать булуның ни икәнен беләсеңмени син?» Гөлнара саксызлык күрсәтте, беренче мәртәбә сердәшен түбәнәйтте, сизенеп, тигезлекне торгызыр өчен, елмаеп Наиләне кочагына алды. «Ә син тормышыңнан тулы канәгатьме?»— дип сорарга базды Наилә. Һәм Гөлнара аңа менә нәрсәләр сөйләде:

«Үз иреннән тулаем канәгать асыл хатын-кыз була диме? Мин моны җенси яктан гына әйтмим, Наиләкәй. Яхшы хатынганиләр кирәген аңлап бетерә алган ир-ат бармы дөньяда? Аңласа, ул гади кеше түгел, ул йә җен-пәри, йә пәйгамбәр. Минем ирем аларның берсе дә түгел».

Гөлнара борынын мәзәк җыерып уйга калды, сердәшенең кочагыннан чыгып Наилә тагын сорау куйды: «Кем соң синең ирең?!»

«Минем ирем — вампир,— диде кинәт Гөлнара,— бу сүзнең татарчасын белмим, убыр микән, аждаһа микән, вампир — кан эчеп яшәүче ярканат була инде, җан иясләренең иң кабәхәте».

Наилә Гөлнараны бүлдермәде, керфек какмады, йотылып һәм йотлыгып тыңлады.

«Ул бер йолкыш студент иде. Минем әти, надан башы белән райком секретаре булып эшләгән кеше, соңрак әллә шул наданлыгын яратып Верховный Совет Президиумы әгъзасы да иттеләр үзен, укыган кешеләр арасыннан кемнәрнедер ярата да иде. Киявен әти күтәрде. Без — күп бала, әни бала ташыган да бала ташыган, мин — төпчек иркә кыз, яшь чагымда үтә беркатлы, менә сиңа сыңар, Наилә дускаем, кая карасам да, офыкта яктылык кына күрә алган бер зат идем. Өйләнештек, күземне йомып егет сайладым, сукыр килеш кияүгә чыктым. Әти тиз-тиз квартира юллады, ирем югарыга баскыч араталарын сикереп түгел, очып үтте. Карыйм һәм ни күрәм: кичәге ыштансыз студент — югарыда! Яшибез, тормыш иркен, тормыш мул, һәммәсе шәп, һич ихтыяҗ юк, эчәр суны чишмәдән ташыйлар, сөт-каймак, итне авыл хуҗалыгы институтының фермасыннан китерәләр, беренче сортлысын гына ашыйбыз. Бала туды, аны ике әби, ике бабай, кардәш-ырулар уч төбендә йөртәләр. Иремә тагын да югарырак урын юрыйлар, якын араларда өлкә комитеты секретаре булачак, дип җибәрәләр. Тирәмдә йөзләрнең юргалавына карап, үзем дә шуңа ышана башладым. Иркә кыз, иркә килен, Казанның сөеклесе булып яшәп ятам. Тормыш сере һич көтмәгәндә, бик гади генә ачылды да куйды... Һай, Наилә иркәм! Башта авыр булды, үләм дип торам. Беркөн шулай, иртән иремә чәй ясап йөрим, кулымда ак чәйнек, Япониядән алып кайтканнар иде бүләккә, тиктомалдан ирем башын кыегайтты да: «Гөлнара, мин акча югалттым... Син алмадыңмы?»— дип сорый. Сүзе колагыма юньләп кермәде дә, болай гына, шаяртып: «Күпме иде?»— дип сорадым. «Илле сум иде»,— ди теге. Коелып төштем, чәйнегем кулымнан ычкынып, затлы кытай ашъяулыгын буядым... «Син алгансың!»— ди бу... Китте ызгыш, купты талаш, элеп алдым теге мокытны, селкеп салдым. Җеп очы кулга тигәч алай гына ычкындыраммы мин ир дигән хәйванны?! Ирем миннән яшереп акча җыя икән! Аннан-моннан кергән ришвәт акчаларын алтмыш меңгә җиткергән бу! Саранлыгын беләидем, шул чакта комсызлыгын ачыкладым моның... Кырмыска сыярлык ярыкларга кадәр тыгылып өйне җентекләп тентеп чыктым, саклык кенәгәләрен, кыбырсык кәнтәйләрдән килгән хатларын, көндәлекләрен табып өйрәндем. Булыр-булмас ирләр җиңүләрен дәфтәргә теркәп үтәргә яраталар, бел! Белгәннәремне аңа ачмадым, кая ул! Куанам, дускаем, шул сәгатьтә мин рухи өлгереп җиттем, ныгыдым һәм бер ачыш ясадым:

гаиләдә тормышны мин алып барам икән! Мин! Тышкы яктан җилбәзәк күренсәм дә, бар авырлык, бар мәшәкать минем җилкәгә салынган икән. Минем көчем, энергиям, дәртем икебезгә дә яшәү көче, тормышыбыз чыганагы булган икән! Аллакай гынам, күрсәнә: ирем — вак, көнче, селәгәй бер бәндә, вампир сымак, убыр булып минем кайнар каным хисабына һаман өскә үрләп, дәрәҗә-орденнар алып һәм боларның һәммәсе дә үз уңганлыгы бәрабәренә килә дип масаеп, ир саналып йөри икән. О-о, гаиләдә ир ир булсын өчен хатын-кыз сансыз-исәпсез көч түгә! Ә мин ир урынына күкрәгемдәге кан хисабына яшәүче убыр үстергәнмен. Шуны аңлаганнан бирле, җан кисәгем, икенче тормышым башланды. Фырт иттереп киендем дә шәһәребезнең иң мәшһүр ир хатыннары белән бер сафка бастым, мунча ширкәтенә юлыктым, иремнән сукыр бер тиен сорамадым, үзем дә бирмәдем. Үземне гаилә башы дип игълан иттем һәм аңа кан бирүдән туктадым. Өлкә комитеты тәтемәде, орденнар яңгыры кыеклап үтте, мин аны ипләп-ипләп, сиздермәслек итеп, үзенең асылына — башмак астына төшерә башладым. Мәгънәсез икән, үсмәсен ир! Эшләсен, мал тапсын, ләкин үсмәсен. Бер хәлдә, күземә карап кына яшәсен.

«Теләкләреңнең барысына да ирештеңме соң?» — дип кыяркыймас кына сорады Наилә, Гөлнараның ирен җәлләп. «Ирешеп киләм. Илле тәңкәсен түгел, бәйсезлеген югалтты ул! Ак магия ярдәмендә ипләп кенә мин аның барлык рухын үземә алам!» «Ничек итеп?» — дип кычкырды тәкатьсез калган Наилә. Гөлнара көлеп җибәрде. «Мин аны сүзсез-өнсез ишәккә әйләндерәм! Ул чишенгәндә йә киенгәндә ике кулымны күкрәгемә кушырып арт ягына килеп басам да күз нурларымны җилкә тамырына, умыртка баганасына терим. Арка миен суырам! Кайчагында артына баскан килеш ике кулымны өскә күтәрәм. Үкчәм идәндә, бармак очларым һавада, ике арада яшен йөртәм, үч ташкыны үткәрәм. Ул хәлсезләнә, борылып карый, куркып кына: «Ни эшлисең?» — дип сорый. «Туңдым, җылынам», — дим мин аңа. «Минем җылымны аласыңмыни?» — дигән була, сораштыра. «Алсам, җылыңны җәллисеңме?» — дип авызын томалыйм тегенең.

Наилә Гөлнараның бичара ирен күз алдына китерде дә, бугазына килеп тыгылган яшьләрен көчкә тыеп, әңгәмәнең сөземтәсен, мәгънәсен көтеп калды. Мондый шәфкатьсезлекне, сихер ярдәмендә ирен изүне бер максатсыз эшләмәс ич инде аның сердәше?!

Тик Гөлнара сер капчыгын азаккача чыгарып селкергә ашыкмады. Наилә, тәкатьсез калып: «Максатың ни? Ахыр чиктә син нәрсә телисең?» — дип сорарга мәҗбүр булды. «Әүвәл башта мин аның җыйган малына хуҗа булырга телим. Элегрәк: «Чит илгә алып чык, йөрт, дөнья күрсәт!» — дип иналдем, колагына да элмәде. Әллә нинди хәйләләр тапты. Хәзер юк! Кая телим, шунда барам... Япониягә алып барачак ул мине, Австралиягә! Канар утрауларында ял итәсем килә минем! Мексикада буласым килә!.. Убыр-вампир миңа хезмәт итсен! Үлгәнче! Тагын ярты ел, бик күпкә түзсә, ел үтсен, аның җаны учка сыярлык булып, кеп-кечкенә калачак. Кеше җанына хуҗа булу гына хатын-кызга тулы бәхет китерә, Наиләкәй!»

Озак сөйләштеләр алар ул очрашуда. Наилә, әүвәл башта юаш кына, әле сокланып, әле кызганып, әле нәфрәтләнеп, ара-тирә җирәнеп тә тыңлаган Наилә, азакта бер акыл җыйнап калды — үз тормышына, читтән торып, ят, күпне татыган хатын булып — Гөлнара булып карады.

Ул да уңга-сулга тайпылмыйча, булачак иренең шапырынулы вәгъдәләреннән исереп, башын җуеп, егетнең шашкан кочагына ташланмадымыни? Дөрес, кочагы упкын булып чыкты егетнең, кызны берьюлы суырып алды, тибрәтте, иркәләде, оныттырды. Аһ,

ул ширбәт айлары! Наиләне юкә балына чумдырмадылар. Ул хыял диңгезендә, өмет-вәгъдәләр океанында бәхетне татыды.

Татлы төш бер өзелә, йокыдан уянмыйча ярамый. Наилә дә уянды, ләкин айнымады. Бер-бер артлы туган уллары, иренең комсыз тырышлыгы, юлда очраган киртәләрне эзлекле җиңә баруы аның күзен ал пәрдә белән каплады. Ул аңа, аның киләчәгенә, җиңәчәгенә ышанып яшәде. Ышанды ышануын, ә алар гаиләсендә энергия чыганагы кемдә булуын эзләп карамады. Дөрес, ире эшләде, кирәгендә мебельче грузчик булды, йөз чөерМәде — кулына себерке тотты, авыр чүкеч белән тимер чүкеде, алай да тормышның бөтен авырлыгы, ыгы-зыгысы Наилә кулында түгел идемени? Ире эштән, укудан арып, гасабиланып, болытлы көндәй кашларын сәлперәйтеп, телен тешләп кайтып кергәндә, бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы хезмәт күрсәткән хатын аны айдай балкып каршыламадымыни? Ире зарланды, Наиләгә зарланырга чират тимәде. Арган иренең җанын тынычландыру өстенә, тәнен дә иркәләргә кирәк иде. Ут чәчелергә тиеш иреннәр арасыннан иркәләү сүзләре генә чыкты, көне буе талган куллар, яргаланган бармаклар ирен иркәләделәр...

Гадәттәгечә, Гөлнараның куркыныч тәҗрибәләрен Наилә үзенчә кабул итте, ышанып ук бетмәде, мәгәр бер уй, бер тойгы күңелгә очлы ук булып китмәскә кадалды, һәм Наилә аны суырып алырга, яраның ямалуын ашыктырырга теләмәде. Ук аның мәшәкатьле тормышына татлы сызлау өстәп, күкрәккә кергән килеш калды...

Һәм, беренче тапкыр, ирен реанимация караватында, төбе тишек көймә хәлендә күргәч, ул аны бөртек тә кызганмады, күкрәктәге ук тагын да тирәнгәрәк үтеп керде, яра зурайды, тирәнәйде...

Ике баласы белән ирен поездда каршылаганда да күңеленә ачу хисе хуҗа булып торды...

Менә хәзер унбишенче больницага очканда, ике якта адашып калган ике баласы өчен борчылып тырпылдаганда ул, Нәҗибен балаларына кушып, бергә кызгана башлады. Моңа кадәр эчелгән нужалар алда көткән газаплар янында уенчык кына булачагын ул кар баскан шәһәр урамнарында ирен эзләп барганда аңлады. Таныш, күнегелгән урамнардан барганда да уйларның төрлесе иңә, бүген аның уйлары аяусыз, ачы һәм авыр иде.

Нәҗипне больницада нибары бер атна яткырдылар. «Хәлегез түзәрлек, инфаркт юк, анализлар әйбәт, ә больницада урын җитми!» дип, тайчанмыйча әйтеп бирде дәвалаучы врачы.

Тормыш тоташ газапка әйләнде. «Үлем», «әҗәл», «зират», «чир», «йөрәк» дигән сүзләрне ишетүгә, Нәҗип: «Хәзер мин дә үләм,— дип калтыранды,— әҗәлем җитте!»— дип даруга тотынды. Валидол, нитроглицерин кесәдән төшмәде, яктыдан караңгыга, караңгыдан яктыга керә алмады. Ул ялгыз калмаска тырышты, әллә нәчә шөгыльгә тотынып карады. Тимерхан карт белән ишек алларын себереште, балта-чүкеч тотып коймa такталарын рәтләштереп йөрде, шифа булмасмы дип, дәреслекләрен актарды. Искәндәр белән Рөстәмен ияртеп Черек күлгә, бала-чага кайнашкан урынга барды, юк, дөньяда әҗәл барлыгын һәм шул әҗәлнең аны кара гүргә өстерәвен бер чакта да онытa алмады. Булды төннәр, Наиләсе ачыргаланып, аннан-моннан гына киенеп телефонга чапты, «ашыгыч ярдәм» икешәр тапкыр килде. «Үләм»,— дип ыңгырашты Нәҗип, врачлар укол арты укол кададылар, анда да тынычландыра алмагач, Нәҗипләрнең кысан фатирында медсестра саклап калгалады. Киләләр, карыйлар, тыңлыйлар, «синус тахикардиясе» дип китеп тә баралар. Тикшерүләр, анализлар берне күрсәтә, ә Нәҗип бөтенләй икенчене, куркынычны сөйли...

Ихтыярын җуйган, кыска арада җиде-сигез килога ябыккан Нәҗип Йосыф улы Нургалиевне врачтан врачка, больницадан больницага, белгечтән белгечкә куып йөрттеләр. Наилә үз хисабына тагын ял ал-

ды, кулыннан эш төште. Иң авыры шул иде: кайткан шәпкә ире янына килгәләп, хәлен белеп йөргән хезмәттәшләре кинәт күренмәс булдылар. Ул аптекаларга чапкан арада заводка кагылып чыкты һәм хәле Нәҗипнекеннән дә авыраеп, бетәшеп кайтты. Директор Мәскәүдә чакта берәү белән килешенеп кайткан да, шул чакырылган кеше, техник фәннәр кандидаты, грузин хатыны Валентина Чхиквадзе ирен, өч яшьлек улын ияртеп, төянеп килеп тә җиткән. Аны лабораториягә мөдир итеп куйганнар, Нәҗипләргә багышланган квартираны да аңа биргәннәр. Өч бүлмәлене!

Наиләне аяз көнне яшен сукты. Теп-тигез җирдә тәгәрәп егылды. Тауга менәргә җыенган урыннан тирән, тар упкынга чәнчелеп барып төште. «Чукынсын бөтен дөньясы! Кырыкмаса кырык чөе кырылсын!»— дип поезд астына ташланырга уйлады. Сабыйларын, рухы имгәнгән көчсез ирен хәтерләп, чакырылмаган уеннан кире кайтты. Дилбегәсе чуалды хатынның, маякларын дулкын төпкә төшерде, кайда ал, кайда арт икәнен белмәс хәлдә калды.

Инде бу хәбәрне иренә алып кайтып тапшырса ни булачак? Йөрәге ярылып үләрме? Инфаркт чалып егып гомерлек имгәк булып калырмы? Әйтми торырга да ярамый, барыбер хәбәр килеп җитәчәк, чит авыздан ишеткәнче хатыннан ишетсен, чарасыз хакта хатыннан да кадерле зат юк, ул китергән хәбәр шунда ук урталай бүленә — кайгының яртысын хатын үзендә калдыра, икенче яртысын хәлең җитмәсә дә күтәрәсең...

Шулай уйлады Наиләнең боек күңеле, шулай уйлап, куркынычлы очрашуга әзерләнеп кайтты. Иплэп кенә, песи сыман шым гына кайтып керде. Көн язга тарткан — кояшлы, поездлар дөбердәүләрен киметкәннәр сыман, янбакчада, талгын җилдә тирбәлеп утырган чия ботакларында песнәкләр сикерешә. Язны ашыктыралармы? Шулайдыр. Юл читләренә кара челтәрләр төшкән. Яз килә! Сөенеп кенә яшисе дә бит, юк. Җае юк, мөмкинлеге җитми, кайгы-хәсрәт ишелеп килә тора...

Гаҗәп! Хәбәрне тыныч тыңлады Нәҗип, сабыр гына кабул итте. Наилә күзен алмады, иренең чырае үзгәрмәде, күзеннән аңа мәгълүм курку галәмәте йөгереп узмады. Үзен төртеп егуларына, юлдан алып ташлауларына Нәҗипнең һич исе китмәгәндәй булды. Даруга да барып ябышмады. Квартираның бик җайсыз чакта кулдан ычкынуын да аерып әйтмәде, ирен иң нык ярсытканы мөдир булып эшкә чит шәһәрдән, грузин хатынының килүе булды. Маңгаен җыерып торды да, җене котырып, хәбәрнең шул өлешен каһәрләргә кереште. «Читтән кеше җыймасалар, ярамаганмы? Мин чирләп егылганмын икән, лабораториядә бүтәннәр беткәнме? Безнең директорның гел шул булды инде, татарны яратмады. Татарны куярга теләмәсәң, менә дигән чуваш егете бар иде. Алемасов! Егетләрнең егете. Тырыш. Ахыр чиктә, татарлардан да мөдир табарга була иде. Әлегрәк тә мөдир грузин булган, аны Чихрадзе алыштырды. Хәзер тагын Чхиквадзе килгән. Бу ни хәл?»

Урыс, татар дип бер чакта да кешене аерып карамаган, бөтен милләт вәкилләре белән бик тиз уртак тел таба алган иренең авызыннан чыккан сүзләр бүген Наиләне гаҗәпләндерде. Әллә шул, килгән гөрҗи хатынын сүгеп, кирәкмәгән якка тәртә каерып, хәсрәтен җиңеләйтмәкчеме? Мөгаен, шулайдыр. Моңарчы милләт аерганы юк иде татар баласы Нургалиевнең.

Исең китәрлек, гаиләдәге һәр аңлаган кешене аяктан егарлык хәбәр, киресен эшләде. Нәҗипкә көч бирде, күңелендә туган каршылык хисе аны урыныннан торгызды. Һәм ул кайтканнан бирле беренче мәртәбә эшенә барырга җыенды. Бу кинәтлек Наиләне куркытты. Наилә читтән-чоттан сораулар биреп аның җебен тартып карады. Ник бара, кемне күрергә тели, кирәкмәскә утын ваклап кайтмасмы тагын? Кызып китеп җүләрлек кылмасмы? Мөдир түгел икән, әйдә, чәнчелеп китсен! Лабораториясендә генә калсын! Яшәделәр, тагын яшәрләр. Наилә тын-

мас, подъезд юар, инде соң чиккә җитсәләр, шәл бәйләп сатар. Казан арты кызы ич, болгар токымыннан, әнкәсе бәйләгән шәлләр һәрвакыт югары бәядә йөрде. Арада Наилә бәйләгәннәре дә бар иде ләбаса!

Ул, шушы дәлилләре белән ирен өйдә калдырмакчы иде, ләкин Нәҗип күзгә күренеп үзгәрде, кайта-кайта чит җирдән кеше чакырган директорның тетмәсен тетте.

«Барам. Керәм. Күрәм. Сөйләшәм! Бала-чагамы мин аларга? Чакырып сөйләшсәләр, укалары коелыр идеме?!»

Наилә, ирен заводка озатып, капка баганасына ябышып, телен тешләп калды. «Яхшыга булсын, ходаем!»

Кызып-янып барган шәпкә Нәҗипнең күңеленә икеле-микеле уйлар да килеп киткәләде. «Мөдирнең бүтән халык вәкиле булуына ник бәйләнәм соң мин!»— дип тә уйлады. Җавап табып тормады, күңеле кырылган, кимсенгән иде. Завод ишеге төбендә аны шактый озак үткәрмәделәр, таныш каравыл начальнигы килеп чыккач кына керергә рөхсәт бирделәр.

Бәхете — директор каядыр киткән булып чыкты. Әгәр Нәҗип хәзерге мәлдәге уйларын ачып салса, аны йә больницага, йә милициягә алып китәрләр иде. Явыз сүгенү сүзләрен секретарь кыз ишетмәслек итеп кабатлап, ул Храмовны эзләп китте. Ходай саклады — Храмов та Мәскәүдә, командировкада икән. Нәҗип чак кына аптырап калды, кая барып керергә белмичә коридорда әйкәлгәндә теге баштан кәс-кәс атлап килүче Изил Латыйповны күреп алды. Латыйповның кулы буш түгел, гадәттәгечә, кәгазьләр тоткан, чырае ачык, йөзе балкыган. Нәҗип исә, сөрем болыты, килеп җиткәч кул бирәсе урынга, йодырыкларын йомарлады, Изилгә үтереп карады. «Тукта, Изил»,— диде Нәҗип нык итеп. «Юк,— диде Изил, гауга чыгасын сизенеп,— вакытым юк. Халык көтә. Профком утырышы. Мәскәүдән вәкилләр бар».

Нәҗипнең маңгаена бер сыр йөгерде: тукта, нигә уен утырышта уртага салмаска?! «Мин дә синең утырышыңа керәм!»— диде ул кинәт. «Мин сине чакырмадым»,— диде Изил, көлемсерәп артка чигенеп. «Чакырган җиргә генә йөрергә син мине кем дип белдең?» «Нәҗип, гафу ит, ашыгам». «Мин ашыкмыйммы?» Юк-бар бәрелешләрдән сагаерга өйрәнгән, бусагаларны җиңел үтеп гадәтләнгән Изилнең Нәҗип белән тарткалашасы бер дә килми иде. «Иртәгә тугызга үземә кил, бөтенесен хәл итәрбез!»— диде ул Нәҗипнең иңенә дымлы кулын салып. Нәҗип кулны иңе белән кагып җибәрде: «Шомартырга маташма!»— диде һәм ишеккә аркылы баскан Изилне бер якка этеп утырышлар залына барып керде. Анда утызлап кеше түземсезләнеп Латыйповны көтәләр иде, алар Нәҗипкә бөтенләй игътибар да итмәделәр. Изил кереп җитте, ым белән Нәҗипкә шым утырырга боерды, утырышны ачып җибәрде. Көн тәртибен расладылар, утырышларга яратып йөри торган кешеләрнең кулы югары күтәрелде, алмаш-тилмәш чыбек чәйнәргә тотындылар... Титан ватылган — эчәргә су юк, тулай торакның бәдрәфенә җил өрә — тәрәзә пыяласы юк, пенсионер Гавриловның карчыгы үлгән, акча илтә барырга кеше юк... Тыңлап-тыңлап утырды Нәҗип, чыдамады, кул күтәреп тормады, сүз биргәнне көтмәде, Изил янына алга чыгып басты.

«Сез монда бәдрәфләр, титаннар хакында гәп куертып эшем иләре булып утырасыз. Ә монда, берләшмәдә, шундый, шундый хәлләр. Ярый, сугыш азагында рейхстагка байрак кадаучылар итеп урыстан һәм грузиннан сайласыннар да ди... Ә хәзер? Ни өчен берләшмәгә аяк баскан урыслар, украиннар һәм башка милләт вәкилләре ел-ел ярым эчендә кинәт кенә үсеп китәләр дә, дәрәҗәле урыннарга менеп утыралар. Ә татар белгечләре, татар галимнәре һаман бер урында таптана?! Әнә, грузин хатыны килеп тә җитмәгән, аның эш сыйфатларын әле беркем белми, аңа һәммәсе әзер: мөдирлек тә, өч бүлмәле квартира да, баласына бакча, бүтән льготалар... Гаделлекме бу? Мин монда директор

тарафыннан милли тарлык күрәм. Кайчанга кадәр монда хокуксызлык дәвам итәр? Берләшмә Татарстан җиренә. Казанга урнашкан лабаса! Директор татарларны яратмый, диләр. Имеш, алар фән белән тирәнтен шөгыльләнә алмыйлар, тел өйрәнеп ярты гомерләре үтә. Грузинканың килүе — шуның шаукымы. Милли тарлык кайчанга кадәр бездә яшәр икән?»

Латыйпов, Нәҗипкә тукталырга боерып, ике кулы, иңбашлары, теле, каш-керфекләре белән меңнәрчә ым биреп караса да, Нургалиевне тыяр, туктатыр көч юк иде. Ул милли чикләүләргә багышлап тагын берничә мисал китерде, директорны «шовинист», партоешманы «ваемсыз», профсоюзны «чүпрәк» дип атады. Латыйпов ул сөйләп бетергәч, бер мизгел уйланып торды һәм: «Без, Нургалиевнең кызулыктан әйткән ялгыш фикерләрен беркетмәгә кертмибез, аны игътибарга алмыйбыз»,— дип йомгак ясады. «Ах, кертмисезме? Ах, игътибарга алмыйсызмы?!»— дип ярсып кычкырды Нәҗип һәм йодрыгын йомарлап бүлмәдән чыгып китте. Утырыштагылар аңга килгәнче ул ишекне тагын ачты һәм: «Сез таш курчаклар булсагыз, мин фикерләремне язып парткомга илтәчәкмен!»— дип кычкырды.

Наилә белән ике көн сөйләшмәделәр. Нәҗипнең йөрәк өянәге кузгалды, ул иртәдән кичкә кадәр дарулар эчеп, уфылдап караватта ятты, тормады диярлек. Кемнәрне очратып, нинди давыл куптарганын ул хатынына сөйләмәде, ни майтарганын үзе дә аңлап бетерә алмый иде шикелле.

Ике көннән аны завод профкомына чакырып курьер килде.

«Бармыйм!»— диде кистереп Нәҗип.

Иренең, бәйдән ычкынып китеп, теге көнне нидер ярамаган эшкә таруын Наилә төшенгән иде, бүген ул да аяусыз булды. «Мөдирлек кулыңнан ычкынгач, синең нәрсәдер җимерәсеңне, тар-мар итәсеңне көтә идем. Чирле башың белән ярамаган эшкә тарыгансың, хәзер күләгәдә посып калыргамы исәп? Хәзер сиңа сугыш түгел, солых кирәк. Бар, тишкәнсең икән —яма, ерткансың икән — ялга».

Хатынының кискен хөкемен ишеткәч, ул чакырган җиргә барып кайтырга булды.

Профкомда аны ике кеше көтә иде. Изил янында утырган тәбәнәк, юантык гәүдәле ирне күргәне дә бар кебек иде Нәҗипнең, кул бирешеп күрештеләр. Изил Нәҗипкә күтәрелеп карамады, чакыртучының ул түгел, ят кеше икәнен Нәҗип шунда ук аңлады, көрсенеп тәрәзәгә, тәрәзәгә орынырдай булып аккан кара-кучкыл болытларга карады. «Сез профком утырышында, кызып китеп хилаф сүзләр ычкындыргансыз. Партоешманы, профсоюз комитетын гаепләгәнсез. Язма рәвештә сүзләрегездән баш тартырга, «ялгышканмын!» дип хатагызны танырга туры килер»,— диде ят кеше. «Танымасам? Киресенчә, фикеремне куәтләп партоешмага язып кертсәм? Мин хаклы идем, фикеремне мең мисал белән раслый алам». Ят кеше белән Латыйпов бер-берсенә карашып алдылар. «Менә... мин сезгә әйттем ич!»— дигән кебегрәк, Латыйпов кулларын ике якка җәеп җибәрде. Үгетләмәделәр Нәҗипне, тәртипкә чакырмадылар. «Уйлагыз алайса, төптәнрәк уйлап карагыз!»— дип озаттылар.

Нәҗип рәнҗеде, ачуы тагын да кабарды, ул өенә кайткач, ике бит кәгазьне тутырып гариза язды һәм Наилә кайткалаганчы дип гаризасын партоешма секретаре Иващенконың өстәленә илтеп салды. Ике көннән машина белән килеп Нәҗип Нургалиевне партоешмага алып киттеләр. Бу юлы бүлмәдә дүртәү утыралар иде. Теге көнне Изил янәшәсендә очраган ир дә монда. Алар басынкы гына нидер сөйләшәләр иде. Нәҗип бүлмәгә керүгә — тындылар. Сүз анда да бик кыска булды. «Гаризаң белән таныштык,— диде Иващенко,— фикерләрең мәгълүм булды. Бәйләнүләрең нигезсез, фикерләрең хата дип саныйбыз. Гаризаңны кире аласыңмы, юкмы?» «Кире алыр өчен язмадым, мин партоешманың бер-бер чара күрүен көтәм!» Бүлмәдәгеләр кузгалмадылар.

алар авыр күз карашларын бер-берсенә йөртеп. Иващенкога нидер ымладылар. «Яхшы,— диде Иващенко.— җавапны тиздән алырсың!»

Көн үтте, төн, тагын бер көн, ике төн узды, хәрби комиссариаттан Нәҗип Йосыф улы Нургалиевне чакырып повестка килеп төште. Бусы һич көтелмәгән яңалык иде. «Әллә халыкара хәлләр начарланганмы?» — дип сорады Наилә. «Аның яхшырганы да, яхшырасы да юк»,— диде Нәҗип пошынып. Наилә ирен юатырга тырышты: «Мөгаен сине белгеч буларак берәр консультациягә чакыралардыр әле!»

Военкоматның кайда икәнен дә оныткан иде инде Нәҗип, көчкә эзләп тапты. «Син комиссия торырга тиеш, без сине армиягә алабыз»,— диде көяз өлкән лейтенант Шумилов. «Армиягә?» — Нәҗип эчтән генә көлемсерәде: бүгенге хәлендәме? Инфарктган чак-чак үрмәләп качкан кешене, утыз өч яшьтә армиягә алсыннармы?

Хәрбиләрнең сүзе кыска, армиягә тек армиягә. Нәҗип Йосыф улы Нургалиев озын исемлек тотып үз больницасына кайтты һәм врачтан врачка йөри башлады. Күзен каратты — «яхшы», диделәр. Колак та сак икән, почмактан пышылдаганны ишетте. Хирург та әллә ни тапмады, невропотолог әштер-өштер әйләндергәләде, каккалап-суккалап маташмады, «годен!» дип егетне чыгарып җибәрде. Наилә белән Нәҗип тагын бер хафалы төн үткәрделәр. Иртәгәсен ул беренче булып терапевт карамагына керергә тиеш. Мәскәүдән кайткач, алар Иван Илларионович белән берничә тапкыр очрашканнар иде инде. «Йөрәгеңнең рәвеше бер дә мактарлык түгел, түгел!» — дип, Иван Илларионович аңа берничә төр даруны эченә тутырган капсулалар йотарга тәкъдим иткән иде. Шәт, Иван Илларионович ике сөйләшеп тормас. «Негоден, чирле, йөрәге тырпылдап кына тора»,— дип язып бирер...

Иван Илларионович та аңа бүтән врачлар кебек үк күтәрелеп карамады, җилкәсенә авыр йөк салган йөкче кебек иелеп нидер мыгырдады, берсен берсенә чәнчегән тезләрен атындырып куйды. Мондый салкынлыкны көтмәгән Нәҗип, учына йөткереп: «Менә бит, Иван Илларионович, военкоматтан комиссия торырга җибәрделәр... Ни кыланалардыр»,— диде. «Күрәм, күрәм,— диде врач, Нәҗип кулыннан кәгазьне алып,— беләм дә!» Ни белгәнен Иван Илларионович аңлатып тормады, врачларча кыеш-мыеш хәрефләр белән «годен» дип сырлап, кәгазьне Нәҗипкә таба этәрде. «Ничек,— диде дәрте сүнеп Нәҗип,— чиремне беләсез, Мәскәүдән кайткан кәгазьләр кулыгызда иде. Дарулар яздыгыз. Бу йөрәк белән мин армиядә нишләрмен? Мин берни дә аңламыйм». «Анда аңлатырлар! — диде врач, кулы белән тәрәзә белән ишек арасын төртеп күрсәтеп,— анда карарлар!»

Чирек сәгать коридорда һушы таралып торганнан соң гына Нәҗип иң ахыргы кабинетка — психиатрга барып керде. Көл сыман чәчләре учма-учма ак калфагы астыннан чыгып, җилкәсенә тәртипсез таралган юан, озын кеше иде психиатр. Чал, тузгыган бакенбардлары, дәү барабан корсагы, нәзек ботын кысып торган тар чалбары, кеп-кечкенә аякларына элгән чүпрәк чүвәкләре аңа ышанычны киметәләр иде. Ак керфекле, ак күзле, сипкелле куллы бу врач Наум Исаакович Фогельсон булып чыкты. Нәҗип килеп керәсен алдан белгән кебек, ул аксыл, эре бөртекле кашларын яман җыерып, ишеккә төбәлеп, бармаклары белән как өстәлгә барабан кагып аягүрә басып тора иде. «Ә-ә, Нургалиев? Килеп җиттеңме?— диде ул мыскыллы аһәң белән,— вакыт, вакыт. Кötәбез!» Нәҗипнең Иван Илларионович янында туа башлаган шиге Фогельсонның кыланышын күреп тагын да көчәйде. «Бала-чага әз туа, армиягә ирләр җитешми, кайбер очракларда өлкәннәрне дә чакыртып алалар, мөгаен, военкомат «Нургалиевне алырга!» дип күрсәтмә җибәргәндер»,— дип уйлады ул.

Фогельсон егеткә чүгәләргә кушты, Нәҗипнең әкрен, сак кына кылануының серен сорады. «Мәскәүдә чирләп егылдым, инфаркт алды дип больницадан чыгардылар»,— дип аңлатты Нәҗип һәм ымсынып

врачның чыраена карады. Психиатр Фогельсонның бакенбардлары кыймылдаудан аның яңак сөякләре уйнаганын белеп була иде. Нигә шулкадәр гасабилана ул?

Врач марш атлатты, Нәҗипнең күз алмаларын уңга-сулга йөрттерде, аска-өскә каратты, борынын чеметеп торды һәм тонык, җансыз тавыш белән: «Сезне бу хәлдә армиягә җибәреп булмый, сездә психик тайпылышлар бар»,— диде. Нәҗипнең эче җылынып китте, армиягә алмасыннар гына, тайпылыш түгел, чурт булсын аңа! «Мин сезне психоневрологический диспансерга җибәрергә мәҗбүрмен, сезгә дәва кирәк!»— диде Фогельсон һәм Нәҗипнең кәгазенә үрелде. Нәҗип өнсез калды. «Ничек?»— диде ул тотлыгып. «Шулай, саулыгыгыз шуны раслый»,— диде Фогельсон. Нәҗип ялт итеп кәгазьне врач кулыннан тартып алды. «Мин сәламәт!»— диде ул, кызмаска тырышып. («Ходаем, монда кайнарлана башласаң «җүләр!» дип әллә кая тыгып куярлар!»)

Исенә кылт итеп моннан бер ел элек ишеткән вакыйга төште. Яңа бистәдә, алар урамында, ике йорт аша гына Сәгыйдулла исемле кеше яши иде. Шофер иде бичара, урамда кеше таптатып, ике елга төрмәгә яптылар. Ике елын шунда, Казанда гына үткәрде бу. Котылып чыккач, урам эскәмиясендә әңгәмә куертканда, Нәҗипне бик яхшы белмәсә дә, башыннан үткәннәрне сөйләде: «Һай, дөньяда әллә ниләр бар икән, күрергә язмасын! Җүләрләр зонасында эшләдем мин, машина йөрттем. Хәйран эшләр вәйран икән анда! Илгә, хөкүмәткә каршы сүз әйткәннәрне җүләрләр арасына илтеп тыгалар да югалталар икән. Сау-сәламәт адәм дә тиле санала. Әгәр берәвесе каршы килеп авызын ачса, тавыш күтәрелсә, уколны тыгып кына куялар, ике ай телсез бүрәнә булып ята теге... Бер мулланы очраттым, егерме ел шунда интегә икән! Арада поплар, студентлар бар, дип сөйләделәр. Галәмәт анда хәлләр!»

Димәк... хәзер Фогельсон язып бирсә... Аны да шунда илтеп тыгачаклар? Ни өчен?

Нәҗип каушап ялына башлады. «Зинһар дим, алай эшләмәгез инде. Зәгыйфь йөрәк белән...» Хатынын, квартирсызлыгын, балаларын телгә алды. Фогельсон кырыс кына тыңлап торды да коридорга ишетелерлек итеп: «Юк, юк! Сорамагыз да, үтенмәгез дә! Сезгә дәваланырга кирәк!»— дип бакырды. Аннан егетне ике кулы белән почмакка этеп кертте, явыз, усал тавыш белән: «Син, атаң башы, партоешмага биргән гаризаңны кире аласыңмы, юкмы? Җыелышта әйткән сүзләреңнән кире кайтасыңмы?!»— дип пышылдады.

Фогельсон бүтән сүз әйтеп тормады, көчле куллары белән почмактан Нәҗипне этеп чыгарды да башы белән ишеккә күрсәтте.

Заводка йон урынына очты Нәҗип, трамвайдан сикереп төште, троллейбуска атылып менде, тыны-өне бетеп Изил Латыйпов янына чабып керде һәм «Сүземне кире алам, алам!»— дип кабатлады. Иващенко янына алар бергә керделәр, партоешма секретаре алар күз алдында Нәҗипнең гаризасын аркылы-торкылы ертып ташлады. «Күптән шулай кирәк иде!»— диде.

Коридорга Изил белән алар бергә чыктылар. Латыйпов нидер әйтмәк булып бераз кысталып торды да: «Башың болай да бетте синең... Психушкада учетка алдылар сине... Әгәр андый-мондый эшең беленсә, исе чыкса, шундук юк итәләр, белеп тор. Минем киңәшне ычкындырма, аң бул! Хатының, балаларыңны җәлләп кенә әйтүем»,— диде.

Изилнең соңгы сүзләрен аңлап бетермәде Нәҗип, аны-моны сорашырга дип, икенче көнне заводка барса, аны эчкә кертмәделәр. Атна азагында аның адресына юка гына пакет килде. Анда: «Нәҗип Йосыф улы Нургалиев завод лабораториясеннән үз теләге белән эштән китте»,— дип язылган иде. Нәҗип кубарылып, әллә кайларга барып җитмәк булып калкынса да, бу юлы Наиләсе чакматаш булды — җибәрмәде. «Беркая бармыйсың! — диде ул, кистереп.— Син үзең хакында гына уйлама! Онытма, синең хатының, ике балаң бар!»

Алар капка төбендә очраштылар. Нәҗип өйдән югалып тору нияте белән урамга чыгып бара иде, Тимерхан карт кайтып килә икән. Нәҗип, йорт хуҗасына юл сабып, түбәнчелек белән башын иде.

Күпме вакыт бер ихатада яшәп, бер капкадан кереп-чыгып йөрсәләр дә, Нәҗипнең Тимерханга туры караганы юк иде. Шадра икән Тимерхан, тешсез икән. Кием-салым да таланган икән. Тимерханның байтак еллар элек кайсыдыр бер оешмада экспедитор булып йөргәнен, шактый нык хуҗалык корганын, соңыннан кыек эшләре фаш булгач, бәладан баш-аяк дип, шома гына чыгып ычкынганын буш вакытларының берсендә Наилә сөйләгән дә иде бугай. Ул чакта хуҗа турындагы мәгълүматлар бер колактан керде, икенчесеннән җиңел генә чыгып китте. Нәҗип «мөдирлек белән» яши башлагач, Тимерхан-шадра, Тимерхан-тешсез бик түбәндә, күз күреме җитмәс аста калган иде. Эшеннән куылгач, ул байтак еллар зират тирәсендә ышкынган, кабер казыган, маклерлык иткән, «уңайлы, коры сукмаклы якта» урын вәгъдә итеп, мәет иясеннән сәмән каерган, марҗалар белән себерелгән, акча туздырган. Тора-бара кулдан мал, беләктән көч, күздән нур качкан, ары-бире кунып йөргән Тимерхан бер таңда өтәләнеп, таланып, шыр сөяген селкетеп карчыгы бусагасына кайтып егылган, тәүбәгә килеп гафу сораган. Кызы Таңсылуның үскән саен кулдан китә башлавын чамалаган карчык: «Әйдә, эт булып өрергә булса да ярар!» — дип, аны кабул иткән. Уклау белән аркылысын-буен үлчәп тәүбәгә китергән.

Акча өчен түгел, утын хакына алар Нәҗипләрне фатирга керттеләр, соңгы сүзне Таңсылу әйтте. Нәҗипнең озын буен, йомры беләкләрен, юантык ботларын комсыз күзләре белән ашый-ашый: «Керсеннәр, ичмасам утын артыннан йөрисе булмас!» — дигән иде кыз...

Дөньяның шушы сөремле, төтенле, шау-шулы почмагын вакытлы гына дип исәпләгән Нәҗип хуҗаларны бер чакта да санга сукмады, прпискага кереп, төпләнеп яши башлагач, ул аларны күрмәскә, очрашканда күрми үтеп китәргә өйрәнде. Сөйләшергә туры килгәндә сүзләрен колакка элмәде, аларны кешегә санамады, санламады...

Бүген бил үзеннән үзе бөгелде, ирен читләренә, күз төбенә төче елмаю җәелде, ул олылап ике кулын Тимерхан картка сузды. Ул бүген картның аны күрүен, бер булса да җылы сүз әйтүен, елмаюын, гомумән, кеше итеп санавын тели иде. Ичмасам, үтеп кенә китмәсен! Туктасын, әпә-чәпә сөйләшеп торсын.

Яңа бистәнең иң иске, келәсе кылтырап, күгәннәре менә ычкынам, менә каерылып төшәм дип торган иң бәхетсез капкасыннан Нәҗип яңа дөньяга чыгып бара иде. Артта калган юллары юк, алар язмыш дәфтәренә сызылып килеп, бүгенгесе көнне резин бозгыч белән сөртеп ташланган кебек, юкка чыкканнар. Яңа дөнья капкасын ачам дигәндә теге яктан Тимерхан шадра, Тимерхан тешсез килеп керде. Ул аптырап, үзенә җылы сузылган ике кулны тотып алды, тырнаклары сынып, сыдырылып беткән икән картның, сул кулының ике бармагын түгәрәк пычкы кыеп төшергән икән. Мыеклары сирәк икән аның, төссез, ямьсез тырпайган мыеклар.

Тимерхан Бишбалтадан, карчыгы Җәмиләнең туган тиешле кешеләреннән кайтып килә, имеш. Агай-эне чәк кенә кәккәннәр, чәркә аракыдан соң бер-ике шешә сыра капканнар, туганнарның йомышы бар, төпчек кызларын кияүгә бирәләр икән, бирнәгә пианино алганнар, төпчек кыз музыка мәктәбе бетереп, балалар бакчасына эшкә дә килешенгән икән... Акчаны бик җиңел вәгъдә итте Тимерхан, фатирчыларның өч айга түләгәннәре юк. «Шушы арада була!» — дигән иде Наилә, Тимерхан, өенә кереп тормыйча, туп-туры фатирчылар ягына үтәргә, аяк терәп акчаны алып чыгарга ниятләп, дәртсенеп кайтып килә иде. Фатирчының капка төбендә үк очравы аны әз-мәз каушатып куйды, шу-

ның өстенә акча җәһәтеннән аның ир белән сөйләшкәне юк иде шикелле, хатын-кыз белән сөйләшү аңа җиңелрәк булса да, чыгып бетмәгән шайтан суы коткысының тәэсире булдымы, ул кыеп Нәҗипкә сүз катты, өч айга акча түләргә кирәклеген искә төшереп: «Хатының белән килешенгән идек, бүген — түләү көне. Акчаның бик тә хаҗәт чагы!» диде.

«Акча» сүзен ишеткән Нәҗипнең башы әйләнеп китте, ул, чыгып китәргә җыенуын онытып, кире борылды һәм мәэюс күзләре белән йорт хуҗасына карап: «Әллә әзрәк көтәсезме, Тимерхан абзый?»— диде. Тавышы җеп шикелле нәзек, ефәктәй йомшак, куян койрыгыдай калтырап тора иде егетнең. Тимерхан исә өстенлекне шунда ук сизеп алды, элгәре Нәҗип кулагасендә кечерәеп калган камыт аяклы, черек теш төпләреннән ис аңкыган шалама карт, җәнлек эзенә төшкән сунарчы эт сыман сагаеп, тәнен дугадай киерде. «Юк, юк! — диде миендә котырган сыра сөреме.— Күп көттек! Һәр нәрсәнең чамасы була! Сез бигрәк!»

Алар башта иплəп кенә, аннан кызып ук талашырга керештеләр. Бирге баштан җилтерәп Җәмилә, аргы баштан курка-курка гына Наилә килеп чыктылар. Карчыгы алдында гайрәт күрсәтергә форсат тапкан Тимерхан карт, Испания корридасында яраланган Севилья үгезе кебек, үкереп җибәрде. «Как так?!. Не сметь! Бүген түлисе и вче. Юкса, белеш милицияләр мыж! Суд аша каерып алырбыз!» Җәмилә карчыкның колагы бу якта ни барын инәсенә хәтле белеп тора, ул да картын котыртып сүз учагына коры ботаклар өстәде: «Түләмисез икән, чыгып китегез!»

Бәхетсезгә-вакытсыз дигәндәй, Таңсылу да өйдә икән, ул да, кулларын имиләре өстенә кушырып, чыгып баскан. Чәче дулкын, муенда камыт бөяте диярлек муенса, түштә нәни ташбака дәүмәләге брошки, беләзекләре елтыр-ялтыр килә. «Түләп чыксыннар, түләп бетерсеннәр! Бер көн тормасыннар!»

Наилә елый башлауга, көчсезлектән Нәҗипнең күкрәген тимер кыршау кысып алды, тын алырга ирек бирми, тәкате бетеп, тегеләрне эт итеп сүгәргә уйлый, тавышы чыкмый, бугазында коры төер утыра.

Сынык тырнаклы кулын бутый-бутый Тимерхан кычкыра, Җәмиләнең төсе уңган күзләреннән зәһәр коела. Таңсылуның түше бер менә, бер төшә, ә Наилә, хәсрәтенә буылып, елапмы-елый. Һәм шушы төркем уртасында басып торган ир кеше көчсез, дәртсез, ни диярга белмичә, адаштырган көчек сыман, ялварулы күзләрен текәп, әле Тимерханга, әле Җәмилә карчыкка карап ала. Иренең нинди хәлгә төшкәнен күреп аңына кайткан Наилә кинәт, ике йодрыгын да йомарлап, ике йодрыгы белән Яңа бистә ишегалдында яшен уйнатып, хуҗаларга тамак ертып кычкыра башлады. «Түләмибез диган кеше бармы әллә, ай алла! Берике көн көтегез, үлмәссез әле! Түләрбез дә ташлап чыгып та китәрбез!»

Авыздан чыккан сүз — очкан кош, аны тотармын димә. Наиләнең сүзе ярсыган хуҗаларны тәмам котыртты, алар өчесе өч ноктадан, өч тавышка бәхетсез ир белән хатын өстенә зәһәр чәчәргә тотындылар.

Кинәт тавышлар тынды. Нәҗип белән Наиләне каяндыр пәйда булган бер кеше култыклап алды һәм: «Әйдәгез әле, әйдәгез! Өегезгә керегез! — диде.— Кая керергә соң!»— дип күзләренә карады. Ят кешене хуҗалар да абайлады, тавышлар тынды, дөбердәп үткән поезд тавышлары, вагоннар котырынып бәрелешкән авазлар колакка ишетелә башлады, хуҗалар һәм фатирчылар дөньядагы бөтен тавышларны күмеп кычкырышканнар икән!..

Өчәүләшеп кыеш идәнле, элеккедән дә шыксызрак күренгән бүлмәгә барып керделәр. Әле баярак күренгәләп торган яз кояшы яшькелт пыялалы тәрәзә турын үткән, өч аяклы аксак өстәлгә, бала караватына, тәгәрмәче өчәү генә калган уенчык арбага әңгер-меңгер кунып маташа иде...

Керүченең исеме Мәхмүт булса да, Нәҗип, Наилә белгәннән бирле,

аны Мудрый дип атап йөртәләр иде. Ни өчен, кем таккан, анысын, мөгаен, Мудрый үзе дә оныткандыр, мәгәр ата кушканга караганда, соңгысы, тагылганы — Мудрый дигәне аңа охшыйрак төшә иде. Урыс-улак арасында да җиңел — Мудрый и бетте-китте! Кемнең соң уйнап кына булса да, Мудрый дип аталасы килмәс?

Чәлди гәүдә булса да, бас тавыш, татарда сирәк очрый андый тавышлар. Явыз Иван, татар җирен басып алганнан соң, калын тавышлы, таза күкрәкле ир-атларны яшәтмәгән, дөньяга килгәннең берен кырып барган. Татар мич арасында, чоланда, мунчада, аулакта гына, анда да пышылдап сөйләшергә тиеш булган, кыскасы, Мудрый — татарлардан могҗиза тавышка ия зат иде.

Керде Мудрый. Нәҗип-Наиләне беләгеннән ычкындырды, вак бәлеш хәтле авызын ерып аларга карады. Хуҗалар ишегалды бәрелешеннән аңгыраеп калган иделәр, нишләргә белмичә шактый ара телсез басып тордылар. Беренче булып Наилә исенә килде, артсыз урындыкны идән тырнатып эшереп: «Утыр, Мудрый»,— диде. «Утырам, утырам, кергәч утырмыйлармы соң? Сез һаман шушында торып ятасыз икән, мин сезне әллә кайчан шәп фатирга күчкән дип йөрим!»

Алдый Мудрый, ул Нәҗипнең күченмәгәнен дә, Мәскәүдә чирләп егылуын да, эшеннән куып җибәрүләрен дә ап-ачык белә. Нәҗипләргә төрле яктан бәла-каза ябырылмаса, ул бүген кереп тә тормый иде. Аңа кешеләрнең түбәндә, пычракта җәфаланган мизгелләре кирәк! Шөкер, юлы уңды: Нәҗип-Наиләне кая барырга белмичә бәргәләнгәндә тотты...

Кайчандыр Нәҗип белән Мудрый якын гына иптәшләр иде, бер торакта, янәшә бүлмәләрдә яшәделәр. Наилә белән Нәҗипне дә ул таныштырды. Икәүләшеп кызлар бүлмәсенә, Наилә янына кереп йөрделәр. Берсендә, Мудрый каядыр киткән иде, Нәҗип кыз янына бер башы барып керде. Наилә нигәдер күңелсез, карасына батып, терсәгенә таянып тәрәзәгә карап утырган иде. «Мудрый бүген килә алмады... Иртәгә килер!» — диде Нәҗип кызны тынычландырырга теләп. Беравык авызына су кабып утырган кыз җәһәт кенә сикереп торды да аның муенына сарылды: «Миңа ул түгел... Миңа үзең кирәк!»

Үпкәләдеме Мудрый, көнләштеме,— моны беркем дә белмәде. Егет киң күңелле, юмарт, зирәк акыллы булып күренергә ярата иде. Сирәк күрешсәләр дә, алар тыштан җылы мөнәсәбәтләрен сакладылар, йомыш-кара төшкәндә, үтечкә акча кирәк чагында еш кына Мудрый катына бардылар. Әҗәткә акча биреп торырга ярата иде Мудрый, сорамаган чакларда да килеп кереп: «Сезнең акча ягы койтымы, мәгез, миннән булсын яхшылык!»— дип әйткән чаклары да булды. Акчаны бирә, кире сорап йөдәтми, түзә: «Бер җаегыз чыкканда түләрсез әле!»— дип тынычландыра да белә.

Кеше бурычка кердеме, ул ихтыярсыздан синең колыңа әверелә. Нәкъ әнә шунысы кирәк тә Мудрыйга! Укып алдыра алмады үзе, ике ел рәттән техникумга керде, кудылар. Өч мәртәбә өйләнде, беренче хатыны ярты ел, икенчесе ике ай ярым гына түзде. Өченчесе, бер кич кунгач та, ире кибеткә сигаретка чыккан арада, күлмәк-күнчеген җыештырып чыгып качты. Сөйләделәр, Мудрый кәләшенең кайнар кочагында ятасы урынга, зөфаф кичендә, керем-чыгым кенәгәсен күрсәтеп, күпме акча төшерүе, тапканын ничегрәк тотуы, кемнәрнең күпме әҗәте барлыгын ялыктыргыч озын итеп сөйләп үткәргән икән. Таңда кәләшне кочмакчы була, кәләш суынган...

Хәзер ул әнисе белән бер бүлмәле квартирада яши, әнкәсенең пенсиясен тиенена кадәр каерып ала, эчми-тартмый (тәмәкесен акча җәлләп ташлады!), таныш-белешләре акчага карта, биллиард уйнаганда алардан көлеп, мыскыллап читтән карап тора, бер тиенен исраф итми. Йоклый торган караваты терәлгән диварда шәмәхә фломастер белән байтак исем-фамилияләр язылган, анда кемгә, кайчан, нинди шарт-

ларда әҗәткә акча биреп торуы теркәлгән. Яткач ул, озак-озак йокыга китә алмый, дивардагы исемнәрне күзәтеп, явыз тантана белән: «Менә сез кайда утырасыз, менә!»— дип йодрыгын йомарлый. Нәҗип белән Наиләнең исемнәре диварга бернична кат теркәлгән, аны күргән саен Мудрыйның куанычы арта. Әҗәткә кергәннәр арасында шактый күренекле кешеләр бар, бер шагыйрь, ике артист күптәннән бу кара исемлектә. Шагыйрь йолкыш кына бәндә иде, хәзер тәлинкә ялап лауреат булды. Мудрыйга биш йөз бирәчәге бар! Шәп! Акчага тыгыз килгән чакларда да Мудрый дәгъваламый, процент-мазар сорамый, з а т л ы к е ш е л ә р а ң а б у р ы ч л ы булып яшәсеннәр! Бүген килеп керүенең сәбәбе дә шул: Нәҗипләрнең хәле соңгы чиккә җиткән икән, дип ишетте. А-а, бу инде аңа иң шифалы сүз, җан дәвасы, тереклегенең терткасы! Бөтен дөнья кораблары ярга килеп терәлсә дә, аңа сөенечтән гайре берни юк! Мудрый яши икән, процентларны ул үзенчә, үзенә кирәгенчә ала: аңа да кемнәрдәндер өстен булырга кирәк! Лауреатлар, артистлар аңа тез чүгеп килә! Әлегә алар, укыганнар аннан җылы сүз көтә! Ул аларга тәүлекнең теләсә кайсы вакытында бәреп керә ала, аңа сүз әйтүче юк! Чөнки аның бу йортта, бу хуҗада алачагы бар! Үз өлеше! Җан биреп ятканда ул аларга шәфкать кулы сузды! Ул! Булгалады, Мудрыйның бер тиенсез калып, тозга ипи кыерчыгы манып ашаган чаклары булды, ә шулай да Нәҗип Нургалиев катына соранып килмәде, үтенечен таптырмады. Чөнки Нургалиев өметле, үсеп бара торган кеше иде. Боерган булса, з у р кеше булачак Нәҗип Нургалиев! Алла кодрәте белән цех начальнигы, баш инженер, директор булып китәр... Лауреат, депутат, бюро әгъзасы булыр... Анда да йолкыш Мудрыйдан йөз чөерә алмас, чөнки аның ничә еллардан бирле әҗәте, бурычы бар! Тора-бара кеше әҗәтенә күнегә, биреп торучы кайтарып сорамагач, түләргә ашыкмый, кешенең шул йомшаклыгыннан оста файдалана Мудрый. Бәлки, шуның өчен аңа Мудрый кушаматы такканнардыр да?!

Бүген ул белешергә кергән иде: сөйләгәннәренчә бик нык чирләгәнме Нургалиев? Үләрлекме аның хәле? Үләрлек икән, бу инде башка мәсьәлә: акчаны аяк терәп сорарга, кире кайтарып калырга кирәк!.. Үлә икән, Наиләсе кемгә булачак?.. Мудрый күңеленең иң ерак упкынында Наилә исеме һаман янып, балкып йөри иде. Бәлки, шул хис тартып китергәндер аны бүген? Кеше күңеленең чиге бармыни? Ә чиксезлекне кем аңлатып бирә ала? Аны бер Эйнштейн аңлаган, ләкин дөнья халкына аңлатып бирерлек дәрәҗәгә ул да өлгереп җитмәгән. Капка какканда шулай уйлаган иде Мудрый, танышларының чиктән тыш гасабиланганын күреп, ул сүзне бүтәннәрдән, монда булмаган хәлләрдән башлады. «Әле Борһановны күмеп кайтып киләбез»,— диде ул рәхәт итеп, күңелле елмаеп. Наилә аһ итте. «Үлдемени?» «Үлмәсә күмәр идекме?» Мудрый теш казналарын күрсәтеп ерылып көлеп куйды. «Утыз биш яшьтә!»

Борһанов ул чакта илдә атаклы штангистларның берсе иде.

«Тимер багана! Беләкләр! Күкрәк чуеннан коелган. Даганы дык итеп сындыра! Чумып су астында өч минут тора! Спорт гомер озайта, ди врачлар, пычагым да белмиләр. Минем штанга түгел, биш кадаклы гер күтәреп караганым да юк, ә мускулларны карагыз әле!» Ул, беләген бөгеп, чеби тавык күкәе хәтле генә калкынган сыек күлмәк җиңенә төртеп күрсәтте. «Тәмле ашаганнан озая гомер!»

Нәҗипнең Мудрый белән хәтсездән очрашканы юк иде. Тимерханнар белән ямьсезләшүнең шаукымы басылгач, ул аның ни өчен килеп керүен аңлады: «Әҗәтен сорарга килгән, мәет козгыны!»

Нәҗипнең хәле хәл икәнне каян исәнгән диген... Димәк, күзәтеп яшәгән, җан бирергә егылганнарын сагалап торган! Димәк, Нәҗип гаиләсе хакында гайбәтләр авыздан авызга күчеп йөри!

Ләкин Мудрый сүзне ерактан чәлмәштереп алып китте, имеш,

«Борһанов үлгән!» Штангист аларның уртак танышлары, сөйкемле һәм ипле егет иде.

Мудрыйның сүзе житез аяклы, аның катында Нәжипкә һич тә җебеп төшәргә ярамый иде, каты холыклы, нык булып күренергә кирәк бу биләмче финансистка! Ни тырышты Нәжип, алай да «үлгән, күмдек, зират», дигән җан өшеткеч сүзләрне ишеткәч, коелып инде. Йөрәге купты, ашкынып, якты дөнья белән саубуллашырга җыенган төсле, кылдый-былдый депелдәде. Кеше үз йөрәгенең тибешен ишеттеме, аның эше харап: күз алдын кара томан сара, авыз эче кибә, хәл китә, күз, кая барып тукталырга белмичә, мәгънәсезгә уңга-сулга тәгәри башлый. Наиләне әйт, җүләр түгел диген, «Кай тирәгә җирләдегез, кеше күп идеме, кемнәр бар иде?»— дип юк-бар сорау биреп утыра. Иренең хәлен күрмиме әллә? Таңсылу бүлмәсе ягыннан, кыйммәтле хушбуй исе таратып, бохар песие килеп чыкты да Мудрыйның тезенә сикереп менде. «Да-а, брат, кырыла халык,— дип дәвам итте Мудрый, песинең йонын кирегә сыйпап.— Зиратта карыйм: күбесе миннән яшьләр ләхеткә кереп яткан. Тәмле ашамыйлар, сараннар, акча җыялар. Комсызлык харап итә чордашларны, шул кимерә бавырларын, бөерләренә шул төшә! Менә мине ал... Иртәнге чәйгә казылык турап кыздырган биш күкәй! Аны май, кара икра белән каплап куйдым. Якын килеп карасын чир!» Мудрый буш тартмалар тутырган арба кебек шалтырап көлеп җибәрде, бохар песие куркуыннан идәнгә сикерде һәм хуш исен чәчеп-таратып теге якка йомылды.

Нәжип, телен оныткан байгыш сыман, ары-бире атларга, юанырга тырышып карады, аптырагач Наиләсе каршысына килеп басты: «Чәй куеп җибәрәсеңме әллә, карчык? Бездә икра юк-югын, мәгәр бәрәңгенең иң кәттәсен — чикмәнлесен пешерербез!» «Кирәкми,— дип баш чайкады Мудрый.— Борһановны җирләдек тә зиратны әйләнеп чыктым. Ай-һай, чебен урынына кырыла халык. Урыс-улак поминкага китте, мин, аллага шөкер, хак мөселманмын, гаеткә йөрмәсәм дә, иманымны сатмыйм. Гаеткә катнашсаң... күреп калулары бар. Әле эни бәлеш куеп калган иде, ашыгам!»

Бу йортта бәлеш белән ярышырлык ризык юк иде, хуҗалар аста изелеп калды, Мудрый тагын тантана итте.

«Син әҗәтне юллап алырга кергәнсеңдер инде, Мудрый. Безнең читенрәк чак бит әле»,— диде Наилә. «Юк! — дип кырт кисте аны кунак.— Киресенчә, хәлегез шәптин түгеллекне исәпләп кердем. Янымда акчам да бар. Күпме тиеш әле сез бу ачкак адәмнәргә?— Ул башы белән тегеләр ягына какты.— Өч айга дидегезме?» «Йөз илле тәңкә!»— дип ярым ыңгырашты Наилә. Мудрый куен кесәсеннән шактый калын, таушалган күн бумажник тартып чыгарды һәм утырган җиреннән үрелеп кыеш аяклы өстәлгә өч иллелекне салды. Уйлап-уйлап торгач, тагын бер иллене өстәде. «Булгач-булгач ике йөз түгәл булсын! Сездән артмас!» «Мудрый! — диде аны кочаклый язып Нәжип.— Без сиңа мең тәңкә бурычлы булдыкмы инде. «Булса соң?— дип рәхәт тантанада йөзде кунак.— Җае чыгар, көне килер, баерсыз». «Яхшылык җирдә ятмас»,— диде Наилә күз яшьләрен сөртеп һәм сорау белән иренә карады. Нәжип ияген какты. Өч иллелекне эләктергән Наиләгә бүтән ым кирәкми дә иде, ул кабыл-тибел Тимерханнар ягына чыкты да акчаны өстәл өстенә чөйде. Тегеләр теш араларына шикәр кыстырып чәй эчәләр иде, иллелекләр май капламычы тирәсенә барып кундылар. «Расчет! — диде Наилә, явызланып.— Менә!»

Ул үз куышына чыкканда Мудрый китәргә әзерләнгән, ишек катына, ярым караңгыга баскан һәм Наиләнең чыкканын гына көтә иде. «Изгелегең онытылмас, кулны бик вакытлы суздың, Мудрый!»— диде Наилә чын күңеленнән. Кунакка әнә шул кирәк тә! Ул хуҗаларның мескенләген, аңа тәмам буйсынып бил бөгүләрен, ике яклап тәлинкә тотуларын күреп очынды. Кем бил бөгә диген? Заводта күз өстендә каш

саналган Нәҗип Йосыф улы Нургалиев! Кайчандыр үзеннән йөз чөергән тәкәббер Наилә! Асыл зат! Бүгенгә аңа шул җитеп арткан, моның ләззәте, җиңү тәме әле ай буенча китәчәк. Ай азагында ул чираттагы корбанына барып, үзенең мул яшәве, тәмле ашавы белән мактаначак, күзенә карап торып тегенең бурычлы җанын уч төбендә дер селкетәчәк. Күп андый бәхетсезләр дөнья йөзендә! Алар арасында Мудрыйлар да яши...

Наилә белән Нәҗип аны озата чыктылар, балаларны иртәрәк алып кайтырга ниятләделәр. Барышлый кибетләргә кагыласы, малайларга әз-мәз төче-мөче аласы булыр...

«Савык, браток! — диде Мудрый чуен башын туп-туры тотып.— Чирләгән өчен акча түләмиләр. Чирләсәң — үл, үлмисең икән — чирләмә!» Тагын шаркылдады Мудрый һәм Наиләнең күзләренә яшерен өмет һәм әрсезлек белән карады: «Шәп әйттемме?— дип сорады.— Зират кырында яшисез, яшьләр үлеп тора, килгән чаклар булгалар, кагылырмын!»

Төнлә Нәҗипне тагын йөрәге тотты, ике тапкыр «Ашыгыч ярдәм» килеп китте. Икенчесендә кардиогруппа да бар иде. Алар кардиограмма яздылар, «Җәһәннәмдә яшисез икән, тавышлар комачаулый!»— дип зарланып, нидер шыпырт кына сөйләштеләр. Нәҗипкә әйткәннәре һаман шул ук балык башы булды: «Куркыныч нәрсә шәйләнми, ял кирәк, саф һава, яхшы ризык... Кавказга барыгыз, диңгездә су керегез! Кырым да килешер!»

Йөз сызыклары үзгәргән, күзләреннән нур качкан иренә карап, Наилә төн ката керфек какмады, иртән башы авыртып, чигәләре чыңлап торды.

## 8

«Тик яткан сау кеше дә чиргә сабышыр! — дип кабатларга ярата Наилә. «Тор! Йөр! Сораш! Йөргән аякка йөрәм иярә! Көнозын түшәм санап акылыңнан шашарсың!»

Көн туган саен хатын җилкәне кимерә башласа, ир-атның эше харап, хатын-кыз теленнән котылмак юк. Мудрый кереп чыкканнан атна үтмәде, Нәҗип Йосыф улы Нургалиев эш эзләп чыгып китте. Берочтан, яшәп торырга җылы почмак кирәклеген дә хәтереннән чыгармады. Бер урында: «Иртәгә кил!»— дип чыгардылар. Иртәгесен: «Юк, алмыйбыз!»— дип кире бордылар. Бу хәл байтак кабатланды, бүген елмаеп, өметләндереп каршылыйлар да, иртәгесен дөнья җимерелгәндәй кара коелып, тиз-тиз борып чыгарып җибәрәләр. Көненә өчәр-дүртәр ишек каккан чаклары булды егетнең, өметле сүз ишетелмәде, якты чырай күрмәде. Исенә Изил Латыйпов әйткән куркынычлы сүзләр килеп төште. Тәмам аптырагач, ул доктор Фогельсон янына юнәлде, ике-өч сүз белән хәлен аңлатты, шиген уртаклашты һәм киңәш сорады. Фогельсон аңа күзенең агы белән карады: «Әгәр минем исем белән авыз чайкап йөри торган булсаң!..»— диде ул, ишеккә күрсәтеп...

Врач яныннан ул хәленең үтә мөшкеллегенә тагын бер кат инанып чыкты... Аның психик яктан какшау икәнлеге төптә язылган да, тиешле оешмаларга хәбәр итеп куелган булырга тиеш!..

Татарда кайгы — кара, сагыш — сары. Кайгыда зәңгәр күз дә карасу шәүлә белән өретелә, алсу яңаклар да казылык төргән эчәге сыман кипшереп, юкарып һәм сарыга сабышып калалар. «Ни булды сиңа, җаным?»— дип кочаклый Наиләнең юкарган иңнәрен Гөлнара. Ни әйтсен Наилә, ни әйтә алсын?.. Нәҗибе эшсез. Совет эшсезенең кабәхәт буржуа илләре эшсезеннән аермасы шактый күп: ул дәүләттән пособие алмый, аны профсоюз якламый, шәфкать-мәрхәмәт ширкәтләре аны бушлай ашатып, бушлай кундырып чыгармыйлар. Капиталистик ил-

нең әшсезе бушлай бүксәсе кап булганчы ясмык штие бөгә, икенчегә аңа нибарысы кәбестәле сосиски ашаталар! Шулай, Нәҗип Йосыф улы Нургалиев, дипломлы, белемле, үзенчә егәрле кеше — эшсез. Егәрле дигәндә чүт кенә тукталып торырга кирәктер, эш табалмыйча каңгырып йөргәннән соң, тагын егәре таралып калды егетнең...

Үзенеке үзенә җиткән иде Нәҗипнең. Наиләсе аның эшсез калуын һаман-һаман искәртеп торса да, килде бер көн, ул завод, мөдирлек, дәрәҗәләр хакында бөтенләй уйламый башлады. Иртәдән кичкә кадәр аны бары тик үлем хакындагы кара уйлар гына биләде. Әҗәл якадан алган икән, кая инде эш турында хафалану?! Үлем турындагы уйлардан арынырга тырышып китапларга тотынды Нәҗип, өч-дүрт бит үтүгә китабын тотып атты. Бит саен үлем, кан коеш, үтереш, кырылыш...

Наиләсе кыстагач, Калинин клубына киноларга баргалады, сеансның яртысыннан ташлап качты. Атышлар, чәнчешәләр, бугаздан буалар, мәетләрне таудай өя торган сугышлар бара. Адәм баласы туу һәм үтереш турында укырга, кырылыш турында карарга ярата шул. Табигате шундый аның, ерткыч табигате. Ике таныш гомер эчендә бер күрешәләр һәм китә сүз: фәлән кеше үлгән... рак бәреп еккан... асылынган... тегене көчләгәннәр... чукмар белән сугып башын ярганнар. Ә Васильевода... Васильевода! Бакча каравылчысы, сөяркәсе белән икәүләп, адәм ите ашаганнар... Өчәү, дүртәү очрашсалар да, әллә кайчан гүр иясе булганнарның ак сөякләрен юалар. Тормышта кап-кара эш кылганнарның да сөякләре агарамы икән? Шулайдыр, ходай тәгалә каршында һәммәбез дә тигез.

Тимерхан белән Җәмилә бер мәлгә тындылар, ни булыр, дигән сыман, шым гына җимерек диварга колакларын куеп тыңланалар. Картлар сагая икән, анда нидер булырга тиеш. Таңсылу югалып торды, бушлай путевка алып, бизәнеп-ясанып Мәскәүгә китте дә, атна-ун көн торып, белемен киңәйтеп, офыгын тирәнәйтеп кайтты. Аның беркая читкә чыкмыйча, шунда Яңа бистәнең ишегалды түренә поскан йортта бәбәй төшереп ятканын күрше-күлән белмәмешкә салышты.

Больницага барырга да ашыкмады Нәҗип, йөрәге җитмәде, «барам!» дип кичтән тәвәккәлли, иртән йөрәге кыскандай була. Караватына ава Нәҗип, көне буе шунда ауный. Наилә эшкә йөри башлады, киткәндә һәр иртәдә: «Бүгеннән калма! Невропатологка күрен!— дип кисәтеп китте. Кардиогруппада килгән врачлар: «Невропатологка күренсен!»— дип киткәннәр иде.

Якшәмбе — Наиләнең ялы, көн озынына иренең колагына чиерткә булып кердe: «Әгәр иртәгә больницага бармасаң, сишәмбедә кулаякларыңны бәйләп врачка үзем илтеп тапшырам!»

Нәҗип сүрән генә елмайгандай итте, ияген какты, эченнән генә: «Сишәмбегә хәтле яшәргә кирәк әле!»— дип пышылдады. Егет көненә кырык тапкыр үлеп, кырык тапкыр терелә иде. Язгы, җип-җиңел бишмәтен кигәндә дә йөрәге кыскандай итә, врач янына икенче катка менгәндә дә шабыр тиргә бата. Иелә алмый, егылып үләрмен, дип коты чыга. Авырта йөрәк, сызлый! Ә врачлар сүз куешканнармыни, һаман бер чыгырны әйләндерәләр: «Куркырлык нәрсә юк. Тәмле аш. Саф һава. Тулы тынычлык, гаиләдә татулык кирәк».

Иренең көннән-көн ихтыярын җуеп, солы кисәленә әйләнгәнен күзәтеп, күреп торган Наилә тәмам гаҗиз иде. Нишләргә? Ни хәл итеп ирен аякка бастырырга? Гаилә тормышын ничек алгарак юнәлтергә? Квартир хакы түләр чак җитә, язга чыгып баралар, балаларга өс-баш, аяк киеме юнәтергә кирәк. Сигезенче мартта хезмәттәш хатын-кызлар һәммәсе яңа костюмнар, затлы күлмәкләр киячәк. Ә ул? Өченче ел рәттән зәңгәр күлмәген киеп барсынмы? Адәм көлкесе!

Хатын-кызның яшәү дәверендә иргә мөнәсәбәте кырыкка төрләнә. Нәҗип чирләгәннән соң әле күпме генә ара үтте, Наилә ирен бер кызганды, ул җебеп-мәлҗерәп яткан мизгелләрдә үтмәс пычак белән

суярдай булды. «Шушы хәтле чүпрәк булса булыр икән!— дип кыйналды ул.— Чиле-пешле арыш кабартмасына тап буласымны белсәм... валлаһи Мәхмүт-Мудрыйга чыгар идем! Тик ятсын иде буаз бумажнигын кочаклап янымда!» Менә нинди ямьсез тиңләүләргә барып җитә хатын-кыз ачуы кызганда! Сизә Наилә, бу уйларның үз файдасына түгеллеген шәйли, ләкин, чирле ир хатыны буларак, бүтәнчә уй йөртә алмый.

Сердәше Гөлнара, иманын ачып салып, күңелен бушатты бушатуын, бер үк вакытта Наиләнең күңелен мәңгегә бозып өлгерде. Әгәр Гөлнара аны котыртмаса, Наилә ул тиклем үк иләсләнмәс тә иде. Күп белү хатын-кызга һәрчак комачаулый, ир белән хатын арасындагы упкынны тирәнәйтә. Наилә уйларында гел бәргәләнә, инде генә онытылам, ирне ир итеп яшим, үзгәрәм дип күңеленә беркетә дә, иренең тир диңгезенә чумып, ыңгырашып: «Үләм, уф!»— дип ятканын күргәч, кепкечкенә, әмма саллы йодрыгын йомарлый, иренең эчкә суырылган, кые төк баскан саргылт яңагына «чалт!» итеп ямьйсы кила. Аннан ике күзе читкә борыла: «Йа раббым, кәферлек ич бу, кәферлек... Аңа кыен чакта мин, никахлы хатыны, нинди әшәке уйлар уйлыйм!»

Каршылыклы, болганчык хисләр онытылды дигәндә, хәлсез Нәҗипнең капка баганасына ябышып торуын күргәч, тагын каны котырына Наиләнең. «Невропатолог катына бәйләп илтеп салам!» Тавышындагы усаллыкны оста яшерә, йөзенә ясалма елмаю таплары йөгерә, сабырланырга тырышып учын-учка ышкый, озынча, нәфис бармакларын шартлата. Аның усалланып котырынуын Нәҗибе сизә, тик үртәшми, карышмый: «Әле ярый, бармак шартлатып кына атасың, кулыңа наган керсә, нишләтер идең икән?»— дип күзләрен яшерә. Наиләсе көлгән була, кысылган иреннәрен көчләп яза, ул сүзгә керми, бәхәс кузгалса, давыл чыгасын сизә, очлы әйберләрдән — пычак-безләрдән, тәрәзә төбендә моңарчы тын яткан үткер кайчыдан читтәрәк йөрергә тырыша. Баладан баш-аяк!

Көннәр үтә торды, кемнәрдер дөньяга килде, кемнәрдер Гафури урамының эрер-эремәс яткан кара бозларын таптаган машина әрҗәләрендә чалкан ятып, Яңа бистә зиратына үтә тордылар. Әҗәл белән тереклек арасында адашып калган Нәҗип, бүген, балаларын таратып, Наиләсен озаткач, шифаханәгә барырга булды. «Бүгеннән калмыйм!»— диде сакалын кырганда. «Бүген!»— диде мышный-мышный ботинкаларын арулаганда.

Ялгыз калгач, кеше үзгәрә, уйлары бүтәнчәрәк була. Сакал кырылып, ботинкалар елтырый башлагач, Нәҗип бүтәнчә уйлады. «Әҗәлең җиткән икән, ник врачларны бимазалап зар җылап йөрергә? Анда ни әйтә алырлар ? Ни белә алар? Әштер-өштер тыңларлар, аптекада булмаган, буласы да юк дару язып тоттырырлар. Ни файда? Дару ашап кемнең терелгәне бар? Больница — зират белән ике арадагы станцаларның берсе. Ничә барды инде шул күчеш нокталарына?! Үләргә икән — үләргә! Кайда эшлисең, кем булып дип, төпчени башларлар... Ну их!»

Гаҗәп, моңарчы, шушы мизгелгә хәтле, ул дөнья кую хакында уйланса, үе һәрчак Наиләсенә, улларына килеп ялгана иде. Күңеле: «Миннән башка ничек яшәрләр?»— дип үрсәләнә иде. Бүген, гүя, алар бөтенләй юк та кебек. Нәҗип аларны онытты, үзе, үз язмышы, үз хәле турында гына уй йөртте. «Шулай... үлми калсам, утыз өчтә өр-яңадан яши башларга туры килә. Утыз өчтә! Бу яшьтә ир-атлар хатынлы, бала-чагалы, фатирлы һәм дачалы була. Дәрәҗәсе, калын гына кесәсе була иренең. Исеменә лаек мохиты, дус-ишләре була. Ә минем нәрсә бар? Кашым да күзем, чирем дә үзем! Өметем дә калмады, ичмасам!»

Һәр яктан килеп үлчәгәндә хәзерге хәле болайрак: яшен суккан агач өстеңә ава — качып котыла алмассың! Кыя-таудан таш ишелә — хәзер басып китәчәк! Бәс шулай икән, нигә пыскып ятырга? Ни пыча-

гыма?! Хатын тапкан акчага күз текәп... Эшсез. Эш булу ихтималы да юк. Йөрәк зәгыйфь. Дөньяда хаксызлык барын тойсаң да, күрәшкәчыга алмыйсың... Үз гомереңдә кыюланып бер тапкыр хак сүз әйтеп бакты, «псих» дип атадылар... Нигә яшәргә? Ни өчен?..

Үләргә, поезд астына ташланырга. Алтынчы больницага барган булып тимер юлга таба атларга да ...вәссәлам! «Ялгыш эләгеп харап булган».— дип бер җыларлар да тынарлар...

Ул сискәнеп китте, төсләр, исләр, тирә-яктагы хәрәкәт күзгә күренмәс булды, ул шәһәр ягыннан килгән поездны шәйләде. Тепловоз, аңа ике вагон такканнар. Артта да гадәти ике вагон... Уртада елык-ялык итеп торган ят вагон. Булмагае! Нинди вагон таптаса да барыбер түгелмени? Тезләре калтыранды, бугазыннан ниндидер авазлар чыкты, шул арада көчле куллар аны эләктереп алдылар, ул, уңнан да, сулдан да болай таба йөгерешкән тимер юлчыларны абайлады...

Милиция бүлегендә аңа гел бер сорауны биреп йөдәттеләр: «Ни өчен син хөкүмәт әгъзалары утырган литер поездга якынлаштың? Син аны нинди яшерен максат белән көтә идең? Махсус составның станция аша үтәсен кая белдең? Кем аны сиңа хәбәр итте?!»

Нинди поезд? Нинди хөкүмәт әгъзалары? Хөкүмәт вәкилләрен түгел, поездны да күрмәде Нәҗип... «Тәгәрмәч астына ташланырга бара идем!»— дип әйтмәде әйтүен. «Больницага бара идем, чирлим, йөрәгем авырта, зиһенем таралган чак булгандыр».— дип мыгырдады. Аңа ышанмадылар, ябык машинага утыртып каядыр, югарырак оешмага алып бардылар. Төн кундырдылар. Иртән сыек кына бер стакан чәй эчерткәч тагын сорау алырга чакырдылар. Ул һаман бер сүзне кабатлады: «Больницага барырга чыккан идем. Ә алтынчы больница кайда? Тимер юлның теге ягында. Тимер юл аша чыгарга кирәкме миңа? Кирәк. Поездны күрмәдем, уйларым бүтәндә иде».

Сорау алучы лейтенант иде, менә бүлмә ишеге кинәт кенә ачылды, аннан капитан килеп керде. Ул башы белән Нәҗипкә ишарәләде дә: «Чыгарып җибәр аны... Псих икән! Учетта!»— диде.

Баш-аягы исән калуына сөенергә дә белмичә Нәҗип өенә кайтты, елап, шешенеп беткән Наилә аның күкрәгенә капланып бик озак үкседе.

Бер нәрсәне белми калды Нәҗип, ул тәгәрмәче астына ташланырга җыенган литер поездда илнең тимер юллары министры дәһшәтле Илья Ефимович Шидловскийдан тыш, аның белән янәшә яшәүче, язмыш сукмаклары тиздән кисешәчәк ике гали зат — хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич та баралар иде.

## 9

Шидловскийның киләсен байтактан беләләр һәм Татарстан мәркәзе шанлы-шәүкәтле Казанда министрны тантаналы курку белән көтәләр иде. Кунак булырга ярата һәм бу җәһәттән үтә кырыс, бөртекчән һәм үтә текә кеше иде Илья Ефимович. Озын буй, бөкре танау, икегә ярылган чыгынкы, нык ияк. Бөркет карашлы күз алмалары бер чакта да як-якка тәгәрәмиләр, министр һәрвакыт алдына гына карый. Тавыш көр, тән сәламәт, ашказаны таза, министрның бер утырганда биш кешелек ашап, җиде кешелек эчә алуы да илдә мәгълүм иде.

Кунак кабул итү олы һәм баш җитмәслек четерекле фән ул! Һәр төбәктә кунакны үз милли гореф-гадәтләренә яраштырып кабул итәләр, шул төбәк осталарының кулыннан килгәнче сыйлыйлар да. Басыйр Бариевич, «Министр килә!»— дигән хәбәр алынгач та, бер минут уйлап тормыйча, җан дусты Иван Иванович янына чапты. Алар, шәһәр советы утырышын нәкъ ике сәгать ярымга кичектереп, кабинетка кереп бикләнделәр. Әзерлекне бүген үк, нәкъ шул минутта башлап җибә-

рергә кирәк, соңга калу үлем белән тиң булачак. Россиянең иң абруйлы тармак министры Шидловский килә! Дәрәҗә ягыннан ул оборона министрыннан гына калыша торгандыр!

Данлы-шанлы, кояшлы-айлы Татарстанда тимер юллар әз. Казаннан Бөгелмәгә барыр өчен чит өлкәләрдән рөхсәт сорарга туры килә. Бәс, хуҗалыгың бәләкәй икән, андый-мондый чатакларны да бик тиз күреп алырга була! Аллам сакласын! Дөрес, вак-төяк чатаклар өчен көенмәскә дә була. Әмма вак-төяк өчен нигә җанга борчу алырга?! Күренмәсен хаталар! Күренмәсен дисәң, башкала кунакларының күзен капларга кирәк! Ә аның кырык төрле әмәлен беләләр Татарстанда!

Тимерюлчылар, шәһәр советы һәм башка мөһим оешмалар белән берлектә, ныклы план нигезендә кунак кабул итү кампаниясен ачып җибәрделәр. Белсен әле мәскәүлеләр татарның кем икәнен! Күрсеннәр! Кавказлылар кунакчыл диләр, аларны куып узарга! Урта Азиядә инде ул сый-хөрмәт, диләр. Азияне дә үтеп китәргә!

Беренче нәүбәттә, әлбәттә, кунакның тамак ягын кайгырту лазим. Мәскәүлеләр ашарга ярата, ризыкның рәтен белә! Белештеләр, Шидловский, асылда балык ризыкларын ярата икән. Балык дигәч тә Каспий хамсасы белән Балтыйк килкиен ашап утырмый инде. Андыйлары ярамаган тагын пешеп төшкән социализмда яшәүче Рәчәй кара корсакларына! Татарстан балыкчыларына, елга, күл буйларында укмашкан артил, бригадаларга ныклы боерык китте: әгәр җәтмәләргә кырпы, эре чөгә, мәрсиннәр эләгә икән, һәммәсе тимерюлчылар карамагына тапшырылырга тиеш. Олы кунак килеп җиткәнче кырпыларны, чөгә-мәрсиннәрне тере килеш сулыкларда сакларга!.. Майлары агып торган ысланган сазаннар, төрек ятаганнары шикелле кәкре чехоньнар (ысланганы гәрәбә кебек үтә күренмәле була аның! Ә исе, исе!.. Чәшке бүрек һәм ысланган сазан белән чехонь ташып, казанлылар икенче аэропортларын салдылар!) бүгеннән Казанга килеп җитсеннәр! Идел-Чулман балыклары белән генә эш йомгакланамы? Илдә балык беткәнмени? Чавыча һәм башка Камчатка балыклары әзерләргә Ерак Көнчыгышка вәкил очты. Министр килеп төшәр алдыннан ул да кайтып җитәргә тиеш. Камчаткада чавыча балыгының күзен генә аерып, имән мичкәләрдә тозлыйлар икән. Тач май була ди, әйдә министрның күзе тонсын, ашап телен йотсын!.. Сукыр һәм телсез министрдан да кулай кеше буламыни бу дөньялыкта?! Миногалар, диңгез кыслалары, елан балыклар алырга вәкилләр Балтыйк буена, Калининградка ашыкты. Акбалык, муксун ише гаҗәеп балыкларны әзерләргә ике кешедән торган бригаданы Обь-Енисей бассейннарына җибәрделәр. Кызыл-кара уылдыкның иң әгъләларын, тере вә эре бөртекләрен алып кайтырга Салехардка — төньякның агач башкаласына ике вәкил юлладылар.

Әле болар эшнең башы гына иде! Иван Иванович белән Басыйр Бариевичның хыяллары яхшы чүпрә салынган камыр кебек көннән-көн ташыды... Казанга тәрәлеп торган орденлы совхозларның берсендә күе сыер сөте эчертеп кенә биш дана чучка малаен симертә башладылар. Аларны өч тапкыр һәркөн чишмә суы белән генә юып, щетиналарын тарап, Пакыстаннан килгән йонтәс, йомшак сөлгеләргә урап кына киптерделәр. Республиканың иң атаклы мал врачлары сәламәтлеген катkat тикшергәннән соң, аерып куелган кышлау печкән үгез, сөттән бүтән ризыкны татып карамаган яшь бозауга да берәр врач, икешәр караучы беркетелде. Врачларны, мал караучыларны Казан докторлары белән Мәскәүдән килгән профессор кат-кат тикшерде, көн аралаш алардан анализлар алып, тәрәтен, бәвелен сынап тордылар. Малларны кем чала, кем туный, итне кем чаба — болар һәммәсе бер ай элек тәгаенләнде, алар, төп эшләреннән азат ителеп, «махсус бригада составына» кертелделәр һәм айлык хезмәт хакын икеләтә ала башладылар. Әгәр югары дәрәҗәдәге кунакны кабул итү утсыз-төтенсез генә үтә калса, каршы алуга катнашучыларның һәммәсенә дә кыйммәтле бүләкләр.

келәмнәр, бәллүр савыт-саба, акча вәгъдә ителде. Мәскәүдән ярдәмгә чакырылган профессорга мехчылар исеменнән кайры тун бүләк иттеләр.

Яшелчә-җимеш, ананаслар, бананнар, кокос чикләвекләре хәстәрен күрергә биш кешелек бригада Рәчәйнең махсус режим белән ашаган Рига, Ленинград, Киев калаларына таралды. Эчемлек ягын дүрт кешелек җитез егетләр бригадасы кайгыртты. Француз, итальян, кытай коньяклары кайтты. Атаклы «Смирнофф» аракысын юнәттеләр. Чистай аракы заводында махсус өлгерткән иссез-тәссез аракыларны Васильево пыяла заводында берәмтекләп эшләнгән шешәләргә тутырдылар.

Хөрмәтле Иван Иванович белән Хөрмәтле Басыйр Бариевич милли якны да онытмадылар. Шидловскийга дип Арчада башмак чиктеләр, кара, чын татар түбәтәе табылмагач (дефицит дисәң дә дефицит!!!) өч тәңкә ярымлык үзбәк түбәтәен алып куйдылар. (Әле ул чакта Шидловскийның баш размерын белмиләр иде,— түбәтәйне бишне алдылар!)

Министр ялгыз йөримени? Аның белән биш урынбасары, ике секретаре, пешекчесе, киендерүчесе, тән сакчылары киләчәк. Кыскасы, салон-вагонга алдан-арттан тагылган дүрт вагон кеше белән шыплап тутырылачак. Аларның һәммәсенә, дәрәҗәсенә карап, сый-хөрмәт, бүләк-санак кирәк булачак. Урынбасарларның берсе гөрҗи, икенчесе казакъ халкыннан икән. Грузиягә һәм Казагстанга шунда ук махсус бригадалар китеп, алар яртышар вагон ул төбәкләрнең ризыгын, эчемлеген кайтарып җиткерделәр. Махсус әмер белән аларга рәхмәт белдерелде...

Ниһаять, министрның һәм беренче урынбасарларның өс-баш, аяк размерлары тәгаенләнде. Боларны ачыклау өчен Мәскәүгә махсус вәкил барып кайтты. Һәммәсе яшертен эшләнергә, илнең тимер юл хуҗалары өчен көтелмәгән гаҗәеп сюрприз булырга тиеш иде!

Милли якны уйлагач, хөрмәтле һәм зирәк Иван Иванович Әнисә абыстайның атаклы каз бәлешен исенә төшерде. «Кирәк булырмы?»— дип сорады шигәеп кенә Басыйр Бариевич. «Илья Ефимович «татар ашы?» дип сорап куйса, бәлеш тә әзер торсын, каклаган каз да!»— дип, суеп каплады Иван Иванович.

Әзерлек эшләренең башында сыналган, хуҗалар сагында җанын фида кылырга әзер, тугры Исламнур торганын зирәк укучылар әллә кайчан чамалап алгандыр, дип уйлыйм. Әйе, Исламнур йокламады, ашамады-эчмәде, хатыны кырына ятмады, Татарстан даны өчен көрәш кырларыннан кайтмады.

Ниһаять, һәммәсе әзер булды шикелле. Шәһәр советының җыелышлар залында, тимерюлчылардан каттә иптәшләр белән берлектә, яшерен киңәшмә үтте. Һәр тарафка җибәрелгән вәкилләр, һәр тармакка беркетелгән сыналган иптәшләр, кәгазьләргә бакмыйча гына, телдән кыска-кыска хисап биргәч, абруйлы утырыш: «Кунакны кабул итәргә мөмкин!»— дигән нәтиҗә ясады. Гөрләтеп кул чаптылар, кайберәүләрнең күзләре яшьләнде, алар аягүрә басып «ур-ра!» кычкырдылар.

Иртәгә Шидловский килеп төшә дигән көнне, печтек кенә чатак булып алды. Иван Иванович белән Басыйр Бариевич министрга хәстәрләнгән бүләкләрне — тун, бүрек, эт тиресеннән тегелгән унталарны күздән үткәреп багалар иде, бүреккә җиткәч, аптырашта калдылар. Буйга пәһлеван булса да баш бәләкәй икән министрның! Нибарысы илле җиденче размер! «Баш зур һәм буй биегрәк күренсен өчен Илья Ефимович озынча, йөнтәс бүрек киярга ярата»,— дип шул көнне генә Мәскәүдән кайтып төшкән вәкил ачыкламаса, тәмам көлкегә калачаклар икән! Бүрекнең дә кулаен эзләп таптылар!

Казан бер төн йокламады. Казан утсыз да кайнады. Казан «сугышчан әзерлеге беренче номерга куелган» хәтәр шәһәр иде. Килде министр, ике аягын ерып, уктай карашын төп-төз каршылаучыларга

төбәп күрешеп чыкты, мондый сөенечле, чиксез олы тантананы шәһре Казан диварларының күргәне дә, ишеткәне дә юк иде. Бик кызганыч, үтә жәл, гади кешеләр аны күрү бәхетеннән мәхрүм калдылар: вокзалны урап алган йөз дә унөч милиционер, кырык ике дружинник халыкны ул тирәгә якын да җибәрмәде. Литерлы поездны ялга, аулак юлга күчерделәр, министр шан-шәүкәтле борынгы калага аяк басты. Төкле аягың белән, Илья Ефимович!

О, ул көннәр, ул көннәр! Гомергә онытылмаслык, хатирәләрдә ныгып, телләрдән телләргә, буыннардан-буыннарга күчеп легендаларга әйләнәчәк тантаналы вакыйгалар! Сый-хөрмәт, татлы сүзләр, милли туганлык, эшчеләр сыйныфы белән Мәскәү кунакларының бер сулыштан сулаулары, алкышларга күчкән кул чабулар. Шунда ук хәбәр таралды: Илья Ефремович үзе дә, аны озатып йөрүче затлы кешеләр дә казанлылардан бик тә канәгать калганнар! Моны ишеткәч, хөрмәтле Иван Иванович «гопакка», хөрмәтле Басыйр Бариевич «эпипәгә» биеп җибәргәннәр, имеш...

Ләкин, ләкин... Ах, шул ләкин! Шул «ләкин» дигән каһәр суккан сүз булмаса, без әллә кайчан коммунизмга барып җитеп, түшәмгә төкереп ята идек инде. «Ләкин» бар, шул аякны бәйләп тота...

Бөтен ваклыкларына кадәр уйланылган, җиде кат үлчәп кенә киселгән иде, юмарт күңелле хуҗалар Илья Ефремовичның бер сәер гадәтен алданрак белә алмаганнар икән...

Министр нигъмәтләргә бай мәҗлесләрдән соң, татлы йокыга китә алмыйча, байтак вакыт интегеп ята икән. Чалкан ята да бер өзмичә тәмәке тарта. Тәмәке төпчеген сүндереп тормый, утлы килеш «черт» итеп төкереп теләсә кай якка очырта икән. Ә хуҗалар, туң башлар, төпчек җыярга махсус вәкил куярга искәрмәгәннәр... Куясы инде шунда Исламнурны! Мондый хәл буласын алдан шәйләсә, Басыйр Бариевич үзе саклап торыр иде министр авызыннан очкан төпчекләрне, уяулыгын югалтмас иде!

Министр очырта тора, утлы төпчекләр литерлы поезд вагонының яртылаш химиядән генә торган почмакларына барып-барып төшә. Салон-вагон, барган шәпкә, җилдә очкыннар чәчә-чәчә яна ук башлый. Китә шау-шу, китә ыгы-зыгы, төтенгәме, хәмергәме баш биреп исергән, чак тончыкмаган Илья Ефремовичны унөч кеше уттан чак алып чыгып өлгерәләр.

«Кылган яхшылыкларыбыз утта очты!» — дип кайгыра Иван Иванович.

«Беттек!» — дип зарый-зарый елый, күрше өлкә чигенә кадәр озата баручы Басыйр Бариевич.

Соңыннан мәгълүм булды: хәлләр алай ук мөшкел булмаган икән! Тугры ярдәмчеләр, җан сакчылары белән бергәләп, сәгате-минуты белән көчәйгән явыз уттан башта министрны түгел, салон-вагонга шыплап тутырылган кыйммәтле бүләкләрне — сандыкларны, чемоданнарны, бүктәрләрне-төеннәрне алып чыкканнар икән!

## 10

Җүләргә чыгарып, «психушка»га тыга язганнан бирле Нәҗипнең кемдер җиңел кулдан «ак чәчәкләр» дип атаган һөнәр иярәренә хөрмәте какшады: агулы, зәһәр үләннәрнең дә еш кына ап-ак чәчәк атканын белә иде инде ул! Бар ул «гөлләр» арасында да чеп-чи наданнары! Йөрәк — гади насос лабаса, йөрәкнең үзгәреш, тайпылыш законнарын да белә алмагач инде! Үзләре юньле нәтиҗә чыгара алмагач, невропатологка аткаралар!.. Барды Нәҗип докторга, барырга туры килде...

Алдан ук искәртеп куйыйк: Нәҗип Йосыф улы Нургалиев бу юлы табибның чынына, остасына тап килде! Бәхете! Врач — кулына зур хокук тапшырылган стрелочник ул, теләсә туннельдән сине яктыга чыгара, теләсә туп-туры зират сукмагына төшерә.

Фәридун Фазлыев кешенең тәненә генә түгел, җанына да үтеп керә алган врач иде. Кырык сигезнең егерме икенче мартында кулга алынып, Особое совещание тарафыннан бер дә юкка ун елга хөкем ителгән кеше, төрмәнең гаять истәлекле беренче төнендә үк төп сорауга җавап таба алмыйча изаланды: ник утырттылар аны? Нигә җәмгыятьтән аердылар? Кемнәр файдасына?

Черек күл камераларында озак яткырмадылар аны, өстеннән язылган донослар өч-дүрт башны кыеп төшерергә җитәрлек иде. Монда совет системасын сүгү, халыкларның бөек юлбашчысына яла ягу, хурлаулар кебек, заманының иң хәтәр гаепләре бар иде.

Фәридун Фазлыев иректә чакта ходай ихтыяры белән чын табиб иде, аның янәшәсендә йөзләрчә наданнар, карьеристлар, эгоистлар, төп вазифаларын онытып, почмак саен: «Бөек юлбашчыбызга мәңгелек дан!» — дип акырып, мактаулы исем артыннан җылыдан-җылы урын яулаганда, Фәридун Фазлыев, эштән бүтәнне белмичә, меңнәрчә авыруларга тереклек суы бирә торды. Даны президиум өстәлләрендә, биек трибуналарда түгел, халык арасында таралды, врачларны аралап-сайлап, авырулар аңа эләгергә тырыштылар. Ниһаять, дәүләт аппараты дигән сукыр көч хәрәкәткә килде, аның туры сүзен — кыек дип, изге гамәлләрен — җинаять дип язып бирделәр. Ялкау-аңкаулар көндәшеннән, янәшәләрендә эшләгән намус, әхлак сакчысыннан котылдылар.

Лагерьда да ул беравыктан врач булды. Анда да кешелек сыйфатларын югалтмады, өстеннәрне түбәннәрдән аерып карамады. «Нигә тотып яптылар, нигә җәмгыятьтәге гадел урынымнан аердылар?!» — дигән дәһшәтле сорауга җавапны, бик күп язмышларны очратып, бик күп яралы йөрәкләрне тыңлагач кына, меңнәрчә җәбер-җәфаларны җиңеләйтергә тырышып, әллә ничә үлемнән котылып калгач кына тапты. Җәмгыять җинаятьчеләрдән түгел, гаделләрдән арынырга, намуслылардан котылырга теләгән икән!

Тапкан җавабы аның рухын сындырырга тиеш булса да, Фәридун Фазлыевның борыны салынмады, ул риясыз рәвештә язмышлар чарпалышып актарылган мәйданга — тоткыннар арасына гаделлек вәкиле булып керде дә пәйгамбәрләрчә — гөнаһлыларга да, гөнаһсызларга да бердәй тугры хезмәт итте. Меңләгән тоткыннар гына түгел, кансыз җәза осталары, лагерь хуҗалары да аны олылап «доктор» дип атап йөрттеләр. Көнчелек — кешелек җәмгыятендә көрәшне хәрәкәткә китерә торган беренче рычаг ул, лагерьда да көнчеләр табылды. Мөртәт бөтен туфракта да яралып үсә! Исән калды Фәридун Фазлыев, илле алтынчы елның февралендә акланып, реабилитацияләнеп иреккә чыкты.

Теге чакта астыртын елмаеп, күңелләрдә зәһәр агу куертып аны озатып калган көнчеләрнең күбесе, тымызык күлдәге кортлар кебек үрчегәннәр иде, берәүләр профессор, доцент булып беткән, иң әрсезләр министрлыкка, обкомга үрелгән, һәммәсе диярлек югары, җылы урыннарга хуҗа булган, өсләренә җылы, томанлы яңгыр булып бүләк, орденнар, мактаулар яуган. Кая карама, атказанган фән эшлеклесе, лауреат та дипломант...

Ул аларны эзәрлекләмәде, күзләренә күренергә тырышмады, елан үлсә дә, агы кала, аллам сакласын. Сталин заманнары әйләнеп кайтмас, дип кем әйтә ала? Фәридун Фазлыев көнчеләр күзеннән читтәрәк булырга тырышты, эш урынын, больницаны да татар ягыннан, шакшы һавалы, сөремле Яңа бистә тирәсеннән эзләде.

Үз өстеннән язганнардан берәү, очрашкач, күзен җиргә тәгә-

рәтеп, аны югары катлау вәкилләре дәвалана торган шәһәрлә шифаханәгә эшкә килергә кыстады. «Үзем урнаштырам!» — диде. Фәридун Фазлыев, табигатенә тугры калып, кызыккыч тәкъдимнән баш тартты. Белеше, керфекләрен мелт-мелт сикертеп: «Төрмә сине төзәтмәгән икән!» — диде. «Күңелең таза, тәҗрибәң ныклы икән, эш кайда да бар!» — дип уйлады Фәридун Фазлыев һәм, бер ай эшләгәч үк, үзенең сайлавыннан канәгать калды. Коллектив дус диярлек, күпчелек татар, кай арада үз телендә сөйләшүчеләр дә очраштыргалый, ара-тирә тимер юлның теге ягында, бистә урамнарында, кичләрен тальян гармун сыздырып җибәрәләр, әтәчләр дә саф татарча «кикерикүк!» дип кычкыра — лагерь кысаларында үз җирен, үз телен, үз моңын чиксез сагынып кайткан иде Фәридун Фазлыев.

Ул Нәҗип Йосыф улы Нургалиевне кызыксынып каршылады...

Яшь чагында бер дә авырмаган авыл егете. Сәламәт үскән. Әтиәнисе исән, тигез. Хәзер дә күңел төшенкелеген исәпләмәгәндә, ябыклыгын уйламаганда, сау-сәламәт күренә. Күзләрендә генә ялвару, курку моңсулыгы, гасабилык галәмәтләре бар. «Тормышым тормыш түгел хәзер, җан газабы. Шул каһәр суккан Мәскәүгә барып әлектем дә, шул ярамады, чир кинәт бәрде! «Үләм!» — дип бик курыктым. Хәзер дә гел әҗәл хакында гына уйлыйм. Үлем-җитем дигән сүзләрне ишетә алмыйм, «ашыгыч ярдәм» сызгыртып үтә башласа, котым ботыма төшә... Иелеп ботинкамны бәйләгәндә җаным бугазыма килә кебек. Бер чиләк су китерсәм, йөрәгемә йонлач тәпиле үрмәкүч ябышкан сыман. Яктыдан караңгыга, караңгыдан яктыга үтә алмыйм, күңел әллә нишли, зиһен томалана, бөтен җирдә теге кортка, әҗәл дигән явыз мине сагалый төсле... Үлемнән башка бер нәрсә хакында да уйлый алмыйм».

Сөйләде-сөйләде дә Нәҗип туктап күзен күтәрде: тылсымчымы әллә бу невропатолог дигәннәре? Ап-ак кашлы, дәү шыксыз борынлы бу доктор аның авызындагы йозакны алды, түбәләмә тулган капчыкны чишеп җибәрде, ул ни тойганын, ниләр кичергәнен, докторларга түгел, Наиләсенә дә ачмаганнарын чыгарды да түкте.

Фәридун Фазлыев аны бүлдермәде, ишекнең теге ягында чират кыштырдаса да, ишек ачылып-ачылып киткәләсә дә, бу егетне кемгәдер аткарырга, өметен кисеп чыгарып җибәрергә ашыкмады. Бу авыру сирәк очрый торганнардан иде. «Мөгаен, хисле кичерешләргә бай җандыр бу ир!» — дип уйлады ул. «Шулай да чир бер сәбәпсез эзләп килми, ишекне табып, нәкъ вакытында шакый ул. Кинәт чирләвегезнең сәбәбен үзегез кай тарафта дип күрәсез? Чир тигән кеше үз авыруының тамырына үзе барып җитә ала икән бу кеше тәненә дә, җанына да хуҗа була ала дигән сүз! Бу бик мөһим! Нинди яман чир килсә дә, кеше үз язмышын кулыннан ычкындырмасын! Тәннең бер әгъзасы да сәбәпсез сыкранмый. Менә минем йөрәк кизүем бар. Йөрәк сиздерә икән, мин даруга, коткару бөятенә барып ябышмыйм. Әүвәл, нигә авырта бу йөрәк, дип эзләнә, тышкы, эчке сәбәпләрне эзли башлыйм. Аракы эчмәдем. Гомумән дә эчмим. Авыр әйбер күтәрмәдем. Авыр сүз ишетмәдем. Йөрәкнең беренче дошманы — авыр сүз. Татарның рухи табиблары «авыр сүзләр ишетсәгез, үткәреп җибәрегез!» — дип безгә изге васыять калдырган... Ниһаять, эзләнә-эзләнә йөрәк тынычсызлыгының сәбәбенә барып җитәм». «Сез бит врач!» — диде Нәҗип, көчәнеп елмая-елмая. «Һәркем үзенә-үзе врач. Кеше организмының, тәненең нечкәлекләрен бер врач та, иң сизгер аппаратлар да белеп бетерә алмый. Сәламәтлек, барыннан да элек, кешенең үз кулында». «Сез җан газапларын күздә тотып әйтәсезме?» — дип сорады сак кына Нәҗип һәм соравы белән Фәридун Фазлыевның күңелендә шик уятты. «Барын да чишеп бетердеме бу егет?» — дип икеләнде ул, ләкин ашыгып сорашырга базмады. Үзе сөйләсен, җиңеләйсен.

Нәҗип бер врачка карап, бер ишеккә колак салып, үткәннәрен кабатлап, ваклыкларына кадәр сөйләп чыкты. Фәридун Фазлыев, чишмәдә су саекканын күреп, ипләп кенә болай дип йомгак ясады: «Сезнең үтәлми калган, хәзерендә җаныгызны борчып, бәгыргезне кимереп торган берәр олы максатыгыз юкмы?»

Нәҗип алдын-артын уйламыйчарак: «Юк»,— дип ычкындырды. Врач әллә аны ишетте, әллә ишетмәде, үз соравының әһәмиятен искәртергә теләгәндәй, сорауны кабатлады. Нәҗипнең сүзсез, иягең күкрәгенә терәп утыруын күреп, егеткә җавап эзләшергә булышты: «Адәм баласының мөмкинлекләре чикләнгән,— диде ул.— Һәркемнең үз офыгы, тормыш кора ала торган мохите бар. Чама чамага туры килергә тиеш. «Ора алмас зур күтәрер!» — дигән татарлар. Ора алырлык егәрең юк икән — күтәрмә! Чөнки актыктан күңелеңә зур үкенечләр килер. Үкенеч — көнчелекнең әнкәсе ич ул! Алар бер-берсенә тагылып йөриләр. Көнчелек исә — иң явыз хисләрнең берсе. Аннан котылмак юк! Булдыра алмастайны алдына куйган кеше гомере буе бүтәннәрдән көнләшә. Аңлата алдыммы икән?»

Врач та, Нәҗип тә тынып калдылар. Һич тә Нәҗип көткәнчә булмады бу очрашу. Фәридун Фазлыев аның тезенә суккаламады, инә төртеп колак яфрагын да тишмәде, физик күнегүләр ясатып сынамады, сөйләтте, сөйләтте дә хәзер аңгырайган сыман тик көлемсерәп утыра! Ичмасам гадәттәгечә «тәмле ашарга, татлы йокларга» кушсын иде! Авыр тынлыкта ишетелгән сүзләр үтә сәер иде: «Мин сезгә психиатр белән киңәшергә тәкъдим итәр идем»,— диде Фазлыев ярым елмаеп. Башта Нәҗип аңламыйча ук торды: ничек, психиатр янына?! Бер тапкыр барды ич ул анда! Чак бәлага тарымады! Тагын шул котсыз Фогельсон янына барып керергәме? Куып чыгарды чыгаруын, ә шомлы нәтиҗәсен теркәгән! «Псих!» дип гамәл дәфтәренә язып куйган!

Фәридун Фазлыев егетнең күкрәгендә нинди уйлар кайнаганны аңлады булса кирәк, тавышын бераз күтәрә төшеп: «Әйе, психиатр янына керегез. Бу тәкъдим сезне борчымасын. Сезне сәламәт дип беләм. Тагын да сәламәтрәк булыйм дисәгез, аның катына барыгыз. Бик ышанычлы, төпле, тормыш мәктәбенең авырын үткән таныш врачым бар. Огородникова фамилияле. Шуның белән киңәшегез әле».

Фәридун Фазлыев уч төбе хәтле генә кәгазьгә бер-ике сүз язып Нәҗипкә тоттырды.

Шөкер, Огородникова дигәннәре теге юлы Нәҗипне боргычлап чыгарган козгыннар оясында түгел, бүтән шифаханәдә эшли икән.

Март азагы. «Март башыдыр — яз башыдыр, күңелне хуш ясыйдыр». Татар тормышының һәр тарафына күзе җиткән бөек пәйгамбәребез Тукай шулай дигән. Авырулар язга чыкканны, авыр кыштан котылганны түземсезләнеп көтәләр. Сырхау кешегә аерата таң аттыру авыр. Җәй — авыруларның өмет таңы ул, һәр бичара: «Һай, җәйгә чыксаммы?.. Сихәтләнепләр китәр идем!» — дип ымсына.

Нәҗип тә мартны көтеп алган иде, әлегә бәрәкәте тими, менә бүген дә Фәридун Фазлыев яныннан сөмсере коелып, торбасы кыеш иске самавыр кебек чайкалып, күзен җиргә тәгәрәтеп кайтып бара. Аякларга тышау салынганмыни, гәүдә, көне буе чүкеч суккандагы сыман авырайган, баш исле мунчадан чыккан кешенеке кебек сулкылдый, чигәләрне өзмәс кысып тора. Көннең чалт аяз икәнлеге күренми, кояш, карны пычрак дип тормый, ашый да ашый, юл чите көртләре кәрәзләнеп, шыбырдап сөрлегәләр, яз шәһәрнең кыш буе җыеп, яшереп саклаган шакшыларын ача. Анда шакшы су түккәннәр, монда көл тавы, арырак мәче үләксәсе килеп чыккан. Чип-чиста кар бөртекләренә тагылып төшкән сөрем, корым кисәкләре хәзер, дымлы, җылы һава дулкыннарына ияреп, яңадан өскә күтәрелә. Җил юк диярлек. Үтеп-сүтеп йөргән машиналар калдырган кургашынлы

авыр һава язны тансыклап киңәйгән күкрәкләргә чир булып кереп тула, бугазны әчеттерә. Яшь әниләр аллы-гөлле ефәк чүпрәкләргә төреп, аллы-кызыллы хыял канатларына утыртып сабыйларын шушы һавага — «сәламәтлеккә» алып чыкканнар. Тимер юл янында нәни генә бакча. Өрәңгеләрнең, кайчандыр горур булган тупылларның башын тумпак калдырып кыркыганнар. Нигә кыркыганнар, ни хаҗәте булган, дип сора — беркем белми. Тупылларга күрше итеп, шпал башларына терәп диярлек яшь наратлар утыртканнар. Ел саен күпме акча исраф итеп утырталар шуларны, җәй дәвамында наратлар корып, шыр таякка калалар. Чөнки нарат агачы шау-шуны, тавышны сөйми. Тавышка иң сизгер агачлар — нарат белән карлыган. Кеше йөри торган сукмак янындагы карлыган куагы бер чакта да җимеш белән куандырмый, алар аулак, тын почмакларда оеп утырырга яраталар. Әгәр бу тупыллар болыт-болыт ябалдашлары белән күкрәп утырса, ни булыр иде? Газны-тузанны тупыл кебек суырган агач безнең якларда юк. Тупыл башларының ни өчен кыркылганын Нәҗип, әлбәттә, белми. Уйлап та карамый. Һәр нәрсәнең сәбәбе була, моннан байтак еллар элек, хөрмәтле Иван Иванович Украинадан монда килеп, шәһәр советының хуҗасы булып утыргач (Мәскәүдән шалтыраттылар, түргә аны үткәрергә киңәш иттеләр!), бик шәбәеп кенә, муенны текә тотып, яль-яшь сылукай белән машинасында тирбәлә-тирбәлә аулакка барганда, тәрәзәдән ак мамыкка уралган бер орлык тирбәлә-тирбәлә очып керде дә Иван Ивановичның кыз ягындагы сул күзенә кадалды. Яшь рәис кадакка утырдымыни, уңга-сулга янтайды, күзе әчеттереп кычытты, сызлады, туктаусыз яшь акты. Чытлык сылукайга нәрсә, авызын тыя һәм йома алмыйча, чирек сәгать шаркылдады. Больницага кагылырга туры килде, сылукайдан бүгенгә аерылырга язган икән. Ул, больницадан кайтуга, шәһәрне яшелләндерү бүлеге мөдирен чакырып алды. Икенче язда ук күккә ашкан тупылларны акылга утырттылар. Черкиләрдән куркып, Сталинның Кара диңгез ярларында ничәшәр йөз ел үскән кипарисларны тунатып ташлатканны ишеткәне бар идеме хөрмәтле Иван Ивановичның, әллә Сталин белән холык уртаклыгы очраклы туры килдеме, тарихта бу мәсьәлә әлегә ачылмыйча кала бирде. Шул елдан бирле шәһре Казан күген сакларга тиешле мәгърур агачларны яз саен сөннәткә утырталар.

Тупыллар тоташтан башсыз, ботакларын бер читтәрәк яндырып, көлен алып киткәннәр. Тупыл төпләре кардан әрчелгән, анда ләмгә катып буш шешәләр сибелеп ята. Менә, сәләмә бушлат кигән берәү иске кәрҗин күтәреп бакчага керде дә, Нәҗипнең буен-сынын, кыяфәтен үлчәп карагач, «Бу шешәләрне җыярга рөхсәтме?»— дип сорады. «Мине шешә каравыллый дип уйладымы бу хәерсез!?»— дип рәнҗеде Нәҗип, эскәмиянең ярылып беткән аргы башына барып утырды.

Психиатрга күренәсе килми иде аның. Эзләнер-чокчыныр да холкыңнан, фигылеңнән бер-бер чатак казып чыгарыр. Йөрәк хастасы янына тагын бер шик килеп утырса, ничек яшәмәк кирәк?

Бакчада ул шактый озак юанды һәм гел Фәридун Фазлыев белән очрашуы хакында уйланды. «Һәркем үз чиренең сәбәбенә, тамырына барып җитә алырга тиеш... Җанның кичерешләрен, тилмерүләрен бары тик җан хуҗасы гына тулаем белә ала!.. Сез берәр чакта нәфесегезне кандыра алмыйча әллә дөньяга бик нык рәнҗедегезме? Сезнең тормышка ашмас хыялларыгыз җан тынычлыгын басып китмәдеме? Вакыйгалар, тормыш шартлары кинәт үзгәреп, сезне бер юлдан икенчесенә алып ыргытмадымы?!»

Баягы сәләмә адәм кар суында шакшы шешәләрне юып маташа һәм сәер, күгәргән тавыш белән моңлы итеп җырлый:

Тагы да шулай, бер күрергә зарыгып,
Үтәр микән безнең гомерләр?..

Берәүнең дә сандыгы буш түгел, күңел түрендә нидер бар, бу бичара йолкышның да бетмәс кайгы-хәсрәте бардыр. Ул да, нәкъ Нәҗип шикелле үк, кайгы-хәсрәтен бер йомгакка урый алмыйча тинтерәп йөридер. Җырның дәвамын тыңларлык хәле юк иде егетнең, ул бетмәс кайгысын бәгыренә урый-урый өенә кайтты, бусага аша көч-хәл атлап керде. Бәхете, Наилә эштә, балалар бакчада иде. Ул кайтканчы а ң а дигән, аңа сыя торган җавапны әзерләп куярга иде. Психиатрга күренергә кирәклеген хатынга әйтергәме, юкмы? Болай да кырын күз белән карый башлаган Наилә Нәҗибеннән бөтенләй йөз чөермәсме? Көнләп түгел, сәгатьләп суына барган арага бу яңалык ни өстәр? Кичкә чаклы башын авырттырып уйланса да, Нәҗип күңеленә хуш җавап табалмады. Көндезге кебек башын аска иеп Искәндәрне бакчадан барып алды. Төпчеккә хатыны кагылырга тиеш иде. Суда ашыгыч пешкән тере ярмалы дөге боткасын ашап, шикәр шакмаган вак-вак тешли-тешли төссез грузин чәен эчкәннән соң, Нәҗип чыгарга җыена башлады. Гаҗәп, Наиләсе бүген: «Кая барасың?»— дип сорамады, капкага тиклем озата чыкмады.

Нәҗип туп-туры Фәридун Фазлыевны эзләп китте. Ул, көндез хушлашканда, «Әгәр бик кирәгем чыкса, кил үземә!»— дип якты чырай белән өй адресын биргән иде. Нәҗип бүген үк барасы итте, хәзер үк! Очраклы рәвештәме, төзәпме — Фәридун Фазлыев аның уйлары төйнәлгән ноктага туп-туры тидергән иде. Нәҗип доктор сорауларының очраклы түгеллеген дә, сораулары эчендә дөрес җавабы да барлыгын инде төшенгән диярлек иде.

Йортны тиз эзләп тапты, Яңа бистәдән ерак та түгел, Павлюхин тирәсендәге биш катлы йортлар арасына кысылган ике катлы, акшары купшакланган, тәрәзә пыялаларын вакыт җиле каралткан йортта яши икән врач. Өйдә булып чыкты, өс-башын җиңелчәгә алыштырган, идәнгә җылы башмакларын куеп, кыршылган диванда кырын ятып, газета укый иде. Нәҗип килеп кергәнгә бер дә аптырамады, торды, хатыны белән таныштырды, үз янына, диванга утырырга чакырды.

«Тагын сезнең янга килдем әле, Фәридун абый». «Мин шулай булыр дип көттем дә». «Ничек алай?» «Без анда сүзгә нокта куеп бетермәдек шикелле». Сүз Нәҗип уйлаганга караганда да җиңел ялганып китте. «Мине сезнең бер сүзегез борчый». «Сүзләр байтак булды, кайсысы борчый икән?» Әзрәк кенә тынып тордылар. Врачның җәмәгате өстәмә чынаяк чәй китереп куйды, нәрсә-кара өстенә ябылган ашъяулыкны ачты. Аннан ике-өч телем ипи, шикәр һәм капламычның төбенә сыланып калган ак май чыкты. Хуҗа белән кунак, шулай ук сүзсез, өстәл янына күчтеләр һәм кыстамыйча да иреннәрен йомырыга тидерделәр. «Ягез, ягез!»— дип сөйләшергә кыстады хуҗа нык ук кызыксынып. «Сөйләргә дип килдем инде! Җан тынычлыгым болай да таралган иде, сезнең бер соравыгыз туп-туры йөрәккә барып тиде». Фәридун Фазлыев дәшмәде, ияген кагып кына куйды. «Бу дөньяда каядыр омтылып, киләчәккә чамадан тыш өметләр баглап яшәгәндә, көтмәгәндә чир килеп кагылгач, корган хыялларыгыз челпәрәмә килмәдеме?»— дидегез сез. Фәридун Фазлыев текә маңгаена сибелгән сирәк чәчләрен артка сыпырып, аңа тагын да яктырак күз белән карады. «Дөньяны аңлау шактый кыен нәрсә, Нәҗип дус». Ул шулай диде, гади генә «Нәҗип» дип исеме белән атады. Соңгы көннәрдә «имгәк, тунеяд, эшсез, әрәмтамак» дигән «чин-дәрәҗә»ләрдән тилмергән җан җылынып китте. «Фәридун абый! — диде ул өзелеп. Врач егетнең тойгыларга бай, хисле булуына тагын бер кат ышанды.— Дөньяны әзме-күпме аңларга була! Чыганаклар күп, дөнья агышын күзәтеп баручылар бихисап дигәндәй... Үз-үзеңне аңлау читенрәк! Бәндә хатасыз, ялгышсыз, язык-ларсыз яшәми, бигрәк тә хәзерге заман шуңа корылган. Әгәр кеше үз-үзен аңларга тырышып карый икән, ул табигый рәвештә үзе кылган гөнаһлар, ялгышлар, хаталар турында да уйларга мәҗбүр була. Шуңа кү-

рә без үз-үзебезне аңларга тырышмыйбыз да».

Нәҗип әңгәмәне алга алып китәргә кыймады, бер-ике сүз әйтеп өлгерүгә, моңарчы үзе хакында үзе корган фикерләренең ишелеп төшәсен сизде. Фәридун Фазлыев җиңел генә иенче якка борылып керде. Әле бу юлның кая илтеп җиткерәсен белмәгән Нәҗип сүз кыстырырга базмады. «Сигез ел төрмәдә утырдым, лагерьларда! — диде гап-гади итеп Фәридун Фазлыев.— Күпчелек акыл шунда тупланганга, мисалларым шул тормыштан була икән, үпкәләмәссез! Анда да яшәү, яшәр өчен тартыш бара... Барып төшкәч тә Казахстанда идем. Безне төзелешкә җибәрделәр. Каравыл офицерлары өчен йортлар салабыз. Коесын казыйбыз, мич чыгарабыз һәм башка шундый күз күргән эшләр. Миңа кайда да эш! Эшләп күнеккән! Кушсалар — наять итеп үтәргә тырышам. Чир китә, гадәт китми, диләр. Рәнҗешләремне онытып, җилкәмә терәлгән мылтыкны санламыйча, ни кушалар — шуны эшлим. Кая җибәрәләр — шунда барам. Күндәм ат кебек. Әгәр янәшәмдә эшкә хирыс адәм туры килсә, бетте, аннан уздырырга тырышам. Суксалар, типкәләсәләр дә — карышмыйм, шулай бер заман шыр сөяккә калдым. Мунчага керсәм —үземне үзем танымыйм. Казахстанда җил анда, җилгә каршы баралмый башладым. Бригадада Карпат ягыннан берәү бар иде, Мукачеводан, Илечко иде фамилиясе, Ростислав Иванович. Күңелчәк кеше иде, телләр белә, укыган. Хәйләгә дә маһир икән. Без, татарлар, хәйләгә оста түгел, туп-турыдан суктырабыз... Карыйм берзаман, көн туса бригадир мактый тегене. «Уңган!»— ди. Ә минем уңганлыгын бер дә күргәнем юк ичмасам! Түзмәдем, «Ник мактыйлар сине!»— дип сорадым. Пырхылдап көлә теге. «Шыр тиле!»— дип мине әрли-әрли шаркылдый. Чак кына ачу кабарды моңа. Ничек инде алай «шыр тиле»? «Җүләр,—ди бу,— син бит зек, токтын, ботында, күкрәгеңдә, маңгаеңда, җилкәңдә — дүрт урында номер. Кеше түгел син — номер! Ә син кешеләрчә эшләргә тырышасың. Син миннән өйрән! Эшкә килгәч тә бригада бер кавым эленке-салынкы йөри, тарта, гәп суга. Ә мин килүгә эш коралы алырга чабам, корал таратучыны тыкырдатам: «Кая минем чүкеч? Кая минем балта?!» Бүтәннәр филонить итә, ә мин кызып-кызып эшкә тотынам! Тузаннар оча! Шуннан бүтәннәр эшкә тотына. Мин, эш кырган сыман, тәмәке пыскытырга утырам. Утырам, йомыш табып читкәрәк каерылам һәм көне буе ялкау симертәм. Көн үтә, кояш баешка бара, съем вакыты җитә, бригада капкага тартыла, конвой чыгып тезелә, ә мин ярсып-кызып эшкә ябышам! Пыр туздырам. Бригадир ашыктыра, зеклар кычкыра: «Давай, топай!» Мин иң актыккы кеше булып инструментларны тапшырам. Бригадир күрмиме шуны? Ул минем хәйләне дә белә, сукыр түгел, ләкин аңа кемнедер мактарга, кемнедер эттән алып эткә салырга да кирәк. Кем бригада күзе алдында эш күрсәтә? Мин! Тора-бара бригадир җай чыккан саен мине мактый, пайканың зурысы миңа эләгә».

Ростислав Иванович сүзеннән мин аптырашта калдым: «Алай ярамый. Бөтенебез шулай хәйләгә сабышсак, норманы кем үтәр?»— димен. «Ни өчен план үтәлергә тиеш соң?— ди бу,— без бит коллар!» «Хәйлә барыбер намуссызлык»,— дип акланырга тырышам мин. «Илдә намуссызлык, гаделсезлек өстенлек иткәндә бер синең намуслы булуыңнан кемгә файда?»— дип авызны каплый бу. «Тормышның үзәк юлы — хәйлә. Хәйлә — үсеш, алга барыш чыганагы, этәргече. Хәйләгә осталар югары дәрәҗә ала, майлы калҗаның дәве аңа эләгә. Командир, власть иясе, юлбашчы була. Әйтик, маршал Жуков, хәйләкәр булмаса, фашистларны тозактан тозакка төшерә алыр идеме?»

Мин бу чагыштырулар белән аслан килешмәсәм дә, әңгәмә азагында күңелем авырайды. Мине «шыр тиле» дип атавы белән дә килештем Илечконың, әмма холкымны үзгәртә алмадым. Кол хәлендә дә тырышып, намусым кушканча эшли бирдем. Ул хаклы иде, мин бер чакта да хәйләгә яраша алмадым».

Нәҗип, бик кызыксынып тыңласа да, Фәридун Фазлыевның сүз сөрешен аңлап бетермәде. Кире дә какмады, килешмәде дә. «Тормышта, кеше яшәешендә тагын бер нәрсә — көнчелек ифрат зур урын били. Көнчелек — күпләрне алга сөйри торган яшерен көч. Зарарлы зәхмәт ул, чир! Ә тигезсезлек хөкем сөргән җәмгыятьтә, мин моны сиңа курыкмыйча әйтәм, көнчелек — идеологиябез, күпчелекнең бердәнбер иманы ул. Кара менә, бездә югары үрләгән кеше генә чын кеше булып санала. Татарда мәгънәле бер сүз бар, «урындагы кеше» диләр бездә. «Урында» икәнсең — син башлык, начальник. Дөньяның бар рәхәте сиңа бирелгән! «Урын яулаган» кеше белән гадиләр арасы үтә ерак! Асылда алар бер чакта да очрашмыйлар. Аерым ашыйлар, аерым ял итәләр, шифаханәләр аерым, күңел ачу урыннары аерым. Тигезлек, гаделлек булмаган җәмгыятьтә көнчелек кеше иманына тулы хуҗа булып ала».

Фәридун Фазлыевның хатыны, әңгәмәгә комачауламас өчен аяк очларына басып кына, тагын берәр чынаяк кайнар чәй чыгарды, кыстатмыйча аны эчеп куйдылар.

Хуҗаның фикере кая юнәлгәнен көндезге очрашуда ук аңлый башлаган Нәҗип: «Сез боларны нигә миңа сөйләдегез, Фәридун абый?» — дип төпченмичә булдыра алмады. Фазлыев, гаепләштән булмасын, дигәндәй, ярым елмаеп, җиңелчә-шук тавыш белән җавап бирде: «Сездә, минемчә, төрмәдәш дустым Ростислав күздә тоткан хәйлә юктыр, ә көнчелек...— Бу урында хуҗа күтәрелеп Нәҗипнең күзләренә карады.— заманча, хәттин ашкандыр дип беләм. Сез «чир вә әҗәл» килеп җитте дип өркеп, уйлаганнарым барып чыкмады дип куркып, бик нык борчылмадыгызмы икән дип уйлыйм. Җавап бирмәгез, кирәкми, чөнки җавап миңа түгел, үзегезгә кирәк. Сез үз халәтегезне аңларга тырышып карагыз!»

Фәридун Фазлыев кабат бу хакта сүз куертмады, бүгенге очрашуга һич исе китмәгәндәй, язгы һава, язын кешеләрнең кәефе кырыкка төрләнүе хакында гамьсез генә бер-ике сүз әйтеп алды. Чираттагы сүзләрен кырт туктатып: «Сез читенсенмәгез. Огородникова янына сугылыгыз әле»,— диде.

Аның лагерьдан котылып чыкканнан бирле болай чишелеп китеп, һич шикләнмичә, ышанып һәм теләп җанын ачып салганы юк иде әле. Ул Нәҗип Нургалиевкә бер күрүдә ышанды. Гомере буе адәмнәргә яхшылык кына кылырга омтылган Фазлыев кемгәдер нык ышанырга, ышанычының ялгыш түгеллеген күреп яшәргә омтыла иде. Җәмәгате: «Чүгез, чәй яңартам, кайнарын китерәм»,— дип, ике-өч тапкыр талпынса да, Нәҗип, озаклап юануын шәйләп, чәйләргә читенсенде, рәхмәт әйтеп ишек бавына тотынды. Фазлыевның егеттән аерыласы килмәде, ул, каударланып, кунакны чак кына озатырга булды.

Чыктылар. Төн карасына чыгып, янәшә басып сүзсез калгач кына Нәҗип Фәридун Фазлыевның тәбәнәк, җилкәсе нык ук бөкерәйгән икәнлеген күрде. Ул аңа өстән, югарыдан карап тора иде.

Көндезге зәһәр исле һава бераз хәл алган, талгын җил исә, җил яз исе, башлары кыркылган мескен тупыллар ягыннан кайры һәм үксезлек исе китерә иде. «Дөрес аңлаган булсам, сездә көнчелек тә, хәйлә дә юк инде, Фәридун абый?» Фәридун Фазлыев яшь тавыш белән көлеп җибәрде: «Көнчелек һәм хәйлә булса, мин шушы татар ягында, сөремгаз арасында, өстән юеш, астан дым тартып яткан хәрабә йортта яшәп ятыр идемме? Минем хезмәт хакымның күпме икәнен әйтсәм, егылып китәрсез!» Нәҗип хуҗаларның сыйга саран чәй табыннарын күз алдына китерде һәм иягән кагып алды. «Чамалыйм». «Ростислав вәгазеннән соң мин аның яраны булып китте дип беләсезме? Һич юк! Әгәр врач икәнлегемне белеп больницага күчермәсәләр, мин шунда, бик күбәүләр кебек, агач бушлат киеп теге дөньяга күчә идем. Хәйләм һәм көнчелегем юклыктан бу дөньяга чак сыеп яшим. Әмма күңелем пакь: пакь күңел җәбер-җәфа тоеп та озак яши!»

Гаҗәп хәл. Фәридун Фазлыев сүз сөйли башлауга гәүдәсе калкып. биегәеп китә, әлерәк кенә баш түбәсе Нәҗипнең култык астына җитә язган кеше үсә, үсә, аның белән бер буйда диярлек булып кала. Ни хикмәт бу?..

«Утыз өч ел җирдә яшәгән кеше үзгәрә аламы соң?»— дип сорады Нәҗип, беренче мәртәбә бүтән кеше алдында үзенең көчсезлеген танып. Фазлыевның яшь тавыш белән көлеп куюына Нәҗип күнегә башлаган иде инде, бу юлы бу яңгыравыклы көлү авазларының үзенә тәэсир көчен тойды. Ул көлгәннән соң Нәҗипкә дә рәхәт булып, җиңелрәк булып кала иде. «Нигә үзгәрмәсен, бишектәге бала йөзгә төрләнсә, кеше, кабер ягасына барып җиткәнче, ел саен, чор саен ниндидер үзгәрешләр кичерә». «Сез дә үзгәрәсезме?»— дип сорады Нәҗип, тотлыгыбрак. «Ник үзгәрмәскә! Менә мин озак елларга кадәр кешенең яшәү формасы — көрәш дип инанып яшәдем. Көрәшергә тиеш адәм баласы һәм вәссәлам! Җирнең матурлыгы өчен дә, кешелек бәхете өчен дә, бигрәк тә киләчәк өчен, кыскасы, һәммә-һәммә нәрсәләр өчен көрәшергә тиеш кеше дип санадым. Шулай дип укыдык, дөнья маңгайга бәрә-бәрә һаман шуны тукыды. «Ленин бабабыз безне гел көрәшләргә чакырган!» Бәхет дигән мөкатдәс сүз телдән төшеп кала язды, аңа бары тик өзлексез көрәш нәтиҗәсендә генә ирешеп була дип ышандык. Һәм бүтәннәрне дә шуңа ышандырырга тырыштык. Ышанмасалар, танклар керттек, илләр арасына таш ныгытмалар бастырдык. Бездә бит шулайрак: сукыр күзләне җитәкли, ялкау уңганны эшкә өйрәтә».

Алар беравык янәшә бардылар. Фазлыевның тагын тәбәнәкләнгәнен сизеп, Нәҗип бераз читкәрәк кагылды. Алар ашыкмыйча, уравыч юллардан әйләнә-тулгана бардылар. Фәридун Фазлыев сөйләргә әзерләнеп тамагын кырды. «Әгәр гел-гел көрәш өчен яши икән, кеше рәхәт күрергә дә, бәхетле булырга да өлгерми. Кеше кирәкмәс җирдә дә көрәш артыннан көрәш уйлап чыгарырга мәҗбүр була. Һәр көрәш — яңадан-яңа корбаннар дигән сүз. Йә җаны әрәм була кешенең, йә тәне. Көрәшләрнең күпчелеге, изге ниятләр белән башкарылса да, көткән нәтиҗәләрне китерми! Юк! Кеше яши икән — бәхет татыр өчен яши. Шуның өчен дөньяга туа. Бәхет! Нигә квартира өчен көрәшергә тиеш кеше?! Бер сынык икмәк өчен нигә тарткалашырга мәҗбүр? Трамвайдагы урын өчен, зираттагы почмак өчен, оят җирен капларлык чүпрәк-чапрак өчен көрәшә-тарткалаша торгач, кеше к е ш е л е г е н җуя, бәхетнең тәмен, кадерен югалта. Кешенең яшәү формасы көрәш түгел, бәхетле булу. Күп илләрдә халыклар моны аңлады инде».

Фәридун Фазлыев лагерьдагы газаплы көннәрен, авыр язмышын бүлешкән иптәшләрен уйлап алды. Төрлечә уйлап, сынап карарга андагы юлдашлары ярдәм итмәдемени аңа?!

«Кайберәүләр көрәшне бәхет дип кабул итсә? Шуңа инанса?»— дип сорады Нәҗип. «Бар, андый фанатиклар очраштыра. Ләкин алар бер чакта да җиргә бәхет китермәгәннәр. Наполеон китергәнме җиргә бәхет? Маркс биргәнме? Адәм баласы кояшлы җиргә бәхет татыр өчен туа!»

Юлдашы уйга калды. Фәридун Фазлыев бәхетле иде, чөнки аның күңелендә асрап, ныгып киткән фикерләре бәрәкәтле туфракка төште. Ул соңгы вакытларда гына күңеленә иңгән тагын бер акыл белән ртаклашырга булды.

«Мин элгәрге елларда, власть теләсә кемне боза, дип ышанып йөри идем. Үземчә, мисалларым да җитәрлек иде! Ялгышканмын? Властька бозык күңелле кешеләр генә омтыла икән! Шәһәребездәге байтак медицина әһелләрен беләм. Күпләр гомер-гомергә ихлас эшләделәр, намус кушканча гадел яшәделәр. Беркем аларга дәрәҗәле урын тәкъдим итмәде, властька чакырмады. Кыек куллы, пычрак күзле, үз мәнфәгатьләре өчен бүтәннәрне бугазлап ыргытырга әзер торучыларны власть үзе эзләп тапты. Әйтик, әлегә аның бозык күңелен берәү дә белми, пе-

сием-песием булып йөри бәндә, ә власть белә, үтәли күрә, һәм элегрәк властьның бер тармагын кулларына беркетеп өлгергән бозыклар үз ишләрен эзләп алалар! Власть чире тумыштан йоккан явызларны үз яннарына җыялар да алар. Ялгышсалар, сайлаганнары алар арасына ялгыш килеп керсә, аларча мөгрәргә өйрәнмәсә, аны шундук кабып йоталар. Власть — аяусыз көч ул, усал, явыз көч. Тоталитар дәүләтләрдә бу аерата ачык чагыла. Власть әһелләре хәйләкәр, алар битлек игән, явызлыкларын яшерергә өйрәнгән, бөтен явызлыкны, усаллыкны, власть башына үрмәли алмаган, ләкин гомер буена шул хакта хыялланган, аларга сукырларча иярген, рухи кол булган гап-гади бәндәләр үти. Власть башында ныгыган тимер куллар, корыч күкрәкләр, таш йөрәкләр балтага бер чакта да үзләре тотынмый, балта гадиләр кулында. Власть әһелләре заман үзгәрүеннән котлары очып куркалар, шуның өчен канлы эз калдырмаска тырышалар. Эзләр бүтәннәрнеке кала. Утыз җиденче ел приговорларында полковниклар имзасы күрәсеңме син? Майорныкынмы? Юк, «атарга, асарга», дигән хөкем карарларына күбесенчә сержантлар кул куйган, гадиләр имза салган. Менә берәүне юк кына гаеп өчен атарга хөкем кылдылар. Властьның әмере бер: юк итәргә! Власть итәгенә якынайтылган коллар гаепсезнең башын чабып өзә, уйлап, исәпләп тормый. Аңа барыбер, кулына балта тоттырганнар икән, ата-анасын һәлак итәчәк, газиз баласын суеп ыргытачак. Чөнки ул т о р м ы ш т а г ы у р ы н ы ө ч е н к ө р ә ш ә. Ул көрәш рухында тәрбияләнгән. «Мы весь мир до основания разрушим, а затем...!» Менә аның шигаре! Палач балтасы ял итми, ул селтәнгәндә власть ияләре кәеф-сафа корып, илнең нәни почмагына сыйган җәннәттә яшәп яталар. Ә балта тотып җан кыючылар, гадиләр, хөкем чыгаручылардан нәрсә белән аерыла? Алар, ахыр чиктә, җәза таягының баш-башлары... Революциядән бирле күпме башлар киселмәгән! Баш кисүче, җан кыючыларны без алтынга яллап чит илдән китертмәгән, алар да шушы кояш астында, шушы җәмгыять шартларында, власть хуҗаларының ихтыяҗыннан туып ишәйгәннәр. Ә шул җәлладларны көнгә күрсәткәннәре бармы? Юк. Андыйлар хатын, балалары катына кайтып: «Бүген өч йөз илле адәмнең башын кых иттек әле!» — мактана алмыйлар инде. Власть ияләре эшче-крестьяннан качып яшәгән кебек, балта тоткан палачлар да, сукыр тычкан кебек, кеше күзеннән, халыктан читтә гомер үткәрәләр. «Кешенең яшәү рәвеше — көрәш!» — дип әнә шундыйлар кычкыра. Һәм ышандыралар да! Адәм балаларын бәхеттән мәхрүм итәләр, аларны хәерчелектә, изелүдә яшәтеп, «Безнең ил иң бәхетле ил!» — дип җырлаталар.

Болай таба килүче өч ир күренде, өч ир очраганда Казан урамнарында сагаерга кирәклеген үзләштергән Нәҗип, юлдашын ым белән урамның икенче ягына кушып, җиңеннән тартты. Нәҗип адымын тыйса да, Фәридун Фазлыев тукталмады, шикле өчлек алар каршысына чыкты, өчәүләшеп челәя-челәя карап нәкъ каршыларына килеп туктадылар. Көтмәгәндә авызлары ерылды, картузлары очып башларыннан купты. Фәридун Фазлыев белән Нәҗипкә юл саптылар, дәшмәделәр. Бераз киткәч Нәҗип борылып карады: «Сәрхүшләр!» — дип сузды. «Тимиләр алар миңа,— дип көлемсерәде Фәридун Фазлыев.— Өчәү очрасалар, берәрсенең минем катка килгәне була. Белмәүчеләр туры килеп җәберләмәсеннәр, дип кайчагында мине озатып та куялар. Беләм, иә караклар алар, йә үтерүчеләр. Власть башында утырып, изге саналып йөргәннәрдән алар кай яклары белән ким?!»

Алар тимер юл янына килеп җиттеләр, уфылдап, сызгыртып тәбәнәк маневр паровозы үтеп китте. «Менә, Фәридун абый, мин кайтып җиттем». «Тимер юлга бик якын торасың икән!» — диде Фәридун тегe яктагы караңгы өйне караштырып. «Бәла булды инде җәфа! Төн ката поездлар үткәнне тыңлап, карганып, каһәрләп ятам». Фәридун Фазлыев тагын көлеп алды. «Ә син, Нәҗип дус, поездлар үтә дип уйлама...

Бу вагоннарда никадәр халык, күпме кеше бәхет эзләп, яки бәхетсезлегеннән качып каядыр бара дип бел... Адәм баласы тиккә генә сәфәр чыкмый. Нужа йөртә аны! Кайгы-хәсрәт йөртә! Поездлар дөбердәп үткәндә син шул хакта да уйла, җаның җиңелрәк булыр!»

Саубуллаштылар. Нәҗип кайтып кергәндә Наилә йокламаган иде әле. Өстәл лампасын, яктысы балаларга төшмәсен өчен, одеал белән төргән, кулларын баш астында кушырып, түшәмгә карап ята. Нәҗип кергәч тә борылып карамады, димәк, уйлары бүтән якта, еракта йөзә булса кирәк. Нәҗип сүзсез чишенде, хатыны тәне һәм сагышы белән җылыткан урынга сузылды. Дөбердәп, йортны нигезеннән кубарып ыргытырга теләгәндәй селкетеп, озак шаулап ишле вагонлы поезд узды. «Ничаклы кешеләр нужа куып сәфәр чыккан!»— дип уйлады күңеле йомшап Нәҗип. Дөнья бер мизгелгә тынды. Таңсылу ягыннан шешә һәм тустаган чыңлаганы ишетелде. «Йокламый,— диде Наилә пышылдап.— Япа-ялгызы салып утыра. Бер шешәне бетерә бугай инде. Гаҗәп, дөньяда булмаган хәл: мине дә чакырган иде, кермәдем». Ике якта ике хатын. Ир югында хатын-кыз уй белән кочаклашып ята. Ни уйлыйлар икән алар?! Таңсылуның нужасын чамаласа да, Нәҗип үз хатынының уйлары кай тарафларда йөргәнен белми иде. Гөлнараны чит илгә, Финляндия белән Швециягә озатып кайткан иде Наилә...

Нәҗип ике кулы белән аны кочып алды, үзенә таба тартты. Башта карышса да, Наилә иплән кенә аның кочагына сеңде, сизде, бүген иренең кулларына бераз көч кергән, күкрәге нығый төшкән иде.



## 11

Ул доктор Огородникованың исемен оныткан иде, кабул итү тәрәзәчегенә арты белән утырган шәфкать туташыннан сорады. Туташ өч эндәшкәннән соң гына акаеп аңа карады, тулышкан, мәмрәп пешкән ал иреннәреннән: «Йөриләр шунда бимазалап... психлар!»— дигәнрәк сүзләр чыкты. Нәҗипнең китми торуыннан алҗып: «Фаина Марковна!» дип акырды.

Кичә Фәридун Фазлыев сабакларыннан соң чиренә дә, үзенә дә бүтәнчәрәк караган кебек тоелды, йокысыннан ул күтәренке күңел белән торды, Искәндәрне бакчага илткәндә, күптән булмаганча, шаяртты, көлдерде. Кире кайтып килгәндә Гафури урамындагы бер йортның капка баганасына терәлгән табут капкачын күргәч, сискәнеп китте. Тагын йөрәге какты һәм Фәридун Фазлыев тәкъдим иткән врач янына ашыкты. Фаина Марковна икән аның исеме. Бүтән ишек төпләрендә садака көтеп утырган хәерчеләрдәй, байтак халык бөялеп тора, алдан килгәннәр урын әләктереп калган, соңарганнар киемнәрен акшарга буяп, диварларга сөялеп җаннарына дәва, тәннәренә шифа көтәләр иде. «Психиатр» дигән язулы пыяла эленгән ишек каты әлегә буш иде.

Нәҗип килеп басуга, эчке яктан берәүнең, ишекне тишәрдәй булып, илереп-тилереп акырганы, аяк тибеп кычкырганы яңгырады. Әллә шул тавыштан куркып таралганмы чират? Ирнең тавышын басарга тырышкан хатын-кыз сүзләре ишетелгәли, ләкин берсенең дә әйткәннәрен аңларлык түгел иде. Ишек аша чыккан тавышны куркып тыңлап торганнан соң, Нәҗип кыюланып ишекне какты. Гауга бер мәлгә тынды, ишек йомшак кына ачылды, һәм эчке яктан дәү гәүдәле, йомры иңбашлы, калын җирән чәчләрен юан толым итеп баш түбәсенә урап куйган, Нәҗиптән дә озынрак гәүдәле, сипкелле ханым күренде. Ак кардай халатыннан төшкән нур аның бит очындагы эре-эре сипкел бөртекләрен алтынга манып, матурлап күрсәтә иде. Бүлмәдә гауга, тавыш дәвам итсә дә, ханым тыныч һәм сабыр күренде. Нәҗипне кул ишарәсе белән үз янына өндәп, янындагы авыруга сүз тәмам икәнен аңлатты. Нәҗип каршысына зәңгәр күзләре тирән чокырларга кереп поскан, арык яңак-

лы, озын, ябык муенлы бер бәндә килеп басты. Аның сөяккә калган озын, шыр бармаклары дер-дер калтырый иде. Ул әллә сугарга ниятләде, әллә төртеп егарга, бәбәкләрен шарландырып текәлеп торды да ишеккә ташланды, ачкан ишеген япмыйча чыгып югалды. Огородникова, һич исе китмәгәндәй, ишекне япты, кулын марля кисәгенә сөртеп, урынына утырды. «Мин сезне тыңлыйм»,— диде ул Нәҗипкә урын күрсәтеп. Аның карашының үткенлеген, гадәти түгеллеген Нәҗип кергәч үк чамалаган иде, хәзер, күзгә-күз очрашкач, сискәнеп, югалып калды. Йә, ни сөйли ала инде ул бу ят һәүдәгә?! «Фамилиям минем Нургалиев,— диде ул битараф кына,— исемем Нәҗип». «Ә-ә, бу сезмени?— диде Фаина Марковна яктырып,— Фәридун Фазлыевич өйгә шалтыраткан иде». Нәҗипнең күңеле тынычланып, арадагы киеренкелек кимеде. Ул, бер җебен дә калдырмыйча, Фәридун Фазлыевка сөйләгәннәрнең бөтенесен сөйләп бирде. Сүзендә зур бер яңалык булып, Фаина Марковнаның күзеннән ул яңалык та читтә калмады. «Характеремда бозыклык бар, ахрысы, минем, кыен ашаган саен югарыга омтылдым, югарыдан торып түбәннәрдән, аягыма тагылган нужадан үч алырга да җыена идем... Өметем шул иде минем, заводка кайтам да лабораториядә мөдир булам, аннан югарырак та үрмәлим. Бүтәнчә киләчәгемне күз алдына да китерә алмый идем! Зур иде минем теләкләр, авыз киң ачылган иде! Хәзер менә сулаган һавамнан кабер исе килә, уйлаган һәр уемда ләхет салкынлыгы, тормышымның һич яме калмады. Әҗәлдән куркам, менә-менә үләрмен төсле!»

Нәҗипнең сөйләгәннәрен үзенә сеңдерә барган Фаина Марковнаның йөзе, утырышы, кыяфәте үзгәрә барды, ул кинәт кенә олыгаеп, тагын да җитдиләнеп калды. Ул, бүтән табиблар кебек, анализлар белән кызыксынмады. Фаина Марковна тәнне түгел, җанны дәваларга күнеккән, гомумән, ул медицинаның төп бурычы — җанга төрле яктан бик җентекле якынаю дип саный иде. Нәҗипнең үз авызыннан чыккан фикерләр аның өчен бик җиткән иде. Нәҗип сүзен бетергәч, ул тәрәзәгә төшә башлаган март кояшының кыйгач нурларына карап утырды да: «Минем янга килеп ялгышмагансыз, сез чыннан да безнең авыру! — диде.— Мин сезнең белән ачыктан-ачык аңлашырга телим. Фәридун Фазлыевич шулай үтенде... Сез кергәндә бүлмәмдә бер кеше бар иде. Сез аны күрдегез. Тотышына, кыланышларына игътибар иткәнсездер. Минем аңа шактый битараф, салкын карашымны да тойгансыздыр. Мин монысын сезгә танырга тиеш түгел идем, мәгәр сез аның кем икәнен белмисез һәм белергә тырышып йөрерсез дип тә уйламыйм. Ләкин аны күрүегез ярап куяр! Бу сезгә тере мисал, кисәтү үрнәге. Ул әнә шул — үлемнән курку чире белән моннан алты ел элек минем яныма килгән иде. Нинди генә дарулар тәкъдим итеп карамадык без аңа, гипноз сеанслары үткәрдек, уколлар алды, санаторийга да җибәрдек, файдасы табылмады. Нигә дисәгез, ул үзе савыгырга теләмәде. Сез сәламәт. Теге төнне, Мәскәүдә, арганлык сезне бәреп еккан. Сез көчегезне тигез бүлә белмәгәнсез, ашыгып-ашыгып алга ыргылгансыз! Максатыгыз зур һәм кызыктыргыч булган! Җигүле ат камытыннан ычкынып чыгып китсә, арбасы артта кала. Ул да җай белән барырга тиеш! Сез сәламәт. Фәридун Фазлыевич та шулай дияргә кушты. Йөрәкнең кинәт дулап куюы була. Ул хуҗасын искәртә, чаманы чамага туры китереп тыелырга куша. Гел ашыгып, кабаланып, чәбәләнеп яшәү йөрәккә сигнал биргән. Сезнең төп чирегез — курку. Йөрәк дарулары белән мавыкмагыз. Дару бер яктан дәваласа, икенче яктан бәгырьне кимерә дә! Харап итә. Сезгә куркуны җиңәргә кирәк. Тора-бара «йөрәгем авырта» дигәнне онытырсыз». «Ничек җиңәргә?!»— диде Нәҗип аска караган килеш. «Үзегез белән үзегезгә көрәшкә чыгарга туры килер! Сезнең бик яраткан бер-бер шөгылегез бармы?» «Нинди шөгыль?» «Бөтен дөньяны онытып мавыгырлык дәвамлы шөгыль. Балыкка йөрисезме?» «Юк». «Ә гөмбәгә? Маркалар да җыймыйсыз инде, шырпы каплары

да... Чаңгы да шумыйсыз? Шахмат, биллиардны да өнәмисез? Әһә, чаңгыга баскалыйсыз икән, өзә-төтә, шулаймы? Сезгә утыз өч. Гомерегезне ни белән үткәрәсез соң сез, иптәш Нургалиев?» Фаина Марковна әрнү катыш шелтә белән Нәҗипнең чарасыз моңаеп калган күзләренә текәлде. «Эшләдем, укыдым, ике ел армиядә бушка селкенеп йөрдем. Өйләндем, бала бактым...» «Болары һәр кеше өчен табигый күренешләр. Болардан тыш берәүне бүтәннән аерып куя алырлык сыйфатлар да булырга тиеш ләбаса! Адәм баласы кирпеч калыбыннан төшкән стандарт түгел! Менә сез импульсивный, хисле, тәэсоратларга сизгер җан. Сезгә кешелекнең гади, гадәти кагыйдәләре генә җитми, сезгә нык мавыгырга кирәк! Нык! Шул чакта сез иңбашыгызга кунган кара фәрештәне онытып тора алырсыз. Әнә, сез күреп калган бичара бәндә мавыгу таба алмады, теләмәде, үз тәгәрмәче астында үзе тапталды. Чирдән котылу, кабатлап кисәтәм, үз кулыгызда». «Балыкка йөрепме?» — диде ышанмыйчарак Нәҗип. «Анысы менә сезнең эш. Үз тарафымнан мин сезгә тынычландыру дарулары бирермен, хәзер «андаксин», «триоксазин» дигән көчле дарулар бар. Дөрес, аларны юнәтү кыен, кирәк булгач, табарсыз. Сез хәзер һәр нәрсәгә ышанып, җиң сызганып, күкрәкне давылларга ачып көрәшергә тиеш. «Җиңәм! Җиңеп чыгам!» — дип иртәдән-кичкә кадәр кабатлагыз. Кирәк булса, гипноз сеанслары алырсыз. Веналарга магнезия уколлары кадарбыз. Сез авыл баласы бит? Мондагы атмосферадан котылып торыгыз, кайтыгыз авылга, юанычларны шунда табыгыз. Тауга менегез. Менгән саен, һәр киртләчтә туктап хәл алыгыз, аска карагыз. Күз алдыгыз киңәйсен, офыклар ерагайсын. Азаккы сүзем шул: үзегезнең рухи көчегезгә ышаныгыз! Сез сау-сәламәт. Сезгә табиб кирәкми, дәвалаучы — хәзер сез үзегез!»

Рецептка үрелгәндә аның кулы Фаина Марковнаның кулына тиеп китте, докторның кулы пешерерлек кайнар һәм коп-коры иде.

Кабинеттан чыкканда ишек тирәсенә байтак кеше җыйналып өлгергән иде, алар Нәҗипне каш җимереп, йодрык йомарлап, дошман итеп каршыладылар, сүгеп озаттылар. Сәгатенә карагач, ул аптырап китте: врач бүлмәсендә ул төп-төгәл сәгать тә биш минут утырган икән!

Кайтса, бөтен өй пыр тузган, әйбер-каралар, мендәр-ястыклар әвәләнеп ишек катына куучкән, балаларның уенчыгы тартмасы белән ишегалдына чыгып ауган, түбәдән тамган тамчы аларны җебеткән. «Ни хәл бу?» — дип, тартма тирәсендә авыр койрыгын сөйрәп Звонок йөри. «Ни булды? Ни бар? Әллә ут-мазар чыктымы?» — дип кычкырды ул карлыккан тавыш белән. Наилә елый-елый шешенгән, сүзен рәтләп әйтә алмый, ул да булмады — аралыктан Таңсылу килеп чыкты. Изүе чишелгән, бәлшерәйгән имиләре ямьсез тирбәлә, күзеннән ут, колагыннан төтен, нык кысканнан тешләре уалып авызыннан зәһәр ташый: «Бер көн тормыйсыз, хәерчеләр, бер көн!»

Нәҗипнең кайтканын тәрәзәдән шәйләп калган карт Таңсылуның утына керосин сибәргә кереп җитте.

Нәҗипнең боек күңеле тагын да шәлперәйде. Ул, Таңсылу авызыннан чәчелгән зәһәр хатынын ялмап йотмасын өчен, ике арага кереп басты, Тимерханга юаш кына эндәште: «Озак тормабыз, Тимерхан абзый. Сөйләшенгәнчә кышлыкка утынны без алган. Беләсез, фатир чиратында торабыз. Чирләп егылмасам, әллә кайчан бирәләр иде. Кумагыз инде!»

Саклап кара моннан болай җан тынычлыгын! Аралыктан моңарчы күренми торган Җәмилә карчык лыпырдап килеп чыкты: «Һай, шөкәтсез ялганчы! Биргәннәр ди сумашишныйга фатир! Вәйт, алдакчылар!» Нәҗип белән Наилә, йөз суларын түгеп, ике сүзләренең берендә «ходай, тәңре» исемнәрен әйтеп: «Әзгә генә түзегез, күчәр урын табыйк сана!» — дип ялваргач кына давыл тынгандай булды, зәһәр җил басылды, хуҗалар өчесе тиң күз алдыннан юк булдылар.

Наилә эшкә китәргә җыенып йөргәндә Таңсылу кайтып кереп, аны

чыгармаган, әйбер-караларны тотып тондырган, мендәр тышларын ерткан, дөге ярмасын ишегалдына чәчкән.

«Ни булган бу шашкан хатынга? Ник котырына алай?» — дип сорады Нәҗип, хатынының җавабыннан яхшылык көтмичә. Наилә кыенсынып кына ачыклады: «Әйтмәм дигән идем, түзәрем калмады. Син югында шыпан-шыпан гына Таңсылу янына ир-ат кергәли иде. Безнең бүлмә аша үтеп йөрделәр. Хәзер синнән читенсенә. Юлына киртә булдың». Шулайрак дип шикләнеп йөргән иде Нәҗип, рас икән. Мондый шашынган чакта хатын-кызны игә китерермен димә, күзенә ак-кара күренми аның, итәк кыска, табан астына җәһәннәм уты кабынган...

Йа хода! Юка такта белән бүленгән теге якта Таңсылу ниләр кыланып ятмаган. Ә бу якта... кысрыкта, аның газиз хатыны, балаларының әнкәсе... Исәеп килгән ике улы! Ниләр күрсәтми бу фатирсызлык!

Нәҗип, хатынының башын тезенә куеп, аны иркәләргә, юатырга тырышты, электән әйтә килгән, еш кабатланган җылы, кадерле сүзләрен тәкрарлады. Хатын тынычланмады, чөнки ул иренең үзе әйткән сүзләргә үзе дә ышанмавын, киләчәкне ал буяуларга юри-марый гына маташтырганын аңлый иде. Иң аянычлысы, иң авыры шул иде: Наилә алдагы көненең кызыксыз, өметсез икәнен уйлаганда, үткән гомеренең дә шыксыз, ямьсез булуын абайлады. Бәла килсә — озакка килә, сумалага баскан саескан хәлендә каласың: башыңны алсаң, койрыгың ябыша, койрыгыңны куптарсаң — башың ябыша. Кичкә кадәр елады Наилә, ник елаганын иренә белдермәде, үз язмышын каһәрләп, Нәҗипне очраткан минутларын каргап елаганын ничек аңа белдерсен ул!

«Әллә әтиләрдән акча сорап торабызмы?» — диде ул, әйберләрен җыештырып, бүлмәне әз-мәз тәртипкә китереп, төс керткәч. Нәҗип авып китә язды: «Әтиләрдәнме? Үлсәм үләм, алардан әҗәткә аласым юк. Туганнарга да бармыйм! Беркайчан да!» «Ә ничек яшәрбез соң?» — дип инәлде Наилә. Нәҗип хатынына җавап тапмады, чөнки алда ничегрәк яшәсен ул үзе дә белми иде.

## 12

Ире чирле хатынның хәле мөшкел, мәшәкатьләре ике мәртәбә арта, көн туды исә, сунарчы эт кебек, арлы-бирле чаба ул. «Андаксин кирәкме?» «Триоксазин?» «Әллә кайчан дефицит ич алар!» Аптека туташлары күзгә карап алдыйлар, буш кул килгән клиентлардан алар астыртын гына көләләр. «Дару кирәк икән бераүләргә, ә табалары коры! Майланмаган!» Белә Наилә хәзер, нәзек билле, бүртмәч иренле, йомры күкрәкле аптека кызлары шоколадны, кыйммәтле исләмайларны яраталар, кул кулны юганда, затлы бүләкләрне арага кыстырсаң. Кытай женьшенен дә табачаклар, әмма даруга дигән акчаны көч-хәл белән җыештырган Наиләнең кәнфит-мәнфитләр алырлык җае юк. Йөри байгыш булып, гомерен кыскартып, ялынып, ямьсезләнеп йөрмәс иде, Нәҗибенә кирәк. Дару йотмыйча йокларга ятса, мендәрен изеп, эчен чыгарып бетерә.

Бүген ул дарусыз яткан иде, кичтән бирле борсалана. Наилә башын калкыта-калкыта аны күзәтә: ходаем, тагын врач чакырырга туры килер микәнни?!

Нәҗип Йосыф улы Нургалиев төш күрә.

Әлерәк кенә аның өстенә ургып-ургып кара ташкын ага иде, аннан котылдым дигәндә, тауга кырын яткан урман ишелә башлады. Дәү-дәү иләмсез имәннәр ботак-канатларын фыр-фыр итеп аның өстенә авалар. Имән каүсәсе астында калып каен, усаклар чыра кебек сына.

Бер имәннең иң оч ботаклары аның баш тирәсенә сузылып ава, яңакларын, шәрә кулбашларын чатлы ботаклар сыдырып үтә. Яралардан каны челтерәп ага. Ул ашыгып канны кулъяулыгы белән сөртә.

Кулъяулыгын күзенә китереп караса, шакката: каны кызыл түгел, сөт сыман ап-ак икән аның! «Нигә агарды бу кан?»— дип куркынып сорый да, үзе үк җавабын да таба: — Эчкән дарулар каныңны агартып бетерде синең, шул дарулар сине үтерәчәк тә!»

Имән ботаклары тозагын аралап чыгам дигәндә генә, баягы ташкын аны ялмап алды да вак йомычка урынына бутап йөртә башлады. И ярсыды Нәҗип, и гайрәтләнде. Һәм күрсәнә: аяк очлары җиргә тиде. Үсәргә тотынды Нәҗип, үсә, үсә, ботаклар җибәрә, гәүдәсе ныгыганнан-ныгый. Башы болытларга тиде берзаман. «Имән мин, имән!»— дип кычкырмак була, тавышы чыкмый. Түшен ышкып карый, иреннәрен каерып ача, өне юк бичараның. Янына Наиләсе килеп баскан, имеш. Ялварып аңа дәшә: «Тавышым булмагач, минем имән икәнемне кем белер соң?»

Каяндыр, тау түбәсеннән ыргылып төшкән җил Нәҗип-имәнне аударды. Нәҗип кечерәйде, кечерәйде дә йомычкага әверелде. Юныш балтасы белән чабып алынган өр-яңа йомычка! Тырпылдый торгач, ул тагын кеше шәкеленә керде, колач салып ташкынга каршы йөзә башлады. Баягы сыман аягы катыга тиде, атлыйм, котылам дигәндә гәүдәсе, кул-аяклары балыкчы җылымына уралды. Әй йолкына уңга-сулга, ычкына гына алмый! Ә су, дөньяга хуҗа булып өлгергән туфан, ургыйургый котырына. «Син түгел, мин ул имән!»— дигән тавыш колагына керә Нәҗипнең... Кем ул имән? Әллә туфан имәнгә әйләнгәнме? Көнчелектән шул батырамы Нәҗипне, җылым булып уралып аны төпкә, үлемгә тартамы? «Туфан синдәй имәнне дә екса, бүтәннәрне әһ дигәнче таптап узачак!»— дип Наилә елый. Ниһаять, Нәҗип юан агач кәүсәсен кочаклап калкына, кулына эләккән үткер пычак белән җылым җепләрен турый, кисә. «Яра! — дип кычкыра Наиләсе.— Нәҗип, яраң бар!» «Үзем дә күрәм!— ди, куанып Нәҗип.— Каным кызыл икән, яшим әле мин, яшим. Мин яшәргә тиеш! Дөньяны туфан басып китә алмасын!»

Шулай дип бер кычкырды да уянып китте.

Шадра түшәм аны сытарга теләгәндәй тагын да аскарак иңгән, су төбе сыман тонык яктылык белән тулган бүлмә суынган, бетеп барган ай урагының нурлары карындык-күгелҗем пыялалар аша чак үтеп кыеш-мыеш идән такталарына ятып торалмыйча тирбәләләр. Иренең уянганын сизсә дә, Наилә йоклаган булып ята, дымлы төннәрдә ютәл бумасы белән интеккән Җәмилә карчык, комганын тотып, корык-корык ютәлләп, тәрәзәгә тия язып үтеп китә. Таңсылу ягында шешә белән тустаган чәкәшеп чылтырый. Нәни Рөстәм төшендә яшел койрыклы колын күреп шаркылдый. Бүрәнәләрнең черек-кара мүген коеп, өйгә тияр-тимәс үткән вагоннар маңгайга-маңгай бәрелешәләр...

Аны шәһәрнең атаклы гипноз остасы Даирский дәвалап карады, врач тырышса да, Нәҗип аңа баш бирмәде, тынычланмады, сеансларны Фаина Марковна киңәше белән туктаттылар. Уколларга йөреп карады, файдасын күрмәде, гел үлем, әҗәл турында уйлады, көннән-көн ябыкты, сарыга сабышты. Квартир хуҗалары белән ара соң чиккә, кайнау ноктасына җитте. «Ашыгызга сәләймә салам! Таегыз моннан!»— диде беркөн Таңсылу. Нәҗип шәһәрнең искерәк йортлар тирәсеннән, фәкыйрь-фокра арасыннан тукталыр куыш эзләп чыгып китте. Йөргән аякка йөрем иярә, сораша-белешә торгач, ул шәһәр үзәгендәге Миславский урамына юлыкты. Фатирчылар кертергә җыенган, биш яшьлек тиктормас оныгын очлы тез башларына кыстырган сукыр-бакыр рус карчыгы Ираида Никифоровна Нәҗиптән кем булуы, кайда эшләве, гаиләсе хакында кайта-кайта, вәзенләп-бөртекләп сорады да сансызланырга тотынган малайның артына чап иттереп берне орды, яшь аралаш үз тормышын сүтәргә керешге. Улы белән килене, әнә, каршыдагы бүлмәдә яшәп ятканнар икән. Улы беркайда да эшләмәгән, көндезге уникегә кадәр йоклаган, кич чыгып югалган, ярты төн авышканда гына кайтып кергән. Хатынын да бер җирдә эшләтмәгән. Нәрсә ашап, каян акча

юнәтеп яшәгәннәрдер. Еллар үткән, бала туган. «Көзгә алты тула ташбашка!» (Карчык малайның артына тагын берне чәпеде.) Башта этисен, ярты айдан әнкәсен дә кулга алганнар да алтышар елга төрмәгә илтеп тыкканнар. Менә кайчаннан бирле шул тыңлаусыз бала белән җәфа чигә. «Алтысы тулмаган, тәмәке суыра башлады!» Пенсиясе әз, уллары бүлмәсенә торымнан-торымга иптәшләре кереп кунгалый иде, акмаса да тама иде, хәзер иптәшләре калмады, һәммәсен төрмәгә тутырып бетерделәр.

«Аерым ишек, аерым бүлмә» дигәннәрен каерып ачып эчкә кергәч, Нәҗип өнсез калды: гомергә кояш нуры төшмәгән, бер тәрәзәле, рамнарын, пыялаларын үрмәкүч пәрәвезләре томалаган ярымподвалның түшәм акшары дымланып, кабырчыкланып купкан, диварлары — дөнья картасы сыман, кыйтгалар бер-берсенә тартылып йөзәләр, идән такталары почмакта череп, бала аягы сыярлык тишекләр ясалган. Ишек ачылуга эре-эре ике күсе шул тишекләргә кереп чумдылар, мыекларын селкетеп, бөртек күзләре белән кешегә карап калдылар, курыкмадылар. Нишләргә?

Нишләргә? Ни кылырга?!

Совет эшсезе, дипломлы, өметле яшь физик Нәҗип Йосыф улы Нургалиев шанлы-шәүкәтле Казан каласындагы шушы фатирны күреп, бер мәлгә мие түнеп калды. Нишләргә соң? Ни кылырга?! Өйдә ике бала, хатын, хуҗалар каргап, янап куа. Атна-ун көн Нәҗипнең йөреп туктаганы юк, аяк табаннары ашалып бетте...

Ираида Никифоровна ярты еллык акчаны алдан сорады. «Шушы ачарбак белән бурычка баттым, прәннек ашый да кәнфит суыра, ничә айга квартир хакы түләмәгән, керәсез икән — ярты еллыкны алдан биреп керәсез». Озак тарткалашкач, елашкач, кочаклашкач, ярты еллыкны өч айга калдырды Нәҗип. Бәлтерәп беткән калтыравык Ираида Никифоровна акча дигәндә тернәкләнеп китте һәм аяк терәп карулашты. «Бүген үк!» — диде ул. Нәҗип Нургалиевнең балтасы суга төшкәнен, көймәсе комга терәлгәнен сизеп: «Өч айлыкны бүген үк китерәсең!»

Март ае гына булса да, кысан тартма — ишегалды җебеп аккан, борыныңны кая борсаң да, авыр ис килеп бәрелә, каршы йортның подвалында, төрле киек-җанварлар тавышына охшатып, кемнәрдер «камыш шаулаталар». Истән качып, танавын тотып ашыгып барган Нәҗипне кар йомарламы куып җитте, ул ярсуыннан буылып борылып караса, орчык кадәр ике юеш танау авызларын ерып торалар. Ишегалды уртасын кыеш-мыеш утын сарайлары, бәдрәфләр бизәгән иде. Бара торгач сизде: йомарлам кар гына булмаган икән, исе чыга башлады, ул бишмәтен салып, пычәтләнгән урынны чистарак кар табып кат-кат ышкыды. Ис бетмәде. Ул, трамвайга утырырга кыенсынып, Яңа бистәгә җәяү элдерде. Кайткач карасалар, пычрак сасы лай эреп итәккә кадәр төшкән. Наиләнең коты очты: «Балаларны ишегалдына ничек чыгарырбыз?!» «Өйдәрәк торырлар, граф балалары түгел, — диде ярсыган Нәҗип. — Күчмичә кая барасың?!»

Нәҗибенең ачуы соңгы чиккә җиткәнен күрсә дә, Наилә бер сүз әйтеп карарга булды: «Нәҗип, акыллым, мондый чакта ата-анадан ярдәм сорауның һич ояты юк. Сорап торыйк әтиләрдән! Хәлләнгәч, тиенен дә калдырмабыз, түләрбез!» Нәҗипне берьюлы ун бал корты, алты шөпшә, өч-дүрт бусан[1] чактымыни, яңак сөякләре калкып шыгырдады, борын тишекләре киерелде, күзләреннән яшькелт очкын түгелде. Ул, җүләр кеше сыман, өзек-өзек җөмләләрне ватып озак кычкырынды: «Ачка үлә.рмен, хәер сорашырмын, әтиләрдән акча сорау түгел, алар ягына борылып та карамам! Безнең хәлне туганнар

[1] Бусан — эре шөпшә.

да, якыннар да белергә тиеш түгел. Барыбер үзем ерып чыгам, бер башым!»

Нәҗип ничек ерып чыгасын хатынына аңлатып тормады, Наиләсе сорамады, киенде дә шыпырт кына чыгып югалды. Алтын балдагын, ерак әбисеннән үк калып, әнкәсе аша аңа насыйп булган борынгы болгар беләзеген ювелирторгка тапшырып, акчаларын учына йомарлап кайтып керде һәм иренә тоттырды. Турсайган, бүселгән ир дә, кулына акча кергәч, әз-мәз җанлана. Нәҗип Наиләнең муенынннан үпте. «Бар, түләп кайт, — диде хатын. — Мин мондагыларга кертеп бирәм». «Җитәме соң?» «Җитүен җитә дә, шунда бетә дә!» — диде Наилә, елмаерга тырышып.

Нәҗип, дәшми-тынмый гына, ирлек горурлыгын учына йомарлап, хатынына туры карарга кыймыйча, чыгып китте дә кичкырын гына кайтып керде. Наилә Тимерханнарның күңелен күргәндер, ул як тынган иде. Таңсылу кунарга кайтмады, поездларның берсе аерата дөбердәп узганда теге якта өстәл селкенеп, идәнгә шешә төшеп тәгәрәгәне ишетелеп калды.

Иртәгә күченәбез дигәндә, Нәҗип Наиләсен иртәләп яңа куышларын карарга китте. Әз-мәз җыештырып, тишек-тошыкларга таш-мазар тутырып, идәнне юып чыгарырга иде исәпләре. Чалт аяз көн, һава җиңел, җайлы сүзләр сөйләшкәләп барып җиткәннәрен дә сизмәделәр. Ишегалды кары эреп беткән диярлек, исләр кимегән иде. Барып керсәләр, ни күрсеннәр, юылмаган шакшы идәнгә кәгазь кыйпылчыклары җәеп, дүрт таза-таза ир шау-гөр килеп карт сугып утыралар. Яннарында ике шешә кызыл, бөршәйгән кыяр кисәкләре, бушаган аракы шешәләре, кабыгы сытылган күкәйләр, кабыклы бәрәңгеләр тәгәрәп яталар. Авызларында тәмәке. Тонык кына булып ятим лампочка яна. Бүлмә идәннән түшәмгә кадәр аракы сасысы, зәһәр төтен һәм агулы сүзләр белән тулган. Ишек тавышына дүртесе дә борылып карадылар.

— Сез кемнәр? — дип сорады Нәҗип, эчкә кереп.

— Ә сиңа кем кирәк?

— Без иртәгә бу бүлмәгә күчәргә тиеш идек.

Җыелганнар ярым көлемсерәп бер-берсенә караштылар, түрдә утырган, шәрә тәне зәңгәр сурәтләр белән бизәлгән, киң күкрәкле, кыска куллы бәндә черт итеп төпчеген почмакка очыртты. Керүчеләрнең нинди эш юллап йөрүләрен аңлагач, алар тыелгысыз көләргә тотындылар. Шәрә тән торып басты һәм бер генә җикеренде:

— А ну, канай отсюда! — диде ул явыз итеп. — Ну! Рви когти, тебе говорят! Фраер несчастный![1]

Нәҗип белән Наилә күздән юк булдылар. Идән юарга алган чиләкне кире кереп алырга да базмадылар. Әзрәк сулышлары басылгач, биргән акчаларын кире кереп алырга дип, Ираида Никифоровна янына керделәр. Керсәләр, ул теге ут борчасы белән ызгышып ята иде. «Ходам, җанымны әллә кайчан алыр иде, шушы сабый хакына гына яшәтә», — диде ул, керүчеләрне каршылап. Теге малай, почмактан күзләрен уйнатып, бер тоташтан такмаклады: «Мин сине тыңламыйм! Мин синнән курыкмыйм! Син мине кыйный алмыйсың.» «Кыйнамам менә!» — диде карчык, нарат күкәе хәтле йодрыгын укмаштырып. «Әти кайтты, әти! — дип үчекләште малай. — Хәзер мин синнән акча сорамыйм, шешә тапшырам да морожный алам. Берне түгел, икене, юк, унны алам! Бөтенесен умырып бетерәм, сиңа бирмим, бирмим!»

«Акча? — диде күккә багып Ираида Никифоровна. — Бар булганын Толям каерып алды, улымны әйтәм, квартир хакын түләргә дә

[1] Караклар жаргоны: «Ычкын моннан! Үкчәңне күтәр!»

өлгермәдем. Әнә, акчаңны эчеп утыралар. Ходаем, кемгә барып егылыйм? Ник алмыйсың минем җанымны?»

Нәҗип Наиләсен Яңа бистәгә кайтарып җибәрде. «Җитәр, — диде, — дөньяның бөтен шакшысын син дә күрмә инде!» Наилә кайтып китте, карчык тәресез почмакка баш орып, укынып калды. Нәҗип, усалланып, тәвәккәл адымнар белән милициягә атлады. «Анатолий Федоровмы? Тәк, тәк... Кайтканмы? Кайчан гына утырткан идек бәдбәхетне. Социалистик гуманизм дип безнең мине чертәләр. Каракны тотып утыртып өлгермибез, кайтып керә. Акча? Расписка алган идегезме?» «Мондый хәл булыр дип, кем уйлаган». «Акчагызны суга салгансыз». «Милиция ярдәм итә алмыймы?» «Федоров белән бәйләнешкәнче эштән китәм мин!»

«Хатыныңны коча казый, кая барырсың, абзый?» — дигәннәр. Карактан милиция дә шүрләп торгач, кемгә барып егыласың? Ул авыр һәм калын ишекне шапылдатып ябып чыккач, ис тигән кешедәй чайкалып торды, күз аллары караңгыланды. Икмәк кибетенә барып кергәнен, шунда ишек катында хәер сорап кулын сузып торган Ираида Никифоровнаны күргәч кенә Наиләсенең «Кайтышлый ипи кереп алырга онытма», — дию исенә төште. Бөтенләй сукырга сабышып, күзләрен йомган карчыкны ул чамасыз кызганды, бая убылып чыккан ачуы сүрелде, чалбар кесәсеннән егерме тиен көмеш эзләп алды һәм шушы, иң соңгы акчасын, мәрхәмәтсез язмыш хәер сорашырга куган ананың бөршәеп беткән учына салды.

Кесәң тап-такыр булса да, өйгә кайтмый әмәлең юк, кайтып керсә, өйдә кыямәт! Таңсылу белән Наилә якага-яка килеп, чәчләрен йолкышып бетергәннәр. Наилә стенага аркасын терәп, сулкылдап елап тора, күз каймалары күгәргән, күлмәгенең җиң төбе умырылып чыккан. Теге яктан Таңсылуның яшелле-мөшелле тавышы ишетелә, малайлар икесе тиң караватъ астына кереп посканнар. Чыгып китәргә әзерләнгән бүктәрләр кайсы-кая исереп тәгәрәгәннәр.

Наилә, күз яшьләрен тыеп та тормыйча, ни булганын сөйләп бирде: «Ул минем кулымны тырнады. Әле ярый ирек бирмәдем, чырайга үреләләр, дивана. Йөри торган нәмәрсәсе белән пыр тузышып кайткан. Анысы өйләнә икән. Ичмасам, без чыгып киткәнче дә түзмәгән. Шуны бездән күрә. Син бер-бер гайбәт җиткергәнсең аңа ди. «Каһәр суккан психлар, дураклар, ач бетләр!» — дип урамны сасыттъ. Әтиләре кызны тыярга чыккан иде, аларны типкәләп кертте. Балалар җылый, әллә җүләрләнгән микән ул?!»

## 13

Ул икенче көнне таңнан базарга китте.

Юк, азык-төлек рәтенә кереп тормады Нәҗип, яшелчә-җимеш тирәсен башын түбән иеп, урап үтте, бер кырыйда кырмыска оясы кебек кайнаган иске-москы сатучылар арасына барып керде. Монда борынборыннан килә торган гадәтләрен саклаган талчукчылар очрый, буяу пумаласы, күзлек кысасы, самовар торбасы, комган, ләгән ише нәрсәләр, башка йорт кирәк-яраклары тезелеп тора. Сөннәт сакаллы, түгәрәк мех бүрек киеп җибәргән, кәкре аяклы елгыр татар агайларының соңгы вәкилләрен, актыкка буынын монда очратасың. Тире-яры почкакларыннан качып-посып теккән товарларын корсакларына урап, ыштан төпләренә тутырып, ялгыш кына базар арасына килеп кергән гамьсез кыяфәт белән йөрүче базар аристократлары да шушында чуала. Шулар арасына ерып керде Нәҗип һәм эзләгән кешесен тиз арада күреп тә алды. Әйе, шул кешене, Наиләнең туганнан тумышканын, Фәтхулла агайны эзләп килгән икән ул. Элеграк

йомыш-кара төшеп колхоз базарына кагылган мәлләрдә. Наилә белән Нәҗип Фәтхулла абзыйлары күзгә чагылганда оялып, шыпан-шыпан читкә таялар иде. Базар әһәлләренә җирәнеп, сатып-алып йөрүчеләргә кимсетеп карарга гадәтләнгән ыштансыз аксөяк Нәҗип Фәтхулла агасының караңгы якларыннан читкәрәк тартылырга тырыша иде. Наиләсеннән ишетеп ул байтак нәрсәләрне белә иде, ә Наиләгә яңалыкларны күп сөйләргә яратучы Миңсылу апасы ияртеп җибәрә торган иде.

Эшендә мөдир булса да, Фәтхулла агай гомере буе базарны яратты. Казан базарлары тирәсендә аны белмәгән, олыламаган кеше юк. Һәркем, әле базар юлында шомарып өлгермәгән сатучылар гына түгел, алып-сатып, эвеш-тәвеш китереп сакалларына кырау төшкән чаллар да, уртакул эшем иляре, кесә караклары, маклерлар, урлаганны җыештырып, сәгате суккач кына малны көнгә чыгаручы атаклы барыгалар да бик ерактан иелеп-бөгелеп аңа сәлам бирәләр. Фәтхулла — базарның кендеге. Үзе вак-төяк белән азапланмый, сатмый да, алмый да, әмма сәүдә кызган көннәрдә ул монда. Ярты сәгатькә булса да кагылып чыга ул, шул кыска арада да тау хәтле эш майтарып өлгерә. Ул — хуҗа, базарның абруе, даны-шөһрәте. Ерак Көнчыгыш тайгасыннан урланып монда килгән кыйммәтле кеш тиреләре дә, сусар, җофар мехлары, үз төбәгебездә иләнгән вак-төяк җәнлек тиреләре дә иң әүвәл аның күзе аша үтә. Илнең дүрт ягыннан Казан базарына җыйналган мехларның төп хуҗасы ул. Адашып килеп кергән мал хуҗаларына мехны куеннан чыгаруга ук: «Ә-ә, Фәтхуллага күрсәт башта!» — дип кисәтәләр. Чәшке, сусар, су күсесе, төлке тиреләрен ул бер күрүдә таный. Фәтхулла әйтә икән — ышан, ул «юк!» ди икән — буйсын. Базарның катгый кагыйдәсе шул. Фәтхулладан хәер-фатиха алсаң — уңасың, ялгышмыйсың, аннан узып нидер кыласың икән, яңадан бу якларда күренермен димә, беттең! Моннан ары аңа буйсынган базар әһелләре сиңа худ бирмәячәк. Ул атаклы караклар, закондагы бурлар белән таныш, чит яклардан килгән каракларга ул барыгаларның адресын бирә, кайсы малны кайсы тирәдә сатарга кирәклеген ялгышусыз әйтә ала. Ул үтә ярдәмчел, әвене янганнарга зур процент белән акча биреп тора, рибачы, әҗәтен түләүне ашыктырмый, процентын гына арттыра. Милиция хезмәткәрләреннән аны белмәүче юк, гаеплерәк сәбәп табылмаганлыктан, аңа бәйләнмиләр, киресенчә, милиционерлар еш кына аңа үзләре мөрәҗәгать итә, юлына аркылы төшәргә теләгәннәрне ул оста һәм беленмәслек итеп органнар кулына тапшыра да ала.

Ял итәргә, базар хәлен күреп юанырга чыккандай, бераз иелә төшеп, халык кайнаган мәйданчыкта горур басып торган Фәтхулланы Нәҗип тиз күрде, бөркет карашлы абзасы да аны ерактан ук шәйләгән икән, икесе дә бүрекләрен калкытып алдылар. Ул үзенә ике яктан бөгелгән бүрекле башларга, дага сакалларга, елмаюлы йөзләргә игътибар итмичә, туп-туры Нәҗипкә каршы китте, халык ашыгып юл ярып, түбәнчелек белән аны озатып калды.

«Нихәл, аспирант, — диде ул, Нәҗипнең уң иңенә таза гына кундырып. — Сеңел сихәтме? Бала-чагалар сау йөриме?» Фәтхулланың беренче сүздән төрттереп алуы егетне каушатты, ул: «Син сорама, мин әйтмим», — дигән кебегрәк җавап белән котылып калды. «Нәрсә? Күпме кирәк? Акча сорарга эзли килгәнсеңдер, шәт?» — Фәтхулла Нәҗипнең аркасына кулып салып, аны кешесезрәк мәйданга алып чыкты. «Акча соңыннан... — диде Нәҗип, яшереп тә, назландырып торырга да кирәксенмичә.— Син миңа яшәр урын тап, Фәтхулла агай». Фәтхулла түш кесәсеннән көмеш савыт чыгарды, ачып чеметеп кенә кәнәфер алды, уртына кыстырды. «Сез ничәү әле? Дүртәүме?» «Дүртәү». «Эзләп карадыгызмы соң?» «Әй, эзләмәгән кая! Балалар белән урнашу кыен, Фәтхулла абый». «Бер фатир бар-барын...

Бар!» «Кайда ул?» Нәҗип үзе дә сизмәстән абзасының ике кулын эләктереп алды. Фәтхулла тормышның рәтен, кадерен белеп яшәүче эш кешесе иде, кайчандыр ул Нәҗип белән Наиләгә нык өметләнеп, баласы юк кеше буларак, үзенә якынайтырга да ниятләгән иде. Нәҗипнең олысымакланып читләшүе генә аны сагайтты. Хәзер үзеннән бер башка биек, утыз өч яшьлек ирнең адаштырылган эт кебек, күзләренә ялварып карап торуын күргәч, ачуы кабарды. Нәҗипкә берне китереп орасы килде. Исен җыеп, күз кабаклары белән ачуын каплап торды, йомшады. «Ленин районында Тимерюлчыларның бер йорт кәмәше бар анда. Аумаган булса! — Фәтхулла көлмәс җиреннән көлеп куйды. — Шунда берәр чолан булмый калмас. Бүлмә үк димим, чөнки бәдрәф уртак, кухня кисәге өч хуҗага бер. Урыны да җайлы түгел, уңда төтен, сулда тимер юл, өстә шау-шу, аста юеш!» — тапкыр сүз әйттем дип, Фәтхулла тагын көлеп алды. «Абзыкай! — диде Нәҗип, хисләренә буылып. — Төрмә камерасыннан җылы урын бирсәләр, шунда да кереп торыр идем!» Фәтхулла куен кесәсеннән карандаш һәм дәфтәр чыгарды, бер битен ертып ике-өч сүз тырнады. «Мә, адресы шушы. Белеп кер: адресыңны таныш-белешкә бирмисең, кайда яшәвеңне эт тә белергә тиеш түгел. Матвей Ионыч дигән кешене эзләп тап, ни эшләргә кирәклеген ул сиңа аңлатыр. Аена түләвең сиксән тәңкә булыр». Нәҗипнең тыны кысылды: «Сиксән?» «Кеше башына егерме сум, — диде исе китмичә Фәтхулла. — Анда закон каты. Мин сиңа бераз акча биреп тора алам». «Проценты ничегрәк соң?» — дип сорады Нәҗип, курка-курка гына. «Синнән алып тормам. Хәер, баегач үзең чамаларсың тагын».

Аның Фәтхулланы кысып-кысып кочаклыйсы, үбәсе, алдына тезләнеп: «Фәрештә!» — дип атыйсы килде. Фәтхулланың да күңеле йомшады. «Нәҗип карендәшем, — диде ул, — тонык кыяфәтеңне күргәч, хәлең мөшкелләгән аңладым. Кем синең юлыңа төшә? Нинди адәм? Кирәк икән, юлыңнан алып ыргытабыз аны. Кушасың икән, дөньядан юк итәбез». «Синең шундый көчең бармы?» «Һи-и, — дип көлде Фәтхулла, — мең тәңкә алалар җан кыйган өчен. Мең тәңкә дә бер ярты». «Юк, — диде Нәҗип. — кирәкми, Фәтхулла абзый. Дөнья гаепле! Дөнья хикмәтләрен аңларга соңга калдым... Аңлармынмы берзаман, белмим. Алга чыга алмадым, узып киттеләр, узып!»

Фәтхулла затлы кайры тунының якасын чиште һәм ак кәгазьгә урап, таза җеп белән аркылы-торкылы бәйләнгән, бүген генә законлы бурлар китереп биргән, шактый калын төргәкне тартып чыгарды. «Мә, тот! Хәлең бетеп китсә, туры үземә кил».

Фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килде, Фәтхулланың төшемне умырган чагы иде, төргәк Нәҗипнең куенын бүлтәйтеп, күңелен җирсетеп кайтты. Наилә белән икәүләп кат-кат санасалар, абзалары дөп-дөрес мең сумны бөдәгән икән! Наилә кырысланды: «Бурыч — муенга салынган элмәк дия идең, Нәҗип. Батабыз ич!» — диде. «Баш исән булсын!» — диде Нәҗип, читкә карап.

Фәтхулланың киңәшен тотып, ул Матвей Ионыч янына ике ярты аракы тыгып барган иде. Матвей Ионыч дигәннәре өч катлы сары йортның икенче катында, кырый бүлмәдә яшәп ята икән. Ул Нәҗипне бүлмәсенә кертмәде, коридорга үзе чыкты. Тәбәнәк, таза бәдәнле, калын җирән мыеклы, күз кабаклары салынган, чиртсәң каны чәчрәп чыгардай кызыл чырайлы бу кеше, «Фәтхулла» дигәнне ишетүгә күзгә күренеп үзгәрде. Нәҗипне этеп диярлек бүлмәсенә кертте, ике якка бүлтәйгән чалбар кесәләренә ишарәләп: «Яратам гәләфи кигән егетләрне!» — дип хихылдады. Ике сүздән Нәҗипне бүлдерде: «Беләм. Аңлыйм. Буш бүлмә бар. Пропискага бүтән йортка кертермен. Акча сиксән тәңкә». «Түләүне кайдагы бухгалтериягә илтергә?» — дип сорады аптырап Нәҗип. «Дурак!! — диде сыек сөт төсле күзләрен челт-челт йомып Ионыч. — Хәер, дуракларны яратам мин. Алар

белән яшәү рәхәт. Дурак! Бүгеннән аллаң да, муллаң да мин. Комендант та үзем, бухгалтерың да. Дружинник та әле җитмәсә. Акча миңа! Квартир хакыннан тыш аена ике ярты. Килештекме?» «Аракы фатир хакына кермимени?» — диде авырыксынып Нәҗип. «Квартирдан кергәне миңа дип беләсеңме әллә? Фәтхулла кешесе икәнсең, синнән яшермим, — диде шыпыртка кучеп комендант-дружинник. — Бу йорт исәп-хисапта юк, биш былтыр сүтелгән санала. Шикләләр иснәнә башласа, май кап. Дөнья шулай бара икән, эт муенын йоны яткан якка сыпыр. Акчасы тәтеми миңа, бар куанычым шул ярты!»

Ул мыекларын кул аркасы белән сыпыргалады, өстәлдәге сыңар стаканга аракы койды. «Эчәсеңме?» — дип сорады. Нәҗип баш тарткач». — Яратам эчмәгән дуракларны! — дип, почмакка карап чукынды да голт итеп стаканын бушатып куйды.

Нәҗип буш бүлмәне кереп карады. Яңа бистәдәге читлек белән чагыштырганда ул шактый биек һәм иркен иде. Ираида Никифоровна подвалы белән янәшә куйганда якты да, коры да иде. Идәне тигез — күкәй тәгәрәтеп уйнарлык! Аш-су пешерерлек кухнясы бар, бәдрәфе уртак булса да, шунда, коридорда гына икән... Бер нәрсә шикне арттырып, борчып, күңеленнән китмәде: «Милиция-мазар тикшерә башласа, ул — эшсез. Имгәк-тунеядецларны шәһәрдән үк сөрәләр түгелме? Димәк, атлаган саен сагаерга туры киләчәк!» Тик тагын кая бара аласың? Алар Ионыч белән кул сугыштылар...

Ул сары йортка борылып карый-карый китеп барды, юлда очраган беренче йөк машинасын туктатып килешенде, алар шул сәгатьтә үк күчеп тә килделәр. Бурычларны түли-түли мең сум бетә язды, җан сакларлык кына мая калды.

«Яңа йортта урын үзгәләрбез, иртәрәк ятыйк», — дип, как идәннең төрле почмакларына тәгәрәшеп кенә өлгерделәр, ишекне нык дөбердәтеп, салмыш өч ирне ияртеп Ионыч килеп керде. Кергәч, бердәнбер урындыкны билэп: «С новосельем! — дип акырды, сөт төсле күзләрен челт-челт йомгалап. — Мегәричең бармы?» — дип белеште. Юк икәнен белгәч: «Моннан болай мин кергәндә запас яртың булсын!» — дип дөп-дөп басып чыгып китте.

Йокы качты. Нәҗип белән Наилә әйләнгәләп озак аунадылар. Көндез ашык-пошык ташынганда, нәрсә-караны урнаштырганда тирә-якта, күрше-күләндә тавыш-гауга артык ишетелмәгән иде, хәзер йортның өч каты тиң җанланды, бөтен тарафтан, астан-өстән, яннан-каршыдан, төрле төстәге тавышлар агылды. Коридорда бала-чага әүмәкләште: сугыштылар, орыштылар, бәрештеләр, үкерделәр. Уртак кухняларда хатын-кызлар урын өчен даулашты. Кемдер радио акыртты. Кемдер радио тавышын баса-баса үзе акырды. Тыпыр-тыпыр биеделәр. Сулыгып елаштылар. Шешәләр ватылды, стаканнар чыңлады. Кыскасы, адәм уллары дөньяда нинди тавышлар чыгара алса, монда барысы да бар, кирәгеннән артык мул иде. Стеналар юкамы, тавыш иләрe гайрәтле идеме, өч катлы сары йорт давыллы-җилле диңгездә адашып калган җүләрләр корабын хәтерләтә иде. Ята торгач бу давыл тына төште, ләкин дөньяда бүтән төрле тавышлар да җитәрлек икән бу якта! Йокыга китә алмый борсаланып яткан төнне урталайга ярып поездлар текелдәп үтте, паровозлар юл кырында яшәүчеләрне куркытырга теләп тоташ акырдылар. ТЭЦ казаннары сызгырып-үкереп пардан бушанды, тимер юлның аръягындагы силикат кирпеч заводы үз тавышын таратып торды, краннар ары-бире шуышып гүелдәде, машиналар маңгайга-маңгай очрашып кычкырттылар, кайдадыр илереп-илереп гармун елады, елады да завод һәм ТЭЦ сасысыннан тончыгып туктады. Чың итеп пыяла коелып төште, мылтык аткан тавыш яңгырады. Тәрәзә ярыкларыннан, ишектәге тишекләрдән туктаусыз агылган газ, сасы һавадан балалар өзлексез йөткерде. Нәҗип белән Наилә, бугазлары кычытуны баса алмыйча,

торып-торып сөт эчеп килделәр. «Яңгырдан качып, кар-буранга эләкмәдекме икән без, җаным?» — диде Наилә.

Нәҗип дәшмәде, сүзе юк иде.

## 14

Сары йортта атна үтте.

Гадәти шәһәр йортларында гомер буе янәшә яшәгән кешеләр күрше-каршыларын белмичә, бер-берсе белән һич аралашмыйча үлеп тә китәләр. Монда законнар, кагыйдәләр үзгә иде, бу йортка ничек юлыгуларын, кайда пропискада торуларын, күпме фатир хакы түләүләрен беркемгә чыгармасалар да, бу бәхетсез бәндәләр уртак тормыш белән яшиләр иде дисәң дә, хата булмас. Тормыш дулкыннары сине монда китереп ыргыткан икән, танау чөеп, күкрәк киереп йөри алмыйсың инде! Эчә-эчә бөтен кешелек сыйфатларын җуйган гомосексуалист доцент, тавышсыз калган наркоман җырчы, ирсез хатыннар, хатынсыз буйдак-импотентлар, бөҗыр кебек җитез, күмер күзле кесә карагы Митя Шорохов, химиядән чәчләре генә түгел, каш-керфекләре сынып-көеп беткән, күз аслары дуга-дуга шешенеп салынган марҗалар, күлмәк итәгеН ел саен бер тотамга кыскарта килсә дә, ир-ат күзе төшми башлаган чәч алучы Гөлнәзирә, дөньяның әчесен-төчесен генә түгел, йөзләгән ирен татыган чегән хатыны Лорелия, бәхетсезләр, гариплэр, ятим-ялпы монда яшәп яталар һәм барысының да тормышы күрше-каршыга көн кебек ачык иде. Нәҗип белән Наилә бер атна эчендә шушы билгесез киләчәккә таба йөзгән сары корабның пассажирларын танып бетерделәр. Бүтәннәр дә Нәҗипнең эшсезлеген, чирле икәнен тиз үк белеп алдылар. Наилә кайда эшләгәнен әйтмәде, хурланды. Күпчелекнең даими эше юк, ир-атлар — кибет, склад тирәсендә уралучылар, хатын-кызлар ашханәләрдә табак-савыт юа, подъезд чистарталар, мәктәп, китапханә кебек урыннарда эшләүчеләр монда бөтенләй юк иде. Уртак тормыш серләре тиз ачылды, монда сер саклаган булып кылану юк икән, шушы сары йортка төс икәнсең, борын күтәреп йөрмә инде, туган! Монда кәеф саклап, тәкәллефләнеп аңлашу юк, ни уйласалар, шуны турыдан-туры чәпиләр, монда рухи коммунизм һәм матди хәерчелек хөкем сөрә иде. Әйе, Нәҗипнең тормыш планнары зурдан иде, ил башына менеп утырган катлау аны үз арасына алган да булыр иде. Мөдир буласы кеше иде. Шәһәрнең дәрәҗәле ягыннан — Вишневский, Лесгафт, Ульяновлар урамнары тирәсеннән байларча фатир да эләгәчәк иде.. Ә бүтәннәр ничек килеп эләккән монда? Аларның да татлы хыяллары, якын елларда тормышка ашарлык планнары булмаганмыни? Сары йортка юлыкканчы, алар, Нәҗип шикелле үк, ялган хыялларга алданып яшәмәгәннәрмени?! Бер төндә өчәр-дүртәр ирнең кесәсен капшап караган Гөлнәзирәнең дә яхшылыкка омтылган мизгелләре булгандыр ич? Ябык, пычрак муенын бердәнбер байлыгы мохер шарф белән ураган актерның да әле өмете өзелмәгән бугай. Ул кич саен сөт җылытып эчә, авызын учы белән каплап, тамагын кыра-кыра коридорда йөренә, үтәли искән җилләрдән курка, чак кына туңып кайтса да, аягын җылы сулы иске чиләккә тыгып утыра. Алдагы тормыш белән яшәүче бердәнбер зат ул булса кирәк. «Икеләтә җүләр! — ди аның турында Матвей Ионыч. — Зыянны шулар сала!» Бүтәннәр алдагы көн, буш хыяллар белән яшәмиләр, алар өчен бүгенге ачы язмыш хакыйкате генә бар. «Иртәгә өчен ишәк кайгырган». Сары йортның иманы бер.

Кесә карагы Митя Шороховның бурлар дөньясында атаклы икәнен беләләр. Митяның монда яшәп ятуына җыйнаулашып сәерсенәләр иде. Ул берчакта да үзе турында авыз ачып сөйләми, ярканат кебек очып кайта, күргәне аның шәүләсен күреп кала, күрмәгәне күр-

ми, бераү дә артыгын төпченми. Митя көндезгәчә үлеп йоклый, тавышларны ишетми, торгач ике сәгать гимнастика ясый, гер күтәрә, коридор буйлап чаба, иелә, бөгелә, бүлмә почмагына эленгән бокс грушасын төя һәм, соңыннан бозлы су белән юына. Аннары ак май ягылган ак күмәч белән бер чынаяк куе кофе эчә. Ишеге бер чакта да бикләнмәсә дә, аның бүлмәсенә беркем керми, ул турдан һәркем аяк очына басып кына үтә. Митя — мондагыларның эчен-тышын белеп бетергән зирәк кеше, ул ташландык карт-корыны кызгана, үзләре дә оныткан туган көннәрен белә, йокысыннан уянгач, трусиктан гына алар янына керә, котлый, кәсебе уң барганда бүләкләр тапшыра — шарфлар, җылы кофталар, бияләйләр бирә, бүтәннәр өчен юк саналган кәкре-бөкре корткаларны олылап: «Мария Ефимовна, Дарья Григорьевна», — дип эндәшә. Чирләсәләр, ул карый, ашарларына әзерли, дарулар өләшә, чирләп больницага кереп ятсалар, көн саен ризык ташый. Матвей Ионыч белән аралары яхшы булса кирәк, очрашсалар, яхшы атлар кебек, баш иешеп кенә үтәләр. Кыскасы, сары йортта Митя каракны яраталар иде.

Бәхетсезләргә монда күңелләр ачык, язмыш уртаклыгы аларны берләштерә, карчык-корчыклар юнәткән ризыкларын юмарт бүлешәләр, эчкәч якага-яка килеп талашканнар да айныгач татулашалар, кинә саклау юк, үпкәләшләр атна буена сузылмый, сөйләмәсәң, беркем синнән сорау алмый, төпченми, тырнаклары җиткән куллар белән җаныңда казынмый. Наиләне бер нәрсә генә борчый иде: алар да, шушы төркем вәкилләре кебек, борылып чыга алмаслык дәрәҗәдә адаштыларммы? Болар да заманында кемнәрнендер кадерлесе, җәмгыятьнең киң хокуклы вәкилләре булган лабаса!.. Берәвесе доцент булган, икенчесе атказанган артист... Ә хәзер...

Сары йорт шәһәр оешмаларында, милициядә юк дип санала. Әллә кайчан сүткәннәр дә нигезен бульдозерлар белән тигезләп бакча утыртканнар. Йорт та юк, андагы кешеләр дә юк... Язмыш тәгәрмәче бөтен авырлыгы белән адәм улларын сытып тигезләгән, юк иткән. Паспортлары төрле җирдәге төрле йортларга язылган аларның...

Нәҗип завод тирәсенә эз дә басмады, хезмәттәшләренең, завод хуҗаларының, директор урынбасары Храмовның хыянәтен ул шул тиклем авыр кичерде, тамактан калды, беркөнне трамвайда Изил Латыйповны күргәч, алдагы тукталышта ук төшеп калды. Ябыкты Нәҗип, Наиләсе ни кылырга, ни пешерергә, ни әзерләргә белмәде. «Иелгән башны кылыч кисми, тагын бер тапкыр барып кара. Мөдир итмәсеннәр, чукынып китсен, эшкә генә алсыннар. Кирелектән тун тегеп булмый!» — дип ялварды. Ирен җиңә алмагач, «Бармасаң, сорамасаң — тормыйм, аерылышабыз!» — дип кычкырды. Нәҗипнең күңеле портланд цемент белән ныгытылып каткан иде. «Ни көтәсең син?» — дип илерде йомшый төшкәч хатыны. «Иртәгәге көнне көтәм»,— диде Нәҗип томанлы гына. Иртәгәләр туды, алар эзсез-өнсез, җылы язда да күңелләрдәге бозны арттырып үтә тордылар. Бер нәрсә гаҗәпләндерде Наиләне: тормышы-язмышы сары йорт кешеләре белән тигезләшкәч, Нәҗип күзгә күренеп тынычланып калды. Чөнки монда бераү дә бер-берсеннән көнләшми, әҗәл-үлем, газраилләр турында уйлап баш ватмый. Яшиләрме бүген — яшиләр, тамаклары туямы — ачтан үлмиләр! Юктан да рәхәт, сөенеч таба ала торган юксыллар арасында Нәҗипкә дә күңелле иде. Ул кухняга чыгып баса, марҗалар белән гәп куерта, коридорга тәмәке пыскытучылар рәтендә дә читенсенми, монда һәммәсе дә у з к е ш е л ә р. Бер-берсен каулямыйлар, хыялланмыйлар, «ник эшләмисең?» — дип ваксынучы юк, «ник эш эзләмисең?» — дип төпченмиләр, тормыш сары йорт кешеләренең ихтыярыннан тыш үз җае белән ага иде.

«Әгәр балалар да булмаса...» — дип йомгак ясады Нәҗипнең иләслектән бераз авырайган күңеле һәм сискәнеп, суыксып китте.

Балалар хакында уйламыйча ярамый иде. Алар бар, алар яшь, ата-ана аларны алга илтергә, укытып, кеше итеп дөньяга очыртып чыгарырга тиеш. Сары йорт бала-чага урыны түгел иде. Монда, гомумән, балалар әз булып чыкты. Бала-чага өчен җәһәннәм базы иде сары йорт. Өлкәннәр үз язмышларын тора-бара яраштырсалар да, балалар бу тормыш белән килешергә теләмәделәр. Өйгә сыймадылар, чабып урамга чыктылар. Ә тыштa... Бер яктан өзлексез поездлар улап үтеп торса, икенче яктан, тузан болытларына ял бирмичә, җәһәннәм арбалары КРАЗлар чапты. Өй биеклеге тәгәрмәчләре белән җирне таптап-мыскыллап тракторлар туктаусыз агылды. Алардан ургылып чыккан әче төтен койрыклары, ТЭЦ торбаларыннан бөркелгән сөрем болытларына кушылып, кояшны капладылар. Җил көнбатыштан искәндә чыдар әмәл калмады, әнәләре саргаеп коелган наратлар арасына кереп утырган желатин заводыннан әллә нинди кабахәт исләр килеп җитте, тәрәзәләр томаланып, ишекләр ныгытып ябылса да, коридор һәм бүлмәләргә кырыгынчы завод казанлыларга озын гомер теләп бүләк иткән агулы газ кереп тулды, бугаздан буды, тамак төбенә утырды, күздән ачы яшьләр агызды.

Сары йорт — кунакчыл йорт, якшәмбеләрдә монда кунаклар килеп тула, бирeдә аларны риясыз гөрелдәп каршылыйлар, бер кыерчык ипи, бер җамаяк тозлы кәбестә янына шешәләр чыгып тезелә, кайсы кунакның кемгә килгәне онытыла, бүлмәләр берләшә, андый чакта балаларны коридорга чыгарырга һич ярамый! Саклап утырырга кирәк. Беркөн Искәндәрне, бик кысталгач, бәдрәфкә чыгарганнар иде, малайны әләктереп алганнар да көчләп сыра эчерткәннәр. Киң күңелле шул сары йорт кешеләре! Сырасы ярамадымы, эчкән савыты шакшы булганмы, бала төне буе косып чыкты. Наилә күпме ара чабып үтеп телефон-автоматка ябышты, врач чакырды. «Ул урамда андый йорт юк, байтак булды инде алдап чакырулар!» — диде кырку хатын-кыз тавышы.

Искәндәр шуннан мантымады, әле эче китте, әле тамагы шеште.

Тора-бара балалар алмаш-тилмәш чиргә сабыштылар, чирле ир янына ике сырхау бала да өстәлгәч, Наиләнең башы хәсрәттән чыкмады. Алсыз-ялсыз чаба торгач, үзе күтәрәмгә калды һәм иртәләрнең берсендә, биле сызлап кузгалырга чама юкта, балаларны авылга кайтару турында сүз кузгатты. «Әйбәт! — дип бик тиз килеште Нәҗип, — тот та бабаларына илтеп кайт!» «Юк инде, аппагым, — дип җәберсенде Наилә. — Чирле ике малайны картлар муенына такмам, безнең аркада болай да шактый җык күрделәр. Чирләткәнбез икән — үзебез карыйк!»

Шуны да уйлады Наилә: әгәр шушы форсаттан файдаланып Нәҗибен авылга алып кайтмаса, көннән-көн гамьсезләнә барган ир тормыш баткагына муеннан кереп чумачак! Биргән вәгъдәләрен, эчкән антларын онытачак, сары йорт бәндәләре белән тигезләшеп ярты хайванга әйләнәчәк. Нәҗип күз алдында үзгәрә: күрше бүлмәдәге сукбайларга иярде, җитен комбинатында ашханә ремонтладылар — эчеп кайтты. «Сантехприбор» ишегалдын, хуҗалык биналарын чүпчардан арулап шактый акча төшергәннәр — Нәҗип җиде шешә сыра алып кергән. Менә сиңа күчтәнәч! Кыстап Наиләне елатты. Тавышы көрәйде ирнең, күз карашы тоныкланды, буйга биегәеп киткәндәй булды. Күршедәге сукбайлар кереп-чыгып йөри башладылар. Боларын күрмәмешкә салышты хатын, күрә калса, өйдә көн-талаш чыгачагын чамалады. Сүзне гел балаларга кайтарып калдырды, көннәр буе «балалар, балалар!» — дип борсаланды.

Апрель азаклары иде, кардан ачылган сары йорт тирәсендә күлләвекләр күбәйде, чокырлар тирәнәйде, тузан өермәләре куерды. «Кышын түздек, инде малайларны җәй дә монда тотсак, харап булачаклар», — диде Наилә. Балаларны савыктырыр өчен нидер эшләргә

кирәклеген күреп торган Нәҗип бу юлы хатынына каршы төшәргә кыймады. «Кайтыйк соң!» — дип Наиләсен җупләде. Акча ягы койты, анысы мәгълүм, тагын бер чуалган төен килеп чыкты. Нәҗип: «Синең атаңнарга кайтабыз!» — дип кыстап-кыстап караса да, Наилә киреләнде. «Нигә сезгә кайтмыйбыз?! Безнекеләрне күргән бар, нигә һаман синең әти-әниеңне читләтәбез?» — дип иренең күзен ачырмады. «Казан артына кайтырга акча әз дә җитә...» — дип сүзен башлаган ирне Наилә шып туктатты: «Эчеп йөрмиләр аны, хайван!»

Эш харап: юлга кирәк акча, Ионыч белән араны өзеп китәргә кирәк, инде Зәй ягына тәвәккәллиләр икән, ничә ел аяк басмаган ата-ана каршысына буш кул селкеп ничек кайтып керәсең?!

Бәхет көтмәгән яктан килеп чыкты. Кесә карагы Митя Шорохов соңгы вакытларда аларга кергәли иде. Керә, ипле генә утыра, дөнья хәлләрен сораштыра, чит илләрдәге яңалыкларны белешә, укырга китап ала, ертмый, пычратмый, вакытында кире кайтара, китаптагы вакыйгалар, сугышлар, орышлар турында озаклап сораша. Митя аңлы, игътибарлы һәм җанлы егет булып чыкты. Ул, бераз ияләшкәч, аларның ничек бу кое төбенә эләгүләре белән кызыксынды. «Сез — ару кешеләр, китапларыгыз бар, үзара сугышмыйсыз, нигә бүтәннәр кебек квартиралар алып, бай булып яшәмисез сез?» «Ә син, Митя?» — диде Нәҗип үз чиратында. Митя: «Мин башка чут!... Иманым шул: ата коммунистлардан башлап чүп-чар халыкка кадәр урлаша икән, нигә мин тир түгеп ризык табарга тиеш? Җүләрме мин, ишәкме? Менә сез нигә череп ятасыз бу ат абзарында? Балаларыгыз бетәчәк монда. Аллергия дигән әкәмәт чыкты хәзер. Рактан да яманрак!»

Нәҗип ачылмаган иде, Наилә, сердәшсез яшәргә күнекмәгән хатын-кыз буларак, үз күргәннәрен, Нәҗипнең капылт чирләп егылуын, эшсез калуын, юк гаепләр аркасында шушы көнгә төшүләрен елый-елый сөйләп бирде. Сүз арасына Ираида Никифоровнаны, акчаларын талап диярлек алган игелексез Анатолийны да кыстырды. Байтак хәбәрләрне колагы яныннан үткәреп җибәргән Митя «акча», «талау» дигән хәбәрләргә игътибар иткән икән, соңыннан, сүз азагында Анатолийның кайда яшәвен сораштырды. Нәҗип белән Наилә бу әңгәмәне онытканнар да иде. Май бәйрәме алдыннан, кичкә кырын, тузанлы әңгер-меңгердә боларга бер ир-ат килеп керде. Керде дә өстәлгә бер төргәк акча куйды. Хуҗалар каушап калды. Анатолийны шәрәтән генә күргәнгә, зәп-зәңгәр татуировкаларын гына хәтерләп калганга, аны танымадылар. Керүче теш арасыннан гына үзенең сукыр Ираида улы икәнен белдерде һәм: «Сез нигә Митя белән танышлыгыгызны әйтмәдегез?! — дип шелтәләде. — Менә, әҗәтне китердем». «Кемгә рәхмәт әйтергә инде моның өчен? — диде Нәҗип акчага үрелергә базмыйча. — Митягамы?»

— Кирәкми! — диде Ираида карчыкның игелексез улы.— Митя боерганның үтәлми калганы юк. Соңыннан тикшереп йөри ул!

Ул төргәккә сәер бер караш ташлады да көрсенеп чыгып китте. Нәҗип төргәкне сүтеп караса-а, анда-а... бишләтә китергән теге юньсез! Ул коридорга атылып чыгып, баскычтан төшеп барган җилкәгә кычкырды: «Әй, әй!» Җилкә тукталып болай таба борылды. «Нәрсә бар?» «Акчаны артык калдыргансыз». «Анысы процент!» — дип кычкырды Анатолий төшә-төшә. «Артканын Митяга кайтарырбыз», диде Наилә. Көн көттеләр егетне, ике, өч көн, Митя күзгә-башка күренмәде.

Якшәмбедә, бәйрәмнән соң, өй җыештырып палас кагарга чыккан Наилә тимер юл тирәсендәге куаклар арасында шикле хәрәкәт күреп туктап калды. Куаклык авызына милиция машинасы белән «Ашыгыч ярдәм» дә килеп туктаган иде. Ак халат кигән ике таза ир агачлар арасыннан носилкага салып нидер күтәреп чыктылар. Наилә якынрак килде һәм носилкага карагач, әрнеп кычкырып җибәрде.

Носилкада йөзе ак киндер кебек агарынган Митя Шорохов мәете елмаеп ята иде...

* * *

Гомер юлының бер сызыгында ир балалар, өйләнеп, гаилә корып, аерым яши башлагач, бер кавымга эти-әнидән читләшеп, аларны онытып торалар. Нәҗип белән дә шулайрак булды. Аның алдагы тормышка үргән матур-матур планнарында ата-анасына урын юк иде. Сирәк-мирәк кенә, балаларның ата-ана алдындагы бурычлары турында колакка чалынганда, йә кино караганда ул үзе туып-үскән авылны, эти-әнисен кыска гына исенә кертеп чыгара иде. «Килер, көне килер! Йортларын торгызырмын, үз хисабыма диңгезгә ялга җибәрермен! Мәскәү күрсәтеп кайтырмын! Тәмле ризыклар тутырып посылкалар салырмын! Өрексез чәй эчертмәм! Акчаны мул итеп бирермен!» — дип, изге ниятләрен ныгытып куя иде ул җаны уянган мизгелләрдә.

Боларның берсе дә тормышка ашмады, берсе дә! Ул, бигенә ыштыр ябып, бүген атасы катына кайтып бара. Кайтмас иде, ике улы чирдән котыла алмый. Баласы чирләгәндә сау калган ана буламыни? Наиләнең дә күз төпләренә каралҗым челтәр кунды, йөзе сулды, чигәләрендә беренче кырау — ак бөртекләр елтырады.

Ата-анага үз вакытында кайтарылмаган бурыч, үтәлмәгән вәгъдәләр баланы түбәнсетә. Нәҗипнең кордашлары, бер үк кояш астында яшәп, бер һаваны сулап, тормыш юлларын җайга салган күпчелек, укып, кеше булып, торымнан-торымга дәрәҗәләрен бер баскыч югары күтәрә-күтәрә балда-майда йөзгәндә, ул «чирләдем!» дип авызын бәлшәйтеп, ата-ана җилкәсенә кайтып төшәчәк. Үзе генә түгел, йончыган хатыны һәм чирле балалары белән. Нәҗип гаиләсе өчен тот та махсус шифаханә ач! Кайтырга ниятләгәч ул Фәридун Фазлыев янына кереп чыгарга теләде — эшсез сукбай, сары йорт сандугачы икәнен искәреп, уеннан кире кайтты. Фаина Марковна янына кереп хәлен сөйләргә теләде — оялды. «Мавыгырлык, онытырлык шөгыль тапмагансың!» — дип әрләр кебек тоелды.

Дөресен әйткәндә, Нәҗип соңгы минуткача икеләнде: туган ягында көтеп торган кимсенүләр, гарьләнүләр аның чирен көчәйтеп җибәрмәсме? Йөрәк чыдамастан кузгалып алса? Казанда шифаханәләр, Фәридун Фазлыевлар, Фаина Марковналар бар, ә анда ни көтә?

Наилә авылга яшерен өметләр баглый иде: «Балалар белән рәттән Нәҗибе дә рәтләнеп китмәсме?» Нәҗибенең һәр сүзне кирегә сукалаганын ишетеп, ул гел бер уйны кабатлады: «Тилекәй! Авыл синең мәхәббәтең. Яңа сауган сыер сөте! Күпереп торган каймак! Йомарламы белән ак май. Катык, әйрән. Сары майда кетердәп пешкән тары коймагы. Түтәлдән өзеп кергән яшелчәләр, болыннарда кузгалак, какы, балтырган, әнис, көпшәләр! Тау чишмәләре! Урман күлләре! Инеш ярында куак саен сандугач. Инештә кәрәкәләр, маймычлар, кызылканат. Малайлар белән таңнан кармак салырга йөрерсез. Урман аланында киерелеп печән чабарсың, без малайлар белән печән әйләндерербез, күбәләрбез, чүмәлә куярбыз. Син минем авылны сагынганымны белсәң иде!..»

Майның бишесенә билет алдылар.

Кеше берәүне бик нык ышандырырга теләсә, үзе дә ышана башлый. Үзе кат-кат сөйләгәннәрне күз алдыннан үткәреп Наиләнең күңеле бөтәйде, бит очлары алланды, тәненә җиңеллек килде, тавышы челтерәп чыкты. «Әтиеңнәргә хәбәр итик!» — диде ул сөенечәнә тулышып. «Юк! — дип кырт кисте Нәҗибе.— Хәбәрсез-нисез, мыштым гына кайтып керәбез. Аэродром якын, ун чакрым ара, төшке

ашка өйдә булабыз». Әти-әниләреннән йоккан хыял канатларына малайлар да утырган иде. «Мин сөтле токмач ятратам!» — диде Искәндәр. «Ә мин, ә мин!.. Бабамнарга кайткач ун морожный бирьюлы аша бетерәм!» — дип шапырынды Рөстәм.

Бер бау криндел, манпаси, өч йөз грамм мәк хәлвәсе, ярты кило кара җимеш сатып алдылар, күчтәнәчләре шуннан артмады. «Төймә дә бүләк, дөя дә!» — дип күрсендe Наилә. Бурычтан гайре байлыгы булмаган хатын ни кылсын? Алай да, киңәш-табыш иштетеп, акчаны кат-кат санап, санаган саен төрлечә чыгарып интеккәч, Рөстәмгә өч тәгәрмәчле велосипед алдылар, сала малайларының күзен ут итеп, чирәмле тигез урамнарда, каз бәбкәләре арасыннан кыңгырау чылтыратып йөрсен әле бер!



## 15

Их, бәйрәмнәр!!!

Тарихның гел бәйрәмнәрдән генә торган еллары була, хөрмәтле Иван Иванович белән Басыйр Бариевичның нәкъ әнә шундый тантаналы, вакыйгаларга мул чоры иде. Кунак каршылыйлар да кунак озаталар, кунаклардан соң үз бәйрәмнәре җитә! Бәйрәмнәрне төрмә сакчылары белән җәлладлар гына ятратмый: алар бәйрәмнәрдә үз хезмәт уңышлары белән мактана алмыйлар. Шәһәр башлыгы белән тимер юллар хуҗасы бәйрәмнәрдә мактаналар да, макталалар да.

Яңа елны каршылау, Май, Октябрь бәйрәмнәрен аерылмас дуслар бигрәк нык ярата, бу бәйрәмнәрне алар «Уңыш җыяр чак», дип атап йөртәләр.

Хикмәтле сүзләр болар, үтә хикмәтле!

Кыш буе сары йорттан әллә кая чыгып йөрмәгән, сердәшлеккә акбашлы шешәләр җитеп ашкан Матвей Ионыч та май җилен сизә, яңагын каплаган мүкне кырып ыргыта, башына елтыр козыреклы яшькелт картузын чәпи, сөт төсле күзләрен челт-челт уйнатып, чите китек түгәрәк көзге каршысында бөтерелә. Йорттан чыга, куанычлы уйларга чумып, йортны хуҗаларча әйләнә, нигезнең купшыган урыннарына бармагын тыгып карый, почмакларга күнитеге белән ныгытып тибә, ах-ух килеп тузаннарны коя. «Алласына мең шөкер, йортның нигезе нык, көзге яңгырлар, кышкы карлар, язгы сулар да аны җимерә алмаган. Тагын чирек гасырга түзәчәк бу нигез. Көтелмәгән яктан бәла килеп, йортыбызны сүтеп кенә ташламасыннар!» — дип укына. Ул карасу төрткеләр мул бизәгән борынын озаклап сеңгерә, бармакларын күнитек кунычына ышкып корыта, күзен кояшка текәп вакытны чамалый һәм, мәрхүм Митя Шорохов бүләк иткән буй-буй пиджагын җилбәгәй җибәреп, тимер юлны аркылы үтеп чыга. Авыр-авыр шпалларны эре җәмкиләргә әләктереп тартучы чуваш, мари хатыннарының сырган чалбар белән тарттырып куйган артларына чәпелдәтә, белешрәк хатыннарга мәзәк сүзләр сиптерә, хатыннар аны куәтләп кешниләр, шаркылдап көлешәләр. Бара-бара Левченко поселогына җитә, беркайда тукталып тормый, берәүгә күтәрелеп карамый, май урманына кергәч кенә адымнарын сирәгәйтә. Язгы урманны чамадан тыш ярата Ионыч! Тол-дүдәк, ялган акча ясаганы өчен төрмә-лагерьларда унике ел гомерен калдырган, чифир эчеп чак кына үлми калган кырыс җан, урманга кереп күмелгәч, бөтенләй бүтән кешегә әйләнә. Сулган коры яфракларны аралап көнгә калкынган яшел кыяк-кылычлар, ары-бире ашыккан эшлекле кырмыскалар, ачыграк урыннарда тирбәлгән шадра куләгәләр аның кыш дәвамында каткан күңелен йомшарталар, җилкетәләр. Ул кулларын җәеп җылы, иркә җиргә каплана, җирне иснi, көздән калып язын кипкән яфракларны учы белән өерләп мендәр ясый да, чалкан ятып, хуш исле мендәргә

башын куя. Уйлары аны еракка, балачагына алып китә, ул яшьтәш иптәшләрен, печәнлектә беренче аунаткан күрше кызы кылый Марфаны, әллә кайчан гүр иясе булып, бүгенгәчә догасыз интегеп яткан эти-әниләрен өзелеп сагына.

Кинәт ул еракта нәзек тавыш белән машина гөжләгәнен ишетеп алды, курчак-солдат кебек сикереп торды, чәч арасына кысылган яфрак кисәкләрен җиргә койды һәм колагын тавыш килгән якка куеп тыңлана башлады: ул көткән машина киләме?

Ионычның тән хәрәкәтләре үзгәрде, ул, сунарга чыккан ач юлбарыс кебек, сыгылмалы, тавышсыз адымнар белән тавыш ягына авышты, машина бер яктан, Матвей Ионыч аланның икенче ягыннан килеп керде. Очраштылар. Машина тынды. Ионыч җиңел сулап куйды...

Ул кулларының дерелдәвен тыя алмыйча, өнсез генә сукранып, пиджагының эчке кесәсен каптырган булавканы озак кына ычкындыра алмыйча интекте, ниһаять, ычкындырып, иске гәзиткә ураган буаз төргәкне шудырып чыгарды. Бу юлы машинада күп еллар хезмәт итеп мең кат сыналган ышанычлы шофер юк, рульдә Басыйр Бариевич үзе иде. Ул очлы иягең каккандай итеп исәнләште, машина ишеге елт ачылды, төргәк кулдан кулга күчте. Очрашу сәбәпләре ашыгырга кушса да, Басыйр Бариевич сабырлыгын югалтмады, төргәкне тез өстенә куеп, тәмләп сүтәргә тотынды. Ионыч җәберсенеп, куе төкереген йота-йота: «Басыйр Бариевич!..» — дип сызланды. Басыйр Бариевич төргәкне учтан-учка йөртә-йөртә: «Тимә! Акча санаганны ярата!» — дип куйды.

Шактый күпне күргән бишлекләр, баш-башлары бөкләнгән унлыклар бер чүмәкәй, көлеп торган егерме бишлекләр, олысымак салмак иллелекләр икенче чүмәкәй булып өелделәр. Пыш-пыш килеп бер санады Басыйр Бариевич, бишлекләрнең почмакларын кайтарды, унлыкларны сөеп тигезләде, иллелекләрне үбәрдәй булып өстә калдырды. Ионыч акчаларны эреләтә дә ала иде, әмма аңа саклык кассаларында күренү тыелган, өч катлы, сары йортта яшәүчеләрдән акча ничек килеп керсә, тиене-тиенгә туры китерелеп Басыйр Бариевичка барып җитәргә тиеш. «Ярый!» — дип мөгрәде, ниһаять, Басыйр Бариевич. Кычытып интектергән иягең кашып, Ионыч шушы сүзне көтеп зарыккан иде, «Булдырабыз без аны!» — дип, җиңеләеп, хуҗасына өмет белән текәлде. Аның баядан бирле ялманып торганын күңелле күзәткән Басыйр Бариевич арткы утыргычка ымлады: «Ал. Сиңа. Бүләк». Ионыч ялт кына арт ишекне ачты, урелеп чүпрәк капчыкны кулына алды. Капчыкта бер шешә аракы, ярты кило чамасы ливер колбасасы, бер баш йомшарган сарымсак бар иде. «Каклаган каз куйдым, әнкәй кучтәнәче. Каз бәлешенең төбе дә сиңа насыйп икән, Ионыч!» — диде Басыйр Бариевич эре генә.

Хуҗа белән тугры хезмәтче, әйткәнебезчә, бәйрәмнәр тирәсендә генә очрашалар, ешрак күрешергә ярамый. Кирәге дә юк, озын сары йорттан ел дәвамында күпме фатир акчасы кергәнен Басыйр Бариевич бик шәп белә. Төгәллек һәм гаделлекне яраткан Ионыч, әлбәттә, үзен буш итми, аның үз исәбе бар, ат аунаган җирдә төк, акча йөргән якта мая калмыйча булмый. Берничә бүлмәне алар базарчыларга, җылы яклардан килгән кишмиш-күрәгә сатучыларга бирәләр. Басыйр Бариевич һәр бүлмәдә алты базарчы куна дип белсә, Матвей Ионыч анда уникене сыйдыра. Һәр борыннан тәүлек саен ике сум! Тамып кына калмый, ага да!

Машина куркып кына фырылдады, икесе ике якка кузгалдылар. Аларның очрашканын беркем күрмәде, миллион адәм яшәгән шәһәр Казанда бу күрешүне тагын бәрәү генә беләчәк. Хөрмәтле Иван Ивановичның кодрәте, Басыйр Бариевичның елгырлыгы белән исән

утырган бу йорт тимерюлчылар балансыннан әллә кайчан сызып ташланган. Айлык керем тиене-тиенгә ике арада тигез бүленә. Иван Иванович йортны чит тыкшынулардан саклашкан хокук тәртибе сакчыларына өлеш чыгарса, Басыйр Бариевич үз тирәсендәге җаваплы иптәшләрне буш итми иде.

Май бәйрәме — алар өчен үтә кадерле, үтә төшемле бәйрәм. Демонстрация үтүгә, алар, шәһәрнең алтын тоткалары, савылып өлкә комитеты буфетына керәләр, аягүрә басып кына бер-ике чәркә коньяк йотып, кара уылдык, семга телемнәре белән авызларын кинәндергәч, таралалар. Хөрмәтле Басыйр Бариевич аллы-артлы, һәркайсы үз машинасында, Идел буена аулакка китәләр. Акча шунда бүленәчәк. Ирләре артыннан аерым-аерым машиналарда хәләл җефетләре дә тантанага килеп кушылалар. Елгыр егет, тимерюлчыларның профсоюз лидеры Исламнур бүген мәҗлеснең уртасында балкып утыра. Татар да кеше ич, килсен, әйдә кинәнсен бер!

Аһ, киче гүзәл! Май киче! Талгын гына аккан чуар-чабар болытларны җиңел аралап, көмеш кош булып самолет оча. Су өстендә уйнаган вак, язгы гөнаһсыз дулкыннарны басып, Идел өстенә хуш исле әңгер иңә. Бераз кәефләнеп алгач, Иван Иванович белән Басыйр Бариевич тән язарга сәйранга чыгалар. Бераз арткарак калып булса да, аларга Исламнур иярә. Җәяү йөрү бәхете сирәк эләккән затлы ил агалары җир тарту көченең рәхәтләнгән тоеп атлыйлар, җиркәй исә депутатның да, каракның табанын да бертөсле кытыклый. Бара-бара болар тимер юлны каплап торучы тоташ стенага — агачлыкка килеп чыгалар. Каен белән ярыша-ярыша үсеп, шактый ныгыган кәүсәле мәгърур имәннәр янына барып баскач, хуҗаларның кәефе тагын да күтәрелә. «Бушбугаз журналистлар: «Табигатькә куркыныч яный, Казан яны имәнлекләре бетте!» — дип лаф ора. Кәнтәйләр! Сукырлар! Килсеннәр, күрсеннәр, ничәмә-ничә чакрымга сузылган бу имәнлекләр! Басыйр Бариевичның бу агачларга һич катнашы булмаса да, ул бүген шат, имәннәрне үзе утыртканмыни, очынып мактана, иңнәренә кагылган ботакларга асылынып уйный. Борылып караса, Иван Ивановичның үткен күзләре имәннәргә түгел, авыл белән агачлык арасында җәйрәп яткан иңкүлеккә төбәлгән. «Шушында симерә инде алайса Әнисә түтинең казлары!» — дип соклана шәһәр башлыгы. Тимерюлчыларның лидеры аңа кушыла: «Шушында симерәләр, бәхете арткыры!» — дип куя. «Мәскәүдән алып кайткан каз ботын кимергән бар, юк, безнең якта май җыйган кош-кортка ни җитә!.. Хәтерлисеңме, өченче ел көртлек атарга барган идек, ә?!» — Иван Иванович хатирәләргә кереп чумса, беттең дигән сүз, каян сүзен, чагыштыруларын таба дигән, сандугач булып сайрый... Сүз дәвамында ул орчык башы сыман бөтерелеп тыңлаган Басыйр Бариевичны шәйләп ала һәм: «Быел ничә бәбкә чыккан?» — дип кызыксына. «Икеояга егерме ике бәбкә!» — ди горурланып Басыйр Бариевич.

Бу күңелле сан аларны сихерли, алар егерме бәбкәне, исәйгән, үсеп казга әйләнгән кошларны күңелләреннән үткәрәләр. Якын вә ерак киләчәк аларга татлы төш булып күренә: әйдә, имәннәр үссен, каеннар шауласын, поездлар үтеп-сүтеп торсын, ил нығысын, әмма шушы тын иңкүлек, кешесез һәм аулак урыннар үзгәрешсез калсын. Тормышның асылы үзгәрмәсен, илдәге гадәтләр шул килеш калсын, халык җитәкчеләрен зурласын, ярабби! Оҗмах диләр, күзгә күренмәгән оҗмахка керү хокукы яулар өчен күпме адәм уллары гомерләрен Гайсә пәйгамбәргә, изге Мөхәммәткә багышлаганнар, ярым-йорты ашап, кара тиргә батканчы эшләп яшәгәннәр. Җир йөзендә дә оҗмахка тиң урыннар барын белмәгәннәрме алар? Ахмаклар, беркатлы сукырлар! Оҗмах, чын оҗмах шушы түгелмени инде?! Тагын нинди оҗмах кирәк адәм улларына?!

16

Нәҗип Йосыф улы Нургалиев яши-яши үз табигатендәге сәер бер гадәтне ачты. Нинди дә булса авыр, чуалчык мәсьәләне чишә алмыйча хәлдән таеп ял итәргә ятса, шулчак, йокы белән уяу арасында зиһене ашыгып-ашыгып эшкә тотына, озак газаплаган, чишелмәстәй күренгән сорауларга җавап үзеннән-үзе күңелгә килә. Иҗат әһелләрендә шундый сәер феномен барлыгын ул кемнәндер ишеттеме, әллә укыганы хәтердә калдымы, үзе белән шундый хәл еш-еш кабатлангач, Нәҗип куркып та йөрде. Гадәти хәлме бу, әллә табигать могҗизасымы? Лабораториядә эшли башлагач әллә ничә тапкыр сынады: баш ватып утырганда табылмаган җаваплар, урынга яткач, йокыга китәм дигәндә генә табылды да куйды. Ниятләп яткан очракларда могҗиза тумады, тинтерәткән мәсьәләләргә җавап табылмады. Аны-моны юрамыйча ятса, «күк капусы ачылды да куйды». Бу сәер күренешне Нәҗип үзе өчен шулай дип атады.

Нәҗип сәер халәтнең эчке закончалыгын ачарга тырышып карады, кайсы көнне, сәгать ничәдә, нинди шартларда күк капусы ачылганын кәгазьгә теркәп барды, схемасын төзеде. Иртә ачылганмы күк, кичме? Әмма ул төгәл генә бер модель ясый алмады, кеше аңында фән дә аңлатып бетерә алмаган күренешләр һәр затта үзенчә була ала, дигән нәтиҗәгә килде. Соңгы вакытларда, чирләп егылганнан соң, аның бу гадәте юкка чыкты, шундый серле-тантаналы мизгелләр кабатланмады. Зиһене буйсынмый башлады, ихтыяр көче күзгә күренеп кимеде. Кеше, әҗәле, үлеме хакында гына уйлау сукмагына төшсә, үлемен тизләтә, курку хисе бүтән хисләрдән өстенлекне ала, кеше аңын кимерә. Мыжыклар, дөрләп кабынучы кинәтләр, үпкәчел-көнчеләр бу дөньядан тизрәк китәләр. Җир аларны күтәреп торып арый да, вакытын белеп кенә, үз тәненнән кагып төшерә.

Бүген җылыкай төенчеген — төпчек улын тезенә утыртып, самолетта кайтканда Нәҗип йокымсырады. Холкы белән чәүчәләк, урын үзгәләүче Нәҗипнең самолетта түгел, икешәр тәүлек кайтып поездда да йоклаганы юк иде — бүген изрәтеп, тәнне мәмрәтеп йокы басты. Мие түнде, күз кабаклары салынды, буыннар йомшап камырга әйләнде. Керфек араларында сәер зәңгәрсу томан хасил булды. Ул үзләре кайтасы юлны — Зәй белән Югары Авыл арасын аермачык күрде. Ирнә буендагы әрәмәдән болыт булып сарык көтүе чыга икән... Ә баш очында тургайлар! Пыр-пыр килеп очалар. Сулда — төбәкнең биек маңгае Кашка тау. Аның итәген туктаусыз юып, Олы су ага... Олы су үзәнен ярып бер тавыш яңгырый: «Нигә кайтасың син туган ягыңа, Нургалиев? Онытылып, чиреңнән качып, авыл ышыгында посып торырга кайтасыңмы? Фәридун Фазлыев белән Фаина Марковна икесе бер авыздан: «Чиреңтәнеңдә түгел, җаныңда. Кеше үз җанына үзе хуҗа була ала», — димәделәрме сиңа? Бәхетсезлек, чир, мәшәкатьләр, өстәмә чыгымнар сорап, син ата-ана канаты астына сыенырга ниятләдеңме?..» Сорау иңкүлек өстендәге кошларны куркыта-пыркыта тирбәлеп йөрде дә Кашка тауны сискәндереп яңгырады. Ул сискәнеп уянды, бүген, күк капусы ачылган кебек булса да, уйларының йомгагы, нәтиҗәсе юк иде. «Әллә гомерем шушы минутта чикләнәме?» — дип уйлады Нәҗип, тиз-тиз уңга-сулга карады: колагына мотор тавышы ишетелмәде. Аңа курку иңде. Тирә-як, һава-күк тып-тын калган иде. Ул Рөстәмен корсагына кысып, үзен түгел, улын коткарырга теләде. Кай төшкә мәтәлеп төшәләр икән? Урмангамы, кыргамы? Ничә секунд гомерләре калды икән аларның? Бүтән пассажирлар нигә тыныч, нигә чәбәләнмиләр, кычкырмыйлар. Бер-бер чарасын күреп өлгереп булырмы? Бразилиядә энеле-сеңелле ике бала, үзләре утырган креслоларга чытырдатып тотынганнар да, биек-биектән җиргә исән-аман төшеп җиткәннәр. Куе ботаклы агач ябалдашына тап килгән берәү вак-төяк

тән җәрәхәтләре белән котылып калган. Кай турдан очалар икән алар? Чулман иделе өстеннәнме? Әгәр алар боздан яңарак ачылган сап-салкын суга барып кадалсалар? У-у, су үтергеч салкындыр әле! Өс кием-нәреңнән котылсаң да, шыкраеп катарсың, чишенмәсәң, быкырдап төпкә китәрсең. Самолет турайды, мотор тавышы гөрләп ишетелә башлады, баксаң, Нәҗипнең «күк капусы ачылуы» дәвам иткән икән. Уйлары борчулы вак-төяк шикләрдән арына алмаган кирле-мырлы уйлар. Бүтән пассажирлар да месләгән, самолет тигез гүли, изрәтә. Нәҗипнең йөрәге, моторга тыңләшергә теләгәндәй, ашкына. Ул тел астына валидол кыстырды. Ис сизеп, Наилә аңа борылып карады: «Хәлең начармы әллә?» «Түзәрлек»,— диде Нәҗип күзләрен йомып...

Зәйгә барып төштеләр. Кызык, Зәй төбәгенә юмарт сибелгән татар-керәшен авылларында Зәй дигән сүз юк, бу як халкы аны «Эзи» дип атап йөртә, «Эзигә бардым, Эзидән кайттым»,— дип сөйләшәләр. Нигә Зәй, Эзи матуррак түгелмени? Самолеттан төшкәндә Нәҗип шулай уйлады. Ирнә елгасы өстен иңләп килгән җил аларны куырып алды. Аэропорттан Югары Авыл юлына чыгуны ныклап уйламаганнар икән, ничектер һәммәсе тиз җайланыр, Зәй-Сарман арасында йөрүче бетмәс, һич югында сөт ташучыларга сыешып кайтырлар, дип ниятләгәннәр иде. Наилә, каерган җилгә бирешмәскә тырышып, итәген тотып, аэропортны урап чыкса да, ике арык аттан һәм балчыкка чумган матайдан ары нәрсә-кара күрмәде. «Әни, кара, балчык мотоцикл, ул уенчыкмы?» — дип сорады Искәндәр. «Пычранган гына ул»,— дип аңлатты пошына башлаган әниләре. Китәселәр самолетка кереп тулды, ул пыр-пыр килеп китеп барды, җил тагын да зәһәрләнде, һавада кәнфит кәгазьләре, коры курай бөтерелде, буш консерва банкасы тәгәрәп килеп Наиләнең тубык сөягенә килеп бәрелде, авырттырды. Алар белән очкан кешеләрнең берничәсе буш буйдак икән, кысыр сумкаларын, кулларын селкеп, Зәй ягына тәпиләделәр. Чемоданлы апалы-сеңелле ике хатынны балчык матай алып китте. Аэропорт хадиме, ишегенә авыр йозак элеп, матай болгатып киткән лайны озын куныччлы резин итекләре белән ера-ера, өенә ашыкты. Нәҗип: «Авыз ачып калмыйк тагын!» — дип, атлылар янына ашыкты. Атлыларның берсе дә Югары Авыл ягына кайтмый икән, кирегә, Мәлем ягына китәләр. Нәҗип: «Олы юлга чыгарып кына куегызчы!» — дип үтенде, тегеләр гармун кабыргалы юртакларына күрсенеп карап: «И туган, юлның нинди икәнен белмисеңме әллә?» — диештеләр. Үзле балчык ябышып авырайткан тәгәрмәчләрен җылатып-сөйрәп, атлылар да кузгалды. Бикле аэропорт, пычрак мәйдан янында, җил күзендә алар дүртәү торып калдылар. «Әни, минем тамагым ачты»,— диде Рөстәм. Наилә, авызы нәзек җеп белән бәйләнгән төенчекне чишеп, күмәч сындырып алды, улына тоттырды. «Ә миңа?»— дип турсайды Искәндәр. Аңа да өлеш чыкты.

Ул арада Зәй ягыннан ава-түнә килүче машина күренде, дүрт күз белән көткәнгәме, әллә юл чыннан да бик хөрти идеме,— машина үтә дә озак килде. Яртылаш лайга манчылган, номерлары гына түгел, ишек тоткалары да күренмәскә әйләнгән машина — яньчелгән канатлы «Запорожец» булып чыкты. Ишегеннән кәтәнә генә, йомры гына бер үсмер җиргә сикерде, лай чәчрәде. «Ибраһим абыйлар кайтмадымыни?» — диде ул. «Юктыр»,— диде Нәҗип, кулын җәеп. «Монда кеше заты калмады»,— диде Наилә эченнән сөенеп. Малайлар алсу яңакларын бүлтәйтеп күмәч бөктеләр. Кәтәнә куныччлары кайтарып бөкләнгән кирза итекләре белән җиргә типкәләде: «Монда корырак икән»,— диде. «Юл начармы?» — дип сорады Нәҗип, тегеңә ярарга тырышып. «Начар гынамы, начар ярым!» — диде кәтәнә, җилгә каршы төкереп. Төкерде дә яңакларын пычрак учы белән сөртте. «Әни, туймадым»,— диде Рөстәм, әнисе итәгенә сырпаланып. «Мин дә!» — диде борын куыгын йотып Искәндәр. Наилә чирдән арынмаган балаларга әрнеп карады: «Бабаңнарга кайткач ашарсыз. Тавык ашы пешереп

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ ◆ БАЛТА КЕМ КУЛЫНДА? ◆

көтәләрдер. Сизәләрдер... Ачкакланмагыз! Ачлар дөньясыннан кайткан диярләр». Нәҗип, юмакай-төче тавыш белән: «Син, шәп егет икәнсең, безне олы юлга чыгарып куйчы»,— дип кәтәнәгә эндәште. «Кая кайтасыз?» «Югары Авылга ла!» Кәтәнәнең «Оһо!»сын аңлау кыен түгел иде. «Буш итмәбез!»— дигән булды Нәҗип кесәсенә суккалап. «Эш андамыни? — диде кәтәнә, җил уңаена оста төкереп.— Ибрай абыйларга ни булды икән? Телеграммасы килде, анда тучны әйтелгән...» Нәҗип үтенечен кабатлады. Кәтәнә үзеннән чак кына бәләкәйрәк балаларга карап: «Төягез хәзинәгезне!» — дип кычкырды. Тиз-тиз машинага кереп чумган малайлар янына бүктәрләрне, кая куйсаң да төртеп-чыгып торган хәсрәт велосипедны кертеп урнаштыргач, Наилә, итәген җыештырып, алар янына кысыларга әзерләнгәндә, кәтәнә сытык елмаеп аны туктатты. «Син, чибәр апасы, ашыкмый тор. Чакыру бармы әллә? Минем машина, бер кузгалса, җен урынына чаба, кузгалмый икән, үшән алаша күк тик тора. Сез, кабынганчы, икегез ике яктан машинаны тәгәрәтеп барыгыз инде».

Бүтән чараң юк, ни кыласың?! Наилә сирәк киелә торган туфлякөймәләренә, майланып-җебеп яткан чокырларга карап авыр сулады да итәген бөрмәсенә кыстырды. Нәҗип, учына төкереп, шофер ягына чыкты. Кәтәнә утырмады, ишеген ачык калдырып, стартерга басыпбасып карады да этешергә әзерләнде. Тик торган арада үзле балчыкка сеңгән иске консерва банкасы кузгалмыйча шактый тирләтте. «Кабынуга, икегез ике яктан утырып өлгерегез!» — диде кәтәнә. Һау-һаулап кычкырып эттеләр, балалар кул чәбәкли-чәбәкли тәгәрәп көлделәр. Мәзәк аларга! Тәки кузгаттылар әҗәл тагарагын, алар бәхетенә юл авыш иде, урыннан бер купкач, машина үз җае белән балчык чәчә башлады. Бер төчкерде, ике, өч! Мотор кабынуга, кәтәнә: «Ятрәк!» — дип акырды, үзе елдам гына руль артына сикерде. Күрсәнә, баралар!

Якын гына араны сәгатьтән артык үттеләр. Зәйгә җитәрәк юл аруланды. Нәҗип: «Син, туганкай, безне Югары Авылга илтеп куйчы!» — диде. «Ибрай абыйлар икенче рейстан калмас, бензин ягы да кәй. Туй. Өйләнәм!» — диде кәтәнә. Акча алмады кияү егете, «Якташлардан аламмы соң?» — диде. Балта сабы хәтле кияү егетенә карап, Наилә ни уйлагандыр, Нәҗибенә әйтеп тормады.

Буласы булды, кәтәнә бензин юлларга китте, алар Зәйнең Сарман ягына чыга торган очында, җилдән ышыкланып, кабык түбәле өйгә сырышып басып калдылар. Озак кына сөйләшмәделәр, күзләр дә, уйлар да гел юлда булды. Бер яктан да хәрәкәт күренмәде, кояш тиз-тиз күченә, үз артыннан көннең яктысын ияртеп офыкка таба ашыга иде.

Зәйдән егерме чакрымдагы авылда Нәҗипнең бертуган абыйсы колхоз рәисе булып эшли. Алдан хәбәр итеп куйсаң, йә булмаса хәзер кереп шалтыратсаң, юлда калдырмас, әмәлен табар иде. Болай да чакчак эләгеп торган аралары соңгы очрашуларында шартлап өзелде. Абыйсы партия конференциясенә килгән иде, урамда ялгыш кына күрештеләр. «Торыр җирең булмасын, эшең җайга салынмасын, бу нинди бала арты бала ташу! — дип кызды абыйсы, Наиләнең Рөстәмне алып кайтуына җене котырып.— Хәзерге заман кешеләре алдынартын кат-кат уйлап, уйларын мең кат уйдырып яши. Әнә, яһүдтән үрнәк ал. Күргәнең бармы герой-ана яһүдне? Бала-чаганы Урта Азия ыбыр-чыбыры ташый. Ә яһүд йә профессор, йә доктор. Бала чүпрәге юып эш майтаралармы бу заманда?!»

Нәҗип абыйсын моңарчы бер дә белмәгән икән, шунда аңлады. «Энисенең хәле ничек, бәбие сихәтме, дүрт саны тигезме? — дип сорашмады партконференция делегаты, ата белән ананы эттән алып эткә салды.

Юк, юк, бүгенге хәлен ул абыйсына күрсәтмәс, белдермәс тә, Зәйдә кунса кунар, аңа шалтыратып тормас.

Абыйсының һәр якны берьюлы күреп яши торган кеше икәнен

ул әзрәк белә иде. «Мин райком секретаре булам!» — дип яшьтән үк киртләп куйган иде Сабит. Ул яшьли биргән вәгъдәсен онытмады, юлыннан читкә тайпылмады, юк-бар кеше белән аралашмады, туган-тумачаны үзе аралашкан түгәрәккә кертмәде, ачык чырай күрсәткән туганнарның, бер заман өскә менгәч, ямаулык сорап киләчәген белә иде. Шул сәбәпле колхозның үз ягыннан ерагын, иң читтәрәген сайлады, өенә бик сирәк, анда да чирек сәгатькә генә кереп чыккалады. Читтәге туганнарына карлыгач канаты хәтле дә хат язмады.

Зәйдә кунса кунар, ялынып Сабит абыйсына бармас Нәҗип!

Вакыт ашыгып акты, балалар көйсезләнде, юанычка аларга велосипедны көйләп бирделәр. Дуңгыз сөреп бетергән Зәй урамында балалар әллә ни иркенәя алмады, тәгәрмәчләре батып интектергәч, уеннан баш тарттылар. «Авылга кайткач, авылга! — диде Нәҗип тәгәрмәчләрне күлләвектә юып.— Анда инде ул чирәмле урамнар! Көмеш күлгә барырбыз, кармак салырбыз, уха пешерербез!»

Тырылдаган тавыш ишетелде. «Машина!» — диделәр алар берьюлы. Тавыш озак көттерде, күзләр тала дигәндә, урам чатыннан «Беларусь» тракторы килеп чыкты. Сөт бидоннары тулы арба таккан, төсен җуйган трактор фырылдап килде дә Нәҗип белән Наилә баскан турга җитеп, үзеннән-үзе туктады. «Югары Авылгамы әллә?» — дип кычкырды Нәҗип. «Шунда!» — дип җаваплады үсмерлеге чыраеннан чыгып бетмәгән тракторчы. Аңа кысылып утырган чәчәкле яулыклы хатын-кыз юлчыларга текәлеп-текәлеп караса да, танымады. «Шунда кайтып барыш ие дә,— диде тракторчы.— Кайтып җитеп булса...» «Җитәрбез»,— диде ярым шукланып янындагы хатын-кыз.

## 17

Түбән Очта Яңа урам бар, тракторчы Мөнир шул очның Мифтахетдин улы икән. Нәҗиптән күпкә яшь булганга, алар бер-берсен белмиләр иде. Кыска һәм тиз таныштылар. Мөнир районга сөт ташый, хатыны Халисә төрле эштә йөри. «Кая кусалар, сөрлегеп шунда барабыз инде»,— диде ул гел көлеп, елмаеп. Мөнир юлчыларның ару киемнәренә карап уңайсызланды: «Бидоннар арасында бик пычрак инде, утырыр урын юк. Председатель кеше утыртканны яратмый, эскәмия куйдырмый»,— диде Мөнир, председатель исемен катыштырып зарланырга ярамаганлыгын белсә дә. «Ярый, ярый, балаларны кабинага сыйдырсагыз, без түзәрбез»,— диештеләр ир белән хатын. Кабинага бер малай гына, ул да көчкә-көчкә генә сыйды. Кулына ике прәннек тоттыргач аның шыңшуы бетте. Халисә апасы аңа авылда ике мөгезле сыер күрсәтергә вәгъдә бирде. «Ялганлыйсың?— диде малай прәннек кимереп,— сыерның мөгезе булмый!» Трактор арбасындагы җиде бидон арасына Нәҗип, Наилә, Искәндәр менеп бастылар. Чайкала-чайкала кузгалдылар. Малайга куаныч, арба янтайган саен аның күзләре куаныч белән тулды, бидоннар бер якка өерелеп арба ава язганда ул кычкырып та җибәргәләде. Ата белән ана: «Батып калмасак ярар иде!» — дип әллә кайчан югалткан ходаларына ялварганда, трактор аксак арбаны сөйрәп әле быкырдык чокырларга барып керде, әле корырак юлга чыгып, күңелле генә мырлады. Ирнә болынын җәфаланып, озак һәм интегеп үттеләр. Ничәмәничә мәртәбә үтеп-сүтеп йөргән Нәҗип Ирнә болынының шулкадәр киңлеген әлек белмәгән икән. «Болай барсак, кайтып җитәбез!» — диде Наилә Искәндәрне җилдән ышыклап, бот арасына кыстырып. «Белгән юк...— диде Нәҗип, күзен алгарак ташларга тырышып.— Анда бер чокыр бар, Җәһәннәм чокыры дип йөртәләр...» Хәвефле чо-

кырга җитәбез дигәндә трактор туктады, мотор сүнде, кабинадан сикереп төшкән Мөнир борынын тарта-тарта алар янына килеп басты. «Ни булды?» — дип сорадылар Нәҗип белән Наилә икесе бер тавыштан. Мөнир карлыккан гаепле тавыш белән: «Ал тәгәрмәч төшеп калган»,— диде. Ышанмадылар. Нәҗип, кабынып: «Тәгәрмәчсез ничек бардык соң без?» — дип кычкырды. Мөнир үзе дә бу хәлгә ышанып бетмәгән иде, аңлатып тормады, кулын җәеп, башын чайкады да: «Хәзер алып киләм, сез төшеп берәр җирдә ышыкланып торыгыз инде, яме»,— диде. Картузын батырып киде дә, иске сырмасының төймәләрен төймәләп, үзләре мең бәла белән үткән юлга борылды.

Башта Нәҗип җиргә төште, аннары үрелеп, биленнән ике кулы белән тотып Наиләне төшерде. Искәндәр: «Кермим, кермим!» — дип кәҗәләнсә дә, аны, «Җилдә ябышып катасың киләме?»— дип, этеп-төртеп кабинага керттеләр. Рөстәм, апасының итәгенә башын куеп, рәхәтләнеп йоклый иде. Ир белән хатын, бер-берсенә карарга читенсенеп, юл кырына, корырак урынга чыктылар. Әче җил юл буе үзәкләренә үткән иде, юка плащларының якаларын тартып томалаганда, күшеккән куллар төймә каптыра алмыйча интектеләр. «Үзем, үзем!» — дип, Наилә Нәҗипнең төймәсенә тотынды, күзләр ихтыярсыз очраштылар. Нәҗипнең кинчә борын тишекләре суланган, ирененнән кан качкан, эшләпә читләреннән бүселеп чыккан чәчләре учма-учма җилдә җилферди иде. Наилә тиз-тиз күзен читкә борды. Үзенең кыяфәте дә әллә кем булмагандыр...

Туктаусыз ерагая барган Мөниргә карап, Нәҗип үзләренең шактый ук четерекле хәлгә тарыганнарын аңлады. Нидер эшләргә кирәк иде! Тычкан исе таратып яткан эскерт төбеннән салам йолыккалап Нәҗип учак тергезергә, Наиләсен җылытырга ниятләде. Бәхете: тартмаса да, юлга чыккан мәлләрдә кесәсендә шырпы йөртә иде. Берне кабызды, ыргылып килгән җил сүндерде, чүгәләп, шырпыны плащ итәге белән томалап сызарга маташты, кабынмады, ярты капны исраф иткәч, ут күксел, черек салам учмасына йөгерде, ак пар һәм зәһәр ис таратып чожлады. Нәҗип, тузынып, плащын салып ыргытты. Җил уңаена очып барган болонья плащны Наилә эләктереп алды. Искәндәр әтисенең ут белән уйнавын күреп, ишекне ачып җиргә сикерде, мәтәлеп китте, тезе, чалбары пычранды. Иренә баядан бирле җенләнеп карап торган Наилә үчне малайдан алды, «Юньсез!» — дип, җилкә чокырына бер-икене кундырып, Искәндәрне кабинага дөмбәсләп кертте. Малай шыңшыды. «Җитәр, улама!» — диде төсе танымаслык булып бозылган Наилә.

Тракторчы һаман ерагая иде. Шушы кадәр араны тәгәрмәчсез ничек үткәннәр алар?

Нәҗипнең шырпысы бетүгә барды, кап юешләнде, кул дымланды, ә салам кабынмады. Ул, күбәләк куган бала сыман, күрмәс күзе белән курай эзләп ары-бире ташланды. Аның акайган күзен, гариплләнеп иелгән гәүдәсен, чалбары астыннан бүселеп чыккан ак күлмәгенең итәген тамаша кылган Наилә, котырына башлаган нәфрәтен чак тыеп, камылларны сыта-сыта, басуда уем-уем туфля үкчәсе тишекләрен калдырып йөренә иде. Тракторчы һаман бара, ул утырган эт дәүмәлеге генә калды. Ялкау ир! Кыл кыймылдатырга да курка! Икәү барсалар, тәгәрмәчне тизрәк алып килерләр иде. Наилә күңеленең шашынганын, кан тамырларында кирелек, үҗәтлек, усаллык дулкыны ташыганын тойды, ирен бәреп җибәрәсе, җебегән кулыннан шырпыны тартып аласы, тирә-юньгә җылы түгел, күгәрек сасы таратып яткан эскерт төбен яндырасы килде.

«Кулыңнан килердәй булмагач, нигә безне интектерәсең?!»

Хатыны авызыннан шушы сүз атылып чыккач, Нәҗип әүвәл трактор кабинасында утырган Халисәгә карады. «Ишеттеме, юкмы?» Пырдымсыз җил ул яктан бәрә иде, ишетмәгәндер, ишетмәве хәерле-

рәк үзеңнән алда авыл арасына гайбәтең кайтып ирешсә, хурлыгыңнан кая барыр җир тапмассың. Ул сүз кайтармады, хафасын сиздереп, Наиләгә күз ташлады. Наиләнең йөзе ертылган, күзе ят, гәүдә тотышыннан тәкәбберлек һәм кирелек чәчрәп тора иде. Сул тезен алгарак чыгарып, уң кулын бөеренә куйган хатынына астан карыйкарый ул тагын шырпысына тотынды. Наилә уе, җаны белән моннан шактый еракта йөзә иде. Ул сердәше Гөлнараны, аның әкрен-әкрен рухы сына барган җебек ирен күз алдына китерде. Гөлнараның бичара ире, мөгаен, аның Нәҗибенә охшагандыр...

Хатын-кызларның ирләренә ихлас тугрылыгына багышлап томтом китаплар язылган, тарих чоңгылларыннан бу тугрылыкка меңәрләгән гыйбрәтле мисаллар табып була. Бусы хак! Бер үк вакытта мондый нәрсә дә бар: хатын-кызлар яраткан ирләренең язмыш каргавына эләгеп, бичара хәлдә калуларын кичермиләр. Без, ир-атлар, ир бәхетсезлеккә юлыккан очракларда хатыннарыбыз һәрвакыт ярдәм кулы сузар, дип ялгыш уйлап юанабыз. Дөньяда ничаклы хатын-кыз булса, аларның табигате дә шул санга бәрабәр. Бер-берсенә тулаем охшаган ике хатын-кыз дөньяда юк. Белегез, хатын-кызлар кыен килгәндә җебеп төшкән ирләрен аямыйлар, кичермиләр, йомшаклыкны гафу итмиләр. Алар моны алдан уйлап, әзерләнеп эшләмиләр, аларның ходай бирмеш холыклары тумыштан шундый, уй сөрешләре шулай корылган, ир өчен җайсыз мизгелләрдә алар ирне сынарга, йә аны чыныктырырга, йә муенсыз калган ирне бөкләп аяк астына салырга тиешләр. Наилә ирен аяп, аны җәлләп һәм яклап, ялгышхаталарына аклау табарга тырышып яшәмәде түгел, байтак яшәде, байтак түзде. Ләкин аның кан тамырларыннан тулышып аккан канның составы үзгәреп килә иде инде...

Саламга төкереп, бушаган шырпы кабын тотып тондыргач, Нәҗип үзен гаепләмәде, бәла-казаларының асылын дөньяга сылтады, тормыш шартларын каргады, юньле трактор чыгара алмаган эшчеләргә дә эләкте, юл салучыларның ата-бабаларына бер-ике татлы сүз юллады, ахыр чик, Наиләсе алдында гөнаһсыз күренергә омтылып: «Шушы якның каһәр суккан юлларын күрмәс өчен дә кайтмадым мин авылга! Авылның каргалган язмыш кичерәсен сизенгәнгә калдым мин шәһәрдә!» — дип сукранды. Нәҗип хәләл җефетеннән, әлбәттә, юату, теләктәшлек сүзләре көтә, уртаклыкка өметләнә иде. Ялгышты. Наилә аның туган авылына кайтып баруын, чирле икәнен, төшеп калган тәгәрмәчнең һич гаебе юклыгын бер кавымга онытты. Шушы зәһәр җилдә, хатынын, ике баласын җылытырлык та әмәл таба алмаган ирне гел-гел гафу итеп буламыни? Юк, андый ук төгәл фикергә барып җитә алмады Наилә, әмма аның хәзерге яман мәлдә кемнәндер ачу аласы, кимсетәсе, үзеннән дә, үз хәленнән дә түбән итеп күрәсе килде.

«Ә син, акыллы баш, шәһәрдә яшәп ни кырдың? — дип кадады ул.— Юньле кешене дөбердәтеп эшеннән кумыйлар. Юньле ир атаанасы, туганнары белән дошманлашмый. Юньле ирнең абруйлы дусишләре була. Юньле ир хатынына елга бер күлмәк яңартырлык булса да акча эшли! Дачасы була аның, квартирасы, машинасы! Ниһаять, юньле ирнең, «псих!» дип келәймә сугып, кала буйлап кара данын чәчмиләр!.. Юньле ир, хатын-балаларын интектереп, акылдан шашканнар белән, наркоманнар, азгыннар белән янәшә, җүләрләр арасында сары йортта яшәп ятмый! Без шәһәрдән качып кайтып барабыз! Безне монда беркем көтми. Көтсәләр, пычрак арбада, сөт бидоннары белән тарткалашып, шашкан җилдә аягүрә кагаеп кайтыр идекме? Балаларга тагын суык тиячәк. Горчичниклар, дарулар, йокысыз төннәр. Аны син карамыйсың бит, хәсрәт, барыгызны да мин карыйм. Мин!»

Булдермәде Нәҗип, колак төбеннән выжлап исеп торган җил хатынның бер сүзен дә урламады, алып китмәде, күтәрергә хәле булмады җилнең, сүзләр аның колак бөтеркәсенә авыр чуер ташлардай шыбырдап коелдылар, катлам-катлам булып күңел түренә тыгызланып утырдылар. Берәр заман аларны таратыр, котылыр көн булырмы?!

Наилә, тонык күз яшьләре каплаган күрмәс күзе белән Ирнә үзәненә карады, кичке кояш нурларыннан алсу, сыек төсләргә манчылган болынга кара пута булып яткан юлда Мөнир күренми дә диярлек иде.

Ниһаять, Нәҗип телгә килде. Халисә ишетмәслек итеп, теш арасыннан сытып соравын чыгарды: «Ни әйттең син, явыз хатын? Ни дип син минем талкынган җанымны ашыйсың?!» Наиләнең давылы басылмады: «Бүтән нәрсә беткәч, хатын ирен ашый башлый!» — диде ул чатнатып. «Син минем үткер хәнҗәр тотып, юлбасар булып тар тыкрыкка чыгуымны көтәсеңме әллә?» «Алар кемнән ким? — дип дәвам итте мәсхәрәләп Наилә.— Әнә, Митя Шорохов, кесә карагы, бүр, ә күпме кешегә, күз алдыбызга игелек күрсәтеп яшәде». «Урлаган акчагамы?!» «Урламаган акчага берәр кеше яшиме бу заманда? Тирә-ягыңа бак, сукыр! Намуслы, гадел яшәгән берәүне тап! Гадел яшәр өчен син дәрәҗәгә омтылдыңмы? Син... син! Югары белемле, намуслы, ихлас кеше, карак Митя талап җыйган акча хисабына туган ягыңа кайтып бармыйсыңмы?!»

Наиләнең тоткасы сынды, бәйдән ычкынды, ул үзе дә моны абайлады, ләкин сүз — очкан кош, тотып кире кайтарырмын димә. Баягы аклык аклык булмаган икән әле, хәзер менә Нәҗип агарынды, ул кулларын килбәтсез бутап, ирен араларыннан сүз урынына күбек чыгарып, күзен акайтып хатыны өстенә чак кына ташланмады. Әле ярый эскерт төбендә әрләнгән казыган чокырга аягы батып егылды, эшләпәсе тәгәри барып сулы чокырга ауды. Халисәдән сагаю дәвере үткән иде, Нәҗип нәзек, әче тавыш белән: «Кайтмыйм мин авылга! Мондый хурлыкка түзәрем юк!» — дип чәрелдәде. «Хурлыкка калучы да, калдыручы да үзең. Мин моны сиңа әллә кайчан әйтергә йөри идем!»

Нәҗип: «Хатын сүзенә ияреп юлга чыккан мин тиле... Хәллехәлсез килеш авылга кайтып баручы мин җүләр... Хатынга сүз ирегә биргән мин дурак!» — дип әрнеп кабатлады. Иллә мәгәр, Наиләсе тыелмасмы дип авызын ачмады. Хатын-кызның буасы ир аркасында ерылса, беттең дигән сүз, ачуы ташып бетеп, күңеле тәмам бушанмаса, аның тыелачагы да, аны тыяр көч тә юк. Наиләнең шундый котырынган чагы иде. Ул үз-үзен белештермичә, елга булып аккан яшьләренә буыла-буыла, ир өстенә бар һәм юк гаепләрне өя бирде. «Кеше булган кеше әүвәлдә бүтәннәрнең кадерен белә. Синең ни кадерең булмады, кеше дә кадерләмәдең. Мине шушы кара көнгә төшердең, балаларны бәхетсез иттең. Ни дип искә алыр алар үткән гомерләрен? Сиңа ышанып кияүгә чыккан мин исәр... Сафуанов ни ялынды, идәндә тәгәрәп йөрде, өрмәгән җиргә утыртмам, җаныем, диде. Ә мин... Сапсыз балта белән агач егарга тотынган исәрне яр иттем. Күрексез гармун, чакмасыз мылтык син!»

Наилә Нәҗипнең йөрәк ярасына учлап-учлап тоз сипте: Сафуанов — Наиләнең беренче йөргән егете иде. Алар танышканда ул өтек кенә бер слесарь иде. Комсомолда җил куып йөрде, профсоюзда тәлинкә тотарга һәм түрәләр узган юлларны себерергә, эз калдырмаска остарды. Өлкә комитетына алдылар, инструктор. Бүлек мөдиренең докладларын, чыгышларын гел ул яза, диләр. Ышаныч казанган, тук, пәрәмәч чырайлы егет. Наилә яшь чагында аның курнус борынынnan, сул як казнасында өскә калкып чыккан тешеннән җай чыккан саен көлә иде. Беренче тапкыр аның исемен күккә чөйде. Түгелергә

торган чиләккә бер тамчы су җитә, чиләк тулды, тулышты һәм ага башлады — Нәҗип эһ тә итмичә арба өстенә сикереп менде, бүктәрләрне, әйбер-караларны берәм-берәм юл кырына тондырды. Кан баскан күзе Зәй ягыннан шуып килгәндәй кыймылдаучы Мөнирне шәйләп алды. «Кайта! — диде ул. — Кайтып килә теге!» «Кайтамы?» — дип тотлыкты, баядан бирле өзмәс очкылык тота башлаган Наилә. Һәм пычракта кадерсезләнеп яткан әйбер-караларын кире чөйде. Нәҗип карышмады, юлның котсыз бушлыгы, салкын офыкка егылып барган май кояшының җансызлыгы, чит хатынга сеңеп йокыга талган чирле ике сабые аны тыйды, ачуын яшерергә мәҗбүр итте. Кая барасың? Кая бара аласың?! Төптәнрәк уйласаң, Наилә бай-так яктан хаклы. Тик нигә ул гаепләү актын хәзер, өметсезлек тулган юлда, хәсрәт диңгезенә батып барганда игълан итте соң?!!

Нәҗип арбадан җиңел сикереп төште. Наилә кулыннан плащын тартып алып, җиңнәрен туры китерә алмыйча сүгенеп, сажин салasala Мөниргә каршы китте. Яхшы булды: әллә кайда, җәһәннәмдә төшеп калган тәгәрмәчне күтәреп килә-килә егетнең иңбашлары чиләнгән иде.

Мең газап белән тәгәрмәчне көйләделәр, киттеләр. Ир белән хатын арасы көйләнмәде. Гаиләдә торымнан-торымга була торган ызгыш-талашларның сәбәбе кайчакта онытыла, чөнки ир-хатын еш кына бөтенләй сәбәпсез ызгышалар, ә талашу урыны күңелгә уелып кала. Бу гауганың урыны истәлекле — эскерт төбе, тычкан исе чәчеп яткан салам өемнәре, буп-буш шыксыз юл, салкын кояш, зәһәр җил күзе булды.

Озакламый җилнең канаты салынды, көн суытты, кояш Кашка тау маңгаен каплаган куе нарат урманының эзмәнкәле очын сыпырып үтте, төссез, яшь ай урагына үрелергә чамалап, азгын бер йолдыз кабынды, аңа икенчесе иярде, йолдызлар зәңгәр күктән кара ашъяулык текteләр, юлаучыларны тагын да каушатып төн килде. Ай яктысы әле саран, йолдызлар ишәйсәләр дә, алардан коелган нурда сәйлән җыярлык түгел, юл күренми, язын-көзен казылган хыянәтчел чокырларга майлы су тулган, тигез җирме, түмгәк-кантарлымы — белеп кара, баралар ава-янтая, баралар, бәла-казаларның азагы булыр сыман күренми.

Ике-өч сәгать «Бетәбез, менә авабыз!» — дип кан калтырап кайта торгач, билгесезлек пәрдәсендә сыек кына утлар җемелдәште. Нәҗип сәфәрләренең азагы якынлашуын, дөрес чамаласа, Югары Авылның Яңа урамына җитеп килүләрен аңлады. «Дөнья елмаерга маташа сыман», — диде ул, сүзен төрлечә аңларлык итеп. Ул Наиләсенә карамаска, аңа якынлашмаска, кагылмаска тырыша иде. Аны өзмәс бер сорау кыйнады: мондый хәлдә киленне ата-ана йортына ничек итеп алып керергә? Шалтырап, дөнья сасытып кайтып кергән ул белән киленне картлар ничек каршылар?

Урамга кергәч, трактор озак бармады, туктады, тынды. Тавышка уянган авыл маэмайлары, ялкау авазлар биреп, бер-берсен искәртәләр, бәла-каза килсә, ярдәмнәрен дә ышандырдылар.

Тездән лай ера-ера, су чупырдатып, арба янына Мөнир килеп басты. «Итәкләрегезне күтәрегез, балакларны сызганыгыз, тотынатотына төшегез. Халисәдән балаларны берәм-берәм алырсыз. Бездән башка Югары Авылның югары очына менә алмассыз. Без сөйләштек. Халисә белән атаңнарга озатып куярбыз». «Һи-и, хәзер үрмәләп тә менеп җитәбез югары очка!» — диде Нәҗип, арбадан төшә-төшә. «Урам аша үтәрлек түгел», — диде Мөнир, Наиләгә төшәргә булышып. «Мөнир, ындыр артлатып меник!» — дип кычкырды Халисә. Ул кычкырган тавышка уянган малайлар көйсезләнә, шыңшый башладылар. Наилә, туфляларына саз тулганны белсә дә, алар янына

ашыкты. Йокысыннан айнымаган Рөстәмне әтисенең иңөстенә меңгерделәр. Искәндәрне Наилә җитәкләде. Велосипед, вак-төяк бөктәрләр Мөнир белән Халисәгә калды. Аяк астында су чупырдады, алдан гайрәт белән юл күрсәтеп Мөнир бара, аңа Халисәсе тагылган. Алардан калмаска тырышып, кунаклар караңгылыкның күзенә кереп баралар. Җеп өзәрлек хәлләре калмыйча, Югары очка менеп җитеп, тыкрыктан Йосыф карт ихатасы турында үтеп капка келәсенә тотынсалар, капка эчтән бикләнгән булып чыкты. «Гомергә капка бикләмәгәнне ни булган боларга?» — диде Нәҗип кабынып. Наилә дәшмәде. Мөнирләр кайтырга ашыктылар: «Бездә дә ике бала!» — диде ул. Халисә: «Берсе имидә... Күкрәкләрем яман шеште, чыдар әмәлем юк!» — дип түшен тоткалады. Мөнир: «Өсләреннән бикләп йөрибез, бакча-мазар юк, күрше әби күз-колак булгалый. Эзигә бармас идең, ачтан үләргә кирәк, ипи кайтармыйлар, он сатмыйлар, тегермән буасы киткәнгә күпме гомер узгандыр!» — дип, кайтучыларга әзрәк аңбелем бирде.

Нәҗип-Наиләнең үз кайгылары онытылды, юлдашларын җәлләделәр. «Көне буе ими капмаган сабый ничек түзде икән?» Ә монда аларны озатышып йөрделәр. Кунаклар авылдашларына чын күңелдән рәхмәт укыдылар. «Яхшылык җирдә ятмас»,— диде Нәҗип, нидер вәгъдә иткән сыман. Озатучы мәрхәмәтле җаннар китүгә, караңгыда шүрләүчән Искәндәр нәни йодрыклары белән капканы төяргә тотынды. Эчтә мыдыр-мыдыр сүз алышкан тавышлар ишетелде, ут кабыздылар, тәрәзәдән сүрән агылган яктылык капка төбен дә әз-мәз яктыртты, ишек шыгырдады. Авыр аягын шудыртып, кемдер капкага якынрак килде, эндәште: «Кем йөри анда?» Әнисенең тавышы! «Без идек бу, әни! — диде көтелмәгәнчә йомшап Нәҗип.— Без кайттык». «Ай ходаем, улым, син мени?»

Ишегалдында хәрәкәт көчәйгәндәй булды, болдыр ягыннан: «Әллә балалар кайтканмы?» — дигән хәлсез сорау ишетелде. Әниләре капкага аркылы салынган, баш-башлары тимер җәяләргә кертелгән бастырыкны тартып чыгара алмыйча интекте, ниһаять, капка ачылды, иңөстенә шәлен салган, ак күлмәкле әниләре, ак ыштан балакларын салындырып болдырда басып торган әтиләре күренде. Карт таякка таянган, сул кулын каш өстенә куйган, бөтен гәүдәсе суыктанмы, каушауданмы дер-дер килә иде. Күлмәк сәдәбен каптыра алмыйча азапланган әнисе арык куллары белән улын кочып алды. «Әби, мин сиңа күчтәнәч алып кайттым!» — дип, олы уллары Искәндәр суыра-суыра чәнти бармак башы хәтле генә калган конфет кисәген авызыннан алып әбисенең учына салды.

## 18

«Җиде бабаңны бел!» — дигән татар. Бу бездә иң олы васыять. Шушы васыятьне бозып, татарлыкка хыянәт кылган мөртәтләргә: «Җиде бабаңны танытырмын!» — дип янаганнар. Җиде баба — җиде буын. Заманына күрә буыннарның гомере дә, багланышы да үзгә булган. Йосыф картның әтисе Сәхәбетдин, бабасы Нургали. Хәтерли әле Йосыф, онытмый, әтисе белән бабасы бер кулның бармаклары булып яшәделәр. Тел уртак, дин-иман бер, бер төбәктә, бер теләктә саф татар карьясында гомер кичтеләр. Тормыш бер төслерәк аккан, гореф-гадәтләр, тайпылышсыз үтәлергә тиешле кагыйдәләр буыннан-буынга күчә барган, яшәү нигезе булып әнә шулар хезмәт иткән. Дин — милләтнең таянычы. Рус мәмләкәтенең уртасында торып калган татарларны милләт буларак тел-ил берлеге генә түгел, ислам дине дә яшәткән, аларны оештырып тоткан, милли рухны саклаган. Иван Явыз Казанны яулап алганнан соң да күпме кимлекләр, жә-

бер-җәфалар күрсәләр дә, татарлар милли йөзләрен югалтмаганнар, чөнки дин яшәгән, дин саклаган. Дин халыклар күңеленә яктылык иңдергән, белем, гыйлем китергән.

Татарның һәр очракка ярашлы бер тапкыр сүзе, мәгънәсе тирән фәлсәфи тапкыр мәкаль-әйтемнәре булган. «Ата-хакы — тәңре хакы», дигәннәр олылар, газиз ул-кызларының башын сыйпап. «Идел йорт — имин йорт»,— дип беркеткәннәр.

Әй, Идел йорт, Идел йорт,
Идел эче имин йорт,
Атам кияү булган йорт,
Иелеп тәгъзим биргән йорт,
Анам килен булган йорт,
Иелеп сәлам биргән йорт,
Кендегемне кискән йорт,
Керем, куным юган йорт!

Бәрәкәтле Идел йортка, татарларның алтын бишегенә багышлап ата-бабалардан күпме акыллы сүзләр, тәгъбирләр, мәкальләр калган. Тагын бик күп, бер караганда гади, әмма тыгыз эчтәлекле законнар буыннарны буыннарга ялгаган, нәселдән тамырга җырлар тапшырылган, тел бизәкләре, язгы күркәм уеннар, «Кырау куулар», «Нардуганнар» күчкән, мөнәсәбәтләр, кардәшлек чылбырлары, мәхәббәт кануннарында нидер үзгәргән, нәрсәдер кимегән, нидер өстәлгән, әмма Идел йортка самими мәхәббәт, туган телне олылау, бер-береңне ярату, хөрмәт хисләре Бөек Болгар заманыннан ук халкыбызда үзгәрешсез кала килгән. Татарлар гаделлекне, пөхтәлекне, чисталыкны яраткан, эш, кәсеп, һөнәр сөйгән, «илләр талап түгел, җир тарап» тамак туйдырганнар. Халыкта тәртип-низам нык булган. Ил агалары, аксакаллар, укымышлылар, дин әһелләре өчен халыкны гадел юлда тоту артык мәшәкатьле дә булмаган, чөнки татарлар урлашмаган, хатын аермаган, хәрәм суларга баш бирмәгән, сасы америка тәмәкесен йортына якын җибәрмәгән. Ишеген бикләмичә, капкасына тирәү салмыйча, теләгән җиренә чыгып йөргән татар, күңеле ачык булган, ул юкта йорт-җиргә, мал-туарга ихлас күрше-тирәләр күз вә колак булып торган. Бер-берсен яклый белгәннәр, татар дөньясына яңа кеше — бәби килгәндә тыйнак сөенгәннәр, ходага гыйбадәт кылганнар, кеше вафат булып, бакый дөньяга китеп, мәңгелеккә рихләт әйләгәч, сабыр кала белгәннәр, бәйрәмнәрдә акырышмаганнар, кайгыда үкерешмәгәннәр, мәгәр «сабанда сайрашканнар».

Күп гасырлар шулай яшәгән татар. Галимнәрнең исәпләве буенча, ислам кабул иткәннән соң Идел-Чулман-Нократ тирәләрендә яшәп йөз илле миллион татар мәңгелеккә күчкән.

Йосыф картка җиде бабасының җылысы әле килеп җиткән, гомер елгасы бабалары салган эздән аккан, артык болганмаган, бусагалар, таш кыялар очрап уңга-сулга сикермәгән, татарның үзе кебек сабыр һәм мәһабәт булган. Йосыфка килеп җиткәч, тормыш кинәт үзгәргән, ил, дин, җир тоткаларын — авылның иң тырыш, иң уңган гали затларын ерак Себергә, эт җиккән якларга үләргә сөргәннәр. Фин, Ватан сугышы чыгып, асыл ирләрнең сөякләре чит кырларда чәчелеп калган. Сугыштан соңгы афәтле елларда, ата улны, ана кызны белми торган болганчык дәвердә, кешеләр авылдагы җәбер-җәфалардан туеп, күпләп-күпләп татар җирен ташлап чыкканнар. Күпчелекнең күзе комсызланган, аңы томаланган, илгә рухи афәт, кансызлык иңеп, шәфкать, мәрхәмәт читкә сөрелгән. Татарның таянычы, гомер-гомергә сафлык чыганагы булган иманыннан колгадәткә кергән. «Татарлык — тарлык!»— дигән татарның наданнары. «Фи-и, татарның гомере бер саплам, бетә ул, бетә!»— дигән укыганраклар. Андыйлар көферлеккә иманнарын сатып урыс-улакка, чу-

ваш-мукшыга әйләнеп, гаиләләре белән, сахра дуңгәләре сыман, урыннан-урынга күчеп йөри башлаганнар. Күчеп йөрү — чегәннәргә килешә, ул аларның милли сыйфаты. Күчкән татар татар булудан туктаган, чит гореф-гадәтләргә баш биргәннәре: «Татар булып Рәчәйдә яшәү читен, ичмасам балаларым шуннан котылсын»,— дип, исемнәрен тузга язмаган кушаматларга алыштырганнар, дөньяны Айрат белән Марат баскан, Дездемоналар, Венералар, Альбиналар, Кларалар котырып үрчегән. Авылда татар карчыгы ике-өч яшьлек сабыен җитәкләп урамга чыккан: «Диздимуны, танавыңны сөрт!» Тефү, нәләт...

Шундый кырлы-мырлы, имансыз дәвергә туры килгән Йосыф белән Мәрьям татар дөньясына уллар да, кызлар да китергәннәр. Элеккечә булса, бер оя булып, гореф-гадәтләрне саклап, телгә тугры калып яшиселәр иде дә, дөнья бозылды, авыллар таралды, халыклар чегәнгә әйләнде. Авыл — ятим картлар, карчыклар гына сыярлык караңгы, фәкыйрь төбәккә әверелде. Картлар, әҗәл килгәнне көтеп, балаларыннан алган открыткаларына куана-куана, үткәндәге хатирәләрне сагынып, бабаларыннан килеп ирешкән риваятьләрне ятлыйятлый җан сакладылар.

Йосыф белән Мәрьям дә, бил турайтып ял итәсе урында, үзләрен генә түгел, туган-үскән җирләрен мәңгегә ташлап киткән балаларыда ризыкландырырга мәҗбүр ителеп, ызан белән түтәлдән баш калкытмыйча интегәләр иде. Тәмуг газаплары күрде авылның бер буыны! Ничә еллар дәвамында бәйрәмнәрдә дә аларның ял иткәннәре юк. Кырым-Кавказларны, шәһәр дачаларын күз алдына да китерә алмыйлар. Җәен-кышын дөньяның аянычлы авыр йөген һаман тарталар. «Американы куып җитеп, узып китәргә» боерык алган бичаралар тәмам бөлгенлеккә төшкән илләрен каннарын биреп яшәтергә мәҗбүрләр. Алар гаделсезлекне сизеп, үзләренең күрәләтә коллыкта яшәүләрен аңласалар да, авыз ачып сөйләшмиләр, телнең юл азагы хәерсез икәнен беләләр! Югары Авылдан утызынчы еллар башында ничә гаиләне туздырып ташладылар. Утыз җиденең ноябрендә мәктәп директоры Хәернасны юк иттеләр. Хәернас артыннан мәктәпкә педтехникум бетереп эшкә кайткан ике яшь егет — Хәй белән Фаез юк булды. Авылның сөйкемле хәзрәте Юныс картны төн уртасында җылы түшәгеннән торгызып алып чыгып киттеләр дә, шуннан: «Алабуга төрмәсендә атканнар икән»,— дигән шомлы хәбәре генә кайтты. Туксәнне ашкан бичара картның ни гаебе булды икән?! «Хәернасны күп белгән өчен, яшь укытучыларны күп сөйләшкән өчен юк иттеләр»,— дип гөман кылды куркынган халык һәм бик озак елларга телен тешләде. Йосыф үзеннән бигрәк балалары өчен курыкты, төрмәгә тыкканнарның бала-чагасына да шәфкать күрсәтмиләр икәнен ул күз алдындагы байтак гыйбрәтләрдән күреп инанган иде. Яшәде — дәшмәде, нужа басса да, ыңгырашмады, кайгысын читкә чыгармады, авыл куштаннарының һәммәсенә бил бөгеп сәлам бирде. Казый итеп куйсалар, ата казга да сәлам бирәсең!..

Еллар үтә торды, ничек тормыш корырга, ничек яшәргә, авыл арасында гадел хөкемгә ничек ирешергә кирәклеген Йосыф карт бер баласына да тапшыра алмады, алар күз алдында комга чәчрәгән су кебек әллә кая, читкә сеңеп беттеләр. Ат җигәргә өйрәтә алмады ул аларны, балта эшенең нечкә серләрен тапшырмады, уллары белән еракта калган бабалары хакында гәпләшеп әчен бушатмады. Аның күргәннәре, белгәннәре беркемгә дә кирәк булып чыкмады. «Берәрсе кайтып килерме?»— дигән яшерен өмете дә учак төбендә пыскып, сүнәр-сүнмәс кенә ята иде инде.

Моннан дүрт ел элек Йосыфның хәле китә башлады, мунча ләүкәсенә менмәде, төз лапас өстеннән малга печән ыргытмады, башы

әйләнде, ике-өч тапкыр кан косты. Шиккә калдылар. Колхоз рәисе аны бик авырлык белән Эзи больницасына каралырга җибәрде. Унике чакрым араны карт җәяүләп бик әкрен үтте, ул көнне больница чиратына эләгә алмады. Шунда, больница баскычы төбендә кунды, иртән беренче булып врач катына керде. Соколова фамилияле, йомшак телле, олы зәңгәр күзле бөкре врач карады аны. «Өч-дүрт көн ятырга туры килер»,— диде Вера Павловна. «Өч-дүрт көн? Эш өстендә кем рөхсәт бирсен миңа?» Чәрәеп карышты чирле карт. Вера Павловна да үзсүзле доктор иде. «Ятасың!»— диде. Картны юындырып, ак күлмәк-ыштан кигертеп, ят исләр аңкыган бүлмәгә кертеп яткырдылар. Өч көн буе тынгы бирмәделәр дисәң дә ярый, үлчәделәр, тыңладылар, әйләндереп-әйләндереп карадылар, бөтен тамырларыннан кан алдылар. Йосыф: «Кайтам, кайтам!»— дип дулагач, дару, киңәшләр биреп озатып калдылар. «Тагын киләсең булыр!»— диде картның кабалануының сәбәбен һич аңламаган Вера Павловна.

«Килмәм, алла кушса, терелдем»,— дип чыгып киткән Йосыф ярты юлда кан косып туктап калды.

Рәис хәтәр кеше иде, элек райкомда эшләгән дә, гаеп-кыегы чыгып, аны иң фәкыйрь колхозларның берсенә баш итеп җибәргәннәр. Җәзасы шул булган...

Ул больницадан кайтып килүче картны ал байраклар җилфердәгән урында, идарә янында каршылады, врач биргән язуны ертып ташлап: «Әгәр иртәгәдән эшкә чыкмасаң, бәрәңге җиреңне кисәм, малларыңны кырга чыгартмыйм»,— диде. Канын космады бу юлы юаш карт, канын йотты, җиңе белән иренен сөртте, икенче таңда колхоз көтүен кырга алып чыкты. Сыер көтә иде ул елны Йосыф. Ала-кола сыерларны иркенгә, Тегермән тавы итәгенә тараткач, хәл таба алмыйча, төнлә сибәләп үткән яңгыр дымландырган чирәмгә утырып, авызын учы белән каплады. Иртәдән бирле аңгырайтып торган башының әйләнүе кимеде, чишмә авызына барып битен-күзен чылатты, битен талгын җилгә куеп торды. Берзаман сыерлар шомыраеп, мөгезләрен күккә күтәреп, бер якка савылып күчә башладылар. Йосыф аны-моны абайлаганчы күпчелек сыерлар мөгезләрен усал чайкап, тояклары белән җир тырнадылар, яшьрәк маллар койрык чәнчеп ферма ягына томылдылар. Малларны туктатыйм дип, юк тамагы белән кычкырып, хәлсез кулы белән таяк болгап торган карт каршысына төлке килеп чыкты. Аның йоны иеп сирәкләнгән, пычрак койрыгы җирдән сөйрәлә, бер колагы башына ябышкан, тешләре ыржайган, авызыннан туктаусыз сары селәгәй ага иде. Куркудан Йосыфның кыска таягы җиргә төшеп китте, каушады — төлкенең котырган булуында аның шиге юк иде. Яшьрәк маллар качып өлгерсә дә, күәс-күәс имиле нәселле терлекләр әллә кая ерак китмәделәр, зәңгәрсу томан белән өртелгән күзләрен алартып төлкегә карап туктап калдылар, кырда төлке күреп гадәтләнгән малларның исе китмәде. Төлке кинәт уңга ыргылды — бер сыерның җиленен каптырды. Сулга сикереп иң юаш, иң сөтләч сыерның сыйрагын тешләде. Йосыф карт хәтәр эшкә юлыкканын аңлап, иелеп җирдән дәү ак таш кубарып алды да төлке өстенә таба китте. Төлке аңа каршы сикерәм дигәндә, көч каян килгәндер, ташны төлкенең ике күз арасына тондырды. Туры тидерде, төлке бер урында әйләнергә, шыңшып чинарга тотынды. «Әһә, тәмсезме?!»— дип шатланды карт. Икенче таш тимәсә дә, төлкенең аяк арасына лапылдап барып төште, төлке ырылдап артка чигенде. Бая сыйрагы тешләнгән сыер, хуҗасына ярдәм кирәклеген сизепме, алагаемга чабып китте, шашкан җанварны мөгезләре белән элеп чөеп тә җибәрде. Өченче ташны кубарып маташкан Йосыф карт күтәрелеп караса, төлкедән җилләр искән...

Котырган төлке монда килешли күрше авылның сарык көтүе

уртасына чабып кереп, байтак хайванны яралаган икән. Күршеләрдә мәргән күзле атаклы сунарчы бар иде, хәлне аңа җиткергәннәр, ул җәлт әзерләнеп эз буйлап чапкан һәм бер атуда «төлке-төлке төләймәнны» атып еккан. Аны шунда, тау кашлагында күмгәннәр дә...

Күрше авыл сарыклары мәзәкләнә башлауга, шау-шу куптарып, төлкене казып алып, башын кисеп, самолет белән Казанга җибәрделәр. Шул ук самолет белән башкаладан биш кешелек комиссия килеп төште. Алар килгәнче Йосыф көтүендәге сыерлар да котыра башлаган иде инде. Сыерлар яман мөгрәп, нык абзар-кураларны ватып-җимереп, биек-биек киртәләрне сикереп чыгып, кем күренсә шуны куа, бер-берсен канга батырып сөзәргә тотындылар. Авыл халкы нишләргә белмичә хафада калганда, комиссия котырган малларны атарга, үләксәләрен яндырырга боерды. Чирле, шикле хайваннардан котылгач кешеләрне карар чират җитте. Кемнәр төлке кагылган мал-туар белән аралашкан да, кемнәр сөт эчкән, кемнәргә чир йоккан булуы ихтимал. Котыру авыруының шндый хасияте бар икән: вегетация чоры, ягъни башлангыч дәвер үтеп китсә, беркемне коткарып, саклап калып булмый икән!

Сөт эчмәсә дә, сыерларда мәзәкләр күренүгә, Йосыф карт аларны тотып ябарга, муенчак, тышау салырга азапланган иде. Аны көнесәгате белән Эзи больницасына салдылар, казанлылар тиешле күләмдә гамма-глобулин да, Сирия әрләненең бөереннән ясалган махсус дару да алып килгәннәр иде. Йосыф картны бу юлы да Соколова каршы алды. Үзгәргән врач, йөзенә курку чыккан, тавышы корыланган, ул Йосыф картның нужадан бөкрәйгән аркасын элеккечә кагарга бер дә ашыкмады.

Алты сәгать саен кададылар Йосыфка уколны, икеләтә арттырып кадап карадылар, картның хәле сәгатьтән сәгатькә начарланды, тамыр тибеше югалыр дәрәҗәгә җитте. Җирле табиблар да, Казан белгечләре дә аптырашта калдылар. Соколова көне-төне карт янынннан китмәде. Йосыфның йөзеннән кан качты, яңак сөякләре бүлтәеп чыкты, сулышы өзелеп-өзелеп алды, басымы бер өскә сикерде, бер төшеп китеп, югала язды. Картның организмында табиблар белә алмаган нидер бар, аңа электән килгән чирләр куркыныч яный, диген шиккә килделәр. Вера Павловна үткәреп ни дә әйтә алмады, теге чакта ярым-йорты ясалган анализлар, картның сүзсезлеге, чирен эзләшергә булышмавы икеле-микеле фаразлардан ерак алып китмәде. Антирабик уколларны туктатырга, картның әүвәлге чирләренә борылып кайтырга туры килде. Бу юл хәтәр, хәвефле иде: элекке чирләрен эзләп төпченгән арада котыру чире бөтен нерв системасына үтеп керсә?

Нидер сизенгән, шикләнү генә түгел, курка ук төшкән колхоз председателе Соколованы аерып алып сораштырды. Вера Павловна: «Әллә Нургалиевне агулы ашламалар тирәсендә артыграк тоттыгызмы?» — дип сорагач, карасына коелып чыгып китте.

Мәрьямбикә дә картын юллап барды. «Хәле әйбәтләнә, әлегә янына кеше кертергә ярамый»,— дип, аны борып чыгардылар. Колхоз рәисе: «Сез аның кем атасы икәнен беләсезме?! Терелтегез!» — дип боерып киткән иде, Йосыфны райком секретаре дәвалана, ял итә торган палатага күчерделәр һәм көне-төне күзәтү астында яткырдылар. Кризис үтте, котыру чире килмәде, өзлегү сәбәпләре һәммәсе өчен сер булып калды. Өч ай ярым дигәндә аны больницадан чыгардылар. Әле өй арасында йомышка юлга ярап торган, колхоз көтүенә чыгарлык хәлле кеше булып киткән Йосыф больницадан күзе, колагы һәм хәтере начарланган инвалид булып кайтып керде.

«Бар, йөр, карал, группа бирерләр!» — диде аңа авыл укытучылары. Йосыф башын чайкады, һич нәрсәгә исе китмәде, бирсәләр — ашады, бирмәсәләр — ач карынга ятып йоклады. Берни белән кызык-

сынмады, сорашмады, башыннан кичергәннәрне телгә алмады. Балалары хакында әлек сөйләшмәскә тырышалар иде, хәзер алар бөтенләй телдән төште, онытылды. Картның бердәнбер юлдашы һәм сердәше булып чикләвек агачыннан ясаган шома таягы калды. Йоклаганда караваты кырына куеп ятты, йорт-курага чыкканда да алды, үзеннән калдырмады.

Истә-оста югында, инде дөнья белән бәхилләшәсе сәгать сугар дип мыштырдаганда, төн уртасында капка кактылар...

«Кем? Газраилме?» Түгел икән, ата-анасының хәер-фатихасыннан йөз чөереп чыгып киткән, ике еллык солдат хезмәтеннән соң да туган төягенә кайтып баш имәгән горур, тәкәббер, һавалы уллары Нәҗип кайткан икән.

Мәрьямбикә эссе табага басты, тыпырдый, очына, оныкларының әле берсенең, әле икенчесенең аркасын барып кага, ни кылырга белми, башы тәмам миңгерәүләнде... Йосыф карт төнге ыгы-зыгыга да гадәтенчә битараф калды, кайтмадылармы — кайтмадылар, кайткannар икән — әйбәт иткәннәр. Бер ара ике яктан да сораулар ишетелгәләде, әмма ләкин бу сорауларга җавап бирелмәде, кунаклар да, хуҗалар да җавапларны аңларлык хәлгә бик озак килә алмадылар. Әбиләре туктаусыз: «Менә син, агай! Менә син, агай! — дип кабатлый да, йөзенче кат: — Ничек кайтасы иттегез?» — дип сорый.

Бер-берсенә күз иярләшә төшкәч, очрашу үз сукмагын тапты тагын. «Үзегез ни хәлләрдә яшисез?» — диде Наилә, Рөстәм кулыннан күмәчле төенчекне сиздерми генә тартып алып. Карчыкның күз яшьләре кипте, аңа эшлекле кыяфәт кайтты, тиз арада киеп алган терсәкләре кат-кат ямаулы күлмәгенең җиңнәрен сызганды. Җиң сызганса, татар карчыгының рәте-торышы үзгәрә. Наилә җиңе сызганулы әнкәсенә карап: «Балаларны юындырып аласы иде, әни. Аларны урынга яткырырлык түгел», — диде. «Күршеләрнең мунчасы суынмагандыр әле», — диде Йосыф карт, зиһене таралган карчыгын коткарырга теләп. «Килен! — дип кычкырды биана, ике кулына бер эш табылуына куанып. — Әйдә, барыйк. Үзең дә юынып чыгарсың». Бөктәр чишеп маташкан Наилә: «И, шулай итикче, монда чупырдап ятканчы, мунчага барыйк», — дип, әнисе сүзенә кушылды. Күчтәнәчләрне хәзер бирергәме, дип иренә карады да, аның җан кермәгән карашын очраткач, нәрсә-караларны җыештырыбрак куйды. Матавык арасында эш табылгач, биана да, килен дә бер мәлгә җиңеләеп калдылар. Наилә Рөстәмне күтәрде, әбисе Искәндәрне җитәкләде, алар «ә» дигәнче күздән юк булдылар. Нәҗип этисенең сүзсезлегенә, сорашмавына башта гаҗәпләнде, аннан рәнҗеде, соңра кызганды: айһай, дөнья картны сыккан икән! Тавышлар басылып, төнгә, йортка гадәти тынлык кайткач кына, Йосыф төссез, тәмсез тавыш белән: «Мунчага күршеләргә йөрибез», — дип сүз катты. «Үзегезнең мунча ярамыйммыни?» — дип, җимне эләктереп алды Нәҗип. Әтисе, таягын идәнгә шакылдатты: «Шулайрак, — дип ачыклады. — Түбәсе ишелде, улым». «Кайчаннан?» «Дүрт ел буладыр инде, — диде карт күңеленнән озак кына санап. — Юк, бишкә үк киткән икән». Картның бот арасына кыстырган таягы идәнгә төшеп китте, ул таякны куып тотарга теләп талпынды, ала алмады, йөткерде, тыны бүленде. Нәҗип таякны алып биргәч тә тиз генә игә килә алмады. Аларның күзләре очраштылар. Күзенә карап ул әтисен танымады, кашы коелган, керфекләре сирәкләнгән, кабаклары җепшеп салынган күз тонык һәм җансыз иде. Борын яфракларыннан ирен читләренә тирән-тирән җәя — нужа бураззалары яткан. Муены, ияге, күптән сөрелмәгән ташландык кыр сыман, ак-сары төкләр белән капланган. Гел күгелҗем таплардан гына торган кул тиреләре аша юан-юан кан тамырлары бүлтәйгән. «Сабит кайтып мунча түбәсен дә ябып китә алмаган икән!» — дип

уйлады Нәҗип рәнҗеп. Карт тонык, җансыз күзләренә көч бирергә теләп астан өскә, аның күзләренә озак кына карап торды.

Әтисенең сүзсез серлелеген, өй эченең моңсулыгын арттырып мич артыннан чикерткә тавыш бирде. «Мунча түбәсен Сабит яба алмый идеме?»— диде Нәҗип, бүтән уйны башына китерергә теләмичә. «Каян вакыты булсын аның? — диде карт.— Колхозы алдынгы, андый җиргә кунак арты кунак ташыйлар. Казаннан да киләләр, имеш, Чаллысы якын, Мәскәүдән дә сыйланырга киләләр, ди. Әллә ялган, әллә чын: хәзерге заман кешеләренең авызы ашаганда гына ачыла, имеш. Беркөн, Мәскәүдән кайткан олы кунакларны да абыеңа алып барганнар, дип сөйләп тордылар. Кем сөйләгән иде соң? Анысы истә калмаган, гөнаһ шомлыгы. Хәбәрләр йөри, сирәк-мирәк безгә дә килеп җитә, үзен бик куптәннән күргән юк. Хәзерге рәисебез — Сабит эшләгән авыл кешесе, шуннан килде, мәгәр аның безне саннап кергәне юк». «Яхшы кешеме рәисегез?»— дип кызыксынды Нәҗип. «Кем белгән аны? Хәзергеләр эшне шома йөртәләр, эт белсенме аның кем икәнен?!»

Әйткәнебезчә, Нәҗип Сабит абыйсы белән хат алышмады, бүтән туганнары белән дә арадашлыкны өзгән иде. Энекәшләр Сабитка ярарга тырышып, аның киңәшен тоттылар, икесе дә армия хезмәтеннән кайтмадылар. Берсе лейтенант погоннары таккач ук Ерак Көнчыгышта, Кытай чигендә калды, икенчесе кадерле төпчекләре, ата-ананың өмете, токымның варисы, марҗага өйләнде дә Мурманскида төпләнде. Өйләнгәннән бирле аның да күзгә-башка күренгәне юк. Сабит Нәҗипкә дә: «Кал армиядә, өс-башыңны дәүләт карый, тамагың тук, атом сугышы башланса, бу сугышта халык кырылып бетеп, армия генә исән калачак. Ә сугыш булачак! Америка империализмын себереп түкмичә, безгә якты көн булмаячак!»— дип язган иде. Нәҗип абыйсының киңәшен тотмады, аның үз исәбе бар иде.

Нәҗип localactырып-суктырып бүтән туганнарының язмышын белешкәләде, этисенә кыска-кыска сораулар бирде, картның белгәне дә әллә кая барырлык булмады. Йә сорауны ишетмәде, җавап биргәндә дә җәелеп китмәде: «Исән-саулар бугай... Бәйрәмгә открытка салганнар ие, кайтканнары, күзгә-башка күренгәннәре юк».

Киткәннәр мунчада хәйран юандылар, этисенең табынны караштырмавы, самавырга тотынмавы гаҗәп тә, ачу китергәч тә иде. «Кеше юлдан тук кайтамыни?»— дип пошынды Нәҗип, балаларын уйлап. Һәм уйлары таркау җыелмаган чакта: «Кайттык әле, көн булырбызмы, ай торырбызмы, җәйне монда үткәрербезме, ныклап ял итәргә исәп!»— дип ычкындырды.

Ах, шул сүзен ашыгып әйтеп ташламаган булсачы!.. Соңыннан бик нык үкенергә, тел очын чәйнәргә туры килде Нәҗипкә.

Карт бу хәбәрдән очынмады, иягенә терәгән таягы гына атынып китте. Шактый утырганнан соң: «Алай икән, алай икән»,— диештереп ияген какты.

Өйалдыннан тавышлар килде, ак сөлгегә биләгән иркәсен күтәреп Наилә кайтып керде, Мәрьямбикә күренде. «Йокым килә, урын җәегез!»— дип Искәндәр мыркылдады. Наилә Рөстәмен сәкедәге мендәргә илтеп яткыргач, самавырга барып тотынды. Мәрьямбикә Искәндәргә урын җәеп биргәч, күзен күтәреп карамыйча гына, табын әзерләргә керешә. Биана белән килен, ир-аттан башка гына очраша алуларына, танышуларына сөенештеләр. Мәрьямбикә карчык, улы югында, ишетмәгәндә Казандагы тормышларын бик җентекләп, вакчылланып сораштырырга, төбенә тоз салырга ашкынса да, Наиләнең капчыгы алай ансат кына чишелмәде. Ул бик гади генә: «Яшәп ятабыз шунда... Әле тормышның җайга салынып беткәне юк... Көйләнеп

кенә киләбез... Шәһәрдә ярдәм итәрлек якын кешеләрең булмаса, тернәкләнү читен...» — дип, шуларга вак-төяк өстәп, хәбәрләрен тәмамлап куйды. Нәҗипнең чирен дә, эшсезлеген дә, бүген юлда пычакка-пычак килеп талашуларын да әйтеп тормады...

Мәрьямбикә шәрә өстәлгә юа-юа чит-читләре чачакланган шакмаклы ашъяулык җәйде, чоланнан балчык чүлмәк төбендә калган сөтне алып керде, юка гына ике телем ипи китереп куйды, үзе бертуктаусыз: «Кайтырыгызны белмәдек шул, кайтырыгызны»,— дип кабатлады. Өстәлгә карап, аның шушы кыска җөмләгә никадәр чын мәгънә сыйдырганын аңлау кыен түгел иде.

Чәй кайнап чыкканны көтмәделәр, уяныр-уянмас яткан Искәндәрне табынга дәштеләр, сапсыз чынаякка сөт агызып, кулына ипи тоттырдылар. «Аша да йокларсың!» Малай телемне күз тирәсенә китереп карады да умырып капты. Гелен бер-ике әйләндергәч тә: «Тәмсез!» дип кычкырып җибәрде. Наилә аңа йодрык күрсәтте, ипинең ләчтәлегән, бармакка сыланып торганын ул күреп өлгергән иде инде. «Кайтырыгызны белмәдек шул, белмәдек»,— дип оялып тәкрарлады карчык. Искәндәр ипине чәйнәмичә генә йотты да тыгылган тамагын сөт белән юып җибәрде. Аны энесе янына, сәкегә илтеп яткырдылар.

Табын шулкадәр ярлы, арык иде ки, ашап тамак та, карап күз дә туярлык түгел иде. Нәҗипнең елыйсы килеп китте, күңеле тулды: «Бер түтәрәм каклаган казлары, бер йомарлам ак майлары да юк микәнни боларның?» — дип өзгәләнде. «Сыер асрамыйсыз, ахры?» — дип сорады Наилә, сер бирмәслек күтәренке тавыш белән. «Хак, хак, килен,— диде Мәрьямбикә карчык,— сыйлы көнең сыер белән, тик менә ни, казалы булдык, сыерыбыз үлде.— Аның иреннәре, өзелеп төшәргә теләгәндәй, калтыранды.— Бик олы казалы булдык. Өч кыш бер кәҗә асрап чыгардык, әнә биргән сөте шунда. Каймак-май күрә алган юк». «Кибеткә май кайтармыйлармы?» — дип сорады Нәҗип, аны-моны уйламыйча. «Кибеткәме? — дип сорады Йосыф.— Югары авылда сыер өч кешедә калды, бүтәннәр асрамый. Май кибеткә каян килсен? Завод торбасыннан май чыкмыйдыр ла?! Сыер асрар хәлләре булганнар авылда калмады, алар май-каймак ашарга калаларга күченеп бетте». Карчыгы аны куәтләде: «Егәре барлар юк хәзер, ходай кушкандыр инде, авыл таралды».

Сүзне ашау-эчү, табын тирәсеннән ераккарак йөртергә кирәклеген аңлаган кунаклар кабыл-тибел күршеләрне сораштыргандай иттеләр. Мәрьямбикә карчык Наиләнең әти-әнисе хакында белеште: «И дөньялар, кода-кодагыйлар белән күрешкән дә юк лабаса, ни булды икән безгә?» — дип җыламсырап та куйды. Картның йомык авызына ымсынып карап торгач, Мәрьямбикә карчык сүз җебен үз кулына алды. Югары очтан башлап Түбән очка кадәр өй борынча йөреп чыкты. Кем кайда, бала-чагалары ничек, кем өйләнгән, кем аерылган, кемнәр яңадан кушылган... Кемнәр былтыргы сабан туена кайтканнар да нинди бүләкләр, күчтәнәчләр тараткannар. Кемнәрнең оныклары кайда укый, кем булырга укый. Мәрьямбикә боларның барысын да белә икән, хәтере нык икән әле карчыкның. Бөтенесен белә, хәтерли, менә үз балаларына чират җиткәч кенә, аның сүз җебе шартлап өзелеп-өзелеп китте, сөйләр сүзе калмады. Ул яңадан Югары очка, күрше-каршыларга әйләнеп кайтты: «Күршең үзеңнән әйбәт икән — тормыш бара. Күршелеккә юньле адәм калмады. Өй аша Мостафалар бар иде, беләсеңме икән. Чүтинекеләр дип йөртәләр иде, шуның хатыны Гөлгенә бер чытыр арба печән урлап тотылып, өтермәнгә яптылар бичараны. Ул өтермәндә чакта Мостафасы Әзигә барып марҗага йортка керде дә алар әллә кая салкын якка чыгып олактылар. Өч ел үттеме икән, Гөлгенә өтермәннән кайтып төшмәсенме? Үзе генә түгел, үзе сыман чәчрәп торган бер хатын алып кайткан, тегендә ахирәтләр булып, бергә ашап-эчкәннәр диме. Алагаем чуен-

дай кап-кара, татарча бер авыз сүз белми, якут диме, макут диме, бер дә пырдымсыз хатыннар булып чыктылар. Күрәләтә тавык урлыйлар! Ишегалдына кер эләрмен димә, шундук юкка чыга. Күз буалармыни, оядан күкәй югала. Элгәрге заманнарда капка бикләп, ишек элеп йөргән юк иде, хәзер кая ул, бетте. Чоланда он тормый, ярмаңны калдырмыйлар да калдырмыйлар. Тәнгә керүгә терәү салып, бикләнеп утырабыз. Морҗаңнан төшәрләр шонныклар! Бәрәңге утыртмыйлар, ындырларын бакра белән билчән басты, шепкән котырды. Төн туды исә бурлыкка чыгалар ярканатлар!» «Колхозда эшләмиләрме?» — диде Наилә сүз булсын өчен генә. «Колхузда? Сыер саусыннармы? Ул шөкәтсезләргә кайсы сыер сөт бирсен? Исләреннән косарлык... Тирес түксеннәрме? Түгәрләр, көт! Тамаклары ничек утәдер, урлаганнарын эчеп бетереп баралар». «Эчәләрме?» — диде Нәҗип, авызын учы белән каплап. «Һи, эчмәгән кая! Шешә төбенә кереп утыралар. Авылда эчмәгән кеше юк, аяксызы-к..сезе шуышып йөри башлый — анысы да шешәгә үрелә, гөнаһ шомлыгы! Минһаҗ абзаң эчүдән үлде. Соскан, соскан, тын юлына бәрәңге барып утырган. Аның күк балта остасы юк ие тирә-якта. Һы, Габделхәйне әйт, Сабан туе батыры иде бит мәрхүмкәй, эчте-эчте дә урман уртасындагы иң карт имәнгә барып асылынды. Менәтерәк! Эзли-эзли табансыз калдылар, районнан чутсыз килде милиция, карга җыелганнан аңышып кына таптылар. Хатын-кызы эчә бит хәзер, кияүгә китмәгән кызлар аяк тибә-тибә җырлап чөмерәләр. Мәликә тутаң, һай бар иде сылу чаклары, эчте-эчте, ходай күрсәтмәсен, ботын-чатын аерып күпер төбендә аунады, кыланмаганы калмады, сумашешнийга яптылар. Чыгарсаң, ирләрнең бугазына ябыша, ди. Әллә ничә кешедә бума зәхмәте, тик торган җирдән авалар да тәгәриләр. Күрмәс өчен әҗәлеңне ашыктырырсың, валлаһи! Җыелганнарга кәмит: «Макмырлары чыга!» — дип, авыз ерып шаркылдыйлар да үзләре үк баш төзәтергә китәләр».

Йокы килү кунакларның кыяфәтенә чыкты, Нәҗип белән Наилә, авызларын читкә борып, алмаш-тилмәш иснәделәр. Йосыф картның башы аска иңеп-иңеп киткәләде. Ниһаять, Мәрьямбикә карчыкның сүз чишмәсе саеккандай булды. Саеккан саегуын, әмма ләкин бетеп җитмәгән икән, төп фикере тел төбендә калган икән: «Менә шулай яшәп ятабыз авылда. Ипи пешермибез, он сатмыйлар, тегермәннәрне җимерделәр. Эзидән ипи кайтса кайта, кайтмаса — юк, кайтарсалар да, безнең ише карт-корыга тәтеми, хәзер арт ишектән бүлешеп бетерәләр. Берәүләр икмәк белән мал-туар симертә, безнең ишегә туя ашарга да юк. Көчленеке мал-туар белән, чучка асрый хәзер татар, ипекәйне улагын тутырып тыгындыра, чүмәлә тиклем бишәр чучка асраучылар бар! Әнә, ачкүз Таҗетдиннар чучкаларына ак он болгатып тугындыралар, ди. Ник симермәсен ул каты борын, ник көрәймәсен. Көзен, кырпак төшүгә, суялар да Әлмәткә алып китәләр. Анда да шул нефтәдән башка шымытыр да юк икән. Ит тә, май да, нефтәчеләрнең сүз әйтергә авызлары да юк, ди!»

Карчыкның хәсрәтле сүзләренә каршы төшмәделәр, хупламадылар да, сүзсез диярлек, күзләрен челт-челт йомып, ияк кагып утырдылар. Мәрьямбикә: «Сезгә чоланга җәйсәм туңмассызмы?» — дип сорады. Улы белән килене, торып басып, тиз-тиз ризалаштылар. Чоланга икән чоланга, тинтерәгән башларны куярлык йомшак мендәр генә булсын!

Чәйдән калган кайнар суны Наилә комган белән салып торды, Нәҗип тәрәзәдән төшкән яктыга чыгып, ишегалдында кыска арада юынып алды. Төн тынлыгын бозарга теләмәгәндәй, берни сөйләшмәделәр. Чоланда салкын толып астына тәгәрәгәч тә, бер-берсенә якынаерга теләмичә, чит-читтә яттылар. Май төне шактый суык иде, иртәнге якта җил күтәрелеп, чоланның тишек-тошыкларыннан шактый

ук өрә башлады, ир белән хатын ирексездән бер-берсенә тартылдылар. Наилә, йокымсырый башлаган ирен сискәндереп: «Трактор тәгәрмәчен Мөнир сазда ничек кигертте икән? Ни белән беркетте?»— дип сорады. Нәҗип кырыс тавыш белән: «Юк-барны уйлап ятмасана!»— дип хатынын сүздән бүлдерсә дә, хатыны сүзенең дәвамын, сөземтәсен эзләргә тотынды. «Димәк, Наилә юлда кайткан чакларны, трактор ватылып торган минутларны уйлый... Йөгәнсезләнеп кычкырынуларын исенә төшерәдер... Үкенәме, юкмы? Әллә юлда дөрләп киткән ялкын монда да пыскыймы? Әтиләр арадагы салкынлыкны сизәләрдер. Ата-ана күңеле сак була! Белә калсалар, барыбызга да читен булыр. Читен, ямьсез булыр... Картларга бигрәк тә...»

Авыл патшасы әтәч кычкырды. Әтәч — авылның байрагы, таңның шаһиты. Нәҗип шул балачак тавышын ишеткәч, сикереп торды, чолан ишеген тавышсыз ябып, ишегалдына чыкты. Төнлә күренмәгән тирә-ягына кызыксынып, сагышланып карады. Өй бүрәнәләре череп, муртаеп беткән, төртсәң таралырга гына торалар. Нигез ниргәләр зыян күргән, алар сары черекка әверелеп, бер-берсен сытып кергәннәр. Өй күзгә күренеп чуккан, тәрәзә борыслары чалыш-чолыш кыйгайганнар.

Читәннәр йолкынган, баганалар ауган, бүрәнә башларындагы быжан тишекләренә сүс тутырганнар да аннан-моннан кызыл балчык белән сылаганнар. Капка баганалары: «Без монда басып торып ардык шул»,— дигән сыман, як-якка авышканнар. Кичә Искәндәр дөбердәткәндә ничек аумаган бу капка?!

Кәҗәсен савып бетереп, сөтле чүлмәген беләгенә кыстырган Мәрьямбикә улы янына килеп басты да, Нәҗипнең озынлыгыннан, күзләре ераклыгыннан куркынган төсле, читкәрәк тайпылды. «Кайтырыгызны белмәдек шул, улым, кайтырыгызны!»— дип авыр сулады. «Белсәгез, нишләр идегез, әни?»— диде Нәҗип, кичәге очрашудан бирле шушы сүзгә әрнеп. «Бәй, коймак изәрлек он табар идек, мунча яккан булыр идек. Югыйсә, күрче чалбарыңны, язгы пычрак муеныңа менеп җиткән ич!» «Мунча түбәгез ишелгән түгелме?» «Күршеләргә ялынып керәбез, улым, күршеләргә!» «Мунчаны үзем ягам!»— диде Нәҗип, шунда ук дәртсенеп. Гәүдәсе җиңеләеп, очынып китте. «Әйбәт булыр, улым. Кичә ягылган мунчага утыны да күп кирәк булмас!» Карчык, әчкерсез сөенеп, утын өемен күрсәтте, мунчага кайсы яркаларның япьтәш булачагын иренмичә аңлатты.

Терәлеп торган күршеләре Фәрәхетдиннәр борын-борыннан мунча яраталар иде. «Фәрәхетдин бер яккан мунчага өч тапкыр чабынырга кирә!»— дип күрше-күләннең шаккатып сөйләгәнен малай чакта ишеткәне бар иде Нәҗипнең. Хәзерендә, Фәрәхетдин дөнья куйгач, мунчалары ни хәлдә икән?

Ул, читән капкага эленгән бозау муенчагын суырып алып, эре ярылган каен яркаларын бәйләп иңенә салды да ындырга атлады. Ындыр капкасына дәү җәяле авыр йозак эленгән икән. Әнисе сөтен куеп, ялт кына килеп чыкты да, биленә тагылган ачкыч бәйләменнән берсен аралап алып, йозакны ачты, улын ындырга шае озата чыкты. «Онытмадыңмы?»— дип Фәрәхетдиннәр мунчасын күрсәтте. Фәрәхетдиннәр — терәлеп торган күршеләр, алардан ары, марҗасын ияртеп читкә чыгып киткән Мостафалар нигезе.

Эшләпә киеп мунчада уралырга яхшысынмаган Нәҗип яланбаш, күлмәкчән генә чыккан иде, авыл өстенә аварга торган шәрә тау өстеннән, әче-әче җил исте, тәнне тешләргә тотынды. Ике арадагы ызаннан төшеп, ындыр арты киртәсе яныннан мунчага борылам дигәндә, мыдыр-мыдыр сөйләшкән тавышлар ишетеп, Нәҗип тукталып калды. Әүвәл башта тез башлары касмакланып каткан чалбарына күзе төште. Оялды. Аннан, тәвәккәлләп, аны-моны уйламаска тырышып, мунчага таба атлады. Барып җиткәч тә ишек кинәт ачылды.

аның каршысына бер-бер артлы ике хатын-кыз килеп чыкты. Иңнәренә берсе кара шәл, икенчесе ак яулык салган хатыннарның икесе дә шәрәтән иде. Алдан кара чутыр, башмак иренле хатын килә, дәү күкрәкләре чегән арбасына тагылган дегет лагуннары кебек чайкалалар иде. Зифа, нәзек сынлы, учка сыеп бетәрлек кенә алсу имиле арттагы хатын, Нәҗипне күргә чүгәләде, яулыгын алып, түшен, бот тирәләрен каплады. Нәҗип Гөлгенәне таныды.

Гөлгенә аннан бер генә яшькә олы булса да, алар бер класста укыдылар. Декабрь чилләләрендә салкын тидереп, Гөлгенәнең әнкәсе иртә вафат булды да, ул бер кыш укырга йөрмәде, икенче көздә Нәҗип аны куып җитте. Балачактан ук чая, кыю, үткер телле булды әнисез бала. Тегермән буасына су керергә төшсәләр, Нәҗипне бала санап, һич тайчынмыйча чишенә, малай каршысына шәрәтән басып, аның төкреген йота-йота җиргә карап торуыннан көлеп, үртәп, Нәҗипнең битенә ут кабыза иде. Элеккегә караганда чибәрләнгән Гөлгенә, аның тәненә азгын тәм, ләззәт йөгергән, бер дә утыз дүрт яшьлек хатын дип әйтмәссең. Бала тапмаган, ахрысы, эче суырылып тартылган, ботындагы җәрәхәт эзе генә, яман җөй булып, күңелне кайтарып тора иде...

Бу очрашу бик аз вакыт дәвам итте. Гөлгенә чүгәләгән килеш калды, аска карап, буен сындырып Нәҗип мунча ишегенә кереп югалды, шабырдатып утын яркаларын идәнгә койды һәм тәбәнәк сәкегә утырып, учы белән маңгай тирен сөртте. Май җилендә дә тирләтә торган хатыннар кычкырып бер көлештеләр дә аяк эзләре тынды.

Бу дөнья Нәҗип күз алдында тотып кайткан татар дөньясы түгел иде. Гөлгенә дә ул белгән татар авылы хатыны түгел, дәшмитынмый, затсызланып, имиләрен асылындырып торган башмак иренле хатын да ят, килешсез иде. Бу манзара аның күңелен ямьсезли, түбәнәйтә, рәнҗетә иде.

«Әгәр хәзер әнисе яисә Наилә төшеп, аны шушы җайсыз хәлдә күрсәләр?» Нәҗип башын күтәрмичә, кабаланып мунчадан чыкты, кабаланып кайтып кулына ике чиләк тотты, бу юлы тыкрыктан, Гөлгенәләр ихатасы күренмәс сукмактан, инешкә төште.

Яр өстенә барып баскач, ул инешне танымады. Баштарак ни үзгәргәнен дә аңламады, балачактан һәр борылышка, һәр тугайга, һәр түмгәккә күнеккән күз бүген ятсынып, инешне кызганып, боегып калды. Ярлар ишелгән, тәбәнәкләнгән, теге борылыштагы тын тугай саеккан, тугай урынында бөкере таш таучык пәйда булган. Кая карама — ертык-пыртык галушлар, ватык тәгәрмәч тугымнары, каз оялары, иләк кысалары, гөбе, сапсыз бәлҗә, ылыбылар, чалгы бизләре, ураклар һәм төрледән-төрле тимер-томыр чәчелгән иде. Ике-өч урында оя-оя каз мамыгы сеңгән, төлке буганмы аларны, мур кырганмы, белеп булмый. Талларда кош тавышы юк, инеш тә тавышсыз ага, юашланган, тал төпләренә, ярның уентыкларына кушуч-кушуч кара май кисәкләре касмакланып каткан иде. Фәрәхетдиннәрнең мунчасы турындагы тубырлы кабыклы карт өянке башын саесканнар сарган. Алар, Нәҗипнең күзен кискән үзгәрешләргә куанышкан сыман, үзара чыкыр-чыкыр киләләр иде. Инешнең суы болганчык, су читләре майлы лай, уртадан зәңгәрсу ефәк булып тоташ нефть ага иде. Баядан бирле ындырга чыккач та борынга бәрелгән авырсы ис инештән килә икән.

Шулчак ындыр капкасыннан билен тотып әнисе чыкты, сөйләнәсөйләнә аның янына ашыкты. «И улым! Зиһенемне заман ашады! Иртән ни уйлаганымны кич онытa торган булдым. Эткәң егылганнан бирле үзем дә сихәтлеккә туймыйм. Суны мунчага каян ташырга кирәклеген әйтеп бирмәгәнмен. Инешкә куптәннән төшкәнебез юк, өч-дүрт ел бардыр. Су урынына әллә нәмәкәй ага. Тегендә, иске те-

гермән урынына дуңгыз яптылар. Өч мең баш мыркылдап ята, ди. Шуларның шакшысы ага инешкә. Кышын-язын мур кыра тегеләрне. Карау җитми, ашарларына юк. Үләксәләрен дә шунда инеш тирәсендәге чокыр-чакырларга ыргыталар икән. Нефтәчеләр Олы су башында, Карама куышта ике җәй яттылар, нефтьләре чыкмаган, казыган тишекләреннән ачы су ургылып ага ди. Әллә җәһәннәмгә тикләм төшкәннәр инде? Үземнең барып караганым юк, илләмәгәр исеннән баш дөңки. Шулайдыр, шулайдыр... Элгәрге елларны каз асрый торган иек, өчәр оя калдырган елларым булды, авыл җирендә каздан да җайлысын тапмый иек, күздән тозлап әләсең дә җәй буе тутәрәм-тутәрәм ит ашыйсың. Уч төбе хәтле ит салсаң да, бәрәңгегә тәм керә. Өченче ел казыбыз унөч бәбкә чыгарган ие. Әтиең сырхау, мин бәрәңге бакчасында чүп утыйм, котырды ул елны чүп! Әшнең очы-кырые юк. Казларым әллә ни арада капка асты тишегеннән чыкканнар да инешкә төшкәннәр. Тавышларын да ишетмәдем сана, колакай. Исемә килеп теркелдәп төшсәм... унөче тиң су читендәге майга чумып җан биреп яталар. Ике атна күземне ача алмадым, жыладым да жыладым. Тәңре безне ташлады, ходай шәфкатен бүтән тарафларга юнәлтте. «Әтигә ни булды?» — дип сорады Нәҗип. «И улым, вакыт табып бер сүләрмен әле сүләвен, чыкмаган жаны белән тамагы гына калды бахырымның. Чирләде дә мантымады. Булса, ашауга таза болай, ашарга гына төткәзеп булмый. Казлар димәктән, ана казны исән килеш тартып чыгардым. Нилəр хикмәтләп карамадым, керәчин белән юдым, кер парашугы белән ышкыдым, рәтләнмәде бичара. Аннан күмдем. Жылый-жылый күмдем актыкны ала казны. Ел саен диярлек ун-унбиш бәбкә чыгара торган ие. Унөч иде ул елны. Ишчугы унысы гына күзгә керсә соң!.. Карын итле була иде! Сатасың икән, базарда каз егерме тәңкә! Хәзер әнә ике сарык асраган булабыз. Икесенә сыңар бәрән. Ел саен ике бәрән китерә торган Акмаңгай ике ел рәттән бәрән сала. Язга чыктык исә, мә, сәмәлүт белән кырга агу сиптерәләр. Әтиең ничәмә-ничә ел сәмәлүткә агу төяшеп йөрде. Әйтмәсә дә беләм, бик беләм: шул җитте аның башына! Күрә авыл: җил чыкты исә агу болынга оча, тауларга куна, урманга тарала. Суда да шул, юлда да! Авызда да шул! Теш арасына тулып кыштырдый. Бөтен авыл сарыклары ютәлли берзаман, шоннык, көтү каршыларга баргач, сүләшмибез — мал тоягына ияреп кайта, тузанга катышып оча! Күпләр сарык асрамый хәзер, умарта корты бетте, бөжән юк, төклетура үрчеми, дөнья тутырып чебен-черки калды. Ул нәләтне агу алмый икән! Әй килә башлый берзаман чебен дуңгызчылык ягыннан! Муенга тула, колакка керә, хет ләхеткә кереп ят. Калмады сыер малы, улым. Кем асрасын? Язын бозау сала, туган бозаулар селәгәйле-маңкалы, ябагасы белән йоны коела. Һәй, һәй!..»

«Ит каян ала соң авыл халкы?» «Итме? — диде сәерсенеп ана.— Кысыр аш ашыйбыз. Бик олы кунак килсә, тавык суялар. Кайнар кысыр аш әләксә, рәхмәт диген инде. Тәңре безне ташлады. Сөтле аш та кунак сые хәзер! Хәер, бер карт-корыга ни җитмәгән? Безгә күп кирәкме?» Мәрьямбикә авыз читен кулы белән каплап, улына астан, бик ерактан карап көлгәндәй итте. «Ә яшьләр ни ашый?» — Бусы үзенчә Нәҗипнең шаяртуы иде. Мәрьямбикә исә бик җитди җавап бирде: «Яшьләрме? Бармыни алар? Юк ич, таралдылар. Балалар таралды дип, элгәре, эткәң белән көенә идек, хәзер сөенеп бетә алмыйбыз. Ике энең әфисәр, Сабит улым әйткәндәй, хөкүмәт киендерә, бушлай ашата. Марҗага өйләнүләренә дә исебез китми, дөньясы шуңа калгач, кая барасың? Татар булып без ни рәхәт күргән? Күз күеге булып монда кайтмасыннар гына!»

*Ахыры киләсе санда.*

# ШИГЪРИЯТ

## Флера Гыйззәтуллина

### Йөрәгемне эзлим

ПОЭМА

Кайсы баламның
Чакыруы икән,
Шаукымы икән
Нинди зыянның? —
Тагын мин бүген
Кичәге сыман
Төнге йокымнан
Тетрәп уяндым.
Иминлек теләп,
Дога озаттым
Жир белән күкнең
Әйләнәсенә —
Жан тетрәүләрем
Жир тетрәвенә,
Күк күкрәвенә
Бәйләнмәсенгә...
Өлкән баламның
Исемен куштым
Йокысыз язган
Шигырьләремә,
Гомеркәйләрнең
Якты назында
Ал офыкларга
Күмелгәненә.
Йолдызга таба
Кулымны сузып,
Сөйгән кешемнең
Хәлен сораштым.
Мин тагын бүген,
Кичәге сыман,
Туар көнемә
Якты юл ачтым.
Һәм көпә-көндез
Йолдыз атылды,
Иминлек иңәр
Офыкка карап;
Ничә ел елап
Сукрайган күзем
Шушы хәлдән соң
Ачылды кабат
Калыкты тарих,
Кара кабердән
Яшәү дәгъвалап
Һәрбер кешегә.
Тарих эзләре
Юнәлтә мине
Халкым моң кичкән
Урман эченә.
Газиз әнкәем
Тулган ай булып,
Озата килә
Балачагымнан:
— Адаша күрмә,
И-и, моңлы балам,
Тормыш — карурман!
Шигырь — карурман!
Шигырь — әманәт!
Шигырь — янар тау!
Ерак-еректан
Балкып күренә...
Шигырь — ул бала,
Иң алсу алма,
Бөртекле ярма —
Йөрәк түрендә.

* * *

Бу яшәү өчен,
Шигърият өчен
Януларымны
Тарих барласын.

---

Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА — *шагыйрә, «Чишмә юлы», «Сәлам хаты», «Акчарлагым — асыл кошым» һ. б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Һаман тормышның
Тартам арбасын,
Тартам баласын,
Тартам ярмасын.

...Авыр моң сала
Тарту нужасы
Һаман да безнең
Газиз башларга:
Ярмасын тотам
Шигырь ашларга,—
Бөртеген хәтта
Җәллим ташларга.
Күңел тарихы,
Яшәү тарихы
Яңаргангамы
Сабак тамырдан —
Җанымның бөтен
Күзәнәгендә
Шаулый карурман,
Шаулый карурман.
Карурманнарга
Китеп адаша,
Сыймый уйларым
Башыма гына:
«Кем көен көйләр?
Кай телдә сөйләр? —
Баламның теле
Ачыла гына».
Баламның җаны
Гөрелди генә
Күгәрчен булып
«Уй кышлагым»да...
— Гөрлә! Гөрлә! — дип
Сикертәм аны
Айлы, кояшлы
Куш учларымда.
Тапшырам аңа
Әманәт итеп,
Чардакка кунган
Күгәрчен гөрен.
Тыныч тормышта
Чыныгу серен
Оныта күрмә,
И бирдәнберем! —
Туганнан алып,
Үз чардагыңда
Минем өченгә
Син дә — күгәрчен!
Күз нурларыңны,
Җыр-моңнарыңны
Кояшка манып,
Җиргә түгәрсең!
Җирдән эзләрсең
Йөз чалымнарын,
Җыр агымнарын
Тукай, Мусаның...
Күккә, биеккә
Күтәрә шагыйрь
Шигырьдә чөеп
Очар кош җанын.
Һәр калкыныштан
Тарихыбызга
Ярдәмгә килә
Хәтер фасылы:
Инде ничә ел
Илгә Мусадан
Ак күгәрченнәр
Шигырь ташыды.

...Туа-тумыштан
Моң җирлегендә
Сабаклы онык,
Канатлы онык!
Син дә кунмассың
Казык башына
Язмыш каргаган
«Ак карга» булып.
...Җыр бишегемдә
Улым ныгуга,
Дөньяга аваз
Салды кыз балам! —
Шигырь хакына,
Бала хакына
Янә, янә мин
Юлга кузгалам.
Юл чыккан саен
Күргән нужалар,
Бергә туплагач,
Җыйнала шактый:
Карурман гизгән
Кара яшеннәр,
Кара кайгылар
Йөрәктә чатный.
...Яшеннәр белән
Чәкәләшерлек
Көч каян алыйм
Шушы яшемдә?
Нәсел-тамырга
Сукмасын өчен
Үз исемемне
Кушам яшенгә.
Ата-бабамның
Исемен кушам
Балам менәсе
Янар тауларга.
...Бер тынар яшен,
Йөрәккәемнән
Тау биеклеген
Даулар, даулар да!

* * *

...Ил тарихына
Күз салган чакта

Килмәсен өчен
Акылга зыян,
Карурманнарда
Балам җуйгандай,
Йөрәккәемне
Мин, гүя, җуям.
Яман ят телдә
Әйтә күк тарих:
Бүгеннән башлап
Дөнья шыр ятим!
Һәм мине күреп
Сискәнеп китә
Тарих катына
Килгән бер хаким.
Каныма сеңгән
Ятимлектәнме,
Йөрәксезлегем
Шулай кушамы? —
Инде кычкыртып
Хисемне суя,
Гомремне суя
Акыл пычагы.

* * *

...Туган тел хакын,
Шигърият хакын
Дучар иткәндә
Кискен законга,
И-и салкын акыл,
Хет берәр тапкыр
Уйладыңмы син
Йөрәк хакында?
Фаш итмәдең ник
Илгә исемен —
Милләтне саткан
Яман кешенең?..
Милләтем күргән
Кимсенүләрдән
Гомерем буе
Мин дә кимсендем.

* * *

Беләм: яулаган
Биеклегемне
Теләмәгәнгә
Кемгә тиңләргә,
Ул — минем йөрәк! —
Упкын төбендә
Мине чакырып,
Елый төннәрдә...
Шуңа төн буе
Йөрәгем әзлим...—
Туры киләчәк
Озак эзләргә.

Кояш төсе бар,
Урман төсе бар,
Упкын төсе бар
Минем күзләрдә!

* * *

Йөрәксез калсаң,
Шигырь ул — упкын!
Кояштан иңгән
Яшь шагыйрь, ишет!
Күзлисеңме син
Минем күзләрне?
Килмисеңме син
Упкынга күчеп?

...Күзең — күземдә!
Балаң — теземдә!
Син минем өчен
Бала — үзең дә...
Шигырь ул — яшьлек!
Шигырь ул — шәфкать!
Шәфкатьле нурлар
Балкый йөзеңдә!
...Шигырь — туй!.. Күлмәк! —
Син туган көнне
Сөяр ярыңа
«Үлчәп» тегелгән.

...Изге күңелле
Ана булсам да,
Сиңа мин, бәлки,
«Изге» күренмәм.
Шигырь ул синең
Туачак балаң! —
Иңмәгән ләкин
Әле карынга;
«Шагыйрь булыр!» дип,
Галим булыр!» дип,
Саклыйм аны да
Өмет багымда.
Мин сине сөяр
Гүзәл кызны да
Теркәдем күптән
Шушы өметкә.
Тик син, өйләнгәч,
Әверелә күрмә
Легендадагы
Яман егеткә!
Син чаба күрмә
Минем башымны,
Хаклап ярыңның
Хатынлык хакын.
Баш белән бергә
Тел дә чабыла,—
Мин кичерсәм дә,
Кичермәс халкым.

* * *

Бу әманәтне
Балам онытса,
Муса язмышы
Хәтерен ашлар...—
Шигырь хакына
Ялгана килә
Ничә мәртәбә
Чабылган башлар!
Тарихның тагын
Әллә кемнәре
Төялә килә
Бишек-арбага...
...Чү, тукта, йөрәк,
Син андыйларны
Минем арбамда
Күреп, каргама!
Алар — телсезләр!
Алар — илсезләр! —
Шигырьдән киткән
Һәммә, һәммәсе...
Әле дөньяда
Алла хакы бар;
Алар да шул ук
Алла бәндәсе.
Алар да шул ук
Акыл хатасы,
Зиһен хатасы,
Йөрәк хатасы.
Гомер-гомергә,
Ил белән бергә,
Күкрәкне җиргә
Терәп тартасы.

* * *

Шушы хатаның
Асылы ятадыр
Упкынга чумган
Йөрәк антымда...
Житте безгә дә
Уйланыр вакыт
Башларга төшәр
Антлар хакында.
Яшерми сөйләр
Вакытлар җитте
Ниләр барлыгын
Кара урманда.
Борын-борыннан
Халык кайгысы
Каңгырып яши
Кара моңнарда.
Ял күтә-күтә
Хисле йөрәктә,
Моңлы йөрәктә
Төкәнә чыдам.
Форсат чыгуга
Масая моңсыз,
Урман корыткан
Давыллар сыман.

* * *

Шул корткычлыктан
Мин исән калдым —
Карурман кичеп,
Шушы яшемдә.
Имин офыктан
Яшьнәсен өчен
Үз исемемне
Куштым яшенгә.
Йолдызга таба
Кулымны сузып,
Сөйгән кешемнең
Хәлен сораштым.
...Мин тагын бүген,
Кичәге кебек,
Туар көнемә
Якты юл ачтым.
Шигырь аралаш
Елмайды көлеп,
Әманәттәге
Тулган ай кебек,—
Йөрәксезлеккә
Түзеп яшәүдән
Төзек яшәүгә
Багланган өмет.

# Мәхмүт Хөсәен

## Сонетлар

❁

И, балачак — яшел чирәмлек!
Ялантәпи сине үттем мин.
Иртеш дулкынында тирбәлеп,
«Әйлән-бәйлән» уйнап үстем мин.

Уйларымда кайтам әйләнеп
Чатыр корган яшел талларга.
Гомерлеккә калдым бәйләнеп
Далаларда аткан таңнарга.

Балачагым төсе тын далам,
Кемнәргәдер ачы әрем ул.
Ә мин алам аннан моң, дәрман,
Күңелемдә — илһам шәмем ул.

И, балачак — хәят бишегем,
Чишмә башы шигъри хисемнең.

❁

Илне иңли күпме көйләрем!
Рухым белән мин иң бай кеше.
Илһам бирә туган җирләрем,
Күңел шуңа — тулган ай төсле.

— Көй дә булса малмы? — ди күршем,—
Көй язудан тамак туямы?!
Сорамыйсың җир син ни өчен?..
Мал оясы — Идел буйлары.

— Женем сөйми акча-мал колын,
Тормышның ул тәмен тоялмый.
Читләп үтә чишмә, тал юлын,
Ярканат ни аңа, тургай ни?!.

Жан мүкләнә рухи сайлыкта...
Яшәү яме — рухи байлыкта.

---

Мәхмүт ХӨСӘЕН *(1923)* — *шагыйрь, публицист; татар, рус һәм казах телләрендә дөнья күргән күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

*

Яз, туктама, ян син, Хөсәен!
Эзлә яңа шигъри энҗеләр.
Йөрәк утын дөрләт көн саен,
Җылы алсын аннан кешеләр.

Илне имгәннәрне син фаш ит,
Түрәләргә тотма тәрилкә.
Күңелләргә моң илт, кояш илт,
Аяз булып тусын һәр иртә.

Көчлеләрен тудыр җырларның,
«Тешле»ләрен, бәлки, басмаслар...
Битлеген ерт комсыз бурларның,
Заман бүтән бүген — асмаслар.

Чын хакыйкать иңсен җырыңа,
Һич хакың юк дәшми торырга.

*

*Зөһрә Сәхәбиевага*

Рәхмәт сиңа, җырчы туганым!
Дәрманга дәрт өсти моңнарың.
Моңнарыңда күпме наз, илһам!
Җыр тибрәтү — асыл вазифаң.

Яңа бер җыр отсаң, син аны
Кешеләргә тизрәк илтәсең.
Җырлар белән бизәп дөньяны,
Каршылыйсың хезмәт иртәсен.

Җир ямьләнә тыныч таң тугач,
Моңга сусап тибә йөрәкләр.
Көмеш курай суза сандугач,
Тып-тын калып тыңлый тирәкләр...

Сез, сандугач рухлы кешеләр,—
Моң дәрьясы белән көчлеләр!

*

Сине күрсәм, кайта уйларым
Гыйшкым чәчәк аткан таңнарга.
Хәтерләтеп яшьлек туйларын,
Дәрт өстисең дөрләп янарга.

Гыйшык утың белән бәгырьне
Үтсәң дә мең тапкыр телгәләп,
Барыбер син миңа кадерле,
Синең белән дөньям түгәрәк.

Күзләреңнең тере ялкыны
Йолдыз булып ява дөньяга.
Көләч йөзең нуры аркылы
Яшьлегебез таңы елмая.

Йөрәгемдә — еллар юшкыны,
Йөздә — тәүге гыйшкым очкыны.

❁

Югалтмаска сөйгән ярымны
Кулдан килгән кадәр тырыштым.
Ә ул китте талап җанымны,
Челпәрәмә килде тормышым.

Улый көзнең ачы җилләре,
Сары яфрак ауный аланда...
Ул китсә дә, аның йөрәге
Миндә тибә төсле һаман да.

Онытамын, тулса күңелем,
Рәнҗүемне аңа, үпкәмне:
Белсәм дә ул тиң яр түгелен,
Сөя алмый йөрәк бүтәнне.

Тугры йөрәк — сөйгән яр колы,
Таш эретә аның ялкыны.

❁

Тугыз баллы дәрья дулкыны
Куба, гүя, йөрәк эчендә...
Белмәс идем мин дә куркуны,
Терәк тапсам синдәй кешедә.

Синең хакка кичәр идем мин
Упкынын да, тәмуг утын да.
Комнан аркан ишәр идем мин,
Күңел кыйблам булсаң йортымда.

«Тормыш өчен бармы тиң ярың?
Эзләп тап, дип, син шул тиңеңне»,—
Бирсәләр дә миңа Җир шарын,
Сайлар идем фәкать мин сине.

Нигә миңа бөтен Җир шары?!
Миңа тик син кирәк нибары.

## Диңгез мәрҗәннәре

❁

Сызылып таң ата офыкта,
Канат җәя җирдә хозурлык!
Суда йөзү рәхәт, кызык та...
Сизелми дә суда кызулык.

Кояш түгел, гүя, карлыгач
Тәнебезгә төсен күчерә.
Ел буена эшләп арыгач,
Ләззәтле ял тансык кешегә.

Саф һавалы алсу иртәләр,
Ай нурына чумган кичәләр
Хисләреңне әсир итәләр,
Гашыйк чаклар искә төшәләр.

Кояш нуры, диңгез һавасы —
Табигатьнең тиңсез дәвасы.

❀

Гашыйк сиңа, диңгез, яшьли мин:
Һәр җәйне ял итәм ярыңда.
Дулкыннарда уйный яшь дельфин,
Рәхмәте зур сиңа аның да.

Иртә таңнан оча ашкынып
Акчарлаклар, балык ауларга.
Парашютлар төсле ачылып,
Медузалар йөзә ярларга.

Керәсең көн буе мең төскә,
Бардыр бирәр тылсым таягың...
Болай уйлау чыга дөрескә,
Һәр чак төкле синең аягың!

Дәвалыйсың безне иплəп син,
Саулык өчен — сихри хикмәт син!

❀

Көз җиттеме — яр буш, яр ышык.
Кояш кача болыт артына.
Дулкыннар, үзара тартышып,
Чәкәләшеп күккә атыла!..

Бөтерелеп шашкын өермә
Дулкыннарны айкый, актара.
Диңгез дулый, диңгез илерә,
Һич күренми күзгә ак-кара.

Чыгырыннан чыгып дулкыннар,
Тау-тау булып ургый ярларга.
Җил-давыллар, чоңгыл-упкыннар
Яба алмый юлны аларга.

Тынгылыкны белми дулкыннар...
Дулкыннарда шагыйрь холкы бар!

*1983—1990*

## Рафаил Төхфәтуллин

# САРМАН БАЛЛАДАСЫ

### 1



Язмыш турында, газап, өмет һәм мәхәббәт турында бу баллада.

Бәлки шуңадыр, анда иң элек сагышлы-хәсрәтле җыр яңгырый:

Әнкәй мине тапкачтин
Ак биләүгә биләгән.
Ак биләүләргә биләгән,
Бәхете булсын димәгән.
И-их!..

Матур җәй көне бу. Кояш аеруча ягымлы, аеруча шәфкатьле елмая, ә җыр үтә дә моңлы инде дә сагышлы-хәсрәтле яңгырый:

һай!..
Дөнья хәлен белеп булмый,
Сау булыгыз, туганнар...

Кояшның болай бигрәк ягымлы, аеруча шәфкатьле елмаюы, мөгаен, кешеләрнең күкрәкләргә сыймас моң-сагышын уртаклашуы, күңелләргә мәңгелек якты өмет салуыдыр.

Басу капкасын чыккач та
Уңга киткән юл булыр.
Чыгар кояш, исәр җилләр —
Бездән сәлам шул булыр.

Кешеләр дә моны сиземлиләр: әнә, аларның җырында кояшның үзе кебек үк мәңге сүнмәс өмет тә чагыла түгелме соң?

Чыгар кояш, исәр җилләр...

Төркем уртасында барган озын буйлы, каратут йөзле егетнең кулындагы тальян бизәкләрендә нәкъ шул чаткылар уйнаклый түгелме?

Кулларын бер-берсенең иңбашларына куеп атлаган егетләр авыл

---

Рафаил ТӨХФӘТУЛЛИН *(1924) — язучы. «Авылдашым Нәби», «Тамчылар ни сөйли?», «Җиләкле аланнар», «Акбуз ат» кебек повестьлар, татар һәм рус телләрендә чыккан дистәләгән китап авторы. Әлмәттә яши.*

урамы буйлап узалар. Моңлы-сагышлы җыр агыла, ә тальян телләрендә, күрек бизәкләрендә кояш нурлары уйный.

Әй!..
Мин киткәчтин кемнәр сөяр
Син сандугач баласын...

Уттай урак өсте. Ләкин халык бүген басуга китмәгән. Капка төбе саен кырыс-уйчан йөзле чал бабайлар, яулык очлары белән күзләрен сөрткәләүче әбиләр басып тора. Тиктормас малайлар да гадәттәгечә таяк-атларына атланып чытыр чапмый, һавага уч-уч туфрак чөеп «болыт ясау» уенын да онытканнар. Малайлар, киндер ыштаннарын арттан бик кискен күтәргәләп, борыннарын бик җитди тарткалап, урам уртасыннан җырлап узучы егетләр төркеме артыннан этешми-төртешми генә атлыйлар.

Яңа уңыш саламын көтеп арган, инде җир төсенә кереп барган өй түбәләре тагын да тәбәнәкләнеп, бөрешеп калган. Йортларның күз-тәрәзәләре моңсу, тонык. Шулай да, бер тәрәзәнең челтәр пәрдәсе кинәт җилфердәп китте дә, шау чәчәкле тамчы гөлләр арасыннан кара каш, дымсу караш бер генә мизгелгә чагылып калды. Алларына гына карап атлаган җырчы егетләр төркеменә кинәт әллә ни булды. Баш өсләрендә чиккән яулыклар җилферди башлады, гармун бөтенләй бүтәнчә яңгырарга тотынды, инде карлыга башлаган тавышларга дәрт һәм яшьлек шаянлыгы кайтты.

Тәрәзәләрдән карыйсың,
Карап кемне күзлисең?
Карап күзең талдырганчы...
Их-ма! Әйт шуны!

Шәрләрәмә авылы үзенең имәндәй ир-егетләрен Герман сугышына озата.

Алар, төркемдәге егетләр, бу афәтнең зурлыгын әле күңелләре белән генә сиземлиләр: моң-хәсрәт белән тулган күңел түрләрендә өмет очкыны әлегә дөрләп китми, чагылып-чагылып кына кала.

Бу очкын-чаткыларның дөрләр көннәре алда әле.

Бүген егетләр туган-үскән авыллары белән саубуллашалар.

Без киткән юлларга карап,
Сагынып саргаймагыз...

Шул егетләрнең берсе — төркем уртасындагы гармунчы егет — карт әти-әнисенең, ике сеңлесенең төп таянычы булган Каюм Юнысов. Ә тамчы гөлле тәрәзәдән кемнең алсу йөзе, дымсу күзләре карап калды соң? Бу алсу йөз — япон сугышында бер кулын калдырып кайткан түбән оч Ярулла солдатның кызы Миңсылу иде.

## 2

Шуннан соң балладада вагон тәгәрмәчләре тыркылдавы, унтерларның «Айт-два, айт-два!» дип тәкрарлаулары, «Раз-два, коли!» дип кычкырулары, «Ах ты, гололобый!» дип яңакка кундырулары ишетелә, дөбер-дөбер барабан сугулар яңгырап тора башлый.

Аннары ул тавышларга снаряд шартлаулары, пуля сызгырулары, «За царя, ура!» авазлары, җан ачысы белән ыңгырашулар, яралы атларның кешнәүләре кушыла.

Шәрләрәмә егете Каюм Юнысов үзенең «Раз-два, коли»дан узмаган хәрби белеме белән, «Ах ты, гололобый!..» — дип яңакка кундыру аша алган сабаклары белән Көнбатыш фронтта австро-немец һөҗүмен тукта-

та алмаса да, пушка итенә ярап куя: янәшәдә шартлаган снаряд аны җиргә сеңдереп, яртылаш күмеп ташлый. «Газиз башкайларыма менә кайларда ятып калырга язган икән...» — дип уйларга гына өлгерә ул.

Ләкин бу әле аның соңгы уйлары булмаган икән.

Күп уйлар уйлыйсы, күп нәрсәләр кичерәсе бар икән әле Каюмның. Кыр лазаретында аңына килгәч, «Юк, мин исән икән бит әле!..» — дип, ничәмә көннәрдән соң, уйларының дәвамын ялгап куя ул.

Үзенең бер аягы төптән үк юклыгын да, авыр контузия алганлыгын да белми әле Каюм бу вакытта. Үзенең җәһәннәм утыннан шактый еракта, Мәскәү каласы лазаретында ятканлыгын да белми. Күрше ятакта Каюмны ут эченнән алып чыккан, үзе дә каты яраланган фин солдаты Тайми ятканлыгын да күзалдына китерми.

## 3

Каюм саташулы-уяулы газаплар эчендә үлем белән якага-яка тартышып яткан арада, бөтен дөньяны тетрәткән зур вакыйгалар була.

Тәрәзәләрне зыңгылдаткан снаряд шартлаулары, пулемет тырылдаулары Каюмның зиһенендә бары тик Көнбатыш фронт кайтавазы булып кына яңгырап тора. Ә инде уй-зиһене ачыкланып киткән бер иртәдә Тайми солдат Каюмга әйтә:

— Беләсеңме, туган! Беләсеңме ре-во-люция! Халыкларга — тынычлык, җир — крестьяннарга, завод-фабрикалар — эшчеләргә!

Каюмның йөрәгендә дә өермә. Берсе өстенә берсе ишелеп актарылучы уйларның очына һич чыгар хәл юк.

Халыкларга — тынычлык, җир — крестьяннарга, завод-фабрикалар — эшчеләргә!..

Шәрләрәмәдә дә яңгырый микән бу сүзләр?

Шунда Каюм, шабыр тиргә батып, ятагына ава. Ә ул ничек иген игәр соң? Аяксыз игенчене Каюмның әле моңарчы күргәне юк.

И Миңсылу!.. Белсәң иде хәлләремне. Юк-юк! Белми торуың хәерле. Ярый әле, моннан ай ярым элек авылга язган хатында аяксыз икәнлеген әйтмәде ул. Яраланып лазаретка кердем, тазаргач, өйгә дә кайтарып җибәрүләре бар, дип, үз хәлен кыскача гына белдерде.

Тайми солдат үз Финляндиясенә ашыгып-ашкынып кайтып китте. Ә Каюмны ниләр көтә икән соң Шәрләрәмәдә? Миңсылу! Бу хәлемдә күзләреңә ничек күреним?!.

Көзге ачы җил тау-тау болытларны актара. Кайдадыр бик дәртле җыр яңгырый. Коридорда яралы солдатлар ярсып-ярсып сөйләшәләр, бәхәсләшәләр.

Каюм, ятагына сеңгәннән-сеңә барып, тын гына үкси...

## 4

Тайми солдатны Финляндиядә, чыннан да, зур эшләр көткән.

Ул Хельсинкига, юлда мең маҗаралар кичеп, салкын декабрь иртәсендә генә кайтып төшә. «Азатлык! Ленин Финляндияне бәйсез дәүләт итеп таный!» — әнә шундый хәбәр каршылый Тайми солдатны. Газеталар тиздән тагын бер хәбәр китерәләр: «Совет властеның югары органы ВЦИК, 1918 ел, 4 январь карары белән, Ленин тәкъдимен раслады».

Нәкъ шул көннәрдә Каюм, ниһаять, лазареттан чыга.

Ике елдан артык шыгырдык лазарет койкасында аунап, беренче мәртәбә дөньяга чыгуы Каюмның. Ниләр көтә икән аны бу иркен дөньяда? Әле һич иләнелмәгән култык таяклары кай юллардан алып китәр аның бу башкаен?

Ыргып-ыргып искән язгы җил шинель итәкләрен җилфердәтә. Әйтерсең ул да: «Торма, Каюм, каккан казыктай, алга атла. Гарип булсаң да, бер аягың, ике кулың, ике култык таягың бар бит әле. Атла, хәрәкәт ит!» — дип дәртләндерергә тели.

Бераз барып, уңга борылгач, трамвай тукталышы булырга тиеш. Трамвай аны Казан вокзалына илтеп куяр. Аннары Каюм поездга утырыр. Поезд аны туган якларга алып китәр. Шәрләрәмәгә. Миңсылу янына.

Казан вокзалы аны мең төрле ыгы-зыгысы белән куркыныч гөжләп каршылый. Кемнәр генә юк монда! Капчык аскан, сакал баскан чабаталы агайлар, авыр итекле, картузлы агай-эне. Чуар шәльяулык бөркәнгән, кайры туннлы түтиләр. Йонлач бүрекле, бохар түбәтәйле, буй-буй кызыл-яшел җиләнле кешеләр, погонсыз, соры шинельле солдатлар. Сәләмә киемле, кара борынлы малай-шалай тыз-быз килә.

Нишләргә, сызлаган аягына һәм тәмам талган култык төпләренә кай тирәдә чүгәләп ял бирергә белми торган Каюм шулчак янәшәдә татарча сүзләр ишетә. Сызлануларын онытып, шунда таба сөйрәлә:

— Әссәламәгаләйкем, мөселман кардәшләр!

Кемнең кай яктан булуы, кай тарафларга юл тотуы турында сорашулар китә. Погонсыз, соң дәрәҗәдә таушалган шинельле, иңбашына штыксыз винтовка аскан бер солдат әйтә:

— Тизрәк кайтып җитәргә язсын, кардәшем, туган авылыңа. Ин беренче шуны әйт авылдашларыңа: влачны нык тотсыннар кулларында. Мин гарип, дип, үзең дә мескенләнеп ята күрмә.

Шуны әйтеп бетерүгә, солдатны каядыр дәшеп алалар. Ул күздән югалуга, кырпу бүрекле бераү Каюмның җиңеннән тотып ала.

— Адәм баласына, яңгыравык тәти сүзләрдән бигрәк, ашарына ипи кирәк. Шуны онытмыйк әле без, энем. Мәнә шул турыда сөйләшик,— ди ул һәм Каюмны бер читкәрәк алып китә.— Бу фәкыйрь дә,— ди ул, мылтыклы солдат китеп югалган якка ымлап,— әнә шулай бушбугаз бәлшәвикләр коткысына бирелгән әдәмгә охшый. И раббым, мөэмин мөселманнарыңны туры юлдан яздыра күрмә, тәүбә-әстәгафирулла! Синең ерак сәфәргә юл капчыгың да бик юка күренә, кесәңдә чамаң ничегрәк соң?

— Бөгелмәгә кадәр бушлай кайтырга язуым бар.

— И раббым! Мәнә шул инде ул бәлшәвикләрнең. Әдәм баласын кәгазь дә, кызыл сүз белән генә туйдырмакчылар. Ай-һай, туганым! Бу болганчык заманда, алай кәгазь тотып кына юлга чыксаң, ничекләр кайтып җитәрсең икән?

— Сәвит юксыллар яклы бит. Ярдәменнән ташламас.

— И алла колы! Ул денсезләр ярдәменә ышанып юлга чыксаң, газиз башкайларың ниләр генә күрмәс... Тәүбә-әстәгафирулла. Уйлашыйк әле бу турыда.

— Яхшы киңәшеңә мең рәхмәтләр укыр идем, абзый.

— Киңәштән бигрәк, иң әүвәл менә моны кабул күреп ал әле син, мелла кем... Габделкаюм энем,— ди кырпу бүрек, кесәсеннән кәгазь акча чыгарып.— Юл газабын үткәндә аллаһе тәгалә юлдашың булсын. Шул шәрәфкә бер дога кылыйк... Инде менә бер дөньяви сүземә дә колак сал. Синең бирәдә аллаһе тәгалә йорты мәчетемездә булганың бармы?

— Юк, абзый.

— Денсез бәлшәвикләр изге аллаһе тәгалә йортымызны бу гөнаһлы җир йөзеннән юк итәргә чамалыйлар. Без болай итик. Хәзер үк изге мәчетемезгә барып, догаларыбызны укып кайтыйк. Аннары, ахшам намазыннан чыккач, хәзрәтемезнең хәер-фатихасын алырсың. Авыр юлыңда хак тәгалә ярдәменнән ташламас, бәрәкалла-иншалла.

Яңа Татар тыкырыгындагы таш мәчет янында кырпу бүрек Каюмга бер төргәк кәгазьләр суза:

— Намаздан чыккач, үзебезнең мөэмин-мөселманнарга берәм-берәм ошбу кәгазьләрне тапшыр. Хәзерге болганчык заманның иң хак сүзләре язылган монда. Мөселман кардәшләр үзеңне дә ярдәмнәреннән таш-

ламас. Миннән хәер-фатиха, бисмиллаһи-рахман илаһи...

Кырпу бүрек китеп югалуга, Каюм кулындагы кәгазьләргә күз сала. «Мөселман кардәшләр! Большевиклар коткысына бирелмик! Аерылганны аю ашар, бүленгәнне — бүре. Үзебезнең милли Шураның яшел байрагы астына тупланыйк! Мөселман солдатлар! Үзебезнең мөселман гаскәрләре сафларына басыгыз! Мөселманнар үз эшләреннең большевик хөкүмәте төзелгән Комиссариатта каралуына юл куймаслар!»

Каюмның күз аллары караңгыланып киткәндәй була. Нәрсә бу? Болар Тайми солдат сүзләренә, лазаретта ятканда ишеткән сүзләргә бөтенләй охшамаган. «Мөселман эшчеләренең дә, бөтен эшчеләрнең дә дошманы бер. Ул — буржуазия!» — дип укыган иде бит Каюм бер газетта.

## 5

Финляндиядә гражданнар сугышы башланып, буржуазия тарафыннан кысрыкланган Кызыл гвардия отрядлары чигенергә мәҗбүр була.

Тайми отряды бу вакытта инде, Карелия урманнарын кичеп, яшь Кызыл Армиянең регуляр көчләренә килеп кушыла. Революция сагында авыр сынаулар үтә бу интернациональ бригада. Совет хөкүмәтенең сугышчан бурычларын үтәүдә катнаша.

1919 елның май башында Тайми интернационалист-кызыларменцлар батальоны белән Мәскәү каласына җибәрелә.

Шунда язмыш Каюмны окопташ дусты Тайми белән янә очраштыра.

Каюмның үз гомерендә иң авыр көннәр кичергән көннәре була бу. Кырпу бүрек калдырып киткән Яңа Татар тыкрыгында ул бөтен җәйне үткәрә. Намаздан чыгучылар, сирәк-мирәк булса да, бакыр акчалар сузып китәләр. Кулына кәгазь тотып юлга чыкканчы, кырпу бүрек әйтмешли, кесәңдә тиеннәр шалтыратып юлга чыгуың хәерлерәк иц. Кесәгә кергән һәр тиен Шәрләрәмәгә таба юлны кыскарта кебек тоела Каюмга.

Көннәрдән бер көн Каюм шул тирәдәге толчок базарына барып чыга. Мондагы шау-шу, мондагы ыгы-зыгы Казан вокзалына караганда да битәррәк. Һәркайсы үз товарын мактап аваз сала. Чу! Кайдадыр тальян моңы ишетелә түгелме соң? Иске булса да чиста-пөхтә киенгән берәү, алдына берничә гармун тезеп куйган да, кулында тальян сайрата.

— Знакум, продаш штули? — ди Каюм, очар коштай талпынган йөрәген көчкә тыеп.

— Коли умеешь, ты сначала сыграй. Сговоримся.

Күңеленә ошаган бер гармунны алып, Каюм «Сарман» көен уйнап җибәрә.

— Наверно, ты из Казанской губернии, служивый? Больно соскучился по родине, видать?

— Да-да, знакум. Сколько просиш?

— Сколько можешь, дай да забери. Их, браток, с тебя ни копейки не брал бы, да нужда...

Шулай итеп, үзенең яшьлек юлдашы тальян белән очраша Каюм. Хәзер инде мәчет тыкрыгыннан шактый читтәрәк, кечкенә бакчада тальян сайратып, моң-сагыш тулы йөрәгенә юаныч таба ул. Үтеп-сүтеп йөрүчеләр, еш кына тукталып, аның уйнавын тыңлап торалар. Зәңгәрсу-коңгырт күзле, уңган сарафанлы бер туташ Каюм янында аеруча еш туктала. Туктала да, тиз генә күздән югала. Үзе югалса да, моңсу карашы һаман янәшәдә кебек кызыйның. Әллә куаклар арасына яшеренеп карап торамы ул? Әллә шулай тоела гынамы? Гаҗәп, бу кызый әллә кай яклары белән генә Миңсылуны хәтерләтә бит!

Бер көнне кызый Каюм янында гадәттәгедән озаграк тукталып кала. Башын кырын сала төшеп, гармун моңын тыңлап тора да кыяр-кыймас сорап куя:

— Солдат, а ты по нашему, по-русски умеешь играть?

— Можно, красавица, можно!

Кызый үзенең Рязань губернасыннан килгәнлеген, бередә азмы-күпме акча эшләү, әне-сеңелләренә ярдәм итү нияте белән яшәвен, әтиләренең исә сугышта үлгәнлеген тотлыга-тотлыга сөйләп бирә.

— Жив будем, не умрем,— ди Каюм.

Ул көнне Каюм кабат-кабат уйный. Уйнаган саен бармаклар житезләнгәннән-житезләнә.

Шул көннән соң кызый бакчада күренми. Их, исемен дә сорап калмады бит, ичмасам. Хәер, исемдә мени эш! Әйдә, Миңсылу булсын аның исеме. Чәчәк сарафанлы Миңсылу...

Күңелдә ташыган моң-юксыну гармуны телләреннән агыла да агыла Каюмның.

Сарафанлы кызый һаман күренми.

Моңарчы Каюм әле көннәрен бакчада үткәрсә, төн кунарга Яңа Татар тыкырыгындагы берәр мөселман кешесенә керә торган була. Хәзер аларга да керәсе килми аның. Күңел өзлексез көтә. Әллә тәвәккәлләп юлга чыгаргамы соң?

Их, бу кыяфәттә Миңсулы күзенә ни хәлләр итеп күренерсең? Авылдашлар ни әйтер?

Жир — крестьяннарга... Аяксыз көе нишләсен ди ул жир белән? Әй, туган жиркәем! Мәңгегә ятим итүең микәнни инде синең бу улыңны? Ятим... Әнә, сарафанлы кыз да ятимә. Аны да мең каһәрле сугыш ятим калдырган.

6

Тайми окопташ дустын башта танымый да тора. Сакал баскан, каратут ябык йөзле аяксыз солдат, тын бакчаның яшел чирәменә жәелеп утырган да гармун тарта, карлыкканрак тавыш белән жыр да сузып жибәрә.

Сарман буйлары да яшел алан...

— Каюм! Браток!.. Син ич бу!

Каюм үз күзләренә үзе ышанмый тора.

— Тайми! Туганым!.. Их-х...

Окопташ дуслар, кочакланышып, яшел чирәмдә әүмәкләшеп алалар. Аннары Тайми, кинәт житдиләнеп, юл капчыгыннан түгәрәк ипи чыгара, шуны урталай бүлеп, берсен Каюмга суза, икенче өлешне үзе ашый башлый. Шулай сүзсез генә тамак ялгап алгач, хәл-әхвәл сорашуга күчәләр.

— Ничек монда син, Каюм? Кайта алдыңмы туган авылыңа?

— И-их!.. Кайтып ни эш кыра алам ди мин анда? Уйлап кара, Тайми, аяксыз крәстиян нишли алсын ди авылда? Мондый хәлдә авылдашларым күзенә ничек күреним? Әти-әниемә дә артык бер йөк кенә бит мин хәзер. И туган, аңласаң иде...

— Аңлыйм мин сине, Каюм, бик аңлыйм. Тик син шуны бел: яңа власть хезмәт кешесен һичкайчан бәладә калдырмаячак! Революциянең асылы шунда. Күңелеңә нык беркетеп куй моны. Без болай итик... Тукта, иң элек мин иптәшләр белән киңәшим. Шундый да акыллы дустым бар минем. Зур революционер. Әнә шуның белән сөйләшеп карыйк. Нинди киңәш бирер, бүген үк килеп әйтермен. Булмый бу болай, Каюм.

Тайми шул көнне үк Эәро белән очраша.

Финляндиядәге эшчеләр революциясе житәкчеләренең берсе Эәро Хааналайнен, 1918 елның январь вакыйгаларыннан соң, бар көчен Россиядә Бөек Октябрь идеаллары тантанасы өчен көрәшкә багышлый. Ул Тайминың окопташ дусты Каюм турында сөйләвен игътибар белән тыңлый.

— Революциядә бериндн вак мәсьәләләр юк,— ди ул.— Бүген үк хәл

итәргә тырышырбыз без моны, Таймн.

Ээро бу турыда көрәштәше Отто Вильми белән дә сөйләшә.

— Бәлки, бу турыда иптәш Ленин белән киңәшербез? — ди Отто.

— Монысын, бәлки, син үз өстеңә алырсың? — ди Ээро. Мәсьәлә шунда, Отто Вильми РСДРПның Стокгольм съездында Владимир Ильич белән очрашкан, аның белән сөйләшкән кеше. Бу турыда ул еш кына горурланып искә ала торган була.

Алар Ленин янына бергәләп керәләр.

Яшь Совет иленең тышкы һәм эчке дошманнарына каршы гаять киеренке көрәш алып барган көннәре бу. Владимир Ильичның эш вакыты минутлап бүленгән. Кичектергесез хәл ителергә тиешле мең-мең мәсьәлә баш калкыта. Барысы да кичектергесез, барысы да мөһим.

Владимир Ильич фин иптәшләрне кабул итәргә дә вакыт таба. Кремльдәге җыйнак, якты кабинеттан чыкканда, аларның кулында менә шушындый язу була:

В народный комиссариат социального обеспечения.
10.V.1919 г.

Прошу оказать всяческое содействие и помощь предъявителям сего финским товарищам... в деле устройства 500 инвалидов, пострадавших в войне с белыми.

Председатель Совета
Народных Комиссаров В. И. Ульянов (Ленин)

## 7

Окопташ дустының күңеле урынында түгел икәнлеген Таймн ерактан ук сизенләп ала. Каюм гармунын берьяк иңбашына аскан да, култык таякларын як-якка селтәп, арлы-бирле йөренә. Таймн, йөгереп килеп, дустының иңбашыннан кочып ала.

— Каюм! Беләсеңме... Ленин безнең кайгыларны яхшы белеп торган. Менә син, аяксыз крестьян авылда нишләсен, дисең. Аның каравы, кулларың исән бит, менә шушы сөялле кулларыңа берәр һөнәр үзләштерергә кушкан Ленин, торыр урын бирергә кушкан.

Арты каерылган авыш эскәмиягә җайлап килеп утыргач кына, Таймн дустындагы үзгәрешкә игътибар итә: Каюм җитү сакалын бик шома кырган, уңган гимнастеркасы чип-чиста юылган.

Кулларында Ленин язуы булган фин иптәшләр үзләренә тапшырылган эшне кыю һәм тиз башкаралар. Икенче көнне үк элекке ак полковник Никольский йортының бикле ишекләре зыңгылдап ачыла, шунда ук урынҗир, кием-салым, азык-төлек төялгән олаулар килеп туктый. Өске каттагы бүлмәләрнең ишекләренә «Итек тегү һәм ремонтлау», «Музыкага өйрәнү», «Столярлык эшләре» кебек язулар эленә, аскы каттагы кухняда гөлдергөлдер килеп казаннар кайный башлый.

Юынып, чиста күлмәк-ыштаннар алмашып, анпары бер тәлинкә тары боткасы ашап, кайнар чәй дә эчеп алганнан соң, Каюм үзен бу дөньяга яңадан тугандай хис итә башлый.

Шунда аның ятагы янына әйбәт кара костюм кигән җирән сакаллы бер кеше килеп туктый.

— Сезне, Юнысов иптәш, кайсы группага языйк? — ди ул, караватбашындагы тальянга карап.— Әлбәттә, музыка группасынадыр?

Әллә нәрсә генә була шунда Каюмга. Гүя ятагы-ние белән талгын гына өскә, биеккә-биеккә очып барадыр кебек тоя башлый ул үзен. Әй, дөнья! Кичә генә ул гармун аскан, көчкә сөйрәлүче йончыган бер сукбай иде. Бүген ул якты, җылы бүлмәдә утыра, өсте-башы чиста, эчкә җылы ризык та керде. Барыннан да бигрәк, кичә генә аңа күпләр кырын күз белән карап үтсәләр, бүген ягымлы итеп «иптәш» дип дәшәләр.

— Юк, ни... иптәш! Гармун ул минем болай гына... Син мине чын эшкә яз. Итек тегәргә дә өйрәтәсез бугай, шунда яз син мине,— ди Каюм һәм, Тайми сүзләрен хәтерләп, бармакларын тиз-тиз йодрыклап-җәеп ала.— Бу куллар булдыра әле. Чын эшне дә булдыра. Ни... Итек тегү эшенә өйрәнергә яз син мине, иптәш?..

## 8

Агымсуда, басма өстендә
Керләр чайкый сай җирдә...

Нигә гел күңелдә кабатлана соң әле бу җыр? Куллар һәр төпчем саен җитезрәк хәрәкәтләнә, калыпка баш киерә, күн кисәкләре генә булган өлгеләр нинди матур итек кыяфәтенә керә бара. Каюм, башын артка каерыбрак, үз эшенә сокланып карап куя, кулларындагы безе, җылык-җылык килеп торган сумалалы җебе, җанлы булышчылар кебек, күндәм-бердәм җөй сузуын белә.

Агымсуда, басма өстендә-әәй...

Эшли торгач, билләрне бераз язып җибәрергә дип, коридордан бер әйләнмәкче итте Каюм. Тамак та кипкән икән, култык таяклары аны почмактагы су багына таба алып китте. Бак өстендәге калай кружкага үрелүгә, артта бик ягымлы тавыш яңгырады:

— Сабыр ит, милый, яңа су салам.

Борылып караса, кулына тулы чиләк күтәргән туташ, аңа күптән таныш кызыкай басып тора. Юк, хәзер ул сарафаннан түгел, өстенә көрән халат киеп алган, башында — кысып бәйләнгән кызыл яулык. Йөзгә ябыгыбрак киткән, ә күзләре — һаман шул ук.

— Әллә таныдыңмы солдат?

— Танымыйча!.. Югалган кыз.

— Югалмадым... Югала гына яздым. Тиф бәреп еккан иде. Тазардым инде.

— Их, Миңсылу!.. Карале, исемең ничек соң әле синең?

— Агаша дип йөртәләр. Сине кем дип белик?

— Каюм мин.

— Каюм-Коля, әйтче... Мин-сы-лу ни дигән сүз ул? Безнеңчә әйтсәк, ничек була?

— Миңсылумы?.. Ничек кенә аңлатырга? Миңсылу — красавица с родинкой дигәнне аңлата инде. Әйе, әйе, красавица с родинкой.

— Ох, күзең очлы икән үзеңнең! — Агаша моңарчы каядыр яшерелгән йөз нурын балкытып, елмаеп җибәрә; бер уңайдан, күз иярмәслек хәрәкәт белән, халат якасын өскәрәк күтәреп куя. Шулай да Каюм күреп өлгерә: муен турысында ясмык бөртеге хәтле генә күренсү миңе бар икән ич моның. Халат якасы белән капламакчы, янәсе...

Каюмның йөрәге авыртулы-рәхәт кысылып куя.

Ихтимал, Миңсылуның да бардыр инде ул миңе. Булмый калмас, татар халкы кызлар исеменә юкка гына «миңле» сүзен дә өстәп кушмый. Ләкин авылда чакта Каюмның моңа аз гына да игътибар иткәне булмады.

Инде менә аның каршында Миңле-Агаша басып тора. Халат якасы белән миңен бик җитез каплап куйды үзе, бу вакытта әнә ничек балкып елмайды. Шул чиксез сөйкемле кул хәрәкәте, аннан да бигрәк, шул балкышлы елмаюы белән егет күңелен әллә нишләтте. Елмаюлы, сөйкемле-җитез кул хәрәкәтле һәм миңле бу мизгел — ике яшь йөрәк арасында күзгә күренмәс җепләр сузылу мизгеле булды. Ә инде ике арада күңел җепләре сузыла икән, бу инде бер дә тикмәгә түгел. Җепләр бәйләнер өчен, төйнәлер өчен яисә чуалып-чәбәләнер өчен сузылалар.

## 9

Ачлыгы-ялангачлыгы, дәрт-дәрманы, мәхрүмлекләре һәм зур өметләре барысы бергә булган ул өермәле елларда җепләрнең шулай чуалыбрак киткән чаклары да булмый калмагандыр. Булгалагандыр.

...Төрле һөнәргә ия булып алган сугыш инвалидлары соңыннан «Вихорь» кооперативына берләшәләр.

— Кеше гомерендә һәрвакыт нәрсәдер җитешми, ул һәрвакыт нәрсәгәдер өлгерә алмый яисә нәрсәнедер эшләү аның кулыннан килми,— ди кооперативның рәисе Николай Иванович.— Без менә шуларның күбесенә өлгерергә тиеш. Җилдәй җитез булырга тиеш. Әйе. Әһм...— Ул, гадәтенчә, күңелле-хәйләкәр тамак кыргалап, «Вихорь»ның киләчәк ният-планнары турында сөйләп китә.

«Вихорь» остаханәсе беренче көннәрдән үк җилдәй җитез эшләп китә дисәк, бу әле һич тә дөреслеккә килеп бетмәс, турысын гына әйткәндә, чеп-чи ялган булыр. Әйтә мондый көннәрдә Николай Иванович:

— Күргәнегез бардыр инде, туганнар, оста тегерманченең тегермән канатлары тып-тын тымызык көннәрдә дә әйләнүдән туктамый. Сызгырып булса да җил чыгара ул, ягъни канатларны шундый итеп борып куя ки, җил дә исми кебек, ә канатлар әйләнепме әйләнә. Әйе. Әһм... Әйдә уйлашыйк әле, ни җитми икән эшебездә?

Уйлашалар, киңәшәләр, бәхәсләшәләр. Уй-күңел өермәләре эш өермәләренә әверелә. Әйләнә «Вихорь»ның канатлары, әйләнә.

Каюмның куллары төнчем артыннан төнчем тезә, күзләре исә Агашаны әле ары, әле бире озатып кала.

Агаша да Каюм янында еш туктала.

— Ой, кайсы бәхетлесенә генә насыйп булыр икән мондый да матур, мондый да нык итекләр?!

— Иң матурын тегәр көннәр алда әле, Агаша. Иң матуры — Миңле-Агашага!

— Күп сөйләнгәнче, кулмәгеңне салып калдырырга онытма. Керләнеп тә өлгергән. Армый эшлә, Каюм!

Әйләнә «Вихорь»ның канатлары, әйләнә.

Шулай көннәр, айлар үтә.

Ә көннәрнең берендә... «Вихорь» осталарын гына түгел, илне, дөньяны кара кайгыга салган көн килә. Владимир Ильич Ленинның вафат булуы турында хәбәр була ул.

Зыкы суык январь иртәсендә «Вихорь» осталары да бөек юлбашчы белән хушлашырга Кызыл Мәйданга юнәләләр. Каюм белән Агаша янәшә атлый.

Уртак кайгы кешеләрне тиз якынайта. Каюм белән Агаша арасында сузылган күңел җепләре нәкъ менә шушы көннәрдә бергә төйнәләләр. Озакламый «Вихорь» ширкәте дуу килеп Каюм белән Агашаның кызыл туен үткәрә.

## 10

Еш кына ширкәт рәисе Юнысовларның чиста-пөхтә кечерәк кенә бүлмәләренә кич утырмага керә. Керүгә, өстәлгә сиздермәстән генә үзенең клиндер, конфет-прәннек кебек күчтәнәчләрен куя да, кечкенә Мансурны түшәмгә кадәр чөя-чөя бер сөеп ала. Алтындай балкыган җиз самавыр өстәл түренә менеп утыра. Чәй эчә-эчә җай гына әңгәмә китә. Тормыш гамьнәре, илдәге, дөньядагы хәлләр турында гәпләшәләр, сүз җебе еш кына «Вихорь»га килеп бәйләнә.

Бервакыт Николай Иванович, Мансурның әтисе ясаган агач атлар, арбалар, бармак тиюгә зыр әйләнүче тегермән, канатларын җилфер-җилфер талпынучы күбәләкләр белән мәж килүенә кабат-кабат күз салып уты-

ра да, кинәт кенә бөтен бит җыерчыкларын яктыртып, әйтә:

— Карале, Юнусов, Мансурның бу ат-арбалары, тегермәне, күбәләкләре безнең «Вихорь»га күпме өстәмә табыш бирә ала бит! Уйлап карыйк әле.

— Ничек... табыш?

— Остаханәдән көн саен күпме йомычканы, тегенди-мондый калдыкны чүплеккә чыгарып атабыз, яндырабыз. Әйтик, шул калдыклардан менә шушындый уенчыклар ясауны оештырсак?

— И-и, Николай Иванович, шәһәр баласының алай ат-арба, тегермән ишеләргә бик исе китәр микән соң?

— Алай димә син, Каюм. Шәһәрнекеме-авылныкымы, бала — бала инде ул. Әллә безнең Мансурның чын тегермән күргәне бармы? Ә иң яраткан уенчыгы шул! — дип сүзгә кушыла Агаша да.

Күп тә үтми, «Вихорь» остаханәсе Каюмның балачакта үзе уйнап үскән мондый уенчыкларны ясап та чыгара башлый, табышын да китерә. Әмма бу хәл Каюмның күңелендә шатлыктан бигрәк, моңарчы тирән үк яткан моңсулык уята. Әнә шул ат-арбалы, тегермәнле, күбәләкле туган якларын өзелеп сагына ул. Юк бит башкалада боларның берсе дә... Юк.

Агаша да көтмәгәндә, кырык эшен кырык якка куеп, Каюм янына килеп утыра да:

— Син, картым, гармуныңны бөтенләй оныттың әле. Әйдә, уйнале бер,— ди. Һәм, нинди көй уйнарга икәнлеген үтенгәндәй, тын гына суза:

Сарман буйлары ла...

Бер кичке әңгәмәдә Николай Иванович, илдә бара торган яңалыкларның иң зурысы итеп, әйтеп куя:

— Синең кемнәрең бар әле авылда?

— Әни белән әти карт та, ике сеңел. Олысы инде кияүгә чыкты.

— Менә, күрдеңме сезнең гаиләгә дә иген игү, мал асрау җиңел түгел анда. Ә менә кооперативларга берләшкәч, һәркайсына кулыннан килердәй эш табылачак. Кулыннан килердәен эшли дә, тиешле түләвен дә ала.

— Димәк ки, мин дә?..

— Ну-ну! Син тик кенә утыр, яме. Син — безнең кооператив члены. Агаша да безнеке. Сезнең турыда сүз бармый монда.

Шалтыр-шылтыр табак-савыт юучы Агаша, аларның сүзен ишетмиме, дәшми. Николай Иванович, саубуллашып чыгып киткәч, ул тын гына ире янына килеп утыра.

— Каюм! Син авылыгыз яныннан Сарман елгасы ага, дия идең. Әйт әле, каеннар да бармы елга буенда?

— Бар, Миңле-Агаша, бар. Шундый матурлар, зифалар.

Агаша, тыелып кына, сиздермәскә тырышып кына, тирән сулый.

— Әгәр монысы кыз бала булса, Миңсылу атлы кушарбыз, яме?

Каюм, нәнине назлагандай, Агашаның чәчләреннән сыйпап куя.

— Ә малай туса?

— Малай тусамы?.. Каюм, сугышта үлгән абыем Яков исемле иде.

— Яков... Кара син, безнең халыкта да бар бит андый исем. Якуб.

Ир белән хатын, бер-берсенә карашып, елмаешалар.

...Язын, Каюм белән Агаша бергәләп өй буена утыртып куйган яшь пар каен беренче бөреләрен ярган көннәрдә, уллары Якуб дөньяга килә.

Күп тә үтми, бөтен «Вихорь» кешеләре аларны ерак юлга — Сарман буендагы Шәрләрәмәгә озатып калалар.

## 11

Вакыйганың баллада өлеше шушында төгәлләнә бугай. Хәер, һәркемнең гомере үзенчә бер баллада ул. Олы-яктысы бар аның, моңлысы бар, гаять ачы-фаҗигалесе...

Шуңа да мин бу вакыйганы җыр-музыкага салып та түгел, шигырь-поэма итеп тә түгел, ә кулымнан килгәнчә, үземчә хикәяләп бирергә булдым.

Күңел кылларымны кайчан, ничек тибрәтеп җибәрде соң әле бу гади дә, моңсу да, каһарман да гомер?

...Язмыш мине дә сугыш инвалиды итеп калдырды. Дөнья халыкларына инде икенче мәртәбә кара сугыш афәте булып ябырылган еллар язмышым-да шулай чагылды.

Соңгы вакытларда безне, сугыш инвалидларын, ел саен шифаханә-ләргә чакырып алалар да сәламәтлегебез ни хәлдәрәк икәнлеген тикшереп торалар.

Әнә шундый чираттагы тикшерү вакытында, врачка керергә үз нәүбә-темне көтеп утырганда, күршем әйтә куйды:

— Хәтеремне калдырдылар әле, малай. Үземә әйтеп тә тормастан, ты-нычлык фондына дип, зарплатамнан акча тотып калганнар. Соң инде, шунда үземә әйтеп алсалар? Бигрәк инде... Безне санга да сукмаулары-мы бу?

Икенче яктагы күршем, таягы белән аягына суккалап куйды:

— Бер караганда, без инде тынычлык фондына җитәрлек бирдек.

— Менә шул-шул,— диде хәтере калган күршем. Аның кулында да таяк иде.— Ярый, мин бер генә аягымны бирдем. Ә менә әти ике аягын да биргән... Шул ук тынычлык фондына дияргә була инде.

— Әтиең дә сугышта булды мени? — дип сорыйсы иттем мин күр-шемнән.

— Булган. Ләкин бу сугышта түгел, теге, беренче герман сугышында. Авыр булган әтинең хәле. Ике елга якын госпитальдә ятса да, авылга кайтып җитәрлек хәле булмаган. Шуннан соң әти Ленинның үзенә мөрәҗәгать итә.

— Ленинга?!

— Әйе, Ленинның үзенә. Бер фин коммунисты ярдәмендә. Бар инва-лидларны да көченнән килердәй һөнәргә өйрәтергә, торыр җир, ашау-эчү якларын җайга салырга кушкан Ленин. Шул турыда язу биргән.

— Менә бит, ә! Кайсы елда була инде бу?

— Әти, бәлки, елын-числосын да әйтеп сөйләгәндер... Мин ул вакытта бала гына бит әле, хәтергә сеңдереп яки язып кую турында башка да килмәгән... Шуннан төрлесе төрле һөнәр үзләштереп чыккан инвалидлар халыкка бик кирәкле әйберләр эшләү, төрлечә хезмәт күрсәтү ширкәтенә берләшәләр. Бар эшләп тапканнары уртак була боларның, тогәл исәптә бу-ла. Барысын да уртага салып киңәшеп эшлиләр, тиенен дә киңәшләшеп кенә тоталар. Әти шулай сөйли иде. Кайда инде ул, хәзерге кебек, үзеңә дә әйт-мәстән, зарплатаңнан тотып калулар. Тынычлык фонды дип... Әгәр киңә-шеп эшләнсә, кем инде андый фондка каршы килсен!..

Ул арада врачка керергә аның чираты җитте. Мин ашыга-ашыга со-рашып кала алдым: исеме Мансур икән, Сарман районының Шәрләрәмә авылыннан. Әтисе — Каюм Юнысов, хәзер мәрхүм инде. Әнисе — Агриппи-на Васильевна, шулай ук иреннән калып озак яши алмаган. Мансур хәзер Әлмәттә тора икән...

Без Мансур белән еш кына очрашып, озак-озак сөйләшеп йөри торган булып киттек. Язмышларында күп уртаклыклар булган кордашларның сөйләшер сүзләре бетәме? Бу сөйләшүләр күңелдә уянган моңны көчәйткән-нән-көчәйтә бара, бу моң, бу аһәң романнарга сыймаслык булып ташый иде. Безнең Мансур белән сөйләшеп йөрүләр, күңелне ашкындырганнан-ашкындыра барса да, фактка әллә ни өсти алмады.

Димәк, тарихка — серле тарихка чумарга кирәк.

Тарих сәхифәләрендә актарынуларым мине тиздән В. И. Ленинның өч фин иптәшкә биргән, югарыдагы язуга юлыктырды. Каюмның ачы яз-мышына якты нур сипкән язу шушы түгелме? Кемнәр алар, фин иптәшләр? Кемнәр алар, 500 инвалид? Нәкъ Каюм Юнысов сөйләп калдырганча

булганмы вакыйга, әллә бүтәнчәрәкме?

Кызганычка каршы, мин бу сорауларга хәзергә төгәл генә җавап таба алмадым. Җитмәсә, фин иптәшләрнең гомер юллары фаҗигале утыз сигезенче елда өзелә...

Каюмның якташлары белән күп тапкырлар очрашулар... Тарих сәхифәләрендә гел актарынулар... Болар тора-бара бер нәрсәне ачыкладылар. Һәркемнең күңелендә олы Тарих үзенчә яңгырый. Һәркемнең үз моң-җыры. Минем Каюм Юнысов турындагы җырым баллада булып яңгырый түгелме соң? Халык күңелендәге баллада.

## 12

Иртән, таң алдыннан, шыбырдап кына яңгыр явып үтте. Быелгы коры җәйдә бик көтелгән, зарыктырган яңгыр иде бу.

Яктырганда, басулар өстен иңләп, офыктан офыкка кадәр, тоташ күксел-ак томан сарган иде. Томан гүя җирнең бар авазларын да каплап алган, гүя үзенә сеңдергән.

Мондый иртәне игенче бик ярата. Томанлы иртәнең көндезе кояшлы, җылы-җилсез булучан. Аннары, томанлы иртә — алда тагын шифалы яңгырлар вәгъдә итә. Бу яңгырлар инде быелгы уңышка әллә ни өстәмәс, ә киләсе ел уңышы өчен бик тә кирәк ул тамчылар.

Юлдашым Якуб та нәкъ шул турыда уйлап бара икән.

— Өмет тамчылары булып яуды бүгенге яңгыр. Акыллы да соң бу табигать! Кеше күңеленә өмет дигәнен тамызып кына тора. Һич өзмәс.

Якуб — озын гына буйлы, иппе-салмак хәрәкәтле ир. Инде пенсия яшенә җитеп килә. Аның кояшта янган озынчарак йөзенә карап, мин кинәт шуны абайлап алдым: нәкъ әтисе чалымнары чагыла ич анда! Без кичә аның өйләрендә гаилә альбомын карап утырган идек. Каюм Юнысов Агриппина Васильевна белән уллары Мансур һәм Якубны алларына утыртып фотога төшкәннәр. Шәрләрәмәгә кайтып китәр алдыннан, Мәскәү хатирәсе итеп.

Анысы, һәркемдә ата-баба чалымнары чагылмый калмый. Ләкин монда төс-кыяфәт охшашлыгы гына түгел, бик тирәннән килүче эзлекле эчке охшашлык та ярылып ята иде. Моны Якубның һәр сүзеннән, һәр хәрәкәтеннән сиземләп була.

Безнең әңгәмә тагын ерак хатирәләрне актара башлады.

— Әти дә, ничек авыр йөрмәсен, басуларны шулай бер әйләнеп кайтырга бик ярата иде. Арып-талчыгып кайтып керә дә сәкегә сузылып ята. Әни шунда ук янына чәй ясап китереп куя. Әти, чәй эчә-эчә, әй китә сөйләп, әй китә. Игеннәрнең ничегрәк торышыннан башланып китә сүз, колхозда эшләрнең барышына килеп тоташа. Аннары Мәскәүдәге тормышларын искә төшерүләр, газета хәбәрләре. Әни, бетмәс өй эшләреннән һич туктап тормый гына, аңа кушылып китә, еш кына уен-көлке кыстыргалый. Шунысы гаҗәп: әти һич кычкырып сөйләми, җай гына сөйли, ә әни аның һәр сүзен ишетә, аңлый иде.

— Ничек?

— Ничек дип... Әни минем яшь чагында бик каты тиф белән авырган, шунлыктан, өлкәнәя төшкәч, колакка ныграк иде. Башкалар сүзен, кычкырыбрак әйтмәсәләр, бик ишетеп тә бетерми, ә минә әтинең һәр сүзен ишетә иде. Иң гаҗәбе шунда әле аның. Кайвакыт, без бала-чага ишетмәскә тиеш диптер, үзара пышылдашып та алалар, бик тиз аңлашалар иде үзләре. Гаҗәп бит!

— Әйтмә дә. Шуны сорыйм әле. Агриппина Васильевна татарча сөйләшә идеме?

— Ничегрәк дип әйтергә?.. Татарча барысын да аңлый, ә сөйләшүгә ягыннан бераз авыррак иде. Шул, колакка ныграк булуы комачаулагандыр инде. Күрше-күлән белән гел татарча сөйләшә иде ул. Авыл халкы бик якын

итте үзен. Гайшә дип, Гайшә апа дип кенә йөрттеләр.

Юлыбыз сөзәк яр буена килеп чыкты. Аста тын елга агышы тәэсир иттеме, беразга сүзсез генә атладык.

— Әллә бераз утырып алабызмы? — диде Якуб, яр буе чирәменә күрсәтеп.

Сүзсез генә берәрне көйрәтеп җибәргәч, елга агышыннан күзләрен алмыйча, Якуб әйтте:

— Син миңа һаман әтием турында сорашкач, күрсәтим дидем. Әтинең ял итәргә чыгып утырырга бик яраткан урыны бу.

— Сайлый белгән Каюм агай ял урынын.

— Күр, барысы да бар бит монда. Елгасы, болыны, өстәрәк басулар башлана.

— Искиткеч! Минзәлә елгасымы әле бу?

— Карталарда шулай дип атала. Елга Минзәлә янында Ыкка килеп кушыла бит, шуңа атаганнардыр инде. Ә субашы аның Сарман районында, халык та аны безнең якларда аккан өлешен Сарман суы дип атый. Җыры да бар бит: «Сандугачлар гына кунып сайрый Сарман буйларында тирәктә...»

— Аңлашыла алайса. Миңа Мансурның сөйләгәне бар. Каюм агай лазаретта ятканда «Сарман» җырын җырлый торган була. Аннары шушы җыр аркасында алар әлеге окопташ дусты белән яңадан очрашалар. Мәскәүдә.

— Әтинең Мансур абый белән серләре бик күп иде шул. Икесенең дә яшьлек еллары сугышта үткән. Аннары, ни генә әйтмә, олы малай бит. Икәүләшеп, шушы урыннарда сөйләшеп йөргәннәрен хәтерлим. Әй, китәләр, минсиңайтим, икәүләшеп титаклый-титаклый, икәүләшеп таякларын селти-селти...— Ул күңелле елмаеп җибәрде дә, шаян бит җыерчыклары шунда ук күләгәле җитдиләнде.— Алай дим дә... Болай йөрүләр бик еш эләкми иде шул үзләренә. Мансур абый тиздән Урал якларына эшкә китеп барды. Әти шулай атнага-айга бер җилләнеп керә дә, басылып эшенә утыра. Колхозның камыт-шыгырчакларын, сбруйларын төзәтеп тору аның өстендә иде. Хәзерге кебек басу тулы трактор мени әле ул чакта. Бөтен кыр эшләре атлар сыртында. Аннары, итек тегү, аяк киемнәре ремонтлау эшләре дә һич бетеп тормый. Ул елларны үзең беләсең инде. Аяк киемең туздымы, кибеттән тизрәк яңасын барып аласы түгел. Әти берүзе бөтен тирә-якка, хәзергечә әйтсәк, көнкүреш хезмәте күрсәтте.

Сөйләшеп утыра торгач, күе томанның инде тәмам эреп юкка чыгуын да сизми калганбыз. Битләрне кояшлы, җылы август җиле сыйпап үтте.

— Якуб, тагын шуны сорыймчы. Каюм ага өлкәнәйгәч тә тальянда уйный идеме?

— Әйе, уйнаштыра иде. Сугыш башланган елны әтинең авылдашларны гел гармунда уйнап озатып калганнары бик истә.

Ул, елгага караган көйгә, беразга сүздән калды. Елга агышы хатирәләр агышын тибрәтә иде бугай.

— Тагын шул бик истә. Илленче елларда монысы. Шулай, югары очның Миңсылу әби үлде... Тукта, елын да төгәл хәтерлим. Илле бишенче елның май башлары бу. Әйе, әйе. Хәтерләмәскә, шуннан соң, нәкъ бер ел үткәч, әти дә дөнья куйды. Ярый, анысы соңыннан. Кичтән үк хәбәрен ишеткән булгандырмы, әти иртүк торды, бик тырышып кырынды, өс-башын алмаштырды. Шомырт чәчәк аткан чак, өй түрендәге шомырт буенда озак кына басып торды. Кесәсенә бер тәлгәш чәчәк тә өзеп тыкканы истә. Монысы шуңа истә калган: чөнки шулчак як-ягына карангалап куйды, әйтерсең, чит бакчадан чәлдерә... Китте авыр гына атлап. Сизеп торам, кәефе бер дә әйбәт түгел үзенең, ләкин... ничек бармыйсың? Тормышы җиңелдән булмады Миңсылу карчыкның. Ире сугышта үлде, өч малаен шул авыр елларда ялгызы ничек аякка бастырганын үзе генә беләдер. Аякка бастылар да, өчесе өч якка дигәндәй, очып та киттеләр. Ул елларда шул Кузбасс якларына инде. Йотып кына бара яшьләрне. Минекеләр дә менә, дүртесе тиңентен, Чаллыга китеп урнаштылар. Төпчегебез Фидаи Армиядә, кайткач, монысы янибызда калмасмы дип өметләнәбез... Ярар,

мин читкә тайпылмыйм әле. Шулай, китте әти Миңсылу карчык белән хушлашырга. Өйлә авышкач, кайтып керде. Озак кына ятып торды. Шуннан соң, гармунын иңбашына асты да, минә шушы урынга чыгып китте. Һәм, беләсеңме, кичке шәфәкъ баеганчы бөтен авылга тальян моңы яңгырап торды. Соңыннан сөйләделәр, безнең бу як урамнар гына түгел, югары очлар да ишетеп торган. И-и, нинди генә көйләр уйнамады әти!.. Ихтимал, соңгы тапкыр гармун тартуы булды бугай аның. Әйтәм бит, Миңсылу әби белән чордашлар, бар күңел моңын бушатуы булгандыр бу әтинең... Кая соң, кузгалыйк, шактый юандык. Карчыкның чәе суынып бетәдер анда.

Шулай дисә дә, үзе урыныннан кузгалмады. Һавага күз йөртеп алды. Аннары кинәт сикереп торды.

— Кара, әтинең истәлеген күрсәтмәдем ич әле мин сиңа. Кичә сүзгә мавыгып хәтердән дә чыккан.

— Нинди истәлек?

— Әтинең итек тегү кораллары. Эреле-ваклы калыплар, чүкече, бизе...

Безнең әңгәмә аягүрә баскан килеш тә һаман дәвам итте.

— Кооператив дигәннән... Әти авызыннан еш ишетелә иде бу сүз. Кооператив дигәч, без авылның кибетен күз алдына китерәбез. Ник дигәндә, авылда кибетне шулай «кооператив кибете» дип йөртәләр иде. «Кооперативка ситсы кайткан, пай түләсәң генә бирәләр икән»,— диләр. «Пай түләсәң, кооперативта такта чәй бирәләр»... Әнә шундый сүзләр генә колакка эленеп калган безнең. Баксаң, әти бу сүзне бөтенләй бүтәнчә мәгънәдә әйткән икән ич. Колхозда ул чакта төрле тәртипсезлек, хуҗасызлык хәлләре чыгып кына тора. Әтинең боларга бик эче поша, бик ачынып сөйли иде. «Юк, җәмәгать, Ленин өйрәтеп калдырган кооперативлар болай булмаска тиеш ул. Нәрсәнедер бозалар, үтәп бетермиләр Ильич өйрәткәннәрне»,— дип авылдашлар белән сөйләшеп утырганнары хәтергә төшә хәзер.

Күпер чыкканда Якуб, култыксага таянып, тукталып калды.

— Әтине Ленин белән очрашкан, Ленин үзе аның белән кул биреп күрешкән кеше, дип йөртәләр иде. Хәзер дә бөтен тирә-юнь моны риваять итеп сөйли...

— Әйе, әйе. Мин дә нәкъ шулай сөйләгәннәрне ишетеп килдем.

Елга агышына карап тагын күпме басып тордык икән? Тормыш мизгелләре вакыт үлчәвенә сыя микән!

Ага Сарман суы. Тын гына көрсенгәндәй, тыелып кына ярсыгандай, иркенләп бер сулагандай ага. Ага да ага...

*1987 — 1988*

*Әлмәт — Шәрләрәмә — Әлмәт*

# ШИГЪРИЯТ

## Данис Хәйруллин

### Күлле шәһәр

Ап-ак шәһәр. Ак йөзенә, һай, килешә
Каеннарның, чаганнарның яшел төсе...
Ак шәһәрдә каян соң бу, нәрсә яна?
Тыннарыма тынгы бирми көек исе...

Күрмәссең бер авыш тәрәз, кыек ишек —
Төзек шәһәр, төзек монда бөтенесе.
Чиркәүдәге тәреданме, мәчеттәге
Айданмы соң — кайдан соң бу төтен исе?

Күлгә баксам — йөз карала, күз карала.
Күккә баксам — мең ел элек йөзгән болыт.
Иң дөресен алар белә, алар гына...
Кемнәр йөргән бу шәһәрдә, ниләр кылып.

Пыскып яткан кисәүләргә баса-баса,
Тарихының төпләренә кадәр төштем...
Төзисең дә яндырасың, нәрсә соң бу?
Нәрсә белән бөек соң син, кеше мескен?

### Халәт

Идел өсте якты көзге иде,
Алама җил ватты көзгене.
Җәй уртасын ялмап кына алды
Итәгендә килгән көз өне.

Бер мизгелдә дөнья алышынды,
Сүнеп-сүнеп алды кояшым.
Идел түзсә, кеше түзәр, диптер,
Тузгытты җил яшен оясын.

И коелды, и коелды утлар!
Күз тутырып яшен-ут җыйдым
Һәм кабындым... Юк, юк, мин элек тә,
Мин элек тә инде ут идем.

Ут — утлыгын яшеннәрдән таный,
Җил җиллеген — давыл туганда.
Мин дә менә — үз-үземә кайттым,
Гамьсезлеккә урын юк анда.

---

*Данис* ХӘЙРУЛЛИН *(1945) — Чаллыда яшәүче яшь шагыйрь, «Хәтер» исемле китап авторы. Шигырьләре көндәлек матбугатта, шул исәптән журналыбызда басылды.*

## Итекче йорты

*Авылдашым истәлегенә*

Бу йортның да сәгатьләре туктаган.
Җилләр генә үтеп йөри тупсадан.
Тоткалары саклый әле йон исен,
Аякларым — киез итек җылысын.

Тәрәзәләр сукрайган — ак төшкән.
...Сискәнәм дә торып басам хак төштән:
— Йон теткәндә иске җәя кереше
Өзелде бит, өзелде бит, күр, күрше!

Сукранды да Сәлах абый вак салды:
— Менә бусы яшь сарыктан — шәп, саллы,—
Һәм киерде җәясенә керешен.—
Йөз итеккә җитә шушы, күрерсең!

Күреп торам: җеге саен үрмәкүч...
Күбәләккә урын сайлый — гүргә күч!
Күбәләккә әйләнгәч тә, аңладым,
Тынмый икән, тынмый икән җаннарың.

Күреп торам, иске җәя кул көтә,
Итекчеләр бармы бүген? Кем тетә?
Пәрәвезлек... Хәтерсез җил көн саен
Күбәләкләр каберлеген селкетә.

## Буяучы карт

Түбә буйый, койма буйый —
Черек-тутык ашамасын.
Буйый акка, йә ахакка
Болдыр, тәрәз кашагасын.

Күкнең төсен — күктәгегә,
Җирдәгегә — җирнең төсен.
Буяучының иманы бер —
Тик үз төсен һәр ни өчен!

Буйый. Буйый. Буяганы
Кара белән ак арасы.
Буйый, юкса белеп тора
Караның да агарасын.

Караласын белеп тора
Буягач та җете акның
Ә барыбер агартмакчы
Табутын да җиде ятның:

— Булса иде җанга үтеп,
Аһ, салават күперейдәй,—
Булмас иде кешелектә
Зәмһәрир кыш, чәчәксез җәй.

Күп уйлаган, күп буяган
Һәм күпләрнең күзен ачкан:
— Буяу шул ул өстә генә...
Вакыт бәреп чыга астан!

## Болгарда

Болгар кызы чулпыларын җуйган...
И сөенә тапкан археолог:
Җиде гасыр аша кулын сузган —
Тәңкәләрне уч төбенә салып.

Ул — туй бүләгедер... Ташлар аша
Үрелепләр карый умырзая...
Соңарганбыз ахры туйларыңа,
Болгар кызы, кая киттең, кая?

## Васыять

Тәрәзәмнән болыт йөзеп керде,
Ап-ак болыт, хыял шикелле.
Таң уртасы иде, аяз иде —
Уйларымда, ахры, шик күрде:

«Уян, олан, уйларыңнан уян!
Төш юрама инде, эш юра...»
Ап-ак болыт, ап-ак болыт никтер
Керфегемә кунып куера.

Һәм чылатты ап-ак мендәремне...
И яктырып китте дөньялар.
Тәрәзәмне киереп ачып куйдым —
Мондый таңнар тагын кемдә бар?

Авыр төшләр төште күңелемнән,
Һаваларга ашмый чак калдым.

Шул иртәдә гомерем буе көткән,
Бик бәхетле иткән хат алдым:

«Саумы, балам! Син — җиденче буын,
Җиде кат җир безне аера.
Таңың аткан инде, таңың аткан,
Калган бары кояш баерга...

Әманәт шул: илең, телең сакла!
Шөкер, әле безнең уйда син.
Синнән тагын җиде буын калыр,
Җидесе дә шулай уйласын!»

Тәрәзәмнән ап-ак болыт керде,—
Таныдым мин Хәтер икәнен...
Оныкларым, сезгә хәтеремне,
Хәтеремне васыять итәмен!

## Күзме әллә?

Су буйлары сары саз булса да,
Бәпкәләре инде каз булса да —
Җәй әле бу!

Күңелкәем моңсу чак булса да,
Кипкән яфрак кебек сак булса да —
Җәй әле бу!

Күзләремә җылы яшь бәрсә дә,
Яшәрсәнә, хәтер, яшәрсәнә —
Җәй әле бу!

Карашларың никтер сәерләнгән,
Карлар явар кебек син көлгәннән —
Күзме әллә?

## Аклыкка соңару

Тулган чагым,
Бик тулышкан чагым,
Ай, дигәндә айга менәр чагым.
Искә төштең бүген, хәтерләтеп
Хисләремнең мамык мендәр чагын.

Тулган чагым,
Ташып-ташып торам,
Ир булсам да инде «балакай»дан.
Мендәреңнең мамыклары ява
Әллә айдан шунда, әллә кайдан.

Күз тимәде,
Җилләр таратмады,
Сукмады бит юкса кояшы да...
Берәм-берәм җыяр идем бүген
Ак мамыкны бәхет оясына.

Иренемә кунып эри аклык:
«Кеше гомерләре тик бер саплам,
Давылдан да калыр бәхет ояң,
Сүздән саклан, сүздән генә саклан!»

Сакланмадым менә...

# Роберт Миңнуллин

## БАЛАЛАР ӨЧЕН ШИГЫРЬЛӘР

### Туган тел

«Туган телем — анам теле»,—
Дияр әле балалар.

«Туган телем — балам теле», —
Дияр микән аналар?

### Кояш алмасы

Җәйге кояш яктырак —
Янып тора ялтырап.

Уяна да иртәрәк,
Уята ул иркәләп

Безнең бөтенебезне,
Безнең һәр көнебезне...

Җәйге кояш эссерәк,
Кыздыра ул көчлерәк!

Үзе шундый түгәрәк —
Бара әнә тәгәрәп.

Әй кызыл, ал да инде —
Нәкъ кызыл алма инде!

Их, кояш — алма булса,
Ул алма алда булса,

Ну ашап куяр идек —
Мөгаен, туяр идек.

Башка авылларга да —
Әйе шул, аларга да

Кояш дигән алманың
Бирер идек калганын!

### Тирәкләргә җил кирәк

«Их, җил чыксын иде дә
Безне уятсын иде,
Их, җил чыксын иде дә
Безне уйнатсын иде,
Их, җил чыксын иде дә
Безне кузгатсын иде,
Их, җил чыксын иде дә
Безгә сүз катсын иде!
Шыбыр-шыбыр
Шыбырдап,
Шыгыр-шыгыр
Шыгырдап,
Сөйләшкән булыр идек,
Серләшкән булыр идек,
Җилләнеп алыр идек,
Сафланып калыр идек.
Җилсез булмый,
Җил кирәк!» —

Диеп уйлый
Тал-тирәк.

---

Роберт МИҢНУЛЛИН *(1948) — шагыйрь, «Бәхетле булыгыз», «Мәңгелек сәфәр», «Айга очтык» h. б. татар һәм рус телләрендә дөнья күргән уннан артык лирика, балалар өчен шигырь китаплары авторы. Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Зу-у-ур авызлы чиләк

Аңлый алмыйм һич кенә —
Әле кичә кич кенә

Чиләгем сулы иде,
Су белән тулы иде.

Бүген иртән торуыма
Чиләктә су калмаган.

Идәнгә дә бер тамчы да
Түгелмәгән, таммаган.

Бозаулар да эчмәгән.
Белмим, ул су нишләгән?

Бу бик серле күренә.
Ә-ә-ә...
Төшендем серенә.

Суны чиләк үзе эчеп
Бетергән булса кирәк.

Чиләк эчкәндер шул, чиләк —
Зур авызлы бит бигрәк!

## Пешмәгән

Сатып алдым мин карбыз.
Тәмле микән? Карарбыз!

Турадым өйдә ваклап.
Ә эче... эче ап-ак.

Тукта, тукта, туктагыз —
Пешмәгән бит бу карбыз...

Ә бит күпме сайладым?!
Бик-бик күпне сайладым.

Чирткәләгән дә идем,
Төрткәләгән дә идем,

Каккалаган да идем,
Суккалаган да идем...

Менә бит нишләгәнмен —
Үзем дә пешмәгәнмен!

## Бу ни эш бу?

Кәефләр шәп булганда
Чыксам әгәр урамга,

Көн буе уйнап йөрсәм,
Кич белән генә керсәм,

Шул урамда — буранда,
Карлар явып торганда,

Лычма су — оегым да,
Лычма су — аягым да,

Юешләнә кулым да,
Юешләнә борын да,

Чабуым да дымлана,
Чалбарым да сулана,

Өйгә кайтып кергәчтен,
Өйдәгеләр күргәчтен,

Күзләрем дә чылана —
Әни бит... ачулана!

## Очасым килә!

— Әтием, минем
Очасым килә!
Ак болытларны
Кочасым килә!

— Син инде, кызым,
Очасың күптән.
Кайтып кермисең
Болытлы күктән.

— Кошлар янында
Тирбәнер идем,
Канатларым юк
Нигәдер минем.

— Канатларың бар,
Кызым, синең дә.
Син аны үзең
Сизмисең генә.

— Йолдызларга да
Менәсем килә.
Анда ниләр бар —
Беләсем килә.

— Гомер юлларың
Әле бик озын —
Йолдызларга да
Очарсың, кызым!

## Илдар Низамов

# КОЛАКСЫЗ ЗАРИФ

ХИКӘЯ



Казанда әле каты сугыш барса да, полклар иртәнге якта ук таралып беткәнлектән, Зариф шәһәрне көн уртасында ук калдырып чыкты.

Башта ул аерым-аерым да, гаилә-гаилә булып та, җәяүләп һәм ат белән дә, кул арбасына җигелеп тә чигенгән, самавыр-ястыклар төяп, кәҗә-сарыгын өстерәп интеккән кешеләр, яралы солдатлар, тиле кебек тик торганда акырып-җырлап барган матрослар арасында болганчык ташкында калган төссез яфрак сыман бөтерелде; дулап-өермәләп давыл якынайса да, яшенләп яңгыр койса да юри аксаклаудан, кулы яраланганга сабышып, мылтыгын сөйрәп атлаудан туктамады.

Аннары гына, урманга килеп кергәч кенә, калганнар сулга — Зөя ягына юнәлгәндә, ул әкрен-әкрен генә уңга каерды.

Ниһаять, башкалардан тәмам аерылды. Шунда ул мылтыгын иңенә асты, аксакламыйча атламакчы булып карады. Кая ул! Аяклар инде чатанлап атларга гына иләшкән, гәүдәсе дә мылтык авырлыгыннан җиргә иңә бара кебек. Мүкәләп диярлек сөйрәлеп, тар сукмактан тагын бераз тайпылды да куе чыршы астына кереп егылды.

Тәне хәрәкәттән тынуга, башын тагын авыру боргычлый башлады. Көне буе чатный инде, каһәр. Менә әлегедәй юл чатында калып, икеле-микеле уйларны хәл итә алмыйча интеккәндә ярыла аның башкайлары, бер дә тик торганда түгел. Казан ычкынды болай булгач, тотып калалмаслар. Матрослар сызды, пехота качты. Көчле, димәк, тегеләр. Чехлар, ди, җитмәсә. Әнглечәннәр дә булыша, ди. «Болай булса, алар Арча, Чар, хәтта безнең Җилгелдедә дә ялт дигәнче булачак,— дип уйлады Зариф.— Ярый әле, аллага шөкер, атып маташмадым үзләренә, берсен дә теге дөньяга җибәрмәдем, үземә дә ул-бу булмады. Хәзер өскә килеп чыксалар да, бирелергә калдым, җай чыкканны гына көтә ием, диярмен...»

Ә болар килеп чыкса, үзебезнекеләр ягъни? Кеше чигенгәч, чигендем дә юлдан яздым, җитмәсә, аяк каймыкты дияр.

Берсе дә килеп чыкмаса нишлисең инде? Гомергә чыршы төбен каравыллап ята алмассың ласа. Өйгә, авылга! Моннан Әлдермешкә дә күп калмый инде, аннары юлны беләм. Их, авылга кайтсаммы?!

Чү, туктале, тумаган тайның билен сындырасың түгелме? Казан ычкынмаган булса? Иә бер-ике көннән болар кире тартып алса? Әнә бит безнең

---

*Илдар НИЗАМОВ (1936) — филология фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Өмет», «Иделем», «Мәхәббәт хакы» һәм башка проза китаплары авторы. Казанда яши.*

ротанықылар Биектау ягына китте. Икенче армиягә кушылабыз да әйләнеп кайтабыз, дип. Вахитов дигән комиссар да каты тора, диделәр.

Бер торды Зариф чыршы астыннан, сулга — Зөя ягына атлап карады; караңгылыкны сылтау итеп, кире чыршы төбенә килеп утырды. Ерак та түгел кешеләр тавышы ишетелеп, ат пошкырган кебек булды, сикереп торып, бу юлы уңга — Әлдермешкә әлдертмәкче булды, тик аяк асты ныграк пычтырдавын тоеп, сазлыкка кереп батмагаем дип, янә борылды.

Мылтыгын да ул башта агач арасына атып бәрде, аннары кире уйлап, мүкәли-мүкәли тагын эзләп тапты, хәтта баш астына ук салып ятты.

Түтә салкыны башның чатнавын баса төшкән кебек тоелды. Бу ягы җылынгач, икенче ягын әйләндереп салып, тагын мылтык салкынлыгын тоюдан бер тын рәхәт кичереп, йоклап та китте...

Зариф сискәнеп уянды. Аталар! Төштә генә түгел, өндә дә аталар ласа! Ул, кинәт айнып китеп, җиргә сыенды.

Тирә-як инде азмы-күпме яктыра башлаган. Атыш, кинәт башланган кебек үк кинәт тынып, аны тагын да сагайтты. Караштырып килми булмас, дип, сагаеп кына бераз атлаган иде, кичә чигенүчеләрдән аерылган юл чатына килеп чыкты. Шунда борылыштан өч ат җитәкләгән ике солдат күренде. Зарифны шәйләп, ялт кына мылтыкка ябыштылар.

Зариф хәрәкәтсез тик катып калды. Бу — кызыллар иде, кичә алар, өч атлы, аны узып киткәннәр иде. «Петроградларны, кавалерияне күрмәдеңме?» — дип тә сораганнар иде.

— Кая юл тотыш? ... диде солдатларның берсе ерактан ук. Зарифка якынайган саен, аның йөзе ачыла кебек иде — кичә күргәнен хәтерләде бугай.

— Бүтәннәр кая, без дә шунда инде, тик адаштым менә,— диде Зариф. Тавыштан тәмам таныдылар, ахрысы, дәшкән солдат мылтыгын төшерде.

— Кайсы частьтан соң син?

— Социалистик ротадан, мөселманский. Таралдык менә...

— Һаман кысалар бит, таралырсың да. Менә безнең дә иптәшне, инде монда чыккач, разведчиклары әрәм итте. Ярый, аты әйләнеп килде әле. Мә, ал пока, аннары күз күрер. Атлана беләсеңме?

— Авыл малае ла без,— дип, Зариф йөгәнгә үрелде, мылтыгын аркасына элде.

Алар тагын бераз җәяүләп бардылар да, «Тирә-якта дошман юк икән, иптәшне аткан разведчик болай гына очраган икән», — дип фараз кылып, яралылар утырган олауларын да алып килеп, алга, Зөя ягына киттеләр.

Солдатлар әле атланып, әле җәяүләп, обоздан читкәрәк китеп, гел алныартны карап бардылар. Зарифны алай ерак җибәрмәделәр. Олау янында гына уяу булып барырга куштылар.

Казаннан ерагайган саен, ату тавышлары да шактый тынып, алар да бераз тынычландылар. Зариф хәтта вәсвәсәләнүдән дә туктады, башы да чатнамас булды. Тик торганда ат кадәр ат бирсеннәр әле! Ифрат рәхәт иде ат өстендә: аның йомшак җылысы бөтен тәнгә тарала, изрәтә. Зариф тагын йокымсырап киткәндәй булды. Тфү, тагын теге төш. Нәкъ өндәге хәлләр кабатлана. Тик менә соңгы мәле, авылдан чыкканда атулары гына...

Ә ул чакта авылда...

...Бик каты ишек шакыдылар. Ялаңаягына итек кенә эләктереп, Зариф тышка чыкты. Агасы икән. Волостька тагын икмәк таларга килгәннәр, ди. Инде революция чыккач та талыйлар, күпме түзәргә була, киттек, туган, ике генә кеше икән, арт сабакларын укытып җибәрик әле, йөрмәсеннәр, ди. Җитмәсә, кяферләр дә икән әле, утка салсак та савап кына алабыз, ди. Кулында ике җәпле үткен сәнәк иде. Зариф ни алырга да белмәде, шулай китте. Волостька чыга торган юлга таба шау-шулап чабучыларга кушылдылар.

Алар килгәндә кемнәрнедер егып ук салып кыйныйлар иде инде. Күрше авылларны күргәч, аларга юл бирделәр. «Бир кирәкләрен, соңгы телем икмәкне авыздан тартып алырга йөрмәсеннәр!» — дип, як-яктан боларны өстереп тордылар.

Зариф, үзе кыйналганнан да битәррәк арып, атлаган саен сөртенә-сөртенә, авылына кайтып китте.

Гомумән, бу көннәрдә ул илдә-көндә барган хәлләрне аңламаудан гаҗиз иде. Австриядә өч ел диярлек әсир ятып, әле генә кайтып төшеп, авылдагы-илдәге хәлләрдән хәбәрдар булмыйча, караңгы урманда япа-ялгызы торып калган кеше хәлендәрәк иде.

Ә теге канлы вакыйгадан соң күп тә үтмәде, карлы-буранлы көннәрнең берсендә аның Ишми абыйсын алып киттеләр. Волостька кергән авыллардан тагын утызлап кешене чүпләп, Чар төрмәсенә илтеп япканнар. Зариф исә үзен алырга килүләрен көтеп, куак төбендә посып яткан куян кебек дер калтырап утырды-утырды да, читкә китеп югалып торырга булды.

Авылдан ул, аллага шөкер, хәвеф-хәтәрсез чыгып китте. Казанда да эшкә урнашты. Аз-мазлап дөнья хәлләреннән хәбәрдар була башлады. Тик язга таба, күңел тәмам утыра дип кенә торганда, бер авылдашы килеп, янә коткы салды. Җавапка тарту өчен аны да эзлиләр, ди. Тегеләргә әле суд булмаган, озакламый буласы ди, хәтта тамаша кылырга килгәннәргә дә икеөч ел өтермә бирәселәр, ди.

Зариф уйлап-уйлап торды да, аллага тапшырып, июнь башларында Кызыл Армиягә — мөселман социалистлар полкына язылды. Шуннан бирле берәз иркен сулыш алса да, барыбер бөтен гәүдәгә тураеп йөри алганы юк, йөри инде менә шушылай, җидегә бөгелеп, күңеленнән мүкәләп. Тагын ниләр күрер икән бу башкайлары?..

Ат өстендә булгангамы, бу юлы Зарифның йокымсыравы төш булып китә алмады, киресенчә, бик уяу, бик аек иде уйлары: авылга ашкына ашкынуын да, әмма инде нинди хәлләр икәнен белми. Ишмиләр инде Чар төрмәсеннән ычкынган булсалар, кармактан ычкынган ташбашлар сыман, башта читкә атылырлар да, аннары барыбер ашаган җирләренә — авылга җыелырлар. Бәлки әле аларны азат итүчеләр, корал биреп, Казанга ук җибәргәннәрдер. Аклар сине төрмәдән бушка чыгармас... Авылга кайтырсың, алар инде шунда булса, Кызыл Армиягә язылганыңны да сизсәләр... Тереләй ашыйлар инде. Әллә, чыннан да, төнлә авылга сыпыртмыйча яхшы иттемме? Менә ат та элəкте бит әле. Тик озаккамы җылытыр аны бу малкай?..

Зарифта атны озак тотмадылар. Шикләнделәр. Атлылар разведкага ешрак йөри иде. Зариф бер тапкыр чак-чак аклар кулында калмады. Ул нәкъ кирәк чагында атып та, чабып та котыла алмый иде. Сәбәбен ачыклый алмадылар, ачыклап та тормадылар, атын алдылар, үзен пехота взводына күчерделәр.

Атны алгач, аның икеле-микеле уйлары көчәйде генә.

Зариф, урмандагы теге төнне искә төшереп, башын кипкән үләнле кəздән алып, мылтык түтәсенә куеп ятты. Түтә салкынча, каты иде. Менә алла хикмәте, баш авыртуы тагын басыла түгелме? Ярый әле, алгы сызыкта обход чиратын уздыргач разъездстанцага кайтып китмәде, тынчу вагонда барыбер йоклап булмас дип, монда — арткы сызыкта — сорап калды. Әле бирегә дә — бер яктан коры ылыс исе, икенче яктан урылган басу исе килеп торган яланда да башкайлар нишләргә белми, вагонда булса, кайларга бәргәләнер иде. Өстәвенә, монда ул кадәр үк хәтәр дә түгел: алай-болай теге як атакага купса, монда кадәр әле разведка бар; аннары, бигүк куе булмаса да, беренче сызык — застава бар. Снаряд дисәң генә инде. Тфү, әйттем исә кайттым, әстәгъфирулла, алайга калса, сукыр снарядка аңа вагоның да әллә ни түгел. Теге көнне, минскилар эшалонына снаряд эләгеп, шактый солдат кырылган, диделәр. Монда әле йә тегеләй, йә болай тайпылып була, ике стена арасында түгел. Ышыкланыйм дисәң, агачлары да хәттин юан.

Зариф менә шулай, әле тегеләрне, әле боларны уйлап, үзара чагыштырып, үлчәп ята. Кемне дә үтереп мактарлык түгел. Моңарчы берсе дә алдыра алмады. Менә шушы тирәләрне генә дүрт тапкыр алдым-бирдем иттеләр ич инде. Каян беләсең монда кайсы як көчле икәнен. Егерме көн буе икелемикеле ят әле. Ничек чатнамасын ул баш?!

Рас анысы, азаккы ташлануда тегеләр безне Идел күпере төбенә үк диярлек китереп тәрәделәр. Шуннан соң калкынып куйдылар, үсенделәр. Янә каты удар ясарга бик нык әзерләнәләр, ди.

Чабаксардан да тагын телеграмма килгән, ди. Бу инде өяз башкаласы Чарга ярдәм сорап Кызыл армия түрәләренә җибәрелгән өченче телеграмма. Моннан берничә көн элек ишетте: Чарда буржуйлар баш күтәреп, Совет властен бәреп төшергәннәр. Шуны ишеткәч, Зарифның бәгырендә сәер бер нәрсә өзелеп киткәндәй булган иде: әллә өмет җебе, әллә түземлек җебе иде ул. Авылда да, болай булгач, тегеләр власте инде. Үз тылында тәртип тота алмаган армиягә өметләнү, ай-һай... Аннары соң, түрәләрнең баш күтәргән өяз үзәгенә ярдәмгә бирәр часть җибәрә алмаулары?..

Үзәгендә нидер өзелгән минутта Зарифның баш чатнавы бетте дә китте. Чөнки ул үз-үзенә кистереп: «Җитте сиңа, болай булгач күперен дә алырлар, Чарга да хуҗа булырлар, суэма, хәл ит, малай»,— дия алган иде.

Шулай дип кисеп салганга инде икенче тәүлек китте. Сизә Зариф, теге якта хәрәкәт бик көчле. Әзерләнәләр. Дөрес, болар да йокламый, туплары бермә-бер артты, аеруча Идел өстеннән тавышлары көчле килә, вакыт-вакыт җәһәннәм сызгырулары чыгарып өстән очып китә,— ком бөртеге булып, агач тамыры буйлап җиргә, тирәнгә сеңәсе килә.

Юк шул, икеләнү барыбер тәмам чыгып бетмәгән икән, бизмәнне ыргытып бәрмәгән, һаман үлчи, шуңа күрә башы да яңадан чатный икән.

Ярый әле бүген менә теге яктан пулемет тавышлары аерата көчле ишетелә. Алар куера бара, куера бара. Сизә Зариф; киләләр. Уйнап килүләре түгел. Чү, алгы рәттәгеләр чигенә дә түгелме?!

Борылып карый-карый, ара-тирә генә ата-ата чигенүчеләр ешайганнан-ешая бара. Моны абайлап, Зариф рәтендәгеләр дә калкынып,— кем тезләнеп, кем басып,— агачка сыенды, затвор тавышлары ишетелде. Әнә атлы разведчик чаптырып үтеп бара.

— Каушамаска, алгы сызыктан йөз адым калдырып, тәртип белән генә чигенергә, урман авызына кадәр! Команда шундый, ике фланг та нык чигенгән.

Әллә-лә-лә, ике яктан да арттан төшкәннәр болай булгач, без «капчык» эчендә калабыз була түгелме соң?! Урман авызына җиткәч, анда ачык алан, ике яктан урап, шул аланга кысып чыгарсалармы?..

Зариф тәмам әсәрәйде, дүрт колагы булса, дүртесен дә торгызыр иде: аланны чыкканчы ук урап куя алмасламы? Урарлар, шәт!..

Башкалар да шулай чамалады, күрәсең: приказны тыңламыйча, чынчынлап элдертү башланды — аланны җәһәтрәк үтеп калырга теләделәр.

Зариф башта үз рәтенекеләрдән калды. Аннан соң Зарифны алгы рәтнекеләр дә куып җитте. Аклар җәһәтрәк килә, ахрысы, әнә бит, ат пошкырганнары да ишетелә, пуляләр да колак төбендә генә сызгыра.

«Тизрәк-тизрәк!» — дип кычкыра-кычкыра, алгы сызыктагылар да үтеп китте. Зариф бик нык аксаган булып, алардан да калды. Арттан нәкъ аның турысында тояк тавышы якынайганнан-якыная, кылыч сызгыруы да ишетелә кебек иде инде.

Артка борылып карарга коты чыккан Зариф, башкача атлый алмас хәлгә килде дә, тезләренә егылып, мүкәләп китте. Ат инде аның өстенә менеп таптый сыман тоелды. Тыны тәмам бетеп, шып туктады, агачка терәлеп, кулларын күтәрде. Күзләрен ачса, ат әле аны таптарлык түгел, шактый еракта, әмма атлы аны күреп алган иде. Шул ук мәлдә Зариф ялт кына аланга да карап алды: шунда чыгып җитә язган. Аланга аяк басарга өлгергәннәрне, чыннан да, урман эченнән ике яклап та пулемет белән кыралар иде. Ярый, аллага шөкер, кабаланмаган әле, нишләр иде хәзер...

Ул калтыраган кулларын бүтәнчә төшермәде. Качып чыкканнарга таулар вәгъдә итәләр-итүен, шушылай бирелгәнне дә үтереп ташламаслар әле, бирелде болай булгач, аллага тапшырып. Һәм ул, кулларын күтәргән килеш, мылтыгын кулбашыннан төшермичә генә, инде килеп җитә язган атлыларга таба кузгалды.

Ике атлы аның каршысында ук катып калдылар. Күзләре төрле якка ялт та йолт. Алдагысы офицер, ахрысы, аның баш очында гына кылычын уйнатып алды.

— Бирeләсең, кызыл сволочь!?

— Бирeләм, господин офицер, так точно. Мөселман мин, үзем бирeләм.

— Ха-ха-ха, бирелми карагыз, барыбер кырып бетерәбез. Хәер, бирелгәннәрне дә теге дөньяга озатабыз, үлем сезгә, жәлләү юк, кыйммәтле мәгълүматлар бирсәң генә инде. Әйтеп кал, давай, бу кайсы полк?

— Курски.

— Сул ягында?

— Мински.

— Уң ягың?

— Петроградски.

— Дөрес лыгырдыйсың шикелле. Шулай да вакытны аласың. Ваня, алан читенә чыгара тор! Допросны, әйләнеп килеп, үзем алам. Пока кул пычратасы булма. Ә син безгә кирәген генә әйтергә әзерләнә тор, мөселман дип юләрлеккә сабышма, телеңне тиз чишәрбез!

Офицер, атын зәһәр камчылап, сул флангка элдертте. Ваня дигәне — чиркәү шәме кебек каны качкан ак йөзле юка гына яшь егет — бер сүз дәшмичә, капылт кизәнеп Зарифка камчы белән китереп тә салды. Аркага төшкән камчының очы яңакка тиеп, урак очы тишкәндәй, битне уттай көйдереп

алды. Зариф шул төшне ялт кына кулы белән тотты. Кан бәреп чыккан иде.

— Топой! — диде егет һәм камчысын алан ягына селтәде,— читкә тайпылсаң, шундук башку долой, гололобый, матри!

Киттеләр. Алан читенә туктадылар. Ул шактый зур түгәрәк иде. Типтигез булып камышлы курпы күтәрелеп килә. Бу ягы сөзәк иңкел булып, теге ягы, биегәя-биегәя, ярыйсы гына үр хасил иткән. Аланда аклар планлаштырган, Зариф көткән кырылыш булырга өлгермәгән шикелле, анда-санда гына гәүдәләр ята. Кыймылдыйлардыр, ахрысы, аларга әле һаман аталар. Шул атуга җавап итеп, үр башыннан да пулемет сиптереп-сиптереп куя. «Тимер юлга күп калмады, болар шул үрдә ныгырга булдылар микән? Гел шулай алар, бирәләр, бирәләр дә, аннары, авыз пешкәч, өрә-өрә тешләшергә тотыналар...»

«Болар» дию Зарифның үзенә дә сәер тоелды. Кемнәре инде хәзер болар да, кемнәре тегеләр? Болары болар инде — аклар, ә элек болар булганы хәзер тегеләр. Әй, шайтан, буталып та бетәрсең монда. Барыбер түгелмени соң?! Тик нишләп әле монысынықылары танышлыкны алай кыйнап өркетүдән, кан чыгарудан башлады. Аэропланнан очырткан кәгазьләрендә алтын тауларына чаклы вәгъдә итәләр иде бит. Учак-учак яктырды аларны комиссар, хет берсен алып каласы калган...

Офицер да килеп җитте. Манма күбеккә баткан атыннан төшеп, аны «калай этәч»енә тоттырды.

— Эх, өлгерә алмый калдык торарга, пулеметлар куеп өлгерде синең кызыл артларың. Әйт, давай, сул флангта кайсы полк?

— Әйттем ич, Мински дип. Ышанмыйсызмыни? Мин бит үзем теләп чыктым сезгә!

— Ничә солдаты бар? Атлылары ничә?

— Атлары разведкада гына аларның, дүрт йөзләп штыклары бар бугай.

— Позициядә күпме пулемет?

— Каян белим мин аны, үзебезнекен дә белмим.

— Ничек белмисең, мин дә беләм аны, дүрт пулеметыгыз бар.

— Мин бит полкныкын белмим дим, ротада әмер биргәндә биш дигәннәр иде.

— Оһо, монысы һәйбәт! Димәк, тагын өчәүсе исән әле. Ә уң флангта?

Сорады офицер, әле юмалап-сырпалап, әле акырып-бакырып, борын төбендә кылычын уйнатып. Ул томаудан интегә иде бугай, атлаган саен борынын бармагы белән тотмыйча гына сеңгерә дә кылычының сабы белән генә сөртеп ала.

Зариф белгәнен яшермәде, сөйләде, шулай итеп кенә аларның күңеленә ярап булыр, дип исәпләде.

Кинәт, каты сызгырып килеп, алардан ерак та түгел снаряд шартлады. Офицер бөтен гәүдәсе белән урманга, ышыкка тартылгандай булды. Әмма тыела алды. Димәк, кызыллар үз артиллерияләренә аларның бирегә күчкәнлеген әйтеп тә өлгергәннәр.

— Бу бит дальнебойный, кайдан аталар?

— Корабтандыр.

— Ничә корабта дальнебойный бар?

— Безне аларга кем җибәрсен...

Шунда тагын бер снаряд баягысыннан да якынрак төшеп шартлады. Мунча ташына салган беренче көчле ачы пар кебек тәтенле, туфраклы дулкын ябырылды. Офицер да, атлар тоткан «этәч» тә урманга тайпылдылар. Зариф егыла язды. Уң флангта снаряд ярылды. Үрдә җанлану моннан да сизелә иде, икенче пулеметлары да җанга килде. Моны сизеп торган офицер нишләргә белми иде.

— Каян болай аталар, әйт, сволочь!

Ул Зарифның изүеннән эләктереп алды да буа башлады. Исерек икән, сасы ис аңкыды.

— Белмим, иншалла белгәнне яшермәдем.

— Беләсең, бәяңне күтәрәсең...

— Билләһи дим, кояштыр!..

— Белмәгәч, монда чыгалар мыни...

Зариф буыла башлады.

— Җи-и-и-бә-ә-эрегез!.. И-и-иптәш, э-э-э, гра-а-а-ажда-нин...

— Сорауга җавап бир!

— Белмим...

Атлар капылт урманга тартылды, егып, адъютантны да өстерәделәр. Шундук колакны томалап, күзне йомдырып, коточкыч сызгыру килеп җитте, бөтен дөнья гөрселдәп китте. Өстән агачтыр, туфрактыр, тимер кыйпылчыкларыдыр — теләсә нәрсә шыбырдап коелды. Ике-өч адымга ыргытылган офицер белән Зариф бергә килеп төшкәннәр иде, офицер сикереп торды да баш та кылычын алды, аннары Зарифның колагын эләктереп, тартып торгызды. Колакны торгач та җибәрмәде. Колак ут булып яна башлады.

— Әйт, дим, беләсең!

— Белмим.

Офицерның күзе бәбәгеннән чыгардай булып акайды:

— Ә-ә-ә-әйт! — дип чинап акырды да, кылычны ялт күтәреп, Зарифның колак читен кисеп тә алды.

Зариф әлегә кадәр кулларын кыл да кыймылдатмыйча, элекке армия хезмәтендәге кебек «по-швам» тоткан иде, хәзер аптырап, кулын күтәрә башлады. Шунда тегe аның киселгән колагын кулына тоттырды. Үзе шундук тагын колакны эләктереп чеметеп тотты.

Зариф бер мәлдә шыбыр тиргә батты, тәне буйлап җылы юеш нәрсә агып төшкәнен тойды, борынына кан исе бәреп керде, башы әйләнә башлады, нәрсә әйтергә белмичә, үз учындагы колагына карап, тораташ булып катты.

Офицер исә шаша гына бара иде.

— А-а-а-и-и-йт! — дип акырды ул тагын да катырак итеп һәм колак яфрагын тагын телеп алды, тагын Зарифның үз кулына тоттырды. Бу юлы Зарифның кулы бөтенләй кан белән тулды. Күз аллары тәмам караңгыланды. Колактан аккан кан авызга, тамак төбенә тула бара кебек тоелды, ул гырылдый, тончыга башлады. Офицер җиргә чүккән Зарифны икенче колагыннан эләктереп алды...

Бу минутта кызыллар алан чите позициясендә тәмам ныгып өлгергәннәр иде. Минскилар белән петроградлар да, резервлар да килеп, берегә алдылар, башкача чигенмәделәр. Флотилиягә телефоннан гына ике якның да координатлары бирелеп, аклар теш батырырга маташкан урыннар утка тотылды. Бөтен фронт буйлап пулеметлар урнаштырылды.

...Кызылларның комиссары алан читләрен бик җентекләп күзәтергә тотынды. Зариф тамашасы да күзенә чалынды. Шунда ул взвод командиры Габитовны дәште.

— Кара әле, синең кызылармеең түгелме ул?

— Бәй-бәй. Минеке шул. Зариф ич! Икенче позициядә иде. Узып киткәндә күршесе күргән, бик каты аксый иде, диде. Ах, тәки эләккән икән...

Аннан соң ул, комиссарның җиңенә кагылып, кинәт кычкырып җибәрде:

— Колагын кисә ич!

Комиссар җәһәт кенә кабат биноклена ябышты. Габитовның да бинокле кулдан кулга китте.

— Зарифның колагын кисәлә-ә-әр!

— Живодерлар! Безнең солдатны турыйлар! Нәрсә карыйбыз!

Бөтен позиция дәррәү куба, мәж килә иде.

Бу кайнар сулышны тойган комиссарның да йөрәге каты дөпелди иде инде, яралы аяклары алга омтылып, тартышып-тартышып куйды. Әмма ул аланның өч яктан да дошман күзе — пулемет көпшәләре астында икәнен онытырга тиеш түгел, полк кадәр полкны күрә торып куркыныч астына куярга аның хакы юк.

Ә солдатлар, үрә басып, тавышланырга ук тотындылар. Габитовныкылар — ротада аерым мөселман взводы — аеруча тузгып китте.

— Мөселман дигәч тә, ул да адәм баласы ич...

— Тиле, мөселманның ни кысылышы бар монда, комиссар үзе дә чуваш егете ич...

— Сөйләдең сүз, чуваш та мөселман булды ди!..

— Юкка базар ясыйсыз, команда көтегез! Дикъкать! — дип тыйды аларны Габитов. Ул арада матрослар да битараф калмаганлыкларын күрсәттеләр:

— Полундра ясап тартып алырга кирәк, комиссар!

Комиссар бер мәлгә икеләнеп торды. Аннан соң кинәт кенә наганын тартып чыгарды да, үрә басып, кычкырып җибәрде:

— Алга! Революция дошманнарын — кеше ашаучы вәхшиләрне себереп атарга, кызылармеецны йолып алырга!

Күзен кан баскан булса да, ак офицер болай таба кузгалган дулкынны

чамалады. Үзе дә инде ул үз сулышына үзе буыла бара иде, ни эшләгәнен дә белешмичә, Зарифның колагын төбеннән үк кисеп алды, канлы ит кисәген җиргә атып бәрде. Зариф чүкте, шулай да авып ук китмәде, тезләнеп калды. Ул инде аңын югалта бара, әмма ниндидер бер көч аны тотып тора кебек иде.

Офицер исә, кызылларның чынлап торып һөҗүмгә ташлануын аңлап, револьверын тартып чыгарды:

— Машков! Атны! Кайда анда безнең артиллерия, күпме көтәргә була йокы бирәннәрен! — дип акырды.

Якында гына снаряд ярылды.

— Син дә калма, мүкәлә! — диде офицер, наган көпшәсе белән Зарифның ияген күтәреп,— хәтереңне эшләтә-эшләтә мүкәлә!

Зариф башын күтәрде. Наган күтәргәннән түгел, үзе күтәрде. Әллә кайлардан көч табып. Ул көч аның карашында әрнү булып, каргыш, нәфрәт булып янып чыккан иде. Офицер Зарифның коточкыч карашын, аннары кап-кара кан булып укмашкан, үзенә таба күтәрелә башлаган йодрыкларын күрде һәм, айнып китеп, читкә тайпылды, кабалана-кабалана атының өзәңгесен кармалый башлады.

— Ах син, кызыл арт!.. Син бит үзең теләп чыкмагансың, син бит аларның шпионы... Мә, жук!..

Ул наганны Зарифның эченә төбәп, курокка басты. Нәкъ шул мизгелдә аларның янәшәсендә үк диярлек снаряд шартлады. Аның дулкыны Зарифны читкә бәреп атты.

Офицер да ат өстеннән очып төшкән иде. Ул берни күрмәгән, берни ишетмәгән һәм аңламаган хәлдә адъютанты артыннан урманга таба җәяүләп чапты.

Зарифны җир үзенә ала бара иде. Әмма ул әллә сәламәт колагы, әллә инде күңеле белән алан ягыннан җирнең салмак дөрелдәвен, пулемет тыкылдавын, кеше тавышларын барыбер ишетте. Юк, аның әле зиһене эшли, йөрәге тибә иде әле. Киләләр!

Урман эченнән дә пулемет тавышы якыная. Зариф аны да тоя. Ул яктан да киләләр. Алар да ерак түгел. Әлегрәк алар килеп җитсә?!

Юк-юк, ул тегеләргә кабат әләгергә теләми! Һич теләми!

Зариф, яралы кулын күкрәгенә китереп кысарга көч тапты. Бераз башын күтәреп, аланга таба шуышмакчы булды. Талпынды, ләкин бер карыш та китә алмады. Тәгәрәмәкче булып карады, юк, гәүдәсен әйләндерә алмады. Сулышы тәмам кысылды. Бетәм, үләм, дип коты тәмам алынды. Акылы белән ул барыбер сизде: коткаручылар колак кисүчеләргә караганда барыбер якынрак, аны барыбер йолып алачаклар, ул алар кулында җан бирәчәк!

Зариф аларны ачык караш белән каршыларга теләде. Киләләр, ходайга шөкер! Әнә-әнә, егыла-егыла булса да киләләр. Киләләр! Иа алла, аның өчен, аның хакына җан бирә-бирә киләләр!

«Ура-а-а» тавышлары якынайган саен, Зариф үз җанының, зиһененең әле исән калган күзәнәкләренә сәер бер хиснең авырттырып та, рәхәтләп тә биреп тула баруын тойды.

Менә алгы рәтләр аның яныннан узып та киттеләр, үзләренә һәм Зарифка таба ут бөркегән пулеметларга таба ябырылдылар.

Ә Зариф, кулы белән үләнгә чытырдатып ябышкан хәлдә, үлем ачысы белән үксеп елап җибәрде...

Әхәт Гаффар

# УТЫН

ХИКӘЯ

*Татар «әфганнар»ының инде моны мәңге укый алмаганнарына һәм әлегә укый ала торганнарына багышлыйм.*



ртән Миннур Дияров болдыр баскычында утыра иде инде. Өйгә кереп барган Фрау атлы мәчеләрен туктатып, ул аның аркасын сыйпарга, колак артын кашырга тотынды. Җиләк-җимеш бакчасының ян капкасыннан әле генә суелган ике яшь әтәч белән сугым пычагы тотып чыгып килүче атасын күргәч, йөзен читкә борды. Ләкин әтәчләрнең җансыз асылынып торган муеннарыннан капка төбендәге шома, чиста ташка тамган ике-өч кан тамчысын шәйләп өлгерде. Атасы Шәехнең:

— Утырасыңмы, улым? — дип соравына җавап кайтармады. Аны болдыр ишегенә уздырыр өчен, баскыч читенәрәк шуышты.

Атасына ияреп, мәче дә эчкә кереп китте. Миннур әтәчләрнең идәнгә йомшак кына шапылдап төшүләрен ишетте. Кулын югач һәм бераз гына өйдә югалып торгач, ата кеше аның янәшәсенә чыгып утырды.

— Тартып алыйкмы әллә? — диде ул.

— Юк әле,— дип, Миннур кире какты.

Шәех учы белән чиста баскыч тактасын сыйпады:

— Җылы монда,— диде.

— Көз әйбәт килгән икән.

Улының болай әйтүе ата кешегә сәеррәк тоелды. Күңел төбенә боз кисәге шуып төшкәндәй булды. «Аның өчен туган авылындагы көз «килгән» генә. Ә минем өчен ул күз алдыма килде»,— дип уйлады ул.

Чыннан да, көн кояшлы иде. Ә менә Шәехнең җаны шомлы. Уллары кичә кичен генә кайтып төште. Шәех үзе һәм хатыны, шул якты шатлыкны йокы пәрдәсе белән араларга теләмичә, таң беленә башлаганчы керфек какмый чыктылар. «Бу баланы ни көтә инде?» — дип, көн арты көн җыелып килгән сагыш тагын уянды. Караңгы төннәрне уяу тота, ә якты көннәрне якты итә торган ул сагышның иге-чиге бардыр иң инде аның, әй? Шөкер, ни булса, шул булган инде. Ни хәл итмәк кирәк. Улының яманрак хәлгә дә юлыгуы ихтимал иде бит әле, дип куанырга гына калды.

Ул яман хәлнең ни белән очланырга ихтимал икәнен Шәех уйлап бетермәде. Дөнья менә хәзерге шикелле тора икән, тагын ни кирәк? Әйе, биргәненә шөкер.

---

Әхәт ГАФФАР *(1949) — «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы», «Олы юлның тузаны» кебек романнар, күпсанлы повесть һәм хикәяләр авторы. Казанда яши.*

— Әһә, улым. Күз әйбәт. Бар нәрсә җитеш.

Җитешен җитеш анысы. Шәех арттырмый. Зарлансаң, гөнаһ булыр. Тагын ни җитми? Уллары исән-сау кайтты. Аллага шөкер. Бөтен гаилә тулысы белән кунган өйдән дә җитешрәк ни бар тагын?

— Бәрәңгегез уңмаган икән. Окопны ачып караганыем,— диде Миннур һәм, атасының кулы кайнар нәрсәгә тигәндәй баскыч тактасыннан тезенә күчүен абайлагач: — Базны инде, базны! — дип, сүзен төзәтте.

Шәех, улын сагайтуын сизеп, кулын тагын баскыч тактасына төшерде. Тик учы җылы тоймады инде. Такта, кырау төшкәндәгечә, чәнчеп-чәнчеп ала кебек иде.

— Булганы җитә-ә-әр,— дип суздзы Шәех.— Быел сугымга ике яшьлек үгез, дүрт бәрән бар. Шуңа өстәп — ике оя каз. Дөнья тулы тавык-чебешен дә куш...— дисә дә, Шәех бу араларда күңелен бимазалап йөргән уйларын әйтеп бетермәде. Җитүен җитә дә бит... җитсен өчен биш пот тоз ашарга кирәк хәзер. Җиткәннең иң зурысы — калган гомер инде аның. Дөнья йорты — михнәт йорты. Әй, ярар сана! Аты коргыры, дип сүгенергә калганмы?! Шуңа күрә Шәех, тавышын күтәреп, сүзен шат кыяфәттә очлады: — Менә шул: туйга артыгы белән җитә, Алла теләсә! — дип, улын җилкәсеннән кочып, кулын шапылдаткалады.

— Туйга? — дип сорады Миннур аңа кырт борылып.— Кем туена?

— Ят сүзме әллә? Тимерне вакытында сугарга кирәк аны! Мин үзем армиядән соң озак буйдаклап йөрмәгәнием.

— Ул бит син...

— Күктән белен яумый ул. Сиңа ни җитмәгән?

— Чак кына җитми, әти, чак кына.

Ата кеше тыенкы гына көлеп куйды:

— Азан әйтми камәт төшермиләр дисеңме?

Киң ишегалдына тагын җил килеп керде. Миннур, иңбашын җыерып, иңенә салган кысан пинжәгенә иркенәебрәк сыярга теләгән шикелле, бөрешә төшеп утырды, сул җиңен бот арасына кыстырды.

— Күр дә тор, килеп чыгар, әһә. Ни җиткәнен-җитмәгәнен шунда чамаларсың. Күз генә тимәсен, сөбханалла гына күренә ул. Миңнурыйны әйтәм... Аны кулдан ычкындырасы түгел, аң бул. Алла бирсә, бездән артмас, хәер-фатиха... Өй — футбол кыры белән бер. Яңа мунчаның иңдилеген кичә үзең сынагансыңдыр.

Җил ургымы ишегалдына коелган тупыл, алмагач яфракларын кугалады. Әмма аларның күмәк кыштырдавы Шәехкә улының тешләрен шыгырдатып кысуын ишеттерми калмады. Шул ук вакытта җил Миннурдан атасының авыр сулап куйганын да яшерә алмады.

— Ярый, улым. Трактор тирәсендә чуалып кайтыйм инде,— диде Шәех.

Ул, баскычтан уфылдап, күңелендәге авыр уйларын сиздереп күтәрелә язуын искәрде дә, җайлабрак утырган булды. Чалбар кесәсеннән таушалган сигарет кабы чыгарса да, кире тыкты.

— Каяле, кичәгенәк синеке катырак тоелганые шикелле,— диде ул.

Миннур янтайды, пинжәгенең уң кесәсеннән сигарет кабы кармаланып алды, аны кисәк каккач, бәреп чыкканын атасына сузды. Ул аны угалап, ирененә капкан арада газлы кабызгычын яндырып җибәрде.

Улының кабызгычны сүндерүен, затлы сигарет кабын култыксага куюын күреп, Шәех:

— Үзең дә көйрәт, улым, җаның басылыр,— диде.

— Ярый алайса,— дип килеште Миннур.

«Юатма сана!»,— дип өстисе килгән иде дә, тыелып калды. Атасы яшь шул әле. Кырык бердә генә. Белгән кадәресен генә белә.

Ата белән ул, һәркайсы үзенекен уйлап, бераз сүзсез утырдылар.

— Фермадан кайткач, әнкәң әтәчләрне чистартып куяр,— дип, Шәех урыныннан кузгалды.— Абзарда тәкә калдырдым. Кара аны, ашатасы-эчертәсе түгел. Үзең беләсең. Мин озак буталмам, кайткач хәл итәрбез.

— Торсын иде әле, әти.

— Нәзере шундый аның.

— Миңа берәр эш юктыр ич?

— Ниткән эш ди әле ул?! Иркенләп ял ит, туйганчы аша... Әһә, тавыкларга өч-дүрт уч бодай сипсәң генә инде.

Миннур кинәт ачуы чыгып әйтте:

— Эчсәм ярыймы соң? — диде.

— Теге... нитмә генә... исермә. Сеңелкәшләрең килештермәс.
— Ә син?
— Эштәге егетләргә, сөенче итеп, бер шешә эләктердем мин. Шунда күз күрер.
Капканы үзе сыярлык кына ачкач, ата кеше улына әйләнеп карады. Ул аның э л е к нинди икәнен яхшы белә иде, ләкин а л д а кем буласын начар чамалый әле.
Ялгызы калгач, Миннур агачлардагы яфракларның шыбырдавын, атасы иртүк ишегалдын себергәч коелганнарының кыштырдавын тыңлап утырды. Ишегалдын күз алдыннан кичереп, кулы белән җаны тансыклаган берәр эш эзләде. Табалмады. А н с ы з да бар җирдә тәртип икән. Йорт-җир нык. Болдыр юылган. Абзар-кура тирәсе чиста. Лапаста яңгырдан ышыклап салам түшәлгән һәм җил кузгатмасын өчен колгалар бастырылган пөхтә печән чүмәләсе тора. Мунча түбәсе ышыгына утын ярып өйгәннәр. Бөтенесе а н н а н башка эшләнгән. А н ы көткәннәр, тик ни уйлап көтсәләр, шулай көткәннәре күзгә бәрелеп тора. Югыйсә, аның өлешенә дә эш калдырырлар иде.
Ул түзмәде. Өйгә кереп, аракы эчте, тозлы кыярны кетердәтеп чәйнәде, аяк астында буталган мәчегә ит ыргытты. Яңадан болдыр баскычына чыгып, сигарет кабызды. Шунда утын өеменең сукыр капка ягына терәлгән өске башына ярмыйча гына тезгән бер дистә чамасы имән пүләннәренә күзе төште. Утын яра торган юан бүкән дә шунда. «Туктале, ярып карыйм әле»,— дип уйлады ул. Җаны сискәнеп китте. Сигаретын төкереп сүндерде дә, тычкан сизеп сагайган мәче шикелле тын гына атлап, шул тарафка юнәлде. Калунның һәм балтаның мунча алачыгында икәнен кичә мунча кергәндә абайлаган иде. Шунда кергәч, калунның тупас сабына үрелгән иде дә, аның белән утынны н и ч е к ярырга кирәклеге исенә төшеп, балта алды. «Үткер»,— дип уйлады ул, балтаның йөзен чамалап. Бусына канәгать калмады. Үткер балта пүләнгә бата гына бит ул. Кат-кат бәрәсе була.
Чыкты. Пинжәген иңеннән кузлага кагып төшергәннән соң, беренче пүләнне бүкәнгә бастырып куйды. Учына төкереп, бармакларын угалап торды, балта сабына ябышты. Кыска селтәнеп, балтаны пүлән уртасына каптыргач, аны иңбашына терәп әйләндерде дә түтәне бүкәнгә китереп орды. Ишегалдында йөргән әтәч, шул тавыштан өркептер инде, гөлдерәп куйды. Абзар ягыннан тәкә аваз салды.
Шул рәвешчә ике мәртәбә китереп бәргәннән соң, пүлән шыгырдап куйды, тагын бер бәргәч, урталай шартлап ярылды, яртышар-яртышар булып, бүкәннән җиргә мәтәлеп төште. Ярылган төшләрендә аның үзагачы, еллык боҗраларыннан сузылган юллары шома, ялтыравыклы, матур иде.
Пүләнне яра алуына сөенә-сөенә ваклап тураклагач, ул бүкәнгә янасын утыртты. Анысы ике аерылы иде. Җиңел ярылсын өчен кыскарак кискәннәр. Шулай да биш тапкыр көчәнеп бәргәннән соң гына биреште.
Өченчесен яргалап бетергәч, карашын ү з е ярган утын күченнән алалмыйча, сигарет тартып утырды. Әчкелтем агач исе тәмле иде. Ул җылымса кояш астында кибеп яткан яфраклар исен дә басты.
Җанга рәхәт булып китте. Солдат күлмәге, арка тиреннән юешләнгән дә, тәненә ябышкан. Күкрәк уемыннан бер-бер артлы эре тир бөртекләре тәгәрәште. Күзен әчеттергән маңгай тирен ул әледән-әле уң җиңе белән сөрткәләде.
«Әни сөенер инде,— дип уйлады ул.— Әти ни әйтер икән? Бәлки сеңелкәшләр дә әллә ничек ятсынып караудан туктар...»
«Ә мин сөеним микән соң? Үзеңнең әйтерең бармы?» — дигән соравына күңеле җавап бирмәде. Болдырда салкын су эчеп төшкәч, балтасын яңадан баш турысына күтәреп бәрер алдыннан төзәп торганда арттан үзенә эндәшкәннәрен ишетте:
— Миннур...
Тавыш иясенең к е м икәнлеген шундук танып, ул балтасын түбән төшерде.
— Синме? — дип сорады ул карлыккан тавыш белән. Артка әйләнеп карамады. Карарга курыкканын сизде.
— Исәнме!
— Саумы.
— Мине кичә көттеңме?
— Кичә.
— Килеп булмады. Дежур идем. Бер апа бик азапланып бәбәй тапты.

— Шулай. Постны ташламыйлар.

— Иә, борыл инде!

Аркасына кул орынгач, Миннур туңып китте.

«Чепуха! — дип уйлады ул.— Күлмәк тиргә чыланган. Шул туңдырды».

Әмма борылды. Миңнурыйга ничек борылмыйсың ди инде? Ул бит — Миңнурый!

«Мин — Миннур, ә ул — Миңнурый. Ике исем — бер язмыш»,— дип шатланды ул тегендә, иң моңсу чакларда искә алып. Үзенең язмышы дип хыялланган, ә моннан соң кем булачагы әлегә билгесез кыз аның күз алдында иде.

— Соңгы хатларыма нигә җавап язмадың?

Миннур эндәшмәде. Болай да билгеле, күренеп тора ич инде.

Кыз аның уен дәвам иткәндәй әйтте:

— Исеңдә тот: минем кызгануымны мәңге көтмә,— диде.

Миннур болай гына, сүз булсын өчен генә:

— Ни көтәргә соң? — дип сорады.

— Сөю генә... Хәер, юк...

Шуннан соң урнашкан кыска тынлык Миннурга киртләч-киртләч таш арасындагы бушлыкны тоташ ут астында йөгереп узарга әзерләнгән чактагыча озын тоелды.

— Хәер, юк,— дип кабатлады кыз һәм, оялган шикелле, карашын читкә күчерде.— Юк нәрсәне генә көтәләр. Син монда. Мин дә шушында. Син булган җирдә мин һәрчак булырмын.

Шулай дигәч, Миңнурый көтмәгәндә аның күкрәгенә сыенды. Бу юлы ул Миннурның инде күкрәген туңдырып җибәрде. Үз сүзеннән кайтырга теләмичә, ул тагын: «Күлмәк юеш»,— дип уйлады.

— Кайттыңмы?

— Җибәрделәр.

— Кайткан булгач, нигә кочмыйсың?

— Кул буш түгел.

— Балтаңны куй.

Миннур балтасын сак кына бүкәнгә яткырып куйды. Тик, кулы бушаса да, кызны кочакларга барыбер базмады.

— Оныткансың,— диде Миңнурый.

— Онытмадым.

— Алайса нигә үпмисең?

— Онытканмын.

— Ә мин онытмадым.

Һәм Миңнурый, күзен йома төшеп, аның иренenә үрелде. Бу юлы аның тәне Миннурны туңдырган шикелле итмәде. Әйтерсең лә ул үз исемен нилектәндер онытып, яңадан хәтерләгән шикелле, әллә кайчан күңеленнән җил булып таралган үбешү тәмен исенә төшерде, шул үбешүнең әсиренә әйләнде. Болай булганы бар иде инде. Армиягә алынганчы, Миңнурыйны капка төпләренә кадәр озаткан кичләрдә. Әзгә генә, кыяр-кыймас, тансыклап кына, моның ни икәнлеген белер-белмәстән, ихтимал, бер бәхет мизгеле төсле тоеп кына.

Шуларның бөтенесе исенә килеп төште, җәйге чилләдә авыр эштән соң салкынча үләнле җылы җиргә ятып хәл алгандай булды. Сул кулын күтәрде, аның нинди үләнгә, нинди җир кантарына тигәнен тойгандагыча, хәзер дә нәрсәгәдер орынганын сизде, шул сизүнең тәненә дә, җанына да рәхәт икәнен искәрде. Гүя учы җылы туфрак кисәгенә орынды, шуны кысты, таратырга теләп угалады. Ләкин әлеге туфрак, юеш кантар сыман, уч төбеннән шуып чыга иде.

Чыннан да, Миңнурый үз тәнен аның сул кулы ягыннан үзе дә белештермәстән ятсынып читләштерде, ерагайтырга теләде. Хәзер инде нидер Миннурның тойгы-кичерешенә туры килмәде бугай. Шуңа күрә ул үз иренен Миңнурыйның иреннән аерды, оялгандагы кебек, күз карашын түбән төшерде һәм кызның ачык халаты астындагы зәңгәр күлмәгенең калку урынын ничек итеп назлаганын күрде...

Очрашу һәм тансык назлашу газапка гына әйләнеп калды. Ул Миңнурыйның күкрәген үз кулының өзелгәннән соң чит җирдә күмелеп калган өлеше белән сыйпаган икән!

Миннур читкә сикерде, озын җиңен селтәп, кыздан кулын каплады, аркан борылды. Кандагардан ерак түгел аяк астында мина шартлагандагы

сыман, «Әни!» дип әллә ыңгырашкан, әллә уйлап кына өлгергәндәге кебек:

— Чыгып кит! — дип кычкырды.

— Ни булды?

— Кит дим, кит!

— Миннур!

— Ки-и-ит...

Ишегалдын төнге госпитальдәге кебек тынлык басты. «Мин — Миннур, ә ул — Миңнурый. Бер исем — ләкин ике язмыш икән инде»,— дип үкенде ул бу юлы. Һәм, таң сызыла башлаганын хәтерләтеп, кызның әкрен генә пышылдап:

— Тагын кабатлыйсыңмы? — дип сораганы ишетелде.

— Кит, Миңнурый!

Агач яфракларының җирдәгеләре тын иде, ә агачтагылары тын гына шыбырдашты. Әйтерсең лә аларны кыз белән егетнең тирән-тирән итеп сулаганнары җилфердәтә иде.

Шунда Миннур, окопка иңгәндәгечә бөрешеп, кинәт иелде, чүкте, кулы белән колагын каплады. Ул ташлар арасыннан миләш чыпчыгыдай күтәрелеп чыгып, үзенә таба томырылган гранатаның кабызгычы шартлавына охшаган аваз ишетте. Авызын зур ачты да тынын кысты. Дүрт секундтан соң кулларын төшерде, тезләренә калкып, киң ишегалдына карады, аннары турайды, башын гына борып, артка караш ташлады. Анда-монда айкалган күз алмалары бер ноктага төбәлгән килеш хәрәкәтсез калды. Һәм бүкәнгә чабылган балтаны, аның йөзе янындагы чәнти бармак очын күреп алгач, күзен йомды. Аннары кинәт ачты. Башы әйләнеп китте, күңеле болганды. Кыз с у л кулын учлап күкрәгенә кыскан, беләге буенча агып төшкән ал кан юлы ак халатының җиңенә җитеп җәелә иде.

Миңнурый, аскы иреннән тешләрен аерды да, күкрәк түреннән саркып чыккан тавыш белән:

— Моннан соң... кит дигәнең саен... тагын дүрт тапкыр шушылай булыр...— дип пышылдады.

*Казан — Таллинн.*
*1989 елның 14—19 декабре.*

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

## Фәиз Зөлкарнәй

# «АРЫН КӨН ДӘ КОЛЛЫГЫҢНАН!»

*Ялган — ул коллар тәкъдиренә лаек өлеш. Азамат иргә исә сүзнең фәкать хак булганы гына килешә.*

АППОЛОНИЙ,
борынгы грек акыл иясе.

Юк, хәзерге татар шагыйрьләрен акларга җыенмыйм мин. Хәтта мактау яки хурлау да түгел исәбем. Мин аларны бары аңларга гына телим. Шуңа күрә иҗатларында тискәре бәягә лаеклы сыйфатлар чиктән ашып баруы турындагы сүзләрне дә тыныч кына тыңлыйм. Ләкин, ни гаҗәп, нәкъ менә шундый «яман» сыйфатлар бүгенге поэзиянең асыл эчтәлеген, хәзергә тикле аның яшәү мәгънәсен билгеләп килгән төп омтылышларын төгәл ачыкларга булыша.

Хәзерге татар поэзиясе дигәндә, гадәттә, 60 нчы еллардан башлап иҗат ителгән шигъри әсәрләр күз алдында тотыла. Үзеннән-үзе тел очыннан төшәргә торган бүгенге атама белән әйтсәк, бу «торгынлык еллары поэзиясе» була инде. Шушы билгеләмәгә яшеренгән фикер орлыгын аралап, бераз бүрттерә төшкәч һәм үрләтеп җибәргәч, «җәмгыятьнең торгынлыгы поэзиядә дә чагылыш тапкан, әлбәттә», дигән катгый раслау килә дә чыга. Шуннан соң инде кайберәүләрнең, бу чагылыш поэзиянең торгынлыгы сыйфатында гәүдәләнде, дип, ике төрле уйларга җай калмаслык итеп өзеп әйтүе дә әллә ни гаҗәп тоелмас. Ләкин уйлыйк әле: чыннан да шулаймы соң бу?

Мин үзем дөреслегенә шикләнәм, әмма шундый раслау яши: янәсе, укучыларның поэзиягә мәхәббәте сүрелде, һәм монда, әлбәттә, поэзия үзе гаепле, имеш...

Беренче карашка, укучы фәкать ике генә очракта поэзиядән читләшергә мөмкиндер сыман: беренчесе — шагыйрьләр, тормыштан тәмам «аерылып», укучыны кызыксындырмый торган әһәмиятсез темалар белән генә мавыкса; икенчесе — укучы шигырьне аңламый башласа... Хәзерге поэзия турында хөкем йөртүчеләрнең күбесе күз алдында яткан шушы ике юлны сайлады. Ләкин бу бит — нибарысы гомуми схема гына, мәсьәләне болай аңлатырга уйласак, ай-һай, ерак китеп һәм тирән кереп булырмы? Аерым шагыйрьләр, аерым шигырьләр һәм аерым укучылар яссылыгына төшеп конкрет фикер йөртә калсак, аның хаклыгы чамалы булу җиңел аңлашыла.

Күрәсең, монда гаеп атта да, тәртәдә дә бардыр, һәм әле, өстәвенә, «юл»ның нинди икәнен дә истән чыгармаска кирәктер. Бәлки, аның «юл»ы нинди икәнен ачыклау мөһимрәктер дә әле?..

Бу «өчпочмак»ның кайбер тарафлары хакында безнең әдәби тәнкыйтьнең инде элегрәк сүз кузгаткалаганы булды.

1978 елны «Казан утлары»ндагы поэзия турындагы сөйләшүдә И. Нуруллин утка май сипкәндәй тәэсир калдырган фикер әйткән иде. Ул, татар поэзиясендә 60 — 70 нче елларда шигырьне катлаулыландырып язу тенденциясе көчәюен искәреп, кайбер шагыйрьләрне (аерым алганда, 60 нчы еллар буынын) аңлаешсызлыкта гаепләде. Шагыйрьләргә шактый җитди гаеп ташлау иде бу, шуңа күрә дә аның фикерләренә каршы реакция бик кискен булды. Ләкин тәнкыйтьченең сүзләрен бөтенләй юкка чыгарырга тырышу, әлбәттә, хата иде. Поэзиядә ул елларда, чыннан да, билгеле бер дәрәҗәдә аңлаешсызлык — «герметизм» пәйда булып, шигъри әсәрләрнең байтагының асыл мәгънәсе укучыларның шактый ук өлешенә буй җитмәслеккә әйләнгән иде бит.

Моңа: «Халыкның шул елларда күзгә ныклап чалына башлаган социаль яктан тәрлеләнә баруына, укучылар даирәсенең чуарлануына поэзиянең үзенчәлекле җавабы бу»,— дип тыныч кына карарга да мөмкин иде, әлбәттә. Ләкин болай уйлау, шулай ук артык гомуми булып, мәсьәләнең тышкы чалымнарыннан гайре бернәрсәне дә аңлатмас иде.

Чыннан да, шулай хәвефсез, табигый күренеш идеме бу, әллә инде җитди авыру башлануын искәрткән беренче билгеләр идеме? Бу процесс кайда һәм кайчан башланды?

Укучыларның аерым төркеме (элита) генә төшенерлек итеп шигырьнең катлаулы формаларына өстенлек бирү дигәндә, иң элек бу эшнең борынгы осталары — мәшһүр суфи шагыйрьләр искә төшә: С. Бакыргани, Ө. Камал, һ. Салихов, Ш. Зәки һ. б. Ләкин безгә, суфилыкны тудырган сәбәпләр белән хәзерге дәвердәге шартлар арасында уртаклык эзләү мәшәкатеннән котылу өчен генә булса да (ә андый уртаклык, һичшиксез, бар дип ышанам мин), сүзне алар иҗатыннан түгел, бәлки якынрак чорлардан башларга туры килер.

Менә Назыйм Хикмәт, яңа заманда төрки шигырьгә революцион үзгәрешләр алып килгән шагыйрьләрнең берсе. Аның автобиографиясендә, әсәрләренең формасы заман капризларына ни рәвешле бәйле икәнен тасвирлаган урыннарда, безне кызыксындыра торган мәгълүматлар бар. Ул 1925 елда Мәскәүдән Төркиягә әйләнеп кайта. Һәм менә нәрсә көтә аны: «Шигырьләрне эшчеләр алдына чыгып кычкырып уку турында уйларга да ярамый иде. Ләкин, төрмәгә эләгү куркынычы янаса да, аларны бастырып чыгарырга мөмкин иде. Бу хәл шигырьнең һәм эчтәлегендә, һәм формасында чагылыш тапты... Шигъри сөйләм шагыйрьнең бер йә берничә кеше белән шыпырт кына сөйләшүен хәтерләтә башлады...»— дип яза ул. Аның шигыре шулай, Маяковский мисалында тәрбияләнгән трибунлыгыннан ваз кичеп, кинаяләр, мәгънәви ярымтөсмерләр, читләтеп әйтүләр теләнә күчә. (Кызганычка каршы, фикерләрен күпме генә яшергән кебек булмасын, Н. Хикмәт барыбер төрмәдән котыла алмый — гомеренең унҗиде елы «таш капчыкта» уза).

Шушыңа тартым шартларда шигырьнең холык-фигыле үзгәрүен без Н. Хикмәтнең замандашы булган татар шагыйре Хәсән Туфан иҗатында да күрәбез. 1940 елда шагыйрьне һич гаепсезгә кулга алалар, шулай аның язмышының уналты елга сузылган бик авыр чоры башлана. Х. Туфан иҗатында 30 нчы елларга кадәр тулысынча өстенлек иткән һәм аннан соң да әле бик үк онытылып бетмәгән туры сүзле трибунлык сыйфатлары менә шунда тәмам юкка чыга. Х. Туфанның тоткынлыкта язган шигырьләре инде бөтенләй бүтән яңгырашка ия. Болар кешенең, әйтеп бетергесез әрнүле эчке сагышыннан бушану өчен, үзалдына гына моңлануын хәтерләтә. Мондый шигырьгә инде сүзнең турыдан ярып әйтелгәнен генә көчәйтеп яңгырата торган трибунаның хаҗәте юк, ул — аңгәмәдәш, күңел сердәше. Сөйләшүе дә аның тыныч, басынкы, әмма кайнар: хисле сулышы күңелләргә тирән үтеп керә. Чөнки һәр гыйбарәсенә, һәр сүзенә шагыйрь күңелендә дөрләгән тетрәндергеч кичерешләрнең ялкыны сарылган. Кычкырып әйтә алмаганнарын шагыйрь инде шыпыртын, пышылдап әйтә...

Шагыйрьмен дигән шагыйрь ялганлый алмый. Хакыйкатьне ничек кенә булса да әйтергә кирәк аңа!.. Һәм ул җаен таба — авызы томаланган көенчә дә, үз хәлен (шул дәвер хакыйкатен) аңлатып бирүгә ирешә.

*Үзем монда — сездә, ял йортында,*
*Күңел ләкин читтән, ерактан —*
*Кайларгадыр илткән юл чатыннан*
*Күз сала күк безнең бу чакка.*

*Хәлне сорап, җанны сыйпап китә*
*Уйга калган иске танышлар,—*
*Сүзләрендә — серле саубуллашу,*
*Күзләрендә — яшерен сагышлар.*

*Нидер тоя күңел, нидер юрый,*
*Юраганы, бәлки, юш булыр:*
*Хушлашырбыз... Бәлки, бик озакка*
*Мин утырган урын буш булыр...*

Әлеге юллар 1940 елны, Х. Туфан хөкем карарын көтеп берьялгызы төрмә камерасында ятканда, иҗат ителгән. Бу хакта мәгълүматы булмаган укучыга, белмим, моның реаль эчтәлеген аңлау мөмкин микән? Кулга алыныр алдыннан гына шагыйрь каләмдәшләре М. Җәлил, Ә. Фәйзи, Ш. Маннур, С. Хәким, Ә. Исхаклар белән бергә Васильево ял йортында була. Әлеге шигырендә ул шул вакытны исенә төшереп, үзенең төрмәдәге хәле белән чагыштырып уйга калган. Кичерешләрен әйтеп бетерми шагыйрь — аңлаган кешегә аңларлык ич.

Ләкин шигырь эчтәлегенең бу мөһим катламы хәзерге укучыга ябык. Аның шунысы аяныч: мондый аңламаулар, шигырьләрнең мондый «аңлаешсызлыгы», татар укучысының төп массасын күздә тотканда, хәзер һич тә гаҗәп санала алмый. Безнең хәзерге укучы, әйтик, француз язучысы Жорж Сименонның ничә вилласы, ничә шәхси секретаре барын, ул бүгенге көнгә хәтле ничә роман язганын ялгышмыйча әйтеп бирер. Яисә менә Пушкин, аның кайсы чорда һәм нинди шартларда яшәгәнен генә түгел, ә бәлки бөтен ваклыклары белән тормыш юлын: аның шактый соңлап өйләнүен, хатыны аркасында дуэльдә атышуын, шул чакта кемнәрнең секундант булуын, үлем түшәгендә яткан чактагы соңгы сүзләрен —

һәммәсен белә. Ә менә татар шагыйренең нинди язмыш белән яшәп, бу дөньядан ничек китүен, яки аның бүгенге көндә ничек яшәп ятуын ул күз алдына да китерә алмый. Хәзерге татар укучысы бу өлкәдә тулысынча бихәбәрдар! Кыскасы, поэзия әсәрләренең күпләргә аңлашылмыйча калуы, аларда әллә ни кызыксыну уятмавы билгеле бер дәрәҗәдә менә шушы хәлгә дә бәйле.

Кызык, Х. Туфан, Ф. Кәрим кебек шагыйрьләребезне, тулысынча димим инде, җитәрлек дәрәҗәдә аңлап, төбенә төшеп укый ала торган укучыларыбыз нихәтле икән? Гәрчә бу шагыйрьләр иҗаты турында беркайчан да беркемнең дә «катлаулы» яки «аңлаешсыз» дигән сүзне әйткәне юк. Баш җитмәс хәл бит югыйсә: карап торышка гап-гади сыман, ә баксаң — аңлашылмый икән! Бер генә мисал, Ф. Кәримнең яшәү мәгънәсе, илгә тугрылык, бирелгәнлек һ. б. турында уйларын чагылдырган гади генә бер шигыреннән:

*Мин диңгездә батып исән калдым...*

— дигән, сугыш еллары поэзиясе өчен гадәти булган бер юл бар. Бихисап проза, поэзия әсәрләрен укып, сугыш тасвирларына тәмам күнегеп беткән укучының карашы бу җөмлә өстеннән шуып кына уза. Янәсе, сугыш вакыты өчен бу бик табигый.

— Ләкин Фатих Кәрим диңгезче түгел ләбаса!

Нәрсәсенә ис китәрлек моның, гадәти бер шигъри бизәк — гипербола гына ич...

Ә чынында, шагыйрьнең фаҗигале язмышы хакында азмы-күпме мәгълүматы булган укучы өчен, шушы кыска гына бер җөмлә дә искиткеч нәрсәләр сөйли ала! Монда Ф. Кәримнең, шәхес культы корбаны булып, 1937 елда кулга алынуы, төрмәләрдә, лагерьларда михнәт чигүе дә, аның төньяк диңгезләренең берсендә су төбенә җибәрелгән үлем баржасында батып, ярты үле хәлендә булса да ярга йөзеп чыга алуы да, үз аягы белән Казанга кайтып егылгач, кабат тотып ябылуы, төрмә больницасында Х. Туфан белән очрашуы да, кат-кат ялваруларыннан, таләпләреннән соң, ниһаять, рөхсәт килеп, аның үз теләге белән сугышка (штраф батальонына!) китә алуы да, сугыш бетәр алдыннан гына (1945 нең февралендә) һөҗүм вакытында берничә мәртәбә яраланып һәлак булуы да — болар барысы да, барысы да чагылыш тапкан. Менә ул кечкенә генә җөмләнең чын бәһасе, чын мәгънәсе! Укучының боларны аңлавы өчен әллә ни күп тә кирәкми югыйсә — нибарысы хәбәрдарлык кына. Аннары юл араларына язылган мәгънәләрне укырга өйрәнүе, үзенең белгәннәре янәшәсенә куеп, чагыштырып нәтиҗә чыгара алуы...

Үз хәлләрен төгәл чамалаган Х. Туфан да, Ф. Кәрим дә ул еллардагы әсәрләрендә бик ачылып китәргә ашыкмаганнар шул. Әйтәселәрен әйткәннәр, әлбәттә,— ләкин тел яшереп, тыштан беркатлы сыман тоелган сүзләре артына бигүк беркатлы булмаган фикерләрен яшереп!

Хәтта ни туры сүзле Җәлил дә, фашист әсирлегенә эләккәч, тел яшерергә мәҗбүр булган: аның «Алман иле», «Черчет ханы», «Дию базы» һ. б.— һәммәсе дә яшерен тел элементлары. Хәер, Җәлилнең тормышы һәм шигырьләре бездә яхшы шәрехләнгән, шуңа күрә дә әлеге образларны без төгәл аңлыйбыз.

«Катлаулы шагыйрь» дигән даны чыккан рус шагыйре Б. Пастернак менә нәрсә язган:

*В родстве со всем, что есть, уверясь,*
*И знаясь с будущим в быту,*
*Нельзя не впасть к концу, как в ересь,*
*В неслыханную простоту.*

*Но мы пощажены не будем,*
*Когда ее не утаим.*
*Она всего нужнее людям,*
*Но сложное понятней им.*

Бу юлларның язылу вакыты — 30 нчы еллар. «Пощажены не будем...»— ди шагыйрь — һәм шәхес культы заманының шәфкатьсез сулышы безнең биткә килеп каплангандай була. «Дөреслек кебек гади» дигән, әйтемгә тартым бер гыйбарә бар телдә. Ләкин әлеге дәвер — дөреслекне гади итеп әйтү чын мәгънәсендә куркыныч булган еллар. «Утаим» сүзен генә алыйк — заманның характерын никадәр төгәл сыйфатлый ул! Кеше күңеленең, җәмгыятьнең үз эченә бикләнеп, дөреслекнең озак вакытларга басылып, яшереп куелган чагы иде бу. Шагыйрь бередә, миңа калса, шигырьләренең ни сәбәпле катлаулы булырга мәҗбүр икәнен аңларга теләгән кешегә аңлarлык итеп әйткән кебек.

Кыскасы, шигырьнең катлауланувы да, «аңлаешсыз» дигән яман тамга алуы да, нигездә, хәбәрдарлык җитмәүдән килә икән. Һәм бу җитмәүчелекнең ике ягы бар икән; беренчесе — шагыйрьне иҗатында билгеле бер кысада бикләп тотарга тырыша торган чикләүләр, икенчесе — укучының хәбәрдарсызлыгы.

Әлеге шагыйрьләрнең гади генә язылып та бүгенге укучыга аңлаешсыз булып калган шигырьләре азмы әллә? Һәм моның гаебен шагыйрьләрнең үзләренә аударып калдыру һичкемнең башына килмәс.

Ә хәзерге шагыйрьләрнең әсәрләре? Билгеле бер әдәби традицияләр (авторитетлы

традицияләр!) формалашуга китергән бу хәлләр аларның иҗатына да үз тамгасын салмагандыр дип кем ышандыра ала?

Шулай, хәзерге көн турында, аның ни өчен тегеләй йә болай икәнлеге хакында уйлана башласаң, һичшиксез, үткәнне искә төшермичә булмый. Бүгенгенең тамыры — үткәндә, бүгенге поэзиянең казанышлары гына түгел, кимчелекләре дә шул заманнарда ук борынлап, тишелеп чыга башлаганнар. Шуңа күрә дә без нәрсә турында гына сүз кузгатмыйк — һаман да шул Сталин заманнарына килеп чыгабыз. Тарихыбыз шул булгач, нишлик, аны һич тә сикертеп узу мөмкин түгел.

Ләкин тарихның күләгәле андый сәхифәләре шәхес культы дәвере белән генә чикләнсә икән лә!

60 нчы еллар ахырына таба илебезнең рухи тормышындагы «һава торышы» янәдән кире якка үзгәрә башлый. Моның иң гади, күзгә төртелеп торган мисалы — шул ук Х. Туфан иҗатында. Ул, XX съездан соң ачылган мөмкинлекләр белән дәртләнеп, шәхес культын фаш иткән шактый усал, туры сүзле шигырьләрен яза, аларның бер өше шагыйрьнең 1962 елгы җыентыгында дөнья күргән. Ләкин шуннан соң аларның кабат басылганы булмады. Дөреслекне әйтеп салган туры сүзгә, шулай итеп, янәдән көн бетә...

Нәкъ менә шул вакытта, 60 нчы еллар уртасында, безнең поэзиягә яңа буын шагыйрьләр килде. Аларның иҗаты шул заман каршылыклары эченнән үсеп чыккан, шуларны үзенә сеңдереп формалашкан. Шунысы гыйбрәтле: татар поэзиясенең гасыр башындагы һәм 20 нче еллардагы күтәрелешенә генә тиңләнә ала торган җанлану еллары бу... Ләкин тау түбәсенә менеп җиту — бер үк вакытта аннан төшә башлау да ич. Шигырьдә «герметизм»ның чынлап торып көчәеп китүе менә шул шагыйрьләр поэзиядә лидерлык яулаган вакытка туры килә. Ягъни, болай карап торышка, бу күренеш — һичшиксез, аларның гаебе...

Ә бит алар үз иҗатларын, Г. Рәхим әйтмешли, өстәлгә ачы торма кебек ачы сүзләрен ыргытып — публицистик турылыкка һәм зур йогынты көченә ия булган дәртле, кайнар шигырьләре белән башлаганнар лабаса! Ләкин, ни өчендер, бу тәр поэзиягә вакытны тарих кызганып кына бирә... Поэзиянең яшәү шартлары сиздермичә генә кире якка таба үзгәрүе, халык күңелендәге тарихи оптимизм хисләренең тора-бара алданганлык, аптырау, күңел кайту хисләре белән алышынуы аларны акрынлап айнытты.

*Син дә бик шат, мин дә бик шат,*
*Бу шатлана, ул шатлана,—*
*Бар микән соң бу дөньяда*
*Безнең дә кебек шат бала?*
*Дөньяны йөреп чыкмаган*
*Илендә йөреп шатлана;*
*Илендә йөреп чыкмаган —*
*Өендә йөреп шатлана...*
*Юктыр ла ул бу дөньяда*
*Безнең дә кебек шат бала!*

Р. Мингалим.

Көннән-көн ишәя барган төрле тыюлар һәм инструкция-күрсәтмәләр белән тәмам чикләнгән кысан, тар тормышка шулкадәр күнеккәнбез ки, элементар мөмкинлекләрне дә бәхет урынына күрә башлаганбыз икән ич!

Шигырьнең катлаулылана баруы, кемнәрдер уйлавынча, шагыйрьләр капризы гына китереп чыгарган нәрсә түгел иде. Әдәбиятка сөйләргә ярамый торган темалар, тормышның ул яктыртырга ярамый торган яклары барлыкка килгән иде. Рәсми рәвештә дөрес дип табылган фикерләргә каршы килә торган уй-кичерешләрне кәгазьгә теркәү катгый тыелган иде. Ләкин поэзия, әгәр ул яшим дисә, әйтәсе сүзен әйтмичә кала алмый. Рухи эзләнүләре, иҗади үсеш логикасы шагыйрьләрне күңел әрнеткеч нәтиҗәләргә (нинди нәтиҗәләр икәне турында алга таба сүз булыр) китереп чыгарды. Поэзия бу нәтиҗәләрне, бу хактагы борчылулы уйларын гади генә, шигырьдә «табышмак кормыйча» гына әйтергә мөмкинлек таба алмагач, урау юллар сайларга мәҗбүр булды. Бу исә, үз нәүбәтендә, шигъри форманың катлауланушына китерде, мәгълүматы, эстетик әзерлеге чамалы булган укучылар өчен шигырьне «аңлаеш»сыз»га әйләндерде.

Шәкли яктан, ягъни поэтика ягыннан гына караганда, мин бу хәлне тискәре күренеш димәс идем. Шигъри фикерне гадәти булмаганча итеп, баш ватканда гына төбенә төшәрлек итеп язу тора-бара поэтик алымнар муллыгына китерде. Фикер өлкәсендә төгәл, кырыс регламентлар хөкем сөрсә дә, поэтика бу вакытта чагыштырмача иркеле булып калды. Эстетик форманы эталектән аерып бәяләргә гадәтләнгән эклектик рәсми фикер монда әллә инде ул кадәр «крамола» күрмәде, әллә инде әлеге чикләүләрен шулай нык ваклап, абсурд һәм көлке дәрәҗәсенә төшерүдән курыкты. Нәтиҗәдә, безнең шагыйрьләргә иҗади ихтыяҗларын һич булмаса шәкли иҗат белән канәгатьләндерү мөмкинлеге калды: ши-

гырь формасы төрләнәнде, баеды. Ләкин сәнгатьтә форма һәрвакыт нинди дә булса мәгънәгә ия: соңрак яңа поэтик алымнарның яңа эчтәлекне гәүдәләндерүе ачылды.

Язмыш иронияce дими ни дисең: күпме бәхәсләр кузгалуга сәбәпче булган «ирекле шигырь» дигән киемәнә ул дәвер поэзиясе нәкъ менә үзенең ирексезлеге, хокуксызлыгы аркасында төренгән булып чыкты!

Рус әдәбиятында «шестидесятники» дигән төшенчә бар. Без аны «60 нчы еллар буыны» дибез. Беренчесе хәзерге вакытта илле яшьләрен тутырган Е. Евтушенко, А. Вознесенский, Б. Ахмадуллина, Р. Рождественскийларга карата әйтелә. Икенчесе яшьләре илле тирәсендәге Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхим, Р. Мингалим, М. Әгъләмов һ. б.ны үз эченә ала. Һәр ике әдәбиятта да поэзиядәге яңарыш процесслары шушыларның исемнәре белән бәйле. Бездәге илле яшьлекләр — И. Юзеев, М. Шабаев, Ш. Галиев һ. б.— Вознесенскийлар белән бер чорда әдәбиятка аяк басуларына да карамастан, алар эшләгән эшне эшли алмадылар. Моны алардан соң килгән буын эшләде.

Шулай бервакыт хөрмәтле бер тәнкыйтьчебез әдәби яңалыкларның хәзерге татар әдәбиятына, рус әдәбияты белән чагыштырганда, биш еллап соңга калып килүенә игътибар иткән иде. Ул моны көнбатыштан Мәскәү аша Казан тарафына күчеп килә торган һава торышы белән чагыштырды. Мәскәүдәге сыман һава бездә, кагыйдә буларак, өч көнгә соңрак урнаша. Чагыштыру матур, эффектлы иде, ләкин мәсьәләнең асылын аңлаттымы соң ул? Поэтик яңалыкның татар поэзиясендә соңрак пәйда булуы аларның, һичшиксез, Мәскәү ягыннан килүе, шуңа күрә соңгаруы турында сөйли аламы? Юктыр, сәбәп тирәндәрәктер...

Мәгълүм ки, шәхес культы һәм Бөек Ватан сугышы татар әдәбиятын олы-олы әдипшагыйрьләрдән мәхрүм итте. Моңа 30 нчы еллардагы вульгар социологизм тырышлыгы тудырган кыенлыкларны да (әйтик, революциягә кадәр яшәгән зур-зур әдипләрнең иҗатларын сызып ташлау) өстәсәк, сугыштан соңгы татар поэзиясенең хәлләре, чыннан да, бик үк шәптән булмавы аңлашылыр. Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, М. Галәү, К. Тинчурин, Дәрдмәнд, С. Рәмиев, Ш. Бабич, Х. Туфан, Ф. Бурнаш, М. Җәлил һ. б.— һәммәсе дә, гүя бөтенләй булмаган да сыман, юк дип игълан ителгән иде. Сугыштан соңгы чор һәм 50 нче еллар — татар әдәбиятының менә шушы чиктән ашкан фәкыйрьлектән чыгу юлын эзләп бер урында таптануы, уш җыю дәвере булды. Бу чорда әдәбиятка килгән буыннар төп җегәрләрен элек булган, әмма югалтылган казанышларны яңабаштан бөртекләп җыю эшенә сарыф итәргә мәҗбүрләр иде. Асылы белән, бу «яңабаштан велосипед уйлап табу» заманы иде. Мондый хәл һич тә әлеге шагыйрьләрнең гаебе түгел, бәлки бәласе булды. Әдәбиятка һәртөрле яңалыкларны, гадәттә, яшь буын алып килә. Шундый вазифаларны үтәргә тиешле яшь буын үткәннең новатор шагыйрьләре иҗаты белән бары тик 50 нче елларның икенче яртысыннан башлап кына таныша алды. Шуңа да татар поэзиясендәге үзгәрешләр менә шушы буын җитлегеп әдәбиятка килгәннән соң гына башланды да. Аңа кадәр бу мөмкин түгел иде әле.

Татар әдәбияты үзенә тән һәм җан сәламәтлеген, шулай итеп, 50 нче елларның ахыры — 60 нчы елларның башында гына кайтара алды. Соңгаруның төп сәбәбе менә шунда иде.

Фәкать шуннан соң гына, фәкать шул нигездә генә шигырьне яңарту ихтыяҗын тоярга, ул ихтыяҗның реаль чалымнарын шәйләргә мөмкин булды. Поэзиянең заман таләпләренә тәңгәл тәэсирлелеген тәэмин итү өчен, һичшиксез, поэтиканың функцияләрен киңәйтергә кирәк иде. Бу эшне 60 нчы еллар буыны шагыйрьләре башлап җибәрде. Шагыйрьләрнең яңа поэтик мөмкинлекләр эзләү вакытында ирекле шигырьгә юлыгуы исә принципиаль яңа нәтиҗәгә — поэзиянең экспрессив табигате симметриягә генә түгел, ә бәлки, шуңа тиклем хакимлек иткән карашларга капма-каршы рәвештә, асимметриягә дә бәйле икәнен аңлауга китерде. Сәнгать әсәре, әлбәттә, симметрия белән асимметриянең диалектик берлеге ул. Моны аңлау исә, үз нәүбәтендә, шагыйрьләргә шәкли эзләнүләрендә, ягъни форма иҗат итүдә кыюлык өстәде. Катлаулылыктан, аңлашылмый калудан да курыкмыйча, экспрессияне, ягъни тәэсирлелекне шигырьнең һәммә катламнарыннан да эзләү ирекен бирде. Шигырьнең тышкы формасы шактый еллар буе каһәрләнеп, үгисетеп киленгән бер нәрсә сыман иде. 60 нчы еллардан соң, төрле юк-бар поэтик ырымнарга ышану кимү сәбәпле, шәкли үзгәрешләрнең күбесе нәкъ менә шигырьнең шушы катламында ясалды.

Иҗтимагый шартлар үзгәрешен чамалап өлгермәгән кайбер тәнкыйтьчеләр шигырьнең шушы яңа сыйфатларына каршы ябырылдылар. Шулай 1965—1966 елларда көндәлек матбугатта шигырьнең яңа формасы турындагы бәхәс кызып, шаулап алды.

*Таш койма өстендә*
*Үсте каен,*
*Тамырлары киткән саен —*
*хәвефлерәк.*

Р. Фәйзуллин

Шушы шигырьне мисалга китереп, бер тәнкыйтьче: «...киң катлау укучы өчен болар-

ның кызыгы булыр микән?.. Шигырь көткән укучы өчен бу кызыксыз булырга мөмкин...»,— дип белдерде. Икенче бер тәнкыйтьчебез, тагын ун елдан артык диярлек вакыт узгач, шушы ук шагыйрьнең бүтән бер әсәрен, эстетик әзерлеге аз булган укучыларга аңлаешсызлыгы өчен ошатмыйча, «катлаулы», «аңлаешсыз» дип игълан итте:

ӘСИР

*Вазада җикән камыш.*
*Ханым кулмәк салгандагы җил*
*ул бик аз шул...*

Реаль тормыш чынлыгын күз уңыннан җибәреп, узган көн критерийлары белән эш итү әлеге тәнкыйтьчеләрне, миңа калса, диалектик фикерләү сәләтеннән мәхрүм итеп, йә ялангач эстетизм, йә вульгарлаштыру позицияләренә китереп чыгарды. Шагыйрь югыйсә төрки поэзиядә борын-борынгыдан хакимлек иткән мозаик фикерләү алымын нибарысы яңа баскычка гына күтәргән иде. Мозаика сәнгате кануннары буенча, мондый шигырьне, һичшиксез, зур бөтеннең бер кисәкчәсе генә икәнен истә тотып, авторның бүтән әсәрләре янәшәсендә карарга кирәк, шул чакта гына аның мәгънәсе җиңел ачыла. Болай уку гади укучы өчен табигый булса да, хөрмәтле тәнкыйтьче, күрәсең, әсәрнең үзен генә аерып алып тикшерергә шулкадәр күнеккән иде ки, бу гадәтеннән кинәт кенә арынырга аның көче дә, сәләте дә җитмәде. Әлеге шигырьләрнең беренчесе Р. Фәйзуллинның туган ил, туган халкы язмышына багышланган әсәрләре арасына урнаштырылган, шушы хәл, һичшиксез, аның эчтәлеген билгели. Икенчесе исә аның шәхескә табигый яшәеш, рухи ирек даулаган башка шундый ук әсәрләре белән берлектә зур бер цикл тәшкил итә — моны да, әлбәттә, искә алмыйча ярамый иде.

Шигырьнең үзгәргән тышкы кыяфәте 40—50 нче елларның лозунг кебек туры һәм коры сүзле рафинадланган рәсми поэзиясе мисалында тәрбияләнгән укучыларның шулай котын алды, аларны читкә тибәрде. Шуңа күрә дә ул, нигездә, яшьләр арасында аңлау, яклау тапты, алар белән бергә акрынлап үсте, үзгәрде.

Тик, кызганыч, җәмгыятьтә хәбәрдарлыкның елдан-ел кимүе, яңа буыннарның мондый поэзияне аңлавын һаман саен кыенлаштыра килеп, тора-бара аларның күпчелеген бөтенләй аерып калдырды — 70 нче еллар укучыларының шактый өлеше поэзия өчен шулай «югалтылган буын» булды.

Безнең матбугатта нәкъ ун ел саен диярлек кабатланып торган поэзия турындагы сөйләшүләрнең төп мәгънәсен, сөземтәсен аерып алып янәшә языйк әле:

60 нчы еллар — шигырьнең яңа формасына «ятсынып» карау...

70 нче еллар — яңа форма белән шигырьнең «аңлаешсызлыгы» арасында бәйләнеш табарга омтылу...

80 нче еллар — поэзия белән укучы арасындагы бәйләнешкә җитди куркыныч яный, поэзия «гомуми кризис» кичерә дип санау...

Бу өч нокта, күренеп тора, шактый туры сызык өстендә ята. Бәя һәм диагноз төгәллеге хакында бәхәсләшергә мөмкин, әмма монда ачык бер тенденция, закончалык ярылып ятуын танымыйча ярамый.

Әйе, торгынлык еллары һәм аннан элгәрерәк дәверләр п о э з и я н е, аннан да битәр — у к у ч ы н ы деформацияләде.

Ләкин бу нәтиҗә генә, минемчә, поэзиянең гомуми кризисы, торгынлыгы турында хөкем карары чыгару өчен аз. Бигрәк тә аны гаепләү өчен нигез була алмый ул.

Әгәр хәзер, чыннан да, укучыларның поэзиядән азмы-күпме читләшүе күзәтелә икән — моңа, барыннан да элек, поэзия түгел, ә озак елларга сузылган хәбәрдарсызлык, хокуклар дефициты гаепле.

Илдәге рухи процессларны күз алдында тотып, А. Твардовский: «Сугыштан соңгы бөтен тарих — коллыктан котыла бару ул»,— дип язган иде. Җиңел генә булмады, юк, коточкыч авыр икән «коллыктан котылу». Асылда, бу әле үз хәлеңне аңлау, шуннан билгеле бер нәтиҗәләр ясау гына иде. Ләкин шул ук вакытта моны аз дип тә әйтәсе килми: үз хәлеңне аңлау — бу инде азатлык юлының башы.

Миңа калса, безнең поэзия халыктагы менә шушы аңлау процессын чагылдыра алды.

Поэзиянең кабул итәргә читен, мәшәкатьле булган катлаулы ассоциатив фикерләү пәрдәсе артына яшеренүе, кинаяләр теленә күчүе исә, халкыбызның борынгы риваятьләрендә сөйләнгән мескен манкорт хәленә төшмәс өчен көрәшүенең бердәнбер һәм соңгы чарасы иде.

# ТУКАЙЛАР РУХЫ

## ЯЗУЧЫ ҺӘМ РЕЖИССЕР РОБЕРТ БАТУЛЛА БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ



*— Батулла әфәнде! Сез бүгенге татар әдәбиятында иң оригиналь шәхесләрнең берсе… Бу үзенчәлек торгынлык хакимлек иткән чорда бигрәк тә ачык сизелде. Сез ул чорда татар зыялыларын оештыру, рухи активлаштыру буенча гаять күп эшләдегез. Менә хәзер искә төшереп әйтә аласызмы: ул елларда торгынлык психологиясе белән типик бәрелешләрегез кинделәр булды?*

— Ул вакытта, ягъни 1969 елда, мин Язучылар йорты каршында яңа тәҗрибәи театр оештырган идем. Такташның иң куәтле шигырьләреннән торган, «Җирнең гыйсьянчы углы» дип аталган шигъри тамашабызны халыкка күрсәттек. Профессиональ артистлар Равил Шәрәфи, Ринат Таҗи, Айдар Хафиз, Эльс Гадел, Батулла башкаруында бу спектакльне тамашачы (күбесе язучы-журналист) көчле алкышлар илә бәяләде. Аяныч, ләкин чыны шул: Язучылар идарәсенең ул чактагы рәисе Ибраһим Гази бу тамашаны тыйды, халыкка яңадан кабатлап уйнатмады. Сәбәбе: Такташның беренче чор иҗатындагы бу шигырьләрен болай зур итеп күрсәтергә һич тә ярамый. Бу — И. Гази сүзләре. Главлит (халык телендә «матбугат цензурасы») аша узган, китапларда чыккан бу шигырьләрне ни өчен сәхнәдән сөйләргә ярамый? Кем әйткән аны, кайда «һич тә ярамый» диеп язылган — анысын союз җитәкчеләре әйтә алмый. Шулай итеп, әле яңа гына барлыкка килгән яңа театр күз алдында һәлак булды. И. Гази мине каты ачуланып, идея тотнаксызлыгында гаепләп, бу эштән азат итте. Хәер, ул эш җәмәгать башлангычында, бары тик «шәп-шәрә» мавыкканлыкка» гына корылган… ягъни түләүсез иде.

*— Без «актив позицияле кеше кирәк!» дип, «көрәшчеләр кирәк!» дип бик күп мәртәбәләр кабатладык. Ә үзебезнең җәмгыять, бигрәк тә власть ияләре, андыйларны бетерү өчен ниләр генә эшләмәде?! Керсез күңелле андый кешегә яшәве бик тә кысен булды… Ә менә хәзер, Яңарыш башлангач, андыйларга яшәү җиңеләеште, дип әйтә аласызмы? Сезнеңчә, андый кешеләргә мөнәсәбәт үзгәрдеме?*

— Юк! Җиңелләшмәде. Әдәбият-сәнгатькә ихластан хезмәт иткән шәхесләрне халык элек тә хөрмәт итте, хәзер дә хөрмәт итә. Әмма аларга нахак яла яккан, аларны хаксызга рәнҗеткән кешеләр җәза, һич югында тәнкыйть тә алмады. Алар — һаман түрә, алар һаман үзләрен хаклы саный. Галимҗан Ибраһимовны сүккән Гали Халит та бүген үзенә аклау тапкан: мин ул вакытта яшь идем, ди. Әмирхан Еникига нахак рәвештә идеологик чатаклык сылаган Камил Фасеев та вөҗдан газабы кичерми шикелле. Элек тә алар обкомның сөекле уллары иде, хәзер дә шулай булса кирәк. Үзгәрмәде әле күп мәсьәлә. Карьерист һаман карьерасын куа, өскә үрмәли, ә олы-олы талантлар һаман читтә кала бирә.

Рөстәм Мингалим — бик күп җитди шигъри кыйссалар авторы, эшчән драматург, җәмәгать эшлеклесе, Язучылар оешмасының арысыз эшчесе. Тукай бүләгенә ул лаекмы?

*— Лаек, күптән лаек. Рөстәм Мингалимне әллә кайчан тәкъдим иткәннәр иде бит инде…*

— Лаек, партоешма тарафыннан Тукай премиясенә тәкъдим ителгән. Нигә соң бирелми, әллә яхшылап тәкъдим ителмиме? Бу торгынлык елларының шаукымы гына түгел, бу — торгынлыкның дәвамы… Илһам Шакир — халыкның җаны. 1956 елдан алып һич туктаусыз халык арасында: Себердә, Камчаткада, Урта Азиядә, Мәскәүдә,

---

Әңгәмәдә бәхәсле фикерләр булуга да карамастан, аны үзгәрешсез бирергә тырыштык. Нәтиҗәне укучы үзе ясар. (Редакция)

Ленинградта — бөтен Советлар Союзына хезмәт итте һәм хезмәт итә... «СССРның халык артисты» дигән исем белән «Социалистик хезмәт Каһарманы» атлы Алтын Йолдыз алыр өчен тагын ни эшләргә кирәк пенсиягә җиткән, сирәк туа торган талант иясенә? Мин бу сүзләремне турыдан-туры культура министры Марсель Таишевка, министрлар советы рәисенең урынбасары Мансур Хәсәновка, обкомның идеология бүлеге мөдире Ренат Харисовка төбәп әйтәм. Әлфия Афзалова белән дә шул ук хәл. Гафу итсеннәр мине СССРның халык артистлары Шәүкәт ага Биктимер, Рөстәм абый Яхин, Азат ага Аббаслар. Илһам Шакиров белән Әлфия Афзалова алардан ким эшләдемени соң? Әлфия ханым белән Илһам түрәләр өчен үги булып туганнармыни соң? Нигә дәшми татар халкы? Нигә бу ике олуг җырчыны якламый халык? Шикаятьләр язарга бик оста бит тамашачы. Гәҗитенә, обкомына, ЦКсына хәтле язалар бер-бер чатаклык чыкса! Ә шәхесне яклап, олы-бөек ике җырчысына тиешен таләп итми татар халкы. Әллә син чыннан да йоклаганмы, татар халкы! Әллә син чыннан да бары тик кара эшче буларак кына кирәкме илгә? Советлар Союзының иң кирәкле урыннарында, иң авыр эшләрне башкаручы халыкларның берсе син, татар халкы, нигә рухи азык та таләп итмисең? Ни өчен культура өлкәсендә эшләүче улларыңны якламыйсың?

— *Бөтен милләттәшләр яратып өлгергән әдәби кичәләр: «Ядкарь», ШТМнар, көлке кичәләре ни рәвешлерәк барлыкка килде? Аларны оештыруда рәсми оешмаларның: мәдәният министрлыгының, Язучылар берлегенең, ВЛКСМ өлкә комитетының ярдәме тидеме?*

— «Ядкарь»гә мине җитәкче итеп куйганда комсомол өлкә комитеты бюросы кешеләре: «Сиңа бездән нинди ярдәм кирәк?»— диделәр. Уйлап тормастан, мин: «Сездән миңа иң зур ярдәм — ул миңа комачауламау»,— дигән идем. Аларның «ярдәме» тиде. «Ядкарь» өч ел да яши алмады, һәлак булды. «Ядкарь» (ягъни үткәннәр, мәрхүм шәхесләр турында якты истәлек вә хатирәләр) исемле бу иҗади берлек мәшһүр шәхесләребезнең ядкарен күтәреп чыгу белән генә шөгыльләнмәде, яшь әдипләр, рәссамнар, артистлар вә композиторлар, музыкантларны үзара таныштыру, дуслаштыру белән дә мавыга иде. Шуның нәтиҗәсендә шагыйрь белән композиторның уртак җырлары, либреттосы белән композиторның уртак операсы, шагыйрь белән композиторның уртак ораториясе, күп кенә яңа драматургларның беренче пьесалары язылды. «Мәкерле песи» операсы (Луиза Хәйретдинова, Зөлфәт), «Кеше» ораториясе (Мирсәет Яруллин, Ренат Харис), Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, Нурихан Фәттахның беренче пьесалары махсус заказ белән язылдылар, ул пьесалар сәхнәләрдә куелды. Фасил Әхмәт белән Разил Вәлинең «Ядкарь» җыры да, үзебезнең «Ядкарь»гә багышлап, аерым заказ белән язылды.

Әмма «Ядкарь»нең иң кызган чагында гына мине, үз теләгемә каршы, бу эштән (түләүсез эштән, үзем оештырган эштән) кудылар. Бу сүзне мин аяк терәп әйтәм, чөнки китмәскә тарткалашып карадым. Ләкин комсомолның өлкә комитеты бюросы мине китәргә мәҗбүр итте. Ул вакыттагы секретарь Василецның әйтүенчә: идеясе какшау кеше «Ядкарь» кебек җитди тәшкилиятнең, яшь иҗатчыларның җитәкчесе була алмый икән. Миннән соң «Ядкарь»нең җитәкчесе итеп Разил Вәлине куйдылар, аннан соң Туфан Миңнуллинны сайладылар. Ләкин алар оештырган бер-ике кичәдән соң «Ядкарь» дигән иҗади берләшмә яшәүдән туктады. Өстәгеләр өчен бу иҗади дуслыкның кирәге булмагандыр, күрәсең. Борынгылар әйтмешли, «Ядкарь»-мәрхүмнең туфрагы нур булсын!

— *Язучы, оештыручы, яшь сәнгать өчен җан атучы Батулланың идея какшаулыгы нәрсәдә иде соң?*

— Имеш, Батулла советка каршы «Мортаза» исемле бер хикәя язган, аны университетның тулай торагындагы шәкертләргә укыган. Әйе, булды, укыдым. Әмма ул советка каршы әсәр түгел. «Идел»нең 1989 елгы 5 санында басылды. Аяныч, могътәбәр И. Гази абзый да теге вакытта бу хикәяне бомба кебек кабул итте. Янәсе, мин бу хикәядә татар халкын урыска каршы котыртам икән... Эш менә ничек: хикәя — Казан ханлыгы җимерелгәч тә татар батырларының Мәскәү басып алучыларның изүенә, көчләп чукындыруына каршы изге көрәшкә күтәрелүе турында. Бу бер какшау идея, янәсе... Имеш, мин берничә урында, Мәскәүдәге Чайковский исемендәге зал сәхнәсеннән дә кырым татарларының нахакка куылуы, хокуксыз яшәве турында сөйләгәнмен. Бусы да дөрес, сөйләдем. Менә шушы сөйләүләрем «крамола» булып минем «гөнаһлар дәфтәремә» теркәлгән. «Бүгенге заманда идеологик диверсия» дигән темага нотык сөйләүче лекторлар коллективтан-коллективка йөргәндә, җирле мисал өчен минем исемне еш атыйлар иде. Имеш, Батулла милләтчелек таратырга тырыша, әкиятләрендә балаларга зыянлы фикерләр үткәрергә маташа. Шулай итеп, мин өстәгеләр генә түгел, Язучылар берлеге җитәкчеләре өчен дә бер «шыксыз үрдәк бәпкәсенә» әвереләдем. Әле дә булса шул тойгыдан аерылганым юк. Кешеләр дә алмашынды, башка заман да килде кебек, әмма мин өске оешмалардан һаман «күсәк» көтеп яшим. Бер өйрәнгәч, һаман кыйнарлар сыман.

Шулай итеп, нәшрият, гәҗит-журнал, радио-телевидение мөхәррирләре минем һәр хикәядән, әкияттән, һәр сөйләгән сүземнән тел төбе, киная, ягъни идеологик диверсия эзләргә-табарга дучар иде. Дүрт ел китап чыгара алмадым. Гәҗит-журналларда хикәя түгел, исемем кергән мәкалә дә басылмый иде диярлек. Чыкканда да кыскартылып, алны-артны, уңны-сулны карап кына чыгаралар иде. «Социалистик Татарстан»да «Колакчын Тайфи» исемле бер әкиятемне басканнар иде дә, ул тагын кара кайгыга әверелде. Бу әкияттә Тайфи исемле төлке баласы үзенең ата-анасын, туганнарын аучылар-

га сатып, түшенә калай аса, тора-бара үзе дә этка әверелә. Ләкин соңра аны аучы, төлке дип, атып үтерә. Кемдер шушы әкияттә дә диверсия тапкан. Имеш, бу әкият обком секретаре Табеев турында икән! Редакциядә баш редактор кара буран куптара. Шуннан соң инде мин ул гәҗитәгә бөтенләй кермәс булдым.

Матбугат ишекләре борын төбендә ябыла торгач, мин телевидениедән балаларга әкият сөйләүне ешайтырга булдым. Әмма кара сакалың кая барсаң да үзеңнән калмый, дигәндәй, телевидениенең баш мөхәррирәсе Әминә Сафиуллина да минем әкиятләрдән «фетнә» эзләп тапкалый башлады. Бәлки, аңа табып биргәләгәннәрдер... Бер әкиятне экранга чыгарыр өчен мин ун әкият язарга мәҗбүр идем. Иҗат стимулы өчен, бәлки, Әминә ханымга рәхмәт әйтергә кирәктер? «Әкиятеңдә бүгенге тормышка киная бар!»— дип, китергән бер әкиятемне баш редактор бора да тора. «Кинаясез әкият булмый бит инде!»— дим.

Юк! Шуннан миң иң кечкенәләргә кинаясез әкиятләр яза башладым. Барыбер табылды киная. Телевидениедән сөйләгән озын бер әкиятем «Тычкан баласы Чикыл»да, имеш, мин, «Мыек Мырый патша» дигән булып — Сталинны, «Мырхыл Дуңгыз патша» дигән булып — Хрущевны, «Йөнтәскаш Маймыл патша» дигән булып — Брежневны... мыскыл итәм икән.

Шулай итеп, әкиятләр тапшыруы да төртелеп калды. Мин бу мөхәррирләрне гаепләмим. Бу әйтүләрем зарлану түгел, менә мин ничек кыен яшәдем, дип батыр булып күренергә дә теләмим. Ихтимал, баш мөхәррирләргә өстән күрсәтмә булгандыр. «Кара исемлек» дигән сүз бар халык телендә. Әнә шул «кара исемлек»тә ул елларда Салих Баттал белән Батулла даими пропискада булды.

Идеямның какшавына тагын бер хикәям сәбәпче булды («Монар»— «Мираж»). Әлеге хикәядә ике шофер ягулыксыз һәм ризыксыз чүл уртасында адаша. Хәлдән тайган юлчыларга мираж күренә, матур шәһәрләр, агачлыклар, чишмәләр — рәхәт тормыш. Берсе алдаучы монар икәнне белгән килеш, икенчесе шул монарга ышанып, баралар да баралар. Ялганга баралар, матур ялганга. Барган саен һәлакәткә якынаялар...

«Куян баласы Нуян» әкиятеннән дә табылды «диверсия». Зәки Нури әйтүенчә, өстәгеләргә бу әкият бер дә ошамаган. Шамил Рәкыйп тә шул сүзләрне әйтте. Имеш, мин кыр куяннары белән йорт куяннарын сөйләштерәм дә, ирекә омтылучы кыр куяннарын мактыйм, хөкүмәтебезгә йон-ит бирүче йорт куяннарын яманлыйм икән. «Үзегезне суеп, тиреләрне туныйлар»,— ди кыр куяны кроликларга.

Тора-бара минем юл «Ялкын» журналына да шартлап ябылды. Унбиш ел бу журналда җөмлә дә бастыра алмадым.

«Ядкарь» үтерелгәч, Шаяннар-Тапкырлар мәҗлесе (ШТМ) дип аталган сатирик кәмитләр, пародияләр, һөҗүмнамәләр театры оештырдым. Бик кызык кичәләр иде ул. Халык ике сәгать буе күзеннән яшь чыкканчы көлә. Халык көлә, ә мин икенче көнне җылыйм. Җә бер сүз кыек әйтелгән, җә бер мәзәк-кәмиттә ниндидер киная киткән. Ул кичәләрне әзерләү ике-өч ай вакытны ала, сценариесен үзем язам, артистларны табып, үзем алар белән кәмитләр тәкърарлыйм, кичәне үзем алып барам. Артистлар да, музыкантлар да, рәссамнар да гел бушка эшлибез. Рәхмәт өчен эшләмибез дә бит, рәхмәт урынына кыен күрүләре дә рәхәт түгел иде шул!.. Ул вакытта идеология җитәкчесе Мөдәррис Мусин, аның ярдәмчесе Ринат Закиров иде. Бу ике кеше мине обкомга чакырып: «Күп эшлисең син, Батулла»,— дип күңел өчен генә булса да җылы сүз әйтмәде. Кечкенә бер мәзәк өчен дә, чүпкә дә тормаслык бер ялгыш сүз өчен дә чакырталар, пешерәләр, анысына атлыгып торалар иде шикелле...

Ибраһим Гази бер җыелышта Чаллыда егерме биш мәктәп ачылганын горурлык белән сөйли башлады. Мин урыннан:

— Ничәсе татар мәктәбе, Ибраһим абый?— дип кычкырдым.

Берсе дә татар мәктәбе түгеллеген бөтен кеше белә, әмма И. Гази сөйли бирде, имеш, татар класслары, фәлән-төгән. Шуннан халык шаулаша башлады. Туфан Тиңнуллин, Рәдиф Гатауллин, мин берьюлы кычкырдык:

— Демагогия белән шөгыльләнмәгез, Ибраһим абый! — дидек.

Минем ярык тавыш катырак чыккандыр шул, обкомга «мунча кертергә» үземне генә чакыртып алды М. Мусин.

1970 елда мин Л. Брежневка ике телеграмма суктым. Ул телеграммалар Казаннан ары киткәндер дип өметләнмим. Әмма бу эш тә Мусин игътибарыннан читтә калмады. Чакырдылар. Телеграммаларның берсе — яшь язучылар өчен журнал сорау, икенчесе татар архитектура җәүһәре Әҗем мәчетенең тулай торакка әвереЛдергәнлеге турында иде...

Дөресен әйтим, И. Гази, З. Нури, Г. Ахуннар Язучылар башында торганда миннән гел идея чатаклыгы гына эзләп маташтылар. Ихтимал, бу минем шикчәнлегем генәдер. Һәрхәлдә, миңа шулай тоела иде. Бәлки аларга да өстән күрсәтмә, «кара исемлек» төшерелгән булгандыр? Юкса, ничек аңлатып була менә бу хәлне. Җәмәгать эшләрендә җигелеп эшләп тә, телевидениедән бихисап әкиятләр сөйләп тә, хикәясен язып, пьесасын куйдырып торсам да, культурабыз өчен шәкертләр әзерләү белән еллар буе шөгыльләнсәм дә, олы докладларда Батулла дигән язучының иҗаты ник бер телгә алынсын! Язучылар олау-олау төялеп тугандаш җөмһүриятләргә кунакка йөри, РСФСР, СССР язучылары корылтайларына барып аралашалар, элемтә урнаштыралар. Мин исемлеккә кергән очракта да кайдадыр өстә исемемне сызалар иде. Шулай итеп, 1985 елда гына, заманалар үзгәрә башлагач кына, Батулла «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән исем алды. Бу сүзләр миңа гына кагылмый. Торгынлыкта кәкре

идеология белән шөгыльләнүче аппаратчылардан зыян-зәхмәт күргән шәхесләр бер мин генә түгел.

— *Торгынлык чорын аңлау, ул чорда яшәгән намуслы шәхесне күзаллау өчен Сезнең «Алып батыр мажаралары» бик тә гыйбрәтле әсәр. Аны иҗат итүегез ничегрәк башланды? Хәзер ул әсәр буенча берәр телевизион фильм эшләргә дәртегез юкмы?*

— Бу сүзләремнән соң мине тыйнаксыз димәсеннәр, зинһар. Тыйнаксыз булырга мине әдәби тәнкыйтьнең иҗатыма карата сукырлыгы, ялкаулыгы мәҗбүр итә. Бу әсәрне мин бөек теләк белән яздым. Татар укучыларына татар халкының, татар батырының язмышын күрсәтәсем килде. Алып Бәргән батыр халкы өчен нинди генә җәфалар, кыенлыклар күрми, ләкин барыбер ул үзенең туган илендә чит-ят булып, фаҗига кичерә. Бу әсәр моннан ун ел элек басыла алмас иде, басылса да аны сүгәргә атлыгып торучылар булыр иде. Хәер, әсәр таки игътибарсыз кала килә. Игътибарсызлык сүгүдән дә яманрак... Рәхмәт Рәниф Шарипкә, ул җылы сүз әйтте. Ләкин әсәр әле һаман сез тәнкыйтьчеләр тарафыннан тикшерелмәгән. Ул бит татар халык әкиятләре нигезендә язылса да, татар әдәбиятындагы оригиналь әсәрләрнең берсе дип уйлыйм. Әгәр бу тыйнаксызлыгым белән разый булмасагыз, иптәш тәнкыйтьчеләр, киресен язып чыгыгыз. Минем үземне аңлар өчен, иҗатымны тулырак күзаллау өчен өч-дүрт әсәремне уку да җитә: «Алып батыр мажаралары», «Юл буенда зәңгәр чәчәк»нең тулы нөсхәсен, «Акбүре» повестен һәм Тукай турындагы «Сират күпере» исемле драманы. «Алып батыр» ул әдәби киносценарий шәкелендә язылган. Әлбәттә, аның экранга чыгарга хакы бар. Әмма кем ул фильмны төшерергә алынсын да, кем ул чыгымнарны капласын? Сүз ияр сүз чыккач, әйтим. Бездә киночылар оешмасы бар, киностудия бар. Башкортстанда боларның берсе дә юк, әмма Уфада нәфис фильмнар студиясе ачылды. Без — татарлар — йоклаган шул, йоклаган! Безнең әле олы-исән шәхесләребез турында планлы рәвештә документаль фильмнар дә төшерергә тотынганыбыз юк. Юкса бу эшнең башы обкомнан чыгарга тиеш иде дә бит...

— *Сезнең элек язылып та бүген дә дөнья күрә алмаган әсәрләрегез бармы? Аларның вакытында чыкмавына конкрет гаепләләр кемнәр?*

— Соңгы елларда минем әсәрләрне басмыйлар, дип зарлана алмыйм, язганнарым дөнья күрә тора. Әмма узган ел язылган ике зур мәкаләмне бөтен редакцияләрдән дә бордылар. Мәкаләнең берсе «Татарстанда милли культураның торышы», икенчесе «Бүгенге шовинизм турында» дип атала. Бу мәкаләләрне басарга бер генә редактор да җөрьәт итми.

— *Димәк, демократия әле дә бәхәсле мәсьәлә?*

— Демократия гомер буе бәхәсле эш булды инде ул Россиядә. Ун-егерме еллар элек язылып та, редакцияләр тупсасын күп мәртәбәләр атлап кереп тә, кире чыгарылган, китапларымнан гел төшерелә килгән хикәяләрем әле дә булса дөньяга чыкканнары юк. Алар ике дистәгә якын. Күптән түгел бөтенесен дә «Идел»гә керткән идем. Өч хикәяне алар басты. Калганнарын кире борды. Хәзер ул хикәяләр «Казан утлары»нда. Нәтиҗәсен көтәм. Ә гаепләләр мәсьәләсенә килгәндә... редакторлар элек өстән ни кушсалар, шуны үтәүче җепле курчаклар иде. Ул хикәя-әкиятләргә «отказ» язган кешеләрнең исемнәре язылган. Үзләренең кулы белән И. Гази да, Ш. Маннур да, Я. Халитов та, Р. Хафизова да, Җ. Тәрҗеман да, тагын бик күпләр тамга салган. Өстән кушмасалар да, ихтимал, редактор-рецензентлар бу әсәрләрне бүтәнчә аңлаганнардыр.

— *Бүген Сезне культура министры итеп куйсалар, эшне нәрсәдән башлар идегез? Безнең мәдәниятта иң ашыгыч башкарасы эшләр нинди?*

— Татарстанда культура министрлыгының абруе юк. Шуңа күрә мөмкинлекләре дә юк. Ихтимал, мөмкинлекләре булмаганга абруе юктыр. Культура министрлары мин белә-белгәннән бирле өлкә комитеты, министрлар советының йомышчысы сыйфатында гына яшәде. Министрлыкның акчасы да аз бугай. Шуңа күрә мөмкинлекләре юк. Министр Алиев эшләгән заманда, мәсәлән, мин бу оешмага бик күп мәртәбәләр: «Миниатюралар театры оештырыйк әле филармония каршысында»,— дип бардым. Әмма культура министрлыгы бу эшне эшләргә теләмәдеме, эшләргә кушмадыларммы, шунысы чын: әһәмиятле бер эш шулай туктап калды. Бу йомыш белән мин культура министрларына 1963 елдан бирле йөрдем. Бифайда. Бер карауга вак кына булып күренгән эшләрне дә министр тикле министрның обком белән киңәшмичә эшләрлек мөстәкыйльлеге булмаганын мин үз күзләрем белән күргәләдем.

Татарстанга Союз статусы алынмаса, татар теленә чын хокук бирелмәсә, министр берни дә эшли алмаячак. Икенче мөһим нәрсә — кадрлар җитмәү. Татарча белүче режиссерларга, татарча белүче сәнгать укытучыларына, музыка белгечләренә кытлык. Бүген ни Мәскәүдә, ни Ленинградта Татарстан өчен укып ята торган режиссер юк.

— *Соңгы еллар тормышыбызда Сезне нәрсәләр куандыра? Нәрсәләр борчый?*

— Әз-мәз булса да илдә үзгәреш бар инде ул. Сүз сөйләргә мөмкин. Ләкин әйтелгән җитди сүзне санга сукмау да бар. АЭС мәсьәләсе әле тамырыннан хәл ителмәгән. Мәскәү татар халкының фикерен инкарь итә. Юмалап, алдап куйдылар да, шыпырт кына һаман атомның оясын төзеп яталар. Татар халкының иң күе төбәгендә коточкыч зур бомба булачак... Татар халкының көннән-көн сәрхүшкә әйләнә баруы, китапка хөрмәтнең кимүе, арзан-очсыз тамашаларга дәррәү йөреп тә, уйландыра торган шәп спектакльләргә йөрмәве, «Карурман»га түгел, бер күзәнәкле зимагур җырларына күбрәк тартылу — бар да борчулы уйлар.

— *Ничек уйлыйсыз: милләтләрнең ирекле булырга тиешлеге безнең илдә нишләп бик тә, бик тә акрын аңланыла?*

— Сталин шовинизмны дәүләт-хөкүмәт сәясәте дәрәҗәсенә күтәреп калдырганга. Бер партиялелек деспотизмга илткәнгә. Ленинның дөрес идеяләрен тырнак очы чаклы да үтәмәгәнгә. Җитәкче оешмаларны карьеристлар, караклар басканга.

— *Тукайча сорауны куйсак, нинди җавап әйтерсез: татар халкы үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?*

— Татар үлмәгән әле, йокламый да. Татар халкы мәрткә киткән. Мәрттән уяныр-мы, юкмы — билгесез. Болай барса, тиз генә уяна алмас.

— *Хәзер татар милләте исән калсын дисәк, нәрсәләр эшләү мөһим дип саныйсыз?*

— Союз статусы, татар теленә дәүләт теле дәрәҗәсе бирү. Татарстанны мөстәкыйль җөмһүрият итү.

— *Безнең яшәүнең бик күп яктан рәте китте. Аны каян, нәрсәдән башлап рәткә кертергә мөмкин дип саныйсыз?*

— Системаны тамырыннан үзгәртергә. Ягъни боерык, янау, куркыту, ришвәтчелек, талау системасын үзгәртергә. Илгә төбәкләп-төбәкләп, тармаклап-тармаклап чит ил капиталын кертергә. Япун, Алман, Америка, Финляндиядән осталар чакыртып, биш-ун ел безгә эшләтергә, һәр ике ягына үзебезнең яхшы кадрларны куеп өйрәнергә. Бөтен илләр белән иркен сәүдә итәргә, игенчене ипигә хуҗа итәргә.

— *Сез партияле кеше түгел. Ни өчен Сез партиягә кермәдегез?*

— Өстән ни кушсалар, шуңа ләббәйкә торучылар тарафыннан партиядән куылганга караганда, партиягә кермичә яшәү мең өлеш әйбәтрәк. Салих Батталны — каһарман очучы, шәп язучыны шундыйлар партиядән чыгарганга!

— *Партбилет ташлап партиядән чыгучылар батырмы, әллә куркакмы?*

— Намуссызлар! Мин: менә партбилетымны ташлап партиядән чыктым, дип мактанучыларны сөймим. Андыйлар үзләренең мәсләксез-буынсыз икәнлекләрен ике тапкыр исбат итә түгелме соң? Ни өчен ул башта партиягә кергән? Карьера эшләп булмасмы, дипме? Әллә кыстагангамы, әллә бернәрсә дә аңламыйчамы? Ничек кенә булса да бу — мәсләксезлек. Партия кешеләренә кыен вакытлар җиткәч, андыйлар партбилет ташлый. Җиңел юл эзләп йөрүчеләр түгелме соң алар?

— *Җитәкче урыннарга партиясез кешеләрне куярга ярамаган торгынлык елларында Сезне, партиясез кешене, ике тапкыр ике профессиональ театрга (курчак театры һәм Тинчурин театрына) баш режиссер итеп куйдылар. Моны ничек аңларга? Сезгә аеруча ышаныч күрсәтү дипме?*

— Башка вариант булмаганга, ягъни кадрлар җитмәү аркасында гына.

— *Сезнеңчә, бүген Тукай рухына тугрылык — ул нинди сыйфатларны дәвам итү дигән сүз?*

— Тукай татар халкының үзаңын-горурлыгын уятыр өчен ике ысулда иҗат иткән. Башта ул татар халкының бөеклеген, эшчәнлеген алга сөргән. Аннан тотып чабаклаган, татарның мескен, фәкыйрь, надан, алданучан булуыннан әче итеп көлгән. Бүген Тукай исән булса, ни язар иде? Һаман шул — татарның сәрхүшлеге, наданлыгы, ләббәйкә-кол булуы, үзенә тиешлесен дә таләп итә алмаслык куркак булуы хакында язар иде. Мәскәү куштаны булып рәхәт сөрүче җитәкчеләр, депутатлар турында сатира язар иде Тукай. Мөтәшагыйрьләр, татарча белми торган татар артистлары, татар халкының фаҗигасен күрсәткән трагедияләр яза алмаган драматурглар, бер дога белмичә күкрәк киереп Корьән сүгүче ялган атеистлар, Россия өчен сугышканда арыслан кебек сугышып, тынычлыкта аттан артык эшләп тә мәхлукъ хәлендә яшәгән татарлар турында хәтәр язар иде Тукай.

— *Татар әдәбиятына үсү өчен бүген нәрсәләр комачау итә? Җәмгыятьтәге факторлар һәм әдәбиятның үз эчендәге сәбәпләр?*

— Әдәбиятыбыз дөньякүләм, милләткүләм фикерләүгә мохтаҗ. Кинаяле, фәлсәфи әсәрләр мәктәбе юк. Бу мәсьәләдә проза да, драматургия дә татар шигыреннән бик нык артта. Татар язучылары бер генә телле, үз теленнән башка алар бары тик урысча гына укый ала. Үз телен тирәнтен-киңентен белгән татар язучылары күп түгел. Корама телдә сөйләшәбез, корама тел белән язабыз. Утызынчы-утыз җиденче елларда һәлак булган әдипләребез дүрт-биш тел белгән. Дөнья әдәбиятын алар оригиналда укыган. Без урысчага тәрҗемәдә булса, укыйбыз, булмаса, хуҗабикәсенең ишектән чыкканын тилмереп, мөңгереп көтеп торучы бозау кебек, Мәскәү итагатен көтеп ятарга мәҗбүрбез... Элек Орынбур, Уфа, Ростов-Дон, Хвалыннан — бөтен Россиядән татар мәдәниятына көчле шәхесләр җыелган. Хәзер ул чишмәләр корыды... Тел-әдәбият-сәнгать буабыз тынчый... Кайбер органнар Язучыларны җитмеш ел буена куркытып яшәде. Бу куркаклык буыннан-буынга күчеп, безнең канда да утыра. Куркак кеше кыю әсәр яза алмый. Мәсәлән, татарда Платонов белән Булгаков күренми әле...

— *Иң яраткан язучыгыз кем? Ни өчен нәкъ менә ул?*

— Гамил Афзал. Ул бөтен ләббәйкәләрдән азат. Куштанлык — аның кан дошманы. Гамил ага чын сатирик. Олы гражданин, каһарман!

— *Төрле жанрларда иҗат итү бер-беренә комачауламыймы?*

— Җитәкче урында утыручы бер каләмдәшем миңа әйткән иде: «Син, Батулла, чәчеләсең. Бер генә кадакка суккан булсаң, син әллә кайчан әллә кем була идең инде»,— диде. Дөрес, мин күп жанрлар белән эш итәм. Ягъни сигезләп «кадакка берьюлы сугып» азапланам: хикәя (балалар, олылар өчен), повесть (балалар, олылар өчен), пьеса (балалар, олылар өчен), әкият (балалар, олылар өчен), укытучы, режиссер, тарихи вакыйгалар җыючы, телевизиончы, кичәләр оештыручы... Кое казучы тирәнгә төшә

Киңгә чәчүче игенче дә бар. Игенчене: «Ни өчен тирәнгә казымыйсың, коечыны: нигә киңлеккә казымыйсың?»— дип сүгү бик акыллы эш булмас иде. Алар икесе дә бик кирәк. Бер кадакка сугып кәкрәйткәннәр дә күп. Ун кадакка сугып эш майтарганнар да җитәрлек, шөкер. Тик тормаска, йокламаска гына кирәк, сугарга кирәк. Шул.

— *Татар әдәбиятына соңгы елларда килгән яшьләрдән кайсыларына бигрәк тә өмет баглыйсыз? Ни өчен?*

— Мин әйтәчәкләрне яшь язучы дияргә дә читен инде. Алар өлгергән әдипләр. Безнең каләмдәшләребез Фәүзия Бәйрәмова, Ләбиб Лерон, Газинур Морат, Ркаил Зәйдуллин, Зиннур Хөснияр, Нияз Акмал, бертуган Зөлкарнәйләр, «Татарстан яшьләре»н чыгаручы яшь журналистлар. Бу кешеләр әдәбиятны үземчелек күрсәтү мәйданы итеп түгел, халыкка хезмәт итәр өчен сайлаган.

— *Сезнең дингә мөнәсәбәтегез нинди? Җанның мәңгелегенә ышанасызмы?*

— Динсезлектән денсезлеккә — бер адым. Динсезләр дин таптап, ил белән идарә иткәндә, денсезлек урамга чыкты... Аллаһка табынган кеше җанның мәңгелек икәненә, һичшиксез, ышанырга тиеш.

— *Бөтенсоюз мәйданына чыгуга Сез ничек карыйсыз? Татар әдәбиятының илдә аз билгеле булуына төп сәбәпләр нәрсә икән?*

— Нигә аз билгеле булсын әле татар әдәбияты? Ел саен диярлек тугандаш телләрдә антологияләр чыга тора. Мин әдәбиятны белә-белгәннән бирле «Правда», «Литроссия», «Литгазета»да, Мәскәү һәм башка нәшриятларда татар язучыларының әсәрләре гел чыга килде. З. Нури, Ә. Ерикәй, М. Садри, Г. Ахун, В. Нуруллин, С. Хәким, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхим, Р. Гатауллин, Ә. Гаффар, Ә. Баян әсәрләре Мәскәүдә, тугандаш халыкларның нәшриятларында чыкты. Такташ, Туфан әсәрләре дә, Тукайның күп шигырьләре дә Моран, Мартынов, Ахматова кебек яхшы шагыйрьләр тәрҗемәсендә дөнья күрде. Т. Миңнуллин, Ш. Хөсәен, Р. Мингалим, Батулла язган пьесалар ил театрларында дистә еллар уйнала. Чыгуын чыкканнар, уйналуын уйнала. Әмма тиешле дәрәҗәдә күтәрелмәгәннәр. Тәнкыйть күрмәгән, әллә күрергә теләмәгәнме?.. Сезнең сорауның беренче өлеше минем җен ачуымны чыгара. Ашарга ите, кияргә ыштаны булмаган кешенең бурычка кереп машина алуы яки, илендә тәртип булмаган көе, Галәмгә миллионнар очырган тиле дәүләт кебек, Татарстандагы, ил буена чәчелгән халкыңның теле бетү алдында торганда, Мәскәүдә урысча китап чыгарып, Бөтенсоюз күләмендә танылырга теләгән язучының язучылыгы да шул — ташка үлчимдер инде! Үз халкында мәшһүр булу җитмәгәнме? Бу беренчел мәсьәлә түгел. Үз йортыбызда хезмәт итик әле, аннан соң чыгарбыз! Бөтенсоюзга гына түгел. Бөтендөньяга!

— *Язучы белән власть ияләре арасындагы мөнәсәбәт нинди булырга тиеш, дип саныйсыз? Бу мөнәсәбәтнең хәзерге хәленнән Сез канәгатьме?*

— «Обком өчен — язучы» түгел, «Язучы өчен — обком» йөргәндә генә кайбер нәтиҗәләргә ирешеп булыр. Аның өчен җитәкченең шагыйрь җанлы булуы шарт.

— *Мао-Цзе-Дун да шагыйрь...*

— Димәк, аның шагыйрьлеге шул хәтле генә булган.

— *Сталин дә шигырь язган, диләр.*

— Сталин ни генә язмады да, ни генә эшләмәде? Ул бөтен өлкәдә дә «белгеч» иде. Һәр язган бәндә — шагыйрь, һәр язылган тезмә шигырь була алмый. Дөрес, патша белән шагыйрь икесе бер шәхестә булган очраклар да аз түгел дөнья тарихында. Бабур солтан шәп шагыйрь, сәнгать сөюче, сәнгатьне үстерүче хаким... Мөхәммәт Әмин хан да шагыйрь... Ниһаять, менә безнең шагыйрь Ренат Харис та Обкомда, бик мөһим бүлектә эшли башлады... Һәр шагыйрьгә үзенең чын шагыйрь икәнен исбат итәр өчен язмыш бер генә форсат бирә. Ренат Харис үзенең шагыйрь икәнен шигырьләре белән исбат иткән кеше. Шушы шагыйрь халыкның иң авырткан җирләрен дәваларга алынырмы? Шагыйрь җитәкчегә буйсынып калмасмы? Әллә җитәкче шагыйрьнең фикеренә колак салырмы?

— *Хәзер нинди яңа әсәр иҗат итәсез?*

— Казан ханы Үтәмеш Гәрәйнең анасы Сөен бикә турында язам. Хода кушса, сәламәтлегем булса, бу ел «Казан утлары»на тапшырырмын, дип өметләнәм. Әсәр тәмамлану алдында.

— *Иң зур теләгегез нинди?*

— Мин егерме сигез яшемдә генә дөньяны хәзерге юнәлешендә аңлый башладым. Шул елдан бирле мин тәкъдиремә (Аллаһка дип аңлашылса да ярый), өч теләк теләп ялварам: гаиләмдә тынычлык булсын иде, иҗатым кулга тотып карарлык булсын иде, татар халкы тулы хокукка ирешсен иде... Аллага шөкер, күз тимәсен, өемдә тынычлык, нур вә җылылык. Шөкер, иҗатым да бик фәкыйрь түгел кебек. Басылган әсәрләрем йөз илле табак. Унҗиде китап чыгарганмын, унбиш пьеса куйдырганмын, режиссер буларак, профессиональ сәхнәдә егермедән артык спектакль куйганмын, ике йөзләп телевизион тапшыру эшләгәнмен, укытучы буларак, унөч ел эшләп, биш чыгарылышның җитәкчесе булганмын. Алдагы ун ел өчен әсәрләремнең җиде томлыгын әзерләп куйганмын... Әмма мин барыбер үземне тулы бәхетле, дип әйтә алмыйм, чөнки минем өченче теләгем һаман үтәлмәгән килеш кала. Татар халкына мөстәкыйльлек, тигезлек теләвем фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килмәде бугай. Җиде миллион татар хокуксызлык киртәләре эчендә яши. Бу дискриминацион сәясәтне бары тик Союз статусы алу һәм татар телен дәүләт теле итү белән генә бетереп булачак.

— *Азәрбайҗан — Әрмән мәсьәләсе турында...*

— Бөек Ватан сугышы алдыннан совет гаскәрләренең Финляндиягә басып керүе,

илле алтынчы елда Мажарстанга басып керүе, алтмыш сигезенче елда хәрбиләрнең Чехословакиягә тыкшынуы, Әфганстандагы җинаятьләр — бөтенесе дә шул илләрнең халыкларына «ярдәм» әләме астында эшләнде. Вөҗданы уяу шәхесләр бу баскынчылыкка нәфрәт белдерде: Евтушенко, Солженицын, Сахаров һәм башкалар...

Азәрбайҗандагы бу хәлләр — икенче Әфганстан, дип саныйм. Гөнаһсызлар, коралсызлар, үз хокукларын яклаучылар һәлак була. Вөҗданы уяу булган һәр ватандаш бу җинаятькә каршы көрәшергә тиеш.

— *Татар әдәби теленнән сез канәгатьме?*

— Татар әдәби теле елдан-ел фәкыйрьләнә. Әдәби телебез базар теленә якыная. Дәрдемәнд сүз төрләрен базардан, урамнан эзләргә киңәш иткән дә бит, әмма ул заманда базарда өч-дүрт тел белгән кеше, Тукайны яттан бикләгән кеше, гәҗит-журналларны битен-биткә укып барган кешеләр булган. Тел күрше телләрдән табигый рәвештә кергән сүзләр хисабына баерга тиеш. Чит телләрдән кергән сүзләр белән пычранырга, чүпләнергә түгел, баерга тиеш. Без өй урынына «дом» дип, «мәктәп» урынына «ышкул» дип сөйләсәк, тел баемый, пычрана гына. Якында гына, мине дә кушып сөйләгезсәнә, дип тилмерешеп торган татар сүзләре булганда, аларны эзләп табарга иренеп, тупас рәвештә урыс-европа телләрендәге сүзләрне кулланабыз. Шундый сүзләр белән матбугат, радио-телевидение эфиры тулган. Бу эштә иң беренче язучылар, журналистлар алда бара. «Ярыш-бәйге» урынына, «турнир» китә, «Габдулла абый» урынына «Абдулла Шарифҗаныч» калка. «С легким паром»нан «җиңел пар белән», «с праздником»нан «бәйрәм белән»нәр килеп чыга. Бу эштә галимнәребез дә ялкаулыклары аркасында бик тырыша, сөйләм телдә көн саен кулланыла торган сүзләрне сүзлекләргә кертергә иренәләр. Соңгы елларда чыккан сүзлекләрдә «дәстәрхан — бәйрәм табыны», «салҗа — соус» һәм башка бик күп сүзләр юк. Профессор Ганиев җитәкчелегендә чыгарылган «Татарча-русча сүзлектә» (ул турыда матбугатта язылды) адәм әйтеп адәм ышанмаслык җитешсезлекләр тулган. «Аборт»ның татарчасы халык телендә дә, әдәби телдә дә «корсак төшерү» түгелме? «Абсолют» сүзен «мотлак» дип язып булмый идемени? «Абсурд» сүзенә дә якын тәрҗемә эзләргә иренгәннәр иптәш галимнәр, «имәнгеч» сүзе белән, искәрмә биреп булса да язарга иде. Сүзлекнең беренче битеннән башланган шушындый «абсурд-имәнгеч» күренеш китапның азагынача дәвам итә. Рәсми мәгълүматка караганда, татар халкының 20-30 өлеше үз телен белми. Белгәннәрнең яртысы телне корама сөйләм теле буларак кына белә.

— *Батулла ага, Сезне әүлия кеше, дип әйтергә була. Моннан утыз-утыз биш еллар элек Сез «крамола» сөйләп, ягъни дөресен әйтеп, ялгыш юлдан барабыз, дип язган кеше. Сез сөйләгәннәр килеп җитте. Моңа мисал итеп «Мираж», «Тимерҗан» исемле хикәяләрегезне атау да җитә. Утыз ел элек әйтелгәннәрне хәзер партия үзе дөрес саный. Димәк, киләчәктә ни буласын утыз ел алдан күргәнсез. Шул турыда әйтергә тырышкансыз. Димәк, Сез бүген дә ун-егерме елдан ни булачагын алдан әйтә аласыз.*

— Горбачев партия башында иң беренче олы эше итеп аракы белән көрәшә башлагач та, мин дусларыма әйттем: ахыры юньле бетмәс моның, дидем. Аракыны кыйбатлатуаны сирәк кенә сатуга чыгарып, кеше сугыштыру, иң әүвәл олы спекуляциягә илтә. Бу спекуляциядән элек тә бай булган сатучылар файда күрәчәк. Бу фәгалият уртача хезмәт хакы алганнарны кимсетү, аларны тагын да фәкыйрьләндерү сәясәте иде. Бу акылсыз эш өч катламга китереп сугачак: иң башта эшчегә, интеллигентка, крестьянга. Аракы өчен чиратта сугышучыларга карап, сатучылар һәм түрәләр үзләрен тагын да канәгатьрәк хис итәчәк. Аларга бәя артты ни дә, артмады ни. Аларга аракы булды ни дә, булмады ни, аларга эчемлекне өйләренә китереп куялар... Милли мәсьәләдә үзара чуалышлар, сугыш башлангач та, корал, танк, автоматтан башка чара табылмады. Бусы инде аракы мәсьәләсеннән дә куркынычрак. Монда шовинизм, дискриминация исе аңкый. Бәс, дидем, илдә гражданнар сугышы башланачак. Ул вакытта әле **Үзбәкстанда да, Азәрбайҗанда да бу хәлләр юк иде. Алгарак эш уңай якка үзгәрмәсә,** халыклар ирекккә омтылачак, бу омтылышны безнең хөкүмәт: хулиганлык, экстремизм, усал милләтчелек, дип бәяләчәк һәм, яхшылык эшләү йөзеннән, бу халыкларның азатлыкка омтылышын кан белән бастырачак. Шулай итеп, Россия халыклар төрмәсе булудан туктамаячак... Тефү-тефү, берүк алай була күрмәсен, әлбәттә!

— *Хәзерге каләмдәшләрегезгә иң мөһим теләкләрегез нинди?*

— Татар халкына үзен саклап калыр өчен дүрт йөз утыз сигез елга өч тапкыр мөмкинлек бирелгән. Пугачев күтәрелешеннән соң Әби патша дин иреге биргән. Дин аркасында татар халкы бик нык тернәкләнгән, өешкән, ныгыган. 1905 нче елдагы инкыйлабтан соң татар иркенлек алган, 1905-1923 еллар татар халкының милләт буларак камилләшкән заманы. Һәм менә хәзерге заман. Бу форсатны без ычкындырсак, кабат беркайчан да халык милләт була алмаячак. Рәсми мәгълүматларга караганда, татар телен туган теле санаучы кешеләр елдан-ел кими бара. Бу эш шушы тизлектә барса, иң күбе илле елдан татар теле гамәлдән чыгып, үле рәтендә калачак... Без рәхимсез цензура кылычы астында иҗат юлы башладык. Сез, яшь каләмдәшләр, иркенрәк чакта язасыз. Көрәшкә атылыгыз. Һәр шигырь, һәр эш, һәр яңу халык мәнфәгате өчен, татар телен саклап калу өчен, мәктәпләрне киңәйтү өчен булырга тиеш. Үзегезгә таләпчән һәм халык өчен кирәкләрне дә таләп итәрлек кыю булыгыз!

*Әңгәмәне әдәби тәнкыйть бүлеге* ***мөхәррире***
*Мансур Вәлиев алып барды*

Хәмит Төхфәтуллин

# КАМИЛ МОТЫЙГЫЙ

*Ул минем этием иде.*

*Эти... Өч революциядә катнашкан, үзенең иң илһамлы, иң мәгънәле елларын халыкка хезмәт итүгә, халык язмышына багышлаган кеше.*

*Эти... Безне аның белән кан берлеге дә, ата белән бала мөнәсәбәтләре дә, дәвамлылык дип аталган бөек хис һәм бөек аваз да, рухи уртаклык булып әверелгән күп кенә идеаллар да берләштерә. Ләкин мин, кайчандыр бу язмага тотынганда, аның турында «эти» дип түгел, ә бәлки «ул» дип яза башладым. Юк-юк, бу минем үз этиемнән йөз чөеруем дә, аннан ераклашырга тырышуым да түгел. Ил язмышындагы коточкыч афәтле еллар ата белән улны, ир белән хатынны, туган белән туганны бер-берсеннән баш тартырга, кардәшлек җепләрен өзеп яшәргә мәҗбүр иткән вакытларда да без эти белән рухи бердәмлектә булдык. Мин аның хатларын яхшы хәтерлим. «Халык дошманы»ның атасы булып әверелгән, шуның аркасында бик күп кимсетелү һәм җәберләр кичергән чагында да аның миңа язган хатлары, мәркәзгә җибәргән төрле үтенечләре — үз улына дөреслекнең кайчан да булса бер калкып чыгачагына ышаныч белән сугарылган иде.*

*Әйе, татар халкының иҗтимагый тормышында, мәдәни дөньясында тирән эз калдырган, беренче басма газета һәм журналларның мөхәррире, беренче татар профессиональ җырчысы булачак Рәсәйнең барлык зур шәһәрләрен айкап чыккан Камил Мотыйгый минем этием иде. Мин аның турында «эти» дип түгел, «ул» дип, Камил Мотыйгый дип язуымны дәвам итәм. Чөнки аның моңарчы киң халык катламнарыннан сәбәпсез яшерелгән исеме дә, кылган эшләре дә минем өчен зур бер каһарманлык билгесе булып тора, ул үзе дә халык язмышыннан аерылгысыз, халык тарихына үрелеп барган бер зат булып күз алдыма килә. Шуңа күрә, бу сүз күңелгә никадәр генә якын булса да, аңа «эти» дип кенә эндәшү, «эти» дип кенә язу ничектер аз булыр кебек...*

## I

1883 елның 25 феврале. Җаек шәһәре. Бу көнне монда, бөек шагыйребез Тукайның остазы булган Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин гаиләсендә бер малай дөньяга килә.

Камил Мотыйгый булып әверелгәнчегә кадәр әле бу малайга шактый сукмаклар, шактый юллар үтәргә туры киләчәк. Аның әле атасы Мотыйгулла мәдрәсәсендә ун ел буена белем аласы, аннан соң Мисырга китеп Каһирәнең Әл-Асхәр мәдрәсәсендә укып кайтасы, туган шәһәре Җаекның «Мотыйгыя» мәдрәсәсе шәкертләренә аң-белем өйрәтәсе, шәхес булып өлгерәсе бар. Соңрак аның тарих, мантыйк (логика), яңа гарәп әдәбияты буенча биргән дәресләрен Тукай һәм башка шәкертләр яратып тыңлаган.

Нәкъ менә шул мөгаллимлек чорында, 1903—1905 нче елларда, Камил Мотыйгый үзенең беренче стена газетасын, кулъязма журналларын чыгара башлый, аларның нәшире һәм мөхәррире була. Әлеге журналларның берсендә — «Әл-гасрел җәдит» журналында Тукайның тәүге әсәрләре дөнья күрә, Камил Мотыйгыйның үз әсәрләре — беренче әдәби парчалары, «Мисырга сәяхәт», «Төш күрү», «Ике Рафик» исемле хикәяләре басыла. Шул ук елларда ул үзенең «Бәхетле Мәрьям» исемле беренче романын яза һәм аны Петербургта бастырып чыгара. Әсәрнең әдәби кыйммә-

тен, сәнгатьчә эшләнешен бәяләү — әдәбият галимнәре кулында. Әмма Камил Мотыйгыйның «Бәхетле Мәрьям»ендә сүзнең хатын-кыз иреге турында баруы, әсәрнең наданлыкка, кияүгә көчләп бирүләргә каршы язылуы инде шактый нәрсә сөйли: димәк, әсәр авторының күңеленә ирек җилләре үтеп кергән, гаделлеккә сусау хисләре тулган. Камил Мотыйгыйның «Бәхетле Мәрьям»е татар әдәбиятының беренче романчылары Заһир Бигиев, Фатыйх Халиди әсәрләре белән аваздаш. Яңа фикерләр белән канатланган яшь мөгаллим, әле генә бөреләнеп уяна башлаган, бәйсезлеккә таба омтылган татар кызларының берсе Мәрьям — аларның матур-сөйкемле йөзләрен, саф мәхәббәтләрен, тәрәккыйгә тартылуларын язганда Камил Мотыйгый, әлбәттә, күңелендәге хыялларын да китереп кушкандыр.

Төрле төбәкләрдән килгән котлаулар, китапның тиз арада сатылып-таралып бетүе аның иңнәренә канат куйгандыр. Әмма бу тынгысыз күңелдә һаман да ризасызлык хисе кала килә: чөнки татар телендә газета-журналлар нәшер итәргә рөхсәт сорап, ул инде бик күп үтенечләр язып карады. Әмма Петербург аның ул гаризаларын һаман-һаман кире кага торды.

Бу — очраклы хәл генә түгел. Моңа кадәр дә татарның зыялылары Каюм Насыйри, Габдрахман Ильясов, Шаһбазгәрәй Әхмәров, Һади Максудов һәм башкалар татар телендә көндәлек матбугат булдыру өчен көч түккәннәр, аларга да рөхсәт бирелмәгән.

Сүз дә юк, әгәр 1905—1907 елгы революция патша империясен какшатмаса, төрле төбәкләрдә, төрле өяз-калаларда калкып-күтәрелеп чыккан милли азатлык хәрәкәте империя диварларын дер селкетмәсә, Камил Мотыйгыйның да уй-теләкләре челпәрәмә килер иде.

1905—1907 елларда Җаекта, татар мәдәнияте тарихында беренче буларак, «Әлгасрел җәдит» һәм «Уклар» журналы, «Фикер» газетасы дөнья күрә. Аларның нәшире һәм мөхәррире Камил Мотыйгый була.

Үз мәдәнияте күгендә кинәт балкып киткән бу йолдызларны халык бик тиз күрә, алдыра, укый. Татар халкының милли аңы һәм милли горурлыгы үсүдә бу газета-журналларның тәэсире әйтеп бетергесез. Үзенең иң үткен шигырьләрен халыкка нәкъ шушы басмалар аша җиткергән Тукай аларның тууын кояш чыгуга тиңләп язган икән, ул инде, әлбәттә, халык күңеленә революцион-демократик идеяләрнең тулуын, халыкны бәйсезлеккә һәм ирекккә өндәүне күздә тоткандыр. Татар матбугатының беренче басмалары бу бурычны тәүге адымнарыннан ук алга сөрә.

## 2

Иң әлек, 1905 елның 27 ноябрендә, үзен «цензурасыз газета» дип атаган «Фикер» газетасы дөнья күрә. Аның битләрендә социаль-демократик партиянең үзәк комитеты һәм урындагы комитетлары карарлары басыла, революцион хәрәкәтнең барышы яктыртыла, думага сайлаулар вакытында социаль-демократик партия кандидатларын яклаган язмалар бирелә; патшаның ялчысына, курчагына әйләнгән җирле бюрократлар, административ чиновниклар, кадимчеләр һәм карагруһчылар ачы тәнкыйтьләнә. Андый язмаларның ялкын теле саннан-санга көчәя бара, газетаның шөһрәте арта һәм ул, көннән-көн үсеп, 5000 данәгә җитә. 1906 елның декабрь аенда «Фикер» газетасы (45 нче сан) «Интернационал» җырын татар телендә бастырып чыгара:

*Сезгә котылуны һич кем бирмәс,*
*Нә алла, нә патша вә нә баһадир.*
*Сез котылмакка җитәрсез*
*Үзегезнең кулларыгыз илә...*

Әгәр «Фикер» газетасының ул еллардагы саннарын күзәтсәң, Камил Мотыйгыйның үзе туып үскән өлкәдә яшәүче казах халкы язмышы турында да тирән уйланганын тоясың. Газетаның беренче саннарыннан ук аның битләрендә казах халкының алдынгы уллары да үз сүзен әйтә башлый. Мәсәлән, газетаның 1906 ел 10 январь санына өстәмә итеп, казах халкының декларациясе бирелә. Казах телендә басылган бу кушымтаны шушы телдә туачак газеталарның бер үрнәге дип тә санарга була. Чөнки бу вакытта Җаек казахларының үз телләрендә чыга торган көндәлек басмалары юк әле. Газетаның нәкъ шул санында казах халкының танылган эшлеклесе Бәхтиҗан Каратаевның зур гына мәкаләсе басылып чыга. Патша хөкүмәтенә каршы юнәлтелгән бу чыгышында Каратаев казах халкына автономия бирүне таләп итә һәм үз халкы исеменнән болай дип белдерә: «Әгәр казах халкының бу таләпләре тәэмин

ителмәсә, ул вакытта аларны сугышып алырга туры киләчәк».— ди.

Кыскасы, Җаекта чыккан татар басмалары казах халкының иҗтимагый фикерен һәм милли узаңын уятуда да зур өлеш кертә, дип әйтәсем килә.

## 3

1906 елның башында, январь аенда, Камил Мотыйгый татар телендә беренче журнал чыгара башлый. «Әл-гасрел җәдит» дип аталган бу басманың дөнья күрүе үзе генә дә зур бер вакыйга, җәмгыятьтә һәм милли азатлык хәрәкәтендә барган көрәшнең бер билгесе.

Рәсәйнең барлык төбәкләреннән котлаулар ява. Татар зыялыларыннан, галимнәреннән килгән тәбрикләр арасында яшь Тукайның да тавышы яңгырый.

Яңа журнал — яңа мөмкинлекләр дигән сүз. Монда инде прогрессив идеялләр белән сугарылган күләмлерәк әсәрләрне бастырып чыгару да мөмкин. Әйтик, журналның 8, 9 һәм 11нче саннарында Тукай тәрҗемәсендә Бахның «Царь-голод — экономические очерки» дигән әсәре бирелгән. Билгеле булганча, Бахның әлеге хезмәте Маркснып «Капитал»ын популярлаштыруда зур әһәмияткә ия. В. И. Ленин, теле гади һәм аңлаешлы булуга игътибар итеп, рус телендә брошюра хәлендә чыккан бу әсәрне партиянең барлык оешмаларына таратырга, кабат-кабат бастырып, барлык эшчеләрне таныштырырга тәкъдим иткән.

Журналның 12 нче санында Фатих Әмирханның Париж коммунасы турындагы язмасы басыла. Язманың максаты ачык: ирек өчен көрәшүчеләрдән үрнәк алырга, бәхет өчен алар кебек кыю көрәшергә!

Монда тагын шунысын да истән чыгармаска кирәктер: 1906 елның соңгы айларында, революцион хәрәкәт каршылыкларга һәм авырлыкларга юлыккан бер вакытта, төшенкелеккә бирелгән күп кенә зыялылар революцион эштән читләшә башлый. Нәкъ менә шундый авыр бер чорда «Әл-гасрел җәдит» журналы демократик идеяләргә һәм революцион көрәшкә тугрылыклы булып кала. Ул гына да түгел, иреккне тулысынча яулау өчен көрәшкә дәшә. Шул ук 12 нче санда Камил Мотыйгый «Мөхтәрәм мөштәриләребезгә тәрбия» дигән мәкаләсе белән катнаша. Журналның 1907 ел өчен программасын билгеләп, укучыларга мөрәҗәгать итеп, ул түбәндәге шартларга туктала:

*«Милләтебезне инкыйраздан коткармак юлында*
*би хак социал-демократик мәсләгендә буларак,*
*нам хөррият казанмак хезмәт итмәктер.*
*Долой бюрократ-провокаторларны! Долой инсаннарга зарарлы адәмнәрне! Хөррият, ирек барча халыкка булсын. Милләт, нәсел вә нәсәп аерылмаенча, руслар га, мөселманнарга, яһүдләргә вә башка милләтләргә, ирләргә вә хатыннарга барчасына тигез хаклар булсын. Иштә безнең мәсләктә будыр».*

Шулай итеп, Камил Мотыйгый үзенең социал-демократик платформага нык таянганлыгын, милли мәсьәләне хәл итүдә нәкъ менә шушы таләпләрдән чыгып көрәшәчәген халыкка ап-ачык итеп әйтеп бирә. Аның бу таләпчән карашы 1904 елны журнал чыгару мәсьәләсендә рөхсәт сорап язган гаризасында да ачык чагыла: «Тик матбугат аша гына халыкның рухи омтылышларына дөрес җавап бирергә мөмкин, тик шул юл белән генә хезмәт ияләренең ихтыяҗларыннан чыгып һәр якның гомуми интереслары нигезендә башка милләтләрне руслар белән берләштерергә мөмкин» (Кулъязма «Әл-гасрел җәдит», 1904 ел, 22 нче сан).

«Әл-гасрел җәдит»нең һәр санында Тукайның шигырьләре басылып килә. Шулай ук монда әле генә әдәбият мәйданына килеп кергән яшь язучыларның чәчмә әсәрләре дә дөнья күреп тора. Халыкның үз тормышыннан алып язылган бу әсәрләр журналның абруе үсүенә дә сәбәпче була.

## 4

1906 елның июнь аенда Камил Мотыйгый тагын бер журнал нәшер итә башлый. Бусы инде «Уклар» дип атала һәм аңа мондый исем бирелүе юкка гына түгел: «Уклар» — сатирик журнал, рәсемле, көлкеле журнал. Камил Мотыйгый оештырган яшь нәшриятнең дүртенче басма органы. Араларында рус телендә чыга торган «Уралец» газетасы да бар. Ике газета һәм ике журнал белән берьюлы идарә итү авырга туры килгәндә, Мотыйгый бу яңа сатирик журналны редакцияләү эшен Тукайга тапшыра. Бу тәкъдимне шагыйрь, дуслык билгесе дип, шатланып кабул итә,

Тукайның чәнечкеле юллары, төрле мәзәкләр һәм көлкеле рәсемнәр белән чыккан журналның даны тиз арада таралып өлгерә. Бер елга якын эшләп, Тукай үзе дә, күрәсең, шактый зур тәҗрибә туплап өлгерә. Аның турында язган истәлекләрендә Камил Мотыйгый: «...бөтен эшне үз кулына алу дәрәҗәсенә җитте»,— ди. Чыннан да, журналга мәкаләләр җитенкерәми торса, шагыйрь бер дә аптырап калмый — тота да үзе яза! «Уклар»да чыккан кечкенә язма-эпиграммаларның күбесе — Тукайныкы. Шуңа күрә бу сатирик журналны Тукай әсәрләренең бер томы дип атасак, һич тә ялгышмабыз. «Уклар»ның беренче санына бирелгән кереш сүздәге «Татарларга хөр Россиянең свободный гражданнары булырга кирәк», дигән кыска гына җөмлә дә аның төп юнәлешен төгәл әйтеп бирә һәм журналдагы көлкеле-чәнечкеле язмаларның гади бер уен-көлке, гади бер шаяру гына булмавын күрсәтеп тора.

Кара көчләр һәм карагруһчыларның янавына да карамастан, «Уклар» үз юлыннан тайпылмый, киресенчә, үткенләнә генә бара. 1906 елның 6 ноябрендә басылып чыккан «Шартлар» исемле мәкаләдә ул үз юнәлешен тагын да ачыграк белдерә: «Капиталистик строй бетеп, дөньяга социалистический тормыш чыкмыйча, капиталның һәр хакыйкатькә пәрдә булып торуы бетмичә, мин үземне мөселман дип йөрүдә бернинди мәгънә тапмыйм...» — диелә ул мәкаләдә. «Шүрәле» дип имза куйган. Тукай мәкаләсе бу. «Бу тормышка кальбән разый булып торган кеше мөселман да түгел, мөэмин дә түгел, инсан да түгел диясем килә» — әлбәттә, әлеге уклы сүзләр кемнәрнеңдер үзәгенә кадалмый калмаган. Нәкъ менә шушы мәкаләдән соң «Уклар»ның нәшире һәм мөхәррире Камил Мотыйгый зур штраф түләргә мәҗбүр була һәм аның журналы, губернатор әмере буенча, басылудан туктатыла.

## 5

Әгәр Мотыйгыйның көндәлек матбугат эшенә кереп китү юлын күзәтсәң, ирексездән 1905 елның көзенә әйләнеп кайтырга туры килә. Һәм монда инде «Уралец» газетасы калкып чыга.

Канлы якшәмбе көннәре Җаекта рус телендә басылып килүче «Уралец» газетасы идарәсен дә какшата һәм каушата. Идарәнең унбиш әгъзасы, мөгаен үз араларында бердәмлек булмау сәбәпле дә, газета чыгаруны туктатырга, типографияне сатарга карар итә. Идарә әгъзаларының төрлесе-төрле политик агымда торганлыктан һәм арада шактый гына низаглар да килеп чыкканлыктан, бердәм революцион эш алып бару мөмкинлеге калмый. Социал-демократик партиянең шәһәр комитеты газетаны саклап калу ягында тора. Алар белән элемтәдә булган Камил Мотыйгый, комитетның тәкъдиме һәм ярдәме белән, вексельләр биреп, «Уралец» нәшриятен үз исеменә ала. Акчалата бернинди хак та кертелми. Хәер, Камил Мотыйгыйның моңа көче дә җитмәс иде; аның ул вакыттагы бөтен кереме, мәдрәсәдә укыткан өчен, аена 25 сумнан гыйбарәт. «Уралец»ны үз кулына алу белән, Мотыйгый аның хезмәткәрләрен тулысынча алыштыра, яңа көчләр туплый. Алар арасында шәһәрнең күренекле җәмәгать эшлеклеләре булу газетаның абруен күтәреп җибәрә. Яңа хезмәткәрләр ратендә Беренче Думаның депутаты Недоносков, Икенче Думаның социал-демократлар фракциясе әгъзасы Козьмодемьянский, Җаекта профсоюзларны оештыручы Ульянов кебек кешеләрнең булуы газетаның эшенә һәм юнәлешенә тәэсир итми калмый. Типографиядә дә социал-демократлардан торган бер төркем эшли. Самодержавиегә каршы язылган материаллар, революция көндәлеге, көн кадагына суккан язмалар һәм шигырьләр — болар барысы да «Уралец»ның сугышчан коралына әверелә. Бигрәк тә В. И. Ленин оештырган «Новая жизнь» газетасыннан алынган материаллар урындагы администрациянең күзенә кылчык булып кадала. «Кызыл флаг күтәреп йөрүчеләр нәрсә телиләр?» дигән баш астында большевикларның программа таләпләрен бирү, «Пролетарии всех стран, соединяйтесь!» җырын бастыру инде патша ялчыларын куарга турыдан-туры өндәү булып яңгырый. Һәм «шәһәр аталары» бу юлы штраф салу белән генә канәгатьләнми: газетаны чыгару административ тәртиптә туктатыла. Зур кыенлыклар һәм тырышлыклар аша, җәмәгатьчелек ярдәме белән, Камил Мотыйгый газетаны яңа исем белән чыгарырга рөхсәт ала. Шулай итеп, 1906 елның гыйнвареннан «Уральский дневник» чыга башлый.

Камил Мотыйгыйның социал-демократлар белән элемтәсе өзелми, киресенчә, ныгый гына. Әлеге партия комитеты тарафыннан тәкъдим ителеп эшкә керешкән һәм матбугат эшен «Уралец»та ук башлаган Д. С. Колотилин белән төзелгән килешүдә һәр ике якның да уртак максатны ачык күзаллаулары күренеп тора. Бу натариаль килешүнең төп нөсхәсе безнең гаилә архивында сакланып калган.

Самодержавие бюрократларына тәнкыйть уты яудыруны «Уральский дневник» бермә-бер арттырып җибәрә. Аның битләрендә социал-демократик партиянең

карарлары чыга, патшаның Октябрь манифестын фаш иткән язмалар басылып тора. Д. С. Колотилин, төрле эзәрлекләүләргә түзә алмыйча, 1906 елның җаендә шәһәрдән чыгып китәргә мәҗбүр була. Камил Мотыйгый мөхәррирлекне үз өстенә ала.

Мәскәү эшчеләренең Декабрь восстаниесе көннәрендә, анда Питердан һәм Җаектан җәза отрядлары җибәреләчәге билгеле булгач, «Уральский дневник» махсус мәкаләләр бастыра һәм солдатларны баш күтәрүчеләргә атмаска өнди, хәтта аерым листовкалар бастырып тарата. Камил Мотыйгыйның карашларын, эшчәнлеген һәм социал-демократлар белән ни дәрәҗәдә бердәм эш йөртүен подполковник Бочкаревның 1908 елның 16 октябрендә жандарм идарәсенә тапшырган әләк язуы ачык күрсәтә, күзәтү ясап, оешманың татар телендә газета чыгарырга ниятләвен әйтә һәм «...Газета әүвәлге нәшир Төхфәтуллин типографиясендә басылачак. Хәзер әле типографиягә арест салынган. Төхфәтуллин типографиясе яңадан эшкә керешү белән, аның янында с/д типографиясе дә эшкә керешәчәк»,— дип хәбәр итә.

## 6

1907 ел Җаектагы прогрессив көчләр өчен бик зур авырлыклар алып килә. Социал-демократлар оешмасы тулысынча диярлек тар-мар ителә. Реакциянең миһербансыз кулы инде башка прогрессив оешмалар белән дә исәп-хисапны өзәргә керешә.

Губернатор боеруы буенча, Камил Мотыйгыйдан нәширлек һәм мөхәррирлек хокуклары алына, атасы Мотыйгулла хәзрәт белән икесен хөкемгә тарталар.

Хокуксыз калган Камил Мотыйгый инде газета-журналларны үз исеменнән бастырып чыгара алмый. Бу — аның өчен зур югалту. Ул гына да түгел, Мотыйгый редакция һәм типография хезмәткәрләре алдында да бик кыен хәлдә. Күпме тырышлык һәм көч куйган, бердәмлек һәм теләктәшлек күрсәткән бу кешеләрнең күбесе — фикердәшләр, дуслар бит. Аларны, исәп-хисапны бетереп, эштән азат итәргәме?! Меңләгән мөштәриләргә ни әйтергә? Алар инде 1907 ел өчен тиешле язылу акчасын керткән. Нишләргә? Менә шушы сорау, бик күп борчулы уйланулардан соң, «Нинди чаралар күреп, эшне ни рәвешле уңай хәл итәргә?» дигән тәгаен максат белән алышына. Котылу юлы гел уйламаган яктан килеп чыга: либерализм идеяләренә хәер-хаһ булган, дөресрәге шул идеяләргә төренеп яшәүне артыграк күргән миллионер Мортаза Гобәйдуллин типографияне һәм «Тәраккый» нәшриятен бөтен газета-журналлары белән арендага алырга ризалыгын әйтеп тәкъдим ясый. Исәп-хисап һәм финанс эшләрен шул хәлендә кабул итеп алырга һәм әлеге дүрт басманың да нәшире булырга, аларны бастыруны дәвам итәргә теләге барлыгын белдерә. Бу тәкъдим, бик яхшылардан булмаса да, башка бер-бер чара калмаганлыктан, Камил Мотыйгый һәм аның даирәсе тарафыннан кабул ителә. Типография эшчеләре дә, редакция хезмәткәрләре дә үз урынында кала. Фәкать Камил Мотыйгый урынына гына яңа редактор билгеләнә. Яңа редактор — Мортаза Гобәйдуллинның сәүдә эшләре белән бәйле булган Хәмидуллин — матбагага кагылышлы мәсьәләләрдә бик сай иөзә. Шунлыктан ул бу эштә Тукайдан ярдәм сорый. Шагыйрь исә шундук ризалык бирә һәм, нәтиҗәдә, төп редакцияләү вазифасы аның кулында була.

Рәсми редактор Хәмидуллин белән Тукай арасы нык. Алар бер-берсен яхшы беләләр. Хәмидуллин — Мотыйгулла мәдрәсәсе һәм аның шәкертләре өчен шактый игелекләр эшләгән кеше. Шагыйрь кайчандыр, мәдрәсәдә укыган чагында, кулъязма журнал «Әл-гасрел җәдит»тә бастырган тәүге шигырьләренең берсен нәкъ менә шушы кешегә багышлап язган иде. Хәзер инде, тәкъдир кушуы буенча дигәндәй, аларга бергә-бергә эшләргә туры килә һәм, әлбәттә, алар бер-беренең сүзенә колак салалар. Алар икесе дә Камил Мотыйгый белән еш аралашалар, татар халкының киләчәге турында сөйләшәләр. Мәдрәсәнең өлкән укытучысы Камил Мотыйгыйга карата булган ихтирам Хәмидуллинның эшчәнлегендә дә, Тукайның язмаларында да һәрдаим сизелеп тора. Хәмидуллин шәхси мәсьәләләрдә дә Мотыйгыйны якларга әзер тора. Мәсәлән, Тукай редакциясендә чыккан «Әл-гасрел җәдит»нең 3 нче санында түбәндәге белдерү урнаштырыла: «Хөрмәтле Камил Мотыйгый Төхфәтуллин кулыннан нәширлек вә мөхәррирлек хокуклары администрация тарафыннан алынгач, табигый, «Әл-гасрел җәдит» журналын сөючеләр кайгырдылар. Газеталарыбыз да беркадәр тәэсир итеп яздылар. Бу кайгыга иштирак әсәре күрсәттеләр. Ихтимал, бәгъзе золмәт сөючеләрдән шатланучылар да булгандыр. Шуңа күрә без бәян итәбез ки, «Әл-гасрел җәдит»нең ошбу 3 номерын мәйданга куйдыкымыз кеби аны һаман да дәвам иттерәчәкбез... «Әл-гасрел җәдит»нең әүвәлге мәсләкенә вә хөррият пәрвәрлекенә аслан хәлил китермәячәкбез».

Мондый сүзләр — мәсләккә тугрылык сүзләре журналда шактый кабатлана. «Без Уральск шәһәренең кояшларын сүндереп караңгыда адаштырырга кулыбызда

аз гына икътидар, тәнебездә җан бар вакытта асла разый булмаячакбыз» (1907 ел, 3 нче сан) дип инанып әйтүләр Тукайның реакцион көчләргә бер җавабы булып та, үзенә күрә ант булып та яңгырый сыман.

Тукай бу сүзләрне язганда, әлбәттә, тиздән газета-журналларны бастыру тукталачагын белмәгәндер. Үзен либерал дип атап йөргән Мортаза Гобәйдуллин үзенең карашын бик тиз үзгәртә һәм, бу эшнең чыгымы бик зур, дигән сылтау белән басмаларны чыгаруны туктата, редакция хезмәткәрләрен дә, типография эшчеләрен дә, исәп-хисап биреп, эштән бушата.

Баштарак үзенә ышаныч тудыра язган Гобәйдуллин бу эше белән үзен Тукай алдында бөтенләй үк ача. Чиксез әрнү хисләре кичергән шагыйрь шуннан соң «Матбага берлә уйнаган бер байга» шигырен яза:

*Булды кондыз, асылы үзгәрде, диеп мин күрсәм үз,—*
*Хәзрәтеңне белештем! — дуңгыз икәнсең син һәнүз!*
*Туктале, бер көн килер дә, өйрәтер, әлбәт,*
*Миллионың ул тар ләхеттә файда бирмәс, бәдбәхет!*

Тукайның мондый усаллыкка хакы бар.

Мортаза бай белән аның арасы элек тә катлаулы була. Тукайның байларга карата карашын, дошманлык хисен күреп торган Гобәйдуллин аны ничек тә булса үз ягына аударырга тырыша, аның көчле каләмен үз файдасына эшләтмәкче була. Имеш, ул Тукайга башкачарак карый, үтә ягымлы мөнәсәбәт тота. Янәсе, Тукай моңарчы чыккан газета-журналлардагы язмаларын Камил Мотыйгыйга ярүдән генә язган. Мортаза бай Тукай белән Камил Мотыйгый арасын бозарга, аларны аерырга тырышып карый. Кыскасы, миллионер Гобәйдуллинның Җаектагы газета-журналларны арендага алуы матбугат белән усал һәм мәкерле бер уен булып чыга.

Басмаларны чыгармау, эшне туктату — бер хәл. Мәсьәләнең әле финанс ягы да бар бит. Типографиянең чын хуҗалары эшне хөкемгә куя. Камил Мотыйгый биргән вексельләрне түләтү мәсьәләсен тикшергән суд типографияне аукцион аша сатарга карар чыгара. Нәкъ шушы көннәрдә Камил Мотыйгыйга каршы да тикшерү оештыралар. Моның өчен сылтау итеп метрика кәгазен казып чыгаралар. Камилгә атасы тарафыннан бирелгән метрика кәгазендә 22 яшь урынына «25 яшь тулды» дип күрсәтелгән һәм шул кәгазь, нәширлеккә рөхсәт сораганда, Эчке эшләр министрлыгына җибәрелгән була.

Әлбәттә, хөкем процессы оештыруның һәм Камил Мотыйгыйны атасы белән бергә хөкемгә тартуның сәбәбен хөкүмәт законнарын бозу белән бәйләсәләр дә, хөкемдарларның максаты бүтәнчәрәк булуы ачык: хөкем утырышы сәяси юнәлештә барып, аларның икесен дә бер үк җиргә — сәяси тоткыннар төрмәсе Петропавел крепостена ябарга карар кыла. Камилне — ел ярымга, улына ярдәм иткән хәзрәтне алты айга ирektән мәхрүм итәргә хөкем чыгаралар. Мотыйгулла хәзрәтне муллалыктан алырга һәм үзе үк оештырган «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыту хокукыннан мәхрүм итәргә дигән карар да яңгырый суд залында.

Хөкем карары укылганнан соң җебеп төшкән һәм тәмам югалып калган кешеләр аз түгелдер. Ләкин үзенең хаклыгына ышанган, үз эшенең дөреслегенә инанган кешене сындыру җиңел түгел, диләр. Камил Мотыйгый да үзенең нәрсә хакына тырышуын, кемгә хезмәт итүен, нинди максатка омтылуын яхшы белә. Һәм ул, суд залыннан чыкмас борын ук, Саратовтагы окружной суд исеменә кассация шикаятен яза. Аның максаты — вакыт оту. Ул белә: шикаять әле тиз генә каралмаячак, ә шул вакыт эчендә шактый эшләр башкарып өлгерергә була. Суд тикшерүе астында яшәвенә карамастан, ул әле шушы араларда гына ике зур эш башлап җибәргән иде. Беренчесе — басылудан туктаган газеталар урынына яңа газета чыгара башлау мәсьәләсе. Бу хакта ул, үткән җәй аенда ук, үзенең фикердәшләре Мусин һәм Тукай белән үзара килешкән иде. Булачак газетаның исеме — «Яңа тормыш», ә аның нәшире һәм мөхәррире Мусин булыр дип уйлаганнар иде. Әлбәттә, бу килешүдә җитәкчелек һәм фактик редакторлык вазифасы Камил Мотыйгыйның үзендә калачагы да каралган.

Алда торган эшләрнең икенчесе — әле яңа гына оешып килүче татар театры артистлары, татар труппасына ярдәм итү. Алар, Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендә Мәскәүгә гастрольгә барган артистлар, кереп булмау сәбәпле бик авыр хәлгә төшкәннәр, тәмам өметсезләнә башлаганнар. Җитмәсә, Кудашев үзе, артистларны ташлап, Петербургка китеп барган. Бу хакта Мотыйгыйга Габдулла Кариев хат җибәргән, кыенлыктан чыгу юллары турында киңәш сорап, ярдәм сорап язган.

Мотыйгый труппаны Җаекка чакыра, дус-ишләреннән җыйнап, юллык акча җибәрә. Аларны каршы алып, спектакль-тамашаларын күрсәтерлек шартлар тудыруда — бинаны табу, кием һәм декорацияләр юнәтүдә башлап йөри.

Җаекта үткәргән ике ай ярымлык беренче сезонын «Сәйяр» труппасы әнә шулай

Камил Мотыйгый ярдәме белән башлап җибәрә. Бу труппа нәкъ менә Җаекта нык-лап оешу чорын кичерә, репертуар туплый, үз мөмкинлекләренә ышаныч тудыра. Алда — Идел буе шәһәрләре, алда — Баку, алда — Казан!

Ә Камил Мотыйгыйга килсәк, аңа суд хөкеменнән котылу өчен, бәлки, нәкъ менә шушы тынгы белмәвенә, югалып калмавын, төшенкелеккә бирелмәве, һәм олы уйлар белән яшәве дә ярдәм иткәндер. Кассация судында аны яклап чыккан адвокат Рудольф һәм аның гаиләсе белән без алга таба бераз танышып үтәрбез әле. Чөнки алар Камил Мотыйгыйга әле тагын бер тапкыр, аның җырчылык һәм артистлык эшендә дә ярдәм итәчәкләр.

Ә хәзергә Мотыйгый, үзенең беренче ниятен чынга ашырып, Тукай һәм Мусин ярдәмендә «Яңа тормыш» газетасын юлга салып йөри.

## 7

Икенче Дума таратылып, Столыпин реакциясенең бар көченә котырынуы Җаек демократларының хәрәкәтен артык озак туктатып тора алмый. Алар, 1907 елның җәендә үк, басылудан туктатылган «Фикер» урынына яңа татар газетасы чыгару турында уйлый башлыйлар. Өч фикердәш — Мусин, Тукай һәм Мотыйгый — 1907 елның 20 июнендә үзара килешү төзиләр һәм Мусинны рәсми редактор итеп билгелиләр.

Мусинның шәхесе һәрьяклап җайлы. Ул — калаччы сәүдәгәр, икмәк һәм он белән сәүдә итә, шәһәрдә аны белмәгән кеше юк диярлек була. Хөкүмәт органнары алдында да ышанычлы кеше исәпләнә, димәк, газета чыгару өчен рөхсәт алу да тизрәк хәл ителергә мөмкин.

Ул елның җәендә Тукай, кем әйтмешли, башы-аягы белән иҗат эшенә чума. Нәкъ шушы айларда ул үзенең «Шүрәле», «Китмибез» һәм башка шундый бөек әсәрләрен яза. «Әл-гасрел җәдит»нең, «Фикер»нең тукталуын, «Тәрәккый» матбагасының тар-мар ителүен шагыйрь бик авыр кичерә, аларны яңадан торгызу турында уйлана. Татар телендә газета-журналлар чыкканда, аның укучылары бөтен Рәсәй иде. Ул үз сүзен, туры сүзен барлык өлкәләргә таралган милләттәшләренә җиткерә ала иде. Ә хәзер...

Бу көннәрдә Тукай мәдрәсәгә, Мотыйгулла хәзрәт янына еш йөри. Элек тә, мәдрәсәдә дәрес алган чакларында да, ул үзенең язганнарын хәзрәткә укып күрсәтә иде. Редакциядә эшләгәндә дә бу гадәтен ташламады. Аның «Китмибез»ендәге фикерләре шул дәрәҗәдә ачык һәм кискен яңгыраган икән, димәк, монда зур укымышлы Мотыйгый хәзрәтнең дә тәэсире бар. Менә ул шигырь туды! Шагыйрь аны үзенең остазына укырга ашыга. Яраткан шәкертен шатланып каршылаган хәзрәт аның укуын дәшмичә, бүлдермичә тыңлый. Укып бетергәч тә сүзсез утыра, дәшми. Бары тик аның күзләре генә очкынланып китә, алар ни сәбәптәндер дымланган. Бу очракта сүзләр артык... Бары тик бер генә нәрсәне кабатлый хәзрәт:

— Афәрин!.. Афәрин!..

Ниһаять, хәзрәт шагыйрьне кочаклап ала һәм «Китмибез!» не тагын бертапкыр кычкырып укуны сорый.

Ә «Яңа тормыш» газетасын чыгаруга рөхсәт, Тукай хәрби хезмәткә каралырга дип авылына кайтып киткәч, Мусин исеменә килә. Газетаның беренче саны 1907 елның 11 ноябрендә чыга. Столыпин цензурасының авыр шартларында «Яңа тормыш» үз сүзен әйтергә, «Әл-гасрел җәдит» һәм «Фикер»дән килгән юнәлешләрне саклап калырга тырыша. Монда инде укучыларга кирәкле сүзне җиткерү өчен төрледән-төрле юллар сайлана. Мәсәлән, газетаның 7 нче санында чыккан «Аракы турында» дигән мәкаләне алыйк. Әлеге «яшел елан»ның халык тормышына бәла-каза китергән нәрсә икәнен һәм бу афәтне хаким сыйныфлар махсус көчәйткәнлекне әйтеп киткәннән соң, автор язманы кинәт кенә менә шул рәвешле йомгаклый:

«Аһ, Россия, Россия! Тагы да ниләр күрәсең бар икән? Кайчан безгә күптән көткән вакыт килер икән? Кайчан без төшләребездә генә күрә торган чын хөррият һәм тигезлекне өнебездә дә синдә күрербез икән? Кайчан килер икән шундый вакыт? Кайчан язучылар әзәрлекләүсез теләгәннәрен яза алырлар икән, кайчан учительләр иркенләп укыта алырлар, ә ораторлар собраниеләрдә куркусыз чыгышлар ясый алырлар икән? Ул көннәрне безгә үзебезгә күреп шатланып каршы алырга насыйп булсын! Ни гүзәл булыр иде бу?!»

«Яңа тормыш»та төрле әдәби парчалар, сатирик язмалар еш басылып тора. Шулар арасыннан «Төш күрүче» исеменнән бирелгән памфлет һәм фельетоннарны аерып күрсәтергә була. Автор еш кына төрле җәнлекләр, кош-кортлар, бөҗәкләр һәм башка җан ияләре тормышына мөрәҗәгать итә, аларның үзара сөйләшүләрен тыңлый һәм шундый нәтиҗәгә килә: бу җан ияләренең дә тормышы кешеләр тормышына охшаш икән, алар да үз хәлләрен яхшырту өчен, ирек өчен көрәш алып

баралар, алар арасында да революционерлар, студентлар, агитаторлар һәм кара көчләр бар икән. Кыскасы, монда ул өндә түгел, ә бәлки төштә генә күрергә мөмкин булган бик күп нәрсәләр турында сүз кузгата һәм моның өчен әнә шул «төш күрү» алымын оста файдалана.

Шундый «төш»ләрнең берсендә («Яңа тормыш», 1908 ел, 15 январь) автор балык патшалыгында балыкларның ирек өчен ничек көрәшүләрен тасвирлап бирә. Гади балыклар, чиктән тыш җәберләүләргә түзә алмыйча, баш күтәрәләр. Боларның буаны ерып җибәрүләреннән курыккан балыклар патшасы манифест язып чыгара: шушы көннән башлап барлык балыкларның да хокуклары тигез, имеш. Моңа ышанган гади балыклар чиксез куана. Әмма аларның бу шатлыклары озакка бармый: чуртан кебек ерткыч балыклар яңадан һәр эшне үз кулларына алалар. Әмма моннан соң чуртаннар үзләре дә озак яши алмый: алданган булуларын тәмам белеп-аңлап өлгергән балык халкы чаң суга, су төбеннән буталып, өскә күтәрелә һәм аны озак вакытлар буена тыеп торган буа җимерелә.

Сизгер укучы, әлбәттә, «Төш күрүче»нең бу язмасында турыдан-туры илдә барган хәлләргә киная барлыгын аңласа кирәк. Әмма әлеге «Төш күрүче» исеме артында нәкъ менә Камил Мотыйгый торганын бик азлар белә. Гомумән, бу елларда «Яңа тормыш» үз юнәлешен, әнә шундый кинаяле язмалар аша булса да, үткәрергә тырыша һәм бу уңайдан «Төш күрүче»нең сәер һәм гаҗәеп төшләре бик оста кулланыла. Монда инде Өченче Думаның асылда контрреволюцион эш алып баруы да, Столыпинның халыкка каршы сәясәте дә кискен һәм үткен тәнкыйтьләнә.

Камил Мотыйгыйның сатирага осталыгы ул мәдрәсәдә чакта ук чыгарган кульязма журнал «Әл-гасрел җәдит»тән башлана. Шул журналның 1904 ел, декабрь ае санында аның «Нәрсәләр генә күрмибез төшләребездә» дигән беренче хикәясе бирелгән.

Инде әйтеп үтелгәнчә, «Яңа тормыш»ның баштан ук сәяси мәкаләләр белән чыгуы аның «Фикер» традицияләрен дәвам итүенә бәйле. Аның битләре дә социал-демократик партия вәкилләре чыгышларына даими урын бирә. Мәсәлән, газетаның 11-15 нче саннарында социал-демократ Девятковның язмалары тәрҗемә итеп бирелгән. Бу язмалар Швеция, Дания, Норвегия, Италия һәм Испания кебек илләрдә яшәүче халыкларның тормышы, андагы сыйнфый көрәш турында сөйли. «Башка илләрдә крестьяннар ничек яшиләр» дигән язмасында автор, Көнбатыш Европа илләрендәге крестьяннарның хәлен тасвирлау белән бергә, андагы пролетариатның көрәш ысуллары хакында да мисаллар китерә, Рәсәй крестьяннары һәм эшчеләренең авыр тормышын чагыштырып куеп, үзенең төп фикерен әйтә: «Тик капитализмны бетереп, фабрик-заводларны эшчеләр кулына, ә җирне крестьяннарга биргәндә генә алар ярлылык-хәерчелектән котыла алачаклар»,— дип сүзен йомгаклый. Менә шундый кыю чыгышлардан соң, «Яңа тормыш»ның санаулы көннәре башлана. Зур штрафлар белән генә чикләнеп калмыйча, газетаның алдагы берничә санына конфискация ясыйлар. Карагруһчылардан төрле янау хатлары килә. Озак та үтми, 1909 елның февраль аенда, губернатор фәрманы белән, «Яңа тормыш» та ябыла.

Бу хәл Камил Мотыйгый өчен аеруча зур югалту була. Ул үзендә ниндидер уңайсызлык, бушлык, чарасызлык сизә. Моңарчы шундый зур өметләр, ашкынулар белән яшәгән кешенең бу халәтен күзаллау авыр түгелдер. «Сәйяр» труппасы китеп барды. Хәзер инде яңа газета-журналлар чыгару, аларның нәшире яки мөхәррире булу турында уйлавы да кыен: рөхсәт бирелмәячәк.

Ныклап киңәшерлек дусларның да таралышкан чагы. Бердәнбер киңәшче — әтисе. Ул да, энисенең сүзенә кушылыптыр, иҗтимагый эшчәнлектән бераз читләшеп, онытылыбрак торырга, сүрелеп алырга өнди. Тик монысы инде Камилгә хас нәрсә түгел. Ул эшләргә, хәрәкәт итәргә, максатына таба туктаусыз барырга күнеккән. Ә максаты — халыкны уяту, аның күңеленә өмет орлыклары салу, ирекка һәм яктылыкка чакыру. Менә шуңа күрә дә, Мотыйгыйның эшчәнлеге кинәт кенә үзгәреп киткән, ул инде үз тормышын башка бер өлкәгә — сәхнәгә багышлаган икән, бу — һич тә «баткан кешенең саламга ябышуы» түгел, ә бәлки һәр мөмкинлекне халыкка хезмәт итүгә файдалану.

## 8

Камил Мотыйгый башта, чыннан да, яңа газета чыгару нияте белән яши, һаман да өметен өзми. Әмма аның һәрбер омтылышы кискен каршылыкка очрый, нәтиҗәсез кала. Ул инде яңадан мөгаллимлек эшенә тотынырга мәҗбүр була. Үзенә хас бер колач белән дәртләнеп, ир һәм кыз балалар өчен мәктәпләр ачып җибәрә, әти-әнисе белән берлектә шул мәктәпләрдә укыта башлый. Тик хәзер инде

аны элекке еллардагы кебек «коры мөгаллимлек» эше генә канәгатьләндерә алмый: мәктәпләрдә әдәби-музыкаль кичәләр оештырыла, Камил Мотыйгый аларның башлап йөрүчесе була.

Мотыйгулла хәзрәтнең гаиләсендә балаларга музыкаль тәрбия бирү игътибар үзәгендә булганлыгын да искә алырга кирәк. Өйдә алган әнә шул тәрбия, үзе оештырган мәктәпләрдәге җырлы-биюле кичәләр Камилдә яңа бер теләк — татар концертлары оештыру теләген уята. Тагын шунысы да бар: «Сәйяр» труппасының чыгышлары Җаекта зур уңыш белән узган, Камил Мотыйгый алар белән ныклап аралашып калган иде бит.

Күп тә үтми, Камил Мотыйгый концерт программасын төзи һәм, концерт куярга рөхсәт бирүләрен сорап, шәһәр властьларына мөрәҗәгать итә. Аның бу үтенечен кире кагалар. Алга куйган максатыннан тиз генә чигенергә күнекмәгән Мотыйгый бу каршылыктан югалып калмый: якыннары һәм дус-ишләре белән кызлар мәктәбе бинасында берничә концерт оештыра.

Мөгаен, кулыннан матбугат мөмкинлекләре тартып алынганнан соң ул беренче мәртәбә иркен сулыш алып куйгандыр: үз максатында ул җыр сәнгатен яңа корал итеп файдалана ала икән ләбаса! Күңел төшенкелегенә бирелә язган кеше өчен бу инде күк капусы ачылган кебек була. Әйе, халык белән җыр һәм музыка ярдәмендә аңлашырга, сөйләшергә, аралашырга, йоклап яткан хисләрне, йокымсыраган омтылышларны уятырга!

Әлбәттә, Камил Мотыйгый кулында җырның да көчле корал булуын аның дошманнары яхшы төшенә. 1908-09 еллар кышында аның тормышына куркыныч янаган вакытлар шактый. Ниһаять, губернаторның Камил Мотыйгыйны Себергә сөрергә хәл кылуы турындагы хәбәр килеп ишетелә. Аның өчен бердәнбер котылу юлы — шәһәрдән чыгып качу.

1909 елның январенда ул Саратов шәһәренә күчеп китә. Татар концертлары оештыруны һәм сәхнәгә юл салуны максат итеп куйган Мотыйгый монда Саратов консерваториясенең танылган профессоры Рудольф белән киңәшә. Алар моннан бер ел элек танышкан булалар. Профессорның бертуган энесе адвокат Рудольфның Мотыйгыйны суд барышында яклавын алдарак әйтеп үткән идек инде. Ул чакта Мотыйгый Рудольфлар йортында берничә тапкыр була һәм бу туганнарның өлкәне белән дә якыннан аралашып-танышып кала. Әле шул чакта ук, Камилнең җырлавын тыңлаганнан соң, профессор Рудольф аның тавышын ошата, аның җырга-моңга сәләте барлыгын әйткән була. Профессор бу юлы да Мотыйгыйга битараф калмый, киресенчә, аның Саратовта татар концерты куярга теләвен хуплап каршы ала. Үзе үк оештыру эшләрен дә башлап җибәрә.

Рудольф үзе өчен яңа булган бу эш белән башка фикердәшләрен дә кызыксындыра. Профессор, алар ярдәме белән, Камил Мотыйгый репертуарындагы егермедән артык җырны нотага язып ала, гармониялəштерә. Камилгә үз җырларының бер өлешен консерватория студентлары оркестрына кушылып башкарырга тәкъдим итәләр. Камил Мотыйгый дүрт ай дәвамында профессор Рудольфтан дәресләр ала, күренекле музыкантлар белән аралаша.

Ниһаять, көтелгән көн килеп җитә. Шәһәр урамнарына эленгән игъланнар Саратов консерваториясендә беренче татар концерты булачагы турында хәбәр итә. Ләкин... Бу юлы да концерт булмый кала. Полицмейстер үзенең элек биргән рөхсәтен гамәлдән чыгара һәм моны, имештер, ислам дине кануннарының концертлар куярга рөхсәт итмәве белән аңлата. Профессор Рудольф һәм аның хезмәттәшләре, Камил Мотыйгыйны яклап, яңадан да властьларга мөрәҗәгать итеп карыйлар. Тик бу юлы да каршылыкка, алга куелган киртәгә очрыйлар.

Полицмейстерның тыю кәгазен консерваториядә концерт башланыр алдыннан гына китереп бирәләр.

Икенче көнне консерватория җитәкчелеге студентлар өчен көндез бушлай концерт оештыра. Камил үзе ияртеп килгән берничә кешедән кала, залда татарлар бөтенләй булмый диярлек. Шуңа да карамастан, аның концерты уңышлы уза, шушы беренче концерт Камилне рухландырып җибәрә.

Бу вакыйгадан соң шәһәрнең алдынгы карашлы татар яшьләре аның җырлавын тыңларга теләк белдерә. Ул да түгел, Миргали Курамшин йортында, тар даирә өчен генә, бер концерт бирелә. Халыктан җыелган йөз сум керем Мотыйгыйның акча ягын, аз гына булса да, яхшыртырга мөмкинлек бирә. Чөнки, профессор Рудольфның эчкерсез ярдәменә карамастан, аның инде матди хәле шактый мөшкелләнгән була.

Саратовтан соң Камил туп-туры Казанга юл тота. «Сәйяр» труппасы оешкан һәм үзенең спектакльләрен даими куеп килгән шәһәрдә, татар халкының милли мәркәзендә концертка рөхсәт алу да җиңелрәк булыр, дип өметләнә ул.

Әмма, полицмейстер һәм губернатор янына керергә рөхсәт ала алса да, аңа монда да кире җавап ишетергә туры килә. Сәбәбе дә, Саратовтагы шикелле үк, бер генә һәм аның асылына төшенү әллә ни кыен түгел: Җаекта чыгып килгән газета-журналлар Казанда да шактый гауга кубарган була. Мотыйгыйның шул басмалар аша бик тә яхшы таныш исеме Казан властьларын шиккә сала.

«Сәйяр» труппасы һәм Габдулла Кариев исә Камилне шатланып каршы ала һәм театрга чакыра.

Казандагы мәдәни тормыш, Тукай белән, Галиәскәр Камал белән очрашып сөйләшүләр, Габдулла Кариевнең һәрдаим булышлыгы, рухи ярдәме Мотыйгыйга яңадан канат куя. Хәер, бу дүрт шәхеснең һәркайсы авыр реакция елларында берберенең җылы сүзенә, ярдәменә һәм фикер куәтенә мохтаҗ булгандыр.

Г. Тукай, Г. Камал һәм Г. Кариев концертлар оештыру өчен рөхсәт алырга берничә тапкыр талпынып карыйлар. Ләкин, күпме генә йөрмәсеннәр, властьларның җавабы катгый һәм бер төрле генә: юк! Ярамый!

Мәсьәлә бөтенләй котмәгәндә хәл ителә. Моның сәбәпчесе — моңа кадәр билгесез бер приказчик Садыйк Әпсәләмов. Камил аның белән «Сәйяр» труппасында эшләгән вакытында танышкан. Ул «Сәйяр»ның рекламаларын таратуда, билетларын сатуда гел булышып килә. Нәкъ менә ул беренче концертларны Сембердә оештырып карарга киңәш итә һәм моңа бәйле барлык мәшәкатьләрне үз өстенә ала. Әпсәләмов анда бу эшкә тегермән хуҗасы Шиһап Иосыповны тарта. Игъланнарда Иосыпов имзасын күргән карагруһчылар, власть вәкилләре эндәшергә дә өлгерми калалар.

Шулай итеп, беренче тулаеле татар концерты 1909 елның 16 июлендә Сембер шәһәренең приказчиклар клубында уадырыла. Ләкин, ни гаҗәп, концертның шаулап узуына һәм зур уңыш белән үтүенә карамастан, Шиһап Иосыпов икенче тамашаны оештырудан баш тарта.

— Концерт программаң бу кадәр дә начар булыр һәм начальствога бу кадәр дә ошамас дип уйламаган идем,— ди ул, икенче концерт турында сөйләшергә килгән Мотыйгыйга.— Әгәр болай буласын белсәм, бу эш өчен ике аягымның берсен дә атламаган булыр идем.

Болай кисәк үзгәрүенең серен барысы да яхшы аңлый, әлбәттә: политик сәбәпләр янә баш калкыта.

Ләкин җырчы тиз генә бирешергә җыенмый. Шәһәр яшьләре концертны кабатлау турында үтенеч белән килгәч, ул аларны Зөя елгасы буена чакыра һәм шәһәр читендә яшерен концерт куярга карар кыла.

Сембердән соң Камил Мотыйгый Нижнийга юнәлә. Бу хакта инде Г. Кариев белән сөйләшенгән-киңәшенгән була. Мәкәрҗә ярминкәсендә, гадәттә, Рәсәйнең барлык якларыннан, чит илләрдән, аеруча шәрык илләреннән сәүдәгәрләр җыела. Халык монда сәүдә өчен генә түгел, күңел ачу өчен дә килә. Табигый ки, күпчелек театрлар һәм мәшһүр артистлар Нижнийдагы гастрольләрен шушы ярминкә көннәренә туры китерә, эшкуарлар арасында көндәшлек китереп чыгара; кайчак кайбер театрлар һәм артистлар «кычкырып яна». Бары тик «Сәйяр» генә көндәшлектән өстен: чөнки ул бердәнбер татар труппасы һәм аның тамашачылары да башка.

Мәкәрҗәдә Мотыйгый янә «Сәйяр» труппасында чыгыш ясый һәм, мондагы хәлне җентекләп өйрәнгәннән соң, үзе аерым концерт бирергә уйлый. Тамашачы өчен борчыласы юк, мөселманнар монда үзләрен иркен хис итәләр. Идел буе, Урал, Себер, Урта Азия сәүдәгәрләре өчен Мәкәрҗә ярминкәсе — елга бер очрашу, аралашу урыны. Анда катнашу — һәр сәүдәгәрнең горурлыгы, мин-минлеге, алыш-биреш мәйданы.

Татар концерты «Бразилия театры» дип аталган зур бинада уза. Бу юлы рөхсәт алу чагыштырмача җиңел була. Саратовта, Сембердә чыгарылган басма игъланнар да үз тәэсирен ясамый калмаган, әлбәттә. Ләкин шул ук вакытта программа җентекләп тикшерелә, концерт чыгышларының байтагы сызып ташлана.

Уңыш көтелгәннән дә яхшырак булып чыга. Концертка керергә теләүчеләр шулкадәр күп, алар фойеда, коридорда, урамда басып торган килеш тә тыңларга риза. Алыпсатарлар моны, әлбәттә, үз файдаларына җайлап калырга ашыга. Татар концерты билетлары алар кулында берничә бәягә кыйммәт йөри. Артистның үз шәхесе дә концерт белән кызыксынуны арттыра: берничә ел элек кенә язучы, мөхәррир һәм матбагачы булып танылган кешене үз күзләре белән күреп калырга теләүчеләр күп була.

Камил Мотыйгый урнашкан кунакханәгә килеп рәхмәт әйтүчеләр өзелеп тормый. Аларның һәркайсы үз ягына чакыра, булышырга вәгъдә итә. Мәкәрҗәгә килгән сәүдәгәрләргә ияреп, татар концертлары турындагы хәбәрләр Рәсәйнең бөтен почмакларына тарала.

Революциягә кадәрге шул сигез ел эчендә Камил Мотыйгый гаять зур империяне аркылыга-буйга йөреп чыга. Татар халкы күпләп урнашкан шәһәрләрдә генә ту-

гел, хәтта зуррак авылларда да концертлар куя. Халык телендәге аның «моңлы җырлар патшасы» дигән исеме тарала, куйган концертларының саны 1500 дән артып китә.

Камил Мотыйгый концертларының ни рәвешле һәм нәрсә бәрабәренә узуын аңлар өчен, һәрбер урында диярлек килеп чыккан каршылыкларны, төрле гаугаларны, карагруһчыларның котырынуын, властьларның һәрдаим тыкшынып торуын, реакция елларын күзаллый белергә кирәк.

Соңрак, татар халкының үзаңы уяна барган саен, Камил Мотыйгыйның тавышы да күтәренкерәк рух ала башлый. Моңарчы ул концертларда җырлап, шул җыр аша халыкка тәэсир итәргә тырышып, җыр араларында шигырь сүзләре кыстырып, кинаяле сүзләр аша эш итсә, хәзер инде иркенрәк сулыш ала, колачлырак хәрәкәтләр ясый. Теге яки бу шәһәргә гел көтмәгәндә генә килеп төшә, алдынгы карашлы татарлар белән бәйләнешкә керә, оештыра, туплый. Әмма ул һаман да күзәтү астында, аның һәр сәфәрен, һәр концертын «сизгер колаклар» ишетеп-тыңлап тора. Мәсәлән, Петербургта ул хәтта үзенең концерт программасын да тәмамлый алмый кала: полиция килүе турында хәбәр алынуга ук, сәхнәдән чыгып югала һәм шул ук төнне шәһәрне ташлап китә. Бу юлы ул саклык чараларын онытып җибәргән, цензура тарафыннан тыелган һәм гадәттә концерт азагында гына башкара торган җырларын башта ук җырлап җибәргән икән. Ә залда, димәк, полициягә хәбәр бирүчеләр дә табылган. Бу вакыйга танылган журналист Кәбир Бәкернең «Кара тап» исемле китабында («Юл» матбагасының 43 нче китабы, 1912 ел) бик ачык һәм гыйбрәтле итеп сурәтләнә. Кемгәдер ришвәт бирү яки штраф түләү аркасында гына котылып калу очраклары Камил Мотыйгыйның артистлык юлында санап бетергесез.

Камил Мотыйгыйның концерт репертуарында Тукай әсәрләре аеруча зур урын били. Шагыйрь әсәрләренә көйне ул еш кына үзе сайлап ала, кирәк икән — укып, кирәк икән җырлап җибәрә. Тукай шигырьләре сәхнәдән яңгырый, юата, уйлата, кемнәрнедер утлы табага бастыра. Әйтик, «Тотса мәскәүләр якаң» дигән әсәрне Мотыйгый «Краковяк» көенә башкара һәм шулкадәр үтергеч сатира тудыра ки, хәтта кайбер капкорсак сәүдәгәрләрнең, җырда үз-үзләрен танып, залдан ук чыгып киткән чаклары була.

Ярлы, фәкыйрь, мескен тормышта яшәүче татар хатын-кызлары язмышы да аның концертларында төп бер тема булып тора. «Корсын, балам, бу кала», «Кызлар хәле», Тукай сүзләренә җырлана торган «Эштән чыгарылган татар кызына» кебек җырларны тыңлаган халыкның йөрәге ирек һәм гаделлек сусап сулкылдамый кала аламыни?!

## 9

Камил Мотыйгый — профессиональ композитор түгел. Ләкин, әйтеп үткәнемчә, аңа үз концерт программаларын үзенә төзергә, шигъри әсәрләргә төрле көйләр табарга туры килгән. Барлык шигырьләрне дә халык көйләре кысасына гына сыйдырып бетерү мөмкин түгел. Хәер, алай итсәң, жанр төрлелегенә дә зыян килүе бар. Менә шул рәвешле эзләнгәндә Мотыйгый үзе үк көйләр чыгару эшенә дә керешә.

Габдулла Тукай сүзләренә язылган «Пар ат» җырын аның иҗади табышы дип санарга мөмкин. Бераз соңрак аның әсәрләрен башка җырчылар үз репертуарына кертә. Ләкин Мотыйгыйны иң канатландырганы — яңа концертлар, аны аңлаган, аның тавышын яраткан яңа тамашачылар. Әнисенең табигый мирасы булып күчкән кыяфәте, ирләрчә матурлыгы, озын буйлы төз гәүдәсе, куе кара чәчләре, эчке бер җылылык бөркеп балкыган көрән-коңгырт күзләре, моңлы тавышы белән ул күпләрне әсир итә. Өстендәге киемнәрнең ятышлылыгы, сәхнәдә үзен иркен һәм табигый тотуы да тәэсир итә, әлбәттә. Замандашлары күңелендә ул әнә шундый мәһабәт бер шәхес булып калган.

Мотыйгый үзенең туган шәһәре Җаекка да кайтып килә. Әти-әнисе инде шактый олыгайган, картайган. Алар белән, энеләре-сеңелләре белән һәм үзенең дүрт баласы белән бергә гаиләдә унбиш кеше. Аларның һәрберсе игътибар сорый, кайгыртуга мохтаҗ.

Камил өйгә кайтып керү белән, гомергә истә калырдай бәхетле көннәр башлана. Ул зур шәһәрләрнең сулышын, әллә нинди баш җитмәс яңалыклар алып кайта. Зур сәхнәләр, атаклы кешеләр турында сөйли, үзе күргән вакыйгалар, полицмейстер һәм городовойлар белән бәрелеш-тарткалаш хәлләрен кәмит бер хәл итеп сөйләп көлдерә. Әлеге хәлләрдән эчләре катып көлгән балаларга инде өйдәге эшләр дә, башка кыенлыклар да җиңелрәк тоела.

Камил кайтса, өйдә концертлар башлана. Монда шулай: кем нинди һөнәр күрсәтә ала — башкарырга тиеш! Шулай булмыйни, янәшәдә зур, танылган артист бәя биреп тора, өйрәтә ич! Әгәр бу нигездән киләчәктә татар сәнгатенең күренекле эш-

лекләләре Галия Кайбицкая (Камилнең бертуган сеңлесе, Татарстанның халык артисткасы) һәм Әдһәм Кайбицкий (Камилнең бертуган энесе, танылган артист һәм режиссер) дөньяга чыккан икән, монда инде аларга, һичшиксез, Камилнең тәэсире һәм иҗат йогынтысы булган.

Моңарчы Камил Мотыйгыйга туган шәһәрендә концерт бирү тыелып килгән иде бит әле. Ниһаять, 1913 елны, инде бөтен Рәсәйгә танылгач, Җаек халкына аның концертын карарга насыйп була.

Концерт зур кунакханә залында үтә. Биш йөз кешелек урын шыгрым тулы. Аяк өсте басып торучылар арткы мәйданчыкларга кереп кысылган. Залга сыймаган халык, кичнең җылы булуыннан файдаланып, җырны урамда килеш тыңлый.

Залда урыслар да байтак. Элеккеге «Уралец» типографиясе эшчеләре дә берничә рәт булып тезелгән. Халык шулкадәр күп булуга карамастан, залда тәртип һәм тынлык. Бу кичне Камил тырыша: әйтерсең, ул бүген элек җырлый алмый калган чаклары өчен дә хак кайтара, якташларына күңел җылысын бөтен барлыгы белән биреп калдырырга тели. Бу концертта ул иллегә якын җыр башкара. Ә инде шул җырларның унсигезен халыкның яңадан сорап алуын искәрсәк, тыңлаучыларның җырга никадәр сусаган булуын да, концертның ни дәрәҗәдә уңыш казануын да күзаллый алырбыз.

Концерт төн уртасында гына тәмамлана. Шулчак сәхнәгә укытучы һәм революционер Кыям Юлдашев күтәрелә, залдагы халык исеменнән, дип, шигырь белән язылган котлау сүзен укый. Халык гөрли, халык кул чаба. «Моңнар патшасы!», «Җырчы әләм!», «Татар Шаляпины!» кебек алкышлы сүзләр яңгырый. Күңеле тулган Камил артык түзә алмый, яшьләнгән күзләрен, дулкынланган халәтен күрсәтмәс өчен, тиз-тиз атлап, сәхнәдән чыгып югала. Ул сәхнәдән чыккач та, халык әле шактый таралышмый тора, ә инде җырчыны өенә кадәр озата киткән төркем-төркем яшьләр үзенә күрә бер манифестация хасил итәләр.

Икенче көнне концертны кабатлау турында сүз кузгаткан Мотыйгый һәм аның дуслары шундый җавап ала: концерт катгый рәвештә тыела!

Ләкин ни генә булмасын, нинди генә кыенлыклар һәм авырлыклар кичерергә туры килмәсен, Камил Мотыйгый инде халык арасында танылган җырчы булып өлгерә, аның исеме татарлар яшәгән барлык төбәкләргә тарала. Ул йөргән яклардагы газеталарның бәһа сүзе, аның концертларына карата язылган төрле-төрле мәкаләләр, аның үз исеменә атап килгән котлау язулары, төрле багышлаулар — болар барысы да Камил Мотыйгый иҗатының танылуы хакында сөйли. Шул ук вакытта татар сәхнәсенә яңадан-яңа көчләр килүен дә истән чыгармаска кирәк. Алар арасыннан иң күренеклеләрен санап китик дисәк, без инде Фәттах Латыйпов, Мирфәиз Бабаҗанов, Мәрьям Искәндәрова, Хәсән Йосыпов, Фатыйма Гомәрова кебек шәхесләрне искә алырга тиешбез. Аларның да иҗат юллары авыр, шәхси тормышлары фаҗигале. Алар да тормыш михнәтләреннән өстен кала белгәннәр, иҗатларын халыкка хезмәт итүгә багышлап, шушы юлда янып-көеп яшәүне артыграк күргәннәр.

## 10

1917 елгы вакыйгалар, революция көннәре Камил Мотыйгыйның тормышына да катлаулы, бүгенге көн күзлегеннән караганда шактый каршылыклы булып тоелган үзгәрешләр кертә. Әгәр аның ул еллардагы эшчәнлеген ныклап күзәтсәң, шуны яхшы күрәсең: Камил Мотыйгый революциягә чын йөрәгеннән ышанган, ул алып киләчәк яңалыкларга чиксез зур өмет белән караган. Бу өмет, әлбәттә, татар халкы язмышына турыдан-туры бәйле булган.

Нәкъ менә шул өмет аны революция дулкыннарында кайната, гражданнар сугышының иң кайнар төбәкләренә илтеп кертә.

Әле 1917 елда ук Мотыйгый Смольныйда Ленинның җир, солых турындагы декретларын, Россия һәм Шәрык хезмәт ияләре-мөселманнарына мөрәҗәгатен тәрҗемә итә. Смольныйда татар телендә чыккан беренче совет газетасы «Ярлы халык»ның редакторы була. 1919 елгы легендар мөселман полкы һәм Чапай дивизиясенең кыргыз бригадасы отып алган һәм яратып җырлаган «Алга, иптәшләр!» дигән җырның көен дә, сүзләрен дә ул үзе иҗат итә.

Октябрь революциясеннән соң ул, нигездә, дүрт шәһәрдә — Петроградта, Самарада, Җаекта һәм Казанда эшли. Самарага ул 1918 елның март аенда гаиләсе белән килә, губревком каршындагы мөселман комиссариатының матбугат комиссары итеп билгеләнә, бер үк вакытта комиссариатның «Киңәш» газетасы редакторы да була. Газетаның беренче саны 8 майда чыга. Ә бу көннәр, май аеның хәвефле көннәре, ак чехларның Самарага һөҗүм иткән чагына туры килә. Камил Мотыйгый, каләмен штыкка

алыштырып, коммунистик дружинага языла. Аның белән бергә, әле унбиш яше генә тулып килгән улы Хәмит тә сугышка керә.

Аклар Самараны, зур көчләр белән һөҗүм итеп, бик тиз арада яулап алалар. Шәһәр башлыклары, шул исәптән В. В. Куйбышев та, ике пароходка төялеп, Иделнең югары ягына таба китеп өлгерәләр. Самара коммунистларының байтагы урам сугышларында һәлак була. Исән калганнары исә шәһәрдә яшеренәләр. Алар белән бергә калган Камил Мотыйгый үз янына яшерен бер төркем туплый, фронт аша элемтә көйләп, ак гаскәрләрнең хәрәкәте турында хәбәрләр җибәреп тора. Самарадан аклар куылгач, аның бу эшчәнлегенә татар коммунистларының гомуми шәһәр җыенында зур бәя бирелә.

Камил Мотыйгый Самарада мөселман комиссариатының эшен яңадан торгызуны башлап җибәрә, шул комиссариатның коллегия әгъзасы һәм «Яңа көч» газетасының редакторы була.

1918 елны, яшь Совет дәүләте төрле яктан чолганып алынган бер вакытта, Җаек ягының казачий гаскәре Саратовка һәм аннан соң Мәскәүгә бәреп керергә план кора. Бу уңайдан фронтка ярдәм итү һәм андагы көчләрне ныгыту мәсьәләсе Революцион хәрби совет тарафыннан махсус карала. Партиянең Үзәк Комитеты үзенең барлык оешмаларына хат белән мөрәҗәгать итә. Әлеге хатта иң беренче чиратта шушы якларда туып үскән, җирле халыкларның телен, гореф-гадәтен белгән абруйлы коммунистларны шушы фронтка җибәрергә тәкъдим ителә.

Бу хат Самара коммунистларының гомуми җыелышында укыла. Үз теләкләре белән фронтка китәргә теләк белдергән татарлар арасында Камил Мотыйгый һәм аның улы Хәмит тә була.

1919 елның февраль аенда, акларны куып барган Чапай дивизиясе белән бергә, Камил Мотыйгый туган шәһәренә — Җаекка кайтып керә.

Беренче эш итеп ул монда партиянең шәһәр комитеты каршында мөселман коммунистлары секциясен оештыра һәм аның рәисе итеп сайлана. Шул ук вакытта ул губревком карамагындагы милләтләр бүлегенең коллегия әгъзасы булып сайлана һәм ревкомның татар бүлегенә мөдир итеп билгеләнә. Шушы бүлек эшли башлау белән, Камил Мотыйгый татар телендә газета чыгаруны юлга сала. «Ихтилал байрагы» дип аталган бу газета казах, татар сугышчылары арасында бик популяр була.

Камил Мотыйгыйның бу вакытлардагы төрледән-төрле эшләрен санап чыгу да мөмкин түгел. Әйтик, 197 нче мөселман полкы ак казаклар белән сугышудан баш тарткач, шәһәр комитеты полкта аңлату эше алып бару өчен махсус бер төркем төзи һәм аның җитәкчесе итеп Камил Мотыйгыйны билгели. Күп тә үтми, полк фронтка китә. Ул да түгел, Чапай дивизиясенең Уфа фронтына күчерелүеннән файдаланган ак казаклар һөҗүмне яңарталар һәм яңадан Җаекка килеп җитәләр. Бу хәлнең җитди сәбәпләреннән берсе итеп разведка эшенең начар куелуын билгелиләр. Шуңа күрә, хәрби командованиенең соравы буенча, партиянең шәһәр комитеты мөселман секциясеннән фронтка егерме разведчик җибәрелә. Әлеге ирекләләр арасында Камил Мотыйгый һәм аның улы Хәмит тә була. Камил Мотыйгый армия разведкасы бүлегенең кушуы буенча берничә тапкыр дошман тылына чыга һәм кыйммәтле мәгълүматлар алып кайта. Аңа бу эштә артистлык осталыгы да шактый ярдәм итә.

Тиздән аны 4 нче армия политбүлеге карамагына җибәрәләр. Монда ул яңа төзелгән гаскәри берләшмәләрне фронтка озата, политбүлек инструкторы буларак, кызыл армия гаскәрләрен оештыру белән шөгыльләнә. Мәсәлән, Пугачев өязе яшьләреннән төзелгән ирекле Башкорт дивизиясе аның турыдан-туры катнашы белән төзелә.

Җаек aклардан икенче тапкыр азат ителгәндә Камил Мотыйгый туган шәһәренә шул дивизиянең сәяси юлбашчысы буларак кайта һәм ныгытылган Урал районының политбүлек инструкторы итеп билгеләнә. Монда да ул, иң беренче эшләрнең берсе итеп, татар телендәге газета чыгара башлый һәм аның исемен «Яңа фикер» дип атый.

Бераздан аны, губком һәм политбүлек кушуы буенча, әле генә аклардан арынган урыннарда советлар һәм аларның органнарын оештыру эшенә җибәрәләр. Мәсәлән, ул Бүкәйлек өлкәсенең I советлар съездында катнаша, аннан советларның бөтен Казахстан I оештыру съездына делегат итеп сайлана. Бу съезд аны Казахстанның беренче Үзәк Башкарма комитеты әгъзасы итеп сайлый.

Менә шундый бер вакытта, үзенең эшчәнлеге үсә барган һәм бу эшкә барлык көчен, талантын биргән бер заманда, Камил Мотыйгый гаять авыр хәлдә кала: Җаекка кайтуга, губком бюросы аны, башлангыч оешмада тикшереп-нитеп торусыз дигәндәй, партиядән чыгару турында карар игълан итә. Моның сәбәбе, имеш, шул: Мотыйгый күршесе Перепелкинны судка тикле порукага алып торган һәм шуның өчен аңа ришвәт бирелгән. Имзасыз шикаятькә корылган бу яла, суд карары белән, Камил Мотыйгыйдан алына, әмма аны партия сафында торгызу мәсьәләсе хәл ителми. Әлбәттә, тиздән партиянең үз эчендә башланачак көрәшне һәм аның бүгенге көндә билгеле аяныч

нәтиҗәләрен күз алдыбызга китерсәк, Камил Мотыйгый язмышындагы бу кискен борылышның сәбәпләрен тирәнрәк аңларбыз. Ә ул вакытта бу гаделсезлек Мотыйгыйны тирән кайгыга сала. Җитмәсә, Җаекта аның турында төрле гайбәтләр тарала, дошманнары аның бу авыр хәленнән бик оста файдаланалар. Бу шәһәрдә торырлык хәле калмаганлыктан, үзенең иҗади мөмкинлекләренә һәм дусларына ышанып, Камил Мотыйгый Казанга килә.

11

Казанда ул журналистлык эшен дәвам итә, «Гажур» матбагасында консультант булып эшли, Халык мәгарифе комиссариатында тәрҗемәче хезмәтен башкара, радио аша чыгышлар ясый, авылларда концертлар куя. Ничәмә еллар өзлексез күченеп йөргәннән соң, ниһаять, беренче тапкыр аңа гаиләсе белән бергә урнашып яшәү мөмкинлеге туа.

Партия сафларында тору-тормау мәсьәләсе, үзенә карата кулланылган гаделсезлек Мотыйгыйны һәрдаим борчый, әлбәттә. Ниһаять, 1924 елны аңа партиянең Үзәк Комитетыннан җавап килә һәм анда Мотыйгыйга партиягә яңадан керергә тәкъдим ителә. Ул шул ук елны Халык мәгариф комиссариатының башлангыч партия оешмасына гариза яза, әлеге оешма аны партия сафына алу турында карар чыгара. Ләкин район комитеты бу карарны кире кайтара: райком фикеренчә, гариза Мотыйгыйның төп эш урынындагы оешмага язылырга тиеш, ә ул мәгариф комиссариатында өстәмә эш башкаручы сыйфатында хезмәт итә. «Гажур»ның башлангыч оешмасы Камил Мотыйгыйның гаризасына түбәндәгечә җавап бирә: «Иптәш Төхфәтуллин — җәмәгать эшләрендә, һичшиксез, күп хезмәтләр куйган кеше, әмма хәзерге шартларда иптәш Төхфәтуллин, ВКП(б) әгъзасы буларак, таләп ителгән дәрәҗәдә файда китерә алмас, аны ВКП(б) сафларына алуны максатка яраксыз, дип исәпләргә һәм үтенечен кире кагарга».

Дуслары Камил Мотыйгыйның хәленә керергә, аңа ничек тә ярдәм итәргә тырышалар. Галиаскәр Камал, Кудашев-Ашказарский, Зәйни Солтанов, Гөлсем Болгарская, Касыйм Шамил, Хәлил Әбҗәлилов һәм башкалар Камил Мотыйгыйның сәхнә эшчәнлегенә егерме ел тулу көнен билгеләп үтү турында тәкъдим кертәләр. Юбилей кичәсе 1928 елның 21 маенда Татар дәүләт академия театры бинасында уза. Концертта Мотыйгый халык җырларын һәм, гадәтенчә, үзе иҗат иткән әсәрләрне башкара. Анда шулай ук Мотыйгыйның дуслары-хезмәттәшләре Фәттах Латыйпов, Фатыйма Гомәрова, Фәйзулла Туишев, Мөхәммәт Яушев, Салих Сәйдәшев, Солтан Габәши һәм башкалар катнаша.

Соңгы елларында Мотыйгый сәхнә әсәрләре язу эшенә ныклап керешә. «Тозак», «Шайтан өне», «Көрәш» кебек пьесалардан соң ул «Уйлап чыгаручы» исемле күләмле әсәргә тотына. Әмма бу әсәрен тәмамлый алмый кала.

Ул елларда илдә барган хәлләр, шәхес культының котырынуы, төрле тарафлардан ясалган һәм күрәләтә ягылган ялалар Камил Мотыйгыйны тынычлыкта калдырмый. Әйтерсең, кемдер аны әкренләп сафтан чыгарырга, юк итәргә тели.

Мәскәүдә Татар опера студиясенең директоры һәм П. И. Чайковский исемендәге дәүләт консерваториясе партоешмасының җаваплы секретаре булып эшләгән улы — Хәмит Төхфәтуллинның кулга алынуы турындагы хәбәр аны инде тагын да авыррак хәлләрдә калдыра. Шул ук 1937 елда Мотыйгыйны моңа кадәр алып килгән персональ пенсиясеннән дә мәхрүм итәләр.

1940 ел ахырында Камил Мотыйгыйга үз язмышындагы соңгы ачы касәне эчәргә туры килә: киләсе елның җәендә Мәскәүдә узарга тиешле зур бәйрәмдә — Татар сәнгате һәм әдәбияты декадасында катнашучылар арасына аның исемен дә кертмәгәннәр. Еллар дәвамында җыелып килгән әзәрлекләнүләр, гаепсезгә гаепләнүләр аша тулган әрну һәм рәнҗү касәсе тулып түгелә — Камил Мотыйгый үз-үзенә кул сала...

Бу адымын гадәттән тыш киеренке халәттә ясавын аның әле соңгы көнендә — 1941 елның 26 гыйнварында язып кул куйган кәгазьләреннән ачык күрергә мөмкин.

Бүгенге көндә, демократия һәм хәбәрдарлык турында җитди сүз алып барылганда, татар матбугаты һәм татар сәхнәсенең беренче карлыгачы булган Камил Мотыйгый кебек шәхесләрнең тормышын, язмышын һәм барлык эшчәнлеген ныклап өйрәнү — заман таләбе. Бу язмам — әнә шул зур эшкә, игелекле эшкә кечкенә генә булса да бер өлеш. Иң авыр елларда да рух сафлыгы өчен көрәшеп яшәгән уллырын онытмаган, аларны, еллар томаны һәм еллар тузаны аша булса да, эзләп-аралап таба алган халкыбыз киләчәккә өмет белән карый. Халкыбызны мин әнә шундый олы, зур халык, нык рухлы, нык хәтерле халык дип саныйм.

**Рафаэль Мостафин**

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ СОҢГЫ КӨННӘРЕ

*«Совет Татарстаны язучылары» исемле библиографик белешмәдә (Казан, 1986) атаклы язучы, галим, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның соңгы көннәре турында болай язылган:*

*«1927 елдан башлап Г. Ибраһимов көчәеп киткән үпкә авыруы аркасында Кырымда даими яшәргә мәҗбүр була. Авыруының торган саен җитди төс ала баруына карамастан, ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр әдәби һәм иҗат эшен дәвам итә. Г. Ибраһимов 1938 елның 21 гыйнварендә Казанда больницада вафат була».*

*Монда китерелгән мәгълүматлар барысы да чынбарлыкка туры килә килүен. Ә тулаем алганда исә — чеп-чи ялган...*

## Кулга алыну

Моннан берничә ел элек мин Галимҗан Ибраһимовның Ялтада яшәгән йортын эзләп тапкан идем. Үзәктән читтәрәк, тау итәгендә, шактый югарыда урнашкан ике катлы, зур тәрәзәле, иркен верандалы агач йорт... Баскыч-баскыч менә торган плитә тротуар буенда төз кипарислар шаулый... Йорт болай да тыныч, аз хәрәкәтле урамнан читтәрәк, аулак җирдә, тоташ яшеллек, үрмәле гөлләр, аксыл розалар, чем-кызыл гладиолуслар арасында урнашкан. Һавасы коры, татлы, сулыш алуы җиңел. Бер як тәрәзәләрдән офыкка хәтле җәелгән нурлы диңгез, икенче яктан зәңгәрсу томан белән өртелгән Ай-Петри тавы күренә.

Хәзер монда нинди дер санаторийның торак бүлмәләре... Көләч йөзле, кара тәнле ярым шәрә ирләр һәм хатын-кызлар йөренә... Музыка, җыр, көлү, кәрт сугу, савыт-саба шалтыраган тавышлар ишетелә...

Ә кайчандыр шушы иркен такта верандада җиңел камыш урындыклар, көрсиләр, ак ашъяулык ябылган түгәрәк өстәл, китап киштәләре торган. Бөек әдип моңсу тынлыкта карасу-яшел кипарисларга карап уйланып, язып яки укып утырган. Хатыны Хәдичә чыгып аңа дару каптырган, стакан белән су биргән, җил бәрмәсен дип, сөякчел җилкәләренә ак пинжәк элгән...

1937 елның 29 август көне дә шундый ук эссе, коры, чалт аяз булгандыр. Көннең иртәнге ягында йорт янына НКВД формасы кигән ике кеше килеп чыга. Берсе өске катка илтә торган текә баскыч алдында кала, икенчесе дворник, пүнәтәйләрне алырга дип китә. Бераздан өске катта гадәти булмаган ыгы-зыгы башлана: урыныннан кузгатылган авыр шкафлар, идәнгә гөрселдәтеп ташланган китаплар, елаган, борчылып пышылдашкан тавышлар ишетелә, ярылган мендәр-түшәкләрдән ак мамык оча... Якын-тирәдә яшәүчеләр арасында: «Йортның өске катында яшәүче атаклы татар язучысы халык дошманы булган икән, Сталинның үзенә каршы яшерен оешма төзегән, имеш»,— дигән гайбәтләр тарала... Имештер, төннәр буе утырып ул советка каршы өндәмә-прокламацияләр язган, аларны машинкада баскан һәм халык арасында тараткан... Имештер, кеше күзенә күренми кереп-чыгып йөрер өчен йорты астында җир асты юлы казылган... һ. б. һ. б...

Әлбәттә, Г. Ибраһимовны якыннан белгәннәр мондый имеш-мимешләргә көлеп кенә карый. Бер үпкәсе генә калган, анысында да тавык йомыркасы хәтле куыш булган, күкрәгеннән резин көпшә аша туктаусыз «чир» тамып торган хәлсез кеше нәрсә майтара алсын? Хәтта бик теләсә дә... Ләкин ышанучылар да табыла... Әдип күршеләренең истәлекләрен, күп еллар үткәч, язучы М. Мәһдиев язып ала.[1]

[1] М. Мәһдиев. Иректәге соңгы көн. «Социалистик Татарстан», 1989 ел, 30 апрель.

Төш вакытларында гадәттәге тәртип буенча Г. Ибраһимов янына аны дәвалаучы врач Зәминә Мостафовна Дагҗи килә. Ләкин аны авыру янына кертмиләр, хәтта эренле бинтларны алмаштырып бәйләргә дә рөхсәт итмиләр. Язучының кулга алынуын белгәч, врач үзенчә протест белдереп карый: «Авыруны урыныннан кузгатырга ярамый, һава алмаштыру аның өчен үлем белән бер»,— дип кисәтә. Ләкин аның сүзләренә колак салучы булмый.

Г. Ибраһимовның гаепләү кәгазьләре арасында медицина белешмәсе саклана. Ул Ялта табиплары тарафыннан (имзалары танырлык түгел) 1937 елның 30 августында язылып бирелгән. Монда Г. Ибраһимовның диагнозы — «үпкә һәм бөер туберкулезы» һәм шул вакыттагы хәле — «үпкәсендә ачык процесс, авыру кан йөткерә, төкерегендә туберкулез таякчыклары табылды», дип күрсәтелгән. Димәк, НКВД хезмәткәрләре авыруның хәлен күз алдына китермәгәннәр, дип әйтергә нигез юк.

З. М. Дагҗи сүзләренә караганда, яңа гына илле яшьлек юбилеен үткәргән язучы — әлеге фаҗига булмаса — шактый еллар яши алыр иде әле. 1936 елда үткәрелгән операциядән соң аның хәле бераз яхшыра: үпкә ярасының шешe кайта төшә, эрен азая, температурасы нормальләшә, үзе күзгә күренеп тазара башлый...

Сүз уңаенда З. М. Дагҗи истәлекләрендә булган бер төгәлсезлекне дә күрсәтеп китәргә кирәк. «Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр» китабында (Казан, 1966, төзүчесе — А. Шамов) басылган язмасында ул, язучыны 29 сентябрьдә кулга алдылар, дип яза. Соңгы елларда төрле архивлардан табылган документлар бу вакыйганың 1937 елның 29 августында булганын ачыклады. Шул ук архив документлары нигезендә язучының нәрсәдә гаепләнүе дә билгеле булды.

## Гаепләү акты

Юстиция капитаны, Татарстанның Дәүләт иминлеге комитеты өлкән тикшерүчесе И. В. Селивановский кул куйган белешмәдә болай диелә:

*«Ибрагимов Г. Г. татарский писатель, член ВКП(б), был арестован в г. Ялте, где находился на излечении, 29 августа 1937 года органами НКВД ТАССР.*

*В ходе следствия Ибрагимову Г. Г. было предъявлено обвинение в том, что «он в 1920 году примкнул к контрреволюционной националистической группе так называемых «левых» в татарской партийной организации, а в 1925 году с определенной частью этой группы вошел в контрреволюционную националистическую организацию, в которой играл роль одного из руководителей, проводил практическую контрреволюционную работу на культурно-идеологическом фронте», то есть в совершении преступлений, предусмотренных ст. ст. 50-10, ч. 1 и 58-II УК РСФСР».*

Күрәбез ки, бер җөмләдә «контрреволюция» сүзе өч мәртәбә кабатлана... Революция өчен җанын-тәнен биргән, патша чорыннан ук үзенең бөтен иҗатын һәм практик эшчәнлеген революциягә багышлаган, революциягә кадәр дә патша төрмәләрендә утырган, полиция күзәтүе астында яшәгән язучыны «контрреволюциядә» гаепләргә мөмкин ме? Һәр әсәреннән халык, милләт, эшче һәм крестьян сыйныфы мәнфәгатьләрен кайгырту, революцион идеалларга бирелгәнлек аңкып тора ич!

Утызынчы елларда «органнарда» эшләгән, хәзер пенсиядә яшәүче берәү (фамилиясен атарга рөхсәт итмәде) моны болай аңлатты. 1935—1936 елларда «троцкийчы-зиновьевчы-бухаринчы блок» «фаш ителгәч», Татарстанның НКВД органнары — әллә үз теләкләре белән, әллә өстән килгән күрсәтмә буенча (соңгысы дөреслеккә якынрак булса кирәк) бездә дә әлеге «оешманың» тармакларын эзлиләр. Төгәлрәк итеп әйткәндә, булмаганны булды, юкны бар, дип күрсәтергә ниятләнәләр. Мәскәүдәге зур дәүләт эшлеклерәнә тиң булырлык, республика күләмендә шулар дәрәҗәсендә тора алырлык иң зур, иң күренекле шәхесләрдән оешма «төзиләр». Алар арасында атаклы галимнәр, популяр язучылар, халык ихтирамын казанган сәнгать эшлеклеләре дә була. (Ф. Сәйфи-Казанлы, С. Атнагулов, С. Борһан, Г. Ризванов һ. б.).

Мөһәрләгән кешене эченә алган шушы «оешмага» җитди «идеолог» та кирәк була. Һәм бу вазифаны Ялтада берни белмичә үлем белән тартkalышып яткан Г. Ибраһимов өстенә «йөклиләр». Язучының кандидатурасы бөтен яктан да бик «кулай» була: беренчедән — чын мәгънәсендә зур фигура, исән чагында ук классик дәрәҗәсенә күтәрелгән язучы, ил күләмендә танылган атаклы галим, зур җәмәгать һәм дәүләт эшлек-

лесе... Икенчедән, кайчандыр сул эсер булган кеше. Билгеле булганча, башка партия әгъзаларын, бигрәк тә эсерларны Сталин берсен-бер калдырмыйча токымына кадәр үк юк итәргә куша. Өченчедән, заманында латин әлифбасын кертүгә каршы чыккан кеше. Димәк, «буржуаз-милләтче», «реакцион пантюркист».

Бу версияне күптән ишеткән булсам да, озак еллар буена аңа ышанмыйчарак йөргән идем. Ләкин ябык архивларда сакланган һәм соңгы вакытта җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим ителгән яңа документлар бу версияне тулысынча раслый. Әйтик, НКВД житәкчеләре тарафыннан 1937 елның 20 июлендә төзелгән Г. Ибраһимовның гаепләү акты нәкъ шул күзлектән язылган. Бу документ Татарстанның партия архивында саклана. Аның турында әдәбият белгече Ф. Ибраһимова «Татарстан яшьләре» газетасында язып чыккан иде инде. Шуңа күрә мин бу мәсьәләдә җентекләп тукталып тормыйм»[1].

Мәскәүнең Үзәк әдәбият һәм сәнгать архивында (ЦГАЛИ) тагын бер кызыклы документ сакланган. 1936 елның ахырларында — 1937 елның башларында Татарстанның партия өлкә комитеты тарафыннан Язучылар союзының эшен тикшерү буенча махсус комиссия төзелә. Аның башына өлкә комитеты хезмәткәре Төхфәт Имаметдинов куела. Нәкъ шушы комиссия карарлары нигезендә, Татарстан Язучылар союзы тар-мар ителә, тәмам җимерелә дә инде. Комиссия карарларындагы Г. Ибраһимовка ташланган гаепләр НКВДның гаепләү актыннан әллә ни аерылмый — бер үк кул белән язылган булуга охшый. Аерма тик шунда: әлеге карар, «халык дошманы», «эсер», «троцкийчы-бухаринчы» Г. Ибраһимовка «тагып» бик күп башкаларны да батыруга, юк итүгә юнәлдерелгән.

«Элеккеге эсерлар Октябрь революциясеннән соң даими рәвештә партия һәм совет хөкүмәтенең барлык эшләренә каршылык күрсәттеләр. Араларында иң абруйлы һәм башкаларга йогынты итүчән идеолог Галимҗан Ибраһимов булды. Ул үзенә алмашка тиешле кадрлар: Толымбайский, Г. Нигъмәти, К. Нәҗми, Г. Галиләрне әзерләде. Ә бу дүрт кеше, үз нәүбәтендә, тирәләренә Х. Туфан, Ф. Кәрим, Ишморатовларны тупладылар. Әлеге дүрт бәндә Г. Ибраһимовны беркайчан да тәнкыйть итмәде, гел мактап кына торды, кылган җинаятьләрен яшерде.

Югарыда саналган кешеләрнең барысы да Г. Ибраһимов белән киңәшеп, аңардан тиешле күрсәтмәләр алып торды, аны бердәнбер марксист дип санады. К. Нәҗми, мәсәлән, Г. Ибраһимовны революциягә кадәр үк марксист-тәнкыйтьче булган дип язды, гәрчә Г. Ибраһимовның «Пролетар әдәбияты турында» китабында Троцкий һәм Бухариннан өзекләр китерелгәнен белсә дә». (ЦГАЛИ, ф. 331, оп.6., ед. хр. 194, л. 68).

Иң аянычы шул: бу ялган документка кайбер язучылар да кул куйган. Әлбәттә, бүгенгесе көндә, җылы кабинетта утырган килеш, башкаларны гаепләү җиңел. Кыскаңнардыр... Чакыртып куркытканнардыр... Үзе турында уйламаса, балалары, хатыны, туган-тумачалары турында уйларга тиеш була... Әмма кул куючылар бер нәрсәне генә аңламыйлар. Башта әлеге кәгазьдә күрсәтелгән язучыларның барысын диярлек кулга алалар (Р. Ишмораттан тыш). Аннан соң инде, «икенче дулкын»да, кул куючыларның үзләрен дә җыеп-җыеп утыртып чыгалар.

## Габделхак Батталов истәлеге

Союз күләмендәге персональ пенсионер, карт коммунист Габделхак ага Батталов Г. Ибраһимов белән 1938 елның башында Пләтән төрмәсенең шифаханәсендә очраша.

Г. Батталов утызынчы елларда Бондюгта (хәзер Менделеевск) партия шәһәр комитетының икенче секретаре булып эшли. 1937 елның октябрендә җитәкче кадрларны тоташтан «себереп» кулга алулар барганда аны да кулга алалар, партиядән чыгаралар һәм Казанга китереп, Черек күл төрмәсенең ялгыз камерасына ябалар. Көн-төн сорау алулар башлана. Ләкин Батталов «каты чикләвек» булып чыга. «Гаебен» танымый, бер кешене дә атамый, бер кәгазьгә дә кул куймый. Тикшерүче чыгырыннан чыгып «физик алымнар» куллана башлагач, протест йөзеннән ачлык игълан итә. Башта моңа артык игътибар итүче булмый. Ашамыйсың икән, дөмек шунда, бик кирәгең бар, янәсе... Ләкин тәмам хәлдән таеп, үлем чигенә җиткәч, аңын югалта башлагач, аны

[1] Ф. Ибраһимова. Хөкем кәгазе. «Татарстан яшьләре». 1989 ел. 26 октябрь.

Плэтэн төрмәсенең шифаханәсенә илтәләр, резин көпшә аша тамагына су һәм шулпа салалар, көчләп диярлек үлемнән коткарып калалар. Аңына килгәндә ул үзен дүрт кешелек сигезенче номерлы палатада күрә. Акрынлап иптәшләре белән сөйләшә, утырып тора, аннан стенага тотынып йөри дә башлый...

Күпмедер вакыт үткәч, палатага Г. Ибраһимовны китереп салалар.

Г. Батталов аны язучы буларак та, кеше буларак та яхшы белә. «Безнең көннәр», «Тирән тамырлар», «Казакъ кызы» әсәрләрен йотлыгып укый. 1932—33 елларда Ялтада ялда булганда сөекле язучысы яшәгән йортны эзләп табып, Г. Ибраһимов янына кереп, озак кына сөйләшеп утыра. Соңыннан да әледән-әле кереп, аралашып, хәлен белеп тора.

Язучы ул вакытта да авыру, хәлсез була. Ләкин шул арада ул танымаслык үзгәрә: тагы да ябыга, алҗый, кечерәеп, ничектер кипшенеп кала, эчкә баткан күзләрендә моңсу-рәнҗү... Калку яңаклы озынча йөзе саргая, кан тамырлары күгәреп-калкып чыга. Ул зур авырлык белән, гыжлый-гыжлый тын ала, кайвакыт бер кәлимә сүз әйтерлек хәле булмый.

Шулай да алар бер-берсен танып, куанышып исәнләшәләр. Г. Батталов язучы янына килеп, сәгатьләр буена сөйләшеп утыра. (Г. Ибраһимов үзе исә ул вакытта аякка баса алмый.) Әдип әйтүенчә, моңа кадәр ул икенче номерлы палатада бер үзе яткан икән. НКВД хезмәткәрләреннән бик зарланган. Алар үзләрен бик тупас, дорфа тотканнар. Кулга алганда бөтен әйберләрен, кадерле кульязмаларын туагытып-ертып идәнгә ташлаганнар. Өйнең астын-өскә китереп, «җинаять дәлилләрен» эзләгәннәр. Таба алмагач, отыры узынганнар. Ахырдан шикле күренгән кульязмаларны әрҗәләргә тутырып, үзен носилкага салып, үзләре белән алып киткәннәр...

Казанга ничек килеп җитүен язучы ачык хәтерләми — аңын югалткан чагы туры килгән булса кирәк. Килеп җитү белән, сорау алулар башлана. Тикшеренүчеләр, язучының тикшерү беткәнче үк үлеп китү ихтималын истә тотып булса кирәк, асруча ашыгалар. «Телен чишү» өчен аерым җәзалар уйлап табу да кирәк булмый — янына врач кертмиләр. Һәм ул көчәеп киткән туберкулез авыруыннан җәфаланып, үпкәсендә җыелган үлеккә буылып, сасы бинтлар арасында кызышып ята. Ләкин үзенең «халык дошманы», «контрреволюцион оешма башлыгы», «милләтче пантюркист» булуын танымый.

Язучы булуын истә тотып, башта аның үзеннән «гаепләрен» яздырып карыйлар. Әмма кулына каләм алырлык хәле дә булмавын күргәч, үзләре язып бирәләр — кул гына куй, имеш. Г. Батталовка ул бу кәгазьдә нинди әшәке гайбәт-ялалар булуын сөйләгән... Хәтта аның әдәби әсәрләреннән дә гаеп тапканнар. Имештер, ни өчен аларда бер генә мәртәбә дә бөек Сталин исеме телгә алынмый? Әлбәттә, Г. Ибраһимов бу кәгазьгә кул куймый, «контрреволюцион оешмада булган» бер кешене дә атамый.

«Мин аның янында көннәр буе кызышкан сәякчел кулын тотып, су яки сыек баланда биреп, башка төрле ярдәм күрсәтеп утыра идем,— дип сөйли Габделхак ага.— Ике-өч көнгә бер врач килеп карап чыга иде. Ләкин кулында кирәкле дарулары, тиешле инструментлары булмаганлыктан, әллә ни файдасы тими иде. Авыруның хәле бераз яхшырган чакларда сөйләшкәләп ала идек. Сәламәтлеге чамадан тыш начар булса да, акылы аек, хәтере яхшы иде. Үзе турында кайгыртмый иде — мин барыбер үләчәк кеше, имеш. Иптәшләренең каефен бераз күтәрергә, күзләрен ачарга тырыша иде»,— ди.

— Бу хәлләр вакытлы фаҗига гына. Партия моны аңлар, берничә елдан булса да төзәтер... Син, Габделхак, яшь әле... Алай үз-үзеңне юк итәргә тырышма... Үлем ул болай да киләчәк, озак көттермәс... Шуны яхшы аңла: ун-унбиш-егерме ел үтәр, ләкин халыкка барыбер җиңәр. Син акланып иреккә чыгарсың. Минем турында дөреслекне дә халыкка җиткерерсең. Юк, мин халык дошманы түгел. Беркайчан да хаин булмадым. Үлгәндә дә большевик булып үләм...

«Бу сүзләрне ул ышанып, чын күңелдән әйтә иде»,— дип сөйли Г. Батталов.

Г. Ибраһимов Г. Батталовка бер атаклы язучы турында бик рәнҗеп сөйләгән. Минем өстән НКВДга шул шикаять язган. Сорау алганда да гел аның ялясына таяндылар, дигән. Хәтта тикшерүче бүлмәсендә аның белән күзгә-күз очрашу (очная ставка) да оештырганнар. «Хәлем булса, йөзенә төкерер идем, тел кыймылдатырлык хәлем булмады»,— дип сөйләгән.

28 февраль көнне Г. Ибраһимовны үлем бизгәге тота башлый. Бөтен тәне тартыла, куллары калтырый...

Берничә көн буе ризык валчыгы да каба алмаган авыруның соңгы минутлары җитә. Г. Батталов тимер ишеккә йодрыклары белән кагып, надзирательне чакыра, врач кирәк, дип әйтә. Ләкин аның үзенә карцер белән янийлар. Ул язучының кипшенгән, күм-күк булып күгәргән иреннәренә кашык белән су тамызып тора, һәм Г. Ибраһимов, соңгы мәртәбә тартылып, җан биргәч, күзләрен йома. Бу турыда сакчыларга әйткәч, ишек ачыла, һәм сакчылар кереп, Ибраһимовның мәетен шундук алып чыгып китәләр. Әйтерсең лә шуны гына көтеп торганнар.

Берничә көннән Г. Батталовны яңадан Черек күлгә күчерәләр. Ике елга якын ялгыз камерада тоталар. Сорау да алмыйлар, гаепләү акты белән дә таныштырмыйлар. Ахыр чиктә, тәкате калмагач, ул янә ашаудан баш тарта, тагын үлем чигенә җитә. Шулай тарткалаша-көрәшә торгач, берничек тә сындыра алмагач, аны иреккә чыгарырга мәҗбүр булалар. Ул Бөек Ватан сугышында геройларча сугыша, соңыннан, пенсиягә чыкканчы, Аракчино поселогындагы гипс заводында эшли.

Әлеге истәлеген ул алтмышынчы еллар башында ук язучы Афзал Шамовка тапшыра, берничә журналист һәм язучыга сөйли, редакцияләргә җибәрә. Ләкин торгынлык елларында бу турыда матбугатта язып чыгу мөмкин булмый. 1989 елны гына Г. Батталов турында яшьләр газетасында кыскача бер мәкалә басыла.

## Ачыклыйсы нәрсәләр күп әле...

Г. Батталов сүзләрен башкалар да раслый. Г. Ибраһимов белән бергә шул ук палатада яткан тагы берәү (фамилиясен күрсәтергә кушмаган), алтмышынчы еллар башында Ш. Даутовка әдипнең соңгы көннәре турында сөйләгән. Бу истәлек «Г. Ибраһимов турында истәлекләр» китабында басылган. Әлеге кеше хәбәр иткән мәгълүматлар Г. Батталов сөйләгәннәрне тулысынча раслый. Әйтик, әдипнең соңгы сүзләре аның хәтерендә болай калган:

— Революция гел шома юлдан гына бармый шул ул. Аның юлында күп кенә кытыршылыклар, киртәләр дә очрау ихтималы бар. Зигзаг ясап та бара икән ул... Ярый, хакыйкать кайчан да булса өстенлек алыр. Партия дөреслекне күрсәтер. Исән калганнар бәхетле яшәсеннәр. Әлбәттә, киләчәк буыннар бездән күп бәхетле булырлар.

Язучы үлгәч, тумбочка ишегенең эчке ягында шундый язу күрәләр: «Партия каршында, халык каршында һичбер гаебем юк. Хакыйкать ачылыр, тарих үз сүзен әйтер. Галимҗан Ибраһимов». Бәлки, числосы да күрсәтелгән булгандыр, тик ул әлеге тоткын хәтерендә калмаган.

Язучы Ибраһим Салахов Пләтән төрмәсендә 1938 елның башында утыра. Г. Ибраһимовның үлеме турында ул төрмә әлифбасы аша ишетә, бу турыда үзенең «Колыма хикәяләре» исемле әсәрендә яза (61 бит). И. Салаховның үзен дә «Г. Ибраһимовның контрреволюцион төркеменә» кертәләр. Сорау алу вакытында тикшерүче Бикчәнтаев, башына төя-төя: «Халык дошманы Галимҗан Ибраһимов кушкан контрреволюцион эшләрне сөйләп бир!» — дип алҗытып бетерә торган булган. Шул ук «гаепне» яшь язучылардан Ләбиб Гыйльми, Сөббух Рафиков, Галимҗан Мөхәммәтшин һ. б.га да такканнар.

Шул вакытларда Пләтән төрмәсе тоткыны булган Җәләй ага Галәветдинов Галимҗан аганың бәдрәф идәненнән шуышып барганын күреп калган. Күрәсең, аны озата чыгарга рөхсәт итмәгәннәр. Үзенең исә аякка басарлык хәле булмаган.

Пләтән төрмәсенең сакчысы булып эшләгән Зарипов фамилияле икенче берәү шулай ук Галимҗан Ибраһимов белән очрашып, сөйләшеп ала. «Үлемнән курыкмыйм,— дип әйткән ди аңа язучы.— Халык алдында пычратуларына гарьләнәм. Барлык язганнарым юкка чыга...»

Кыскасы, Г. Батталов истәлегенең дөреслеккә туры килүендә бернинди шик калмаска тиеш. Шулай да бер нәрсәгә ачыклык кертергә кирәк. Г. Батталов Г. Ибраһимовның үлемен февраль ахырларында булды дип сөйли. Дәүләт иминлеге комитеты тарафыннан бирелгән белешмәдә исә 21 гыйнвар күрсәтелә. Кайсысы дөрес? Озак тикшеренүләрдән соң бер нәрсәгә инандым: Г. Батталовның хәтере бу урында хилаф кылган. Тарихчы А. Литвин Пләтән төрмәсенең архивында түбәндәге документ таба: *«Акт номер 3 от 21 января 1938 г. Мы, нижеподписавшиеся, врач ОМЗ Маврина,*

*лекпом Байкиев и старший надзиратель Петров составили настоящий акт о том, что лишенный свободы Ибрагимов Галимзян, прибывший из Казанской тюрьмы номер 1 21.10.37 умер 21.1.38 от туберкулеза легких и туберкулезного плеврита».*

Бу документ төрмә шифаханәсенең журналындагы язулар белән дә раслана. Журналларның берсендә: «Сообщено о смерти Ибрагимова начальнику тюрьмы номер 1 т. Нугуманову 24.1.38, т. к. 22 и 23 числа января были нерабочими»,— дип язылган. Бераз түбәндәрәк: «Схоронен в общем порядке следственной больницы 27.1.38»,— дип өстәлгән.

Бу яңа табылган документларга таянып, без, Г. Ибраһимовның үлгән көнен 1938 елның 21 январе, дип шикләнмичә әйтә алабыз. Тагын бер нәрсәгә игътибар итегез: язучы Казанга сентябрь башларында китерелгән, әмма төрмә шифаханәсенә 21 октябрьдә генә күчерелгән. (Бу турыда И. Салахов та үзенең «Колыма хикәяләре»ндә яза). Үлгәч тә мәетне атнага якын җирләмичә яткызганнар. «В общем порядке» дигән сүзләрне ничек аңларга? Гадәттә, болай булган. Башта мәетләрне подвалдагы бер салкын базда тоталар. (Тоткыннар сүзләренә караганда, Г. Ибраһимов үлгән көнне шул ук шифаханәдә тагын җиде кеше җан биргән.) Утыз-кырыклап мәет җыелгач, өсте ябык йөк машинасына төяп Архангель зиратына илтеп күмгәннәр. Моның өчен зиратның төньяк өлешендә зур чокыр казылган булган. Шунда китереп аударгач, мәетләр өстенә сүндерелмәгән известь, аннан бер кат туфрак сибеп чыкканнар. Бер чокыр тулгач, икенчесен, аннан өченчесен казыганнар.

Архангель зиратында Г. Ибраһимов каберендәге һәйкәл шартлы рәвештә генә куелган. Г. Ибраһимов кабере турында әлегә хәтле берниндн рәсми документ табылганы юк. Бәлки, ул булмагандыр да...

Һәм, ниһаять, тагын бер бик җитди мәсьәлә: Г. Ибраһимовның кульязмалары язмышы. Билгеле булганча, Кырымда ул «Безнең көннәр» романының икенче китабын тәмамлый, аны нәшриятка тапшырырга әзерләп куя. Романның беренче китабына да җитди үзгәрешләр кертә. Редакцияләү белән генә чикләнмичә, яңабаштан язып чыга. «Казакъ кызы» романын да редакцияли һәм әсәрнең икенче кисәге өстендә эшли. Шактый күп публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләре, фәнни хезмәтләр яза. Кызганыч, бу кульязмалардан берсенең дә әлегә кадәр табылганы юк.

Бу мәсьәлә буенча Дәүләт иминлеге комитетына Язучылар берлеге идарәсе дә, партиянең өлкә комитеты да, Татарстанның Министрлар Советы рәисе урынбасары М. Х. Хәсәнов та мөрәҗәгать итеп карадылар. Нәтиҗәсе булмады. Миңа бирелгән рәсми җавапта, мәсәлән, болай диелә:

*«При аресте Г. Ибрагимова была изъята папка с документами, какими конкретно не указано, которая в настоящее время не сохранилась, попытка обнаружить эти документы успехом не увенчалась».*

Нинди папка турында сүз бара икән? Истәлекләргә караганда, кульязмалар берничә әрҗә тәшкил иткән бит! Бәлки, араларында ниндидер рәсми документларны туплаган папка да булгандыр. 1937—38 елларда җәйнең иң эссе көннәрендә дә Черек күлнең котельный морҗасыннан куе-кара төтен бөркелеп торган — кулга алынганнарның рәсми кәгазьләрен, документларын, кульязмаларын яндырганнар...

Шундый ук аянычь хәл Г. Ибраһимовның Ялтага киткәндә Дәүләт музеена тапшырып калдырган өй җиһазлары һәм искиткеч бай китапханәсе белән дә була. Рәсми рәвештә опись төзеп, расписка алып калдырган булсалар да, бер нәрсә дә сакланмаган. Хәтта Г. Ибраһимовның булачак музеена куярлык бер әйбер дә калмаган. Тарихның аяусыз көннәре безне күп кенә хәзиналәрдән мәхрүм иткән.

**Марсель Әхмәтҗанов,**
филология фәннәре кандидаты

# МӘГЪРИФӘТЧЕ ШӘМСЕТДИН КҮЛТӘСИ ХАКЫНДА ЯҢА МӘГЪЛҮМАТЛАР



Тарихыбызда Күлтәсиләрнең берсе — философ, астроном Шәмсетдин Күлтәси генә мәгълүм. Хәлбуки, бу галимнең башка ир туганнары да булып, алар турында да сөйләрлек сүзләр бар. Шәмсетдин Күлтәсинең тулы исеме Шәмсетдин-Мөхәммәд, бине Нурмөхәммәд бине Таһир, 1932 елда Татарстанның хәзерге Арча районына караган Күлтәс авылында 75 яшендә вафат булган.

1978 елның 24 июнендә Арча эшчеләр поселогында безгә Шәмсетдин Күлтәсинең улы, озак еллар совет оешмаларында эшләгән Ибраһим ага Таһиров белән очрашып сөйләшергә туры килде. Ул чакны Ибраһим ага әтисе, туганнары турында кызыклы истәлекләр сөйләде, үзләренең нәсел шәҗәрәләрен тасвирлады. Ул шәҗәрә түбәндәгечә килеп чыкты:

Таһир
/Хәзерге Мамадыш районына кергән Максим авылында яшәгән/.
Нурмөхәммәд

Шәмсетдин-Мөхәммәд
/1857-1932/

Мөхәммәдфатих
/Гурьев, Троицк шәһәрләрендә яшәгән, балалары үлгән/

Мөхәммәдхафиз
/Төрекмәнстанда һәм Үзбәкстанда яшәгән, Мерв шәһәрендә тәрҗемәче булып эшләгән./

Мөхәммәдзакир
/Казанда яшәгән. Чар /Царево-Кокшайск/ өязендәге пыяла заводы управляющие булып хезмәт иткән./
/1864-1912/

Салих
Мәрьям

Сөгъдәлислам
/1886-1942/

Фәридә
/1888- ? /

Тәлгать Әхмәров
/ -1969/
Арча районы Яңа Иябашта яшәде.

Нух
/1895-1943/

Ибраһим
Таһиров

Рәйхана /1907-1977/
Арча районы, Бәхтияр авылында укытучы булып эшләгән.

Ә хәзер истәлекләргә күчик.

**Ибраһим Таһиров истәлеге.**

«1911 — 1912 елларда ишан доносы белән полиция безнең өйгә тентү ясарга килгәләде.

Бер килгәндә әтине башта старостага чакырдылар. Әти чалма-чапаннарын киеп старостага барды. Анда аны исправник чакырткан була. Исправник әтигә: «Менә безгә шундый-шундый китаплар кирәк, алар синдә бар, аны синдә күргән шаһитлар бар», — ди. Мин хәзер ул китапларның исемнәрен хәтерләмим инде. Исправник: «Безгә шул китапларны бирегез, алар безгә кирәк, алып китәрбез», — ди. Әти: «Бездә андый китаплар

юк»,— ди. Шуннан соң исправник безнең өйне тентергә ике стражник белән килә. Алар килгәннең әүвәлге төнендә эти безгә кунакка кайткан энесе Фатих һәм туганнары Нух, Закир белән берлектә ниндидер китапларны бакчадагы ябык беседканың идән астына казып күмгәннәр иде. Фатих абыйлар шул беседкада яшәделәр.

Тентү кергәч, бездәге барлык китапларны карап чыктылар. Аларның һәрберсенә цензура рөхсәте бар дип басылган иде. Тентү вакытында этине төрле сораулар белән аптыратып бетерделәр. Эти русчага оста иде, һәрберсенә җавап биреп торды.

Безгә Нәҗип Түнтәри еш килә иде, ул этинең дусларыннан булды. Галимҗан Ибраһимовның да безнең өйдә эти белән очрашканы бар. 1925 елда эти янына тарихчы Газиз Гобәйдуллин килеп китте. Ул чакларны Арчада кантон укытучылары әзерләү курслары эшләде. Газиз Гобәйдуллин шул курсларда укытты. Эти кушуы буенча мин аны Арчадан Күлтәскә ат белән барып алдым. Ул бездә ике көн торды. Моннан тыш эти янына укытучы (һәм шагыйрь) Кыям Юлдашев килеп йөрде. Татарстан хөкүмәте наркомы булып эшләгән Каюм Мәһдиев тә эти белән аралашты. Каюм Мәһдиев ул чакта мәгариф шөгъбәсендә укытучы булып эшли иде, соңыннан репрессиягә дучар булды. Эти янына килеп йөрүчеләрдән тагын Арча педучилищесы укытучысы Ибраһим Якуповны хәтерлим.

Этинең бик зур китапханәсе бар иде, таралып бетте.

Этинең энесе Закир Таһиров РСДРП членнары белән бәйләнештә иде. Аның йортында большевикларның листовкалары, револьверлары сакланган. Аны Сәгъделислам абый сөйләде. Сәгъделислам Мулланур Вахитов белән аралашкан, аларда фатирда торган. Бервакытны Сәгъделислам Закир абыйсында кунган кичне аларга полиция тентүгә килә. Закирның хатынының әнисе аһ-ваһ итеп озаклап ишек ачканда коралларны һәм листовкаларны бәдрәфкә ташлыйлар. Шунда бер төргәк листовка онытылып калган була. Әби аны итәк астына тиз генә алып кыстыра да, эчем авырта, дип сыкранып йөри. Полиция әбине тентеми, йорттан берни дә табалмыйча китә.

Закир абый Казанда авырып вафат булды».[1]

Ибраһим ага Таһиров миңа этисенең фоторәсеме дә бар диган иде. Ләкин ул чакны таба алмады, каядыр куйган иде. Шуннан соң аның белән янәдән дә 1989 елның июнь урталарында гына очрашырга туры килде. Мин, Шәмсетдин Күлтәсинең фоторәсеме табылмадымы икән, дип гел истә тотып йөргәнгә, Ибраһим ага Таһировка кердем. Ул инде тагы да олыгайган, ялгыз калган. Шулай да ул мине онытмаган булып чыкты, өенә алып керде, этисенең фоторәсемен табып күрсәтте. Сурәт 1926 ел чамасында төшерелгән. Анда алгы рәттә, уңда — Шәмсетдин Күлтәси, сулда — дусты Нәҗип Түнтәри, артта баскан Ш. Күлтәсинең энесе Хафиз төшкәннәр. Ибраһим аганың рөхсәте белән Арча район газетасы редакциясе хезмәткәрләре ярдәмендә сурәттән фотокүчермә алдык. Ул укучылар игътибарына тәкъдим ителә.



[1] Казан татар зиратында Габдулла Тукай каберennән бик еракта түгел, Закир Таһировның кабере бар. Аның ташында «Закир бине мулла Нурмөхәммәд Таһиров әл-Күлтәси 48 яшендә 1912 елның 3 декабрендә вафат булды» диеп язылган иде. (Марсель Әхмәтҗанов).

**Тәлгать Әхмәров истәлекләре.**

(Шәмсетдин Кұлтәсинең сеңлесенең улы Тәлгать Әхмәров (1917—1989) белән 1983 елның 11 июлендә Арча районы Яңа Иябаш авылында очрашкан идек. Истәлек, шул вакытта язып алынды.)

«Кұлтәс авылы янында гына Казан бае Габдерахман Ишморатовның җирләре бар иде. Аның җирләре хәзер «Үрнәк» совхозы карамагында.

Җирбиләүче Габдерахман Ишморатов Шәмсетдин Кұлтәси өстеннән гел жалоба йөрткән. Аның шикаяте буенча Шәмсетдин Кұлтәси йортында полиция бер җәйдә 28 мәртәбә тентү уздыра. Аны революционерларга ярдәм иткәне өчен эзәрлеклиләр.

Шәмсетдин Кұлтәсинең улы Сәгъделислам — революционер була. Ул Мулланур Вахитовның дусты һәм аларда фатирда торган. Бу вакытларда ул В. М. Молотов белән дә таныш була. М. Вахитов аның белән бергә Кұлтәскә кунакка кайтып йөргән. Минем Сәгъделислам, Мулланур Вахитов, Нәҗип Түнтәри бергә төшкән фоторәсемне күргәнем бар, Ибраһим Таһировта. Казанда Шәмсетдин Кұлтәсинең улы Нухның кызы Дания апада әлеге һәм башка фоторәсемнәр саклана.

Сәгъделислам Таһиров (Кұлтәси) 1931 елны Казандагы 40 нчы завод директоры булып торды. 1931 елны аны гаепләп партиядән, эштән чыгардылар. Сәгъделислам шуннан соң Мәскәүгә Үзәк Комитетка, В. М. Молотовка хат яза. Хатның тәэсире булып, аны партия членлыгына кайтаралар, һәм ул Казандагы Мамык (Ватный) фабрикасы директоры булып эшли башлый. Аның гомеренең соңгы көннәре авыр булды. Ул 1941 елны Казанда психбольницада үлде. Сәгъделислам Таһировның орден-медальләре дә бар иде. Шул ук елда аның хатыны Гафифә дә үлде. Гафифә телче галим Мөхәммәтхан Фазлулинның сеңлесе иде.

1941 елда Шәмсетдин Кұлтәсинең кызы Зәйнәп, улы Нух Кұлтәси вафат булдылар.

Шәмсетдин Кұлтәсинең сеңлесе Гарифә Түбән Оры авылында (хәзерге Арча районы) Сәмигулла хәзрәт хатыны иде.

Шәмсетдиннең энесе Хафиз Кұлтәси бер китап язган кеше. Үзбәкстанның Мерв шәһәрендә яшәде һәм шунда үлгән булса кирәк.

Энесе Фатих Кұлтәсинең улы Салих 1913 елда туган, кызы Мәрзия 1915 елда туган. Салих рухи авырлыкларга чыдый алмый, 1932 елда сәламәтлеге тәмам какшый.

Шәмсетдин Кұлтәсинең кабере Кұлтәстә, кабер ташы да бар. Ул минем беренче укытучым иде».

# МӘҢГЕЛЕККӘ ЮЛ

Бакый ага Урманче белән Нәкый ага Исәнбәтнең иҗат эшчәнлекләре күпкырлы булуга сәбәп һәм җирлек нәрсә икәнен Нәкый агадан сораганым бар. Ул моңа җавабында үзенә хас төплелек һәм кыскалык белән: «Заман һәм Тукай» дигән иде. Инде китеп: «Ул заманны, «яңарыш чоры» дип атап булырмы?» — дигәч, аксакалларыбыз икесе дә Тукайлы заманны гасыр башының өч революциясе белән бәйләп аңлатканнар иде.

Әлбәттә, бу ике затның икесенең дә Тукайдан ун ел чамасы гына соң туулары һәм Тукай исән чагында 16 һәм 13 яшькә хәтле үсүләренең дә әһәмияте юк түгелдер. Шулай ук, инде менә 90 елга якын Тукай рухы белән яшәгән заманда торуларын, иҗат итүләрен дә читкә куеп булмыйдыр. Әгәр бу көннәргә хәтле яшәсә, алар белән бергә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган, Вәли карыйдан җырлар өйрәнеп йөргән, шигырьләр язышкан Фәтхи Бурнаш та, мөгаен, поэзия һәм драматургия белән генә чикләнеп калмыйча, башка күп өлкәләрдә дә иҗат иткән булыр иде.

Әмма алар иҗатын Тукайлы заман белән аеруча якын иткән, бәйләгән нәрсә — халыкчанлык. Хөкүмәт тарафыннан «Халык язучысы» дигән рәсми исем бирү турындагы карар кабул ителүгә үк Нәкый ага беренчеләрдән булып шул исемгә лаек булды. Бакый агага да, үз ихтыярыннан булмаган утыз еллык «одиссея»сен тәмамлап, Казанга кайтуга ук, Татарстанның һәм РСФСРның халык рәссамы дигән исемнәр бирелгән иде.

Халыкчанлык дигәннән, тагын аларның чичәнлек сыйфатындагы ораторлык сәләтен дә атыйсы килә. Исәнбәт һәм Урманче ораторлыгын, төрки халыкларга хас булганча, сүздән сурәт ясау традицияләрендә тикшерү — киләчәк эше. Аларның Тукай заманындагыча, ялкынлы һәм сабыр, логик эзлекле һәм образлы, саф татар телендә төгәл композицияле хикәя иҗат итеп сөйләүләрен магнитофонга гына язып барасы бар.

Бакый ага Урманче туганнан бирле җыр, үткен сүз яраткан, хәзер дә хәтерендә бик күп җырлар йөртә. Һәммәсен кайда ишеткән, кемнән открытка, алар нинди шартларда (үзе әйтмешли «шараитта») ничек җырлана — яхшы хәтерли. Күрәсең, ул җырлар аның аңында тере сурәт, картина булып сакланадыр.

Менә ул 10 яшендә, җандай яраткан дәү әнисе өендә, бәрәңге ашап утыра. Идрис Урманче гаиләсе белән Күл Черкененнән үз авылына, Кече Салтыкка күчеп китәргә җыена. Булачак рәссам яшенә тыгыла-тыгыла, үзе туган өйдә әбисенә шундый җыр җырлый:

*Ялтыр-ялтыр итәдер ат өстендә ыңгырчак,*
*Инде җитте китәр чаклар, кайчан җитәр кайтыр чак?*

Аһ, ул изге җанлы, сөйкемле һәм нык куллы, эшчән Маһибәдәр әбисе портретын язып кала алган булса! Булмаган шул андый мөмкинлек. Аның каберенә дә ап-ак мәрмәр ташны, 90 елга якын саклаган олы мәхәббәте билгесен, менә быел, нәкъ 54 ел үткәч кенә куя алды. Үзе Кабалан авылыннан өйрәнеп килгән нинди генә җырлар, бәетләр өйрәтмәде икән Габделбакыена Ишморат кызы Маһибәдәр! Бер үтә борынгысы әлегә хәтле Бакый ага фикерен били:

*Казаннарга барсаң Арчадан бар, Алатырдан барсаң әйләнеч,*
*Сагынган чагыңда бер карарсың, чалып бирим изү бәйләвеч.*

Изү бәйләвечен дә бүләк иткән, аны ничек чалуны да өйрәткән әбисе, әмма Казанга каян Алатыр аша әйләнгеч юл булуын сорашмый калган оныгы...

Бакый ага гомер буена Күл Черкендә откан җырлардан картиналар язарга тели:

*Ян тәрәзә төбендә чигү чигә кыз бала,*
*Кыз балага карый-карый йөрәк маем сыза ла.*
*Ике җирән пар кашка, басып торалар ташка,*
*Ашый алмыйм, эчә алмыйм син җаныкайдан башка.*

Ә инде Кече Салтыкта бер егетнең җырлап урак уруы күз алдыннан китми икән:

*Алай да түгел, болай, сабанда сайрый тургай,*
*Җан биргәнгә җүнен бирер үзе яраткан ходай.*

Халыкның сүз белән сурәт ясау осталыгы алдында рәссам гаҗиз дә булып кала: «Керфегеннән гөлләр тама, күрсәм йөрәгем яна» — ничек итеп ясыйсың шуны? — ди. Яисә:

*Ялан да җирләрдә ямьле була ак тирмәләр корып җәйләргә,*
*Кая гына барсаң, дустың булсын каршы чыгып атың бәйләргә,—*

дигән җыр халык тарихына алып кереп китә. Мөнә «Салтык болынын» ясаганда зәңгәр күлмәкле ир кешенең култык астына кызыл буяулар төшерә. «Бу инде» аклы да гына күлмәк, бурла кештәк буладыр?» — дим. «Кештәк? Кайда шулай җырлыйлар? Табып китер әле шул җырны?» — дип, җыр җыентыкларын актара, язу эшләренә керешә.

Ә менә этисеннән өйрәнгән бу җырны:

*Утыртма ла читән, ник утырттың арасында гөлләр булмагач.*
*Минем күңелемне ник ярсыттың, үз күңелләреңдә булмагач,—*

һәм тагын 1934 елда Мәскәүдә Шәриф Камал 50 еллыгында Фәйзулла Туишев баянына кушылып, җырлаган «Ончы Фәхри»ен ул зур мәҗлесләрдә, халык алдында җырларга ярата. «Ончы Фәхри» — борынгы, онытылып бара торган җырлардан. Соңгы елларда ул Татарстанда халык авызыннан язып та алынмады бугай. Себер якларында Төмәннән алып Иркутскига хәтле аны җырлап, скрипкада уйнап күрсәткәннәрен язып алдык. Сүзләре бик мәгълүм түгел. «Тәфтиләү», «Баламишкин» кебек, аны теләсә кайсы җыр сүзләрен куеп җырлау да килешми. Бакый ага репертуарындагыча киң, иркен тавыш белән җырлау аны тарихи-героик җырларга якынайта.

*Җегет тә чакларым, ай, бар иде, киң урамнар гына тар иде.*
*Җегет тә булып ла йөргән чакларымда шәһәрләр саен ярларым бар иде.*
*Урманнарга керсәң сызгырып кер, тибрәнмәгән яфраклар калмасын.*
*Урамнардан узганда уздырып бар, сокланмаган кызлар калмасын.*

«Тәфтиләү», «Мәдинәкәй», «Шахмай», «Сәгать чылбыры», «Казан сөлгесе», «Һаваларда йолдыз», «Зөлхиҗә» кебек билгеле җырлар, бәетләр магнитофонга язып алынды. Кабат язылганнары да бар. Арада «Нәүруз бәете» кебек уникаль әсәрләр дә бар. Ни әйтсәң дә, мәдрәсә шәкертләре буларак, Нәүруз көнендә (хәзергечә 21 март) чаналарга төялеп, өйдән-өйгә йөреп:

*Әй, Ишбабай, Ишбабай, мич башыннан төш, бабай,*
*Биш тиен акча бир, бабай! Нәүруз мөбарәк бад! —*

дип җырлаганнарын хәтерләүчеләр хәзер инде күп түгел.

«Сак-Сок» бәетләрен дә Бакый ага кебек, Тау ягындагы моңлы борынгы көй белән әйтүчеләр сирәгәя бара (ул күбрәк «Хазбулат удалой» көенә охшаш көй белән әйтелә).

1925 елда Башкортстанда ул «Азаматов кантон», «Колой кантон», «Шәүрә килен», «Сандугач» h. б. җырларны өйрәнгәнен сөйләде. Кемнән, кайда, ничек өйрәнгәнен дә язып куйдык. Әмма «Ашказар»ны белүен әйтмәгән иде. Күптән түгел аны Шамил Монасыйповка җырлап торганын ишеттем, бүтән ишеткәнем юк. Югары нотадан башланганга еш җырланмый микән? Пассивта булгач, көй онытылмый микән? Һәрхәлдә, музыка белгечләре игътибар итәргә тиешле фактлар бу.

Казакъ җыры «Сары чәчле кыз»ны көн саен диярлек җырлап ала ул. Күрәсең, тавышны тикшерү һәм тәртиптә тоту өчен уңайлыдыр ул җыр:

*Карлы тау кайда карлы, кайда карсыз,*
*Ир җегет кайда маллы, кайда малсыз...*

Ә менә «Сырымбет» дигән (Чокан Вәлиханов туган җир исеме) икенче матур җырны сирәгрәк җырлый башлады, шуңа аның сүзләрен оныта бара, ә көен үзгәртми. Гомумән, элек өйрәнгән көйләрен һич онытмый Бакый ага. Әмма хәзерге яраткан көйләрен отып алмый, аларны пластинкада тыңлап эшли. М. Мозаффаровның «Менәргә иде Урал тауларына», И. Якуповның «Яшьлегемә кире кайтыр идем» җырларын Илһам Шакиров башкаруында, Гали Ильясовның үзе язган җырларын, Ишмулла кураен һ. б. кат-кат куеп тыңлый.

Башкару ысулларына килгәндә, сәнгать әһелләре Б. Урманче тавышын итальянча куелган дип билгелиләр. Сикәлтәле тормыш юлларында тавышны итальянча кую осталарына да тап булганын сөйли ул. Әмма аның тавышы табигый куелышта да булуы ихтимал. Халык җырчыларының иң осталары, гадәттә, беркайчан профессионал өйрәтүче күрмәгән була.

Шунысы да кызык, яхшы җырлаучыны тыңласа, иң әүвәл әлеге җырның портретын ясыйсы килә аның. Аннан да гаҗәбрәге — кайберәүләренең әле йөзен дә күрмәгән, радиодан гына ишеткән була ул. Шунда ук чакыртып алырга тырыша, әңгәмә кора,

портретларын ясый. Фәридә Кудашева, Рафаэль Ильясов, Ания Туишева — шундыйлардан булдылар.

Халык иҗатын, халык тормышын белү Б. Урманченың фольклорга атап ясаган әсәрләрендә генә түгел, ә бөтен иҗатында чагыла. Аерым фольклорга багышланган эшләреннән Хуҗа Насретдин мәзәкләренә ясаган график сурәтләре, «Өч батыр» дип чыгарылган казакъ әкиятләренә иллюстрацияләрен, Үзбәкстан музеенда саклана торган «Коркот» скульптурасын, шүрәлеләрен, су анасы һәм малай, «Кәҗә һәм сарык»ларын һ. б. санарга мөмкин. Аның фольклорны белүе, аңлап эш итүе аеруча Тукай, Дәрдмәнд иҗаты буенча эшләнгән әсәрләрендә күренә. Билгеле булганча, алар турыдан-туры иллюстрация түгел, ә шигърияттәге нәзыйрә кебек, бер үк темага иҗатчылар ярышуы булып кабул ителә. Әйтик, «Шүрәле» темасына, «Кисекбаш»ка акварель һәм тушь белән ясалган бик күп әсәрләре турыдан-туры Тукай әсәрләрен күчерми, ә аларны тулыландыра, аңлата, баета. Яисә «Казан вә Кабан арты»нда убырның үз «портреты» юк. Аны ясар өчен рәссамга фольклорны, халык ышануларын, хорафатларын яхшы белергә кирәк. Ә инде «Өч кыз» әкиятенә ясалган ана, кызлар, тиен, үрмәкүч, гөберле бака һ. б. график рәсемнәрендә һич фантастикасыз, реаль тормыш картиналары чагылыш тапкан.

«Баллада» дип исемләнгән нәкыш әсәре «Сак-Сок» бәете темасына багышланган. Биредә рәссамның фольклор һәм аңа хас закончалыкларны яхшы белүе сынлы сәнгать өлкәсендә яңалык, ачыш ясауга китергән. Фольклорда вакыт һәм пространство бер яссылыкта чагыла. Рәссамның бу полотносында перспектива юк, бәетнең бөтен сюжеты бер киндергә сыйган һәм төсләр белән хәл ителгән: күгәреп таң ата, кәләпүшле, канатлы ике малай исә кыр кәҗәләре, тиеннәре чабышып йөргән, фантастик агачлары үсеп утырган тауның як-ягында менә-менә юкка чыгачак. Киндернең аскы уң почмагында — авыл өенең эче һәм моңлы карт белән карчык. Ул фигураларда иксез-чиксез хәсрәт, үкенеч тасвирлана. Бөтен картинада төзәтеп булмаслык фаҗига төсмере: димәк, чып-чын баллада.

Бакый ага Урманче «Дастаннар» томына да зур өлеш кертте: «Ләйлә һәм Мәҗнүн» дастанын ул шигъри өлешләре белән хәзерге телгә якын итеп күчерде.

Г. Тукай, үләренә берничә көн кала, Ф. Әмирханнан Ш. Мәрҗанинең борынгы Болгар турындагы бәетен сораткан. «Мөстафәд әл-әхбар»дагы бер бәет (шигырьне) Бакый ага гарәпчәдән болай дип тәрҗемә итте:

*Гүя бу манарага азанчы аяк басмаган,*
*Алланы зекер итеп, хакка өндәмәгән.*
*Гүя яшәмәгән Болгарда мөэмин,*
*Имин булып, ул илдә ахшам да йөрелмәгән.*
*Әйе! Булган алар бер заман!*
*Һәлак итте аларны*
*Язмышның үзгәрүе һәм ризыкның киселүе.*
*Сәламнәр Болгар иленә!*
*Хуш җиләсләре аның кайгылар сөрә*
*Мөсафир күңеленә.*

Халык рәссамы Бакый ага Урманченың яраткан мәкале: «Белгәнгә ялгыш, белмәгәнгә нәкыш». Гарәп мәкальләреннән исә «ляйадри вә ляйадри ма ляйадри» (белми һәм белмәгәнен дә белми) дигәнне кабатларга ярата. Аны «Кем галимин галимин эгъят мәзаһибөһү, кәм җаһилән җаһилән тәлкаһа мәрзука» (күпме галимнәр гамь чигә, аптырап яши, күпме наданнар тук, ризыклы яши) дигән шигырь белән дә ачыклап куя.

Ул, шулай, халык иҗаты, халыкчанлык аша үткән заманнарны хәзерге һәм киләчәк белән бәйли. Тукайлы заманны тулыландыручылар сафында бара.

**Флора ӘХМӘТОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

# ТАТАРЛАР КОРЕЯДА

Татарларның Ерак Көнчыгышка күчеп китүләре XIX йөзнең соңгы — XX йөзнең әүвәлге елларында башлана. Боларның күпчелеге Пенза һәм Тамбов губерналарында яшәүчеләр була. Анда игенчелек белән шөгыльләнер өчен җан башына туры килгән җирнең азлыгы, кәсеп итәр өчен бүтән мөмкинлекләрнең дә тарлыгы аркасында, милләттәшләребезнең байтагы Көнчыгыш Кытай тимер юлын салуда бәхетен сынап карарга сәфәр чыга. Яңа төзелә башлаган тимер юл буендагы Кытай шәһәрләре Маньчжурия, Хайлар, Харбинда әнә шулай татарлар да оя кора башлый. Кыска гына вакыт эчендә алар монда сату-алу эшенә дә керешеп китәләр.[1]

Россиядә революция булу һәм гражданнар сугышы кабыну мондагы тормышка да, шул исәптән, татарлар хәятенә дә тәэсир итә. Гадәти бәйләнешләр җимерелә, сәүдә сүлпәнләнә, акча бәяләре буталып бетә. Революция һәм сугыш дулкыны Кытайга мөһаҗирләрнең яңа төркемнәрен алып килә. Алар арасында төрле төбәктән купкан төрле катлам вәкилләре — шәһәр һәм авыл халкы, байлыгыннан колак каккан кешеләр дә, эшчеләр, игенчеләр, приказчиклар, укытучылар, хәрбиләр дә — төрле караштагы затлар күп була. Аларның һәммәсенә хас бер уртак сыйфат фәкыйрьлек икәнен «Ерак Шәрык» (1924, 2 сан) газетасында басылган «Качаклар: сиену дәверләре» мәкаләсе дә раслап тора.

Тормыш никадәр авыр һәм караңгы булса да, аны дәвам итәргә кирәк. Шул сәбәптән, бу кешеләр дә кәсепкә керешә. Маньчжуриядә шартларның яхшыруына өмет итмәгәнлектән, күпләр Япониягә юл тота. Монда да аларның хәтсезе сәүдә эшенә алына. Әмма Япониядә 1921 елда җир тетрәү татарларга да зур зыян китерә, кайберәүләрнең мөлкәте тулаем да җуела. Шундыйларның бер өлеше, иминрәк җирлек эзләп, Кореяга күчеп китә. Монда алар шәһәрдән шәһәргә, авылдан авылга йөреп сату итүче кырык тартмачыга әверелә. Шулай йөреп бераз мая туплагач, алар гаиләләре белән Сеул, Тэгу, Пусан, Инчхон, Пхеньян, Синыйжу һәм башка калаларда төпләнеп, кибетләр ача башлыйлар. Торабара елдам, тырыш сатучыларның кайсылары яхшы ук баый. Габдулла Хаким, Локман Сөләйман (Сеул), Фатыйх Надыйрша, Вәли Мөхәммәт (Пусан), Исхак Акчура, Габдулла Чуди (Тэгу), Хөсәен Туктамыш (Тэҗон), Хафиз Морат, Гыйниятулла Морат (Пхеньян) һәм башкалар әнә шундыйлардан. Гомумән алганда исә, Кореяда кибет тотучы татарлар саны алтмышка якынлаша. Кибетләрнең күпчелеге хуҗаларының исеме белән йөри, ләкин арада «Алтай», «Нур», «Казан», «Кама», «Байкал» дип аталганнары да була. Татар сәүдәгәрләре малны Япониянең Осака, Токио шәһәрләренең күмәртәләп сатучыларыннан китертәләр. Кибетләр иртәнге сәгать биштә-алтыда ачыла һәм кечке унбер-уникеләргә кадәр эшли, кием-салым, тукыма, галантерея товарлары белән сату итә.

Кореяда татарлар кайда да бергәрәк тупланып урнашырга тырыша, бу аларга уртак дини һәм милли тормыш белән яшәргә, балаларын татарча укытырга, мөселман зиратын булдырырга ярдәм итә. 1926 елда алар баеган Габдулла Нугман хисабына татар җәмгыяте өчен махсус ике катлы бер бина сатып алалар. Аның беренче катында зур зал, идарә утырышлары һәм хезмәтче торыр өчен бүлмәләр бүленгән була, икенче катын мәчет — гыйбадәт ханәсе һәм балалар укый торган мәктәп сыйныфлары били.

Химаячесенә бәйле «Нугмания» исемен алган мәктәп алты еллык белем учагы рәвешендә оештырыла, анда төрле елларда Зәйнәп Рәхим, Габдулла Хәким, Разия Дәүләткилде, Халидә Камайлар балалар укыта.

[1] «Казан» журналы, 1970, 2 сан, 37-40 бб., Истанбул; Ибраһимов Габдерәшит Ислам дөньясы, 1 т. Истанбул, 1987, 191-193 бб.

Мәчет ханәсенә җомга һәм бәйрәм көннәрендә Сеул татарлары намаз укырга җыела.

Зур залда туй һәм бәйрәм тантаналары, дини һәм милли хәтер мәҗлесләре, балаларның күңел ачу уеннары уздырыла. Җырлы-биюле кичәләргә башка шәһәрләрдә яшәүче милләттәшләребез дә килә. Сеулдагы һәм башка шәһәрләрдәге татар җәмәгатьчелеге тормышын Мукденда чыгарылган «Милли байрак» (1935-1945), Токиода нәшер ителгән «Яңа япон мөхбире» (1932-1938) газеталары даими яктыртып тора.

Кореяда татар җәмәгатьчелеге төрле шәһәрләрдә үз мәркәзен төзесә дә, мөселман зираты бөтен илгә бер генә — Сеулдә генә пәйда була. Бу дәүләттәге милләттәшләребез шунлыктан Сеулгә алып килеп җирләнә.

Сеулдә дини эшләрне имам Габдулкәрим Рәхим башкара. Соңрак аның вазифаларын Габдулла Хәким, Габдулхак Нугман, Мөхәммәт Зариф Янгураз, Гарифулла Гыйззәтләр үти. Пусанда исә бу эшне Вәли Мөхәммәт үз өстенә ала.

Кореядагы җәмгыять эшләренә Габдулла Нурмөхәммәт, Кәрим Сөләйман, Мөхәммәт Зариф, Галим Сәләхетдин, Төркиягә күчү дәверендә исә аеруча Исхак Багдаш, Гыйниятулла Моратлар җитәкчелек итә.

Татарлар һәрвакыт бүтән диннәргә хөрмәт белән карый. Дини ышану һәркемнең шәхси эше, моңа берәү дә тыкшынырга тиеш түгел. Шуңа күрә милләттәшләребез бу җәһәттән кореялыларга йогынты ясарга тырышмый. Шулай да алар белән бергә эшләгән һәм яшәгән кореялыларның бер өлеше ислам динен кабул итә, намаз, ураза кебек мөселман йолаларын үти башлый.

Кореядагы татарларның әһәмиятле бер дини эше — Сеулдәге татар җәмгыяте һәм Токиодагы Ислам җәмгыяте үзара берләшеп, 1934 елда Коръән, 1950 елда «Коръән тәфсире» нәшер итүе һәм аларны Ерак Көнчыгыштагы барлык мөселман мәхәлләләренә таратуы. Ерак Шәрыктәге татар мәктәпләре өчен кирәкле дәреслекләрне бастыруга Кореядагы барлык милләттәшләребезнең якыннан катнашуын канәгатьләнеп искәртергә кирәк.

Икенче бөтендөнья сугышы башлану Корея тормышына да тискәре йогынты ясый. Сәүдә эшләре сүлпәнләнә. Япония барлык көчен хәрби әзерлеген күтәрүгә биргәнлектән, читкә мал сатуын киметкәннән кимет бара һәм, ниһаять, бөтенләй туктата. Шунлыктан бик тиз арада Корея кибетләре тәмам бушап кала.

Икенче бөтендөнья сугышы Ерак Көнчыгышта да зур үзгәрешләр китереп чыгара. Корея икегә бүленә. Күп тә үтми, шул икегә бүленгән халык үзара сугыша башлый.

Дәһшәтле хәлләр якынлашуын сизенгән Корея татарлары, инде күп мәртәбә авызы пешкәнлектән, бу юлы иминлекләрен алдан ук кайгыртырга керешәләр. Аларның күпчелеге гарасат куерганчы ук Төркиягә, бер өлеше исә бүтән мәмләкәтләргә күчеп китә. Әнә шулай Кореяга килеп тупланган татарлар язмышы, монда утыз елдан артык гомер сөргәннән соң, башка тарафларда дәвам итә башлый.

**Мәхмүт ТАҺИР,**
Истанбул шәһәре, Төркия.

# ХАТЛАРДАН ЮЛЛАР

* * *

Мин Ленинград шәһәрендә яшим. «Казан утлары» журналын ел саен алам. Аның аша татар әдәбиятының яңа әсәрләре, татар мәдәнияты яңалыклары белән танышып барам. Журналда халкыбызның тарихы, төрле заманда яшәгән галимнәребезнең тормыш юллары, иҗат эшчәнлекләре еш яктыртыла. Узган елгы 7 санда Шиһабетдин Мәрҗани турында укыдык. Шул мәкаләгә бәйләнешле сүзләрем бар.

Минем бабам — Шәмгунов Мөхәммәтситдыйк Шәмгун углы Шиһабетдин Мәрҗанидә укыган. Бу турыда миңа әтиемнең бертуганы Галия апа сөйләгән иде. Бабай үзе мулла нәселеннән булмаган. Үсмер чагында ул бер муллага печән чабарга ялланган. Зирәклеген күреп, мулла аны укырга җибәргән. Апам әйтүенчә, бабам Шиһабетдин Мәрҗани турында язып та калдырган, ул язмалар кайдадыр басылып та чыккан. Бабай югары белемле, указлы мулла булган. Үзе яшәгән Губан авылында (хәзерге Куйбышев өлкәсе) мәдрәсә тоткан. Дин сабаклары белән бергә, мәдрәсәдә дөнья сабаклары да укытылган. Бу — Ш. Мәрҗани күтәреп чыккан мәгърифәт тәгълиматын тормышка ашыруның бер үрнәге.

Күренекле галимебез Латыйф ага Җәләйнең дә бабай белән бәйләнеше булган. Л. Җәләй ага гаделлек, яңалыклар өчен гомер буе көрәшеп яшәде. Ул үзе ярлы гаиләдән чыга, мәдрәсәдә укый, шәкертләр укыта. Һәрвакыт каршылыкларга очрый, мәдрәсәдән-мәдрәсәгә күчеп йөрергә мәҗбүр була. Йөри торгач, Л. Җәләй ага Губан авылына минем бабай карамагындагы мәдрәсәгә килеп чыга. Бу мәдрәсәдә дә ул каршылыклар күрә. Биредә аңа бабай теләктәшлек белдерә. «Тимәгез Латыйфка, ул дөрес юлдан бара»,— дип аны яклый. 1856 елда туган бабам озын-озак яши. Аның соңгы көннәре фаҗигале үтә — Сталин репрессиясенә эләгә. Аны 1938 елда 82 яшендә кулга алалар. «Бабай сине кулга алачаклар, син югалып тор»,— диючеләр була. Бабай ышанмый. «Нишләп мине алсыннар, минем берниндн начар эш эшләгәнем юк»,— ди. Аны икенче көнне үк алып китәләр. Таягына таянып өйдән чыгып киткән. (Таягын янына куеп төшкән фоторәсемен безгә җибәргән иде). Бабай әле сугыштан соң гына үлгән. Кайсы төрмәдә булганын, кайчан, кайда, ничек күмелгәнен белмибез. Сталин үлгәч кенә, безгә аны аклаган язу килде.

**Роза МИНГОЛОВА.**

«Казан утлары»ндагы гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку-язу дәресләрен өйрәнгәннән соң, тырышып-тырмашып гарәп әлифбасында кулдан язылган бер кәгазьне укырга керештем.

Бу язу әниемә 1931 елда авыл шурасы тарафыннан бирелгән, шул заманга караган, фани дөньяның бер белешмәсе булып чыкты. Анда бабакамның (әниемнең әтисе) революциягә кадәр фәкыйрь, ә аннан соң урта тормышлы булуы, 1931 ел башында колхозга керүе, шулай ук агай-энеләренең дә колхозда булулары турында язылган иде.

Бу белешмәнең эчтәлегеннән соң шундый хәлләр ачыкланды: тырыш, фәкыйрь игенченең тормышы НЭП заманында урта хәллегә барып җиткән. Ә минем әтиемә андый белешмә алырга туры килмәгән. НЭП чорлары узган булган һәм аңа Беломор-Каналны казырга туры килгән...

Кадерле редакция! Сез буыннар арасында күпер салучыларга охшап киттегез. «Игелекле эш күрсәгез, рәхмәт әйтергә онытмагыз»,— дип өйрәткәннәр иде безне. Сезгә хат аша рәхмәт әйтәм! Игелекле эшләрегезне шулай дәвам итсәгез иде.

**Зөфәр БУЛГАКОВ.**
Уфа шәһәре.

Ни өчен соңгы елларда күп кенә әсәрләрнең астына иҗат ителгән елы язылмый. «Нигә кирәк ул?» — диярсез. Кирәк. Әдәбият укытучыларына да, әдәбият сөючеләргә дә, тарихчыларга да. Иҗат — билгеле бер чор җимеше ул. Күпвакыт әсәрләрне укыйсың да: «Бу фикерне язучы ничәнче елда әйткән?» — дип сорау куясың. Чыннан да, әсәр кайчан язылган? Миндә генә түгел, әдәбият белән шөгыльләнүче башкаларда да шундый кызыксыну туарга мөмкин — мин моны шикләнми әйтәм.

Кыскасы, әсәрнең язылу елы күрсәтелсен иде.

**И. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН,**
Бәләбәй педагогия училищесының
татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Кояш Тимбикованың журналда чыккан «Табылдык хатлар» повесте һаман күңелдә тора. Моннан алдарак аның «Нигә сагынам икән?», «Кышкы талпыну» әсәрләрен йотлыгып укыган идек. Бу юлы да иң әүвәл аның әсәрен укып чыктык. Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ына тиңләшерлек әсәр ул. Язучы әсәргә йөрәк җылысын биреп, барыбызны борчыган әхлак мәсьәләләрен югары күтәреп, хәтерләребездә уелып калырлык итеп язган. Әсәрнең кечкенә генә кимчелеге дә бар шикелле. Әйтик, повесть Гөлләрия җиңгәсенең хаты белән тәмамланса, тагын да отышлырак булыр иде кебек. Укучылар әсәрнең дәвамын үзләре дә, һичшиксез, уйлап табырлар иде. Гөлләриянең хәмер эчүне ташлавы ышандырып бетерми, чөнки бу аның холкына туры килми.

Язучы Кояш Тимбиковага яңа әсәре өчен рәхмәтләребезне белдерсәгез иде. Без аңа саулык-сәләмәтлек, иҗат юлында уңышлар телибез, яңа әсәрләрен көтәбез.

Әнәс һәм Мәрзия **ХӘСӘНОВЛАР,**
Судак шәһәре.

Үземне борчыган бер фикер белән уртаклашасым килә. Мин хәзерге көндә русчадан татарчага тәрҗемә китаплар чыгаруны берничек тә аңламыйм. Аларны берәү дә укымый бугай. Хәзер русча белмәгән татарны көндез чыра яндырып та табалмассың. Ә татарча белмәгән татарга сукыр кеше дә адым саен килеп төрбелә. Нигә юкка кәгазь, вакыт, акча әрәм итәргә икән? Киресенчә, татар язучыларын русчага тәрҗемә итүне җанландырасы иде.

Рәис **МӨХӘММӘДИЕВ,**
Башкортстан, Чишмә районы,
Ибраһим авылы.

Үзаң, уян!
Чык син кысан кабырчыгыңнан!
Күзәтергә түземем калмады инч...
Инде, яшәр өчен,
Бабаларым рухын чакырам.

Әйе, чакырам. Дөньяда яшисе бар бит. Ләкин ничек үзгәрергә, кемнән киңәш сорарга? Нигә соң халкым төнге йокысын көндез дә дәвам итә? Шулай булса да, без эшебезне дәвам итәргә тырышабыз. Мәктәпләребездә балаларга татар теле дәресләре кертә башлады, туган телне өйрәнү курслары ачылды, гарәп әлифбасын өйрәнү түгәрәге дә эшли. Тик безне аңларлык, бергә эшләрлек яшьләр генә бик аз. Алар халкыбыз рухыннан аерылганнар инде. Шушы яшьләргә атап, өлкә газетасына мөрәҗәгать тә язган идем, куркытылар, ахры, басып чыгармадылар.

Кулдан килгән эшләрне эшлибез, дигән идем. Г. Тукайның туган көненә багышлап әдәби кичә уздырдык. Газетада кечкенә хәбәр дә басылып чыкты ул хакта. Даһи шагыйребез иҗатын өйрәнү һәм аны рухын халыкка кайтару — халкыңа хезмәт итүдер дип саныйм. Тукай үзе безне шулай өйрәткән.

Әлфия **ДУЛАТОВА,**
Әстерхан шәһәре.

Журналның узган елгы 12 санында аксакалыбыз Нәкый Исәнбәтнең «Сынатмаска кирәк, җегетләр!» дигән әңгәмәсен укыгач, мин дә үз фикерләремне сезгә язарга булдым. «Нигә шул кадәр чәчелгән бу татар халкы? Туган-үскән җиреннән нигә шулай җиңел аерылган?» — дигән сорауларны куя Нәкый ага. Туган илне, туган телне онытмаска кирәклеген әйтә.

Мин үзем 1957 елдан бирле туган илемнән читтә яшим. Ник китүемне сөйли баш-

ласам, язарга кәгазь җитмәстер. Туган якларымны сагынып йөрәгем гомер буена җылады. Күп халыкны күрдем, күп милләтләр белән бергә эшләдем. Татарның берсеннән-берсе качып яшәгәнен дә гомер буена күреп торам. Башка халыклар үз-үзләрен яклашып яшиләр. Нигә алар таралмаган да, таркалмаган да? Нигә алар адашып йөрмиләр? Моңа җавап итеп, бер генә мисал китерәсе килә. Безнең республикада Яр-Чаллы, Түбән Кама, Кама Аланында зур төзелешләр булды. Менә хәзер Алабугада яңа төзелеш башланды. Шул төзелешләргә кайтырга дип, татарлар ярдәм сорадылар, яздылар, үтенделәр. Һәм хәзер дә шулай. Нигә аларның йөрәк яраларын, күз яшьләрен беркем дә күрми?! Өлкәннәр һәм яшьләр Ватанына, ата-бабасы туфрагына кайтып төпләнсә — кешеләр күңеленә иман иңәр иде. Моңардан кемгә зыян икән? Мин үзем күп тапкырлар, гаиләм белән кайтырга дип, төрле оешма һәм редакцияләргә хатлар яздым. Җавап кына булмады. Мин Дагстанда яшим. «Диңгез буеннан кайтып йөрмәгез инде»,— диделәр миңа Алабуга төзелеш оешмаларының берсендә. Бу 1985 нче ел иде. Ә җандагы сагыш, хәсрәт диңгезен кая куярга соң?! Миңа хәзер 49 яшь. Исәнлегем яхшы, көчем бар. Таяныр җирем булса — улым белән кайтыр идем. Безнең арттан үзенең гаиләсе белән кызым да кайтыр иде. Миңа ярдәм итүче табылырмы?

**С. ЗАРИПОВА,**
Дагстан АССР, Дуппи поселогы.

Журналның соңгы саннарында чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез турында мәкаләләр басылып чыкты. Болар укучыларны куандырды. Ләкин бит сезнең тирә-ягыгызда гына да бик күп татарлар яши. Әйтик, Башкортстанда, Оренбург, Чиләбе, Ульяновск өлкәләрендә. Алар милләт буларак югала баралар яки башка милләткә әйләнәләр. Ни өчен икәнен сез үзегез дә бик яхшы беләсез.

Журнал хезмәткәрләреннән, галимнәрдән, язучылардан сорар идем: шушы төбәкләрдә яшәгән туганнарыбызны милләт буларак саклап калу өчен сез ни эшләдегез? Татарстан хөкүмәтенә төрле тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать иткәнегез бармы? Нәтиҗәсе нинди?

Ярый, икенче мәсьәләгә күчик. Соңгы вакытларда татарларны «болгарлаштыру» башланды. Сез мине дөрес аңлагыз. Һәр татар үзенең туган тамырын белергә тиеш. Горурланырга тиеш. Ләкин бит бүген без дөньяга татар этносы буларак билгелебез. Әлеге катлаулы һәм бик тә җаваплы вакытта, барча татарларны берләштерү өчен, милләт буларак коткарып калу өчен, тарихыбыз хакына безгә бүген татар булып калырга кирәк. Таркаулык безнең халыкны болай да гасырлар буена таркаткан ич инде.

Республиканың статусын күтәрү, татар телен дәүләт теле итү — менә сезнең һәм безнең бүгенге эшлисе эшләребез. Тагын бер мәсьәләне күтәрәсе иде. Миграция мәсьәләсен. Республикада халкыбыз азчылык милләт булып калды. Бу куркыныч киләчәктә дә сакланачак. Газеталарда чыккан белдерүләрдә озакламый Алабугада зур төзелешләр башланачагы турында әйтелә. Ул башланды да бугай. Бәлки бу миграция — татар халкын бетерү өчен соңгы һөҗүмдер. Безнең галимнәребезгә, язучыларыбызга, артистларыбызга, укымышлы кешеләребезгә, бәлки, Литва, Эстония, Латвия укымышлыларыннан үрнәк алыр вакыт җиткәндер. Халкыбыз сездән игелек көтә, сезнең күзгә карап тора, хөрмәтләләребез!

**С. РАМАЗАНОВ,**
Нижневартовск шәһәре.

# ӘЙДӘ, ХАЛЫККА ХЕЗМӘТКӘ...

**Матбугатта инде хәбәр ителгәнчә, шушы елның февралендә Казанда, киң җәмәгатьчелек катнашы белән, республика «Ватан» җәмгыятен оештыруга багышланган тантана булды Бу яңа җәмгыять нинди ихтыяҗларны күздә тотып төзелде соң! Аның эшчәнлеге, максаты, милләтебез хәятендә тоткан урыны нидән гыйбарәт булачак! Күпсанлы журнал укучыларыбызның да кызыксынуларын истә тотып, бу сораулар белән без җәмгыятьнең рәисе академик Мирза әфәнде Мәхмүтовка мөрәҗәгать иттек.**

**М. И. МӘХМҮТОВ:**

— Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә карата соңгы ике-өч ел эчендә татар җәмәгатьчелегенең игътибары арткannan-арта бара. Бу — без татарларда гына түгел, башка күпсанлы милләтләрдә дә шулай. Дистәләрчә еллар рәсмиян гел «дошман» итеп саналган кешеләр белән хат языша, кунакка йөрешә дә башладык инде. Бу халәтнең, бу күренешнең сәбәбе нәрсәдә соң? Үзгәртеп кору уңаеннан хәбәрдарлык, демократиянең җәелеп китүеме, әллә башка сәбәпләр дә бар микән?

Татарстан Министрлар советы карары нигезендә, «Ватан» җәмгыяте оешып, яңа иҗтимагый хәрәкәт башланып киткәч, мин бу хакта ешрак уйлана башладым. Безгә ни җитмәгән, әллә үзебездә булган проблемалар азмы, әллә буш вакытыбыз күбәеп киттеме?

Юк, хикмәт боларда түгел, әлбәттә. Җәмәгатьчелекнең теге яки бу мәсьәлә белән кызыксынып китүен җентекләбрәк өйрәнсәң аның нигезендә элек башка да килмәгән әллә ничаклы сәбәпләр ятканын күрербез. Сүз уңаеннан мин аларның берничәсен әйтеп китәр идем.

Беренчесе — безнең илебездә тормыш күп еллар буе чикләнеп, башка дөньядан «тимер пәрдә» белән капланып килде. Ике капма-каршы идеологиягә корылган мондый яшәеш, матди һәм рухи яктан да нык аерылып, ике төрле эздән барды һәм җәмәгатьчелекнең аңына, психологиясенә көчле тәэсир итте.

Ниһаять, үзгәртеп кору чорына аяк бастык. Капма-каршы басып торган дөньяны ничек килештерергә? Ике яктагы халыкларны ничек якынлаштырырга? Нинди юллар белән кешеләрнең күңелендә тынычлык, дуслык хисләрен ныгытырга? Безгә таныш булмаган дөньяны, аның кешеләрен яхшы белергә кирәк иде, әлбәттә. Моның өчен рәсми дипломатия генә түгел, гайрерәсми халык дипломатиясе дә кирәк. Бездә тормыш шартлары чагыштырмача авыр булганга күрә, «Анда» халык ничек яши икән?», «Анда» тормыш шартлары нигә безнекеннән яхшырак?» шикелле сорауларга җавап эзләп, халык уяна һәм уйлана башлады. Дөньяда тынычлыкны ныгыту җәһәтеннән чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең тормыш-көнкүреше белән табигый кызыксыну тагын да артты.

Икенче сәбәп тә бар. Ул ике өлештән тора: берсе — дөньяви кызыксынудан тыш, бағланышларга өмет белән дә каравы, икенчесе — таррак даирәләрнең хыялы. Дөньяви төшенчәсен мин ахирәткә бәйләмим: матди тормыш, көнкүрешне күздә тотып әйтәм. Анда бездән яхшырак яшиләр, тормышларын бездән әйбәтрәк оештырганнар икән, без алардан үрнәк алып, тормышыбыз вә җәмгыятебезне яхшырта алмабызмы микән? Андагы татар кардәшләребез бездән хәллерәк икән, алар безгә үзгәртеп коруның кайбер мәсьәләләрендә булышмаслар микән? — шикелле сорауларга җавап эзләп, өмет баглап, күп кенә кеше «теге» якка күз ташлый.

Бу сәбәпнең икенче өлеше — татар интеллигенциясе, хәзерге зыялылар күңелендә милләтне агарту өмете. Мондый фикер белән янып йөргән кешеләрнең хыялы — совет чорында югалып, төшеп калган мәдәни байлыкларның билгеле бер өлешен кире кайтарып булмас микән дигән уйлар...

Бу процесс русларда көчле бара. Алар читтә яшәгән милләттәшләрен илебезгә чакыралар, радио-телевидениядән сөйләтәләр, аларның китапларын бастырып чыгаралар. Әйтик, март башында Мәскәү Голицын, Шереметьев, Пущиннар һ. б. шундый борынгы князьләр, графларның токымнарын зур хөрмәт белән каршы алды, кунак итте. («Известия» 2.03.90).

Өченче сәбәп — илдәге уянуны күреп, теге яктан да безнең тормышыбыз белән кызыксынуның көчәюе. Илне демократияләштерү андагы үзгәрешләргә дә киң юл ачты. Әлеге кызыксыну, «перестройка» белән генә чикләнмичә, милли хисләрнең, туган

телне саклап калу теләгенең, рухи тормыш һәм мәдәни мәнфәгатьләрнең кузгалышына да ярдәм итте. Ят мохиткa сеңеп бетмәс өчен көрәшә чит илдәге кардәшләребез.

Тагын шунысын онытмыйк: Ватаныннан читкә чыгып киткән кешедә «ностальгия» чире була. Туган якны, үз өммәтеңне сагыну — безнең халыкта күптән инде «милли» бер сыйфатка әверелгән. Мәсәлән, 1670 елларда татар шагыйре Мәүла Колый гарибләр (ватаныннан читтә яшәүчеләр) турында болай дип әйткән:

*Хак[1] бирмәсен һичбер кемгә гариблекне,*
*Гариблек барча хальдә михнәт иркән;*
*Би мәкян[2] вә би чара горбәт[3] чигеп,*
*Йөрәкендә хәсрәт уты йанар иркән... .*

Гомумән, узган гасырларда татар шагыйрьләре гарәп, фарсы, төрек илләрендә күп еллар укып йөргән. Анда, үз илләрен сагынып кайту көннәрен көтеп яшәгән чакта, күңелләрендәгене кәгазьгә бушата торган булганнар. Бу тойгылар гасырлар үтү белән дә үзгәрмәгән. «Туган илне, туган җирне төштә күрсәм дә файда»,— дип җырлыйлар хәзерге Япониядә яшәүче татарлар (Япониядәге кардәшләребез», «Социалистик Татарстан», 4/III-90).

Шуңа күрә, бездән берәү чит илләргә барып татар кешесен очратса, анда аны иң кадерле кунак итеп каршы алалар, хөрмәт итәләр, көннәр буе сөйләшеп утырырга ризалар. Үзләрен исә совет татары кунакка чакырса, шулай ук шатланып риза булалар. Бу турыда чит илләрдә йөреп кайткан фәннәр докторы Әбрар Кәримуллинның кат-кат сөйләгәне бар.

Андый очрашулар берәр рәсми сәбәп булганда бигрәк күбәеп китәләр. Мәсәлән, былтыр татар халкы ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңае белән Казан, Уфа h. б. шәһәрләрдә булган тантанага чит илләрдән йөзләгән татар килде. Шуннаң соң ватандашларыбызның чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән элемтәләре тагы да ныгыды, хат-хәбәр аша бер-берсенең хәл-әхвәлләрен белешү белән беррәттән, кунакка йөрүләр дә күбәеп китте. Дуслашу, очрашу — кирәкле шөйдер.

Алдарак әйтелгән фикергә кайтыйк. Мәдәни мирас дигәндә без рухи байлыкны күздә тотабыз. Философиядә «җисемләшкән» һәм «җисемләшмәгән» яки «тере» белем бар дип исәпләнә. «Җисемләшкән» белем — кеше уйлап чыгарган кагыйдәләр нигезендә тегe яки бу әйбер, машина, җиһаз ясалса, бу белем кулланышка, гамәлгә кергән, дип санала. «Тере» белем исә әйбердә түгел, кешенең акылында, зиһенендә, башында булган белем, ягъни физик, химик, әдип һәм филологлар белеме, осталык, маһирлык, фикерләү сәләте, дигән сүз.

Мәдәни мирас та, шул җәһәттән карагaнда, ике өлешкә бүленә. Берсе аның «тегe» якта милләттәшләребез тарафыннан язылган китаплар, картиналар, рәсемнәр, кул сәнгате әйберләре (төрле-төрле зиннәтләр, бизәнү, киенү әйберләре h. б.). Шул исәптән элек монда — Россиядә язылып та читкә чыгарылган китаплар саны аз түгел. Мәсәлән, профессор Ибраһим Нуруллин язмаларыннан без бөек язучы, әдип Гаяз Исхакыйның мирасы нихәтле зур һәм бай икәнлеген белдек. Аны халыкка кайтару үзе бер шатлык булыр иде, чөнки башкорт яисә казакъ халыкларының кайбер өлгер вәкилләре Кол Галиләрдән калган мәдәни мирасыбызга хуҗа булмакчы булып йөргәндә, без үзебезнең хәзинәне «безнен халыкныкы» дип вакытында әйтеп калмасак, тарих битләрендә һаман да «кыргый татар» булып калачакбыз.

Югарыда сөйләгәннәрем «җисемләшкән» белем-мираска керә. Аның «тере» өлеше дә шактый зур. Чит илләрдә татарлардан эшчекрестьян гына түгел, зыялылар да байтак. Алар арасында дөньякүләм танылган галимнәр, профессорлар, дипломатлар, мәҗлеспарламент депутатлары, зур эш (бизнес) башында торучы талант ияләре, артистлар һәм әдипләр бар.

Чит илдә яшәүчеләрнең бер өлеше татарча әйбәт сөйләшә, үз телләрен сакларга тырыша. Алар туган телләрен югалтудан куркалар, чөнки җәмәгатьчелектә татарча сөйләшү юк. Тел бетсә, кешенең милли үзенчәлеге дә бетә, ерактан килгән рухи тормышы ярлылана, атабабадан килгән күп кенә сыйфатлар югала. Чит илләрдә түгел, Россиянең төрле төбәкләренә сибелгән үзебезнең татар кардәшләребез дә күңелләре белән һәрчак Казан ягына карыйлар.

Чит илләрдә яшәүче кардәшләребезгә үзебез нәрсә бирә алабыз соң? Совет илләрендәге тарихыбыз төрле вакыйгаларга бай. Мәдәниятебез дә, бигрәк тә аның язма өлеше, элекке алфавит-әлифбаларын югалтуга карамастан, шактый тәрәккыят итте: китап дөньясы киңәя бара, музыкада Сәйдәшев, Яруллин, Җиһанов, Мансуровлар, гуманитар фәннәрдә Закиев, Тумашева, Кәримуллин, Хаков, Халиковлар кебек дисталәрчә профессорлар, дөньякүләм танылган Сәгъдиев, Вәлиевлар кебек академикларыбыз бар. Әдәбиятта исә мәшһүр әдипләр Нәкый Исәнбәт, Риза Ишморат, Әмирхан Еники, Гомәр Бәшировлар башлап киткән исемлекнең зурлыгы да бәхәссез. Башка илләрдә яшәүчеләр җиткерерлек мәдәни үрнәкләр, шул исәптән «... тел, лөгать вә әхлак» алмашырлык белем ияләребез, шөкер, җитәрлек.

Халык дипломатлары сыйфатында аларны тик юллыйсы гына бар. Сөйләшсеннәр, дуслашсыннар, зур Ватаныбызның башка илләр белән дуслыгын ныгытырга булышсыннар гына... Шул изге хәрәкәттә «Ватан» җәмгыяте, һичшиксез, прогресс, тәрәккыят сукмакларының берсе булыр.

Сүзлек: [1] Хак — Алла. [2] Би мәкян — урынсыз. [3] Горбәт — читкә тибәрелеп йөрү.

## Җәвад Тәрҗемановка — 70 яшь



Җәвад Әфтах улы Тәрҗеманов 1920 елның 8 июлендә Казан шәһәрендә мулла гаиләсендә дөньяга килә. 13 номерлы беренче татар урта мәктәбен алтын аттестатка тәмамлап, 1938 елда Казан химия-технология институтының механика факультетына укырга керә. Бөек Ватан сугышы елларында ул, институтта һәм аспирантурада уку белән бергә, хәрби заводта автомат-станокларны көйләүче инженер-технолог булып эшли. 1950 елны техник фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен диссертация яклый, Казан химия-технология институты кафедрасында озак еллар доцент булып эшли. Аның дистәләрчә фәнни хезмәтләре бар. 1981 елдан Татарстанның атказанган фән һәм техника эшлеклесе.

Җәвад Тәрҗеманов пионер чагыннан ук матур әдәбият белән кызыксына. Күп укый, үзе дә хикәяләр һәм шигырьләр яза. 1938 елда, унынчы класста укыган чагында, «Кызыл галстук» исемле беренче китабы дөнья күрә.

50 ел эчендә (1938—1988 еллар) Җәвад Тәрҗемановның СССР халыклары телләрендә һәм чит телләрдә сиксәнләп китабы басылып чыга. Аның дөньякүләм танылган күренекле әсәрләре — «Шуктуган» әкият-повесте һәм «Көмеш дага» романы.

1946 елдан бирле ул — СССР Язучылар берлеге әгъзасы

## *Каләмдәшләребез — СССР Язучылар берлегенең яңа әгъзалары*

### Наилә Вәлитова



Наилә Минһаҗ кызы Вәлитова 1946 елда туган. Әгерҗе районының Иж-Бубый авылында урта белем ала. Алабуга дәүләт педагогия институтын тәмамлаганнан соң, Иж-Бубый һәм Казан мәктәпләрендә укыта. 1971 елдан алып Татарстан китап нәшриятында эшли башлый, хәзерге вакытта матур әдәбият редакциясенең өлкән редакторы.

Наилә Вәлитова тәрҗемәсендә Э. Успенскийның «Крокодил Гена һәм аның дуслары», В. Распутинның «Онытма гомергә», Н. Думбадзеның «Мәңгелек канун» исемле әсәрләре татар телендә китап булып басылып чыкты.

## Фирая Зыятдинова



Фирая Гали кызы Зыятдинова (Шиһапова) 1945 елда Арча районының Мамыш авылында туа. Сигезьеллык мәктәпне тәмамлагач, колхозда эшли башлый. Кичке мәктәптә урта белем алып, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Аннары, бер ел мәктәптә укытканнан соң, Татарстан китап нәшриятында эшли башлый. Бүгенге көндә ул — нәшриятнең матур әдәбият редакциясендә редактор.

Фирая Зыятдинованың шигырьләре башта республика газета-журналларында дөнья күрә. Ул тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. 1985 елда К. Паустовский хикәяләрен тәрҗемә итеп, «Яңгырлы иртә» исемле китап чыгарды. Соңрак аның «Матур буласым килә» һәм «Язгы ярсу» дигән мөстәкыйль шигырь җыентыклары да дөнья күрде.



## Рафис Гыйззәтуллин

Рафис Әхәт улы Гыйззәтуллин 1955 елда Сарман районының Урта Кәшер авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлагач, 1972—77 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, югары белем ала. Аннан соң «Татарстан яшьләре» газетасында эшли, Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Хәрби хезмәттән кайткач, «Ялкын» журналында эшләп ала. Бүгенге көндә ул — «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә әдәбият һәм сәнгать бүлегенең өлкән хәбәрчесе.

Рафис Гыйззәтуллин балалар өчен язылган «Очучы буласым килә» (1984), «Урман юлы» (1987), «Көтелмәгән сорау» (1990) исемле китапләр авторы.

## Марк Зарецкий

Марк Давидович Зарецкий 1937 елда Киев шәһәрендә туган. Казан педагогия институтын тәмамлагач, Куйбышев (Татарстан) шәһәре мәктәпләренең берсендә рус теле һәм әдәбиятын укыта. Аннан соң Казанда эшче яшьләр мәктәбендә, техник һөнәр бирү училищесында эшли. 1963 елдан башлап Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә редактор вазифасын башкара. Ул — Татарстанның атказанган культура хезмәткәре.



Марк Зарецкий рус телендә яза һәм аның балалар өчен «Птицы — наши друзья», «Наш зоопарк», «Зеленые доктора» исемле китаплары дөнья күрде. Аның тарафыннан күп кенә танылган татар язучыларының һәм шагыйрьләренең әсәрләре русчага тәрҗемә ителде.

1987 елда Марк Зарецкийның «Речь» дип исемләнгән шигырьләр җыентыгы Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты.

# Шәйхзадә Бабич

## Халкым өчен

Ап-ак алтын җырларымны җырламыйм данлык өчен,
Җырлыймын алтын илемнән, үз туган халкым өчен.

Саф көмештик җырларымны җырламыйм алтын өчен,
Җырлаем тик саф көмештик саф йөрәк халкым өчен.

Чәчкә төсле җырларымны җырламыйм зәукым өчен,
Җырлаем тик чәчкәдәй кызларга бай халкым өчен.

Дәртле кайнар җырларымны җырламыйм дәртем өчен,
Җырлаем тик мәңге шат, дәртле, көләч халкым өчен.

Егъламыйм мин көннәрем сыргак, суык салкын өчен,
Егълыем тик ярлы мескен, кызганыч халкым өчен.

Яшь чагым, алтын чагым, ялкын чагым булсын фида
Халкым алдында минем биргән таза антым өчен.

## Кем өчен?

Айга үрләп, нурда уйнап,
Күкрәгемне нурладым.

— Ит гафу, әй, ай, дидем,
Мин нурларыңны урладым.

— Һич зарар юк, ал, диде ай,
Ал да чәч нур халкыңа,

Мин дә бит төн хакына
Алдым кояшның нурларын.

Татар поэзиясе антологиясе.— Казан, 1956, 253, 261 бб.

شیخ زاده بابیچ

## حالقم اوچون

آپ - آق آلطن جرلارمنی جرلامیم دانلق اوچون ،
جرلیم آلطن ایلم اوچون ، اوز توغان حالقم اوچون .

ساف کمش تیك جرلارمنی جرلامیم آلطن اوچون ،
جرلایم تیك ساف کمش تیك ساف یوره‌ك حالقم اوچون .

چه‌چکه توسلی جرلارمنی جرلامیم زوقم اوچون ،
جرلایم تیك چه‌چکه ده‌ی قزلارغا بای حالقم اوچون .

ده‌رتلی قاینار جرلارمنی جرلامیم ده‌رتم اوچون ،
جرلایم تیك مه‌نگی شات ، ده‌رتلی کوله‌چ حالقم اوچون .

یلامیم مین کوینه‌رم سرغاق ، سوویق ، سالقن اوچون ،
یلایم تیك یارلی ، مسکین ، قزغانچ حالقم اوچون .

یه‌ش چاغم ، آلطن چاغم ، یالقن چاغم بولسون فیدا
حالقم آلدندا مینم بیرگه‌ن تازا آنتم اوچون .

## کم اوچون ؟

آیغا اورله‌پ ، نوردا اویناپ ؟
کوکره‌گمنی نورلادم .

- هیچ زارار یوق آل ، دیدی ، آی ،
آل دا چه‌چ نور حالقیگا !

- ایت غفو ، ئه‌ی ، آی دیدم
مین نورلا ریگنی اورلادم .

مین ده بیت تون حاقینا
آلدم قویاشنك نورلارین .

*Текстны журнал өчен Җәүдәт Миңнуллин һәм Раиф Мәрданов әзерләде.*

# *Китаплар дөньясында*

**Нияз Акмал. Күгәрчен сөте.** Повесть Б. 1 с. 10 т.

**Гамил Афзал. Сайланма әсәрләр.** Б. 1 с. 90 т.

**Бер тауда ун Чишмә.** Яшь шагыйрьләр җыентыгы. Б. 1 с. 10 т.

**Клара Булатова. Миләш кагы.** Шигырьләр. Б. 60 т.

**Наис Гамбәрев. Баш очында кояш.** Шигырьләр. Б. 30 т.

**Рәдиф Гатауллин. Кар астында гөлләр.** Шигырьләр. Б. 1 с. 20 т.

**Рәшит Гәрәй. Тургайлы тугайларым.** Шигырьләр. Б. 1 с. 20 т.

**Әмирхан Еники. Сайланма әсәрләр.** 3 томлык. 1 том. Б. 1 с. 90 т. 2 том. Б. 1 с. 90 т. 3 том. Б. 1 с. 90 т.

**Фарсель Зыятдинов. Тагын килде язлар.** Шигырьләр. Б. 10 т.

**Сәйдә Зыятдинова. Айның туган чагы.** Шигырьләр. Б. 10 т.

**Фирая Зыятдинова. Ташкын.** Шигырьләр. Б. 40 т.

**Зәки Зәйнуллин. Сугыш алды малайлары.** Повестьлар. Б. 1 с. 10 т.

**Әнисә Ибраһимова. Сары умырзаялар.** Повестьлар. Б. 90 т.

**Илсөяр Иксанова. Ышанасы килә.** Шигырьләр. Б. 30 т.

**Вахит Имамов. Нәзер.** Повестьлар. Б. 1 с. 10 т.

**Рәисә Ишморатова. Тормыш дәвам итә.** Повесть. Б. 65 т.

**Казакъ повестьлары.** Б. 1 с. 60 т.

**Барлас Камалов. Уйлый күңел.** Хикәяләр. Б. 25 т.

**Хатыйп Касыймов. Акчишмә.** Шигырьләр. Б. 10 т.

**Рәфкать Кәрами. Очар кошлар белән янәшә.** Б. 1 с. 20 т.

**Фатыйх Кәрими. Сайланма әсәрләр.** Б. 1 с. 70 т.

**Әбрар Кәримуллин. Татар халкының исеме һәм җисеме.** Б. 35 т.

**Кави Латыйпов. Иркен сулыш.** Шигырьләр. Б. 30 т.

**Флүс Латыйфи. Ак-карага тимәскә.** Повесть һәм хикәяләр. Б. 90 т.

**Мәгъсүм Латыйфуллин. Сәйдәшнең балачагы.** Повесть Б. 55 т.

**Әдип Маликов. Бергә яккан учаклар.** Шигырьләр. Б. 70 т.

**Мәдинә Маликова. Фидая.** Роман. Б. 1 с. 20 т.

**Фәнил Мансуров. Агыйделкәй алкын.** Повестьлар. Б. 90 т.

**Газинур Моратов. Оча җырлар.** Шигырьләр. Б. 40 т.

**Ринат Мөхәммәдиев. Солтангалиев.** Роман. Б. 1 с. 50 т.

**Хәйретдин Мөҗәй. Сугыш язмалары.** Б. 95 т.

**Мәгъсүм Насыйбуллин. Күктән иңгән дәлил.** Повестьлар. Б. 85 т.

**Вакыйф Нуруллин. Сайланма әсәрләр.** 2 томлык. Б. 4 с.

**Газиз Нәсин. Эт койрыгы.** Хикәяләр. Б. 65 т.

**Панова В., Вахтин Ю. Мөхәммәт пәйгамбәр.** Б. 1 с. 20 т.

**Шамил Рәкыйпов. Кайдан син, Жан?** Повесть. Б. 1 с.

**Басыйр Рәфыйков. Вакыт җиле.** Шигырьләр. Б. 70 т.

**Гәрәй Рәхим. Татлы сагышларым.** Повестьлар, хикәяләр. Б. 1 с 60 т.

**Җәмит Рәхимов. Сагыш.** Повесть. Б. 25 т.

**Әхмәт Рәшитов. Иман яңартканда.** Шигырьләр. Б. 35 т.

**Габделхәй Сабитов. Урман кызы.** Хикәяләр. Б. 75 т.

**Фоат Садриев. Тозлы бал.** Пьесалар. Б. 1 с. 50 т.

**Татарча-русча сүзлек.** Б. 1 с. 80 т.

**Рәүфә Уразманова. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре.** Б. 30 т.

**Радик Фәизов. Адымнарым.** Хикәяләр. Б. 1 с. 30 т.

**Заһит Фәйзуллин. Язмыш бормалары.** Роман. Б. 65 т.

**Нурихан Фәттах. Сызгыра торган уклар.** Роман. Б. 2 с. 80 т.

**Равил Фәхретдинев. Болгар вә Казан төркиләре.** Тарихи язмалар. Б. 1 с.

**Ренат Харис. Көзге мәхәббәт.** Шигырьләр. Б. 70 т.

**Хуҗа Насретдин мәзәкләре.** Б. 1 с.

**Гали Хуҗиев. Таныш күзләр, таныш карашлар.** Шигырьләр. Б. 1 с.

**Данис Хәйруллин. Йөрәк тибеше.** Шигырьләр. Б. 30 т.

**Ризван Хәмид. Китәм инде.** Пьесалар. Б. 1 с. 50 т.

**Гарәфи Хәсәнев. Елның дүрт фасылы.** Хикәяләр. Б. 1 с.

**Нурислам Хәсәнев. Бәхилләрме йөрәк.** Повестьлар. Б. 95 т.

**Зиннур Хөснияр. Тәгәри китте язмышлар.** Повестьлар һәм хикәяләр. Б. 1 с. 10 т.

**Фаил Шәфигуллин. Өй салуның ние бар.** Повестьлар. Б. 1 с. 40 т.

**Нил Юзиев. Татар шигыре.** Тикшеренү. Б. 1 с.

**Фәнис Яруллин. Һәр күңелдә сер ята.** Пьесалар. Б. 1 с. 50 т.

**Мөдәррис Әгъләмов. Мин әйттем.** Шигырьләр. Б. 1 с.

**Әдәби мирас.** Г. Әпсәләмов, И. Гази, Г. Кашшаф һәм башкаларның истәлекләре, хатлары, көндәлекләре. Б. 80 т.

**Тәүфикъ Әйди. Елан угы.** Роман Б. 1 с. 60 т.

**Юныс Әминев. Сафура бураннары.** Пьесалар. Б. 1 с. 60 т.

**Рәшит Әхмәтҗанов. Моңлану.** Шигырьләр, поэмалар. Б. 1 с. 70 т.

**Рәшидә Җиһаншина. Күңелем түреннән.** Истәлекләр. Б. 30 т.

1991 елда болардан башка да бик күп китаплар — балалар өчен шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр, фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр, авыл хуҗалыгы, техника, сәнгать буенча тикшеренүләр, совет һәм чит ил язучыларының әсәрләре, рус телендә дисталәгән җыентыклар дөнья күрәчәк. Алар турында киңрәк мәгълүматны «Татарстан китап нәшриятының 1991 елга аннотацияле тематик планы»ннан алырга мөмкин. Сез ул план белән китап кибетләрендә таныша һәм үзегезгә кирәкле басмаларга алдан ук заказ биреп куя аласыз. Татарстаннан читтә яшәүчеләр бу «План»ны Казаннан соратып алдырырга мөмкин. Заказны Казандагы «Китап-почта» кибетенә дә җибәрергә була. Адресы: 420057, Казан шәһәре, Октябрьская урамы, 18.

*Хөрмәтле укучылар, китаплар киләчәктә сездән җыелган заказ санынча гына басылачак. Теләгән басмаларны кулга төшерер өчен заказларыгызны август-сентябрь аеннан да кичектерми бирегез!*

## ХАКЛЫК ӨСКӘ ЧЫГА

30—40 нчы һәм 50 нче еллар башында булган репрессияләргә бәйле материалларны өстәмә өйрәнү буенча КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы комиссиясенең Үзәк Комитет секретаре А. Н. Яковлев рәислегендә узган чираттагы утырышында «контрреволюцион солтангалиевче оешма»га бәйләнешле рәвештә җаваплылыкка тартылган гражданнарны реабилитацияләү мәсьәләләре каралды. ОГПУ органнары тарафыннан ясалма рәвештә оештырылган «эш» буенча, 1928 ел ахырында, Милләтләр эше халык комиссариаты коллегиясе әгъзасы М. Х. Солтангалиевкә һәм тагын 76 кешегә контрреволюцион оешмада тору турында нахак бәла ягыла. Тикшеренү чынбарлыкта мондый оешманың булмавын күрсәтә. СССР Югары Советы Президиумының 1989 ел, 16 январь Указы нигезендә, бу эш буенча ОГПУ карары юкка чыгарылды һәм шушы уңайдан репрессияләнгән гражданнар тулысынча реабилитацияләнде. Акланучылар арасында халкыбызның бик күп күренекле уллары, партия һәм әдәбият-сәнгать эшлеклеләре бар.

СССР Югары суды Пленумы М. Х. Солтангалиевне иң югары җәзага тарту турында Югары суд хәрби коллегиясенең 1939 ел, 8 декабрьдәге хөкемен юкка чыгарды һәм бу эшне, җинаять составы булмау сәбәпле, туктатты.

Бернинди нигезсез партиядән чыгарылган М. Х. Солтангалиев һәм аның «эше» буенча узган хезмәткәрләр КПСС сафларында торгызылды.

Бу турыдагы материаллар «Правда» газетасының быелгы 1 июнь санында басылды.

## ТАТАРСТАННЫҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАП

22—24 майда В. И. Ленин үзәк музееның Казан филиалында, Татарстанның 70 еллыгына багышлап, «Совет Татарстаны: тарих һәм хәзерге чор» дигән темага фәнни конференция уздырылды.

Конференциянең пленар утырышында татар халкының милли дәүләтчелеге проблемалары турындагы доклад белән КДУ профессоры, тарих фәннәре докторы И. Р. Таһиров чыкты. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры профессор М. З. Зәкиевнең доклады «Автономия һәм милли тел статусы» дигән темага багышланды. СССР Фәннәр академиясе Урал фәнни үзәгенең Башкортстан бүлеге тарих, әдәбият, тел институтыннан тарих фәннәре кандидаты В. В. Болтушкин «Совет федерациясен үзгәртеп кору — милләтара мөнәсәбәтләрне җайга салуның төп юлы» дигән теманы яктыртты.

Аннары конференция секцияләргә бүленеп эшләде. Конференция эшендә, Казан галимнәреннән тыш, союздаш һәм автономияле республикалар, Мәскәү, Горький, Свердловск һәм башка шәһәрләрнең галимнәре катнашты.

## БӨТЕНСОЮЗ ФЕСТИВАЛЕ

19 майда Чаллыда илебездәге яшьләр театрларының Дүртенче Бөтенсоюз фестивале ачылды. Ул республикабызның — 70, КамАЗның 20 еллыгына багышлап үткәрелде. Анда илебезнең төрле төбәкләреннән килгән 8 милли театр коллективы спектакльләрне туган телләрендә күрсәтте. Әрмәнстан, Молдавия, Украина, Грузия кебек союздаш республикалар вәкилләре белән бергә, тугандаш Башкортстан, Чувашстаннан килгән коллективлар да чыгыш ясады. Болардан тыш, Болгария, Польша, Канададан да кунаклар катнашты.

## ЧУВАШ ӘДӘБИЯТЫ КЛАССИГЫ ЮБИЛЕЕ

Билгеле булганча, ЮНЕСКОның егерме бишенче сессиясе карары белән, чуваш әдәбиятына нигез салучы Константин Ивановның (1890 — 1915) йөз еллыгын тантаналы рәвештә билгеләп үтү бу елның бөтендөнья календарена кертелгән иде.

22 майда Чабаксарда уздырылган тантаналы кичәдә татар шагыйре Кави Латыйп чуваш телендә К. Иванов турында чыгыш ясады. Кунаклар Иванов исемен йөрткән урам бәйрәмендә фәнни конференциядә катнаштылар, завод һәм авыларда булып, хезмәт коллективлары белән очраштылар.

## МИЛЛӘТТӘШЛӘР ЯНЫНДА

Апрель аенда язучы һәм галим Мөхәммәт Мәһдиев, Казан дәүләт университеты профессоры Т. Галиуллин, доцентлар Ф. Әгъзамов, Җ. Зәйнуллин Ульяновск телевидениесенең татар телендәге тапшырулар редакциясе чакыруы буенча борынгы Сембер җирендә кунакта булдылар.

Шәһәрдә эшләп килүче «Туган тел» җәмгыяте һәм телевидение тапшырулар комитеты беренче көнне алар белән Профсоюзлар культура сараенда очрашу кичәсе оештырды. Очрашудан соң «Чулпан» җыр һәм бию ансамбле концерты булды. Кичәдән җыелган акча тулысынча Салих Сәйдәшев һәйкәлен салу фондына күчерелде.

Галимнәр икенче көнне укытучыларның белемен күтәрү институтында өлкәдәге татар теле һәм әдәбияты укытучыларына лекцияләр укыдылар, ә кичен телевидениенең «Чишмә» программасында катнаштылар. Алар белән «Турыдан-туры элемтә» оештырылды.

## ТАТАР ГАЛИМЕ — СУОМИДА

Хельсинки университеты чакыруы буенча, 1990 елның январь-апрель айларында Казан дәүләт университеты доценты Хатип Миңнегулов Финляндиядә булып кайтты. Гыйльми командировка вакытында ул фән галимнәре белән очрашты, Фин-Угыр җәмгыяте утырышында катнашты; китапханә-архивларда татар мәдәниятенә мөнәсәбәтле күпсанлы материаллар белән танышты. Хельсинки, Тампере, Турку шәһәрләрендә яшәүче милләттәшләребез алдында татар әдәбияты тарихыннан лекцияләр укыды, аларны кызыксындырган күпсанлы сорауларга җавап бирде.

## МӨСЕЛМАН ИНСТИТУТЫ

Татарларның поляк һәм литва халыклары белән дуслыгы бик ерак заманнарга барып тоташа. Моннан алты гасыр элегрәк кыю татар сугышчылары немецларның «Тәре походы»н җиңү өчен батырларча сугышалар, Польша, Литва җирләрен дошман коллыгыннан коткарып калалар. Шуннан соң татарларга үзләре кан койган туфрактан җир бүлеп бирелә, дин тотып, үз гореф-гадәтләре белән яшәргә рөхсәт ителә. Мәсәлән, бүген Польшада гореф-гадәтләрен, динен саклап калган, төркем-төркем авылларга берләшеп яшәүче татарларны меңәрләп санарга мөмкин.

Күптән түгел Польша башкаласы Варшавада Мөселман институты ачылды. Аның инициаторы — Мөселман бердәмлеге җәмгыяте. Институт Польша һәм Литва мөселманнарының күпьяклы проблемаларын өйрәнәчәк, милләтне үстерү юнәлешендә тикшеренүләр алып барачак. Бер үк вакытта институт нәшерлек эше белән дә шөгыльләнергә исәп тота.

## БАШКОРТСТАН АССР

Башкортстанның көнбатышында урнашкан Октябрьск шәһәрен Татарстаннан Ык елгасы гына аерып тора. Биредә яшәүчеләрнең күпчелеген татарлар тәшкил итә. Күптән түгел техника йорты каршында Татар-башкорт иҗтимагый үзәге оештырылды. Бу инициативаны күтәрүчеләр арасында фән кандидатлары, инженерлар, укытучылар, врачлар, культура хезмәткәрләре бар иде. Үзәкнең оештыру комитеты рәисе итеп өлкән инженер Марсель Гарипов сайланды.

Узган елның декабрь аенда Ишембай шәһәрендә «Таң» исемле татар җәмгыяте берләшмәсе оештырылган иде. Берләшмәнең шәһәр халкына булган беренче мөрәҗәгатендә мондый фикерләр әйтелә: яңа уку елында шәһәр мәктәпләрендә татар класслары ачарга, милли мәдәниятне, гореф-гадәтләрне халыкка кире кайтарырга, барлык милләтләрнең тигез үсүе өчен бөтен мөмкинлекләрне файдаланырга һ. б.

Җәмгыять халык депутатларының Ишембай шәһәр башкарма Советының 1989 ел, 1 декабрь карары белән расланды.

## ҮЗБӘКСТАН

Үзбәкстан халкы арасында татарлар сан ягыннан өченче урынны алып тора. Биредә алар өчен культура-агарту үзәге оештырылды. Ташкентта булган оештыру конференциясендә яңа җәмгыятьнең уставы һәм программасы расланды, идарә сайланды.

Икенче ел инде татарларның «Сабантуй», «Гөбәдия», «Туган тел-туган көйләр» дигән бәйрәмнәре үткәрелә. Милли үзешчән коллективлар күбәйде, татар теле курслары оештырылды. Үзбәкстанның 35 мәктәбендә ана телендә укыта башладылар.

## КУСТАНАЙ

Өлкә радиосы программасында татар телендәге «Якташ» исемле тапшырулар яңгырый башлады. Хәзерге көндә Татарстанның 70 еллыгына багышланган тапшырулар циклы дәвам итә.

«Якташ»ны күрше Чиләбе өлкәсендә яшәүчеләр дә тыңлый.

## ТУБЫЛ

Бу якларда Арангуловларның «Ләйлә» исемле гаилә ансамбле киң билгеле.

Ансамбль оештырылган елларда ирле-хатынлы Арслангәрәй һәм Сәкинә Арангуловлар гына җырласа, хәзер балалары үсә төшкәч, программа баеды. Игезәкләр Хөсәен белән Хәсән, армиядә хезмәт итеп кайткач, Тубыл шәһәр сәнгать һәм культура училищесын тәмамладылар. Алар үзләре дә җырлар иҗат итә. Кече уллары Айвар исә армиядә солдат җырлары фестивалендә җиңеп чыкты.

## РЕДАКЦИЯ КУНАКЛАРЫ

10 майда Үзбәкстанның халык рәссамы, СССРның һәм Үзбәкстанның Дәүләт премияләре лауреаты, профессор Чыңгыз Әхмәров редакциябездә кунакта булды. Милләте буенча татар булган атаклы рәссам үзбәк һәм татар мәдәнияте бәйләнешләре турында сөйләде, күп санлы сорауларга җаваплар бирде.

Бу останың ТАССР сынлы сәнгать музеендагы үзенчәлекле күргәзмәсе казанлыларда зур кызыксыну уятты.

24 майда редакция хезмәткәрләре Төркиянең Мәрмәрә университеты профессоры Надир Дәүләт белән очраштылар. Өч сәгатькә сузылган җанлы әңгәмә вакытында, дөньяның төрле төбәкләренә таралып яшәүче татар халкын барлау һәм алар арасында мәдәни элемтәләр урнаштыру турында кызыклы сөйләшү булды.

# МӘРҖАНИ МӘЧЕТЕ

Казан шәһәренең милли архитектура истәлекләреннән аеруча әһәмиятле урынны, шөбһәсез, чын мәгънәсендәге сәнгать әсәрләренә әверелгән гаҗәеп тарихи корылмалар — мәчетләр алып тора. Шуларның берсе К. Насыйри урамында урнашкан Мәрҗани мәчете, әлбәттә.

Мәгълүм булганча, 1552 елда Явыз Иван яулап алганнан соң Казандагы барлык мәчетләр диярлек хәрабәгә әйләндерелә. Аннары ике гасырдан артык татарларның тарихи мәркәзендә ислам динен тотучылар өчен берниндн дә гыйбадәт корылмасы салырга рөхсәт ителми. Әмма XVIII йөзнең яртысында мәмләкәттә сәяси хәлләр шактый үзгәрә. Сыйнфый хәрәкәтнең куәтле ташкынына көчле милли азатлык дулкыны да килеп кушыла. Көрәш манзарасына дини төсмер дә өстәлә. Хакимият дилбегәсенең кулдан ычкынуыннан шүрләгән патша хөкүмәте мөселман халыкларына берникадәр ташламалар ясарга мәҗбүр була.

1767 елда Казанга Екатерина Икенче килә (халкыбыз теленә Әби патша булып кергән). Форсаттан файдаланып, Казан татарлары аңардан шәһәрдә таш мәчет салырга рөхсәт сорыйлар. Рөхсәт бирелә. Каюм Насыйри раслаганча, Әби патша мәчет урынын хәтта үзе билгели. Патша хәзрәтләре кире уйлый күрмәсен дип, Аксак Каратунның вәхшиятен үз җилкәләрендә татыган мөселманнар дәррәү эшкә керешәләр. Ул гына да түгел, берьюлы дип әйтерлек ике мәчеткә нигез салына.

Хәзерге Мәрҗани мәчете салынып бетәр-бетмәс, җирле урыс түрәләре гауга күтәрәләр: мөселман мәчетенең манарасы православие чиркәве гөмбәзеннән биегрәк ләбаса! Моны болай калдырырга ярыймы соң! Әби паштага шикаять җибәрелә: «гаделсезлек» кичекмәстән төзәтелергә тиеш. Ләкин Екатерина да аптырап калмый, шау-шу күтәрүчеләргә: «Мин мөселманнарга урын микъдарын җирдә билгеләдем, әмма күккә никадәр чыгарсалар да, ихтыярлары, күк минем милкемдә түгел»,— дип җавап бирә.

Шулай итеп, 1770 елда Казанның Иске Бистәсендә (1552 елдан соңгы вакытта) беренче таш мәчет — хәзерге Мәрҗани мәчете калкып чыга. Янәшәсендә шул ук чорларда Апанай мәчете дә пәйда була. Без бирелә сүз алып бара торган гыйбадәт йорты элек «Иске таш мәчет», «Беренче мәхәллә мәчете», аннары «Юнысов мәчете» дип йөртелә, соңыннан биредә 1867—1881 елларда имамлык кылган Шиһабетдин Мәрҗанигә нисбәтән «Мәрҗани мәчете» исемен ала.

Ш. Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») дигән мәшһүр хезмәтендә бу мәчетне бер генә кеше салдырмаганлыгын, аның өчен 62 кешедән җыелган 5 мең сум акча тотылганын күрсәтеп үтә.

Мәрҗани мәчете, вакытлар үткән саен искерү-тузу сәбәпле, аерым мөлкәт ияләре, шәхесләр тарафыннан күп тапкырлар (1795, 1797, 1833, 1863, 1885, 1887 һ. б. елларда) төзәттерелә, төзелешенә үзгәрешләр кертелә, бизәлә, рәшәткәләр белән әйләндерелеп алына. Мәсәлән, 1863 елда мәчетнең михрабын берникадәр көнчыгышка юнәлдерә төшеп, биегәйтеп һәм киңәйтеп, бер тәрәзә куеп эшләткәннәр. Берничә ел үткәч, бинаның алдыннан канат чыгарып, озынлыкка бер тәрәзә арттырганнар һәм баскыч бүлмәсен таштан кордырганнар. 1885 елда Зәйнулла бине Госман тарафыннан манарасы ныгытылып, мәчет яңадан бина кылына, 1887 елда азан әйтә торган мәйданчык тимер рәшәткә белән уратыла. Хәзер мәчет, нигездә, үзенең 1887 елдан соңгы күренешен саклый.

Мәчет кыйблага — Мәккә тарафына юнәлтелгән михрабка ия турыпочмаклы мәһабәт бинадан гыйбарәт. Традицион яшел түскә буялган дүрт кыеклы түбәгә сигез кырлы манара утыртылган. Аның җир өстеннән биеклеге — 30 метр. Манараның өске өлешендә мөселманнарны биш вакыт намазга өндәүче мөәзин өчен зур булмаган мәйданчык эшләнгән. Мәйданчык өстендә дә беркадәр дәвам иткәннән соң, манара кәүсәсе күккә ашу символы булган берничә кырлы шпиль белән очлана. Шпильне алтынга манчылган шар һәм аңа конус сыман нигезе белән таянган ярымай бизи.

Белгечләрнең раславынча, бинаның бизәлешендә милли нәкыш элементлары өстенлек итә. Мәчетне салган татар осталары эчке зиннәтләү эшләрендә болгар-татар сәнгатенә хас йөзем тәлгәшләре, лалә чәчәге һәм башка үсемлекләр сурәте кулланганнар.

Бинаның әһәмияте бүгенге көндә аның архитектура һәйкәле булуы белән генә чикләнми. Мәчет — бер үк вакытта татар халкының матди һәм рухи байлыгының гәүдәләнеше, аның фаҗигале вә гыйбрәтле тарихының чал шаһиты да.

**Равил Әмирхан,**
тарих фәннәре кандидаты.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле әдип, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Мөхәммәт Мәһдиев.

**Ю. Филимонов** фотолары.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1991 ЕЛДА

Журналыбыз киләсе елда да укучыларны татар язучыларының иң яхшы әсәрләре белән таныштырып барачак. Редакциябез хәзинәсендә халкыбызның үткәнен һәм бүгенге тормышын гәүдәләндергән, замандашларыбыз күңелен кузгатырлык шәхесләрне һәм вакыйгаларны сурәтләгән түбәндәге кызыклы роман һәм повестьлар бар:

**Гариф Ахунов.** Гомер юлы (Сукырлар арасында). *Роман.*
**Гомәр Бәширов.** Онытма. *Повесть.*
**Батулла.** Сөенбикә. *Тарихи роман.*
**Аяз Гыйләҗев.** Йәгез, бер дога. *Повесть.*
**Гаяз Исхакый.** Көз. *Повесть. (Әдәби мирастан).*
**Ринат Мөхәммәдиев.** Солтангалиев. *Роман.*
**Атилла Расих.** Кәгазьдәгеләр һәм хәтердәгеләр. *Роман.*
**Фоат Садриев.** Таң җиле. *Роман.*
**Гурий Тавлин.** Афәт. *Роман. 2 нче китап.*
**Нурихан Фәттах.** Хыял вә хаят. *Роман.*
**Мәгъсүм Хуҗин.** Чөй. *Повесть.*
**Миргазиян Юныс.** Бөркетләр кыясы. *Повесть.*

Редакция өйрәнә башлаган һәм киләчәктә тәкъдим итәргә ниятләгән әсәрләр арасында бүтән әдипләребезнең дә романнары, повестьлары һәм хикәяләре, шагыйрьләребез, драматургларыбызның яңа пьесалары һәм поэмалары бар. Журнал битләрендә әдәбиятыбыз һәм сәнгатебез үсеше, тарихи үткәнебез, туган телебез һәм гореф-гадәтләребез язмышы, Татарстанның матди һәм иҗтимагый тормышы, милләтебезнең киләчәге турында кайнар фикер алышу көтелә. Бу мәсьәләләрне тикшерүдә галимнәребез һәм җәмәгать эшлеклеләребез дә актив катнашачак.

**«Казан утлары»ның Бөтенсоюз каталогындагы индексы — 73210. Аңа Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә чикләнмәгән күләмдә язылырга мөмкин. Бәясе — бер елга 10 сум 80 тиен.**

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)